ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1989

*Журналның 800 нче сан*



*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм*
*Татарстан АССР*
*Министрлар Советы карары*

# 1989 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1989 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирергә:

1. **Надыйров** Илбарис Нурислам улына (җитәкче), **Әхмәтова** Флора Ваһап кызына, **Җамалетдинов** Ленар Шәйхи улына, **Мәхмүтов** Хуҗи Шаһиәхмәтов улына һәм **Ярмөхәммәтов** Хәмит Хөснетдин улына (үлгәннән соң)—12 томлык «Татар халык иҗаты» фәнни җыелмасы өчен.

2. **Вәлиуллин** Хөснулла Вәлиулла улына — композитор, «Самат» операсы, «Еллар үтә» исемле соңгы елларда иҗат ителгән җырлары җыентыгы өчен.

**КПССның Татарстан**
**өлкә комитеты**
**секретаре**
**Г. И. УСМАНОВ**

**Татарстан АССР**
**Министрлар Советы**
**Председателе**
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

6

(800)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


М. МӘҺДИЕВ. **Татар журналлары** . . . . 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ә. БАЯНОВ. **Аллаларны бәреп төшердек без...** *Шигырьләр* . . . . 11

Г. РӘХИМ. **Кулга-кул тотынып.** *Шигырьләр* . 15

Ф. ЯРУЛЛИН. **Көрәшләрдә билләр чыдарлык.** *Шигырьләр* . . . . 18

М. ХӘБИБУЛЛИН. **Илчегә үлем юк.** *Роман* . . 22

А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ

А. С. ПУШКИН. **Мәгъдән базларында...** *Шигырьләр* . . . . 90

А. АХМАТОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

А. АХМАТОВА. **Юатырга теләп...** *Шигырьләр* . 91

ВЕНГР ШАГЫЙРЕ — «КАЗАН УТЛАРЫ» КУНАГЫ

КАРОЙ ЧЕХ. **Алтын-көмеш.** *Шигырьләр* . 92

Б. КАМАЛОВ. **Узган гомер бигрәк җәл.** *Повесть* . . . . 94

1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

Р. МИҢНУЛЛИН. **Ялгыз калгач.** *Шигырьләр* . 125

ӘДӘБИ МИРАС

И. НУРУЛЛИН. **Макталган һәм тапталган әдип** . . . . 128

Г. ИСХАКЫЙ. **Башкорт бәхете.** *Хикәя* . . . 129

Ә. ӘХМӘДУЛЛИН. **Гаяз Исхакый әсәрләренең исемлеге** . . . . 135

Х. ТУФАН. **Төрле еллардан.** *Шигырьләр* . . 139

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ХӘСӘНОВ. **АЭС салды хафага** . . . . . 143

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. **Тукай ~~яшен узганда~~** . . . . . 156

УКУЧЫ СҮЗЕ

Р. ВАХИТОВ. Дуслыкның бөек көче . . . . 166
А. ИБРАҺИМОВ. Ак тапларны киметә . . . 167
М. МИНАЧЕВ. «Без дә хакның бәндәсе» . . . 169

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Л. ИХСАНОВА. Язмыштан узмыш бармы? . . 170

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Америка галиме татарлар турында . . . . . . . . . . . . . . 172
Җ. МИҢНУЛЛИН. Утызынчы елларда... . . 178

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Н. АРСЛАНОВ. Яшь дустым Фаил . . . . 182

ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Р. ГЫЙЛӘҖЕВ. Гөслә һәм ятаган . . . . 184

Журналыбызны кайда күпме алдыралар . . 188
Бер сорауга — бер җавап . . . . . . . . . 138
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . 190
М. Хөсәен сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы. Сәйдәш моңнары. Җыр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Юбилейный — 800-й номер журнала открывается статьей писателя и ученого М. МАГДЕЕВА, в которой рассматривается история татарских журналов — предшественников «Казан утлары».
«Проза и поэзия»: начало романа М. ХАБИБУЛЛИНА «Послу нет смерти», повесть Б. КАМАЛОВА «Прошедшее не вернуть». Стихи А. БАЯНОВА, Г. РАХИМА, Ф. ЯРУЛЛИНА.
К 190-летию А. ПУШКИНА и 100-летию со дня рождения А. АХМАТОВОЙ публикуются новые переводы на татарский язык. В журнале представлены также стихи венгерского поэта КАРОЙ ЧЕХА.
1 июня — Международный день защиты детей — стихи Р. МИННУЛЛИНА.
В рубрике «Литературное наследие» впервые за последние полвека публикуется рассказ известного писателя начала XX столетия Г. ИСХАКИ «Счастье башкира». В статьях профессоров И. НУРУЛЛИНА и А. АХМАДУЛЛИНА освещаются некоторые аспекты творчества и сложного жизненного пути писателя-эмигранта, приводится библиография произведений писателя.
Х. ТУФАН — «Стихи разных лет».
«Публицистика»: М. ХАСАНОВ. «Страсти вокруг АЭС».
В рубрике «Литературная критика» публикуется статья М. ВАЛИЕВА «Молодые — в возрасте Тукая»; рецензируются книга Т. Айди «Волшебная сила» и повесть Н. Гиматдиновой «Госпожа моя».
«К истории культуры»: статья А. КАРИМУЛЛИНА «Американский ученый об истории татарского народа» и статья З. МИННУЛЛИНА «В тридцатые годы».
К 50-летию Ф. Шафигуллина. Статья Н. АРСЛАНОВА «Мой юный друг».
«Татарские музыкальные инструменты»: Р. ГИЛЯЗОВ. Гусли и ятаган.
Любителям музыки предлагается текст и ноты новой песни М. ХУСАИНА и А. БАКИРОВА «Мелодии Сайдаша».
Дневник культурной жизни, интервью о журнале, объявления.

*Баш редактор урынбасары* Рашат Низамиев, *җаваплы секретарь* Флүс Латыйпов.
*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 03.04.1989 ел. Басарга кул куелды 25.05.1989 ел. ПФ 02097. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ Б-162. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ТАТАР ЖУРНАЛЛАРЫ

### «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ 800 НЧЕ САНЫ ЧЫГУ УҢАЕННАН

Бу уш урында берни дә барлыкка килә алмый: «иске, черек тормышны җимереп, без яңа якты тормыш корырбыз» дигән канатлы җыр белән сак эш итәргә кирәк. Чөнки мәшһүр «Интернационал» җыры (1871) бар. Анда коллык дөньясын җимерү турында гына сүз бара. Шуны җимереп, яңа, иркен дөнья төзү кирәклеге әйтелә.

Без байтак җимердек. Татарның беренче әдәби журналлары — бүгенге «Казан утлары»ның башлангычы булган «Шура», «Аң» журналларын буржуаз, милләтче, панисламист, пантюркист дип бөтенләй пычратып бетергән хәсрәт «галимнәребез» әле дә исән, исән генә түгел, алар әле һаман трибунада. Алар хәзер безгә «үзгәртеп кору»ның кирәклеге турында акыл өйрәтәләр. Ә журналистика, әдәбият тарихында «Шура»лар, «Аң»нар яши. Аралар ераклашкан саен бу журналларның тарихи әһәмияте тагын да ачыграк күренә бара: Риза Фәхретдинев, Габдулла Тукай, Җамал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Әхмәтгәрәй Хәсәни, Закир һәм Шакир Рәмиевләр эшчәнлегеннән башка журналистика һәм әдәбиятыбыз тарихын күз алдына китереп кара!

Безнең әдәбиятчы-тарихчыларыбыз арасында (барысын да галим дип әйтергә тел бармый) сталинизм чорында бер тенденция туды: тарихи фактларны аерым кысаларга бөкләп тыгып, аларны үз концепцияңә буйсындыру, бәя бирү. Бу зарарлы юнәлеш торгынлык елларында да дәвам итте. Ә бит тарихи фактлар аерым кешеләрнең бәясенә мохтаҗ түгел. Лев Гумилев хаклы: тарихчы фактларны ачып, күрсәтеп бирергә генә тиеш. Бәяне заман, тарих үзе бирә. Илле ел элек без күкләргә чөеп мактаган шәхесләр, зур вакыйгаларга бүгенге заман, тарих үзе һич тә без көтмәгәнчә бәя биреп ятмыйммыни? «Искеләр» бит шуңа борчыла, шуңа «теге заманны» сагына, тыпырчына...

Әйе, «Шура»быз, «Аң»ыбыз бар иде. Безне уйлый белергә, тормышка фәлсәфи караш ташларга өйрәткән акыллы, тирән «Шура»быз, безне матурлыкка-нәфасәткә карый белергә өйрәтә башлаган «Аң»ыбыз бар иде. «Шура» — фарсы сүзе, «киңәш» мәгънәсендә. Совет властеның беренче елларында безнең республиканы «Шуралар җөмһүрияте» (Советлар республикасы) дип йөртәләр иде әдәбиятта.

Миңа бу мәкаләмне язганда 1926 елда Казанда басылып чыккан «Вакытлы татар матбугаты» исемле альбом-энциклопедия ярдәмгә килә. Аны библиограф Исмәгыйль ага Рәмиев чыгарган. Башка халыкларда булса, моны кабат басарлар, тулырак итеп эшләрләр һәм тагын бер кат басарлар иде. Без — юк. Без утызынчы елларда ук инде мирасның кадерен белмәскә өйрәнеп калдык. Хәзер шуны рәхәтләнеп дәвам итәбез. Без эшләмәгәнне читләр эшли. Әнә шул ук эшне — Россия империясендәге төрки вакытлы матбугат тарихын белешмәлек рәвешендә Франция галимнәре А. Беннигсен һәм Л. Келькеже алтмышынчы елларда эшләп чыгарганнар иде. Мин ул хезмәтне конспектлап чыгар өчен махсус рәвештә шуңа җитәрлек дәрәҗәдә француз теле өйрәндем. И. Рәми һәм француз галимнәренең бу хезмәтләре — минем көндәлек өстәл китапларым. Аларда фактик мәгълүмат тупланган. Бәя бирү белән мин кызыксынмыйм. Әнә Исмәгыйль ага да, утызынчы елларга таба кретерийларның кая табарак авышканын сизеп, нинди калын, саллы «Шура»га альбомында ярты биттән аз гына артык урын биргән — пролетарий матбугаты түгел бит...

«Шура»ның беренче саны 1908 елның 10 гыйнварында Оренбургта дөнья күрә. Наширләре (издательләре — ягъни финанс расходларын үз өсләренә алучылар) — Закир һәм Шакир Рәмиевләр. Журнал «Вакыт» нәшриятында басыла (анысы да Рәмиевләрнеке). Журнал үзен фәнни, гыйльми, тарихи журнал дип тәкъдим итә. Чыннан да,ниләр генә юк анда! Дин, мәчетләр тарихымы, мәшһүр кешеләрнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында зур күләмле мәкаләләрме, әдәбиятка, эстетикага кагылган фәлсәфи фикерләрме, тарихмы, атом теориясе яки бөек рус әдәбияты, язучылары турында-

гы мәкаләләрме — «Шура» үз заманының энциклопедиясе ролен үтәгән. Хәер, энциклопедиясез татар (китапханәгә кереп гарәп хәрефендәге журналларны актарырлык сәләте булган филолог-тарихчылар) өчен ул әле дә энциклопедия хезмәтен үти. «Шура» — татар журналлары арасында иң даими матбугат органы. Аның төпләнмәләрендә без еллар, вакыйгалар алмашынуга карап бер чиктән икенче чиккә таба сикерүләр күрмибез. Беренче саннарыннан алып нинди рубрика ачкан булса, тугыз ел буена (1918 елның гыйнварына кадәр) шуларны алып бара. И. Рәми эшләгән схема буенча «Шура»ның менә мондый бүлекләрне даими алып барганлыгы күренә. 1. Мәшһүр адәмнәр вә олугъ хадисләр; 2. Мәкаләләр; 3. Диннәр хакында нәзарият (теоретик мәгълүмат); 4. Дини мәсьәләләр; 5. Тәрбия вә тәгълим (өйрәтү); 6. Хифзыссыйхәт (гигиена); 7. Асаре гатикага гаид (археологиягә, борынгы истәлекләргә кагылышлы); 8. Әдәбият; 9. Әшгар (шигырь); 10. Хикәя; 11. Тәкъриз вә интикад (язылган әсәргә мактап бәя бирү һәм тәнкыйть); 12. Мөрасәлә вә мөхаварә (хат язышу һәм әңгәмә); 13. Хәвадис (вакыйгалар); 14. Матбугат хөласасы (йомгаклары); 15. Матбугъ әсәрләр (басылып чыккан); 16. Мөтәнәүвига (төрлесеннән, «аннан-моннан» бүлеге); 17. Ләтаиф (анекдотлар); 18. Гыйбрәтле сүзләр; 19. Табышмаклар; 20. Идарәгә мәктүбләр (хатлар); 21. Идарәдән җаваплар.

Библиограф И. Рәми, заман критерийларына яраклашып, бу рубрика эчендә «бик тә эшкә яраксыз, мәгънәсез материаллар да бар иде» дип билгели. Шулай әйтми хәле юк, чөнки белешмәнең башында ук кисәтеп куя: «Моның мәсләге турында сүзне озынга җибәрмичә, милли либераллык юлы белән динчелекне бергә алып барган һәм милли энциклопедия тибындагы журнал дисәк, шаять аңлашылыр». Шул ук вакытта белешмәлектә журналның иң популяр булуы, «технический ягыннан, һичшиксез, беренче урынны тотуы» турында әйтелә.

«Альбом»ны бүген яңабаштан тезесәк исә, менә нәрсәләргә игътибар ителми калмас иде: беренчесе — журналның редакторы Риза Фәхретдинев шәхесе турында. Аның үз эшенә фанатикларча бирелгән, халкына хезмәт итү юлында үзен-үзе аямаган зур эрудицияле, ләкин гадәттән тыш тыйнак табигатьле шәхес икәнен күрер идек. «Шура» редакторы Р. Фәхретдинев иҗаты бездә әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Өйрәнсәк, гаҗәп хәлләр күрер идек: редактор үз журналының битләрендә үзен тәнкыйть иткән мәкаләләргә урын бирә; Тукайның иң затлы, тирән фәлсәфи шигырьләрен («Иһтида», «Читен хәл», «... га» (шома тормыш...), «Сайфия» кебек — иң авыр, саллы шигырьләрен журналында бастырган редактор, үзе турында; «Минем шигырь өлкәсендә мәгълүматым бик түбән»,— дип әйтә ала. Игътибар итик: үзенә карата мондый хөкемне В. И. Ленин гына чыгара алган: экспрессионизм, кубизм, футуризм кебек «изм»нарны, дигән Ленин, аңламыйм. Хәзер әйтәләр: Ленин дәүләт җитәкчеләреннән әдәбият-сәнгатьнең кайбер күренешләрен аңламаучыларның соңгысы булган. Икенчедән, «Шура» журналында без татар әдәби-эстетик фикернең беренче чаткыларын, әдәби тәнкыйтебезнең нигез ташларын аерып алыр идек: бу юнәлешнең башында, әлбәттә, Риза Фәхретдинев тора. Өченчедән, бу журналның без татар халык акылының җәүһәрләре сандыгы икәнен ачар идек. Журналны битләп, санлап өйрәнгәндә мин аннан бик күп канатлы сүзләр, афоризмнар күчереп алдым, байтак мәзәк җыйдым. Г. Ибраһимов исемендәге институт чыгарган «Татар халык иҗаты» дигән күптомлык хезмәтнең «Мәзәкләр» китабына «Шура»дан бик күп мәзәк керде. Алтмышынчы елларда мин аларны «Чаян»да бастырган идем, фәнни аңлатмада алар «Чаян»нан дип күрсәтелгән.

«Шура» журналында — татар халкының акылы, үткән юлы, тарихы. Без бит моңарчы «Татарстан АССР тарихы»н яздык, борынгы Урарту дәүләте казылмаларында нинди ташлар табылса, бездә дә шуларны табарга тырыштык. Кондратий Булавин, Степан Разин восстаниеләре көнәнә туры килерлек параллель вакыйгаларны үзебездә табарга омтылдык, гел параллель эзләдек. Нәтиҗәдә, татар тарихы язылмыйча калды, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри хезмәтләрендә моңа ишарәләр, юнәлешләр бирелеп кенә калды. Болгар тарихчыларының хезмәтләре безгә килеп җитмәгән булып чыкты, ә соңрак заман тарихчыларының (мәсәлән, Г. Әхмәрев һ. б.) зур бер халыкның тарихын сөреп чыгарга көчләреннән килми иде. «Шура»да — тарих. Халык тарихы. Моны, «Шура»ның бу хәзинәсен, алтмышынчы еллардагы «язгы җылылык» («оттепель») чорында Казан университетының тарихчы, әдәбиятчы галимнәре сизеп-тоеп алдылар. Шул җылылык чорында университет студенты М. Госманов диплом эше итеп «Шура»ның библиографиясен дә төзегән иде. Ул библиография инде аерым китап булып нәшриятта җыелып, корректурасы да килгән иде. Безнең кулыбызда бүген нинди зур белешмәлек буласы иде ул китап чыккан булса. Ләкин «перестраховщик» җитәкчеләр моны чыгармый калдылар. Аның бердәнбер корректурасы тегәрҗеп белән төпләнгән көе кайдадыр, кемдәдер саклана, минем аннан файдаланганым бар...

«Шура» журналы һич тә, утызынчы-кырыгынчы елларның тәнкыйтьчеләре сүккәнчә, буржуаз журнал түгел. Хәер, матбугат органына карата андый тамга бүген ничегрәк яңгырый икән әле ул? «Йолдыз», «Вакыт», «Кояш», «Аң», «Бәянелхак» — буржуамы? Аларда Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, М. Гафурилар хезмәт итсәләр дә «буржуа»мы? «Шура» күп сүгелде. Алда әйткәнебезчә, аны сүккән галимнәр әле исән. «Шура» журналына башкачарак — объективрак мөнәсәбәтне без беренче башлап «җылылык» елларында язылган М. Гайнуллин һәм Р. Нәфыйков хезмәтләрендә сиздек.

Инде башка заман килде.

Инде «Шура» битләрендә (миллионерлар, капиталистлар органы!) Ш. Камалның

«Акчарлаклар» әсәренә реклама бирелүе турында да сөйләргә мөмкин. Татар прозасының нигезен тәшкил иткән «Диңгездә», «Иөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм» (Г. Ибраһимов), «Уяну», «Әүвәл-әүвәл заманда», «Буранда» (Ш. Камал) кебек әсәрләренең нәкъ менә «Шура» битләрендә басылып чыгуы һич тә очраклы булмаса кирәк. «Шура» Октябрь революциясенә кадәрге татар әдәбияты, әдәби-эстетик фикере үсешенең төп үзәге булды. Журнал бүген без өйрәнергә тиешле яки әле генә өйрәнә башлаган бик күп мәсьәләләрне кузгатты, үз укучылары белән җанлы әңгәмә алып барды. Арадан берсе анкеталар аркылы иде. 1909 елда журнал үзенең укучыларыннан яраткан әсәрләрен санап бирүне үтенә. Бу чорда әле Г. Ибраһимов, Ш. Камал прозасы башлангыч адымнарын гына ясый, әлбәттә инде, күпчелек Г. Исхакый әсәрләрен атый. Г. Исхакый әсәрләре турында журналда күп санлы мәкаләләр, бәхәсле фикерләр басыла. Мәсәлән, аның «Тормышмы бу?», «Ике йөз елдан соң инкыйразмы?» әсәрләре турында күп санлы укучылар фикерләре, М. Мәрҗани, Г. Ибраһимовларның зур күләмле мәкаләләре шунда басылган. Г. Ибраһимовның «Әдәбият агымы» исемле күләмле мәкаләсендә (1911 ел, 22 сан) Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйразмы?» әсәренә искиткеч зур бәя бирелгән.

Журналда Р. Фәхретдиневнең үз хезмәтләре аеруча әһәмияте, күтәргән мәсьәләләренең перспективалы булуы белән аерылып торалар. Энциклопедист галим буларак, редактор Р. Фәхретдинев һәрвакытта да документальлек, биография-библиография мәсьәләләрен беренче планга чыгара. Ул басылган әсәрләргә генә түгел, әлегә басылмаган, кайдадыр тарих тузаны астында билгесезлектә яткан хезмәтләргә дә игътибар юнәлтә. «Язылганын ишеткән идек, басылганы мәгълүм түгел» — менә редактор Р. Фәхретдиневнең эзләнүче тарихчыларга юнәлеш бирүе. Гарәп телендә, ди ул, гүзәл телдә, Мәрҗанигә хас стильдә Г. Курсави биографиясе язылганын беләбез. Әмма ул басылып чыкмаган. Ул кайда икән? Ә менә Ильяс мирза Бораганский нәшрияты (Мәскәү) 1909 елда «Гогольнең тәрҗемәи хәле»н рәсеме белән бастырып чыгарган булган, ул нәрсә мәгълүмме? («Шура», 1915, 2 сан). Журналда Р. Фәхретдиневнең гарәп шагыйрьләре, гомумән, шигырьләр хакындагы, Мәгарри, Акмулла, Исм. Гаспринский, Тукай, Ш. Мәрҗани турындагы фикерләре, мәгълүматлары — бүген өйрәнүчеләрне көтеп ята торган бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Журнал Россия империясенең төрле чикләрендә яшәүче татарлар турында зур мәгълүмат бирә, аның битләрендә Польша, Литва татарлары турында еш языла (Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими). Бөек рус язучыларына игътибар белән беррәттән (Гоголь, Толстой), журнал даими рәвештә төрек әдәбияты белән таныштырып бара, гомумән, Төркиядәге иҗтимагый-сәяси, әдәби-эстетик фикер үсеше турында күп яза. Кызганычка каршы, бүген без, әдәбият фәнебез күпме генә алга киткән булмасын, Төркия әдәбияты турында ләм-мим, хәбәрсез. Бу хәл, әлбәттә, безне бизәми. Заманында Р. Фәхретдинев, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими, Ф. Әмирханнар төрек әдәбиятының һәр сулышын тоеп, аның прогрессив казанышларын иҗатларына сеңдереп яшәгәннәр. Безнең әдәбият галимнәре әле дә булса утызынчы ел кысаларыннан — тар күңеллелектән ычкына алмыйлар. Дөресе — ычкынырга көчләре җитми!

«Шура» шулай татар аңын дер селкетеп, баетып, уйларга, бәхәс итәргә, хыялланырга өйрәтеп, динне дә, сыйныфларны да сүкмичә, ләкин наданлыкка, фикер торгынлыгына каршы көрәшеп тугыз ел буе шау итеп яшәп алды. Яңа совет әдәби журналына җирлек хәзерләп, 1918 елның башында соңгы санын чыгарды да сыкранусыз, күз яшьсез, каргаусыз гына яңа дәүләт — Совет җөмһүриятенең законына буйсынып, туктап калды. Заманында «Шура» барлык татар язучылары өчен дә осталыкка өйрәнү мәктәбе булды.

«Шура» традицияләренә нигезләнеп, шуңа ышыкланып 1912 елда Казанда әдәби-эстетик журнал «Аң» туган иде.

«Аң» — Г. Тукай, Ф. Әмирхан тудырган чын мәгънәсендәге әдәбият-сәнгать журналы. Аның наширләре Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм Зәйнәп Хәсәни. Журнал аларның «Гасыр» нәшриятында басыла. Журналның юнәлеше хакындагы идея кайчан ничек тууы, моны оештыру буенча алдан нинди әзерлек эшләре күрелүе турында соңгы еллар матбугатында байтак материал күренде. Кабатлап шунысын әйтик: «Шура» — авыр, салмак журнал. Р. Фәхретдинев тә бик таләпчән, абруйлы кеше. Аны Россиядә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә дә беләләр, таныйлар. Шуның өстенә ул еракта — Оренбургта чыга. «Шура»га үтеп керү, ай-һай, авыр. Әнә аңа ерак Бохарадан Һ. Такташ та шигырь җибәреп карый, ләкин кая ул! Журнал битләрендә бит Р. Фәхретдинев, Җ. Вәлиди, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Кәрими, Й. Акчура, З. Рәмиев (Дәрдмәнд) кебек эре фигуралар кылыч уйната. Ә Казан яшьләре? Бераз җиңелрәк, үтеп керердәйрәк, диннең, татар-төрки тарихының теш үтмәс катлаулы мәсьәләләреннән бераз гына азат булган әдәбият-сәнгать журналы чыгару кирәк түгелме икән? Акчага бай ирлехатынлы Хәсәниләрне Г. Тукай, Ф. Әмирхан шуңа этәрәләр. Европача тәрбия алган Әхмәтгәрәй Хәсәни моңа күнә. Булачак журналга исемне дә әлеге ике идеолог — Тукай, Әмирхан бирәләр. Тукай журналның беренче саны өчен махсус шигырь дә яза: Бишенче ел революциясе белән уянып, татар укымышлылары бик күп газета-журнал чыгара башлаган иде. Аларның төрлесе булды: файда китергәне дә, зарар китергәне дә. Тукай — зирәк кеше. Яңа журналга багышлап язган шигырендә ул, теге елларга бәя биреп, болай ди:

*Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек, булсын кабул...*

һәм яңа шартларда, яңа революцион күтәрелеш һавасында шагыйрь я ң а журнал күрергә тели.

*Утте инде, дусларым, ул үткән эш, ни булса ул;*
*Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән.*

Журнал үз тирәсенә бик тиз авторлар коллективы туплый. Монда Тукайның иң соңгы шигырьләре урын ала. Болар Тукай үзе бераз яшәп киләчәктә мәҗмугасын үзе төзегәндә дә бер дә шиксез шунда урын алырлык әсәрләр: «Шиһаб хәзрәт», «Толстой сүзе» (2), «Толстой сүзләре», «Хәстә хәле», «Даһигә», «Буш вакыт», «Мәктәп», «Кыйтга» (көчләремне...) кебек шигырьләр. «Аң» журналы битләрендә Тукай гомеренә йомгак ясый һәм халкы белән хушлаша. Күз яшьсез. Горур хушлаша.

Журналның бөтен күтәренке-эстетик пафосы, әдәбият белән сәнгатьнең консолидациясенә омтылышы Г. Ибраһимовның шул еллардагы иҗат манерасына туры килә. Хәер, журналга секретарь булып урнашкач, журналның әдәби-эстетик йөзен билгеләүгә аның иҗаты зур тәэсир ясый. «Аң»да Г. Ибраһимовның күтәренке-романтик (реализмга тартым) «Табигать балалары», «Көтүчеләр», «Мәрхүмнең дәфтәреннән» әсәрләре басыла.

Татар яшьләренең иҗтимагый-эстетик-әдәби фикерләре киерелеп-кысылып актык чигенә җиткән, дөньяда зур үзгәрешләр көткән бер чор бу. Заман, иҗтимагый тәртипләр, мохит яшьлеккә кыса, изә. Яшьлек иреккә ыргыла. «Аң»ның бу юнәлешенә Оренбург яшьләре дә игътибар итә. «Шура»да яки «Вакыт»та мәшәкатьсез генә басыла алса да, Ш. Камал «Аң»га «Көзге яңгыр астында» дигән хикәясен юллый. «Аң»да Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында сурәтләнгән тар татар тормышына протест яңгырый, авыздашлык чагылыш таба. Г. Газизнең журналда бу роман турында киң планлы тирән фәлсәфи мәкалә язып чыгуы (1913, 11 сан) һич тә очраклы түгел. Журнал тирәсендә Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнан торган «өчлек» барлыкка килә. Г. Тукай белән Г. Ибраһимов арасындагы әдәби-эстетик фикер каршылыклары бик нык булуга карамастан, кысылган татар мохитендә бу өч кеше журналны ялтыраталар. Ф. Әмирханның бөтен иҗаты өчен хас булган төп темасы — яшьлекнең кадимилеккә протестын нигез итеп алган, искелектән көлгән хикәяләре — «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы», «Танс кичәсе», «Сәмигулла абзый», «Салихҗан карый» романтик уйчанлык, өзгәләнү, эзләнү хисләренә корылган «Бер хәрабәдә», «Сүнгәч», «Яз исереклегендә» кебек хикәяләренең шушы журналда басылуы бик табигый. «Аң» — әдәби журнал буларак, нәкъ менә Ф. Әмирхан иҗатына туры килә. Журналга яшь артист, башлап язучы К. Тинчурин да килеп керә: аның «Хәкимҗан агай», «Ак чирбик», «Юбилей» хикәяләре шунда басыла. Булачак «Мәрҗәннәр» авторы шулай беренче чирканыч ала, язган әлеге хикәяләре, әлбәттә инде, «Шура»га үтмәс иде.

Югарыда күрсәтелгән авторлардан тыш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Гали Рәхим, С. Рахманколый, Г. Алпаров, М. Гафури, Г. Кәрәм, М. Хәнәфи, Ф. Агиев, Г. Рәфикый, Ш. Әхмәдиев, С. Сүнчәләй, Х. Кәрим, В. Җәләл, Г. Шәрәф, Н. Хәлфин, М. Фәйзи, М. Гали, һ. Атласи, Н. Думави, Фәрид Ибраһимов, Габдулла Харис, Габдрахман Сөнгати, Җ. Вәлиди, Гыйффәт туташ, Шәһәр Шәрәф, Садри Җәләл, Заһид, Нуркин, Н. Исәнбәт һ. б. яшьләрнең әсәрләре басыла.

Журнал: «Сәнгать, нәфасәт, хосусән, рәсем мәсьәләсе җитди рәвештә куелып, бердән бу хакта нәзари бәхәсләр булачак, икенчедән, мәшһүр җиһан булган Рафаэль, Микеланджело, Леонардо да-Винчи, Рембрандт, Репин кебек даһиларның сәнгатьләреннән нәмүнәләр (үрнәкләр) биреләчәк һәм милли тарихымыз, милли хәятымыз, милли каһарманнарымыз вә мөһим хадисләр (вакыйгалар) хакында рәсемнәр булачак»,— дип белдерә. Мавыктыргыч реклама! Чыннан да, «һәфтияк», «Бакырган», «Төхфәтелмөлүк» китаплары белән тәрбияләнгән татар егетенә (алар да, безнең кебек, яшьлек дәртен кичкәннәр) кинәт кенә Париж салонынннан репродукцияләр... Журнал яхшы кәгазьдә, рәсемнәр белән, затлы кара буяу белән басыла. Шигырь, рәсем, кинәт кенә нәсер, көтмәгәндә... орнамент.

«Аң» журналы, Оренбург «Шура»сының Казандагы көяз иркә сеңлесе кебек, татар яшьләренең күңелен җилкетә-җилкетә аларны яңа җилләргә, яңа заманга әзерли. Еллык бәясе дүрт сум булган бу журнал үзенең абонентларына 1915 елда бушлай «Альбом» дигән мәҗмуга бүләк итә дә (Г. Ибраһимовның искиткеч тирән-фәлсәфи сүз башы белән), 1918 елның урталарында эстафетаны яңа заман рухына тапшырып, яшәүдән туктый.

Әмма традицияләр беркайчан да яшәүдән туктамыйлар. Дөресрәге, аларны берни дә туктата алмый. Аларны туктатып торып була, күпмедер дәрәҗәдә имгәтеп, сырхауландырып була, тик... үтереп кенә булмый.

Романовлар заманында матбугат иреге мәсьәләсендә бик үк ирек күрмәгән, ләкин инде 1905 ел революциясе нәтиҗәсе буларак матбугат иреге алган, газета-журналның тәмен татып өлгергән татар халкы, татар зыялылары бөек борылыш елларында күпмедер айларга матбугатсыз кала. Ләкин озакка түгел. Әле тегендә, әле монда (күбесе хәрби) газеталар барлыкка килә, журнал чыгару юлында эзләнәләр. Сәгыйт Фәйзуллин, мәсәлән, 1920 елның февралендә Малмыжда «Якты юл» дигән журнал чыгара башлый («әдәби, фәнни, тәрбияви һәм сәяси журнал»). «Эш» газетасы бу уңайдан Казан журналистларын акрынлыкта гаепли: «...матбугат мәркәзе саналган Казан

революция дәверендә бөтенләй буш калды... ничаклы әдип, мөхәррирләр була торып, моңа яраклы бер журнал юк. Бәлки, кәгазь кытлыгы ди торганнардыр. Ләкин Малмыж өязе кәгазь тапканда Казанның кәгазь юк дип торуы уйга да, акылга да сыя торган түгел. Турысы, Казан йоклый диясе килә. ...Атаклы Казан шул гомердә бер журнал чыгара алмый».

Алай ук түгел инде, әлбәттә. Казан зыялылары, җәмәгатьчелек эзләнә. Яңа журналның формасын, эчтәлеген, «адресын» эзли. 1920 елның мартында «Кызыл шәрык» исемле сәяси, иҗтимагый, әдәби, гыйльми айлык журнал чыга башлый. Чыгаручы орган — «Россия коммунист (большевик)лар партиясе хозурында шәрык халыклары коммунист оешмалары мәркәз бюросы». Журнал әдәби әсәрләре белән бик ук мактана алмаса да, анда байтак гыйльми хезмәтләр басыла. Борһан Мансур редакторлыгында ел ярым чамасы вакыт басыла (соңгы ике саны Мәскәүгә күчеп чыга). Журналда Ф. С.-Казанлы, Г. Ибраһимов, С. Атнагулов, Микъдад Борындык (Борындыков), В. Шәфигуллин, К. Әмири, Ә. Сәгыйди, С. Кудаш, Ф. Бурнаш катнашалар. Казанның һәрбиләре дә үзләренең әдәби журналын чыгарырга әзерләнәләр. 1921 елның башында кызыклы гына старт алып, Казанда «Кызыл дәфтәр» исемле әдәби-сәяси Кызыл гаскәр журналы чыга. Анда Ф. Әмирханның «Чәчәкләр китерегез миңа!» дигән фәлсәфи-лирик нәсере басыла. Ф. Бурнаш оештырган бу журнал нибары бер генә сан чыгып кала. Әдәби журнал тудыру юлында эзләнүләр дәвам итә. Параллель рәвештә «Мәгариф эшләре» (1920, Эстәрлетамак), «Мәгариф» (1921, Казан), «Игенче» (1921, Казан), «Кызыл шәрык яшьләре» (1922, Казан), «Алмашка» (1922, Новониколаевск — хәзерге Новосибирск) һ. б. журналлар чыгарыла. Әмма боларның берсе дә чын мәгънәсендә әдәби журнал була алмаган кебек, әдәби үзәк тә була алмыйлар әле.

Ниһаять, 1922 елның маенда Казанда Гасыйм Мансуров (1894-1957) редакторлыгында «Безнең юл» исемле гыйльми, сәяси, әдәби, иҗтимагый айлык журнал чыга башлый. Ул вакытта әле Татарстан Язучылар союзы төзелмәгән. Шуңа күрә журнал «Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз башкарма комитеты белән Халык Комиссарлары советы нәшере» дигән гриф астында чыга. Бу журнал инде хәзерге «Казан утлары»ның башлангычы булып исәпләнергә хаклы. Бераздан бу журнал «Татарстан мәгариф эшләре комиссариаты органы» булып чыга башлый. 1922 елда дөнья күргән беренче саннары кечкенә форматта булып, әле журналның «техник йөзе» табылмаганлыгын күрсәтеп торалар. Ләкин 1923 елдан (5 нче саннан башлап) журналның форматы зурая (хәзерге «Чаян» форматына якын), яхшы кәгазьдә, шактый калын итеп басыла. Журналның беренче санында шундый белдерү бар: «Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, «Безнең юл» журналын чыгара башладык. «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә — Казанда булса да, бу мәҗмуга Россиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем, әдәбият мөхибләренең (сөючеләренең — М. М.) ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми, сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде. Эшче-крестьян гаммәсенең (масса — М. М.) азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булсыннар иде».

Журнал татар әдәбиятының революциягә кадәрге үткәне белән яңа чор әдәбиятын тоташтырган зур бер әдәби лаборатория, мәйдан ролен үти. Еллар буенча аның редакторлары бик еш алышынса да, әдәби көчләре даими буларак кала. Болар: Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Ф. Бурнаш, М. Парсин, С. Атнагулов, Г. Рәхим, Г. Газиз, С. Җәләл, Ф. Әмирхан, К. Нәҗми, М. Фазлуллин, Г. Баймбетов, М. Җәлил, Ф. С.-Казанлы, М. Гали, Х. Туфан, Г. Кутуй, Сәмави (Т. Чөнәкәй), проф. И. Н. Бороздин, Исх. Рәхмәтуллин, К. Рәхим, Х. Кәрим, Н. Хәким, К. Әмири, Г. Гали (журналның җитәкче постларында да эшли), Х. Наум, Х. Вәли, Г. Алпаров, Г. Сәгъди, һ. Такташ, М. Корбангалиев, Г. Чыгтай, Г. Толымбайский һ. б.

Бер дә шикләнмичә әйтергә мөмкин ки, «Безнең юл» журналы әдәбиятка Такташны бирде. Такташның иң җитди әсәрләре шунда дөнья күрде. Катлаулы чор иде — сталинизм шаукымы астында әдәбиятка һөҗүмчәнлек, кан коярга чакыру тенденциясе дә килеп керде, журналда болары да басылды. Мондый катлаулы чорны әдәбият галимнәре яңабаштан тикшереп яңача бәя бирерләр әле, тик шунысы бәхәссез: «Безнең юл» журналы илебездә чыккан әдәби журналлар арасында киң диапазонлы, зур әдәби колачлы җитди журнал буларак үсте.

1930 елның июленнән бу журнал, ТАПП органы буларак, «Атака» исеме белән чыга башлый. «Атака» дигән исем аның эчтәлегенә дә йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Бөтен үткәнебезгә, тарихыбызга каршы һөҗүмгә, бөтендөнья революциясенә чакыра башлаган чор бу. һ. Такташ әйтә бит:

*Тиздән көрәш.*
*Тиздән атака...*
*Трата... та... та... та... та...*

Х. Наум, Ф. Мөбарь, Г. Толымбайскийлар составындагы «әдәби отряд» игелекле, бай татар әдәбиятына каршы шулай һөҗүм башлый.

1933 елның январенда Казанда Татарстан совет язучылары союзын оештыру коми-

тетының беренче киңәйтелгән пленумы ачыла. Шул пленум карарлары нигезендә, «Атака» журналы 1933 елның январь саныннан «Совет әдәбияты» исеме белән чыга башлый.

Әдәбиятта яңа чор башлана. «Совет әдәбияты» инде ул яңа буын — Ә. Ерикәй, Г. Кашшаф, Ф. Хәсни, А. Шамов, Г. Разин (Бәширов), М. Әмир, Г. Минский, К. Нәҗми, М. Җәлилләргә канат куячак, зур киләчәкле журнал.

Тик 1937 еллардан соң аның битләрендә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Гобәйдуллин, Ф. Кәрим, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти исемнәре генә күренми инде.

Хәер, журналның бу чорлардагы сәхифәләре аерым бер тикшерү-эзләнүне өмет итеп кала әле...

(1902—1930)

1. **«Миръат»**. («Көзге») 1902 ел, Петербург (ярым татарча, ярым гарәпчә), барлыгы 22 сан чыга. Нашире һәм редакторы Габдрәшит Ибраһимов.
2. **«Ислах»**. 1905-1906 еллар чигендә, Әстерханда, барлыгы 2 сан чыга. Нашире һәм редакторы Әбүбәкер Дашкин.
3. **«Әлгасрел-җәдид»**. 1906-1907 елларда Уральскида. Нашире һәм редакторы Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин.
4. **«Әд-дин вә әль-әдәп»**. 1906 елда, Казанда. Туктала-туктала байтак еллар чыгып килә. Нашире һәм редакторы Галимҗан Баруди (Галиев).
5. **«Чикерткә»**. 1906 елда, Оренбургта, рус һәм татар телләрендә.
6. **«Чүкеч»**. 1906-1910 елларда, Оренбургта. Нашире һәм редакторы Тимерша Соловьев.
7. **«Уклар»**. 1906-1907 елларда, Уральскида, барлыгы 6 сан басыла. Рәсми нашире һәм редакторы К. Мотыйгый-Төхфәтуллин, фактик редакторы Г. Тукай.
8. **«Туп»**. 1907 елда, Әстерханда, барлыгы 3 сан чыга. Нашире Корбангали Илембитев, редакторы Хәбибулла Гомәрзадә.
9. **«Тәрбияи әтфаль»**. 1907 елда, Мәскәүдә, балалар журналы, барлыгы 5 сан чыга. Рәсми нашире һәм редакторы Заһид Шамил, фактик редакторы Ф. Әмирхан.
10. **«Карчыга»**. 1906 елда, Оренбургта. Нашире һәм редакторы Шакир Мөхәммәдев.
11. **«Дин вә мәгыйшәт»**. 1906-1918 елларда, Оренбургта. Нашире Вәли мулла Хөсәенов, редакторы Заһидулла мәзин Хәйруллин, соңрак — Фәизхан мулла Даутов.
12. **«Яз»**. 1907 елда, Оренбургта, кыска гомерле журнал. Нашире һәм редакторы Йосыф Мозаффаров.
13. **«Нәҗат»** (котылу, исән калу). 1907 елда, Петербургта, бер сан чыгып кала, анысы да конфискацияләнә. Нашире һәм редакторы Рәшит казый (Габдрәшит Ибраһимов).
14. **«Шура»**. 1908-1918 елларда, Оренбургта. Наширләре Шакир һәм Закир (Дәрдмәнд) Рәмиевләр, редакторы Риза Фәхретдинев.
15. **«Тәрбия»**. 1908 елда, Казанда, барысы 4 сан чыга. Нашире Ф. Казакова, редакторы Мирзагали Саинов.
16. **«Мәгълүмат»**. 1908 елда, Уфада, рәсми дини журнал, барысы 70 ләп сан чыга, мөфти М. Солтанов фәрманы белән туктатыла, 1916 елда мөфти С. Баязитов фәрманы белән яңадан ачыла. Беренче редакторы Сабир Хәсәни, аннан соң — коллегия.
17. **«Яшен»**. 1908-1909 елларда, Казанда, барысы 10 сан чыга. Нашире һәм редакторы Г. Камал.
18. **«Икътисад»** (Экономика). 1908-1913 елларда, Самарада (Куйбышев). Нашире һәм редакторы Фатих мулла Мортазин.
19. **«Мәгълүматы җәдидә»**. 1911 елда, Уфада, дини журнал. Нашире һәм редакторы Локманхәким Канзафаров.
20. **«Мәгариф»**. 1909-1910 елларда, Әстерханда, барысы 10 сан чыга. Нашире мулла Габдрахман Галиев, редакторы Мөхәммәдсадыйк Рәхимколов.
21. **«Ялт-Йолт»**. 1910-1918 елларда, Казанда. Нашире — «Юл» көтепханәсе, редакторы Әхмәт Урманчиев.
22. **«Акмулла»**. 1911-1916 елларда, Троицкида, көлке журналы. Нашире һәм редакторы Хәбибрахман Ганиев.
23. **«Аң»**. 1912-1918 елларда, Казанда. Нашире — «Гасыр» көтепханәсе, редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни.
24. **«Хокук вә хәят»**. 1913 елда, Казанда. Нашире һәм редакторы Шәйхгаттар Иманаев.
25. **«Мәктәп»**. 1913-1914 елларда, Казанда. Нашире — «Сабах» ширкәте, редакторы Шиһаб Әхмәров.
26. **«Ак юл»**. 1913 елда, Казанда, балалар журналы. Нашире һәм редакторы Фәхрелислам Агиев.

27. **«Мөгаллим».** 1913 елда, Оренбургта. Наширләре — Оренбург укытучылары, редакторы Хәсән Гали.
28. **«Ислах көтепханәсе».** 1913 елда, Оренбургта, ике генә сан чыга. Нашире билгеле түгел, редакторы Себердән Хөҗҗәтелхаким Мәхмүдев.
29. **«Сөембикә».** 1913-1918 елларда, Казанда, хатын-кызлар журналы. Нашире һәм редакторы Ягъкуб Хәлили.
30. **«Кармак».** 1915-1917 елларда, Оренбургта, көлке журналы. Нашире һәм редакторы Мәхмүт Мәрҗани (Галәү).
31. **«Авыл көнкүреше журналы».** Русча «Сельскохозяйственный листок»ның тәрҗемәсе, 1914 елда, Уфада, Октябрь революциясенә кадәр килеп җитә. Нашире — Уфа губернасы земская управасы, рәсми редакторы шул ук управаның председателе П. Карапачинский, тәрҗемәчесе Сәгыйт Рәмиев.
32. **«Русия сәүдәсе».** 1914 елда, Казанда. Платформасы: «Син үзеңдә яхшы мал барын игълан итмәгәч, халык аны каян белсен?». Нашире һәм мөхәррире Шәрәфетдин Шәһидуллин.
33. **«Уфа кооператоры».** Уфада 1917-1918 елларда чыга. Наширләре — «Уфа вилаяте җәмәгать кибете союзы» һәм Златоуст, Уфа, Бөре, Эстәрлетамак вак бурыч ширкәтләре союзы. Рус һәм татар телләрендә басыла. Редакторы Егоров, татарчага тәрҗемәчесе Самат Шәрәфетдинов.
34. **«Балалар дөньясы».** 1917 елда, Казанда. Нашире һәм редакторы Ягъкуб Хәлили.
35. **«Азат ханым».** 1917 елда, Әстерханда. Лозунгысы: «Яшәсен хөр Россиянең азат мөселман ханымлары!». Нашире һәм редакторы Гыйсмәтулла Мөслимов.
36. **«Мохтарият»** (бәйсезлек). 1917 елда, Уфада. Нашире — Эчке Россия һәм Себер мөселманнары милли идарәсе, секретаре Мөбаракша Хәнәфи.
37. **«Шәрык кызы».** 1918 елда, Казанда. «Сөембикә» журналына охшаш юлдан бара. Нашире һәм редколлегиясе — «Россия мөслимәләре мәркәз бюросы». Язышучылары Ф. Әмирхан, Г. Газиз, Ф. Бурнаш һ. б.
38. **«Укытучы».** 1918 елда, Казанда. Нашире һәм редколлегиясе — «Россия мөселман укытучыларының мәркәз үзәк бюросы».
39. **«Халык мәгарифе».** 1919 елда, Әстерханда. Нашире — «Вилаять мәгариф шөгъбәсе (бүлек)» редакция коллегиясе — «Гыйльми һәйәт», җаваплы кешесе Шәриф Саттаров.
40. **«Якты юл».** 1920 елда, Малмыжда. Әдәби, сәяси, фәнни журнал. 1921 ел ахырынача чыга. Нашире — Малмыж өяз мәгариф шөгъбәсе, соңыннан — Вятка вилаять мәгариф шөгъбәсе. Редакторы — һәйәт (комиссия). Г. Хәбиб, С. Фәйзуллин, Габди (Г. Ибраһимовның псевдонимы, ләкин бу псевдоним белән башка кешеләр дә язган, моны тикшерергә кирәк), Г. Динмөхәммәт (Ишми ишанның улы) һ. б. катнаша.
41. **«Кызыл шәрык».** 1920 елда, Казанда. Сәяси, иҗтимагый, әдәби, гыйльми айлык журнал. Ел ярым тирәсе дәвам итә. Беренче редакторы Борһан Мансуров.
42. **«Мәгариф эшләре».** 1920 елда, Эстәрлетамакта. Нашире — Башкортстан советлар җөмһүриятенең мәгариф комиссариаты. Шул ук елда туктатыла. Язышучылары Мирсәид Сафин, Ризван Алушев һ. б.
43. **«Кызыл дәфтәр».** 1921 елда, Казанда. ПУР каршындагы Шәрык бүлеге органы, бер генә сан чыга. Җаваплы редакторы Ф. Бурнаш. Тиражы 10 мең данә, бушлай таратылган.
44. **«Мәгариф».** 1921 елда, Казанда. Нашире — Татар социаль Советлар җөмһүрияте халык мәгариф комиссариаты. Беренче редакторы — Вәли Шәфигуллин, аннан соң — коллегия. Журнал озак еллар буена чыгып килә. (Хәзерге «Совет мәктәбе» журналының башлангычы.)
45. **«Азык эше һәм кооперация хәбәрләре».** 1921 елда, Казанда. Нашире — Татарстан азык эше комиссариаты һәм Татсоюз. Редакторы — һәйәт (коллегия).
46. **«Игенче».** 1921 елда, Казанда. Нашире — Татарстан җир эшләре халык комиссариаты. 1925-26 еллардагы редакторы Ф. Сәйфи-Казанлы.
47. **«Кызыл шәрык яшьләре».** 1922-1924 елларда, Казанда. Нашире — Россия яшь коммунистлар Союзының Татарстан өлкә комитеты һәм Мәркәз комитет янындагы төрек халыклары мәркәз бюросы. Беренче редакторлары М. Парсин, Г. Гали. Соңрак Ш. Рәмзи.
48. **«Мәгариф фронты».** 1922 елда, Уфада. Нашире — «Вилаять (өлкә) мәгариф шөгъбәсе, Мәгариф эшчеләре союзы һәм Вилаять һөнәрчеләр союзлары шурасының (советының) агарту бүлеге», редакторлык — коллегия. Язышучылары Газим Мансуров, Шәриф Сүнчәләй.
49. **«Алмашка».** 1922 елда, Новониколаевск (Новосибирск) шәһәрендә. Нашире — РКП(б) һәм РИКС Себер өлкә бюроларының агитпроп бүлекләре. Редакторлык — коллегия.
50. **«Безнең юл».** (хәзерге «Казан утлары»ның башлангычы). 1922 елда, Казанда. 30 нчы

елларга кадәр килеп җитә. Наширләре — Татар Социал Шуралар Җөмһүриятенең (республикасының) мәркәз башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары советы. Беренче редакторы Газим Мансуров, аннан соң редакторлар гел алмашынып тора.

51. **«Бабич».** 1922 елда, Уфада. Лозунгысы: «Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!» Болай дип күрсәтелгән: нашир вә мөхәррирләре (редакторлары) И. Рәмиев, Д. Юлтый, Н. Кадыйри.
52. **«Яшь эшче».** 1922 елда, Мәскәүдә. Нашире — РКСМ Мәркәз комитеты янындагы татар-башкорт бюросы. Редакторлык — һәйәте тәхририя. Авторлар — Ш. Рәмзи, М. Парсин, Н. Исәнбәт, С. Мортазин, М. Максуд, Г. Нигъмәти, һ. Такташ, Х. Наум, С. Атнагулов, К. Әмири, И. Рәхмәтуллин, Ярлы Кәрим, Булат Ишемгулов, Сарим Фәхри, Имам Насыйри, Г. Ибраһимов, Нур Сәйфи һ. б.
53. **«Шәпи агай».** Китапханәләрдә бик аз сакланган, Свердловскида чыккан көлке журналы. Моны Свердловск шәһәрендәге «Сабан һәм чүкеч» газетасы базасында чыгарганнар.
54. **«Чаян».** 1923 елда Казанда чыга башлый. «Гажур» нәшрияты, әдәби-сәяси, көлке журналы. Редакторлык — коллегия.
55. **«Яңа юл».** 1923 елда, Уфада. Редакторлык — коллегия. Язышучылары — Д. Юлтый, Г. Касимов, Г. Шомаси, С. Рәмиев, И. Рәмиев, Ф. Туйкә, З. Бәшири, Х. Кәрим һ. б.
56. **«Сигнал».** 1925 елда, Казанда. «Татарстан үзәк башкармасы исемендәге татар-башкорт сугыш мәктәбенең органы». Журналның икенче саны чыкмый кала. Редакторы Кави Нәҗми.
57. **«Сугышчан алласыз».** Нашире — «Сугышчан алласыз» җәмгыятенең Союз Үзәк Советы. 1925-1937 елларда Мәскәүдә чыга. (1934 елдан соң «Фән һәм дин»). Редакторы Галиәсгар Чыгтай (Гафуров).
58. **«Авыл яшьләре».** 1925 елда, Казанда. Әдәби, фәнни, сәяси журнал. Үзәк РКСМ комитеты каршындагы татар-башкорт бюросы һәм Россия ленинчы яшь коммунистлар союзының Татарстан өлкә комитеты органы. Редакторы Ш. Фәхретдинов, секретаре һ. Такташ.
59. **«Авыл көнкүреше».** 1925 елда, Минзәләдә. Нашире — «Игенче» газетасы, редакторлыгы — коллегия.
60. **«Сәнәк».** 1925 елда, Уфада, көлке журналы. Лозунгысы: «Авызың чалыш булса, көзгегә үпкәләмә». «Яңа авыл»га кушымта булып айга бер чыга.
61. **«Октябрь яшьләре».** 1924-1925 елларда, Казанда. Нашире — Россия яшь коммунистлар Союзы Татарстан өлкә комитеты органы.
62. **«Яшь авыл».** 1925 ел, апрель, Мәскәүдә. РЛКСМ Үзәк комитеты органы.
63. **«Кечкенә иптәшләр».** 1924-1928 елларда, Мәскәүдә. Ленин комсомолы ҮКның татар-башкорт бюросы тарафыннан чыгарыла.
64. **«Октябрь баласы».** 1929 елда, Мәскәүдә. Редакторы М. Җәлил.
65. **«Атака».** 1930-1932 елларда, Казанда. Әдәбият, сәясәт, сәнгать журналы, ТАПП органы.
66. **«Азат хатын».** Иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журнал. Казанда 1926 елдан чыга башлый.
67. **«Ударниклар».** 1930-1932 елларда, Мәскәүдә. Комсомол ҮК органы. Редакторы М. Җәлил.
68. **«Яңалиф».** 1927-1930 елларда, Казанда. Татарстан Яңалиф дәүләт комитеты органы, сәяси, әдәби, иҗтимагый журнал.
69. **«Тамашачы журналы».** Татар Дәүләт академия театры органы. 1927-1930 елларда Казанда чыга.
70. **«Яңалиф».** 1930-1932 елларда, Казанда, айлык сәяси, художество һәм тәнкыйть журналы. Татарстан халык агарту комитеты һәм Совет язучылары оешмасы органы; 1933 елдан — «Совет әдәбияты» исемендә Татарстан Совет язучылар Союзы органы.
71. **«Яңалифче».** 1929 елда, Новосибирскида. «Яңалиф Себер край комитетының катнашы белән «Азат Себер» газетасына кушымта булып чыга.
72. **«Бәләкәй ударниклар».** 1931 елда, Свердловскида, 1-2 группалар өчен дәреслек-журнал. Свердловск Берләшкән Урал бүлеге чыгара.

ИСКӘРМӘ

*Татар журналларының 1925 елгыдан соңгылары әлегә кадәр системага салып өйрәнелмәгән. Югарыда китерелгән мәгълүматлар И. Рәминең «Татар вакытлы матбугаты» (1926) исемле белешмәлегеннән (анда 1925 ел белән туктала) һәм Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсе каталогыннан алынды. Татар матбугаты тарихы буенча тулы бер белешмәлек бастырып чыгару филолог һәм тарихчы галимнәрнең кичектермәс бурычы булып кала.*

# ШИГЪРИЯТ

## Әхсән Баянов

### Аллаларны бәреп төшердек без

Аллаларның бәреп төшердек без барын!
Баш ияргә, бил бөгәргә күнектергән
Ул затларның затсызлыгын инде чөнки
Күп буыннар күреп белгән.

Мәҗүсиләр баш орса да ак каенга,
Син мәңгелек кодрәт безнең, бөек көч, дип,—
Баскынчылар әйләндергәч аны көлгә,
Калкып калган бары карачкы төп.

Төп башына утырып калган ач бәндәләр
Күпме шыңшып, күпме яшь бит түккән шунда!
Тик соңынтын, янгынны һәм төпне онытып,
Тез чүккәннәр килеп баскынчыга:

«Син — аллабыз, алып килдең яңа тормыш,
Синең кодрәт белән без шат тормыш кормыш.
Башкаларны кол итәргә булышырбыз,
Фатихаңнан берук аермаска тырыш!»

Табындылар суга — акты җиргә кан, яшь,
Табындылар утка — яктырмады караш.
Табындылар ай, кояшка, мәгърифәткә,
Ә патшалык итте ызгыш, талаш.

Тарихтан күп, артык та күп сабак алгач,
Инде үзебезгә мыек чыкмый калмас!
Җитәкчене гади чүлмәкчеләр арасыннан
Таптык дисәк... булып чыкты палач...

Кул болгады яңалары: «Дуслар, ишләр,
Шәп атлыйбыз дөрес юлдан, изге юлдан!»
Юлда ләкин коела торды һәм тапталып,
Аунап калды мәсләк, вәгъдә, иман.

•

Инде нишлик, нишлик, сез, аллалар, җирне,
Күкне, суны пычраттыгыз һәм җаннарны.
Инде үзебез чистартырбыз без аларны,
Саклый алсак, аклый алсак Җирне,
Күкне, Суны, Вөҗданнарны.

---

Әхсән БАЯНОВ *(1927) — шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык китап авторы. Казанда яши.*

## Дөрес бара

Сокланмаска мөмкин түгел, җайлы үзең.
Шома сүзең, трибунага ябышып тугач.
Син — Цицерон! Гәрчә булмый, сүзләр эзләп
Кесәгә һич керми, диеп, сине, кордаш.

Кайчан керсәң дә буш түгел: уң кесәңдә —
Җитәкчене үтереп мактый торган нотык.
Сул кесәңдә — дус-ишләргә ачы тәнкыйть,
Теләсәң дә койрыгыңны булмый тотып.

Түшәмнән чүпләп булса сан, тулса план,
Уң кесәдән ал да сип башлыкка мактау.
Ә тулмаса, кесә — башка, эшчең түзсен,
Үпкәләсен үзенә, рас җебегән, ялкау.

Тик хәерсез, хәлләр көйсезләнә кайчак —
Сулдан уңны аермыйча — буталасың.
Җитәкчене эштән алган чакта мактап,
Шарык-шорык көлгәч халык, тукталасың.

Аптырау тик синең өчен асла чит бит,
Эшкә өндәп тиргәү гел дә фарыз чара.
Һәм сөйлисең куллар бутап!
Рәхмәт сул кесәгә — шул коткара!
Эшең әйбәт, дөрес бара!

## Кызыл ут

Казан, Казан, нишләттек без сине?!
Сулыш алу синдә ник читен?
Күзгә күренеп ага өстә сөрем,
Урамнарың тулы күк төтен.

«Туган җирнең төтене дә татлы»,
Диеп күпме, күпме яшәлде.
Узган чакта «туган урам»нардан,
Нишләп тама күздән яшь әле?

Машинага утырып чаба Вакыт,
Тулпарлардан төшкән күптән ул.
Борынгының саклап тик бер катын,
Башкаларын ваткан, сүткән ул.

Кат артыннан яңа катлар өеп,
Ул күтәрә килгән Казанны.
Дистә каттан карап:
«Рәхмәт, Вакыт!» —
Дияргә тик җайлар аз әле.

Чырай сытып карый тәрәзәләр,
Һәм балконнар чәчи, йөткерә.
Машиналар, машиналар үкереп,
Биткә төтен һәм газ төкерә.

Машиналар — урамда һәм өйдә.
Машиналар — эчтә һәм тышта.
Яңа өметләрнең күзе әчетә,
Сау килсә дә алар тормышка.

Сумалалы түбәләргә кунып,
Дәшә чәүкә, чыпчык һәм карга:
«Туган җирнең без дә үз авазы,
Сез бәхетле бары без барда!»

Корыч нерв җепселләре сызлый
Күперләрдә, капка, коймада.
Идел моңлы, татар җаны сыман,
Кошлар таңда куркып уяна.

Урам чатларында — яшел балкыш...
Кимү белми тизлек, кызулык.
Машиналар... Җитте кычкырыр чак:
— Вакыт, туктал, алда — кызыл ут!
Кызыл ут!

## Тумыштан

Диктатура? Аңлар өчен аны
Кемдер бәлки укып тырышкан?
Баш һәм йөрәктән тыш, без җиде кат
Тиребез белән тойдык — тумыштан.

Ул көч, ихтыярны бирде башта
Законлата эшче сыйныфка.
Тешен кояр өчен уракны тик
Чүки торды чүкеч бик оста.

Чүки торгач, ирек һәм сүз бирде
Бюрократик балта, мылтыкка.
Ә соңыннан — эшсез батырлыкка,
Ташсыз сарай салган мутлыкка.

Инде онытыйк дисәк, төшкә кереп,
Ул куркытып безне уята.

Акыл өлешен тартып алган хәйлә:
«Вөҗдан, Иман! — диеп сүз ката.

Вәгъдә итә яңа матди муллык,
Алда байлык тагын бихисап!..
— Юк, байлыктан алда безгә, дибез,
Кирәк әхлак!
— Әхлак? Ул ни хак?

Әллә кул чабасы, әллә тагын
Ярты гасыр көтеп торасы?
Әллә чаң сугасы:
— Булачакмы берчак
Вөҗдан, Намус диктатурасы?!

Чаң сугасы...

*

Мөмкин түгел яшәү искечә:
Мин ышана алмыйм аллага
Һәм ышана алмыйм иблискә.

Мин ышанам бары Кешегә!
Бар нәрсәгә кеше хирес ул —
Үзе алла,
Үзе иблис ул.

*

Бөекләрнең улый океаннары,
Диңгезләре дулый зурларның.
Ә минем бар койрыксыз Кабаным,—
Башсыз гәрчә — һәм бар Болагым.

Диңгезем юк, әйе, океан ерак.
Алар шаулап торган киңлеккә
Чыгар юлда илләр таптап узмам.
Иделем бар, миңа шул җитә.

Беркемнән дә сатып алынмаган,
Тартып алынмаган, басып алынмаган
Җирем минем, суым — язмышым!
Артык һәм аз түгел, үземә таман,
Чәчәм, урам — җитә табышым.

Уңга бәрелмичә, сулга сугылмыйча,
Үз кыйбламa табан барышым.
Юл басмасын катыйль —
Бары шул.

## Яратабыз...

Бәндәләргә бәлки бик ис китми,
Табигатькә мәгәр гашыйклар без.
Урман яшеллеген эчеп, ашап туйгач,
Чыгарабыз изеп балчыклар без.

Остардык һай — соң җилеген җирнең
Агу өреп кудырабыз өскә.
Чишмә һәм инешкә кош-корт килсә,
Муеннары гәрчә бөгелеп төшә.

Безгә нәрсә — төшсен! Үзебез түгел,
Киләчәк бит түләячәк хакын.
Катламнарның сатып кара маен,
Читләрдән без кайтартабыз ак он!

Ватандар без: җәнлеген дә җирнең
Рәнҗетмибез, чыккан чакта форсат.
Кочаклыйсы килә, иркәлисе,
Мамыкларын уңай якка сыйпап.

Ак хисләрне санламыйча мәгәр,
Кача төлке, бүре ята ялгыз.
Шуңар эзләп, табып, мылтык шартлатабыз...
Аннан кочып сөя, яратабыз!

## Көзгеләр

Бар иде бакча әүвәлдә:
Бер бүлмәгә керәсең,
Моңарчы үзең белмәгән
Төсләреңне күрәсең.
Уңда көзге, сулда көзге,
Алда көзге — карыйсың.
Шунда гүя киләчәгең,
Шунда гүя тарихың...

Булсаң әгәр икейөзле,
Мыскылларга бетә җай:
Карап тора йөз рәвешең
Күргәзмәгә куйгандай.
Борын чөеп йөрсә ярың,
Аны да алып кер, яме.
Төп-төз гәүдәле чибәрне
Күр син, ул бит шүрәле!

Җиңел иде шулай әүвәл
Кәкре итү төзләрне.
Тик хәзер юк ул бүлмәләр,
Хәлләр хәзер үзгәрде.
Ватыкларын җыеп түктек,
Җимерелде көзгеләр.—
Үзләреннән куркып бугай,
Мөгезлеләр сөзделәр.

Ах-ух килеп, мөгезсезләр
Юк итеште аларны.
Әйтерсең ки, кәкрәйтергә
Төз әйберләр калмады.
Шулай булса-булмаса гәр,
Минем тәкъдим зирәктер:
Бөкреләрне төзәйтүче
Көзгеләр бик кирәктер.

Турайтырлык әйберләр һәм
Адәмнәр юк түгелдер.
Чынлап булмаса, уйнаптыр —
Уйлап карыйк шуны бер.

## Диварлар көтә

Сары яфракларга ияреп оча
Ак кәгазьләр — кеше сурәтләре.
Адәмнәрнең калган үрнәкләре,
Гайбәтләре оча, өрәкләре.

Кайчан гына, бизәп диварларны,
Торган иде алар — мәгъруp рәтләр.
Кылганбыздыр без, аларга багып,
Гыйбадәтләр бәлки, гыйбадәтләр.

Каныбызга сеңгән ул гадәтләр —
Олыладык: «Яшә, яшә!» — дидек.
Хәзер әнә таптап узды иптәш.
Беркем гаеп итмәс — килде хөрлек.

Кемдер көлә, кемдер ыңгыраша,
Аунагандай җирдә йөрәкләре.
Ә диварда буш урыннар көтә —
Ак эшләрме, ялган бизәкләрме?

Вакыт үтә...

*1988*

# Гәрәй Рәхим

## Кулга-кул тотынып

*1987 елның маенда Башкортстанда үткәрелгән Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре уңае белән.*

Башкортстан, синең туфрагыңа,
Синең данлы кара туфрагыңа,
Синең җанлы, изге туфрагыңа —
Күкрәгеңә кулны куйгандай,
Ялан кулым белән кагылдым.
Шушы җанлы, изге туфрак аша,
Шул борынгы, иске туфрак аша
Кандаш, җандаш башкорт туганымның,
Телдәш, моңдаш башкорт туганымның,
Горур, батыр башкорт туганымның,
Сылу, матур башкорт туганымның
Рухи зурлыгына табындым.
Шушы туфрак аша мин үземдә
Тойдым Агыйделнең ургуын,
Урал тауларының горурлыгын,
Салаватның нәсел-ыруын,
Җанны сызып алган курай моңын,
Дала кымызының дәвасын,
Тулпар тояклары тупырдавын,
Мостай чалган сазның авазын.
Болар бар да зурайттылар мине,
Күршең Татарстан баласын.
Нинди рәхәт бүген ачык әйтү,
Нинди рәхәт бүген ярып әйтү —
Татар белән башкорт баласының
Киләчәккә табан мәңге бергә
Җитәкләшеп кенә барасын.
Кулга-кул тотынып барасын!..

Нинди рәхәт!..

## Гафу ит син мине, романтика

Күкләр мине никтер аңламады.
Нык алдады зәңгәр романтикам.
Мәңге бетмәс дип ышанган гомер
Булып чыкты бары сыңар тотам.

Боз түбәле серле «пик»лар булды
Яшьлектәге чиксез хыялымда.
Тик гомергә авыл башындагы
Нәни бер тау карап торды миңа.

Мавыгылды океаннар белән,
Мин тайфуннар кичкән батыр, имеш.
Гомер буе ләкин битем юды
Бакча артындагы нәни инеш.

Тропиклар белән исәрләндем,
Телләремдә булды джунгли.
Үзем йөрдем һаман әрәмәдә
Шомырт исләренә җилли-җилли.

Чарльстоннар, роклар, джазларны
Чәчрәп-чәчрәп чыгып яклადым мин.
Тик артымнан гел озата килде
Мине тик Мин иткән «Баламишкин».

Байтак модный исемнәрне укып,
Бөеклек бит шушы, диеп, тукып
Күпме йөрдем,
                әмма туганнарым

Булды Тукай, Сәйдәш, Туфаннарым.

Әйе, күкләр мине аңламады,
Әмма җирем мине алдамады.

Ерактагы зәңгәр яулык булып
Җилфердә син, әйдә, романтикам.
Бер дә бетмәс дип ышанган гомер
Булсын әйдә бары сыңар тотам —
Тик мин туган җирнең бөтенлеген,
Гүзәллеген шул тотамда тотам!

Романтикам, гафу ит син мине,
Мин бит бары шуның белән отам.

---

Гәрәй РӘХИМ *(1941) — шагыйрь, прозаик; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык шигырь, проза китаплары авторы. Ул ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

## Оптимист

Татар җыелган җирдә
Бәйрәмсез булмый бер дә.
Ике татар — бер базар,
Базарда телләр язар.

Җәйнең матур көнендә,
Илнең бөтен җирендә,
Җыелышып татарлар
Сабан туе ясарлар.

Анда да бергә-бергә,
Монда да бергә-бергә,
Кайда да бергә-бергә —
Татар бергә гомергә.

Татар җыелган җирдә
Мәзәксез булмый бер дә,
Дәмәк[1]сез булмый бер дә,
Бәйрәмсез булмый бер дә —
Татар боекмый бер дә.

Ул бары тик моңлана,
Шул моңы гимн аңа.
Татар ашыкмый гүргә —
Ул оптимист гомергә!

## Яхшы күңелле кеше

Эзлим...
Эзлим...
Кайда,
Кем син,
Яхшы күңелле кеше?
Һәм, гомумән,
Бармы соң син,
Яхшы күңелле кеше?

Әллә безнең заман өчен
Казылма бер атмы син?
Я нәселе юкка чыккан
Археологик затмы син?

Булсаң әгәр, күренеп ал,
Хәбәрең сал безгә дә.
Кар кешесе кебек йөрмә...
Син соң ничә нөсхәдә?

Яхшы күңелле булудан
Әллә тәмам ардыңмы?
Музей экспонатына
Әверелеп калдыңмы?

Девальвация кичергән
Акча хәлендәме син?
Химикат сибеп көйдергән
Бакча хәлендәме син?

Тик бер тапкыр эндәш инде,
«А-у» — диген, «А-у» — дигәнгә.
Тиз генә язып куярбыз
Хет кызыл кенәгәгә.

Без күпләр!
Без бик көчлеләр!
Эшлибез мең төр эшне.
Тик син кая?
А-у!..
Аваз бир,
Яхшы күңелле кеше!

## Аклык

Ак болыттан ап-ак нурлар иңә,
Аклык иңә Аккош күленә.
Аккош күле бу аклыгы белән
Бер ак кыйтга булып күренә.

«Аккош күле!» Чәчәкләрең ап-ак...
Ап-ак сагыш белән уфтандым.
Аккош күле, син бит безнең өчен
Шигъри биләмәсе Туфанның.

---

[1] Дәмәк — кызыклы, күңелле. Диалекталь сүз. Автор.

Син югалта күрмә, Аккош күле,
Каеннардан төшкән аклыкны.
Югалтмабыз без дә күңелләрдә
Хәкимнәрдән калган хаклыкны.

Ап-ак теләк телиселәр килә
Сез дусларның бары-барына.
Күңелкәйләр манчылгандыр ахры
Аккош күле аклыкларына.

*

Сәламәтлек, тамак, ял турында,
Үз хакында тәмам онытып,
Бүген кирәк булган бөтен эшне
Эшли алса кеше,
ут йотып
Йөрүләрен исенә дә алмый...
Әйтерсең, ул һич ут йотмады —
Канәгатьлек белән әйтеп куя:
«Бүгенге көн юкка чыкмады...»

Эшли-эшли тәмам эштән чыгып,
Чирләп аугач урын өстенә,
Менә-менә җаны чыгачагы
Инде анык булгач үзенә,
Кичкә кадәр әгәр үлми калса,
Чакмый калса әҗәл чакманы —
Канәгатьлек белән әйтә тагын:
«Бүгенге көн юкка чыкмады...»

## Китап

Ничә көн буе бер дә туктамый
Келтер дә келтер, әйтерсең, чыгыр —
Минем күңелдә келтерәп тора
Кәгазь-каләмсез язылган шигырь.

Майланган кебек түгел,
күп чакта
Шыгырдый тормыш шыгыр да шыгыр.
Тик бер юаныч —
күңелдә тора
Кәгазь-каләмсез язылган шигырь.

Үз төсен таба, калыбын таба,
Ныгый, шомара, әйтерсең, чуер,
Чуерташ кебек бик тә табигый
Кәгазь-каләмсез язылган шигырь.

Кемдер шигырьгә кул селтәмәкче,
Янәсе: «Кемгә кирәк ул, «шыер»?!»
Ялангач йодрык булып ор аңа,
Кәгазь-каләмсез язылган шигырь!

Утырмыйм да мин өстәл артына,
Әйдә, көнләшеп кашыңны җыер.
Мин үзем китап —
күңелем тулы
Кәгазь-каләмсез язылган шигырь.

## Иске, изге...

(Гармунчы монологы)

Мин урамда тальянымны
Бер сыздырып җибәрсәм —
Бер көтү кыз бөтерелеп
Йөри иде тирәмдә.

Мин уйнаган шаян көйгә
Яшь-җилкенчәк җырлады.
Үзәк өзгеч моңлы көйдән
Карт-корылар елады...

...Хәзер гармун тавышына
Шаккатмый инде кем дә.
Бар шәһәрне дер селкетеп
Битломаннар үкерә.

Бөтен халык авыз ачып
Шуларны тыңлый хәзер.
«Әпипә»ләр урынына
Металлар чыңлый хәзер.

Тик нишлим соң?!
Мөмкин түгел
Үзгәртергә бу җанны —
Бер ялгызым сыздырам мин
Көмеш телле тальянны...

Иске, изге тальянны...

# Фәнис Яруллин

## Көрәшләрдә билләр чыдарлык

Актарыла тарих катламнары,
Кул тимәгән тирән катламнар.
Алар безнең кагылганны көтеп,
Җиргә күмелеп күпме ятканнар!

Ә без артык кыюсызлар булдык.
Кагылырга куркып тарихка,
Хакыйкатьне гел тирәләп уздык,
Риза булып рухи тарлыкка.

Шул тарлыктан безнең әкрен-әкрен
Тын кысылды, күкрәк кечерәйде.
Ә куркаклык шул тар күкрәктә дә
Тамыр җәйде һаман, көч җәйде.

Куркаклыкның бер әсире булып,
Күпне күрми генә яшәдек.
Гаделсезлек күрсәк — күзне йомдык,
Безгә тимәсәләр — дәшмәдек.

Үле җаннар артты тирәбездә,
Арта барды шәүлә-өрәкләр.
Күз яше дә тишә алмый торган
Ташка әйләнде бик күп йөрәкләр.

Хакыйкатьне, мәңге чыкмасын дип,
Ташлар белән томтык бастырып.
Замананы узып китмәк булдык,
Арган атны кыйнап чаптырып.

Әй ашыктык:
«Тизрәк, тизрәк!» — дидек,
Рапорт бирер өчен ашыктык.
Әй кычкырдык:
«Күбрәк, күбрәк!» — дидек,
Ә үзебез... һаман ачыктык.

Кайнарланып: «Алга, алга!» — дидек,
Тәгәрәдек үзебез гел артка.
Егылганда «Ура!» кычкырдык без,
Шул сүз ятышлы дип колакка.

Җитте вакыт, хакыйкатьне инде
Таш астыннан тартып чыгардык...
Беләкләрдә көч бар әле безнең,
Көрәш өчен — билләр чыдарлык.

## Елый белмәү

Күп нәрсәдән мәхрүм калдым
Елый белмәү аркасында.
Яшьләр түгел, очкын булды
Күзләремнең чакмасында.

Ә бит, юкса, дөньясында
Әз булмады елар чаклар.
Елау гына түгел, хәтта
Бүре булып улар чаклар.

Ачлык белән хәерчелек
Яңакларга сугып торды.
Суккан саен көлтә-көлтә
Күздән утлар чыгып торды.

Кемнәрдер зар еладылар.
Ә кемнәрдер нык булдылар.
Елый белеп елаучылар
Ач елда да тук булдылар.

Тук булдылар, киенделәр,
Кикерделәр, симерделәр.
Елый белмәүчеләр генә
Бер сыныкка тилмерделәр.

Заманалар рәтләнгәч тә
Елаучылар кала бирде.
Мескеннәр гел елый-елый
Үз кирәген ала бирде.

Кемдер елап исем алды,
Кемдер елап бүләк алды.
Күзләрендә яше юклар,
Рәхмәт көтеп, эшләп арды.

---

Фәнис ЯРУЛЛИН *(1938) — шагыйрь, прозаик, драматург; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермегә якын китап авторы. Ул — Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

Әйе, күпләр үзләштерде
Кайда ничек елау серен.
Ә мин — тинтәк һаман менә
Шуның серен белми йөрим.

Хәер, миңа еласам да
Ышанмаслар, белеп торам.
Шуңа күрә еламыймын,
Горур гына көлеп торам...

Шул горурлыкның бәясен
Үзем генә белеп торам.

## Илле

Исте җилләр, акты сулар,
Еллар бөкте минем билне.
Барыр булсам анда-монда,
Дару алып чыгам юлга —
Миңа инде хәзер илле!

Сукранамын, сыкранамын,
Сүгәм хәтта каршы җилне.
Яшьлек керә төшкә генә,
Йөрәк тибә көчкә генә —
Миңа инде хәзер илле!

Кызмыймын да, тузмыймын да,
Тешләп кенә йөрим телне.
Ун кат уйлыйм әйтер сүзне,
Гаҗәп җитди йөртәм йөзне —
Миңа инде хәзер илле!

Чү, чибәр кыз үтеп бара,
Кояш йөзле, камыш билле.
Иярә аңа уйларым,
Турая сыным-буйларым,—
Миңа әле бары илле,
Миңа әле бары илле!

*

Яратыр идем көзне мин
Яз кебек якты булса,
Җиргә төшкән тамчылары
Бал кебек татлы булса.

Юллары пычрак булмаса,
Җилләре җылы булса.
Һәр оя кошлы булса һәм
Һәрбер кош җырлы булса.

Яратыр идем көзне мин
Әгәр яратып булса.

Болытларын җиңел генә
Куып таратып булса.

Дөньядагы пычракларны
Өреп киптереп булса.
Җырын оныткан кошларны
Җырлы иттереп булса.

Яратыр идем көзне мин
Син язларда калмасаң,—
Язгы тамчы булып һаман
Йөрәгемә таммасаң,—
Яратыр идем көзне мин...

## Безне сөйгән кызлар-туташлар

Кай җирләрдә хәзер йөрисездер,
Яшьлектәге тугры юлдашлар.
Әй сез, олы җанлы,
Әй сез, миһербанлы,
Кайнар канлы кызлар-туташлар.

Сезнең куллар әгәр кагылып китсә
Эреп төшә иде бар ташлар.
Әй сез, җырлы-моңлы,
Әй сез, нечкә кыллы,
Йомшак куллы кызлар-туташлар.

Җылылыгын саклый әле һаман
Сез баш куйган безнең иңбашлар.
Әй сез, тәмле сүзле,
Әй сез, серле күзле,
Якты йөзле кызлар-туташлар.

Сүнмәгез сез бер дә, сүрелмәгез,
Яшьлек күгендәге кояшлар.
Әй сез, мәрхәмәтле,
Әй сез, мәхәббәтле,
Безне сөйгән кызлар-туташлар.

## Атар идем синең исем белән

Кушмас идем синең исемеңне
Иң-иң якты йолдызга да хәтта:
Кем соң инде йолдызларның исемен
Төннәр буе гел кабатлап ята?

Гүзәлләрдән гүзәл утрау ачсам,
Исемең бирмәс идем аңар да мин:
Килерләр дә пычрак аяк белән
Гүзәл утравымны таптарлар дим.

Биек тауны да мин исемең белән
Юк, атамас идем һич кенә дә:
Таулар да бит ишелә әкрен-әкрен,
Таулар да бит бер чак кечерәя.

Гөлләр, күлләр, елга-диңгезләр дә
Ачып бирә алмас җисемеңне.
Гөлләр шиңәр, елга-күлләр кибәр,
Кем хәтерләр аннан исемеңне?

Синең исемең җырга гына лаек,
Озын була матур җырның даны.
Мәңгелек җыр яза алсам әгәр,
Исемең белән атар идем аны.

## Ике алма

Шулай сеңеп калган җанга,—
Ике учыңда — ике алма.
Алмаларың түп-түгәрәк,
Тора иде нур сибәләп.

Килеп кердең, түргә уздың,
Алмаларың миңа суздың.
Бер алмам — сафлыгым, диден,
Бер алмам — яшьлегем, диден.

Алмаларың алдым учка,
Килалмыйча тордым һушка.
Очып китәр кебек иде
Әверелеп алар кошка.

Еллар белән чаптым алга,
Ике учта — ике алма.
Берсе — бетмәс сабырлыгың,
Берсе — сүнмәс матурлыгың.

## Кайнар дулкын

Иреннәреңә тиюгә
Бәрелде кайнар дулкын.
Шул кайнар дулкыннарның мин
Кайнар сулышын йоттым.

Айкалды, чайкалды диңгез,
Сыймады ярларына.
Төшкән юк иде диңгезнең
Бу кадәр кайнарына.

Йөзәм дулкыннар аралап,
Күпмегә җитәр көчем?!
Кайнар диңгезләрдә йөзү
Зур бәхет минем өчен.

Батсам да кайнар диңгезгә
Үкенмәм һич, үкенмәм.
Кайнар дулкыннар һәрвакыт
Сыйпап торыр битемнән.

## Тик сиңа бирер идем

Туктаусыз нәрсәдер юасың,
Кулларың өлгерми кибәргә.
Синең шул кулларың нур сибә
Кояшсыз көнне дә өйләргә.

Матурлап, чистартып, агартып
Үтәләр гел шулай көннәрең.
Аклыкка, пакьлеккә куанып
Җилләрдә җилферди керләрең.

Әгәр дә бер әмәл тапсалар
Керләнгән җаннарны юарга,—
Шикләнми тоттырыр идем мин
Аларны тик синең кулларга,—
Юарга, юарга, юарга.

## Алмаштырмыйм

Алмаштырмыйм синең бер карашыңны
Гомеремнең әллә ничә таңына.
Шул караштан күпме нурлар эчәм мин
Яктылык бик кирәк чакта җаныма.

Алмаштырмыйм синең бер елмаюны
Гомеремнең әллә ничә язына.
Синең шушы бер елмаю белән дә
Күмеләмен чын мәхәббәт назына.

Алмаштырмыйм синең тамчы яшеңне
Коеп яуган җәйләрнең яңгырына.
Мәңгелек дым бирә бер тамчы яшең
Саф мәхәббәт чәчәге тамырына.

Алмаштырмыйм синең бер керфегеңне
Җир шарының иң гүзәл гөлләренә.
Керфегеңә сеңгән нурлар яктысын
Саклап тотам иң кара көннәремә.

*

Кайчан гына әле агачларның
Күрке булган нәфис яфраклар,
Саргаешып, җиргә коела бүген,
Үткән-киткән җәйге шәп чаклар.

Кулланыштан чыккан акча кебек
Ауный хәзер алар юлларда.
Шушы күренеш горур агачларны
Салган әнә тирән уйларга.

*

Гамьсез генә атлап барган чакта
Битне куеп көннең җиленә,
Сары күбәләктәй сары яфрак
Килеп кунды минем иңемә.

Әллә ничек авыр булып китте,
Чүгеп куйдым хәтта мин азрак.
Ә бит, юкса, төште нибарысы
Сары көздән килгән бер яфрак.

*

Куа күпләр дан йә мал артыннан —
Арыганын белми, ял итми.

Малга комсызларга мал бер җитә,
Данга комсызларга дан җитми.

*

Яхшы атка камчы кирәк түгел,
Ул болай да чаба егылганчы.

Тик тормышта начар аттан бигрәк
Яхшы атка төшә күбрәк камчы.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ИЛЧЕГӘ ҮЛЕМ ЮК

РОМАН

## I

Сарай кәтибе Хафиз алтын кара савытын кечкенә өстәлгә куйды, дикъкать белән каурый каләмен очлады, шуннан соң гына бөкләнеп өстәл янына утырды һәм ап-ак кәгазь битенә карады да уйга калды.

Тәхет өендә тыныч. Сәлим хан бүген дә кермәде, иртән иртүк яңа сарай салып яткан осталар янына китте. Ашыга хан, тизрәк сарайны өлгертәсе килә. Хәер, сарай әзер иде инде, бизәү-нәкышләү эшләре генә калып бара иде. Киң Иделнең иң биек яр башында торгызылган мәһабәт сарай ханның дәрәҗәсен дә күтәрер сыман иде. Кәтиб Хафиз белә, Сәлим хан яңа сарай төзүче һәр таш кисүче, һәр нәкыш-бизәк төшерүче янында озаклап туктап тора, теге я бу бизәк ошамаса, останы куып җибәрергә дә күп сорамый иде. Кайбер нәкыш вә бизәк ясаучыларны исә хан дәшми-тынмый гына күзәтә. Димәк, ханга останың эше ошый һәм ул аңа түләүне дә бермә-бер арттырачак. Сәлим хан бигрәк тә оста Алпар колның ташка бизәкләр төшерүче үсмер улы Дәуран нәкышләгәнне карап торырга ярата иде. Шаккатмалы иде үсмернең эшенә. Хәзер үк шушындый бизәкләр төшергәч, балигъ көннәрендә ниндәен эшләр кылмас бу бала?. Дәуран янына туктауга, Алпар оста кырын күзе белән генә хан ягына карап ала. Горурлана иде осталар остасы Алпар улы өчен. Горурланмаслыкмы! Иң оста нәкыш төшерүчеләрне дә көнләштерерлек итеп эшли. Хәер, бер дә гаҗәпләнәсе юктыр, оста Алпар аны бу эшкә балачактан ук өйрәтте. Аннары бу бала Сәлим ханның икенче хатыны Туйбикәдән туды. Саксин каласы тарханы кызы Туйбикә Сәлим ханга икенче хатын булып килде. Ханның беренче хатыны өянәге тотып ята, йөри дә, рәтләп сөйләшә дә белми иде. Әнә шуннан соң, аксакаллар үгетенә таянып, Сәлим хан Туйбикәгә өйләнде. Әмма өч ел бергә гомер итеп тә балага узмады. Шуңа күрә, ханның дәвамы булырга тиешлеген искә алып, Сәлим хан Туйбикәсен осталар остасы Алпарга бирде дә тегеләргә никах укытты. Туйбикәнең башта моңа кәефе кырылса да, оста белән гомер итә башлагач, чәчәк аткан гөлдәй янә гүзәллә-

---

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН *(1927) — әдип, «Кубрат хан», «Чоңгыллар», «Сулар үргә акса да» романнары, күп кенә повестьлар, хикәяләр, мәкаләләр авторы. РСФСРның һәм Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

неп китте. Туфрагы уңдырышлы булдымы оста Алпар йортының, Сәлим ханны югалтуына мыскал да рәнҗемәде, киресенчә, шуннан соң аны беркайчан күрмәсә дә, рәхмәтләр укыйсы килде элгәреге иренә. Бәхетнең байлык вә дәрәҗәдә түгеллеген кол ир белән яши башлагач кына белде хатын. Аннары тәхет иясен искә төшерүнең хаҗәте дә калмады — галиҗәнап тиздән кыпчак ханы Сарбайның кызы Зөбәрҗәткә өйләнде. Зөбәрҗәт исә Сәлим ханга берсе артыннан берсе ике углан табып бирде. Галиҗәнапнең түбәсе күккә тиде. Ул гынамы, еллар үтүгә, Зөбәрҗәте аны янә куандырды — кыз бала да тапты. Кызга исемне хан үзе бирде — Назлыгөл дип атады. Каланың түбән очында, нәкъ шул таңда диярлек, оста Алпарга биргән Туйбикә дә угыл тапты. Бу хәбәр Сәлим ханга ишетелгәч, ул ни куанырга, ни хәсрәтләнергә белми аптырауга калды. Ләкин ахырда куануы җиңде — Туйбикә өчен шатланды. Ул бик тә, бик тә балага узарга теләгән иде ләбаса. Һәм менә аллаһы тәгалә аңа бу бәхетне бирде. Ахыр чиктә куанычка әверелгән бу хәбәрдән соң Сәлим хан колы Алпарга ирек бирергә ымсынган иде, ләкин тегенең китеп югалуыннан куркып, ниятеннән кире сүтелде. Болгардагы һәм Бөек Каладагы иң күркәм биналарны Алпар оста торгызган иде. Болгарга килгән чит ил сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләр Сәлим хан колы Алпар күтәргән биналарны күрерләр иде дә таң калырлар иде. Останы сатып алырга теләүчеләр дә булмады түгел, әмма Сәлим хан якын да килмәде. Оста Алпар аңа кадерле иде. Ул аңа үзенә аерым өй салырга рөхсәт итте, ризык-нигъмәтне дә үз табыныннан ким бирмәде. Әмма оста Алпар барыбер Сәлим хан колы булып калды. Галиҗәнап монда да ипле чарасын тапты — аңа хатыны Туйбикәне бирде. Туйбикә оста Алпарга кияүгә чыккач, зәмзәм суы эчкәндәй түгәрәкләнеп, тулыланып, нәфисләнеп китте һәм моның өстенә, ханга үч иткәндәй, ир бала табып куйды. Углы туганнан соң оста Алпар сабырланып калды. Багучылары ханга җиткерделәр: имеш, баласының кендеген кисүгә, әти кеше аның кулына чүкеч тоттырган икән, шуңа тиңсез оста икән ул бала.

Тәхеткә утыруының өченче елында ук Сәлим хан яңа сарай салдырырга кереште. Әлбәттә инде, сарай салуны осталарның остасы Алпарга йөкләде. Һәм менә Бөек Каланың йөзек кашы булып Идел елгасы буенда хан сарае торгызылды. Инде, ниһаять, бизәү эшләре бетеп бара. Бизәү эше вак мәсьәлә түгел, сарай йөзе — ил йөзе, хан йөзе. Шуның өчен булса кирәк, Сәлим хан көн аралаш диярлек бизәүчеләр янына килде. Килгән саен оста янында Туйбикәне күрде. Күрде дә хатынның гүзәлләнеп, бала тапкач чын мәгънәсендә чәчкә атып китүенә сокланып карады. Гәрчә ничә ел үткән, Зөбәрҗәте шул еллар эчендә ханга өч бала табып биргән булса да, Сәлим хан кайчандыр үз хатыны булган Туйбикәгә тансыклап карады. Юк, бу тансыклавы хатынны сагынудан түгел иде, хәтта көнләүдән дә түгел, хатынның бала табып үстерә башлагач яхшы якка үзгәрүеннән гаҗәпләнү тойгысы гына иде. Аллага шөкер кылырлык, Зөбәрҗәте табып биргән ике угланы балигъ булды, Сәлим хан аларга ике төбәктән ике каласын бирде — әмир итте, хәзер инде әнә үзләре угланнар үстерәләр, моның янына Назлыгөле җитеп килә. Насыйп иткән булса, аны да кияүгә бирер. Яшь әле, өлгерер, кыз картаймый, бал искерми, диләр.

Гомумән, ата-бабаларыннан үзгә буларак, Болгар тәхетенә утыргач, Сәлим хан күп нәрсәгә иреште. Иң мөһиме, күрше Владимир кенәзе белән төрле сәбәпләр аркасында бозыла-сүтелә килгән, кайчак хәтта теге яктан да, бу яктан да яу белән беткән солыхны яңартты. Ул гынамы, икенче угланы Илһамга кенәз нәселеннән Мария атлы кәләш алып кайттырды. Чулман-Җаек елгалары буена кирмән-калалар салдырды. Төньяк-көнбатыш тарафтагы чикләрне кан кушу белән ныгыткач, Сәлим хан көньяк-көнчыгыш тарафына игътибар итте һәм күрде: төрки халыклар белән чикләнгәнгәме, бөтенләй сакланмый диярлек икән ул яклар. Бу эшкә ул күрше-тирәләреннән җәберләнеп, я булмаса

бөтенләй тар-мар ителеп, ил-суларыннан куылып җибәрелгән, туган илҗирләрен ташлап, Болгарга килеп сыенырга мәҗбүр булган кыпчак ыруларын кабул иткәч кереште. Кыпчак вә болгарны тел вә гореф-гадәттән аерып булмый, шуның өчен бу кыю һәм батыр халыкны болгарлар бик теләп үз араларына алдылар. Сәлим хан аларга авыл утырырга урын, мал-туар үрчетергә болынлы елга буйларын, иген игәргә бүтән җирләрен бирде. Шул ук вакытта Табгач, Бохара, Рум, Кияүкала, Новгород, Өргәнеч, хәтта Димәшкъ калалары белән сәүдә итүне тагын да җанландырып җибәрде. Иң-иң мөһиме шул иде янә: Сәлим хан тәхеткә утыргач, берәү дә зурдан кубып Болгарга яу килмәде. Владимир кенәзенең зур булмаган дружиналары чик буендагы авыл-кирмәннәрне борчып китkәләсәләр дә, зурдан алып орышмадылар. Угланы әмир Хаҗи төньяк-көнбатыш чикләрне ныгыту исәбе белән Казан елгасының өске ягынарак кирмән салды. Владимир кенәзенең көчәеп китүеннән курка калган чирмеш бәгенә дә кала-кирмәнен ныгытырга булышты Сәлим хан. Шуның өстенә яңа сарай булдыру аның күптәнге хыялы иде. Ниһаять, менә сарай да өлгереп килә. Сарайның тәмамлануын күрергә, хан белән ханбикәгә ияреп, кызлары Назлыгөл дә килгән иде.

Беренче тапкыр шунда күрде хан кызы Назлыгөлне оста Алпар углы Дәүран. Күрде дә таң калды — шундаен гүзәл иде Назлыгөл, үсмер егет кыздан күзен ала алмый торды. Мәгәр үзендә ханбикәнең зәһәр карашын тоеп, шундук эшкә кереште. Күңеле — хан кызында, күзләре төшергән бизәктә иде егетнең. Аның каравы, анасыннан ниндидер тыю сизеп, Назлыгөл Дәүран остага игътибар итми калмады. Егетнең йөзендә дә, чәчләрендә дә таш оны, ул хәтта кершән булып кашкерфекләренә дә кунган иде.

Сәлим хан оста егет салган бизәкләргә карап торды-торды да:

— Киләчәктә менә кем Болгарда мәһабәт биналар торгызыр,— дип әйтеп куйды. Бәлкем атасының нәкъ менә шул сүзләреннән соң хан кызы Назлыгөл оста егеткә игътибар иткәндер? Ни генә булмасын, шул көннән алып Назлыгөл әтисенәме, әнисенәме ияреп, сарай бизәүчеләр янына килергә нияләште. Килә-килүгә, кыз оста егет янына ашыкты. Кызны күрүгә, егетнең дә йөрәге күбәләк канатларыдай талпынып куя торган булды. Дәүран кыз килмәгән көннәрдә кәефсезләнде, чарасыз калып, хан килеп керәсе капкага караштыргалады. Кызны күрмәгән көннәрдә йокысы йокы булмады, ашы аш дигәндәй...

Болгарда бер белекле кеше — кәтиб Хафиздан дәресләр алган хан кызы Назлыгөл мәхәббәтнең ни икәнен белә иде инде. Мөгаллиме аңа еш кына мәхәббәт хакында хикәяләр сөйли, ул гынамы, кызның йөрәген тагын да җилкендереп, көннәрдән бер көнне Сөләйман Суваринның «Нурларның яктылыгы — серләрнең хаклыгы» китабыннан сөю вә сөелү хакында матур-матур өзекләр укыды, шуның белән кыз йөрәгенә тагын да ялкын өстәде. Назлыгөл оста Дәүран төшергән бизәкләргә көннәр буена карап торыр иде дә, анасы ирек бирми: кызын оста егет янында тотасы килми, тизрәк алып китү ягын карый иде. Янына Назлыгөл килеп басу белән, Дәүран аңа сизелер-сизелмәс кенә сирпелеп ала һәм шуның белән кыз күңеленә янә ут өсти иде. Ә бит укытучысы кәтиб Хафиз бер күзгә-күз карашып алу дүрт мәгънәне аңлата ди: йөрәк ачкычын, күңел теләген, җан тиңлеген, әйтер сере барлыгын. Шушы бер карашы белән хан кызы оста Дәүранга йөрәк ачкычын бирде, күңел теләген аңлатты, җаны-тәне белән аңа тартылуын сиздерде, әйтер сүзләре барлыгын төшендерде. Тел белән әйткән сүзне барысы да ишетә, барысы да аңлый, күз карашын исә бары тик ике кеше генә аңлыйдыр. Бу хәлне гәрчә башкалар күрсәләр дә, ул аларга сер булып каладыр. Кызы Назлыгөлнең оста егет белән күзгә-күз карашып алулары Зөбәрҗәт ханбикәне тәмам чыгырыннан чыгара язды. Әйе, башкалар бернәрсә дә аңламый, хәтта Сәлим хан да; ә менә ана кеше булarak, ханбикә Зөбәрҗәт шундук нидер сизенде, нидәндер курыкты—

тизрәк китәргә ашыкты. Һәм, әлбәттә инде, баласын да калдырмады. Мәгәр соңарган булып чыкты — кыз йөрәгенә оста егетнең мәхәббәт угы кадалган иде инде. Кайтып барганда Назлыгөл сорап куйды:

— Инәй, останың аты ничек икән?

— Кол ул, балакай, атаңның колы. Атасы да кол, оланы да.

— Адәм баласы булгач, ди, укытучым, колның да аты була, ди.

— Сиңа аның аты кирәкми, балакай.

— Анасы кем соң аның, анасы бардыр бит, инәй?!

— Сиңа анасы нигә тагын!— дип кызның кулыннан тартып куйды ханбикә.

— Мин аның анасын беләм, инәй, укытучым әйтте...

— Белгәч, нигә сорыйсың?!— Ханбикә кызының яңагына сугып җибәргәнен сизми дә калды.

Назлыгөл еламады, киресенчә, анасына карап сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйгандай итте.

— Коллар алар, анасы да, атасы да, уллары да. Атаңның коллары!— Ханбикә кызын җитәкләргә иткән иде, Назлыгөл кулын кире тартып алды да алдан китеп барды.

Әйе, хан кызы Назлыгөл һәммәсен дә белә иде. Атасы Сәлим ханда кияүдә булган тархан кызы Туйбикә кол була алмый, шулай икән, аның улы да кол түгел. «Түгел!»— дип ярсынды Назлыгөл йөгерә-атлый анасыннан ерагая барып.

Ханбикә Зөбәрҗәт Сәлим ханны берәүдән дә көнләмәде, мәгәр күңел күгендә аның икенче хатыны Туйбикәгә карата һәрчак нидер пыскып торды. Ялкыны да, төтене дә юк иде әле ул көнләүнең, илләә Туйбикәнең җиткән улын күргәч, өстәвенә кызы һаман аның янына ашкынгач, күңел күгендәге пыскып торган көнләү галәмәте әкрен генә көйрәргә тотынды. Хәтерен актара башлагач, янә хикмәтле хәлләр искә төште. Ул Назлыгөлне тапкан төндә Туйбикәнең дә тулгагы тотып ятуын ишетеп, Сәлим хан сарай кендек әбисен аңа җибәргән иде. Хан кадәр хан кендек әбисен җибәрде Туйбикәгә. Ә бит исенә дә төшереп карарга тиеш түгел иде кебек, күптән колы Алпарга кияүгә биргән, күпме гомер узган... Ә хан һаман Туйбикәгә битараф түгел. Күрә ич ханбикә Зөбәрҗәт, сизә бит, ире оста балага да битараф түгел, хәтта аның белән горурлана кебек. Назлыгөле тагын, Назлыгөле ни кылана — оста егеттән күзен дә алмый.

Куркуы, үз-үзен тыя алудан гаҗиз калып кызына сугып җибәрүе бары тик шуннан иде ханбикәнең.

## 2

Бер атна элек кенә Болгар башкаласына зур кәрван белән килеп төшкән Хәрәзем шаһы илчесе үтерелү хәбәре Олуг Калага җитүгә, тынычлыгын югалткан Сәлим хан Исхак вәзирне ашыгыч төстә сарайга чакыртып алды. Әрмән кәләпүше кигән, кирәкмәгән чандыр гәүдәле, озын буйлы вәзире тәхет каршына килеп басуга, хан аннан төксе генә сорап куйды:

— Кем үлтерде Олуг Мөхәммәт илчесен?

— Ханым, колагым дөрес ишетәме, Садак илче түгел, сәүдәгәр иде кебек.

Вәзир шул сүзләрне әйтте дә, үзенең хаклыгына шикләнә калып, кечкенә өстәл янында утыручы хан кәтибе Хафизга күз төшереп алды. Аның бу кыланышына ханның ике ягына баскан җансакчылары ирен чите белән генә елмаешып куйдылар. Сарайдагы бар нәрсәдән дә хәбәрдар булган ханның җансакчылары вәзир Исхакның самимилегеннән елмаялар идеме, вакыйга хакында бер-бер яңалык беләләр идеме, вәзир шәйли алмады, әмма шундук аркасы тирләп чыкты, ул гынамы, сулкыл-

дап күз кабагы тартыша башлады. Вәзирдәге бу үзгәрешне күреп, Сәлим хан шикләнә калды, тегеңә текәлебрәк карады һәм тәхетенә тураебрак утырды да башын чөя төшеп:

— Вәзир Исхак, Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт илчесе Садак турында сүз бара. Беләсең килсә, Төн илләренә чыгарга ярлыкны мин аңа үзем биргән идем.

Бу хәтлесен генә вәзир Исхак белә белүен, әмма сәүдәгәр Садакның илче булуын тәүге тапкыр ишетүе идеме, эшнең асылына хәзер генә төшенгәндәй, әүвәлтен як-ягына каранды, ахыр ярдәм итәрдәй кеше тапмагач, кәтиб Хафизга текәлде. Хан кәтибе Хафиз гүя аны күрмәде дә, дикъкать белән каләм очлап утыра бирде. Вәзир җаны-тәне белән тойды: кайсыдыр бөҗрада хата җибәргән ул. Тәмам чарасыз калып, хан каршына баш орды.

— Гаеп миндә, шөһрәтлем, Олуг Мөхәммәт илчесен саклау өчен сак бирә алмадым. Мин аны чынлап та сәүдәгәр генә дип уйлаган идем, чөнки хәйләкәр илче ни сәбәпледер Шайтан каласы белән кызыксынды, барыр юлын да шуннан башлады. Аннары иң хәтәре — тимерче Әхмәт углы Бәкер белән кызыксынды. Сезләргә мәгълүм булса кирәк, Болгар Шайтан каласында чуен коя, күпләп тимер ясый. Белгәнемчә, ханым, ул чуенны башка илләрдә коючы юктыр. Моңа кадәр Шайтан каласына ят берәүнең дә кергәне юк иде кебек. Әмир Хаҗи угланыгыз Шайтан каласын күз карасы кебек саклый...

Сәлим хан вәзирен тыңламый иде инде, ул, тынычлыгын югалтса да, сабыр итте, дәшмәде, авыз чите белән генә мыскыллы рәвештә елмаеп куйды. Вәзир Исхак элек бар нәрсәдән дә хәбәрдар булыр иде, кыен хәлләрдә калган ханга ярдәмгә һәрчак үзе килер: киңәшен бирер, кыен хәлләрдән котылу әмәлен табар иде. Күп изгелекләр эшләде вәзир Сәлим ханга, димәк ки, Болгарга. Эшли тора, тагын да эшләр. Әнә күрше Владимир кенәзе белән ничек җайлады: киңәшүләр алып барды, ике арада сәүдә эшен тагын да җанландырып җибәрде. Ул гынамы, хан угланы Илһамга кенәз нәселеннән кәләш алып кайтты. Ә менә Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт илчесе Садакка мөнәсәбәттә ул хата җибәрде, күрәсең — кулында хан ярлыгы булган кешегә сак бирмәгән. Ә бит белде Төн илләренә китүен. Белде. Ләкин кем уйлаган аның Шайтан каласына керәсен! Аннары кем ачыклаган аның илче икәнен. Вәзиргә Садакны сәүдәгәр диделәр. Шәех Игәнәй шулай диде. Ялганлады булып чыгамы? Бик ихтимал ич! Шәех Игәнәй күптән өнәми иде аны. Җитмәсә, хан угланы Илһамга кенәз нәселеннән кәләш алып кайткач. Әнә ул ничек, гел инде тәгәри китте йомгагым шикеллерәк. Вәзир Владимирдан кайтып кына төшкән иде, ашыга-кабалана шәех Игәнәй килеп керде һәм беренче сүзе итеп: «Сәлим хан Олуг Мөхәммәт сәүдәгәре Садакка Төн илләренә чыгарга ярлык бирде, сак кирәкмәс, мин аңа үземнең бер мөридемне кушып җибәрәм»,— диде. Вәзир Исхак хан белән киңәшеп тормады, шундук килеште. Хан ярлыгын алган читятларны элек тә шәех мөридләре озаткалыйлар иде. Ә ул әнә ничек килеп чыкты: шәех Игәнәй күләгәдә калды, ә таякның юан башы Исхакка төште. Бөтен хикмәт шунда иде: нигә дип Садак Шайтан каласына керә? Хәер, җүләр булмаса, Сәлим хан бу хакта белергә тиеш иде кебек, ә ул гел белмәмешкә сабышып тора. Шайтан каласына кем керсә дә, аннан исән-имин чыкмас иде. Димәк, Сәлим хан Садакка ярлыкны белеп биргән булып чыга? Әллә ни шунда. Үтереләсен белгәч, нигә дип ярлык бирә. Бәлкем ул илченең Шайтан каласына керәсен белмәгәндер? Алай дисәң, нигә дип шәех Игәнәй мөриден илчегә ияртеп җибәрә? Кем тозак кора вәзир Исхакка? Ханмы, шәехме? Әллә соң бердән эш итәләрме? Вәзир Исхак кирәкми башладымы ханга? Шайтан каласына чит-ятларны кертү тыелганлыгын барысы да белә, хәтта шәех Игәнәй дә, хан турында әйтеп тә торасы юктыр. Шайтан каласына кергән чит ил кешеләренең аннан исән чыкканнары булмады, моннан соң да булмас. Бол-

гар дәүләте чуен кою серен сакларга тиеш. Бәлкем шуңа күрә сәүдәгәр Садак Болгарга илче сурәтендә килгәндер? Бик ихтимал ич!

Илчегә үлем юк, дигән борынгы төркиләр. Болгар аны бозды, соңы хәерле була күрсен. Ә бит моңа кадәр Болгарга килгән илче һәрчак исән-имин кайтып китә иде. Бүген исә ил-туранда булмаган хәл кылынды. Тәңре каргышлары төшмәгәе Болгарга. Бу хәлдән хәтта хан үзе дә курка калган, илчене үтерүчене таптырасы килә. Таптырып ни кыла алыр? Үтерүче угланың әмир Хаҗи булса, нишләрсең, Сәлим хан? Анысын белмим, ә менә бүтән икән, ике дә уйламыйбашын кистерерсең, я булмаса, дар агачына астырырсың. Тик менә сәер хәл: нигә дип әлеге Садак Шайтан каласына керергә теләде икән? Билгеле инде, чуен кою серен белергәдер. Юха еландай сәүдәгәр Садакны Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт илчесе итеп Болгарга җибәрә. Бурычы гаять тә кәттә илченең: Шайтан каласына үтеп керергә, ул гынамы, чуен кою серен ачарга, я булмаса чуен коючыны урлап Өргәнечкә алып кайтырга. Адәм баласы күтәрә алмастай бурыч йөкли Олуг Мөхәммәт илчесе Садакка. Нигә дип ярлык биргән Олуг Мөхәммәт илчесенә Сәлим хан? Ярлык бирмәгән хәлдә илче, бик ихтимал, борылып кайтып китәр иде. Әмма Сәлим хан Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт бик сорагач, бик үтенгәч, каршы килә алмаган. Илчесе үлеме хакында ишетсә, Олуг Мөхәммәттән мәрхәмәт көтмә, яу килмәсә дә, Сәмәрканд, Бохара, Өргәнеч, Һират һәм башка калаларындагы Болгар сәүдәгәрләрен дар агачына астыруын көт тә тор. Моның ахыры ни белән бетәсен Сәлим хан бераз абайлый сыман. Андый гыйбрәтле хәлләр элек тә Болгарда булгалаган. Ибраһим хан Болгар тәхетендә утырган мәлдә Бөек Калага йөзбашы Тургай белән кыпчак ханы Әюп килә. Ни өчен килә дала ханы Бөек Калага — Болгарга? Тарихчы бу хакта язмый. Мәгәр вәзир Исхак бераз чамалый — изге теләк белән килә дала ханы Болгарга — берләшергә тәкъдим итә, Болгардан Азакка, Азактан Румга сузылган сәүдә юлын сакларга вәгъдә итә. Сөйләшүләр барышында Болгар ханы Ибраһим дала ханы Әюпкә Владимир кенәзе Юрий Долгорук белән Болгарга яу килүен исенә төшерә. Булмаган хәл түгел, булган хәл. Җитмешне узган Әюп хан иң яраткан кызы Сусылуны Владимир кенәзе Юрий Долгорукка кияүгә бирә. Кияү булгач кияү, тегеңә кыенга килгәндә һәрчак ярдәм кулын суза — яуга дәшсә яу бара. Хак анысы, дала ханы Әюп кияве Юрий Долгорукка ияреп бер Болгарга гына яу килми, Новгород, хәтта Кияүкалага да яу чаба. Кыскасы, кыпчак ханы Әюп кияве ярдәм сораганда бернәрсәдән дә баш тартмый. Әйе, киявенә ияреп килә кыпчак ханы Болгарга, Иделнең өске ягындагы олы базар каласын киявенә алырга ярдәм итә. Нәкъ менә шуңа Болгар ханы Ибраһим аны кичерә алмый. Һәм гаять җитди тәкъдим белән килгән кыпчак ханы Әюпне агу эчертеп үтерә, ә йөзбашы Тургайны Өргәнечкә кол итеп сатып җибәрә. Берәүләр Ибраһим хан кыпчак ханы Әюпне агулап үтерткән, диләр, икенчеләре базга ташлаткан, имеш, дип сөйлиләр. Ни генә булмасын, Әюп ханның үлеме Болгарга явызлык китерә. Болгар ханы Ибраһим җитмеш яшьлек Әюп ханны үтереп кенә тынычланмый. Владимир кенәзе Юрий Долгорук Кияүкалага яу киткәч, аның калаларына яу чаба, әллә ни зыян итә алмаса да, буш кул белән әйләнеп кайтмый.

Бәйрәм ашы кара-каршы, диләр.

Кияүкала тәхетендә калган Юрий Долгорук угланы Андрей Боголюбка васыять әйтеп җибәрә: бабам Әюп өчен болгарлардан үч ал! Атасы авырып китеп, дөнья куйгач, тәхеткә утыруга, Андрей Боголюб, гәрчә үзе Ибраһим ханның сеңелесе Рокыяга өйләнгән булса да, Болгарга яу чаба — атасы васыятен үти. Хәтәр бетә Болгар өчен бу яу. Андрей Боголюб Болгарга буйсынып яшәгән мукшы илтабары Пургасны үз канаты астына ала. Болгар ханы Ибраһим яшь кенәздән шактый алтын биреп кенә котылып кала. Әнә шулай әкрен генә Болгар белән урыс кенәзләре арасы бозыла башлый. Мөэмин хан чорында урыс кенәзе Свя-

тослав Болгарга янә яу килә, әлбәттә, инде ул да буш кул белән генә кайтып китмәгәндер. Хак анысы, ханнар, кенәзләр арасында сугышлар гел юктан да булгалап тора. Берәүләре тәхет бүлешә — туган белән туган орыша, икенчеләрен күрше байлыгы кызыктыра, өченчеләренә җир-су җитми, дүртенчеләренә көтүлекләре аз тоела, бишенчеләре данга сусаудан яу чаба, алтынчылары базар бүлешә, җиденчеләренә хатын-кыз сәбәпче була. Урыс белән болгар арасында исә һәрчак базар өчен орыш бара. Куәт вә гайрәт җыеп килгән Владимир-Суздаль кенәзе белән Болгар ханы Сәлим хәзер солыхта. Мәгәр бу озакка барырмы? Андрей Боголюб кенәз Болгар килене Мәрьямбикәгә ияртеп, аның тынычлыгын сакларга дигән булып, Сәлим ханга йөзбаш Баянны җибәрә. Мәрьямбикәнең тынычлыгын Саксинда сакларга тиеш була ул, әмма Сәлим хан Баянны һәм аның азатларын[1] үз сараена ала. Ул гынамы, Баян баһадир үтенечен тыңлап, Бөек Калага чиркәү салырга рөхсәт итә. Бу хәлне ишеткән Андрей Боголюб Сәлим ханга олау-олау бүләк җибәрә. Бүләкләр белән бергә христиан динен кабул иткәннән соң Болгардан китәргә мәҗбүр булган, Суздальда епископ дәрәҗәсенә ирешкән Габбас та килеп төшә. Габбасның Болгарга кайтуы Бөек Калада гелән бәйрәм төсе ала, христиан динендәге әрмәннәр, греклар, урыслар, болгарлар чиркәү тирәсенә җыелып өч көн гыйбадәт кылалар. Юрий Долгорук заманында ук Бөек Калада үз урамын булдырган Владимир каласының бай сәүдәгәре Кучкин, шушы җайдан файдаланып, Сәлим хан казнасына өч мең алтын бирә. Чиркәүне Болгар осталары күтәргән була, аларга да мулдан түли Кучкин сәүдәгәр. Шушы көннән алып, Бөек Кала өстендә даң-доң чаң суга башлыйлар. Мөселман мәхәлләләрендә яшәүче болгарларның моңа эчләре поша, шәех Игәнәй исә тәмам ярсына, йокыдан кала, мәгәр әллә ни кыра алмый — Сәлим хан шәехне бик тиз тынычландыра. Хан, мәхәлләне тынычландырырга дип, сарай азатлары башында торучы Баян баһадирны җибәрә. Шаулаша башлаган, христианнар урамына йодрык күрсәтеп җикеренгән бер-ике мөселманны сөңгегә алгач, халык бик тиз тарала, кемнеңдә хан зинданында черисе килми, күрәсең. Шушы көннән алып ике дин әһеле арасында күзгә күренмәгән, әмма күңел күзе һәрчак күреп торган яман сугыш башлана. Болгарның Айдар хан заманыннан ук ислам динен кабул итә башлавын искә алып, шәех Игәнәй Олуг Мөхәмматкә хат арты хат җибәреп зарлана һәм шул чакта Хәрәзем шаһына Болгарда тиңе булмаган тимер-чуен коя башлаулары хакында хәбәр итә.

Күршең белән тату яшә, сәүдә ит, күк астында барыбызга да җир җитәрлек тә бит, әллә нигә без теләгәнчә генә бармый. Борынгы бабаларыбыз бик дөрес әйткәннәр югыйсә: «Күрше хакы — тәңре хакы!». Явызлык Болгарга һәрчак явызлык кына китерде. Менә тагын бер яман явызлык кылынды: Болгарда илче кадәр илче үтерелде.

— Вәзир Исхак,— диде Сәлим хан бертын уйланып утыргач.— Бу ни инде тагын? Ил өстенә янә явызлык юллавыңмы?

— Иртәгә ни буласын белү бары тик пәйгамбәрләргә генә хас сыйфаттыр, ханым. Мин гаепле, ялгыштым.

— Ялгыштым, имеш. Уйлап карадыңмы, вәзир, ни баһагә төшәчәк бу ялгышың? Дәшмисең, вәзир! Йә хода, элек базар-калалар өчен сәүдәгәрләр генә ызгыша иде, хәзер әнә ханнар кылыч уйната башлады. Болгарда булган гыйбрәтле хәлләрне исеңә төшеримме әллә, вәзир? Кыпчак ханы Әюпне үлтереп Ибраһим хан ни отты?! Иделнең өске ягындагы сәүдә каласын кулдан ычкындырды, мукшы илтабары Пургасны югалтты. Илчесен үлтергән өчен Олуг Мөхәммәт Болгарга яу белән килеп төшмәсме?!. Мин сиңа, вәзир Исхак, җирем-суым, илем-халкымны ышанып тапшырдым. Әйт киңәшең, ни кылыйм?

— Ханым, киңәшем сезгә шул булыр: Идел буена кирмән кала сал.

[1] Азатларын — Меңбашка буйсынган сугышчылар, дружина.

Олы су юлы өстендә булсын, җиде юл чатында утырсын. Иделнең өске ягындагы сәүдә каласын күмеп китсен. Олы Иделгә койган Казан елгасы тамагында күз күреп туймаслык урын бар.

— Вәзир Исхак, белсәң булса кирәк, мин ул җирләрне угланым Хаҗига бирдем.— Сәлим хан ирен чите белән генә елмаеп куйды, кисәк аның башына шаккатмалы бер уй килде: Исхакны яңа базар-кала салынасы урынны карарга җибәрергә. Хаҗи углан Казан елгасы буена чак кына өскәрәк кирмән салды, әмма сәүдәгәрләр анда бик сирәк күтәрелә. Казан елгасы тамагына базарлы зур кирмәнкала салганда Хаҗитархан сәүдәгәрләре өске якка күтәрелеп тормаслар иде.— Син хаклы, вәзир.— диде Сәлим хан тавышын ягымлылата төшеп.— Казан елгасы тамагына базарлы кирмәнкала салсак, Болгар отар иде. Ләкин анда яшәгән чирмешләр вә төркиләр ул төбәкләрне мактамый. Елан, кабан дуңгызы күп икән. Елан патшасы Аждаһа шунда яши икән, дип тә сөйләүчеләр бар.

— Елан камнар гайбәте генә ул, ханым. Шул төбәктә яшәгән кам ул еланнарны үзе үк бетерер дә. Мин шул урыннан да кулай төбәк белмим, ханым. Хәзәр диңгезеннән күтәрелгән һәр сәүдәгәр юл өстендәге базарлы калага туктамый калмас. Аннары янә бер нәрсә бар, ханым. Төн илләреннән килгән халык та шунда җыелыр иде. Сәүдәгәр бал корты кебек бит ул, товарлы җирне үз күрә.

— Хуш, вәзир, ышандык та ди сиңа. Кәтиб Хафиз әйтә, вәзиргә ун сыйфат хас булырга тиеш ди: үткен күз, сизгер аң, киң күңел, затлы кием, ягымлы мөнәсәбәт, саф акыл, югары белем, мәһабәт кыяфәттер, ди. Янә алдан күрә белү һәм, әлбәттә инде, илгә мәхәббәт һәм тугрылыктыр. Кала кадәр кала салу авыл торгызу гына түгел, акча кайдан алырбыз, вәзир?

— Ханым, угланың әмир Хаҗида бүген җиде кала торгызырлык байлык бар.

Вәзире Исхактан бу хәбәрне ишетүгә, Сәлим хан хәтта тәхетеннән күтәрелә төште.

— Угланда? Байлык?! Каян килсен аңа ул тамаша байлык?! Дөрес ишетәмме, вәзир?!

— Дөрес ишетәсез, ханым. Әмир Хаҗи кулында Урал таулары, эремә таш базлары. Күпләп чуен коя угланың әмир Хаҗи. Чуеннан тимер ясый. Шайтан каласына бүген дә олау-олау эремә таш кайта. Тимерче Әхмәт угланы Бәкер аны корыч тимергә әверелдерә. Эшләр болай барса, Болгар калаларының коймаларына кадәр чуеннан булырдыр дип уйлыйм мин, ханым. Бу ысул белән тимер табуны нә Румда, нә Өргәнечтә, нә Нәүгәриттә белмиләр. Чуен башы Болгардыр, ханым. Байлыкны саклый белгәндә, тиздән Болгар кала өстенә кала сала башлар. Хәзер шигем калмады, Олуг Мөхәммәт илчесе Садак чуен коючы Бәкерне кулга төшерергә килгән булуы ихтимал. Чуен коюны тимерче Әхмәт белән улы Бәкер генә белә. Әхмәт үзе түгел, улы Бәкер коя чуенны...

Сәлим хан беравык дәшми утырды. Ниһаять, ул вәзир әйтергә теләгән сүзнең асылына төшенде булса кирәк, Бусагабашка кул изәде. «Димәк,— дип уйлады Сәлим хан,— Олуг Мөхәммәткә табиб Хәсән түгел, чуен коючы Бәкер кирәк булган икән. Димәк, Садак илче булмаган, шымчы, кеше карагы, бер хода белә кемдер». Алай да Сәлим ханның тәүге карарыннан кайтасы килмәде. Илче кадәр илчегә кул күтәргән икән, ул җәзасын да алырга тиеш.

— Вәзир Исхак, Садак ни өчен килсә дә, аны кем үлтергәнне белергә телим. Син миңа шул үтерүчене табып бир. Миңа калса, вәзир, син ханыңнан нидер яшерәсең кебек?

— Баскан урынымда җир упсын, ханым, берни дә белмим,— диде вәзир Исхак һәм уйлап куйды: «Әйтергәме шәех Игәнәй хакында, юкмы? Юк, кирәкмәс, шәех белән бәйләнмә, шәех кулында көч-куәт, ниһаять, бөтен ислам дөньясы.— Коръән тотып ант итәм, ханым, мин Олуг

Мөхәммәт илчесен үлтерүчене табармын. Кеше инә түгел, дигән борынгылар.

— Вәзир, безгә бу җирләрне бабабыз Кубрат хан биреп калдырган. Угланы Кодрак, хәзәрләр кысуга түзә алмыйча биргә күчеп китәргә мәҗбүр булгач та, мөстәкыйльлеген югалтмаган. Ул гынамы, Идел, Җаек, Чулман, Агыйдел, Ука, Зөя, Ык елгалары буйларында көн күргән төрки бабаларыбызның ырулары белән кардәшләнеп алган, чирмеш, угыр һәм янә бүтән кабиләләр белән дуслашып, сәүдә итә башлый, ахырда тыгыз элемтәгә керә — дәүләт оештыра. Болгар куәтләнеп киткәч, кала өстенә кала торгыза, Табгач, Кияүкала, Рум, Өргәнеч шәһәрләре белән сәүдә итә башлый. Болгар иген игә, мал үрчетә, тире или, бал җыя, балавыз сыга, сумала кайната, балык җилеме җитештерә, кием тегә, ук-сөңге ясый, хәзер әнә чуен коя башлый. Болгар үстергән ашлыкны Румнан, Новгородтан килеп алалар. Ата-бабаларыбыз биреп калдырган мул сулы елгаларыбызны, кара туфраклы уңдырышлы җирләребезне, базарлы калаларыбызны саклау өчен гаскәр кирәк. Беләсеңдер, Ибраһим хан Владимир кенәзе Юрий Долгорук белән базар бүлешә алмый яшәде. Без исә аның хаталарын кабатламаска тиешбездер. Минем берәү белән дә ызгышып яшисем килми. Олуг Мөхәммәткә хыянәт иттек — илчесен үтердек. Олуг Мөхәммәтнең кулы озын, Болгарга гына җитәр. Әүвәл аягы керсә, үзе дә килер. Шуңа күрә боерам: чик буенда торучы баһадирларга ямчылар җибәр. Бүгеннән алып, чик аша бер генә сәүдәгәр дә, бер генә дәрвиш тә чыкмасын да, кермәсен дә. Кыен хәлдә калдык без синең белән, вәзир Исхак.

— Гаеп миндә, шөһрәтлем. Кичерә күрегез.

— Сине кичереп кенә илгә иминлек килсә икән ул!

— Хак әйтәсез, шөһрәтлем.

— Хаклык — саклык билгесе. Җир телсез булса да, ил күзсез була алмый. Ил күзе син булырга тиеш идең, вәзир. Без барыбыз да кыйблага карап намазга утырабыз, аллаһы тәгаләгә изге сүзләр яудырабыз, ә күңелләребез сафмы? Ул хакта уйлап та карамыйбыз.

— Йә аллам, тәүбә диегез, шөһрәтлем!

— Адәм баласының йөрәк телен белсәң икән ул, вәзир,— диде Сәлим хан уйга калып. Бераздан дәвам итте:— Кем Болгарны саклый бүген, вәзир? Кыпчак, урыс азатлары да йөзбашлары. Кайда болгар үзе, ни белән шөгыльләнә? Сату итә болгар, һөнәр иясенә әверелеп китте: тегүче, тире иләүче, тимерче, ташчы, сәүдәгәр, һич югы бал җыя, я булмаса, дәрвишлек кыла. Куасы иде Ага Базардагы бөтен булган дәрвишләрне Төн илләренә дә, шаех Игәнәй каршы. Имеш, дәрвиш халкы — изге җан ул. Ил кайгысы калмады болгарда, вәзир. Менә син үзең кем идең? Минем вәзиремә? Атаң кем иде?

— Без — тураннар, ханым. Бик борынгы халык. Бу хакта фарсы шагыйре Фирдәүси дә язып калдыра. Хак әйтәсез, ханым. Туранның бер өлеше кыйбланы йөрәк белән, беришe йөз белән тоядыр. Иман йөрәк аша үткәндә генә ил турында кайгыртадыр кеше, ханым. Бердәмлек югала бара Болгарда. Әнә энегез Мөхәммәтгалим бәк нишләде? Кул астыгыздан качып, кыпчак ханы Янтакка барып елышты. Шуңа күрә әйтүем моны, ханым, Казан елгасы тамагына салынасы кала базар төбәге генә булып калмасын иде, Казан кирмәне дә булсын иде. Ил терәге булырдай кирмән торгызылса, Болгарның куәте тагы да артыр иде. Миңа калса, угланыгыз Әмир Хаҗиның Казан кирмәнен шул төбәккә күчерергә кирәк. Яңа урындагы кирмәннең диварлары, манаралары таштан булсын, Болгар остага беркайчан да мохтаҗлык кичермәде. Янә бер киңәшем бар, ханым. Ул хакта үзегезгә генә әйтер идем.

— Киңәшең әйтерсең. Дала төлкесе Янтакны исемә төшереп, ачуым чыгардың әле. Ни җитмәгән тагы аңа? Болгар тәхетен энемә алып бирергә җыенамы әллә тагын? Мин энем Мөхәммәтгалим бәккә изгелек кылмадым дигән кешенең теленә тилчә чыгар. Нә малы, нә кирмәне булма-

ган көе мин аңа Саксин каласын бирдем. Суарын ышандырырга җыенган идем, юк, канәгать булмады, баш күтәрде. Башын диванага салып йөргән өчен халык үзенә «Карак Галибәк» дигән кушамат такты. Илгә әйләнеп кайтса, Карак Галибәкнең башы минем сөңге очында булыр.— Сәлим хан тәхет булмәсендә калган бердәнбер кеше — кәтиб Хафизына таба борылды:— Син ни әйтерсең бу хакта, Хафиз?

— Уйлаганым шулдыр ханым: бер акыл иясе «Алты чирүең булганчы, алтын вәзирең булсачы!» дип әйтеп әйткән.

— Хак әйткән. Ә менә син, вәзир Исхак, алтын була алмадың. Йә, хәзер киңәшең әйт. Хафиз, булмаса, син чыгып тор.

— Ханым, борынгы бабаларыбыз, кала-кирмәннәрен мәңгеләштерү өчен кала торгызыласы төбәккә хан нәселеннән ир бала корбан иткәннәр, ягъни тереләй кала нигезенә күмеп калдырганнар.

— Гафил булганнар бабаларыбыз, вәзир. Иллә сүзеңдә хаклык бар. Борынгылар һәрнәрсәне ихластан эшләгән. Мин бу хакта уйлап карармын, вәзир, уйлап карармын. Инде дәш һәммәсен дә. Хафизны да дәш.— Кәтиб Хафиз килеп кергәч, хан аңа Олуг Мөхәммәтнең хатын укырга кушты:— Укы әле шул хатны тагын бер, кәтибем,— диде.

Кәтиб Хафиз Сәмәркандтә эшләнгән кәгазь төргәгенә язылган Олуг Мөхәммәт хатын сүтеп җибәрде һәм, шаех Игәнәйгә охшатып, бераз гына тыңкышлап укый башлады.

*«Бисмиллаһи р-рәхмани р-рәхим! Туран дөньясында олуг дан тоткан, илаһи әмерләр биреп халык вә илен бәхетле иткән шөһрәткә ия Бөек Болгар ханы, ышбу хатны Хәрәземшаһ Олуг Мөхәммәт юллый. Кош теле хәтле генә хатымны җанын фетнәгә салырлык дәрәҗәгә җитеп мәне якын күргән илчем Садак тапшырыр. Ыру-кардәшем Сәлим, без икебез дә ислам күге астында җиде елга, җиде тау, җиде дала илендә яшибез. Безнең иман-тел вә гореф-гадәтләребез генә түгел, гозер-зарларыбыз да бердер: илләребездәге хөрмәткә лаеклыларның дан-дәрәҗәсен күтәрү, күрше-күләнгә игелек кылудыр. Хактыр, Туран илтабарлары һәрчак киң күңелле, юмарт, гадел вә ярдәмчел булдылар, шуңа күрәдер, аллаһы тәгалә безгә һәрчак игелекле булды, мәрхәмәтеннән ташламады, язган итсә, киләчәктә дә ташламас. Иншалла, иман китергән адәм үз теләгенә ирешер, аллаһы тәгаләнең кодрәте зурдыр. Илчем Садакның Төн илләрен күрәсе килә, шуңа, рәхим итеп, шул тарафларга чыгарга ярлык бирерсең. Гозеремнең беренчесе шулдыр. Бер хакыйкать бардыр: аллаһы тәгалә безгә шаһ дәрәҗәсен бирсә дә, сәламәтлеген аның үз кулына тапшырган. Сырхаулап киттем бит әле, ыру-кардәшем Сәлим. Ашаганым аш түгел, эчкәнем бал, дигәндәй, дөньядан ямь, яшәвемнән тәм тапмый башладым. Хак тәгалә якты дөньядан берәүнең дә тәкъдире җитмичә киткәне юк. Өмет белән яшим. Үткән айда син җибәргән атыданы Туран дөньясына таралган табибем Таҗетдин Болгари вафат булды. Өргәнечкә төкле аягы, җиңел кулы белән килгән иде, авыр туфрагы җиңел булсын. Ыру-канкардәшем Сәлим, син һәрчак гозер иткәнгә иман-игелек кылып, яманлыкны тыеп, яхшылыкны яклап хакимлек иттең. Икенче гозерем шулдыр: сараеңда мәрхүм Таҗетдин Болгариның энесе Хәсән ибне Юныс табиблек итә икән. Җибәрче аны Өргәнечкә! Үтенечем кире какмасаң, аллаһы тәгалә берне ике итеп кайтарыр.*

*Тазаррыг кылып, өмет итеп Хәрәземшаһ*
*Олуг Мөхәммәттер».*

— Инде инандыңмы, вәзир Исхак, илче Садакның кем булуына? Ә син аны шымчы, тимерче урларга килгән карак иттең. Боерам: Олуг Мөхәммәт илчесе Садакка кул күтәргән кеше атна-ун көн дигәндә сараем зинданында булсын! Аннары Чәчкә бәйрәменә кенәз Андрей Боголюбны чакырт. Янә тагын, бәйрәм үтүгә, базарлы кала төбәген карарга китәрсең. Үзең белән Сувар казыйны, кәтиб Хафизны алырсың. Әйе, оланнар да кушылыр. Баһадир Баян озата барыр.

— Минем үз азатларым да бар, ханым.

— Үзеңнекеләрне калдырып торырсың. Гали белән Булат яңа кала нигезен үз күзләре белән күрсеннәр.— Сәлим хан бертын уйланып торды да һәммәсенә дә күз йөртеп чыккач:— Өстәмә боерыгым Баян баһадир кулындагы хатта булыр, хатны анда баргач кына ачып укырсыз! Үтә кушканны, вәзир!..

Вәзир Исхак барысына да төшенде. Сәлим ханның теләге изгедә— яңа кала салынасы төбәктә... Калганы хакында уйларга кодрәте житмәде Исхакның. Шулай ук аның киңәшен тотарга исәпләдеме хан? Йә ходам, тагын ни белән бетәр бу хәл?!

— Шөһрәтлем, оланнар нигә кирәк анда?— Вәзир хан алдына тезләнде.— Хаталандым мин...

— Тор, вәзир! Шатланасы ит. Мин киңәшеңне тотарга карар иттем. Барысы да син дигәнчә килеп чыкса, урының ил түрендә булыр.

Вәзир әкрен генә күтәрелде, күндәм генә ишеккә таба кузгалды.

— Сабыр ит, вәзир!— диде хан.

Вәзир ханга таба борылды, баш иде.

— Тыңлыйм, шөһрәтлем.

— Әллә киңәшең тотып ялгышлык кыламмы, вәзир?

— Бер хакыйкать бар, ханым. Гаепле — бер, гаепләүче — икеләтә гөнаһлыдыр. Инде тагын бер киңәшемне тыңлагыз, ханым. Жибәрмәгез табибегез Хәсәнне Олуг Мөхәммәткә. Ул сезгә аны кире кайтармас. Гарәпләр: әүвәл сәламәтлегеңне сакла, аннары илеңне, дигәннәр.

— Вәзир Исхак, ханга тагын бер-бер әйтер сүзең бармы?

— Кичерә күрегез, шөһрәтлем. Мин биредә бары тик канат кагучы гына, сез очучы вә очыртучыдыр.

Сәлим хан каударланып көмеш кыңгыравын зеңләтте, шунда ук хан каршына бусагабаш Камай килеп басты.

— Ни боерасыз, ханым?

— Шәех Игәнәйне, табиб Хәсәнне, башказый Ишкулны һәм ханбикә Зөбәржәтне дәш. Тиз йөре, бер аягың монда, бер аягың анда булсын.

Кәтиб Хафизны, сарай елъязмачысын, Сәлим ханга угланы Хажи табып биргән иде. Берәүләр Хафизны әүвәл Багдад солтанында китап күчерүче, берәүләр битекче, хатчы булып торган, өстәвенә солтанга мәдхияләр укыган, дип әйтәләр. Әмма сарай кәтибе Хафизның кем икәнен белүче бердәнбер кеше әмир Хажи иде. Кәтиб Хафиз Багдад солтанында да хезмәт итмәгән, хатчы да, китап күчерүче дә булмаган, гәрчә бу эшләрне башкарып килсә дә, ул нигездә китап жыючы иде. Китап сатып алу өчен ул төрле эшләр башкарды: битекче дә, язу күчерүче дә, тимерче дә булды. Әмир Хажи исә аны тимерче Әхмәт алачыгыннан табып алган иде. Көннәрдән бер көнне угланы әмир Хажига Сәлим хан килеп керде. Күрде дә угланы әмир Хажида китап күчереп утыручы Хафизны, икенче көнне үк аны сарайга илтеп куярга боерык бирде. Чарасыз калган Хажи атасына каршы сүз әйтә алмады, Хафизны төяде дә сарайга озатты. Сәлим хан монда аны кәтибе итте һәм, китаплар күчерү белән бергә, аңа ханлык елъязмасын алып баруны йөкләде. Кәтиб Хафизның иллә дә матур язуына сокланмаган кеше юк иде. Хатчы үзенә йөкләнгән һәр эшне бирелеп, самими рәвештә һәрчак жиренә житкереп башкара, Хафизның бу тырышлыгын күреп, Сәлим хан аңа хезмәт хакын арттыра, сарай өчен китаплар алуны йөкли. Шул заманнан бирле базарда хан кәтибе Хафизны күрә башлыйлар. Аның янында хан казначысы булыр, Хафиз теләгән китапларны капчыкка тутыра барыр, акчасын түләр һәм бертуктаусыз сукраныр: «Хөрмәтлем, бу хәтле китап сиңа нәрсәгә, астыңа жәеп ятарга жыенмыйсыңдыр лабаса? Алай дисәң, тышлары каты»,— дип сукраныр. Әмма аны Хафиз гүя дә ишетмәс, яңадан-яңа китаплар эзләр, табар, алыр һәм хан сараена алып кайтыр, хан китапханәсенең шүрлекләрен яңа китаплар белән тутырыр иде.

Әнә шулай Хафиз хан сараена бик тиз ияләшеп китә. Ул хезмәт хакы турында уйламый диярлек, аңа яңа китап булса, шул бик житкән. Казанган акчасын да ул бары тик китап алырга гына тота. Хафиз сарайдагы берәү белән дә дуслашып китә алмады. Казна башы белән исә ул үзен бик яман тотты. Анысы Сәлим ханга да зарланып алды, әмма хан аны тыңларга да теләмәде.

— Шәхес буларак кәтиб Хафиз барыгыздан да өстен, казнабаш. Юкны сөйләп йөрмә!— диде.

Казнабаш телен тешләргә мәжбүр булды, чөнки хан хаклы иде, сарайда, кәтиб кебек, үз эшен жиренә житкереп башкаручы юк. Аннары Хафиз сарайда булган хәлләргә: ыгы-зыгы, жәнжаллар, гайбәтләр, тантаналарга бөтенләй катнашмады, гүяки, ул хәлләр аңа кагылмый да иде. Аның үз эше — өстәле-кәгазе, карасы-каләме бар, аннары китаплары. Хан китапханәсе аның иң зур байлыгы иде, ә дөньяви хәлләр аны кызыксындырмады диярлек. Сарайга күчеп килү белән Сәлим хан аңа тарих китабын бирде. Кәтиб Хафиз Болгар галиме Ягкуб Ногман кулы белән язылган китапны ачты да күз яше белән елап жибәрде. Күрәсең, бу китапны кулына тоту аның күптәнге хыялы булгандыр. Шуннан иманды Сәлим хан кәтиб Хафизга — изге кеше, шундайлар житми аның сараена. Кәтиб Хафиз өчен шул көннән алып, китаплар дөньясындагы хәлләр киңәя барды, сарайда булып торган хәлләр көннән-көн тарая барды. Ул шул кадәрле бирелеп эшләде ки, гүя, аның янында кешеләр дә юк иде, гүя ниндидер шәүләләр генә йөри. Ул аларны күрми, күрсә дә ишетми, ишетсә дә һични белән дә кызыксынмый. Иллә тирән фикер ияләрен ишетә һәм тизрәк акыл иясе сүзләрен язган китабына төшереп калырга ашыга иде. Вәзир Исхак кебек кешеләр Хафиз өчен әллә бар, әллә юк, хәтта тәхеттә утыручы хан үзе дә аның күзенә бик сирәк чалына иде. Ул аларны күрмәде. Бердәнбер игътибар иткән кешесе — бусагабаш Камай иде. Бәлкем Хафиз башкаларга игътибар итмәгән кебек, аңа да игътибар итмәс иде, бусагабаш Камай чамасыз юан һәм кечкенә гәүдәле булмаса. Аяклары кыска булу сәбәплеме, ул атлап йөрми, гүяки тәгәрәп йөри кебек иде. Авызы зур, иреннәре калын, тешләре сирәк, әйткән сүзен бер тыңлауда гына аңлап бетермәле түгел. Хәер, Хафизга аның сүзләрен аңлавы да кирәкми иде, кәтибне Камайның килеш-килбәте, кыяфәте кызыксындыра. Ул беркайчан да ханнан кайтарып сорамас, һәрчак кушканны гына эшләр, бәлкем шуңа гамьсездер, шулай пошмаганга юандыр Камай. Кайчак Сәлим хан Камайны каршы кайтарып сорамаган өчен генә сараенда тота кебек тоела иде Хафизга. Ни генә булмасын, Сәлим хан аны бик сирәк ачулана, хәтта бик ачуы килгәндә дә тегенең кыланышыннан чыдый алмый көлеп жибәрә иде. Кыскасы, Сәлим хан өчен бусагабаш Камай да әллә бар иде сарайда, әллә юк. Шунын өченме, кеше белән күзгә-күз сөйләшергә кирәксә, барчасын куганда да Хафиз белән Камайга сүз катмас иде Сәлим хан. Бүген исә вәзир белән икәүдән-икәү генә калырга теләгәч, хәтта Хафизга да чыгарга кушты. Ни әйтте хан Исхакка икәүдән икәү генә калгач, кәтиб Хафиз өчен сер булып калды. Бу хәл тикмәгә генә түгел иде, шуңа кисәк гасабиланды, шуңа хафага калды әмир Исхак. Иллә ашыкмаска булды, сабыр төбе сары алтын, ди халык. Әүвәл ул Сәлим ханның хәйләсен белергә теләде.

Сарайга шәех Игәнәй килеп керде. Өстендә ап-ак жилән, башында ап-ак чалма, аягында ак болгари итекләр иде.

— Тәмам гүрдән чыккан диярсең бу шәехне,— диде кәтибе ишетелерлек кенә итеп Сәлим хан. Игәнәй тәхеткә якынаюга исә хан урыныннан купты, аңа каршы китте. Шәех ашыкмады, кабаланмады, үз дәрәжәсен үзе бик әйбәт белә иде ул. Чалмасының бер очын иңе аша ташлаган, бер очын түшенә төшергән килеш, жай гына ханга таба атлавын белде.

Курештеләр. Сүзсез генә түргә уздылар. Шәех Игәнәй Сәлим хан янәшәсенә утырды, шуннан соң гына дога кылырга дип кулларын күтәрде, аңа тәхет бүлмәсендәге һәммәсе дә ияр деләр. Бары тик бер Хафиз

гына башып китаптан күтәрмичә утыра бирде. Һәммәсе дә авыз эченнән генә дога укып, шаехка ияреп, битләрен сыйпап куйдылар. Шуннан соң гына шаех Игәнәй:

— Исәнлекме, саулыкмы, ханым?! Угланнар, оланнар, кыз бала Назлыгөл, бикә үзе ни хәлдә яталар? Киленнәр, бала-чагалар, сау-сәламәтләрме? Шулай була күрсен,— диде.

Шаех Игәнәй тамак кырып, сарайдагы һәммәсенә күз йөртеп чыкты, мәгәр хәтта ул да Хафизны читләтеп узды. Күрәсең, шаех өчен дә әллә бар, әллә юк иде сарай кәтибе. Сарайга баш казый Ишкул килеп керде, баш ия-ия ханның сул кулына килеп чүмәште. Шаех янә тамак кырды.

— Бик тә яман хәл ишеттем бит әле, ханым. Хакмы, ялганмы, тизрәк беләсем килә. Албаш багучыңнан узып булмады, сиңа житкергәннәрдер инде — Шайтан каласына киткән Олуг Мөхәммәт илчесен елгадан табып алганнар, ди. Батып үлгән, имеш. Моңа кадәр Болгарның илчеләргә кул салганнары юк иде кебек. Хак булса, ахырзаман килүедер, бер дә бүтән түгел. Бу хәл хак булса, аллаһы тәгалә кичермәс безне, ил өстенә бер-бер афәт-каза китерер.

— Хуш, шаех Игәнәй. Сине тыңладык, инде безне тыңла. Хак хәл, Болгарда гомер булмаган явызлык кылынды. Иллә кылынасы кылынды диик, инде ни кылыйк, киңәшең әйт, шаех. Син аллаһы тәгаләгә барыбыздан да якынрак кеше.

Шаех сарайдагыларга янә күз йөртеп чыкты, кәтиб Хафизга янә күз төшермәде һәм, барысы да сарайдан чыгып китсен, дип ханга ишарә ясады. Сәлим хан янә сарайдагы куштаннарга, шул исәптән вәзир Исхакка да чыгып торырга кушты. Тәхет бүлмәсендәгеләрне гүя җил алды, бары тик кәтиб Хафиз гына, миңа хан боерыгы кагылмый дигәндәй, язма өстәле янында утырып калды.

— Илче Садакны шайтанлылар суга батырып үлтергәннәр, ханым,— диде шаех зур яңалык әйткәндәй башын чөя төшеп.— Шайтан каласы кем кулында, ханым? Угланың әмир Хаҗи кулында. Андагы йөзбаш Туран баһадир кемгә буйсына? Әмир Хаҗига. Димәк, ханым, илче Садакны үлтерүче дә...

Сәлим хан бер сүз дә әйтмәде, көмеш кыңгыравын зеңләтте. Һәммәсе дә янә тәхет бүлмәсенә керделәр. Хан вәзиргә текәлде.

— Вәзир Исхак, илче Садакны суга батырып үлтергәннәр дип бара шаех. Бу хакта син хәбәрдар идеңме?

— Юк, ханым, белми идем, хәзер генә ишетүем.

— Ярый, үлгән артыннан үлеп булмый. Без исән һәм без чарасын да күрергә тиешбездер, шаех?

— Хак тәгалә, ханым, хак тәгалә,— диде Игәнәй.— Сусап калган адәм чишмәгә житкәч, житәр микән миңа бу чишмәнең суы дип уйлар, ди. Тәкъдире суга батып үләргә язгандыр...

— Шаех, Олуг Мөхәммәт миннән сарай табибем Хәсәнне сораган. Ни кылыйм, жибәримме табибемне, юкмы?

— Олуг Мөхәммәт сезгә мөрәҗәгать иткән, ханым, үзегез хәл итәрсез. Минем киңәшем шулдыр: җибәрергә кирәк Хәсәнне. Бабаларыбыз берне биргән икене алыр, дигәннәр.

— Ханым, тыңламагыз шаехне! Җибәрмәгез Өргәнечкә табибегез Хәсәнне. Кәттә табибегез Тажетдинне дә шулай соратып алган иде, кайтармады. Эт авызыннан сөяк алып буламы. Тажетдин вафат, инде энесе Хәсәнне дә җибәрсәгез... Болгарга да игелекле вә белекле табибләр кирәк, ханым,— диде вәзир кайнарлана төшеп.

— Тыңламагыз вәзирегезне, ханым. Җибәрегез табибегезне Олуг Мөхәммәткә. Ул анда солтан булыр, сезнең дәрәҗәгезне күтәрер.

— Чит илләрдә солтан булганчы, үз илемдә олтан булсамчы, дигән борынгылар, шаех,— диде Хафиз. Сәлим хан кәтиб ягына карамый гына вак-вак итеп ияк кагып куйды.

Ул арада сарайга җилләнеп ханбикә Зөбәрҗәт килеп керде. Һәммә-

се, хәтта хан да аягүрә бастылар. Ханбикәнең өстендә — кеш тиресе белән каелган, алтын укалы табгач ефәгеннән тегелгән күлмәк, якасы бөрмәләнгән, итәкләре күпертелгән; башында — асыл ташлар белән бизәлгән калфак, иңендә — Рум сәүдәгәрләреннән алган, гөлҗимеш чәчкәләре төшерелгән чуклы шәлъяулык. Озын куш толымына тезгән көмеш тәңкәләр ханбикә атлаган саен зеңләп китә. Тыңлаган саен тыңлыйсы килә иде Сәлим ханның шушы зеңләүне. Йөреш-кыяфәтендә үк чиксез нәзакәт һәм мөлдерәп тулган гүзәллек күреп, сарайдагылар бермәлгә ханбикәдән күзләрен ала алмый тордылар.

Гүзәл Зөбәрҗәт Сәлим ханның иң яраткан хатыны булды. Аннан соң ханның берәүгә дә күзе төшмәде, ул берәүгә дә өйләнергә теләмәде, ә бит Олуг Мөхәммәт әнә җиде-сигез хатын тота. Сәлим ханга исә бер Зөбәрҗәт бик җиткән иде. Кыпчак далаларында туып, саф дала һавасын сулап үскән кыз Сәлим ханга килүгә, үз тәртипләрен урнаштырды. Иң сәере шул булды, берәү дә, хәтта хан үзе дә аңа каршы әйтергә базмады. Ханбикә ир-ат янында беркайчан да йөзен каплап йөрмәде, мәҗлесләрдә һәрчак ханның уң кулында утырды, кирәк дип тапканда ханга килгән илчеләргә кадәр сүз катты. Мөселман дөньясыннан килгән илчеләр ханбикәнең бу кыланышын ошатмадылар, шаех аша ханга: «Бу бер дә шәригатьтә булган нәмәрсә түгел»,— дигән сүзләр житкерделәр, әмма моннан сарайда һични үзгәрмәде, ә инде христиан дөньясыннан килгән илчеләр ханбикәгә сокланып карадылар, күреп туймас булдылар.

— Хөкемдарым-ханым,— диде Зөбәрҗәт ханбикә түргә уза-уза ягымлы-йомшак тавышы белән һәммәсен дә үзенә җәлеп итеп.— Илче Садакның гәүдәсен алып кайттылар, ни кыласың, ни боерасың?

Нәкъ менә шул сүзләрдән соң, мәсьәләнең асылына яңа гына төшенгәндәй, Сәлим хан сакалына ябышты. Илченең мәетен күрәсе килми иде аның. Кылынасы кылынган иде инде. Киресенчә, бу хәлдән аның тизрәк котыласы килә, гасырлар буена кан кардәш яшәгән, беркайчан да чикызаннары ачыкланмаган бертуган төркиләр-хәрәземлеләрнең ачуын китерәсе килми иде Сәлим ханның. Әмма нишләмәк кирәк, язмыштан узмыш юктыр, күрәсең. Илче Садакны ислам йоласы кушканча җиренә житкереп ханнар зиратына күмдерергә, башын җүләргәрәк салып йөргән бусагабаш Камайга әйтергә: сәдаканы кызганмасын, мул итеп өләшсен— эт көнеле бер сөяк. Кем белә, Садакның үлем хәбәре Өргәнечкә житкәнче Олуг Мөхәммәт тә сүрелә төшәр, моның өстенә, болгарларның илчене үтә дә кадерләп күмүләре хакында ишетеп, кан кардәше Сәлим ханны кичереп куюы да бар иде. Ат аягына ат басмый, Олуг Мөхәммәт тә, Сәлим хан да олуг дәүләтләр башында утыралар, ил язмышы алар кулында. Ә ниндидер бер сәүдәгәр Болгарда үлеп калган икән — булмый торган хәлме? Үлем агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Зират кадере — кабер, кабер кадере — изге сүзләр уелган кыйммәтле таштыр. Адәм бу дөньяга килә дә китә, ә ташка уелган сүзләр кала. Кайтарак уйлаганда башка сыймаслык нәрсә түгел иде илче Садакның үлеме. Элек-электән үк Төн илләренә чыгарга теләгән илче-сәүдәгәрләрне болгарлар үтерә килгән. Аларның күбесе елгага, сазлыкларга батып үлгән. Шулай кирәк булган. Чөнки Төн илләре белән сәүдәне Болгар үзе генә алып барырга теләгән.

— Ни боерасыз, хәкимем?— диде вәзир Исхак.

— Кабат әйтәм, вәзир, Өргәнеч ягына кеше түгел, кошлар да очмасын. Болгарда булган Болгарда калырга да тиеш. Шулаймы, бусагабаш Камай?

— Дөрес әйттегез, ханым.

— Шулай булгач, кушканны үтә, вәзир!

— Барысын да сез дигәнчә итәрмен, шөһрәтлем!

Сәлим хан үз боерыгыннан канәгать калып, башын чөя төште.

— Җәмәгать, бер атнадан чәчкә туе җитә. Күрше-күләнгә хәбәр салынды — кунакка дәштек. Чәчкә туе хакында атна буена сөрән салы-

гыз! Һәр мәхәлләдә бер сөрән салучы булсын.

— Кардәш ырулар чәчкә туен сабан туе дип йөри,— диде бусагабаш Камай.

— Чәчкә туемы, сабан туемы, җыенмы — безнең өчен ул иң зур бәйрәм. Сый-хөрмәтне мулдан әзерләгез. Бөек Кала тарханы, сиңа әйтүем. Кем, Карабай тархан, мондамы үзе?

— Мин монда, ханым,— дип атылып чыкты Карабай тархан.

— Сабан туена Чәчкә-ананы да дәшегез. Ил анасы исемен йөрткән Чәчкә-анага хөрмәтем зурдыр. Шулай дип җиткер үзенә, хан сине үзе дәште, диген. Инде китегез!

Сарай бушап калгач, Сәлим хан Хафиз ягына сирпелеп алды. Чәчкә-ана исеме тел очына килүгә, Сәлим ханның хәтере сафланып киткәндәй булды. Бу исем дә аның күңелен сафландыра иде. Чәчкә-ананы кайчандыр кам Болгар картның карчыгы булган, диләр. Хакмы ул хәбәр, буш сүзме, беркем белми иде. Мәгәр Сәлим хан белгән кадәресе дә бик җиткән иде. Әмир Хаҗи углан кам Болгар картны Шайтан кирмәне нигезенә үзе үк кереп ятты дип бара. Бу хакта Чәчкә-анага әйткәч, карчыкның бер дә ышанасы килмәде. Болгар кам ислам динен кабул итмәде, мәгәр ул үзен-үзе кумәргә кушмас, тәңре белән турыдан-туры сөйләшә ала иде ич ул. Чәчкә-ана: «Ислам динен мин дә кабул итеп бетермим, ханым. Илле бу хакта коръән тотып ант иткәнем дә булмады. Мин аллага үз күңелем белән ышанам, ул үз күңеле белән ышана иде. Шуңа камлыкка чыгып китте ул», диде.

Ни әйтә ала иде хан имче, албасты, ырымчы, әфсен укып әле яп-яшь кыз сурәтенә, әле төлкегә, кирәк икән, тычканга әверелә алган Чәчкә-анага? Аңа ничә яшь икәнен берәү дә белми иде. Ни өчен сарайга елыштырды соң Чәчкә-ананы Сәлим хан? Мәҗбүр булды. Көннәрдән бер көнне Хаҗи угланы авырып китте, тәненә сары төс ятты, күзләре кешене танымас булды. Угланны ул вакытта сарайда хезмәт иткән Таҗетдин дә сәламәтләндерә алмады. Ә ханбикә Зөбәрҗәт үрсәләнде: беренче балалары, Болгар тәхетенә утырасы углан! «Йә угланны терелтәсен, ханым, йә мин синнән китәм!— диде ул. Кыю, тәкәббер, тәвәккәл иде Сарбай хан кызы Зөбәрҗәт.— Чакыр Ык буенда яшәүче Чәчкә-ананы, аның дәвасын белмәгән чире юк, дип әйтәләр». Сәлим хан нишләргә белми тәмам югалып калды. Чөнки моңа кадәр Чәчкә-ана кебекләрне, шәех Игәнәй кушуы буенча, Иделгә батыра килделәр. Иделгә ташларлар иде дә батып үлгәннәрен, «ходa үз янына алды», дип кадерләп күмәрләр иде, ә инде ярга йөзеп чыкканнарын тотарлар иде дә, «Моны аллаһы тәгалә кабул итмәде, язгы күптер», дип үтереп, урманга ерткычларга илтеп ташларлар иде. Сихерче дигән даны чыккан Чәчкә-ананы сарайга китерергә мәҗбүр булды Сәлим хан. Аннары үлеп яткан бала бүлмәсеннән һәммәсен дә куып чыгарды, хәтта Зөбәрҗәт сылуга да калырга рөхсәт итмәде. Җиде көн дигәндә Чәчкә-ана угланны җитәкләп хан янына чыкты. Үз аягы белән йөри, сөйләшә, барысын да таный иде Хаҗи углан. Шул хәлдән соң, Игәнәйнең котыртуына карамастан, Сәлим хан сихерче карчыкларга кагылдырмады. Аларга тигән шәех мөридләрен хәтта зинданга яптырды, ике көннән Чәчкә-ана үтенече белән тегеләрне дар агачына астырды. Шул хәлдән соң Чәчкә-ана сарайның кадерле кунагына әйләнеп китте. Әмма Сәлим ханга ул бик сирәк килде, олыгаюы идеме, Болгар камның үлемен ишетеп, күңеле кайтуы идеме, Сәлим хан белмәде. Шуңа карамастан, хан аны һәр бәйрәмдә сарайга чакырды, кадерле кунаклары янына утыртты. Сәере шул иде: Чәчкә-ананы сарай табибе Хәсән дә якын итәр иде.

Сарайга чакыртылган табиб Хәсән, аңа ияреп әмир Илһам килеп керделәр.

— Илһам углан,— диде Сәлим хан тегеләр исәнләшүгә.— Бүген иртәгә Булат белән Галигә ундүрт яшь тула. Баян баһадир аларга каешкылыч бирер. Бәйрәмнән соң вәзир Исхак яңа кала нигезен карарга ки-

тә, оланнар да барсыннар иде дип әйтәсем килә. Булачак кирмән кала нигезен үз күзләре белән күреп кайтсыннар дигән идем. Кем белә, бәлкем киләчәктә шул калага кайсы да булса әмир булып утырыр.

— Бара күрсеннәр, атам.

— Хуш, углан. Инде син тыңла, табиб Хәсән. Сине Олуг Мөхәммәт Өргәнечкә дәшә... барырсың. Миннән фатиха.

— Ханым,— диде табиб Хәсән һәм як-ягына каранып алды.— Өргәнечтә абыем Тажетдин, анда бару минем күптәнге хыялым иде.

Сәлим хан чак кына: «Абыең вафат»,— дип әйтми калды.

Сарайга кабаланып каравылбаш Таймас баһадир килеп керде, ул туп-туры хан каршына узды. Моңа берсе дә гаҗәпләнмәде, каравылбашны берәүнең дә тоткарларга хакы юк иде.

— Ханым, Жаек елгасын бер авыл Мәләкәс ыруы кичеп чыкты. Илтабарлары Аучы Тимер атлыдыр. Яшь. Чарасыз. Атасы яуда ятып калган. Теләге: ил-җиребездә авыл торып калудыр.

— Ыруы зурмы, илтабар үзе бире килдеме? Ни каттың, илтабар Аучы Тимернең ыруы зурмы дим?

— Үзе монда, үзе әйтер, ханым.

— Бусагабаш Камай, алып кер илтабарны.

Сәлим хан каршына яланбашлы, табгач ефәгеннән күлмәк кигән, биленә киң каеш буган, төз сынлы, базыграк гәүдәле илтабар килеп басты, бер тезенә генә тезләнеп ханга баш иде.

— Бөек Болгар ханы Сәлим ата, җирегездә авыл торырга игелек бирсәгезче. Җир-суымны маңгелләр яулады, атамны үлтерделәр, ир-атларымны әсир иттеләр, хатын-кызларыбызны нукерләренә бүлештеләр. Бик азыбыз гына качып котыла алдык. Чарасыздан каршыгызга килеп баш оруым, ханиям...

— Ил-җәйләвең кай тарафта иде, баһадир?

— Иртеш елгасы буенда иде, ханым. Оябыз зур булмаса да, биләгән җирләребез житәрлек иде, мал-туарга бай идек, бүрек тотып бирәүгә дә бармадык.

— Маңгелләрнең ыруы зурмы, көч-куәте нидә?

— Көч-куәте таңре кулындадыр, ханым. Унбиш яшьтән алып житмеш яшькә кадәр һәр маңгел орышта катнаша. Илтабарларының аты Тимерҗандыр, ыруының исәбен белмим, ханым.

Сәлим хан кәтибе Хафиз ягына күз ташлады.

— Кәтиб Хафиз, маңгелләр ыруы хакында син хәбәрдармы? Ни ашый, ни эчә ул халык? Көнкүреше? Утрак яшиләрме, җәйлиләрме? Тоткан иманнары, гореф-гадәтләре? Ни әйтерсең?

— Ханым, маңгелләр гайрәтле халыктыр. Ашаганнары иттер, эчкәннәре кымыздыр. Маңгел атта туа, атта үләдер. Төп кәсепләре юлбасарлыктадыр. Табгач сәүдәгәрләренең әйтүенә ышансак, бүгенге көндә маңгелләр күрше тирәдәге ыруларны буйсындырып, көч-гайрәт җыеп киләләр.

— Коралларын нидән ясыйлар?

— Кораллары тимердер. Көчлене хәйлә белән, хәйләкәрне көч белән җиңә, диләр.

— Ил язмышын кем хәл итә?

— Аксакаллардан торган корылтайдыр. Корылтай башында илтабарлары Тимерҗан торадыр. Яшь булса да, илтабарлары каты бәгырьле, нык куллы, диләр. Атасы Йөзүгәй татарлар ыруы белән орышта ятып кала...

— Ашаган ашын, эчкән эчемлеген белдек. Табынган иманнары нидән гыйбарәттер?

— Табынганнары борынгы болгарларның таңреседер, ханым. Илла гореф-гадәтләре ямандыр. Сырхаулаган бер адәм баласын сусыз далага куып чыгаралар, үлгәннәрен күммиләр дә, яндырмыйлар да, җәнлекләргә ташлыйлар.

Кәтиб Хафиз укыган китабын өстәлгә куйды, кулына каләмен алды. Сәлим хан беравык дәшми утырды. Борынгы төрки болгарларның да төрле аллаларга табынган заманнары була. Ләкин алар беркайчан да үлгән кешенең мәетен җәнлекләргә ташламый, кадерләп күмә, яннарына тәңре фәрештәләре килгәнче дип өч-дүрт күнлек азык-төлек куялар. Юньле халык түгел бу, барысы да гореф-гадәттән башлана, гореф-гадәте яман булган ыруның кылган эше дә ямандыр. Хәбәрдар булып торырга кирәк бу яман халыктан.

— Кәтиб Хафиз, мәңгелләр хакында миңа хәбәр итеп торырсың. Миңа ул халык ошамый,— диде Сәлим хан, тәхетеннән күтәрелде. Мәләкәс ыруы илтабары янына килде, баһадирның иңенә кулын салды.— Торыр җир-суың Агыйделгә койган инеш буенда булыр, баһадир. Иген игәм дисәң, өйрәтерләр, инде мал-туар асрап көн күрәм дисәң, рәхим ит. Бүгеннән сине баһадирым итәм. Сәлим хан сине үз канаты астына ала. Буйсынуың Тубыкбай баһадирда булыр. Сәлим хан игелеген алдың, илтабар Аучы Тимер!

## 3

Ачык тавышлы сөрән салучылар Бөек Каланың урам-тыкрыкларында өндәүләрен атна буена тәкърарлый торгач, көткән көн дә килеп житте. Чәчкә бәйрәмен белгән кебек, көн дә чалт аяз булып туды. Кояш чыгып, үлән-чәчкә кыякларында энжедәй чык бөртекләре кибүгә, Ага Базар аша Бөек Кала халкы киң болынга агыла башлады. Бу олуг бәйрәмгә Сәлим хан бик күп кунаклар чакыртты. Бәйрәм башланырга ике-өч көн кала Идел буе кибетләр белән тулды. Болгарда урам-урам булып яшәгән урыс, әрмән, рум халкы да бәйрәмчә киенеп болынга төште. Иртән иртүк Бөек Каланың жиде мәчетендә дә жиде тапкыр азан кычкырылды, чиркәүдә төрле моңнар чыгарып чаң суктылар.

Хан гаиләсе һәм туганнары, сарай аксөякләре болынга төшкәндә елга буе тулы халык иде инде. Бу тамашаны күреп, Сәлим хан Гали, Булат оланнарны янына чакырып алды. Бер көндә диярлек туып, бүгенге көндә үндүртенче язларына аяк баскан оныклар хан-бабалары дәшүгә, атларын чаптырып килеп тә җиттеләр. Оланнар икесе дә хәрби киемнән, калканнары булмаса да, билләрендә кылыч, хәнҗәр, иң аша җәя кигәннәр иде. Көмеш тәңкәләр белән бизәлгән ук савытларында һәр олан үзе теләгән төскә буялган уклар. Чаптырып килгән оланнар хан-бабалары арбасына житүгә, беравыздан диярлек:

— Бәйрәм котлы булсын, бабакай, бәйрәм күңелле булсын, дәү инәй, бәйрәм, бәйрәм!— дип кычкырдылар. Сәлим хан оныкларыннан канәгать калып, янәшәсендә утырган ханбикәгә нидер әйтергә дип борылган гына иде, елга буенда боргы кычкырта башладылар.

— Әй-әй-әй, Улдәмирдән кунаклар килә, кунаклар килә!— дип аваз салдылар.

Булат белән Гали олан Иделгә таба чаптылар. Владимир кенәзе Андрей Боголюб Болгардан алган кәләше Рокыя белән кунакка килгән иде. Инде Сәлим ханга хәбәр итүләренчә, чәчкә бәйрәменә олуг кенәз кораб-кораб товар китерә икән, бу хәл чын булса кирәк, елга ярына өч-дүрт кораб килеп төртелгән иде.

Сәлим хан мәйданның иң күркәм урынына алдан корып куелган чатырга юнәлде, аңа ханбикә Зөбәрҗәт һәм башкалар иярделәр. Яр буена килеп туктаган корабларда төрле-төрле җилкәннәр, биредә Хәзәр диңгезе ягыннан килгән, озын юл узган Багдад сәүдәгәрләренең дә, Кара диңгез аша килгән Рум сәүдәгәрләре корабларын да күрергә була иде. Ул корабларны агымга каршы бурлаклар китергән. Озын юл узган һәм, ниһаять, Болгарга килеп житүгә ирешкән бурлаклар карлыгачлар кебек яр кырыена тезелешеп, килеп житү куанычыннан булса кирәк, кип-

кән балык кимереп утыралар, чуар киенгән болгарларны тамаша кылалар иде. Күп тә үтми, Новгород каласы сәүдәгәрләре дә күренде. Новгородлылар корабларын аккошка охшатып ясый һәм төрле төсләргә буяп бизәргә ярата, аларның кигән киемнәре дә чуар, кызлары бераз чытлыкай, һавалы, зәңгәр күзле булыр. Сәүдәгәрләрнең бурлакларында кайгылары юк, йөк бушатучыларны ашыктыралар, кайбер акрынрак кыланганнарына камчы белән сыдырып алырга да күп сорамыйлар иде.

Владимир кенәзе Андрей Боголюб үзе белән бик күп кызлар, егетләр алып килгән. Кораб басмасыннан чыгуга, кенәз каршына Булат белән Гали килеп бастылар һәм, кулларын йөрәк турларына куеп, аңа баш иделәр. Кенәз аларның икесен дә кочагына алды һәм күтәреп җиргә куйды.

— Каенишләр, димәк?— диде кенәз әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Каенишләр,— диделәр оланнар беравыздан.

Кенәз киң җилкәле, гәүдәгә тәбәнәгрәк булса да, таза кеше иде. Ул басмадан төшеп килгән кенәзбикәне күтәп алды да Гали белән Булат оланнарны аңа табарак этеп җибәрде, янәсе, апагыз белән дә күрешегез. Ул арада һәммәсе дә кораблардан төште, кенәз тирәсенә җыелдылар. Кенәз кузгалырга боерды. Иң алдан бүләкләр тоткан кыз кузгалды, аның ике ягына иң гүзәл чибәрләр килеп бастылар. Кызларның кулларында бал тәпәне, икенчесенең кулында җем-җем итеп торган кеш тиреләре. Кызларда киң итәкле, кызылга ак чәчкәләр төшкән сарафаннар, аларга ияргән унлап егет якалары чигүле ак күлмәк кигәннәр, билләрен ефәк бау белән буганнар, баш киемнәре юк, аякларында кара болгари итек. Ыспайлар, тазалар, яшьләр, житезләр. Алар кенәзнең күз карашыннан ук ни эшләргә тиешлекләрен беләләр, каршы алучылар моны шундук сизеп алдылар, соңгылар арасында албагучы Таймас баһадир егетләре дә бар иде.

Кенәзбикә уң яктан, кенәз сул кулыннан иләмсез киң җилкәле баһадир атлый. Баһадирның мыеклары карабодай саламыдай тырпаеп тора, ул каршы алырга килгән болгар кызларына карап куя да мыегын сыпырып ала, тамак кыра һәм ошаганнарына мәгънәле итеп күз кыса иде. Кенәзбикә тәмам өлгереп, өзелеп җиргә төшкән алмадай сылу иде. Үтә дә затлы киенгән, башында кеш тиресе белән каелган, очлаеп килгән түбәсенә кадәр энҗеләр тезелгән калфак, күлмәге әйтерсең лә гелән көмештәндер — кояш нурларында ялт-йолт итә, аякларында итәк астыннан очлары гына күренеп киткән сафьян итекләр. Ул әле иренә карый, әле каршы алырга килгән болгар кызларына. Аның да шулар кебек гамьсез йөргән чаклары бар иде ләбаса. Ул якташларына елмая, таныш булмасалар да, барчасына да ияк кагып кына булса да сәлам юллый иде. Кенәз өстендә җилән сыман кафтан, кафтан көмеш җепләр белән тукылган, сәдәфләрен эләктермәгән — җилбәгәй җибәргән, аякларында тез капкачларын каплап торган итекләр. Муенындагы алтын тәресе әле бер якка, әле икенче якка селкенә. Кенәз каршына болгарларның берәүсе йөгереп килә, бер касә кымыз бирә. Кенәз «эһ!» дип касәдәге кымызны эчә дә савытны читкә ташлый һәм кымыз китерүченең иңбашына дусларча кагып:

— Рахмат, курдаш!— ди.

Икенче берәүсе кенәзгә эче бал китерә, кенәз аны янәшәсендә атлаучы баһадирына бирә, тегесе эчеп куя да, мыегын сыпырып:

— Рахмат!— ди. Һәм икенче мәлдә өстендәге җиләнен сала да бал китерүченең иңенә ташлый.

Кенәзнең кызлары мәйданга җитә, хан чатыры янына юнәлә. Сәлим хан һәм ханбикә Зөбәрҗәт кунакларны каршы алырга күтәрелә, аларга башкалар ияре. Алдан ханның җария кызлары китә, кызларның иң гүзәлендә көмеш табакка катырган чәк-чәк, икенчесендә табгач ефәгеннән теккән, иң оста тегүче тарафыннан чигелгән күлмәк, өченчесендә көмеш тәңкәләр белән бизәлгән болгар күненнән эшләнгән каеш иде.

Әүвәл кенәз чәк-чәкне кабып карады, аннары күлмәкне алып артында басып торган егеткә бирде, бил каешын биленә буды, шуннан соңгына кызларның битләреннән үбеп чыкты.

Ниһаять, хан белән кенәз очраштылар.

— Олуг кенәз күрше-шабра, төкле аягың белән Болгар җиренә!

— Олуг хан, шатмын-шатмын исән-имин сине күрүгә!

Кочаклаштылар, битләрен биткә куештылар. Шуннан соң Сәлим хан Рокыя белән күреште, кенәз исә ханбикә Зөбәрҗәтнең битеннән үбеп алды, бу хәлдән комачтай кызарынып киткән ханбикәгә:

— Татлыдыр алмадай битләре ханбикәнең! — дип, төчеләнеп алырга да өлгерде.

Ул арада барысы да килгән кунаклар белән күрешә, исәнләшә, үбешә, кочаклаша башладылар, ахыр шау-гөр килеп, чатыр астына, күләгәгә таба кузгалдылар. Кунаклар утырышырга да өлгермәде, аларга табак-табак ризык-ниг-ъмәт китерделәр. Ризык ташучы ир-егетләр, кунак кызларга җиткәч, такмак әйтеп тә алдылар.

— Сылуым-чибәрем, матурым-гүзәлем, сары кашларыңны бер сикертче, зәңгәр күзләреңне бер күримче. Баллы бавырсагым татып карачы, керфекләрең күтәреп баксаң — мин булырмын синең көткәнең. Көтеп торсаң бозлар киткәнен, корабларның юлга төшкәнен — мин булырмын синең сөйгәнең...

Кунак кызлары хи-хи көлешә, вата-җимерә төрки телдә сөйләшмәкче булалар. Ул да түгел, мәйдан уртасына Зөбәрҗәт ханбикәнең җарияләре чыкты. Алар янына йөгереп курайчылар, боргычылар басты, кайсыдыр кубызда уйнап җибәрде. Кызлар җырлый-җырлый, такмак әйтә-әйтә биеп киттеләр, һәркайсы үз һөнәрен күрсәтте, җир астыннан калыккандай, егетләр пәйда булды, алар кызларны иш-ишкә китереп бии башладылар. Иш-ишкә килеп табышкач, егетләр кызларга ислемай, беләзек бирде, кызлар егетләргә кулъяулык тапшырды. Болгар биючеләре мәйданнан чыгып китүгә, сөйләшеп куйган кебек, кенәзнең баһадиры әче итеп сызгырып җибәрде. Мәйдан уртасына көпчәктәй әйләнә-әйләнә кунак егетләре чыкты, боргычылар, балалайка һәм сыбызгычылар катнашып китте. Егетләр һөнәрләрен күрсәтеп бетерүгә, мәйданга сабыр-салмак кына, су өстеннән йөзгән аккошларны хәтерләтеп, кызлар кузгалды. Егетләр, кызлар бик тиз ишләрен тапты. Һәм бергәләшеп биегәч, иш-иш булып мәйданны ташлап киттеләр.


Биючеләргә гөр килеп кул чаптылар. Кенәз аерата тырышты, ул инде кәефләнеп тә алган иде, әле янәшәсендә утыручы хатынына, әле баһадирына нидер әйтә һәм тагын да кул чабарга тотына иде. Менә кенәз түзмәде, сикереп торып бар биючене мәйданга яңабаштан чакырып алды да өсләренә учлап-учлап көмеш тәңкәләр сипте, аңа карап Сәлим хан да биючеләр өстенә көмеш тәңкәләр яудырды. Китте көлеш, чыр-чу килеп тәңкә җыю һәм халык бу тамашага янә гөрләп кул чапты.

Ниһаять, кулына озын колга тоткан, аңа төрле төстәге чигүле сөлгеләр аскан мәйданбаш күренде. Ул колганы мәйданның нәкъ үзәгенә кадап куйды.

— Җәмәгать, келәмгә көрәшче оланнарны чакырам. Оланнар көрәше башлана!

Чәчкә бәйрәменең иң кызык өлеше — оланнар көрәше. Сәлим хан оланнар көрәшкәнне аеруча яратып карый һәм бүләкләрне дә мулдан бирә иде. Балалар мәйдан уртасына чыгып баса барды. Күп булмаса да, шактый үсмер җыелды. Мәйданбаш һәм аның ярдәмчеләре аларны иш-иш бүлеп чыкты, кулларына сөлгеләр бирде.

Сәлим хан Андрей Боголюбны тикмәгә генә кунакка чакырмаган иде. Менә ничә ел инде Болгар белән Владимир кенәзлеге солыхта. Быел солыхның соңгы елы. Яңартасы иде. Ни уйлый икән кенәз бу хакта? Әйтик, Сәлим хан солыхны озайту ягында. Үткән ел, Сәлим хан белән киңәшмичә, кенәз мукшыларга яу чапты. Бу уңайдан Сәлим хан илчеләр



А. Тимергалина рәсеме.

аша кенәзгә канәгатьсезлек белдерде. Кенәз шунда илчеләргә әллә шаяртып, әллә ихластан әйткән: «Бик күпне күрсә ханыгыз, Болгарына ук яу чабармын»,— дигән. Илчеләре илгә кайтып, кенәзнең сүзләрен җиткергәч, Сәлим хан ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Илчеләр арасында да төрле кешеләр бар иде, аларның күбесе бай сәүдәгәрләр гаиләсеннән, әлбәттә инде, үз мәнфәгатьләреннән чыгып та эш итәләрдер. Шуңа карамастан, Сәлим хан алар сүзенә ышанды һәм бу хакта кенәз белән әңгәмә тотарга исәплəп тора иде. Кенәзнең кәефе әйбәт, ул якты йөз белән сөйләшә, бигрәк тә вәзир Исхак белән бәхәсләшергә ярата иде. Сәлим хан юк-юк та шул якка күз төшереп ала. Андрей үз көчендә, ир уртасы гайрәтле чагы, илчеләр бик теңкәсенә тия башлагач, әйтеп тә ташлагандыр. Бу дөньяда кенәз белән хан гына түгел, туган белән туган җир-су бүлешә, орыша, сугыша.

Олы Идел буйларында җыр яңгырый. Халык бәйрәм итә, мәйданда оланнар көрәшә. Батырга батыр чыгып та килә кебек инде. Әйе, шулай икән шул, мәйданбаш батырга батыр калган оланнарны мәйдан уртасына алып чыкты. Шулчак батыр калган оланнарга хан белән ханбикәдән бүләкләр китереп бирделәр.

Сәлим ханның кәефе әйбәт иде. Кинәт аның башына бер тиле уй килде. Батырга батыр чыккан оланнар көрәшеп ята. Тукта, ул да үз онықларын көрәшкә чыгарса? Әйдә, тамаша кылсын халык, онықлары алышканны күрсен. Алар да кеше янында кеше.

— Җыенбаш, мәйданбаш! — дип кычкырды Сәлим хан.— Бире кил әле. Әйе, әйе, син!

Ханның бу сүзләреннән соң мәйдан гына түгел, тирә-юнь тынып калгандай булды. Уң кулында утыручы ханбикә Зөбәрҗәт ирен туктатмакчы итте, әмма хан, аңа игътибар бирмәстән, мәйданбашны чакырды. Ханның сул кулында утыручы вәзир урыныннан купты, йөгереп мәйданбаш янына барды, тегеңә нидер әйтте һәм хан янына әйдәде. Илһам белән Хаҗи угланнар бер-берсенә карашып алдылар. Имеш, ни кылырга исәбе аталарының? Икенче мәлдә инде аталарының ни теләгәнен аңлапмы елмаештылар, аның сәер гадәтләрен беренче тапкыр гына күрүләре түгел иде шул.

Сәлим хан бу уенның ахыры ни белән бетәсе хакында баш ватмады, күңеленә бер уй килгән икән, ул аны, таш яуса да, тормышка ашырыр. Ханмы ул, түгелме!

Хан дәшүен аңлап алгач, мәйданбаш йөгерә-йөгерә чатыр янына килде.

— Ни боерасыз, ханым?

— Кибәк баш, нигә дәшкәч тә ашыгыбрак килмисең? Артың каешны тансыкладымы әллә, ахмак! Сөрән сал, хан онықлары көрәшә, дип сөрән сал!

— Баш өсте, ханым!— диде мәйданбаш һәм шаяртмыймы бу дип, бертын кузгалмый торды.

— Дивана баш, ни әйттеләр сиңа! — дип әтәчләнеп килеп кунды мәйданбашка вәзир.— Сөрән сал!

— Һе, менә сиңа мә, булмаганны,— диде мәйданбаш.— Килешерме соң бу, ханым?

— Вәзир,— диде Сәлим хан.— Кем куйды бу ахмакны мәйданбаш итеп?

— Чын була, димәк, мин бит шаяртасыз дип торам, ханым,— диде мәйданбаш.— Алай булгач, батырга ни вәгъдә итәсез?

Бу хәтлесен хан да, вәзир дә көтмәгәннәр иде, күрәсең, бермәлгә аптырабрак калдылар. Хан вәзиргә, вәзир ханга карашып алдылар.

— Әйе, батыр калган оланга ни вәгъдә итә ханым, ди бит әле кибәк баш,— дип зәһәрләнде вәзир.— Күр әле моны, әй!

— Белдер халыкка, тәхетен вәгъдә итә диген,— диде Сәлим хан һәм сискәнеп киткәндәй булды.

Вәзир мәйданбаш янына килде һәм аның колагына нидер пышылдады, шуннан соң мәйданбаш йөгерә-атлый диярлек мәйдан уртасына юнәлде.

Ул кулын күтәреп тынычланырга кушты һәм калын күкрәк тавышы белән хан сүзләрен кабатлады. Бермәлгә генә тынып калган халык ур-ра кычкыра башлады.

Ул арада Исхак янына бер азат килде, тегеңә нидер әйтте, вәзир хан янына узып рөхсәт сорады. Хан азатка аяк кагып, ризалыгын белдерде.

— Бар, килсен! — диде вәзир Исхак азатка.

Азат китеп барды, күп тә үтми мәйданга Тубыкбай баһадир килеп керде һәм туры хан чатырына юнәлде. Тубыкбай баһадир кулында Табгач сәүдәгәрләренең ефәк юлы. Аны борын-борыннан ук шулай дип йөртәләр. Тубыкбай ефәк юлын саклый, сәүдәгәрләрне рәнҗетми, исән-имин уздырып җибәрә. Сәлим хан Тубыкбай хезмәтеннән канәгать иде. Башка бәкләр кебек кул сузып сарайга килмәде, ук-коралдан башка нәрсә сорамады, башкалар кебек кирмән калалар салам дип тә йөдәтмәде, бабалары кебек киез йортларда яши бирде. Ханга булган бүләген дә үз вакытында китерде, бурычка кермәде, кирәгеннән артык мал тотмады. Хак анысы, сарайда тәрбия алган энесе белән тыныч яши алмады, тегесе агасы белән дәгъвалашып чыгып китә, качкын булып йөри, диделәр. Ләкин Тубыкбайның ханга килеп бу хакта бер тапкыр да зарланганы булмады. Шуңа да якын итә иде баһадир Тубыкбайны Сәлим хан.

Тубыкбай өстендә кеш тиресе белән каелган күн күлмәк, кулында куй маенда кайнаткан камчы, билендә киң каеш, киң кунычлы итекләре тезенә җитәр-җитмәс тора. Баһадир Сәлим хан каршына узды, баш иде һәм кунак кенәзгә карап алды, кенәз аның сәламен алып ияк какты. Сәлим хан баһадирга чатыр күләгәсеннән урын күрсәтте, әмма Тубыкбай утырмады, янына берсеннән-берсе үсмеррәк оланнарын дәшеп алды. Оланнар тезелешеп хан каршына килеп бастылар, сөйләшеп куйгандай, бергәләп ханга баш ордылар. Шуннан соң гына Тубыкбай баһадир әйтер сүзен башлады.

— Олуг ханым, саумысыз! Саумысыз, сылуларның сылуы Зөбәрҗәт ханбикә! Саумысыз, кунаклар, әмирләр, киленнәр, оланнар,— диде Тубыкбай бертуктаусыз бил бөгә-бөгә.

— Сәламең алдык, Тубыкбай, инде гозерең әйт. Һәй, йомыш дим тагын. Бичәң кая соң, баһадир? Гүзәл бичәң?

— Бичәм-күгәрченем, кара кашым, карлыгачым быел җәй башында ук дөнья куйды, ханым. Биш оланны биш каурые итеп миңа ташлап китте. Сандугачлар кайткан чаклар гына иде. Бөтен тереклек уянгач кына китеп барды карлыгачым-сылуым. Чәчәкләр уянды, күбәләкләр терелде, ә минем җаным-бәгърем гүргә керде.

— Нигә сарай табибе Хәсәнне дәшмәдең?

— Кыймадым, ханым. Чәчәк-Ананы дәшкән идем, килде, карады да өметсез диде.— Тубыкбай баһадир ханбикә Зөбәрҗәт артына басып торган зәңгәр күзле җариягә күз атып алды, күренеп тора, көнчыгыш сәүдә юлын саклаучы баһадир кем ашадыр кыз хакында хәбәрдар, аннары кыз да баһадир хакында хәбәрдар булса кирәк. Тубыкбай аның ягына карауга, сылукай, аучы каршына кинәт килеп чыккан җәнлек кебек, сискәнеп китте, өрфия яулыгы белән күзләрен генә калдырып йөзен каплады һәм ханбикә артына посты.

— Бичәң сылу иде, Тубыкбай, урыныcы оҗмахта булсын. Әйе, үлгән артыннан үлеп булмый, дигәннәр картлар, дөньялыктагыда дөнья кайгысы булыр, дип әйткәннәр, бичәң калдырган менә бу каурыйларны итәгеңә салырдай, күзең төшкән сылу бармы соң? Биш олан табып биргән бичәңнең урыны җәннәттә булыр, рәнҗемәс, дип әйтүем...

— Хак әйтәсез, ханиям, рәнҗемәс. Иш күгәрченнәрдәй гөрләшеп гомер иткән идек тә бит... «Күзең төшкән сылуың бармы», дигәч, күңелем тулып киткәндәй булды әле.

Һәм Тубыкбай күзләрен генә калдырып яулык каплаган жариягә күз төшереп алды.

— Табарсың, табарсың, баһадир, синдәй ир-атка та табылмагач,— диде Сәлим хан.

— Хәкимем,— диде Тубыкбай.— Сәүдә юлыгызны имин тотам, бер генә сәүдәгәрнең дә зарланганы булмагандыр. Аллага шөкер, Ил-Болгарга зыян-зәүрәт китергәнем булмады, булса, ишеттерерләр ие. Теләгемә фатиха бирсәгез, икенче көнне үк бер көтү ат болынызда булыр ие, ханым.

— Теләгең әйт, Тубыкбай. Җир өстендә яткан хәзинә булса, игелегем юктыр, чөнки хәзинә ил байлыгыдыр. Инде жир өстендә йөргән жан иясе икән — рәхим ит, әйт теләгең. Теләгең изгедәндер бит, баһадир?

— Баскан урынымда жир упсын, ханым. Ниндәй сүз ди ул. Оланнарга ана кирәк. Канатсыз — кош, катынсыз ир булмас, диләр. Кулымда гына йөртер идем.

— Ай-һай,— диде ханбикә Зөбәржәт баһадирның шыттыруын ошатмыйча.— Ирләргә ышанма, Иделгә таянма, диләр түгелме? Мактанма алай, Тубыкбай. Халык әйтә бит, батыр мактанса — жир убар, куркак мактанса — жил кубар, дип.

— Бәй, Акъанам, ир йөрәгендә жигүле ат булмаса, ни пычагыма ул хатын-кыз ярына. Мактанырлыгым булганга мактанам, Акъанам.

Сәлим хан кеткелдәп көлеп жибәрде һәм янә Тубыкбайның оланнарына карап алды. Баһадирның кемгә күзе төшүен кыяр-кыймас кына оланнар ягына баккан ханбикәнең асравын күрүгә үк сизеп алган иде. Ахыр түзмәде, иелә төшеп, ханбикәгә нидер әйтте. Зөбәржәт сылу хан белән килешмичә, башын чайкады. Айсылу атлы кызны аңа кыпчаклардан алып кайткан иде Биккол сәүдәгәр. Сайлый белә иде кызларны хан сәүдәгәре. Якташы булгангамы, ханбикә кызны үз баласыдай яратты. Бирмәве дә бар иде. Шуңа күрә Сәлим хан Тубыкбайга:

— Син, баһадир, бу хакта ханбикәңә мөрәҗәгать ит инде. Айсылу аның асравы, житмәсә якташы, аннан үтен,— диде.

Шуны гына көткән кебек, Тубыкбай ханбикә Зөбәржәт каршына тезләнде. Бу тамашаны күреп-күзәтеп торган кенәз Андрей башын чайкап куйды.

— Акъанам Зөбәржәт, ай-кояштан нур алган асравыгызга күзем төште, язган бәхетемнән мәхрүм итмәгезче. Болын чәчкәсез, дала кылгансыз, бала анасыз булмастыр. Ышбу оланнарга Айсылуыгыз ана булсачы?

Шулай диде дә Тубыкбай аягүрә басты, ханбикәгә баш иде, ата артыннан оланнары килеп, берәм-берәм ханбикәгә баш ордылар. Ханбикәнең күңеле нечкәреп китте.

— Йә хода, йә хода, күрче, күрче боларның кыланышларын. Һай, изге булгандыр синең, Тубыкбай, тәүге бичәң. Бала холкы анадан, батырлыгы атадан, диләр бит. Йә ходаем, бигрәкләр килештерәләр инде.

Моңа кадәр бер якка да сүз катмаган Акбикә килен телгә килде:

— Яшь арасы бик зур түгелме соң, анам? Чабата тукырга рәтле чөшлесе калдымы икән...

— Ай аллам, килен, бу ни дигән сүз инде тагын! Килешмәгәнне!

— Чабатасы булгач, чөшлесе бардыр, бардыр,— диде Сәлим хан.— Булды, Тубыкбай, әйт, урлапмы, туйлапмы аласың?

— Алса, туйлап алсын, алмаса алмасын. Ханым, синең ни сөйләвең инде тагын?!

— Туйлап, никах укытып, зурлап алса гына разый бул, анакаем,— диде Мәрьям килен.

— Барысын да сез дигәнчә итәрбез, бикәләр. Сүзегездән чыкмам, игелегегезне генә бирегез.

— Шәех Игәнәйгә акчаң кызганмасаң, никахны тиз тотар,— диде Сәлим хан.

— Аяк астыгызда тупрак булыйм, олуг ханым. Мең рәхмәт сезгә, оланнарым ятим итмәдегез.

— Тубыкбай баһадир, асрау кызым Айсылу дала ханы Сарбай ыруыннан. Белекле, укый-яза белә, сылу-гүзәл, исеменә җисеме килеп тора, рәнҗетә күрмә, намазлыкка утырып каргарым. Инде кызның үзеннән сорыйк, бөтенләй үк ят итсә, бигайбә, баһадирым.— Ханбикә каерылып асравына карады.— Йә, балакай, ни әйтерсең?..

Кыз бермәлгә тәмам югалып калды, алай да зәгыйфь тавышыннан аңлады ханбикә Айсылу ризалыгын.

Тубыкбай баһадир, ханбикә елмаюга, кулындагы камчысын җиргә ташлады да оланнарына ым какты, тегеләре йөгерешеп килеп, аталарының кулларына, иңнәренә асылындылар.

Сәлим хан канәгать калды. Тубыкбай һәрчак аның канатында булды. Батыр, кыю. Ул Сәлим ханга ин кирәк кеше иде.

— Халаяк, Сәлим хан әмере белән аның оланнары үзара көрәшәчәк. Батыр чыккан оланга хан тәхетен вәгъдә итә!

Бусы, һичшиксез, артык иде, Сәлим хан, айнып киткәндәй, вәзиренә нидер әйтте, тегесе йөгерә-атлый барып, мәйданбашның җилән җиңеннән эләктерде, койты гына тартып куйды.

Мәйдан уртасына Гали олан белән Булат оланны җитәкләп диярлек алып чыктылар. Ни сәбәпледер, мәйдан кечерәя башлады, бер өлеш халык: «Гали олан җиңә, Гали олан хан була!» — дип, икенчеләре: «Булат олан җиңә, Болгар тәхетенә Булат олан утырачак!» — дип, тамак ерттылар.

Бер җуләре, һәрхәлдә шулай дип уйлады Сәлим хан, мәйдан уртасына йөгереп керде һәм:

— Ур-ра, ур-ра! Яшь ханнар көрәшә, яшь ханнар көрәшә! — дип акырырга кереште. Мәйдан караучы азатлар аны шундук эләктереп алдылар, күтәреп алып, мәйдан читенә ташладылар. Ул да түгел, икенче берәүсе:

— Әйтсен, әйтсен хан, батыр калган оныгына ни бүләк итә? Тәхетенме?! Бүгеннән үкме? Үлгәчме? Бүгеннән үк, бүгеннән үк!

Бу хикмәтле кешене дә мәйданнан алып чыгып киттеләр, хәтта арт ягына камчы да төште бугай, яңадан әйләнеп кермәде.

— Халаяк, ишеттегез булса кирәк, хан батыр калган оныгына тәхет вәгъдә итә! — дип кычкырды мәйданбаш.

Гали белән Булатка сөлгеләр тоттырдылар. Хан оныклары алыша башлады. Башта алар шаярып кына көрәштеләр, мәгәр тора-бара кызып киттеләр, көрәш чынга әверелде.

Көтмәгәндә Гали олан Булатны күтәреп алды, әйләндереп атып та бәрде.

Мәйдан тирәсе күк күкрәгәндәй чатнап куйды, яше-карты мәйдан уртасына ташландылар, батыр калган Гали оланны күтәреп алырга, яшь ханны сарай тәхетенә кадәр күтәреп илтергә теләделәр. Ләкин халыкны уртага уздырмадылар, мәйданны боҗрага алып, сөңгече азатлар басты.

Мәйданбаш батыр калган оланны кулына күтәрде дә хан чатырына таба алып китте, башын ия төшеп, җиңелгән бала аңа иярде.

Ул арада батыр калган оныгына Сәлим хан тәхетен вәгъдә итүен ишеткән халык мәйданга таба агыла башлады. Барысының да бүген-иртәгә хан тәхетенә утырасы угланны үз күзе белән күрәсе килә иде. Халык мәйдан боҗрасын кысрыклый, кечерәйтә, кысарга кереште. Сәлим ханның уйлары чуалды. Халыкны алдау — хатын алдау гына түгел икән. Хан бу хакта бик күптән белә иде. Халыкны бер алдарсың, икеөченчесендә ул баш күтәрергә дә күп сорамас. Сәлим хан Гали оланның атасы әмир Хаҗига күз төшереп алды. Әмир Хаҗи берни булмаган кебек дисбе тарта, ә менә бикәсе утлы табада утырамыни — борсалана, ни кылырга белми интегә иде. Илһам углан да тыныч түгел, йөзе ап-ак,

әйтерсең, гүрдән чыккан. Мәрьям бикә исә иренең җиңенә ябышкан да җиңелгән һәм мәйданбаш артыннан башын иеп атлаган угланына баккан — күз яшен дә сөртмичә елый. Бу мәйданбашны гына күр инде! Нигә инде баланы күтәреп китерә! Оланнар уен уйнадылар, уендагы уенда калыр да. Хак анысы, ике оланның берсе вакыты җиткәч тәхеткә утырыр, тик бүген түгел, хәзер түгел. Халыкны гына кара син. Ни кылана?! Яңа хан яңалык китерер, ясакларны киметер дип уйлауларымы? Булмастыр, андый хан тумаган әле, туар ул, мәгәр әле түгел, хәзер түгел, бер хода белә кайчан. Ә бүген балалар уен уйнадылар, уен! Әллә чынлап та арттырыбрак җибәрдеме? Арттырыбрак җибәрде бугай. Тарихта булмаган хәл түгел, тәхет өчен туган туганны, ата улны, ул атаны үтергән.

Сәлим хан эчтән ачыргаланып, ханбикә Зөбәрҗәткә игътибар итте. Ханбикә үзалдына оялып, аның өчен оялып, кызарынып утыра иде. «Ханбикә хаклы булган,— дип уйлады Сәлим хан.— Тәхет вәгъдә итү уен эш түгел. Тәхет вәгъдә иттең ни дә, җаның бирдең ни!»

Ханның ни турында уйлавын белгән кебек, Зөбәрҗәт ханбикә:

— Ут белән уйныйсың, ханым,— диде.— Оланнар күңеленә генә түгел, халык күңеленә дә яман коткы салдың. Үкенечләргә калмагае бу кыланышларың, ханым...

— Сөйләмә юкны, ханбикә. Уен уенда калыр да.

— Сөяк бирми, эт иярми, ханым. Ике көчек бер йортны сакламый.

— Көчекләр язмышы минем кулда, ханбикә.

— Язмыш хода кулында, ханым. Синең кулда бары тик хода биргән акыл. Аны да сак кулланмаган хәлдә баш югалтыр дәрәҗәгә җитәргә мөмкин икән.

— Бүген инандыңмы?

— Бүген, ханым.

— Үтәр ул, ханбикә, үтәр. Үрдәкне суга ташлап батырмыйлар.

— Күр әнә, оныкларыңның берсе күз яше белән елый, икенчесе көлә, елмая. Мәрьям килен әнә тәмам үксеп бетте.

Зөбәрҗәт ханбикәгә оныкларның икесе дә якын иде. Булат оныгы аңа әбекәй диде, Гали оныгы исә Акъанам дип дәште. Ике бертуганнан тусалар да, холыклары белән бер-берсенә һич тә охшамаганнар иде. Булат олан күбрәк баһадирлар янында уралды, Гали олан исә кәтиб Хафиздан, табиб Хәсәннән аерылмады. Еш кына Гали ханбикә кызларына ияреп болынга дару чәчкәләре җыярга төште, тегеләргә шигырьләр укыды, мәхәббәт турында шигырьләр ишетүгә, күзләре елтырый башлаган кызларга карап ханбикә: «Бу оланда нидер бар, бу кадәр күп белмәс иде»,— дип уйлап куйган иде. Ә инде Җамалетдин Руми шагыйрьнең татлы, акыллы шигырьләрен әйтә башлагач, ханбикә олан өчен курка калган иде. Хиссияткә бирелүчән Гали оныгы өчен курку әнә шунда килгән иде ханбикәгә. Һәм шул чактагы куркуы янәдән кабатланды. Сәлим хан мәйданбаш күтәреп килгән оныгына дошманга караган кебек карап тора иде.

Ханбикә Зөбәрҗәт ни әйтергә белми каушый калды. Юкса, Шарукан хан ыруыннан чыккан Сарбай кызы иде ласа. Һәрчак кыю, тәвәккәл булды, ә монда кисәк Гали оныгы өчен курка калды. Гали оныгы өчен генә түгел, Булат оныгы өчен дә. Урыс кенәзләре кысрыклый башлагач, Сарбай хан Идел елгасын кичеп, Кенәле елгасы буена авыл туктады. Күп тә үтми аның ыстанына Болгардан мөридләр килеп төштеләр, атна-ун көн үтмәде, Сарбай хан ыруы белән ислам динен кабул итте һәм баш иеп Болгар ханына килде. Хан аны колач җәеп каршы алды, Иделнең түбән якларын сакларга кушты. Сарбай хан, җәйләүне ташлап, утрак тормыш корырга кереште. Әмма җәй килдеме, күңеле ашкынды, җыенды, Җаек тирәләрен әйләнеп кайтты, ләкин инде ерак китә алмады. Картлык килде аңа. Аталары дөнья куйгач, угланнары җәйләми башладылар. Өлкән угланы Бачман үз ыруы белән Бөек Калага күчеп килде

һәм сарайда йөзбаш булып калды. Сарбай ханның икенче угланын Сәлим хан Өргәнеч белән Сувар калалары арасындагы сәүдә юлын сакларга билгеләде. Ыру-кабиләсе ишәеп киткәч, Сөләйман баһадир, атасы җирләрен кече энесе Шарлыкайга биреп, ерак та китми үзенә кирмән кала салды һәм аны Бозаулык дип атады. Баян баһадирга кадәр үк Зөбәрҗәткә ияреп килгән Бачман меңбаш әмир Хаҗига күчте һәм, Казан елгасы буена кирмән салып, баһадир булып тора башлады.

Ханбикә Зөбәрҗәт һәрчак Сәлим ханның тезгенен кулында тотар иде, бүген исә беренче тапкыр ул тезгеннең ычкынуын тойды. Нигә тыймады ханны? Ә бит туктата ала иде. Яисә вәзир Исхак нигә туктатмады? Бу нихәл?!. Ханым, ханым, картая башлавыңмы, акылга җиңеләюеңме? Ни сәбәпледер, шаех Игәнәй дә күренми. Яратмый шаех хәлык уеннарын, аңа хәтбә әйтсә бик җиткән. Үзе ханны мактый, үзе аның үлемен тели. Һич аңламассың бу шаехне. Зөбәрҗәт ханбикәне киләкилүгә яратмады Игәнәй. Була бит шулай, күз ташлавы булды шаех Игәнәйнең яшь хатынга, уйлап куйды: «Бусысы Туйбикә булмас, бусысы ханны үзе биетер». Мәгәр бер ханны гына биетмәде ханбикә булып алган Зөбәрҗәт, ул Игәнәйне дә читтә калдырмады. Иң әүвәл Болгарга пәрәнҗә керттермәде. Ә бит ни тырышты шаех, ни үгетләде ханны, ни котыртты халыкны, ханбикә исә аның ел буена алып барган үгетен бер көн дигәндә сөтте дә ташлады. Мәҗлестә пәрәнҗә мәсьәләсе кузгалгач, көтмәгәндә ханбикә Зөбәрҗәт килеп керде. Килеп керде дә хан янына узды, янәшәсенә утырды. «Шаех,— диде ул ашыкмый гына.— Китапта бер дә хатын-кызга пәрәнҗә кигерегез, диелмәгән. Болгар хатын-кызларына пәрәнҗә кигерергә бик тә телисең икән, әүвәл үз хатыннарыңнан башла, яшеннән. Икенче көнне үк качып китмәсә». Шулай диде дә ханбикә Зөбәрҗәт, ничек килеп кергән булса, шулай чыгып та китте.

Кыпчак кызы Зөбәрҗәт азатларына әйтте: «Игәнәйнең яшь хатынын урлагыз да миңа китерегез». Азатлары ханбикә боерыгын бик тиз үтәде, шаех Сәлим ханда утырган арада яшь хатынны сарайга, ханбикә бүлмәсенә китереп тә җиткерделәр. Зөбәрҗәт чибәр хатын белән мөлаем генә сөйләште, булган хәлне аңлатты.

Икенче көнне шаех Сәлим хан алдына түгел, ә ханбикә алдына килеп баш орды. Болгарда яңадан пәрәнҗә мәсьәләсен кузгатмассың, дип Зөбәрҗәт Игәнәйдән коръән тоттырып ант иттерде. Һәм, әлбәттә инде, иртәгә яшь хатының өеңдә булыр, дип кайтарып җибәрде. Икенче көнне чынлап та яшь хатын кайтып кергәч, шаех Игәнәй аңардан, «кая булдың», дип сорамады һәм өйдә түгел, урамда да йөзен капламаска кушты.

Бу хәл турындагы хикәят Сәлим ханга барып җиткәч, ул эчен тотып тәгәри-тәгәри көлде һәм:

— Һәй дә Зөбәрҗәт, һәй дә Сарбай хан кызы! — дип, ханбикәсе белән горурланды.

Тураннарның гадәтенчә борын-борыннан тәхет атадан угланга түгел, ә бабадан оныкка күчә килә. Әмма Туран дөньясында тәхетне атадан угланга калдыру очраклары да булгалаган. Сәлим хан угланнары җиткәндә үз көчендә иде әле, тәхетне угланнарына бирмәде, ә икесенә ике каласын биреп, тегеләрне әмир итте. Угланнар үзләре дә тәхет дәгъвалама-дылар шикелле, аталары тәкъдиме белән шундук килештеләр һәм ырулары белән билгеләнгән калаларга күчеп киттеләр. Күз тия күрмәсен, исән-имин яшәп яталар. Ә менә оныклары арасында тәхет өчен кан коелуы бар иде. Бүген әнә шуның җеп очын күрде ханбикә, моны, әлбәттә, Сәлим хан да сизде булса кирәк, тәмам кәефсез утыра.

Мәйданбаш Гали оныкны Сәлим хан каршына китереп бастырды.

— Гали онығыгыз батыр калды, ханиям. Халыкка вәгъдәгезне җиткерегез.

«Кем бу мәйданбаш? Вәзир кешесеме, әллә гафиллеге белән үч аламы? Тегеләй булса да, болай булса да, мин сиңа моны болай гына

калдырмам, мәйданбаш»,— дип уйлады Сәлим хан, утырган урыныннан кутәрелергә дә, кутәрелмәскә дә белмичә аптырап.

Булат олан елый, гарьләнгән. «Гарьлән, гарьлән, олан. Гарьләнә-гарьләнә балигъ бул. Ирне ир иткән сыйфат синең яшеңдә гарьләнә белү. Син хан оныгы, ихтимал, әле язган булса, тәхеткә дә утырырсың. Ә монда булган хәл гел үен гына булып калыр. Уенда гарьләнә белгән сугышта да гарьләнер, диләр. Ә дошманнан җиңелү ир-ат өчен бер гарьләнү генә дә түгел хәтта, ә үлем, әче үлем!»

— Ханым, Гали олан батыр калды. Вәгъдәгезне әйтегез, халык көтә!

Мәйданбаш сүзләрен әйтеп бетермәде, Гали олан бабасы каршына килеп баш орды.

— Дәү атам, тыңлама аны, ил тәхетен оныкларыгызга бирергә иртә әле сиңа. Бер белекле әйткәндер: «Тәхет ханны түгел, хан тәхетне бизәр», дип. Без туганым Булат белән болай гына көрәштек. Уен уенда калыр.

— Акыллы олан,— диде кенәз Андрей һәм сикереп урыныннан торды, килеп Гали оланны күтәреп алды.— Шундый оныгың булса икән!

— Алар минем икәүдер, бер тәхеткә ике кеше утырмый,— диде Сәлим хан әллә үртәлеп, әллә кенәзнең кысылуын ошатмыйча.

— Игелекле олан, игелекле,— диештеләр хан куштаннары да.

— Вәзир, көрәшне дәвам иттер,— диде Сәлим хан. Аның әле һаман кәефе юк иде.

Мәйдан уртасына көрәшкә егетләр, ир урталары чыкты. Аларга җирәбә салдылар, таңкә сикертеп, күн ягы туры килгәннәргә сөлге өләштеләр. Көрәш башланды. Көттереп кенә көрәшкә Тубыкбай баһадир да чыкты. Алышлар бик тиз бетте. Кайберләре бил алдырып кына чыгып китте. Ниһаять, батырга батыр калдылар. Кыпчак батыры йөзбаш Карабаш һәм баһадир Тубыкбай. Батырлар бик озак бер-берсенә бирешми иза чиктеләр, ахыр Тубыкбай батыр Карабашны күтәрде, шул чак Андрей кенәз сикереп торды һәм:

— Алдыр, алдыр, багатур! — дип кычкырып җибәрде.

Тубыкбай батыр Карабаш батырны җиргә бәрде һәм бертын тормый утырды.

— Өстенә төште, билен кузгатты,— дип,батырның хәленә керүчеләр табылды.

Иллә Тубыкбай баһадирның биле дә кузгалмаган, ише өстенә дә төшмәгән иде, ул торды да кулындагы сөлгесен оланнарына болгады.

— Атагыз җиңде, атагыз җиңде, угланнар!

Мәйданбаш Тубыкбай батырның кулыннан алды, әмма шундук мәйдан уртасына кенәз Андрей атлады.

— Тукта, мин көрәшә батыр белән, мин!

Барысы да аптырашта калды. Кенәз белән көрәшү ярый торган хәлме, килешерме? Тубыкбай баһадир әүвәл ханбикәгә карады, аннары Сәлим ханга. Әйе, кунакка килгән кенәз белән кем көрәшә инде. Хан үзе үк кушмас.

— Мин көрәшә, син көрәшә,— диде кенәз һәм мәйданбашның кулыннан әле генә җинелгән батырның сөлгесен тартып алды, кулына элмәк итеп үрде. Тубыкбайга таба атлады.

— Булмастыр, ахры, кенәз,— диде Тубыкбай баһадир курка калып. Ярамаган эш кылса, Сәлим хан аны берсүзсез Айсылудан мәхрүм итәчәк иде.

— Булыр, багатур,— диде кенәз һәм батыр калган Тубыкбай биленә сөлгесен элмәкче итте.

Ул буйга озын булмаса да, киң күкрәкле, кара көдрә чәчле, биек маңгайлы, карчыгарак борынлы кеше иде. Кыяфәте белән бик үк килешле булмаса да, зур зәңгәр күзләре аны ягымлы итәләр, күзләренә карауга, кеше аның чарасына буйсына иде.

— Көрәшә-көрәшә! — дип кычкырды Сәлим хан.— Хан кушкач, көрәшми кая барсын!

Тубыкбай чарасыз калып, кенәз биленә сөлгесен ташлады, икенче кулы белән сөлгә башын эләктереп алгач, янә Сәлим хан ягына күз ташлады. Шаярып кына әйтмәдеме, белмәссең ул ханнарны, кунак кенәзне күтәреп бәрсә, ни әйтер, Айсылудан гына мәхрүм итеп калмас, зинданына ук яптырыр. Бусы тагын нигә дип атылып чыкты, аяклы каза, кияү холкы күзгә күн, диләр, хак икән. Кунакка килгән, үз дәрәҗәсен үзе белеп кенә карап утырырга иде. Күтәреп сылармын да үзеңне, баһадирың түгел, кенәзбикәң дә җыеп ала алмас сөякләреңне. Бәрәм дисең дә, ай-һай, бәреп булыр микән. Сөякләре эре, бил тотышында тәҗрибә күренмәсә дә, дивана көч бар бу бәндәдә, бар.

— Җәмәгать, халаяк, батыр калган Тубыкбай баһадирга урыс кенәзе чыкты. Әйтсен хан, батырга ни?

— Вәзир,— диде Сәлим хан.— Җыен бетү белән бу мәйданбашны зинданга илтеп ябыгыз. Хәзер минем исемнән әйт: батыр калганга иярле ат булыр.

Хан әмерен халыкка житкерделәр, мәйдан гөж килә, умарта күче диярсең, мәйдан боҗрасы янә кысыла башлады, янә сөңгечеләр мәйдан тирәли бастылар. Батыр калганга иярле ат бүләк итү күптәннән килә иде инде, алай да Сәлим хан атны мәйданга ук кертеп куярга боерды. Батыр калучыга атны ул үзе тапшырачак. Атны мәйданга китереп керткәч, Сәлим хан йөзен чытты.

— Алып китегез, күзем күрмәсен. Китерегез үземнең Алмачуарымны,— диде Сәлим хан.

— Ханым, хәкимем,— диде вәзир.— Алмачуар Болгарда бер ат, Болгарда бер аргамак. Ат белән бергә Болгар даны да китәр...

— Сөйләмә юкны, вәзир. Ат баш түгел, ат булыр, дан кайтыр, баш кайтмас. Үтә әмеремне, вәзир!

Хан әмереннән соң чарасыз калган вәзир мәйдан кырына Бөек Каланың мактанычын мәйданга алып керде. Барысы да толпарга сокланып карап тордылар. Йөгәнен, иярен, япмасын, өзәңгеләрен күрче — гелән алтын-көмештән. Йә хода, бу бүләккә батыр калуы үзе бер дандыр.

Соңгы мәлдә генә баһадир Тубыкбай тагын бер тапкыр Сәлим хан ягына карап алды. Нишләргә тиеш ул? Кенәзне егарга ярармы, бәргән хәлдә Сәлим хан ошатырмы? Әллә соң күтәреп, билен кысып кына куяргамы? Әмма Сәлим ханның карашын күрмәде баһадир, хәер, күрсә дә аңламас иде, чөнки кенәз аның билен тартып китерә башлады. «Ашыкма, кенәз, ашыгып куян куалар, мин сиңа куян түгел, Агыйдел буйларындагы урманнарда үскән аюдыр. Тубыкбай сиңа тиз генә бил бирә буламы. Батырга батыр калган көрәшчеләр ашыкмыйлар, кенәз. Әүвәл син аның көч-куәтен сына, бил тотышын чамала».

Тубыкбай сизелер-сизелмәс кенә билен уйнатып алды, кенәз кысып китерергә теләгән сынын бушата төште һәм үз чиратында кендәшенең касыгына йодрыгын кадады. Кенәзнең муен тамырлары камчы сабы юанлыгы булып бүртенеп чыкты, касыгына ишенең йодрыгы кадалуына түзә алмыйча боргаланырга тотынды. Ләкин Тубыкбай, моның ише көрәшчеләрне генә сындырганы бар иде, йодрыгын алмады, киресенчә, тагы да батыра төште. Һәм кисәк Сәлим ханның торып басуын күрде. «Юк, ярамас кенәзне бәрү, һич булмас димә, Сәлим хан кәләштән мәхрүм итәр. Ә Айсылу миңа бүген бүләккә дигән мең ат тора. Ат ни ул минем өчен, ат хатын түгел, аны болынга төшәсе дә тотасы, ә Айсылу кебек чибәрне, пәйгамбәр алдына барсаң да, таба алмассың. Әлбәттә, шәп булыр иде булуын Сәлим ханның иң яраткан аргамагын борын төбеннән алып китсәң, ләкин минем бүген максат башка — Айсылу».

Тубыкбай сөлгене тагы да кыса төште, йодрыгын кенәз касыгына тагы да батырды.

«Син, тиле баш, бәрә күрмә тагын»,— дигән тавыш ишетте Тубык-

бай. Кем шулай әйтер, мәйданбашмы? Юк, ул дәшми-тынмый карап тора, хәрәмләшмиләрме, имеш. Колакка гына ишетелдеме? Хода шулай Сәлим ханның авазын җиткердеме?

Кенәз ах-ух килә башлады, Тубыкбай кенәзнең билен янә бераз тартып куйды.

«Билең гел юк икән бит, кенәз»,— дип эченнән үзалдына сөйләшкәндәй уйлады ул.— Ә бил дигән нәрсә көрәшчегә кирәк ул, кирәк. Билең нечкә булсын дисәң, ат ите аша син. Ат ите бирә гайрәтне ир-атка. Син минем карлыгачымны нигә берсе артыннан берсе биш олан табып бирде дип беләсең — ат ите ашады Тубыкбай — сөеп туймадым мин аны, яратып. Ә миңа оланнар кирәк иде, оланнар алар ил тәрәге, ата тәрәге. Синең әле хатының гаҗәеп тә гүзәл, бала табамы соң, тапса кемне китерә — кыз баламы, оланмы? Хәер, синдә тегесе дә, монысы да юктыр әле. Мырк-мырк йөргән, биле-аягы булмаган, май-сызыктан гына торган чучка ите ашап нинди малай тусын инде! Нигә йөзең сытасың, кенәз. Мин бит — йөзең күрмәсәм дә тоям, кыен сиңа көрәшүләре. Касыгың авыртамы? Авыртыр шул. Көрәш ул орыш кырында кылыч селтәү генә түгел, көрәш ул көч сынау, гайрәт билгесе, көрәшнең үз хикмәте, үз хәйләсе бар. Орышта куәтле җиңә, күп вакытта азат түгел, корал орыша».

Шулай дип уйланды Тубыкбай һәм шуның белән оттырды да. Ул кенәзнең билсез билен тартып китермәкче итте, янәсе, күтәреп кенә аякларына бастырмакчы, бәрмәкче булды, аңа бүген ат та, дан да кирәкми, аңа бүген зәңгәр күзле Айсылу кирәк иде. Тубыкбай кенәзне күтәрә башлады. Авыр иде көндәш, төп кебек гүя җиргә ябышкан иде. Тубыкбай «эһ!» диде дә кенәзне эләктереп алмакчы итте, әмма көндәше билен шуытып алды, билсез бил баһадир сөлгесеннән шуып төште. Шул мәлдә кенәз Тубыкбайны күтәреп алды да җиргә орды. Мәйдан бермәлгә шым булды. Һәм кинәт гүя җир тетрәде — бүрекләр һавага очты, Сәлим хан урыныннан сикереп торды, йөгереп ат янына килде һәм мәйдан уртасына таба, Тубыкбайны бәрүенә ышаныр-ышанмас басып торган кенәз янына китте. Ур-ра кычкырулар, шау-гөр Иделнең аръягындагы урманнарга барып бәрелде һәм кайтаваз булып, бик озак ишетелеп торды.

Сәлим хан мәйдан аша тыпырдап биеп барган Алмачуарының йөгәненнән тоткан килеш кенәз янына туктады.

— Батырга хан бүләге ышбу ат булыр, кенәз!

— Кыйракмас иды, хан. Багатур гайратлы, кучлы, ат кучы бар багатурда.

— Алыгыз-алыгыз, кенәз,— диде мәйданбаш кысылып.— Туран гадәт такуй. Бүләк!

— Тор, Тубыкбай,— диде Сәлим хан һәм аягына баскан батырга биленнән каешын салып бирде.— Сиңа — хан каешы, баһадирым. Сынатмадың, Айсылуыңны бүген үк алып китә аласың...

Шулай диде дә Сәлим хан, килеп кенәзнең кулын кысты, ике батырның да кулларыннан алып өскә күтәрде дә:

— Татулык, дуслык! — дип кычкырды.

Болгарда мондый бәйрәмнең булганы булмагандыр. Сәлим хан шат иде, барысы да ул теләгәнчә узды, Тубыкбай да канәгать, кенәзнең дә кунак буларак күңеле үсте. Бәхәссез, ат шәп, Алмачуар кебек ат Болгарда бер иде, вәзир хаклы, әмма аттан кадерлерәк әйберләр дә бар әле бу дөньяда — тынычлык, дуслык. Вәзир Исхаккамы моны аңларга. Ә ат шәп. Ат өстендә гөлҗимеш сурәте төшкән рум япмасы, яллары тезенә җитеп тора, озын торыклы, колаклары тырпаеп, нинди иягә тап булдым дигәндәй, әле алга, әле артка юнәлә. Кенәз атның ял астына кулын тыкты, кашыштырды, ләпәп алды, ат тынычлана төште, башын селкеп куйды. Шунда кенәз тагын бер егетлек эшләде, өстеннән алтын укалы кафтанын салды да Тубыкбайның иңенә салды.

— Сиңа, кордаш. Минем бүләк!

Тубыкбай кенәз биргән кафтанны киеп җибәрде һәм чатыр астында дүрт күзләп үзен күзәткән Айсылуга карады — кыз елмая иде.

— Айсылуны калымсыз алырдай итеп көрәштең, Тубыкбай,— диде Сәлим хан.

— Калым таш яуса да килер, ханым. Егет сүзе бер булыр.

Сәлим хан баһадирның бу сүзләрен янә хуплады. Ул белә иде: кояш чыгышта матур, кош — очышта, кеше юмартлыкта матур. Адәм баласы бу якты дөньяга кунакка гына килә, бар күрәсе теге дөньяда, ди, китап. Димәк, үтүчән бу дөньядагы хәлләр. Үтүчән булгач, күбрәк изгелек кылырга кирәк. Тубыкбай баһадир хан күз алдында янә бер карышка үсте ошбу бәйрәмдә. Мондый бәйрәмнәр Сәлим хан гомерендә янадан булмады.

## 4

Сарай мәктәбендә Гали олан өчен бөтенләй икенче дөнья башланды. Иң әүвәл ул кәтиб Хафиз белән якынаеп китте. Кәтиб Хафиз аны шигърият дөньясына алып керде. Бериш шәкертләр аны тыңлады, берише үзара сөйләшеп утырды, ә менә Гали олан кәтиб Хафизны беренче дәрестән үк яратты, үз итте. Сарай мәктәбендә гадәттә дәүләт өчен хәрби йөзбашлар әзерлиләр, бирегә көн саен шәех Игәнәй килде, сарай шәкертләренә коръән сүрәләреннән изге юллар укыды, яраткан шәкертләренә ятларга аятьләр бирде. Хәрби һөнәргә шәкертләрне хан тарафыннан куелган баһадирлар өйрәтә, бирелә аларны уктан алырга, сөңге ташларга, кылыч белән орышырга чыныктыралар, атта йөрергә өйрәнү хакында әйтеп тә торасы юк. Кыскасы, Сәлим хан сарай мәктәбендә ата-бабаларының гадәтләрен тотып, дәүләтенең иминлеген сакларга йөзбашлар әзерли һәм шулар арасыннан иң булдыклыларын сайлап меңбаш итә. Әлбәттә инде, шәкертләр арасыннан сарайда илче булып хезмәт итүчеләр дә чыга иде. Шәкертләр арасында хан оныкларына да ташлама ясалмый, мәгәр хан оныклары барыбер хан оныклары булып калды. Тәрбиячеләр арасында Гали белән Булат оланга игътибар башкарак иде, хан оныкларына хәтта аерым тәрбиячеләр билгеләтте. Ханбикә Зөбәрҗәтнең каһәренә эләккәч, языклары өчен сарайдан куылган казый Нисбахны Гали оланга беркетте. Шул көннән алып, казый Нисбах Гали оланнан бер тотам да калмады, инәгә саплаган җеп кебек, олан кая барса, ул анда булды. Галине ул бер күрүдә яратты. Кешеләрне хөкем итәргә өйрәнгән казый Галине яратса да, аның урам малайлары белән шар сугуын, төрле уеннар уйнавын килештереп бетермәде. Билгеләнгән тәрбияләнүчесен урам малайлары арасыннан әләктереп алды да җирдә яткан чыбык белән Гали оланның арт ягына сыптырды. Тәрбиячесенең бу кыланышы хан оныгына бөтенләй ошамады һәм ул казый Нисбах кулыннан чыбыкны тартып алды да тәрбиячесенә кизәнде.

— Сук, сук, дивана, казыйларыңа кул күтәрә башласаң, сиңа тәхет тигәнче кызыл кар явар. Йөрисең шунда хан оныгы дәрәҗәсен төшереп, җыен әтрәк-әләм малай-салай арасында. Нигә Булат олан бу төпсез ыштан кигән малайлар арасында бер дә күренми? Дәшмисең?! Вакланмый ул, хан онығы булуын белә. Ә син?!

— Казый Нисбах, мин сине бабама әйтәм. Ул, бусагабаш Камайга кушып, артың каезлатыр...

— Каезлатсын. Ул апара тәпәненең үзен каезлыйсы бар. Йөри шунда хан бабаңның башын катырып, тузга язмаганны сөйләп.

— Ә мин үзем сиңа суксам, казый?

— Йөзеңә оят килмәсә сук, бу хәл дан тоелса, аны да бабаңа житкер. Хан оныкларыннан барысын да күтәргә була, дигән иде аны кәтиб Хафиз, хак икән, кизәнгән була бит әле, шайтан ялаган нәмәстә. Бир

чыбыгың! Булат туганың әнә Баян баһадир янынннан да китми, меңбаш буласы килә. Ә синең хәрби уеннар остазың Бачман баһадир атнага бер килә, анда да сине күрми киткән чаклары була.

— Бачман баһадирга сүз әйтмә, казый!

— Ни өчен мин аңа сүз әйтмәскә тиеш икән, алланың кашка тәкәсеме әллә ул кыпчак баһадиры? Йә аллам, кыланышын, олан Гали!

Шулчак сарай ягында ат менгән кешеләр күренде. Сәлим хан ауга юнәлә икән. Алдан чаптырып килгән азатлар, урам тутырып шар сугышлы уйнаган малайларны чәчеп-сибеп ташладылар, бары тик хан оныгы һәм аның тәрбиячесе Нисбахка гына сүз катырга кыймадылар. Нисбах казый белән хан оныгы Гали юл читендә басып тора бирде. Сәлим хан алар белән тигезләшкәч, оныгына кул изәде.

— Сиңа азатлар да тимәде, малайларны камчылар белән тараттылар,— диде казый Нисбах.— Йолдызлы кеше шул син, олан, йолдызлы кеше, маңгаеңда йолдыз бар.

— Нинди йолдыз? — дип Гали олан маңгаен тотып каравын сизми дә калды.

— Ни өчен мин сиңа килеп эләктем дип беләсең, Гали олан?

— Әйе шул, ни өчен, казый Нисбах?

— Телем аркасында.

— Кайгырма, казый Нисбах, мин сине якларммын. Телисеңме хезмәтчем итәм. Гомереңә янымда булырсың?

— Миңа күп яшәргә калгандыр дип уйлыйсыңмы, хан оныгы?

— Тәкъдир килмичә, берәүнең дә теге дөньяга киткәне юк, ди шәех Игәнәй.

— Шәех хаклы, тәкъдир килмичә берәвебез дә үлми. Ләкин бабаң көн саен диярлек кеше башын кистерә, аларга кем китерә икән ул тәкъдирне? Шул ук Игәнәй түгелме икән, олан Гали?..

— Миңа иртәгә ундүрт яшь тула, казый. Бабам безгә каеш-кылыч бирәчәк, ханның каеш-кылыч бирүе оныкларының балигъ булу билгесе, хезмәтче тотарга хокуклары була, димәк ки.

— Син мине, Олуг Мөхәммәткә һәм Владимир кенәзенә илчеләр башында барган кешене, хезмәтче итәргә җыенасыңмы, хан оныгы?! Әй бу язмыш дигән нәмәрсәне, тотып тукмасаң иде үзен бер. Беләсеңме, хан оныгы, мине кем эштән чыгарып ташлады?!

— Кем?

— Әйдә, кайта-кайта сөйләрмен,— диде казый Гали оланның иңеннән кулын алмыйча кузгалып.— Кем булсын, гүзәл дәү әниең — ханбикә Зөбәрҗәт. Ул болай булды. Мин Владимирдан йөреп кайттым, булган хәлләр хакында сөйләргә дип хан янына кердем. Барысын да җиренә җиткереп исәнләштем, ханнан, кем әйтмешли, фатиха алдым һәм сөйли башладым. Сөйли генә башлыйм, ханбикә сүз кыстыра, сөйли генә башлыйм, янә нидер сорап куя бу. Шуннан түзмәдем, хан янына якынрак килдем дә: «Куып чыгарасызмы моннан ханбикәгезне, ханым, юкмы?!» — дидем. Табигый, ханның күзләре шар булды, минем сүзләрне дәү әниең дә ишеткән икән, колакларына кадәр кызарынып чыкты бу. Ай чибәрләнеп китте дә үзе, гел менә күз алмаслык булды, күрдем дә таң калдым, телдән яздым — тик карап торам икән ханбикәгә. Әлбәттә инде, мине сарайдан җилтерәтеп чыгарып ташладылар. Ул гынамы, хан зинданына төшереп бикләделәр. Икенче көнне хан үзе килде. Янәсе, үз акылындамы илчесе? Үз акылында, әмма сырт кабарган, хан белән тырт-мырт сөйләшәм. Кара Пулатта казый булган чагымда мин уйнашта тотылган хатыннарны үлемгә хөкем иткәләгән идем, хан шулай кушты, ул кушмаса да, яратып бетермим мин андый затларны. Әлбәттә инде, бераз арттырыбрак та җибәргәләдем, языксыз хатыннар да эләкте бугай. Әмма, әлегә кадәр иманым камил, гөнаһсыз хатын-кыз юк ул, юк! Сөяксез ит булмаган кебек, гөнаһсыз хатын-кыз да юк! Әйтик, аллаһы тәгалә һава туташны җиренә җиткереп яратып, оҗмах гөл-

бакчасында интегеп йөргән Адәм белән кавыштыргач, кем татлы алма ашарга Адәмне котырта? Иблис түгел, һава туташ. һә-һә, үзең дә беләсең икән, кәтиб Хафиз сөйләгәндер әле. Улмы? Шулайдыр дип уйлаган идем дә аны. Әнә шуның өчен мин ул хатын-кызны, аз гына гаебе булса да, үлемгә хөкем иттем. Ханбикәгә бу ошамаган, киленнәре дә дәгъва белән килгәннәр дип ишеттем. һәм күп тә үтми, мине казыйлыктан алдылар, илче итте бабаң. Мәгәр илчелектә дә озак тора алмадым, аннан да кудырды дәү әниең. Инде менә сиңа килеп каптым — тәрбияче, имеш. Нинди тәрбияче булыйм, ди, мин! Хак анысы, бабаңа үпкәм юк, мине яклады, ханбикә хөкем итәргә кушкан иде, алып калды. Иллә ханбикәсенә каршы сүз әйтә алмады, яңадан илчелеккә җибәрмәде.

— Казый, дәү әнием хакында яман сөйләмәсәң иде.

— Менә анысы булмастыр, хан оныгы. Әбекәең Зөбәрҗәт азгын хатыннарны үлемгә хөкем иттермәскә дип бара, ә мин килешмим, азгын икән — дар агачы аңа.

Гали олан сүзен шигырь белән әйтте:

— Ак сарайда балчымын, ана Иделдә салчымын,
Әчтерханда тучымын, кыр-калада укчымын;
Анам сорсаң — никахсыз, атам сорсаң — билгесез,
Илем сорап ни дисең, артык бала туган соң...

— Йә аллам, олан Гали! Гайсә улы Әмәттәндер бу юллар.— Казый Нисбах олан алдына тезләнде.— Ал, олан, мине хезмәтчең итеп. Ала күр! Ханбикә Зөбәрҗәт мине ат тизәгенә бутап ташлады, битемә юынтык су сипте. Сәлим хан чарасыз калып, кулларын җәйде. Житдилек җитми ханга. Онықларына бөтен җыен алдында тәхетен вәгъдә итте, соңыннан уен белән бетерде. Мин күп түздем гафилләргә. Борынгылар: «Адәм баласы акыллы янында — акыллы, җүләр янында — җүләр, исәр янында — исәр, дивана янында — дивана булыр», ди. Минем акыллы кеше янында буласым килә. Мин сиңа төннәр буена китаплар укырмын. Көчле берне тапса, белекле меңне табар, ди. Болгар минем җаным да, тәнем дә, иманым да. Иң изге иманым гаделлек булды, табынганым — акыл иясе дер. Бабаң Сәлим хан дәү әниең аяк астында олтандыр, ул ни әйтсә, шуны тыңлап яши бирә. Ә гомер дигәнең үтә тора, үзгәрә. Болай булса, көннәрдән бер көнне Болгарны яуларлар, акыл ияләрен дар агачларына асарлар, җүләрләрдән бер елга суын икенчесенә ташытырлар, хатын-кызларыбызны үзләре белән алып китәрләр. Сагынырга изге зат, сокланып карарга гүзәл табылмас...

Гали олан ни кылырга белми аптырый калды. Ул бу кешене аңлады да, аңламады да. Акайганрак күзле, карчыга борынлы, озынча юка-чандыр чырайлы, изүенә ябышсаң җаны очып чыгып китәргә торган кешенең теле-телгә йокмый, ул гынамы, колак торырлык сүзләр сөйли иде. Кашанда яшәгәндә Гали олан еш кына ат абзарының чормасына менәр иде, шунда күрер иде ул бу кешегә охшаган төн кошын — мәче башлы байгышны. Казый Нисбахны байгышка охшатты да көлеп җибәрде.

— Көлмә, олан,— диде казый.— Бабаң өч хакыйкатьне онытып яши: һавада уклар сызгырганда гына илең тыныч калыр, әчкән суыңа дошман каны кушылганда гына татлы булыр, итне дошман угына кидереп кыздырганда гына тәмле булыр, диләр. Аты-исеме гайрәтледер бабаның кылган эше аздыр. Табгачлар шартлагычлар тапканнар, ди, әнә китәсе иде шунда, алып кайтасы иде ул шартлагычны ясау серен, дошман дигәннәре ил чигенә килергә куркып торырлар иде. Борынгылар ир-егетләренә: «Орышмаган — оттырыр, орышканы мул торыр», дигән. Бабаң Владимир кенәзенә олау-олау ашлык озата, ташчыларыннан чиркәү салдыра, атаң әмир Хажи шуңа олау-олау тимер сата, ук-сөңге озата. Ул уклар көннәрдән бер көнне әйләнеп кайтмаслар микән, ясаган осталарының йөрәкләренә кадалмаслар микән? Син ул

чиркәү салырга киткән осталарны кире Болгарга әйләнеп кайтырлар дисеңме?! Булмас ул. Кенәз аларга җир бирер, өй салыр, иллә дә иленнән җибәрмәс. Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс. Һөнәрчеләре арткан саен куәте арта барыр Владимир кенәзенең. Кенәз анда Күчтем бай ырулары белән ызгыша. Кем белә, бәлкем ул аларны җиңеп тә чыгар. Инде чыгышымны беләсең килсә, хан оныгы, белеп тор: атам Саксин каласында бер сәүдәгәр иде. Мөгаллимем — шәех Сөләйман ибне Давыт Саксин-Суваридыр. Бөек Калага мине ул җибәрде.

— Кичер мине, казый Нисбах,— диде Гали олан һәм тәрбиячесе алдында тезләнде.— Кичер мин гафилне!

— Тор, хан оныгы, килешми сиңа минем алда тезләнергә. Синдәй ирләр бары тик ике җирдә, ике очракта тезләнергә тиеш: ил әләме алдында һәм чишмәдән су эчкәндә.

— Казый! — дип Гали олан остазының кулын үбәргә үрелде.— Ташлама мине. Иртәгә синең хакта бабама әйтермен, ул риза булыр, игелеген бирер.

— Хуш, син дигәнчә булсын, олан. Аллага тапшырыйк,— диде күпне күргән казый.

* * *

Икенче көнне иртән иртүк Гали олан бабасы Сәлим хан янына юнәлде һәм үзе белән казый Нисбахны да алып керде. Сәлим ханның кәефе юк иде. Гали оныгы йомыш белән мөрәҗәгать итүгә, ул Нисбахка күтәрелеп тә карамыйча:

— Итә күр,— диде.— Тагын нинди йомышың бар?

— Башка йомышым юктыр, бабам.

Сәлим хан алай булгач, ничек кердең, шулай китә бир, дип кул селтәде. Гали олан белән Нисбах чыгып киткәч, бусагабаш Камайга берәүне дә тәхет бүлмәсенә кертмәскә кушты. Сәер халәттә калды Сәлим хан оланны күргәч. Чәчкә бәйрәмендә булган хәл күңел түрендә яңа өр-яңадан калыкты. Гали оныгы гаепле түгел, моны хан белә иде, гаеп үзендә булды. Оланның андагы кыланышы итагать билгесеннән узмады, кара халык котырынды, шул хәл кәефен бозган иде Сәлим ханның. Кем котырта кара халыкны? Шуны беләсе килә иде аның. Ага Базар сәүдәгәрләреме, сарай куштаннарымы, я булмаса һөнәр ияләреме? Әйе, һөнәр ияләре дә булуы бик мөмкин, соңгы вакытта Бөек Калада бу халык аерата күбәеп, ишәеп китте. Узынды, симерде халык. Бер-бер хәл кылмасаң, баш күтәрергә дә күп сорамаслар. Албагучы Таймас баһадир кешеләре ни карый, акча алырга яраталар, ә ханнарына йодрык янаганда, халык артына посалар. Аларны да гаепләп бетереп булмый, зинданнар тулы качкын, карак һәм канун бозучылар. Аннары Ага Базарда җиде илдән җиде халык сәүдә итә, бар, белеп бетер кем нәрсә сөйләгәнне. Ул гынамы, кануннарны рәхимсезрәк итә башласаң, Сәлим хан халкын рәнҗетә, дип гайбәт таратулары да бар әле. Юк инде, ничек булган, шулай кала бирсен. Ханбикә дөрес тойган икән, уеннан уймак чыгып куя язды. Язса гына бер хәл, халык ханнан нидер көтә башлады. Моны кичә халык алдына чыгуга ук сизде. Ура кычкыру да юк, хан авызыннан яңа сүз көткәндәй, тик күз акайтып карап торалар. Аннары кая ул хөрмәт итеп баш иеп каршы алу да, баш орып озатып калу, әйтерсең, ханнарын түгел, күршеләрен очраталар, дәшүче дә, баш оручы да, сәлам бирүче дә юктыр. Сәлим хан үз күңелен үзе күтәрергә теләп, сәлам дә юллаган булды, юк, дәшмәделәр. Болай чынлап та тәхеттән төшереп куюлары бар...

Сәлим хан күзләрен түшәмгә текәп, уйга калды. Кәтиб Хафиз кыштыр-кыштыр нидер яза. Менә ичмасам кайгысыз кеше, яза да яза, язмаганда китап укый, бер нәмәрсәдә дә гаме юктыр. Картлар әйтмешли, моңа үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын.

Аллаһы тәгалә Сәлим ханга бик яшьли тәхет бирде. Бу хәл Болгар ханы Солтан Морат үлгәч булды. Ибраһим хан тәрбиясендә үскән иде Солтан Морат белән Сәлим. Сәлим хан ата-аналары кем булганын әле дә белми, аларның икесен дә Ибраһим хан тәрбияләп үстерде. Солтан Морат ушлырак, зирәгрәк иде, үләр алдыннан Ибраһим хан тәхетен аңа васыять итте. Сәлим исә Сувар каласына күчеп китәргә мәҗбүр булды. Ике тәкә башы бер казанга сыямы? Моны ул Ибраһим хан үлгәч тә сизде. Мәгәр Солтан Морат кыска гомерле булды, тәхеткә утыруының икенче елында ук дөнья куйды. Сарай куштаннары Бөек Калага Сәлимне чакырып алдылар һәм хан иттеләр. Ибраһим хан Багдад халифеннән фатиха алган кеше иде, мәгәр ни отты? Күрше урыс кенәзе Юрий Долгорук белән орышты — бер каласын югалтты, мукшы илтабарын һәм аның җирләреннән ваз кичәргә мәҗбүр булды. Сәлим хан тәхеткә утыруга, Ага Базар сәүдәгәрләре җыелып сарайга килделәр, биләренең җыем алуыннан зарландылар. Сәлим хан аларга: «Уйлап карармын»,— диде. Һәм күп тә үтми Ага Базарда сәүдә иткән сәүдәгәрдән, чит ил кешесеме ул, болгармы, ышбу көннән җыем алу бермә-бер киметеләчәк, дигән фәрман чыгарды. Шул хәлдән соң Ага Базар сәүдәгәрләре аны һәрчак якладылар, кирәк чакта акчасын да бирделәр, «юмарт хан» дип исемен дә дөньяга тараттылар. Кичәлебүгенле исә Ага Базар сәүдәгәрләре дә кисәк кенә үзгәрделәр. Аларның хәйләләре Сәлим ханга аңлашыла иде: яшь хан янә яңалык китерер, Ага Базарда сәүдәгәрләрдән ясак җыюны янә киметер. Бит килгән ханнар аларга һәрчак изгелек кылдылар, нигә, әйтик, шул ук олан Гали моны эшләмәс икән? Тәхеткә генә утырсын, эшләр.

Ага Базарда булган хәлне күз алдына да китерәсе килмәде Сәлим ханның. Базарга ул аудан кайтышлый керде, укка алган җәнлекләре белән мактанмакчы иткән иде, киресенчә килеп чыкты — аларга караучы да булмады, әйтерсең, ат биле аша аскан ике бүре, җиде төлке, унлап куян киек җәнлек тә түгел иде.

Кәефе юклыгы Сәлим ханның янә шуннан иде. Кенәз теләнә-үтенә Бөек Каланың меңгә якын ташчысын алып китте. Имеш, башкаласына чиркәү салдыра. Әйдә, салдыра бирсен, Сәлим хан да ким куймый анысы — мәхәллә саен таш мәчет торгызды. Кенәз менә ничә ел инде Болгар сәүдәгәрләреннән кергеннән артык ясак җыя, әлек бер дә алай итми торган иде, уртак базар каласы булгангамы, урыслар да, болгарлар да җыемсыз сәүдә итә торган иде.

Сәлим хан тәхетеннән купты, ишекле-түрле йөренергә тотынды. Йөри торгач, хәзер үк вәзирне чакырырга дигән фикергә килде. Бусагабаш Камайга вәзир Исхакны чакырырга кушкач, Сәлим хан янә тәхетенә утырды. Ниһаять, ул катгый карарга килде — кала салуны ашыктырырга, кала төбәген карарга онныкларны да җибәрергә. Кала төбәген сайлагач, хатны ачып укырга дип вәзир Исхакка баглап, Баян баһадирга хат язып бирергә булды. Онныкларның берсеннән кан коймыйча да котыла ала икән ич ул. Һәм бу хәлдә аңа вәзире ярдәм итте. Соңыннан ул бу хәлдә кемне гаепләргә җаен табар...

Вәзир килеп кергәч, Сәлим хан уйлаган фикерен әйтте һәм аңа иртәгә үк юлга кузгалырга боерды.

— Барысын да сез дигәнчә итәрбез,— диде Исхак.

Ул чыгып киткәч, Сәлим хан бусагабашы Камайны чакырды, ләкин авыз ачып сүз катырга да өлгермәде, хезмәтчесе:

— Ханым, угланың Хаҗи килгән, йомышы бар икән,— диде.

— Дәш, керсен,— диде Сәлим хан.

Дөресен әйтергә кирәк, аның бер дә угланы Хаҗи белән очрашасы килмәгән иде. Үзсүзле, тәкәббер, атасыннан аерылып чыгарга җыенгандай, һәрчак мөстәкыйльлеккә омтыла, бер Шайтан каласында меңнән артык азат тота. Казан кирмәнендә мең азатны ашатып яткыра. Кыскасы, углан атасына буйсынмый башлады. Бәхәссез, илче Садакны да

аның кешеләре үтергәндер әле. Житмәсә Шайтан каласында дөньяда булмаган чуен коя, йозләгән тимерче тота. Кашан каласы тулы һөнәрче, тире иләүче, чүлмәк ясаучы. Ул гынамы, сызгыра торган туплар да ясый икән, диган гайбәт йөри. Ярый гайбәт кенә булып калса? Ә Яким бай сәүдәгәренең энесе Апанай нишли икән Кашан каласында? Тимерчелеккә генә өйрәнә микән? Әйе, чуен коюны серен белергә теләүчеләр дә ишәеп китте.

Алай да ни йомыш китерде икән угланны Бөек Калага? Бәлкем ул илче Садакны кем үтерүен әйтергә килгәндер? — дип уйлады Сәлим хан, ишектән килеп керүче угланы әмир Хаҗидан күзен дә алмыйча.

— Әссәламе галәйкем, атам!

— Вәгаләйкем әссәлам, углан. Әйдә, түрдән уз, түмәрдән утыр. Ишеттерделәр, углан, атаң әмеренә колак салмыйча, Яким сәүдәгәр товар ишләренә ук-сөңгеләр сатып ятасың икән?

— Атам, Яким сәүдәгәр товар ишләре Бөек Калада бер урам, Кашанда ике урам тоталар. Аннары Яким сәүдәгәр оланнары, туганнары Владимир кенәзе белән бәхәстә. Аларның бу өлкәдә безгә ярдәме тиеп куюы бар, диюем.

— Хуш, шулай да булсын ди, углан. Әйе, гәрчә без кенәз белән солыхта булсак та, аның оясында ни булганны белеп торуың, бар нәрсәдән дә хәбәрдар булуың мине куандырды. Мәгәр мине бүген ул нәрсә кызыксындырмый, углан, илче Садакны кем үтергәнне беләсем килә. Мин илче үлеме аркасында Олуг Мөхәммәткә табибем Хәсәнне җибәрергә мәҗбүр булдым, хәзер энә сарайга рум Антонийны алдым, болай әйбәт табиб, диләр, ләкин әллә нигә минем аңа күңелем ятып җитми.

— Илче Садакның үлеме миңа да билгеле түгел, атам.

— Менә монысы сәер, углан. Олуг Мөхәммәт илчесе Шайтан каласына керергә ярлык ала. Илче калага керә һәм аны икенче көнне елгадан табып алалар.

— Илче белән барган шәех мөриде исән калган. Ничек соң ул исән калган икән, атам? Алар Шайтан каласына бергә барганнар лабаса. Бу хакта миңа азатларым әйтте, атам! Илче Садак турында Бөек Калада имеш-мимешләр йөри. Ул Олуг Мөхәммәт тарафыннан чуен коючы Әхмәт угланы Бәкерне урларга килгән икән, диләр. Кем үтерсә дә барыбер түгелмени, атам, ул илчене?! Илче безгә изге максат белән килмәгән. Аннары, миңа калса, Олуг Мөхәммәткә чуен коючы хакында кемдер хәбәр иткән. Кем? Менә шуны белсәгез икән, атам!

— Илче Садакка ияреп Шайтан каласына киткән, исән кайткан мөрид икенче көнендә үк юкка чыга, углан.

— Шәех Игәнәйгә бар булган хәлне сөйләп биргәч юкка чыга, атам. Моннан шуны әйтергә була: сер урлауны шәех Игәнәй оештырган. Тик кемдер аларга комачаулаган.

Сәлим хан як-ягына каранды, аннары чебен куган кебек селтәнергә тотынды.

— Сөйләмә булмаганны, углан. Ил серен сатарга шәех бармас... Әйе, күеп торыйк бу вакыйганы.

— Атам, чуен кою сере Болгарда туды, Болгарда калыр да.

— Бирсен ходай диясе генә кала, углан.

— Нигә алай дисең, атам?

— Моңа кадәр бер генә дәүләтнең дә тегә я бу серне еллар буена саклап тора алганы булмаган, шуңа әйтүем.

— Ә без сакларбыз, атам.

— Үзең үк сатып җибәрмәсәң... Бүртенмә әле ул тамаша, углан. Синдә энә урыс осталары эшли, алар тик яталардыр дип беләсеңме? Һә, дәшмисең. Дөнья ул, углан. Инде хәзер мине тыңла. Ибраһим хан атабызның җиңел кулы белән, белгәнеңчә, Идел түрендәге Утәк

базар каласы Андрей кенәз кулына күчте. Хәзер ул Болгар сәүдәгәрләреннән җыем ала башлаган. Безгә, углан, түбән табарак, шулай ук Идел буена базарлы кала салырга кирәк. Үткәне күмеп китсен. Без биредә уйлаштык-уйлаштык та ул каланы Казан елгасы Олуг Иделгә койган төбәктәрәк салырга дигән фикергә килдек. Анда Чияле тау дигән калку урын бар икән, аста — Кабан күле.

— Атам, анда елан мыжлап тора, күл буе тулы кабан дуңгызы. Анда гомер итүче төрки кардәшләр, чирмешләр Чияле тауда еланнар патшасы Аждаһа яши, диләр.

— Беләсеңме, ул еланнар хакында вәзир Исхак ни диде? Ул төбәкләргә кала салдырмас өчен камнар уйлап тапкан хәйлә генә ул, диде.

— Бирсен ходай, шулай була күрсен.

— Аннары Казан кирмәнен анда күчерергә булыр. Килешсез урында, углан, ул кирмән. Ни зур елга буенда түгел, ни олы юлда, дигәндәй. Килеш, углан, безгә Мәкәрҗә каласыннан да олырак итеп Идел буена Базаркала салырга кирәк. Кирмәне дә шунда булсын. Ил тынычлыгын кирмән тота. Җир синеке, осталар минеке.

— Яхшы, атам. Мин бу хакта уйлап карармын.

— Син, углан, әлегә борчылма, башта вәзир Исхак барып кайтсын, аннары җыелып бер сөйләшербез. Базарканы салуда Илһам углан да читтә калмас дип уйлыйм. Кече онык үсәме? Акбикә килен исән-саумы? Теге Бачман баһадир сеңлесе, аты коргыры, ничек кенә соң әле, әй, Зәйтүнә бугай, ни бетереп ята, кияүгә чыкмадымы әле? Юкмы? Килгән бер яучыны куып җибәрә икән, дип ишеттем. Хакмы шул?

— Атам, Зәйтүнә белекле, акыллы кыз. Күңеленә ошаган кеше килгәч, чыгар ул, чыкмый калмас.

— Ишеткәнсеңдер инде, сарай мәктәбен тәмамлап, иленә кайтып киткән Тубыкбайның энесе Җик Мәргән агасы белән дәгъвалашып, качаклыкка башын салган икән. Тубыкбай үзе дә эзләми, миңа да килгәне булмады. Җик Мәргәнне синең урманнарында качаклык кыла дип сөйлиләр, хакмы шул?

— Юк сүздәр, атам, бер ишетмәсәм, бер ишетер идем, гөнаһлы буласым килми. Җик Мәргәнгә хөрмәтем зур иде, иллә аның бу тапкырлыгын мактамас идем.

— Акыллы әйттең, углан. Ата кеше, абый кеше энесе белән ызгыша башласа, илдән иминлек китүе бар. Кала салыр алдыннан безгә иминлек кирәк, углан. Шәех әнә: епископ Габбас теш кайрый, кара халыкны котырта, ди. Кяфер, имеш. Әйе, кяфер, мәгәр ил кяфере. Болгарга Юрий Долгорук яу белән килгәч, мөселманы-христианы иңгә-иң килеп дошманга каршы сугышты. Һәм илне саклап алып калдылар. Үз күзем белән күрдем мин ул хәлне, орышларга да катнашырга туры килде.

— Атам, миңа бу хакта фикер йөртергә кыендыр. Мин епископ Габбасны да, шәех Игәнәйне дә яратмыйм. Миңа камнар якынрак, алар җирдәге кеше белән әңгәмәдәш, болар исә кеше өметен күккә юнәлтәләр. Күктән мин бары тик бер изгелек көтәм — яңгыр. Калганы адәмнең үз кулындадыр.

— Тәүбә диген, углан. Ни сөйлисең син! — Сәлим хан кәтибе Хафизга күз төшереп алды. — Инде кит. Кит-кит, юлында бул!

— Атам, тагын бер гозерем бар иде.

— Ни тагын?

— Кече угланымны сарай мәктәбенә укырга алмый торсаң иде. Бу хәбәрне ишеткәч, киленең Акбикә кайгыга калды. Өйдә жан иясе дә калмыйммыни инде, дип елый.

— Еласын. Хатын-кызга күз яше ни ул? Ирме син? Хан оныклары барысы да сарай мәктәбендә укырга тиеш. Киләсе атнадан да калмый Җәббар оныгым сарай мәктәбендә булсын! Миңа ана куеныннан чыкмаган меңбашлар кирәкми. Орыш кырына имчәк кабып кермиләр.

— Яхшы, атам, син дигәнчә итәрмен.

Әмир Хажи атасы янынна айтер сүзен әйтә алмый чыгып китте. Сәлим ата угланның бөкрәя төшкән аркасына карап калды. Төз гәүдә, саллы сын иде углан да, моны да дөнья йөге бөгә башлаган, дип уйлап калды Сәлим хан. Кырыгынчы язын тутырып килә, әле булса бер хатын белән яши. Өйләнер иде тагын берәүгә, шуннан угланнарың өчен ул хәтле эчен өзелмәс иде. Ә кече оныгым миңа Гали олан югала-нитә калса кирәк, әмир Хажи.

Угланы чыгып китүгә, Сәлим хан кәтибе Хафизга дәште.

— Кәгазь-каләмен калдыр да, бар әле, һавага чыгып кер, Хафиз. Тукта, әүвәл яз. Һиҗри белән 573 елда, милади белән 1177 елда җәйнең иң ямьле аенда Казан дәрьясы Олуг Иделгә койган төбәктә Болгар ханы Сәлим моңа кадәр ише булмаган Кирмән Кала салырга фәрман бирде. Кала сарае торгызыласы урын сайлауны вәзире Исхакка йөкләде. Яздыңмы? Инде бар, чыгып кит.

Кәтиб Хафиз чыгып киткәч, Сәлим хан бусагабаш Камайдан табибе Антонийны чакырырга кушты. Табибе килгәч, алар икәүдән-икәү бик озак сөйләшеп утырдылар. Ул чыгып киткәч, хан янә бусагабаш Камайны дәште, тегесе озын-озак керми торгач, аңа ябырылды:

— Кая йөрисең, апара тәпәне! Иртәгә үк куам мин сине. Ат караучы итеп куям. Юк, Җаек буена җибәрәм, кирмән торгызырга, җаның чыксын балчык ташып!

— Гаеп миндә, шөһрәтлем, ат караучы туры айгырны чыгарган иде, йөгәнен ычкындырган, тота алмый изалана...

— Син тоттыңмы?

— Тоттым, ханым. Әнә карагыз, җиләнем ертты, мәнсез җан.

— Шактый ук сөйрәп бардымы, җиләнең ерттымы? — дип, Сәлим хан кет-кет көлә башлады. Чынлап та, көлмәслек тә түгел иде, бусагабаш Камайның бите сыдырылган, затлы җиләне иңеннән алып чабуына кадәр ерылып чыккан иде. Ханга ияреп, үз кыяфәтеннән Камай үзе дә көлә башлады. Көлгәндә аның дәү корсагы койка кебек дерелдәде, тавышы ишетелмәсә дә, бит-чырае бүртенеп чыкты. Тавышы үчкән, әмма бөтен гәүдәсе калтырап торган бусагабашын күрде дә Сәлим хан аптырый калды. Бу ни хәл, нигә монын тавышы чыкмый?

— Карале, Камалетдин,— диде хан беренче тапкыр тегенең тулы исемен атап.— Нигә синең көлгәндә тавышың чыкмый?

— Белмим, ханым,— диде Камай көлүдән кисәк туктап.— Әчемә китәдер...

— Эчеңә? — дип гаҗәпләнде Сәлим хан янәдән көлә-көлә.

Камай да көлә башлады, әмма тавышы янә чыкмады.

— Мин сине, бозау ялаган нәмәстә, ат караучым итәм, ә ат караучымны бусагабашым итеп куям.

Камай шундук көлүдән туктады, гәрчә тавышы чыкмаса да, Сәлим хан моны тегенең җитдиләнеп киткән чыраеннан чамалады.

— Гаеп миндә, шөһрәтлем.

— Гаеп, нинди гаеп ди тагын! Карале, Камалетдин, нигә сине хатыннар яратмый? Ник дип менә, әйтик, сине күрсә, ханбикә Зөбәрҗәтнең дә йөзе чытыла?

— Алай дип әйтмәс идем мин, ханым. Хатын-кыз эт белән бер бит ул, итсез сөяккә эт ташланамы?

— Һе-е, ни-ни дидең? Менә сиңа мә!

— Йөзен чытып җирәнеп карамый ул миңа, ханым, моны ашап карасаң иде бер, дип карый.

Сәлим хан шаркылдап көлеп җибәрде, эчен тотып, тәхетеннән үк шуып төште. Ахыр ул күз яшьләрен сөртә-сөртә, аһ-ух килә-килә көчхәл белән тәхетенә утырды һәм:

— Юк, мин сине беркемгә дә бирмим, бусагабаш Камай. Мин сиңа, сиңа мин кирәк. Теге оста Дәүран һаман зинданда утырамы?

— Зинданда утыра, ханым.

Сәлим хан беравык уйланып утырды.

— Ярый, утыра бирсен. Кирәге булгач, чыгарырбыз.

## 5

Иртән-иртүк ике оланны да сарайга китерделәр. Сарай каршында аларны үзләренә җайлаштырып тегелгән хәрби киемнәр белән өзәңгеләре кыскартылган иярле атлар көтә иде инде. Оланнар тиз генә киенеп алдылар, бәйрәмчә булмаса да, әйбәт, җайлы утыра иде аларда кием. Ул арада сарай йортына меңбаш баһадир Баян килеп керде. Ул оланнарның атка атланганын көтеп торды да үз янына дәшеп алды. Шул чак Сәлим хан болдырга чыкты һәм оныкларын хәрби киемнән ат өстендә, җитмәсә Баян баһадир янәшәсендә күреп, йөрәге кысылып куйды. Оланнарның берсе сарайга әйләнеп кайтмаска тиеш булачак ич, хат инде Баян баһадир кулында, аны кире сорап алу кыен. Бу хан тарафыннан йомшаклык күрсәтү булыр иде. Ике туган арасында кан коеләчәктә коелганчы, хәзер...

Сәлим хан җыелганнарга кул изәде. Баян баһадир атын капкага борды, аңа оланнар да иярде. Ә капканы чыгар алдыннан аларны казый Саксин, кәтиб Хафиз куып җиттеләр. Гали олан мөгаллимен күреп, кычкырып ук җибәрде.

Менә эчке кирмәннең авыр имән капкалары ачылды, асма күпер төшерелде һәм сәфәрчеләр хан кирмәненнән чыгып киттеләр. Баян баһадир Сәлим хан боерыгы белән сәфәрчеләрне озатырга йөз азат алды. Капканы чыккач, баһадир йөзбашка туктарга боерды. Алар вәзир Исхакны көтеп алдылар. Вәзир асма күпердән чаптырып чыкты, әмма шундук кире кирмәнгә кереп китте. Тик беркавым вакыт узгач кына вәзир яңадан чаптырып килеп җитте һәм көтеп торган Баян баһадирга:

— Кузгалдык! — дип кычкырды.

Басу капкасын чыккач, алдан барган Баян баһадир атын җилле генә юырттырып алып китте. Аңа оланнар, кәтиб Хафиз, Саксин казый, вәзир һәм йөзбаш карамагындагы азатлар да иярде.

— Казый агай, безнең белән тигезләш, атың сикертеп чаптырма, эчең төшәр! — дип кычкырды артына әйләнеп Гали олан. Баян баһадир да артына әйләнеп көлемсерәп куйды һәм:

— Тавышы көр чыга бу оланның, әллә сәфәр арасында йөзбаш итәбезме үзен? — диде янәшәсендә барган вәзиргә. Вәзир баһадирга бер сүз дә әйтмәде, нигәдер аның кәефе юк иде.

Чокыр-чакырлар, инешләр аша салынган күперләр үтелде, ул арада кояш та күтәрелде, арканы кыздыра башлады, өстәге хәрби киемнәр авырайды, билгә таккан кылыч бертуктаусыз ботны каезлады. Кече Чирмешән елгасына җиткәч, атларны эчерделәр, бераз ял иткән булдылар. Бөек Каладан чыккач та авыз ямый сөйләшеп барган оланнар да тынып калды. Кече Чирмешән елгасын кичкәч, Баян баһадир дүрт азатны алдан җибәрде. Алар хан сәфәрчеләре үтәсе юлның иминлеген тикшереп килергә тиешләр иде. Бу юлдан бер тапкыр гына үтмәгән Баян баһадир, кичкә кадәр Ибраһим каласына җитәргә тиешлекләре хакында искәртеп куйды. Берәү дә аңа каршы әйтмәде һәм әйтергә хаклары да юк иде. Баян баһадирда сәфәр чыккан хан вәкилләренең иминлеге иде. Янә бер елгага җиттеләр. Әмма күпер җимерелгән булып чыкты. Багучы дүрт азат кичү эзләп түбән таба чаптылар. Күп тә үтми, алар борылып та килделәр, ерак та түгел җайлы урын бар икән. Җилле генә юырттырып елга яры буйлап түбән төшә башладылар, бераз баргач, чынлап та кичү күренде — җигүле ат белән берәү елгадан чыгып ята иде.

Кичүгә алдан якынлашкан азатлар су чәчрәтә-чәчрәтә җигүле ат янына чаптырып керделәр. Арбалы кешенең аты елга уртасында туктап калган, иясе исә атын камчы белән чыбыркылый, ә бахбай мәхлук, ары сугыла, бире сугыла, тик арбаны кузгата алмый интегә иде.

Азатлар арба янына җитте, ике як тәртәдән алып, аны җиллә генә кичүдән алып чыктылар. Ат тотучы, озын мыеклы агай арбадан төште, баш ия-ия әсирлегеннән коткарган азатларга рәхмәт укыды. Шуннан соң ул атның ыңгырчак бауларын төзәтте, аркалыгын күтәрә төште, камыт челдереген сүтеп кысты, төрле бизәкләр төшерелгән кыңгырауны бөгәлҗәне җайлагандай итте. Гали олан дикъкать белән аңа карап тора иде, чыбылдык ачылды һәм арбада бер туташ күренде. Гали олан туташны күрде дә тәмам телсез калды. Туташ мөлаем генә:

— Мең-мең рәхмәт сезгә, азатлар! — диде.

— Туганкай, яшь азат, атыңны читкәрәк ал, тәгәрмәч астында калуың бар, туганкай дим! — диде ат тотучы.

Мәгәр Гали олан ат тотучыны күрми иде инде, ул, сихерләнгән бердәй, һаман кызга карап, теле аңкавына ябышкандай, сүз әйтә алмый тора иде. Кыз мөкиббән киткән яшь азатка тыенкы гына елмая, ул үсмер егеттә балаларга хас кызыксыну да, шул ук вакытта ир-егетләргә хас гашыйк булу галәмәтләре дә күрә иде.

— Юл башыгыз кайдан? — дип сорады, ниһаять, үсмер, мәгәр шул соравы белән кинәт күз алдында үсеп-исәеп киткәндәй булды.

— Ишләреннән каласын ич инде, мәргән,— диде кыз, кайгыртучанлык күрсәтеп. Кызның тавышы Гали олан йөрәгенә сары май булып төште. Аның кызны тагын-тагын сөйләштерәсе килде.

— Рәхмәт, сезне юлга чыгаручыга, рәхмәт кичү күрсәтүчегә, меңмең рәхмәт ат тотучыңа. Нигә дип сорамагыз. Ул елга уртасында туктап калмаса, мин сезне күрмәгән булыр идем. Бик ихтимал ич?

Оланның бу сүзләреннән арбага менеп утырган һәм дилбегәсен кулына алган ат тотучы да туктап калды, ә туташ исә тәмам әсәрләнде, алар икесе дә ни әйтергә дә белми һаман кузгалып китмәгән, ишләреннән калган яшь азатка карап тора башладылар. Үз акылындамы бу егет, ни булды мәргәнгә?

— Ат тотучыгызга мин менә бу кылычымны бүләк итәм. Ни өчен дип сорамагыз. Әйтмим. Кылыч минеке. Бу — бер. Икенчедән, ат тотучыгыз булмаса, мин сезне очратмаган булыр идем. Изге жан ул. Изгеләргә кылыч түгел, жан да бирерсең.

Менә сиңа мә! Ничек сөйләшә мыек та типмәгән үсмер азат. Балигъ егетләрчә кылана. Күр инде моны, чынлап та кылычын ычкындырып, ат тотучыга бирде. Тегесе дә ала бит әле. Йөзбаш ни әйтер, каеш белән каезласа?

— Ташбулат агай, ярамас бит. Күр әнә баһадиры борылып та килә түгелме!

— Кылыч минеке, телим бүләк итәм, телим болгап атам. Баһадирым килсә дә, бер сүз дә әйтмәс, әйтергә хакы юк.

Йә хода, ни тамаша тәкәббер сөйләшә тагын үзе. Ходаем, ул бу гына булмасын тагын инде үзенә.

— Гали олан,— дип килеп җиткән йөзбаш.— Баян баһадир сезнең арттан җибәрде. Әнә үзе дә килә инде.

Тузан туздырып, җан фәрман чаба-чаба Баян баһадир килеп җитте. Килеп җитте дә атын тыеп, арба янына туктады, күзе шундагы туташка төште. Сәер, баһадирның кырыс чырайлы йөзе, кызны күрүгә, елмаюга җәелде дә китте.

— Ат тотучының колагын борырга кирәк,— диде баһадир.— Шушындый кызны су уртасында калдыра язган.

— Мин аны мактап торам әле, баһадир. Хәтта әнә үзенә кылычым бүләк иттем. Ни өченме? Кайчан очратыр идем бу кызны кичүгә атын кертеп батырмаган булса ышбу адәм!

— Азатыгыз шул хәтле телгә оста, баһадир,— диде ат тотучы.— Ни, ярамаса, мин аңа кылычын кире кайтарам.

— Кылычын кире алса, мин аны үзем дә мактамас идем, ага кеше.— Шулай диде дә Баян баһадир, туташка мөрәҗәгать итте: — Барыр юлың, торыр илең кай тарафта?

«Никадәр гүзәллек үзендә, хан оныгы белә кемгә гашыйк булырга. Әй, үтәсе, үтәсе әле ул гашыйк булулар. Гали олан. Мин дә синең кебек чакларда күргән берсен алиһәгә санап, үлепләр гашыйк була торган идем. Күзләрен генә күр әле син аның, гүя бау белән тартып китерә үзеңне. Нур, нур балкый, кояш чыктымыни, үзе-күзе, елмаюы кояшка тиңмени!»

— Баһадир, синең тутый кошны күргәнең бармы? — дип сорады Гали олан.

— Юк, батырым. Ә менә бу кызны күргәч, тутыйны күрдем, дип әйтәчәкмен.

— Мин дә, баһадир.

— Баһадир,— диде ат тотучы.— Кызның аты Зөләйхадыр, кайтыр юлыбыз Ибраһим каласыдыр. Әйтсәм әйтим инде, баһадир, Зөләйханы сез түгел, менә бу батыр кызыксындыра.

— Алаймы,— диде Баян баһадир һәм атын камчылый-камчылый ничек чаптырып килгән булса, шулай чаба-чаба китеп тә барды.

— Ә яшь мәргән нигә китми? — диде Зөләйха һәм нәзакәтле итеп елмайды.

— Атаң-анаң исемен ишетмичә, яшь мәргән беркая да китмәс, Зөләйха,— диде Гали олан.

— Аннан сорама син аны, мәргән, миннән сора. Атасы кала бие Ягкубтыр. Калганын үзең табарсың.

— Алай булгач, мине дә белеп калсын инде Зөләйха туташ. Атым Галидер, йортым Бөек Каладыр, баруым яңа кала нигезен күрергәдер. Кем белә, бәлкем, бүген сезнең алда торган яшь мәргән шул каланың әмире булыр.

— Бирсен ходай, әмирләр дә пәйгамбәрләр түгел, бирсен ходай,— диде ат тотучы агай.

— Ә мин бабаларымнан, Чирмешәннән утырмадан кайтып киләм,— диде кыз ирәя төшеп.

Кыз елмайды һәм Гали олан өчен гүя янә күк капусы ачылды. Гел шулай елмаеп торсын иде, кадер кичәсендә күк капусы ачыла, диләр, әгәр дә мәгәр шул мәлдә теләгең әйтеп өлгерсәң, хода сиңа барысын да бирә икән, бар булган теләгеңә ирештерә. Ат тотучы агай әкрен генә кузгалып китте, Гали олан арба читенә тотынып бара башлады. Кызның кыйгач кашлары өскә сикерде, озын керфекләре җилпенеп алды, елмаюыннан шушындый якты булып китте ки, Гали олан ни кылырга белми атына камчы белән сукты, берара чаптырып барып, кире әйләнеп килде.

Ат тотучы атын атлатып кына бара, хан оныгы бүләк иткән кылыч тез өстендә ята, ул кылычны сыйпый, авыз эченнән генә нидер укый.

— Зөләйха, күзләрегез сезнең кояштыр, йөзләрегез тулган айдыр. Керфекләрегездән нурлар тамадыр, иреннәрегездән баллар агадыр. Әй, нурлы йөзең төшләремдә күрсә идем, сәнең исмең әйтә-әйтә үлсә идем...

— Абау, ни сөйлисең, мәргән, шигырь бит бу!

— Гүзәллегең күреп, гакылым җуйдым, һуштан язып, егылып төшсәм, алырсыңмы, сылуым, арбаңа...

— Җыру бит бу! Менә әкәмәт!— диде кыз яшел ефәк яулык белән күзләрен генә калдырып каплаган җирдән, йөзен ачып җибәрде, рәхәтләнеп елмайды, ул да түгел, башыннан яулыгын сыдырып төшерде, сыңар толымын күкрәгенә алды. Чәч толымына тезгән көмеш тәңкәләр зеңләп куйдылар. Туташның бу хәрәкәтендә, мин сине кабул иттем, дигән кебегрәк мәгънә ята иде.

Алга китеп барган хан сәфәрчеләре арасында Гали олан өчен иң әүвәл кәтиб Хафиз борчыла башлады.

— Вәзир, нигә баһадир Баян Гали оланга ирек бирә? Житмәсә хан оныгы. Килешмәгәнне кылана түгелме? Вәзир Исхак дим, нигә дәшмисен?

— Куып житәр ул безне, Баян баһадир үзе дә ашыкмый кебек.

«Бәлкем аның соңгы тапкыр кызлар белән очрашуыдыр. Кеше якты истәлек белән теге дөньяга китәргә тиеш»,— дип уйлады вәзир. Ни каты бәгырьле булса да, ул хан оныкларын кызгана иде. Әле жирәбәнең кайсы оланга чыгасын белми, илла бер нәрсәне ачык белә: ике оланның берсе Бөек Калага әйләнеп кайтмас, берсе яңа кала нигезенә ятып калыр. Вәзир ханы боерыгын карусыз үтәр. Шунсыз аңа Бөек Калага әйләнеп кайтасы да түгел. Кем белә, бәлкем анардан юлда ук котылырга дип әмер биргәндер мәкерле хан. Тикмәгә генә хан Саксин казыйны алар белән жибәрмәде, кирәк табалар икән, Исхакны юлда ук хөкем итәчәкләр — йә агулы елан чагар хан оныгын, йә аттан егылыр. Кара Пулатта казый вазифасын үтәүче Саксин кирәк дип таба икән, хәйләсен табар, аның кулыннан бик күп кешеләр үткән. Алай да Исхакны тиз генә юк итә алмас, ул әле Кара Пулат казые белән көрәшеп карар. Барысы да хода кулында. Без юлда, юлда исә урман — колак, кыр — күз. Сак бул, вәзир Исхак. Ахмак Сәлим ханга ахмак тәкъдим бирдең, инде чарасыздан кылынган хатадан чыгу жаен кара. Алай да оланнар кызганыч. Яңа күзләре ачылып килгән чаклары, кызлар күрү белән күзләре яна торган мәлләре... Баян баһадир азатлары арасында да хан шымчылары булуы бик ихтимал. Шиге төшкән кешегә өчәр катлы шымчы куя белә Сәлим хан. Хәер, кемне гаепли ала вәзир, үзе үк шулай тикшерергә өйрәтте ханны. Хәзер әнә кайтыр, үктәй үзенә үк төшә бу бәла. Вәзир кирмәннән чыкканда ук сизенде, аны күзәтәләр. Белмәсә бу хәлне бер кәтиб Хафиз белмидер. Аңа ике дөнья бер моржа. Хәер, алай дип әйтеп булмый, кәтиб ханнан күп тапкыр белекле, акыллы һәм төплерәк фикер йөртә, кодрәтендә булса, вәзир әнә кемне утыртыр иде хан тәхетенә. Юк, берәү дә алай итә алмый, ханнар алла тарафыннан тәхеткә утыртылалар, моны шәех Игәнәй шулай ди, мәгәр Исхак белә: шәех Игәнәй тарафыннан сайлана һәм тәхеткә утыртыла ханнар. Болгарга бу бозык гадәт Айдар хан заманыннан ук керә, ислам дине белән бергә килә. Бу гадәтне бозарга яки сүтәргә һичкемнең хакы юктыр. Имеш, хан аллаһы тәгалә тарафыннан жибәрелә. Йә хода, никадәр томаналык бу халыкта! Ханнар алла тарафыннан жибәрелә буламы?! Халык моның асылын беләме? Белүчеләр дә бардыр. Илла дәшмиләр. Әйе, шәех жүләр түгел, хәер, епископ Габбас та шул ук жырны жырлый — ханнар, кенәзләр алла тарафыннан жибәрелә. Хак анысы, аллаһы тәгалә жибәргән ханнар вә кенәзләр арасында гайре табигый акыллылары да буладыр, әмма күпме яши инде ышбу дөньяда Исхак, андый ханны вә кенәзне күргәне булмады. Хәерле булсын, күрми китеп тә баруы ихтимал. Сәлим хан оныкларының берсеннән ничек котылырга белми иде, вәзир Исхак коткарды. Киләсе ханнарны кем коткарыр? Шәех Игәнәйме? Аның максаты бердер — карусыз буйсындыру, алла исеме белән ул теләсә кемне алдына тезләндерә ала. Менә кемдә куәт, менә кемдә кешелек язмышы — Болгар дәүләте язмышы! Әйе, кемнәр генә утырмый Болгар тәхетендә. Берәүләре дәүләтне ныгыта, икенчеләре тарата, өченчеләре ата-бабалары жыйган байлыкны чит-ятларга өләшә, дүртенчеләре көрәш-куләп белән тынышмый, бишенчеләре хатын-кыз артыннан куа — хатыннары күп, димәк, дәрәжәсе дә зурдыр. Олуг Мөхәммәт, әйтик, бер көтү хатын тота, дип әйтәләр. Бер көтү хатын тоткан кешедә нинди дәүләт кайгысы калсын ди инде! Болгарда иң куәтле, иң акыллы хан Бөек Болгарга нигез салучы Кубрат буладыр, әлбәттә. Хәзәрләр белән орышта һәлак булса да, аның исеме еракларга яңгырап тора. Шуннан дошманнарның кыс-

рыклавына чыдый алмыйча. Кубрат ханның беренче угланы Батбай хәзәр каганына баш иеп бара, икенче угланы Кодрак Иделнең өске якларына көчеп китәргә мәҗбүр була, өченче угланы Аспарух Дунай буйларына юнәлә. Үз ыруы белән Иделнең өске ягына күчеп килгән Кодрак хан, мондагы төрки кардәшләр белән кушылып һәм ису, вису, угыр халыклары белән тыгыз элемтәгә кереп, яңа дәүләткә нигез сала. Ахыр ул да дөнья куя. Аны Ишкул хан алыштыра, ниһаять, тәхеткә Болгар атлы хан утыра, аннары Туки хан. Туки ханны Болгар тәхетендә ислам динен кабул иткән Айдар хан алыштыра. Айдар хан Болгар тәхетен өянәкле кызын дәвалаган гарәп табибе Хәнҗәлгә калдыра, тик Хәнҗәл хан озак яшәми, Болгарның салкын һавасы ярамыймы, аллаһы тәгалә аны да үз янына ала. Зәбир хан, аннары Болгар тәхетенә Мөхәммәтәмин хан утыра. Мөхәммәтәминнән соң Болгар белән Шелке хан идарә итеп ала, ул үлгәч, тәхеткә Багдад илчесе Ибне Фазланны кабул иткән Алмыш хан менә. Аны исә Микаил хан, Микаилны Нәсер, Нәсер ханны Талиб хан, ары китеп Болгар тәхетендә Мәэмүн хан, Шәмсун хан, Хәйдәр хан, Мөхәммәт хан, Сәгыйт хан, Бараҗ хан, ахыр килеп калалар төзүче, Болгарны мөстәкыйльлеккә алып чыккан, урыс кенәзе Юрий Долгорукның замандашы Ибраһим хан утыра тәхеткә, аны тәрбиягә алган угланы Солтан Морат алыштыра, ниһаять, Болгар тәхетенә Ибраһим ханның тәрбиягә алган икенче угланы Сәлим хан менә. Сәлим ханнан соң Болгар тәхетенә кем утырыр? Монысын бер хода үзе белә иде. Сәлим ханның угланнары тәхеткә утырмады, анысы хәл ителде — икесе ике кала әмирләредер. Димәк, каладыр ике оныкның берсе. Оныкларның берсе яңа кала нигезендә ятып калыр. Кыргыйлыктыр бу хәл? Бик мөмкин. Киләчәк буын безнең бу хәлдән көләр, мәгәр замана хикмәтләре дип кичерер. Ләкин вәзир Исхак ахмак Сәлимгә ярамаган киңәш бирүен берәү дә белмәс. Сәлим хан суга батып барган заттай, саламга тотынып котылырга теләп, аның киңәшенә ябышты. Бердәнбер юанычы бар вәзирнең: бу чараны бер ул гына уйлап тапмаган, ата-бабалардан ук шулай килгән. Яңа салынасы кала мәңге утырсын, озын гомерле, куәтле, нык булсын өчен, борын-борын заманнан ук кешеләр кала нигезенә бала күмгәннәр. Иң хәтәре шул иде: бу йоланы хәзер бер халык та тотмый, ә менә Сәлим хан моңа ике куллап ябышты.

Ахмак, тиле, җүләр беткән!

Тукта, җүләр-җүләр дим дә, Сәлим хан моны юри эшләгән булса? Әйтик, вәзиреннән котылу өчен!? Бик җайлы ич! Вәзир Исхак оныкларның берсен кала нигезенә корбан итә, ә хан вәзирнең башын кистерә? Чөнки... Әйе, чөнкиме? Чөнки шәригать кушмаган эш кылган. Гафиллек бу, томаналык!

Менә сиңа мә, менә сиңа ахмак хан?!. Хәйләкәр, хәйләкәр Сәлим хан. Әйтәм аны, җүләр янында җүләр, акыллы янында акыллы булып кылана, гәрчә тегесен дә, монысын да бик үк яшереп бетерә алмаса да? Һай, бу дөньяны, бу адәм баласын, никадәр мәкер йөртә үзендә!

Вәзир артына борылып карады, олан Гали бик ерак калган иде.

— Йөзбаш, алып кил оланны! — дип боерды ул катгый төстә. Һәм вәзир кинәт кенә үзендә тәүге куәте кузгалуын тойды. Әйе, башта ул алышып карар, күз күрер, кем кемне алдырыр.

Йөзбаш әче итеп сызгырып җибәрде, бу сызгыруга, оланның аты арба яныннан шундаен итеп эздереп алып китте ки, Гали чак кына иярдән очып төшеп калмады. Өйрәтелгән ат Галине күз ачып йомганчы төп төркемгә китереп тә җиткерде.

— Дулаттың бит атыңны, олан. Тартма тезгенең, иркенгә җибәр, тик чапсын, туктар бер! — дип кычкыручылар, киңәш бирүчеләр табылды, күбесе эчләрен тотып көлешә башладылар. Мәзәк иде ат өстендә туып, ат өстендә үләргә җыенган азатларга.

Гали олан чынлап та беренче мәлдә курка калган иде, әмма

азатларның киңәшләрен тотып, тезгенне бушатуга, ат бертын чабып барды да кире борылды.

— Дуласа да тыйдым үзен,— дигән булды, йөзе ап-ак булса да куркуын сиздермәскә тырышып Гали.

— Татлыдыр туташның телләре, юкса атың дуламас иде, көнләде ул сине кыздан,— диде артыннан килеп җиткән йөзбаш.

— Баһадир,— диде Гали куркуы үтүгә,— тагын бер әйләнеп килим әле... Килим инде, мин сезне күздән яздырмам.

— Бар инде, бар,— диде Баян баһадир үзалдына көлемсерәп, туташның гүзәллеге аның да күз алдында иде.

Гали олан тагын атын камчылый-камчылый кире чапты. Шул чак Чулман күренде. Азатларның берсе җыр башлады:

Зәңгәр күгең, зәңгәр суың, Иделкәем,
Ярсу күңелләрне басадыр,
Балбалларың торган тугайларың
Моңсу күңелләрне тартадыр...

Ибраһим каласына житәрәк, хан сәфәрчеләре юлын кара халык урамына кайтып килүче көтү бүлде. Сыерларның имчәкләре тулышкан, атлаган саен сөт сибелә. Көнозын эссе кояш астында көтү көткән көтүчеләр елангай озын чыбыркыларын яман итеп шартлатып ала. Иллә атлары бер дә өшәнгән кебек түгел иде.

— Алышабызмы атларны, көтүче?— дип шаяртып алды бер азат, мәгәр көтүче аңа хәтта әйләнеп тә карамады.

Кала читендәге урам башына килеп керүгә, вәзир юлчыларга туктарга боерды. Әчке кала капкалары ябык, асма күпер күтәрелгән иде. Ахшам намазы вакыты, намаз бетмичә, капкаларны ачмаслар— тәртип шундый.

Хафиз еш кына Гали ягына күз төшергәләде. Ул әлегә ни өчен кала нигезен карарга баруын да белми иде. Хан кушты, димәк, шулай кирәк. Исхак та еш кына Галигә карап тора. Нигә булыр? Булат гел Баян баһадир янында, гәпләшәләр, көлешәләр. Ә менә Гали бер читтә, берәү белән дә сөйләшми дә, аралашмый да. Борчулы, боек, йомылып калган. Әллә соң бер-бер нәрсә сизенәме? Хан аны булган хәлне тарихка язып калдырырга дип җибәрде, ә менә оланнар нигә? Әйдә, хан аларны да җибәрсен, ди, кайсыдыр кайчандыр булачак калада әмир торып калуы бар. Әйдә, шулай да булсын. Тик нигә вәзир Исхак нәкъ менә Гали оланга сәер итеп карап-карап куя? Күр әле бу Кара Пулат козгыны Саксин казыйны, гел минем янда. Ни кирәк икән үзенә? Юк инде, кәтиб Хафиз сиңа, Кара Пулат козгыны, авыз ачып сүз катмастыр. Синең белән сөйләшәсем килеп тормый әле. Булат олан туганыннан көнли бугай, ул да тора да Гали ягына карап ала. Көнли, әлбәттә. Чәчкә бәйрәмендәге көрәштә Гали батыр чыкты, ә бабалары Сәлим хан Болгар тәхетен аңа, ягъни җиңүче Галигә вәгъдә итте, андый-мондый җирдә түгел, бөтен халык алдында. Булат оланда тәхет өчен көрәш ялкыны. Моны сукыр булмаган һәр кеше күрә булса кирәк, дип уйлады кәтиб Хафиз.

Бу мәлдә Гали бөтенләй уйламый, хан оныгының күз алдыннан әле булса юлда очраткан Зөләйха иде. Галинең чын хәлләтен кәтиб Хафиз күрә алмады, чөнки гашыйк булу аның өчен ят нәрсә иде.

Бары тик вәзир генә Галинең хәлен бераз аңлый иде. Ул белә иде егет чактагы гашыйк булуның кадерен. Ул янә бер нәрсәне яхшы белә иде: кызлар бар яктан да иртәрәк өлгерә. Туташка, мөгаен, унҗиде яшь тулып киләдер, ә хан оныгы әле нибарысы ундүрт язны күрде. Башта кызкай оланны яшьсенде, баласынды, аннары... Ир-ат йөрәк белән гашыйк була шул. Кыз шуны аңлады бугай. Хәер, хатын-кызны аңлаган кеше бәхетсездер ул. Серле булып кала алсалар гына гүзәл алар, серле булганда гына күңелне тартып, җилкендереп торалар. Без, ирләр, хаталанабыз, аларны алиһә итәбез, ә алар бер дә алиһә түгелләр, җир

кешеләре, ирләр кебек үк дөнья көтәләр, бары тик уй-хыяллары гына башка — мамык кебек җиңел, җил чыкса очып китәргә торыр, ирләр уйхыялы исә җирдә яткан таш сыман, тузан эчендә аунаса ауный, очып, күтәрелеп китәргә ашыкмый.

Асылма күпер төшерелде, капкалар ачылды, хан сәфәрчеләре эчке калага керделәр. Кирмән каравылбашы вәзир Исхак белән Баян баһадирга баш ия-ия, түр яктагы өйләрнең берсенә узарга юл күрсәтүче бирде, башкаларны да бик тиз таратып бетерде. Каравылбаш азатлары хан оныкларын атларыннан гына күтәреп алмадылар.

Өйгә урнашуга, Гали вәзир Исхакны түгел, Баян баһадирны эзләп китте. Баһадирны тапкач, ул ояла-тартына гына кала бие Ягкубны күрергә теләге барлыгы хакында әйтте. Баян баһадир вәзир белән киңәшеп килде, шуннан соң гына Гали оланны озатырга ике азат биреп, бик соңга калмаска кушып, чыгарып җибәрде.

* * *

Кала бие Ягкуб үзенә хан оныгының килеп керүен һич тә көтмәгән иде, күрәсең, өй турысына хан азатлары килеп туктагач, кабаланып капкасын ачарга тотынды.

— Рәхим итегез, кунаклар. Үтегез, үт! Атларыгызны әнә теге баганага бәйләгез. Азатлар, сез, кадерлеләрем, әнә шул тал астындагы өйгә керерсез, анда сезне ашатырлар, сыйларлар. Гали олан, ә сез, түр өйгә рәхим итегез!

Ибраһим каласының бие Ягкубны Гали олан белми, хәер, аңа аны белү дә кирәкми иде, иң мөһиме, ул Зөләйханың атасы.

— Саумысыз, Ягкуб ага, исән-сау торасызмы! — диде Гали олан атыннан төшүгә, тезгенен йорт иясенә тоттырып.

— Ай син аны, саумы олан, исән-сау килеп җиттегезме? Сөйләдесөйләде Зөләйха, бәладән дә коткаргансыз икән үзләрен. Ат тотучымның тәмам түбәсе күккә тигән — кылыч бүләк иткәнсез икән. Әйем, үт әйдә, үт, олан,— дип, кисәк кенә якын итеп дәшә башлады Ягкуб би.

Кала бие Ягкуб өйне юан-юан бүрәнәләрдән салган, тәрәзәләрен зур, болдырны киң итеп эшләткән. Болдырга менгәч, Гали олан Чулман ягына бакты — хозурлык иде биредән караганда — күреп туймаслык манзара. Елганың аръягында күзәтү манарасы, шул тирәдә үк ат көтүе утлый, аннан арырак зур булмаган авыл өйләре, авылның нәкъ уртасында манарасын күккә чөеп мәчет утыра иде.

Ягкуб би хан оныгы Галинең үзенә ни өчен килеп керүен белмәде һәм ул бу хакта аңардан сорашмады да. Гадәт буенча, хан нәселеннән өеңә кеше керә икән, бу йортка бәрәкәт явачак, имеш. Нинди бәрәкәт — ул хакта берәү дә белми, мөһиме ул түгел, мөһиме — бүген Ягкуб би өенә хан оныгының килеп керүе иде. Бәрәкәте, нинди сурәттә булса да, бер килер. Бу хәлгә гәрчә каушабрак калса да, Ягкуб би Гали оланның ни өчен нәкъ менә үзләренә килеп керүен бераз чамалый иде. Олан үсмер егет кеше, юлда Зөләйханы очраткан... Шул инде, очраткач, бик ихтимал, гашыйк булгандыр. Зөләйха кызына хан оныклары да гашыйк булмаслык түгел, гүзәлләрнең гүзәле! Аннары буй җиткереп килгән кызны башлы-күзле итсәң дә ярап куяр иде. Хак анысы, хан оныгы яшьрәк күренә, ахыр чиктә эш андамыни, эш Гали оланга кызы Зөләйханың ошавында. Кызның гәүдә-сынында тулымлык, ир-ат күңелен тартып тора торган мөлаемлек, күз-йөзендә тел белән әйтеп бетермәслек ягымлылык күреп, Ягкуб би әлләниләр өмет итеп ята иде. Һәм менә бар икәнсең әле син, ходам, күрдең — хан нәселеннән адәмең җибәрдең.

Ул арада болдырга Зөләйха үзе килеп чыкты һәм исәнләшеп өйгә кереп китте.

— Килеп життек, Зөләйха,— диде аңа Гали олан һәм кыз артыннан иярде. Бу хәлгә Ягкуб би бераз каушый калды.

— Зөләйха кызым,— дип иярде ул Гали оланга.— Табын хәстәрләсәгез иде. Анаң кая, кая урала? Керсен әле бире! Бәй, шулай дими, хан оныгы кунак килде, хан оныгы, балакай.

— Хан оныгы?— дип гаҗәпләнгәндәй итте Зөләйха.— Рәхим итегез, хан оныгы, түрдән узыгыз! Мин хәзер...

Гали түргә узды, идәнгә ташлаган атлас мендәргә кырын төште һәм кыланышы белән Ягкуб бине янә бер шаккатырды. «Күр әле моны, кыланышын гына күр, әй, хан токымы хан токымы инде, нигә баш ватам»,— дип уйлады һәм үзе дә Гали янына кырын төште.

— Ягкуб ага, калада кызлар өчен мәдрәсәләр бармы?

— Юк, илхан,— диде Ягкуб би борынгы хан угланнарын шулай дәшүне исенә төшереп.— Ул тубалбашларга хода тарафыннан бирелгән акыл да артыграк дип уйлыйм әле мин.

Бу юлы Гали олан гаҗәпләнде һәм туп-туры ата кешенең күзләренә карады, шаяртмыймы, янәсе. Мәгәр күрде, сизде, би сизелер-сизелмәс кенә елмая, аны яшьсенә, баласыта. Әлбәттә, хатын-кызлар мәдрәсәсе хакында үзе дә бераз шыттырды шыттыруын, ак киез җәйгән идәнгә атлас мендәр өстенә кырын төшүе белән дә арттырып җибәрде, иллә хан оныгы ла ул, ә би бары тик кала башлыгы. Гали кәтиб Хафиздан алган белемен кулланырга булды.

— Ягкуб ага, дөньяда нәрсәне төшенүе кешегә бик авыр бирелә?

— Их, илхан, илхан, яшәп-яшәп тә төшенеп җитмәгән нәмәрсәләр күп инде ул. Әйтик, миңа үз-үземне табу бик тә авыр булды.

— Иң җиңеле ни булды?

— Кешегә киңәш бирүдер, илхан. Киңәш бирү һәрвакыт җиңел.

— Кайчан кеше бәхетне тоя?

— Кайчан дип, сәламәт тәндә сәламәт акыл булыр, дигәннәр картлар. Сәламәт тәнле кеше иң бәхетле кешедер, илхан. Сәламәт кешенең иң әүвәл күңеле изгедә булыр, уе-хыялы яктыга омтылыр, сәламәт тәнле кеше тәрбиягә дә тиз бирелүчәндер, бәхет әнә шундадыр, илхан.

Юк, кала бие белекле кеше, Гали моңа шундук инанды. Димәк, атасына охшаса, кызы Зөләйха да акыллы булырга тиеш. Ә чибәрлек, дип әйтә кәтиб Хафиз, әнә шул сәламәт тәннән киләдер. Гүзәллек һәм гакыллык барча хатын-кызга да бирелми, ди кәтиб Хафиз, бик сирәк була гүзәл дә, гакыллы да булган хатын-кыз, ди. Ә менә мин шундыйны очраттым — Зөләйха акыллы да, чибәр дә.

— Минем укытучым башкачарак уйлый хатын-кыз хакында, Ягкуб ага. Ул әйтә: хатын-кыз күңеле языклы да, языксыз да, ди. Ягъни изгегә — изге, гөнаһлыга — гөнаһлы, ди.

«Менә сиңа мә, олан гына димәссең үзен. Фикер сөрешен генә кара син аның»,— дип, торган саен гаҗәпләнә барды Ягкуб би.

— Хаталандым, ахры, Гали. Шул хатын-кызның йөзенә пәрәнҗә яптырмас өчен болгар төркиләре өч йөз елга якын ислам динен кабул итми торалар. Хатын-кыздан башка булгандыр дип уйлыйсыңмы ул хәлне?! Өргәнечкә ислам дине килүгә биш былтыр.

— Хатын-кызның нурлы йөзен ирләргә карарга дип яраткан ходай, ди укытучым, Ягкуб би.

— Анысын бер хода үзе беләдер инде, илхан. Кайчак миңа, хатын-кызны шайтан үзе яраткандыр, дигән уй килә. Безнең ишене котыртырга дисәң үзләрен. Йә хода, тикмәгә генә чәче озын, акылы кыска, димиләрдер шул...— Ягкуб би Гали оланга күз төшереп алды да, хан оныгының кәефе кырылуын күреп, тизрәк хатасын төзәтергә керeште.— Безнең тархан алар хакында: акылны хатын-кыздан, һөнәрне ир-аттан ал, ди. Хатын-кыз арасында да акыллылары бар инде ул. Әнә минем Зөләйхам укый-язарга үзлегеннән өйрәнде дияргә була. Хәзер әнә китаплар күчерә, яттан белгәне дә искитмәле.

Шул вакыт, гомере озын булгыры, Зөләйха килеп керде.

— Табын әзер, атам, рәхим итегез, түр өйгә узыгыз.

— Мин тәхеткә утыруым белән иң әүвәл хатын-кызлар өчен мәктәпләр ачтырачакмын, Ягкуб ага,— диде, кыз да ишетсен дип булса кирәк Гали.

— Бирсен ходай, илхан, авызыңа бал да май. Ә хәзер, әйдә, чәй эчеп алыйк, әллә нигә тамак кибеп киткән кебек булды.

Ягкуб би хан онычының мактануын килештереп бетермәде, алай да дәшмәде, әйдә, мактана бирсен, аның кебек чакта кем бераз һаваланмаган да эреләнмәгән. Картның яшәрәсе килә, үсмернең тизрәк картаясы килә, шул гына. Үтәр ул, үтәр. Бер аңардан гына калмаган.

Түр өйдә мул итеп табын хәстәрләнгән, кунак оланны Ягкуб бинең хатыны каршы алды, тыйнак кына, авыз читен яулык очы белән каплый төшеп кенә. Галине түрдән узып утырырга кыстады. Гали олан утыргач кына ул:

— Исәнме-саумы, Гали олан! Исән-сау килеп җиттегезме?!. Рәхмәт инде бәлага тарыган Зөләйхабызны коткаргансыз икән. Ходай изгелегегезне икеләтә кайтарсын. Ата-анаң исән-имин калдыларммы? Энең дә бар икән. Ул ни хәлдә? Сарай мәктәбенә укырга киләчәкме? Шулайдыр, шулайдыр, хан онычы бит.

«Энем Җәббар хакында азатлардан сорап белгән булырга тиешләр»,— дип уйлады Гали олан, би хатынының бар нәрсәдән дә хәбәрдар булуына аптырый калып.

— Зөләйха кызымны әйтәм, утырмага барам-барам дип йөдәтеп бетерде. Баргач әнә кайтам дип хат артыннан хат җибәреп торды. Юкса бабаларында да күңелле дә бит. Туган якларга җитәме. Ил-ярыңның чыпчыгы да сандугач булып сайрар, ди бит.

— Анасы дим, син кунакка ашарга бирмисең түгелме? Җитеш әле, Гали олан, җитеш, җитеш, менә бу кымызны да тотып ал. Син, илхан, бик тыңлама ул хатын-кызны. Син аңа дөнья хакында сөйлисең, ә ул үз зарын сайрый. Беркөнне шулай күрше Габдулла хатыны кергән иде, өч тиенлек сүзләре булмагандыр, ярты көн гомерләрен авызга-авыз куеп уздырдылар. Әйтсәң — койтысың, әйтмәсәң — ничек түзмәк кирәк...

Би хатыны өстендә бөрмәле итәкле куе яшел төстәге күлмәк, башында калфак, аякларында сафьян читекләр, түшенә көмеш тәңкәләр тезгән күкрәкчә таккан, кулларында көмеш беләзекләр, бармакларында алтын йөзекләр.

— Зөләйха кызым, нигә дәшми генә утырасың? Син дә булыш анаңа,— диде Ягкуб ага көлемсерәп.

— Атасы, аягыңа басмагандырмын бит? Шулай булгач, әйтер сүзең кунак киткәч әйтерсең...

— Һәй, тик тор әле син, анасы. Әнә Зөләйха кызыңа сүз бир. Утырмадан кайтып төште, сөйләр хәбәрләре бардыр.

Атасы шулай дигәч, Зөләйха кызарынып чыкты. Кыз өстендә утырма якалы зәңгәр күлмәк, күлмәк өстеннән күз явын алырлык кызыл ефәк камзул кигән, эре гәүһәр ташлардан тезгән муенсасы, башындагы энҗеле калфагы, кулларындагы беләзекләре — күреп туймаслык итә иде кызны. Кызыл читекләрен итәк астынарак җыеп утырган да тиенкы гына әле чәк-чәккә, әле йөзем җимешенә үреләә, үрелгән саен җиң эченнән ап-ак мәрмәрдәй беләге күренеп китә. Гали оланның юк-юк та кызның әнә шул ап-ак мәрмәрдәй беләгенә күзе төшә иде.

— Зөләйха туташ, син сарай мәктәбендә укып идеңме?

— Белмим,— диде кыз озын керфекләрен еш-еш каккалап, Галинең күзләренә карап.— Анда соң кызларны да алалармыни?

— Алмыйлар. Ләкин мин алдырыр идем.

— Гали илхан, табиб Хәсәнне Өргәнечкә куган икән, диделәр. Хак булдымы шул хәбәр?

— Кем кусын аны?

— Әйтик, бабаң,— диде Ягкуб би.— Ханнар яратмаган кешеләрен элек-электән чит җирләргә китәргә мәҗбүр иткәннәр.

— Табиб Хәсән мөгаллимем иде, Ягкуб ага. Аны Болгардан бирәү дә кумады. Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт каты авырып киткән, бабамнан табибе Хәсәнне җибәрүен үтенгән иде.

— Шулай дип уйлаган идем дә аны. Табиб Таҗетдинне дә шулай дип соратып алган иде ул Олуг Мөхәммәт. Авырмый да, чирләми дә, хәйләле, иленә акыл ияләрен җыя. Акыл иясе ни ул? Акыл иясе — ил дәрәҗәсе, илхан.

Бу хәтлесе Гали өчен бөтенләй яңалык иде, әмма ул бигә сер бирмәскә тырышты, сарайда булган хәлләрдән яхшы хәбәрдарлыгын сиздерергә теләп:

— Бабам ялгышмас, бабам барысын да белеп эшли. Миңа ул бөтен халык алдында тәхетен вәгъдә итте, тәхеткә утыруга, мөгаллимем табиб Хәсәнне мин илгә кайтарачакмынн,— диде.

— Җитешеп утыр әле, Гали олан,— дип кыстый башлады Ягкуб би артыгын сөйләп ташлавыннан курка калып. Хан оныгы бабасына кайтып сөйләсә, Ягкубның башыннан сыйпамаслар, хатын белән ханга ышанма, диләр.

Гали олан үзен ышбу гаилә алдында белекле итеп күрсәтергә тырышты һәм ул моңа ниндидер дәрәҗәдә ирешге дә бугай. Илләр дөньяны шактый гизгән, Ибраһим каласы бие дәрәҗәсенә ирешкән Ягкуб аның сүзләренә ышанып җитми, моны хан оныгы хуҗаның ирен чите белән елмаеп куюыннан ук аңлады. Ләкин Гали Ягкуб аганың ни турында уйлап утыруын белми иде. Ибраһим каласы бие хан оныгының фикер сөрешенә куанып утыра иде. Гадәттә ханнар бала чактагы хыялларын тормышка ашыручан булалар. Берәүләр бала чакта дөнья илләрен яулау хакында хыяллана, ә берәүләр исә тәхеткә утыруга балачактагы хыялын тормышка ашырырга керешә, янә беришесе исә, илемне чәчкә итәм, дип дәүләт даирәләрен белекле итү хакында хыяллана һәм шул хыялын тормышка ашырырга тырыша. Бу олан да мәктәпләр ача башласа, ил чәчкә атар иде. Кешене хайвани дәрәҗәгә түбән тәгәрәтү чараларының берсе — гафиллектер. Кеше күңеле яшьлек хатирәсе белән бәхетле, яшьлек хатирәсе аның өчен саекмас чишмә, сүнмәс йолдыз, телдән төшмәс җырудыр. Ә Зөләйха балакай илханга олансытып карый. Киәкмәс иде алай, кызым. Ханнар сабый чактан ук кәттә була. Син аны үзең белән тиң күр, балакай, хәтта олылап дәш, ханым, диген. Кем белә, насыйп иткән булып, хан тәхетенә дә утырып куюы бар оланның.

Эчке бер үҗәтлек белән Ягкуб би кызының хан оныгы белән ихластан сөйләшүен теләде.

— Кызым, әллә мәйтәм, кубызда уйнап күрсәтәсеңме илханга?

— Атасы, нишләвең инде бу тагын!— диде хатыны, ир кешенең кыланышын ошатмыйча.

— Ә син, анасы, ирләргә кысылма. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый. Тик кенә утырсаң икән...

Зөләйха ояла-тартына гына кулына кубыз алды һәм сабыр гына бик борынгы көйләрне уйнап җибәрде. Гали өчен ул алмагачына кунып сайраган сандугачка әверелде.

Гашыйк кешегә вакыт сизелми. Бу — хакыйкать. Гашыйк кеше өчен көн дә, төн дә бер. Аның өчен сөйгәне янәшәсендә булса, шул бик җиткән. Моны кем алдан сизде: кызның анасымы, атасымы? Юк, икесе дә бер вакытта сизделәр һәм, сүз куешкандай, эшләребез бар дип, икесе тиң чыгып киттеләр. Икәүдән-икәү генә калгач, Зөләйха ачыла төште. Башта ул кыяр-кыймас кына шагыйрь Баласагунлының, аннары Гаттарның шигырьләренә, бераздан Җәләлетдин Руми әсәрләренә күчте, нәкъ менә шуның белән Гали оланны тәмам әсир итте кыз. Руми аның иң яраткан шагыйрьләреннән берсе иде. Бу хәтлесен үк ышбу кыз-

дан котмәгән иде Гали олан. Гашыйк булу бер хәл, ул, гүя, чирдер, авырыйсың да үтә дә китә, инде кызның акылы сине әсир итсә, котылыйм димә, шул көннән син аның колы. Сылуларда исә җиткән кызмы ул, кияүгә чыгып бала тапкан хатынмы, үзенә генә хас тартыну гадәте булыр. Алардагы галәмәтләр: мөлаемлек, гадилек, оялчанлык, тартыну һәм үзен көчсез итеп күрсәтергә тырышу көчлелек сыйфатыдыр. Ә егетләргә исә һәрчак һавалану, мактану хастыр. Тәүге очракта кыз да, хан оныгы да үз урынында иделәр.

Гали кызга сарайда булган яңалыкларны сөйләде. Тубыкбай баһадирның сарай мәктәбен бетергән энесе Җик Мәргәннең качкын булып йөрүе, Шайтан каласын салган оста Дәүранның хан зинданында утыруы, хан булгач, аны бер көн дә анда тотмаячагы, киресенчә, аңа ирек бирәчәге хакында сайрады. Ул гынамы, оста Дәүран хан кызы Назлыгөлне ярата, дип ишеттерделәр аңа, иң әүвәл ул аларга өйләнешергә рөхсәт бирәчәк. Качкын булып атасы урманнарында йөргән Җик Мәргәнне сарай субашы — гаскәр башлыгы итәчәк. Ә инде үзенә килгәндә, ул Зөләйханы беркайчан да онытмаячак, иң әүвәл ул аларга кайтышлый кереп чыгачак, таш яуса да гәрчә төп сәфәрчеләр башка юлдан китеп, уратыбрак килергә туры килсә дә. Чөнкиме? Әйе, чөнки ул аңа гашыйк, бер күрүдә үк гашыйк!..

Хан оныгы шулай диде дә кызның хуш исләр аңкытып торган кулларын үбәргә керешге. Кыз аңа ирәя төшеп: «Миңа алтын түбәле өй салып бирерсең»,— диган булды. Ибраһим каласы бие Ягкуб кызының укыганы да, ишеткәне дә бар иде: егетләр кызларга ниләр генә вәгъдә кылмый, алар аңа әле һавадагы йолдызны алып бирә, әле күктәге айны, гәрчә бөтен дөнья караңгыда каласын белсәләр дә, хәтта кояшның үзен вәгъдә итәләр. Тик аның сөйгәненә генә якты булсын, тик ул гына бәхетле булсын. Соңгысы, әлбәттә, бөтенләй кеше ышанмастай хәлләр, шуңа да карамастан, егетләр сөйгәннәре өчен һәммәсен дә эшләргә әзер була. Сәере шул иде: кызлар бу хәлгә ышанмасалар да, егетләрнең борчак чәчүен рәхәтләнеп тыңлыйлар!

Ягкуб кызы Зөләйхага унҗиде яшь тулып килсә дә, бала янында бала иде әле. Гали олан кисәктән кыюланып китеп, шулай булырга тиеш дип булса кирәк, кызның алсу битеннән үбәргә үрелде. Нәкъ менә үрелде. Зөләйха исә, хан оныгының буе җитмәсен исәпкә алып, чак кына тез чүккәндәй итте. Беренче үбү икенчесенә коткы: бирде, бу юлы Гали олан кызны кочаклап ук алды. Һәй, шул кызлар кочу мәл...әре, тәүге тапкыр татыганнан соң, төшләргә кереп иза чиктерүләрен белсә икән үсмерләр! Ул хәтлесен әлегә белмәсә дә, Гали олан бөтен тәнендә рәхәт тетрәну тойды, кызның хуш исле сабын белән юганнан соң татлы исләргә күмелгән бит-йөзеннән кат-кат үбүгә, хан оныгының башы әйләнеп киткәндәй булды. Айныса, бусагада кызның атасы басып тора сыман. Бакса, ул чынлап та...

— Әтием,— диде кыз атасын күрүгә.— Гали илхан миңа Руми шигырьләрен сөйләде.

— Илхан,— диде Ягкуб би, кызның сүзләрен ишетмәмешкә сабышып.— Вәзир азатлар җибәргән, сине дәшәләр.

Әйе, тышта эңгер инеп килә, вәзир, күрәсең, борчыла башлагандыр. Гали оланның моннан китәсе килми иде, тик ул вәзиргә буйсынырга тиеш. Килер бер көн, ул тәхеткә утырыр һәм бүген аны чакырып алган вәзир үзе аның каршына ашыгыр.

Гали кызның кулларыннан алды, күзләренә карады, хан оныгының йөрәге янә кайнарланып китте, аның Зөләйхага нидер бик-бик кадерле сүзен әйтәсе килде, әмма авызы кипте, гүя, теле аңкавына ябышты, яңа гына тел очына килгән сүзе идәнгә төшеп китте. Шушы очрашу мәлләрендә ничектер олыгайган сыман тоелган хан оныгы кызга итагатьле генә баш иде — саубуллашты. Зөләйха аңа бер кәлимә сүз әйтә алмады, хәер, нәрсә әйтә алсын ул, көн эчендә үзенә гашыйк булган, шул арада

аның йөрәген яулаган үсмер егет китәргә җыена һәм ул китәр дә, ләкин ул аны гомер-гомер онытмас. Аның да егетләр белән тәүге тапкыр кулга-кул тотынышуы, күкрәгенә сыенган егетнең йөрәк тибешен тыңлавы иде. Кызның озын керфекләре җилпенеп-җилпенеп алды, әйтер сүзе серле күзләрендә, алсуланып киткән гүзәл йөзендә калды.

Гали олан болдырга чыкты, баскыч янына ук килеп баскан атына атланды да, тезгенен кулына алуга, камчысы белән атына сыптырды. Олан астындагы аргамак әллә көтмәгән бу хәлдән, әллә шулай өйрәтелгән булып, арт аякларына басты, тәрәзәдән карап торган кыз «аһ!» итте. Юк, берни дә булмады хан оныгына, ат яңадан үз җаена килде һәм ачык капкага ташланды. Соңгы мәлдә генә күренеп калган сурәт: тәрәзәгә капланган Зөләйханың йөзе иде. Ат капкага таба китүгә, аның йөзендәге куркуы үткән, ул тыйнак-сабыр гына, әмма бераз гаҗәпләнә төшеп елмая.

Хан оныгы кулында гүя ат тезгене түгел, гүзәл туташның йомшак куллары иде.

* * *

Икенче көнне Ибраһим каласын чыгып, шактый җир узгач, Хафиз атын хан оныгы янәшәсендә атлатып китте.

— Кәефең юк кебек, олан?

— Остазым, кыен миңа, бик-бик кыен!

Кәтиб Хафиз нигә дип сорамады, ул бераз чамалый иде, олан нидер сизенә, күңеле тоя, йөрәге. Кичә аңа Баян баһадир оланнарны вәзир алырга кушкан дип әйтте. Вәзир кушу белән генә оныкларын җибәрер иде микән хан? Ай-һай. Ни тели бу оланнардан вәзир Исхак? Нигә алып бара? Кәтиб Хафиз белә иде, вәзир алдында ни кычкырынса да, ахыр чиктә хан барыбер аның киңәшен тотачак. Исхакның сарайда кырыккан кешесе — ханбикә Зөбәрҗәт. Ханбикә белми калдымы оланнарның бирегә китүен, әллә ул да беләме вәзир белән хан арасындагы сөйләшүне? Ни өчен Сәлим хан вәзир белән икәүдән-икәү генә калырга теләде һәм калдылар да? Элек алар бер дә кәтиб Хафиздан ятсынып тормыйлар иде кебек. Димәк, ул чыгып киткәч, хан белән вәзир ни хакындадыр сөйләшеп алганнар? Нигәдер әзерләнә вәзир, нидер кылмакчы. Ни? Кәтиб Хафиз белми иде. Ә инде хан оныгының боегуын, кәефе юклыгын гелән шуңа юрады. Оланның гел балтасы суга төшкән. Үлем көтмидер бит? Йә хода, ни уйлыйм инде тагын! Ә нигә соң Әбүгалисина: «Кеше үләчәген өч көн алдан сизенер»,— дип әйткән? Әллә ул үлем дигәне минем үземә юнәлгәнме, олан шуңа боекмы? Алай дисәң, кемгә хилафлык кылды ул! Юк кебек. Юкмы?! Языксыз яшәргә телисең! Сарайда утырганда хан турында азмы гайбәт ишеттең. Нигә берсен дә үзенә әйтмәдең?!. Һе, гөнаһсыз, имеш. Агач ботаксыз, кеше гөнаһсыз буламы.

Һәр халыкның үз могҗизасы бар. Бу каланы салып Сәлим хан да могҗиза ясамакчы буламы? Чынлап та, Болгарның ние бар? Юктыр. Хәтта дине дә ком сахраларыннан килә. Ни табигатенә, ни гореф-гадәтенә туры килми. Әмма шәех Игәнәй тиресеннән чыгарга житешеп, гарәпләрнең җырга тиң телләре белән Сәлим ханга багышлап һәр ходай бирмеш көнне хәтбә укый. Әйе, румнарның сыннары, яһүдләрнең китаплары, гарәпләрнең дөньяга тараткан диннәре бар. Болгарның ние бар? Сәлим хан, кемнәндер ишетептер, гел бер сүзне кабатларга ярата: «Мөхәммәт пәйгамбәр дин табучы түгел, кануннар чыгаручы гына булган». Әйе, кануннарны адым саен чыгарган Мөхәммәт пәйгамбәр, ә үзе адым саен гөнаһ кылган. Сәлим хан нигәдер бу сүзләрне шәех Игәнәй каршында әйтми. Шәехтән шүрлиме? Кәтиб Хафиз белми иде. Сәлим ханга еш кына епископ Габбас килә, алар икәүдән-икәү генә бик озак сөйләшеп, бәхәсләшеп утыралар. Ни хакында бәхәсләшәләр?

Кәтиб Хафиз янә белми. Бары бераз шәйли иде. Сәлим хан кенәз Боголюб табынган дин белән дә кызыксына. Бәлкем ул Әндеринең рухи коралын белергә телидер. Бик ихтимал ич! Әйе, ни белән көчле Боголюб? Коралы белән түгел, коралны Болгар да оста ясый. Әллә соң әнә шул дине беләнме? Бер тапкыр бәхәсләшкәндә алар янына Хафиз килеп керде. Сәлим хан да, епископ Габбас та аны күрми калдылар. Шунда епископ Габбас әйткән иде: «Хан, аллага тән белән түгел, җан белән ышанырга кирәк»,— дигән иде. Уйланырлык иде епископның бу сүзләреннән. Хафиз да бу хакта бик озак уйланды. Җан белән ышангач, нигә соң бу ике дин әһелләре дә кан коялар, коралларын камилләштерәләр, бөтен максатларын кеше күңелен әсир итәргә юнәлтәләр. Кая монда гаделлек? Кеше һәр дингә тәне белән кереп, аннан җаны белән чыгарга тиеш. Йә хода, әллә ниләр кылә башка. Болай бик күп уйлансаң, акылдан да язарсың, һич булмас димә. Сарайда утыра-утыра бернәрсәгә инанды Хафиз: «Болгар дәүләте кылыч тотып яу чабучы баһадирларга түгел, акыл ияләренә мохтаҗдыр».

Сәлим хан еш кына кәтибе язган китапны укыштыра иде. Бер тапкыр әлеге юлларга төртелгәч: «Хакыйкатьне бер иман белән генә яклап булмыйлар, кулга кылыч та тотарга туры килә»,— диде.

Әйтер сүзен ул тиклем ачык итеп җиткермәсә дә, бераз абайлады Хафиз, Сәлим хан ул уйлаганча ук садә түгел, аның да үз халкына карата фәлсәфәсе бар. Сәлим хан халкының ни теләвен белә кебек, ә менә шәех Игәнәй белән епископ Габбасның ни теләүләрен белеп бетерми. Сизә-күрә бит Хафиз бу ике кеше әүвәлгечә пычакка-пычак килеп яшәсәләр, бәла тууны көт тә тор. Ә епископ Габбас белән шәех Игәнәйнең максатлары бер: халык кына түгел, хан һәм кенәзләр дә сукыр килеш аларга иярсен. Шуңа күрә Болгарга акыллы хан кирәк, бик кирәк. Тик кая ул? Ул синең белән янәшә бара кәтиб Хафиз — Гали олан ул. Халык аңа бер тапкыр иманын бирде инде, бу Чәчкә бәйрәмендә булды, тиздән икенчесе дә булыр...

Бу хакта Хафиз тарих китабына да яза алган булыр иде, яза алмый. Язса, икенче көнне үк башын кисәчәкләр, ханнар хыянәтне кичерми, алар күкрәгендә уч төбенә сыярдай йөрәк түгелдер, таштыр. Таш булмаса, көн аралаш кеше башын чаптырмаслар иде. Сәлим хан: «Елга — ярына, халык ханына буйсынырга тиеш»,— дияргә ярата.

Аларны Баян баһадир куып җитте, атын янәшәдән атлатып китте. Кәтиб баһадирга карамый гына:

— Баһадир, ни өчен юллар кисешә?— диде.

— Һе, миңа нигә ул. Белмим дисәм, ни әйтерсең?

— Нигә кисешә юллар, баһадир?

— Берәүләр кояшка таба бара, икенчеләре аннан качалар,— дип сүзгә кушылды Гали.— Шуңа кисешә юллар, остазым.

— Хак, олан, хак. Әйтик, менә гарәпләрне алыйк. Аларда эссе, түзмәле түгел. Ә алар бирегә килә, диннәренә ияреп җайлашырга маташалар. Юк, җайлаша алмыйлар. Күпләренә салкын тия, күпләре ачка үлә. Чөнки гарәп эшләп ашарга өйрәнмәгән. Аңа бик аз гына ризык та җиткән, өсте-башы өчен кайгыртмаган. Менә ни өчен Айдар ханның кызын терелткән гарәп табибе бабасы үлгәч, бик аз гына тәхеттә утырып кала. Безнең табигать гарәп өчен ят җирдер. Шуңа карамастан, һәр гарәп, Болгарга килдеме, өйләнә. Шуның өчен булса кирәк, гарәп сәфәр чыкса — өйләнер, болгар сәфәр чыкса — кинәнер, диләр. Мин дә менә кинәнә-кинәнә барам, баһадир. Гарәп йөрәге белән ялганнар, болгар — теле белән, диләр. Бу хакта Ягкуб Ногман да язып калдырган. Ә хәзер миңа шуны әйт, баһадир: вәзир оланнарны кала нигезен күрсәтергә нигә алып бара?

— Менә монысын бөтенләй белмим. Син аны вәзирнең үзеннән сора,— диде Баян.

— Сорамыйм, беләм. Оланнар булачак каланың нигезен күр-

сеннәр, дип алып бара. Кем белә, киләчәктә Болгарның башкаласы булып куюы бар дип уйлавы. Әйт әле, баһадир, Сәлим хан сиңа нинди хат бирде? Гомумән, син кем яклы?

— Кәтиб Хафиз, минем өчен Сәлим хан да, вәзир Исхак та бердер. Алар боеручылар, мин азаттыр.

— Ни өчен сиңа Сәлим хан хатны бирде дип уйлыйсың, баһадир?

— Ышанганга дип уйлыйм, кәтиб Хафиз.

— Синеңчә Сәлим хан үз вәзиренә ышанмый, сиңа ышана төшә булып чыга? Хак әйтәләр: кешене алла түгел, ул үзен-үзе үзгәртә.

— Син дә хаклы, кәтиб, мине дә гаепләп бетермә. Әйтик, Рум императоры колларын азат итү өчен тегеләрнең диннәрен кабул итә, дин башлыгы булып алгач, тегеләрне янә кол итә. Шуннан ни үзгәрә? Император император булып кала, коллар — кол.

— Дөрес әйтәсең, баһадир, тәхет татлыдыр. Татлы булмаса, тәхеттә утыручылар теләсә нинди дин кабул итмәсләр иде. Император, тәхетен югалтмас өчен, христиан динен, ягъни үз колларының динен кабул итәргә мәҗбүр була. Ун еллар элек Сәлим ханның энесе Мөхәммәталим бәк, агасы белән килешмичә, үз ишләрен алып, кыпчак ханы Янтак даласына кача. Анда ул Янтак хан кызына өйләнә, тик хәзер әнә илгә кайту хакында хыяллана икән. Кайтам да абыемның башын кисәм, тәхеткә үзем утырам, дип әйтеп әйтә икән. Татлы, татлы, баһадир, тәхеттә утырулар. Ни өчен дип уйлыйсың? Сәлим хан исә: «Мөхәммәталим бәк канга сусаган, башын кисеп канлы капчыкка салыгыз!»— дип яный.

— Алай булгач, Мөхәммәталим бәк белән очрашасым бар икән әле минем, кәтиб Хафиз.

— Аның белән очрашмавың әйбәтрәк булыр, баһадир. Уктан очкан кошны ала, сөңгедә беркемгә бирешми. Менә акыл дигәне чамалы, акылны хода үлчәп кенә биргән аңа.

Калкулыкка күтәрелделәр һәм күз алдында иге-чиге булмаган манзара пәйда булды — ике елга тиң Олуг Иделгә коя, калкулыктан караганда офык читләре зәңгәр рәшәдә тибрәлә иде.

— Чияле тау шушы инде,— диде вәзир Исхак һәм аттан төшмәкче итте, шулчак бер азат кычкырып җибәрде:

— Вәзир, төшмәгез, аяк астында еланнар!

Шунда гына озын юл килгән сәфәрчеләр җирдә мыжлап торган еланнарны күрделәр. Атлар пошкырынып артка чигенә башлады, кешеләр дә куркынып кире борылды.

— Кәтиб Хафиз,— диде вәзир.— Ни кылабыз!

— Казан кирмәне моннан ерак түгел, диделәр. Әүвәл анда барыйк. Атлар да йончыды, юл да озын булды. Киңәшербез.

— Казан кирмәненә!— дип боерды вәзир.

* * *

Казан кирмәнендә аларны баһадир Бачман үзе каршы алды. Хан сәфәрчеләре хакында ул хәбәрдар икән инде, һәммәсен диярлек колач җәеп капкадан уздырды.

Кәтиб Хафиз белән Гали оланны бер өйгә куйдылар. Бачман баһадир моны Хафиз үтенече буенча эшләде. Вәзир Исхак һәммәсен күреп, күзәтеп торса да, бер сүз дә әйтмәде. Дөрес, нигә игътибар итәргә тиеш әле ул? Баян баһадир белән Булат олан бергә керделәр бит. Әйе, барысы да хода кулында, язганны күрми үлеп булмый.

Кичке якта Хафизны вәзир үзе урнашкан өйгә дәшеп алды.

Гали өйдә ялгызы гына калды. Хәер, ул үзе генә түгел иде инде, аның белән Ягкуб би кызы Зөләйха да бар иде. Ул аның белән сөйләште, кызга сораулар бирде һәм бик рәхәтләнеп аның җавабын тыңлады. Хыялында ул кызның алсу битләреннән үпте, нечкә биленнән кочты,

нәфис кулларыннан тотты, бераз гына моңсу, шат, бәхетле күзләренә карады, ул күзләрне ике түгәрәк күлгә охшатты, хәтта шул күл суында битен юасы килде, чынлап та битендә су тойды, юк, су түгел, күз яше икән — Гали олан йөрәге тулышкан бәхеттән тавышсыз гына елый икән бит, үзе дә сизмәстән күз яшьләре ага икән...

Икенче көнне оланнарны Бачман баһадир оештырган ауга алдылар. Әллә ни кыра алмасалар да, бер поши, ике бүре алып кайттылар.

Кичке якта шаулаша-шаулаша әйләнгеч тирәсенә җыелдылар. Бачман баһадир һәммәсенә дә кисеп-кисеп ысланып кыздырылган ит бирде. Шунда ук чокып ясалган мичкә белән эче бал китереп утырттылар. Кәефләнеп алган азатлар бераздан елга буена төшеп киттеләр, аларга Булат белән Гали дә ияреде. Елга буендагы кичке уенга якын тирәдәге авыллардан яшьләр дә килгән иде. Бу урынны Кызлар яры дип йөриләр булып чыкты, әйлән-бәйлән уйнаганда Гали белән Булат та уенга катнаштылар. Казан кирманендә һәм кирман тирәсендәге авылларда яшәгән кызлар хан оныкларын еш кына уртага алды. Уеннар, биюләр, ярышлы уйнаулар, сайлаулы, яки чүпләшле уеннар шул хәтле ошады оланнарга — таралганда китәселәре килми башлады.

Кичке уеннан оланнарны Бачман баһадирның азатлары өйләренә кадәр озатып куйды. Бачман, соң булса да, оланнарны кирмән капкасы янында каршы алды, Галине өенә кадәр озата барды. Углан аңа якын иде, атасы әмир Хаҗидә хезмәт иткәне өчен генә түгел, анасы Акбикәгә битараф булмаганы өчен дә. Бачман баһадир ир уртасы кеше, әмма әлегә кадәр өйләнми яши, моңа гаҗәпләнүчеләр дә бар иде, әмма Бачман буйдак булып гомер итә бирде. Ишеттергәләделәр, имеш, баһадир әмир Хаҗи бикәсе Акбикәгә гашыйк, мин башка берәүне дә яратмаячакмын, дип ант эчкән икән, иллә моңа ышану кыен иде, баһадир каравыш кызлар тота, ә инде кемнедер ярату яки яратмау аның тәгаен үз эше иде. Мәгәр бу хәлне Гали белми иде, белсә дә, һични әйтә алмас иде. Бачман баһадирның якын итүен ул тулысы белән үзенең хан оныгы булуыннан күрде.

* * *

Хафиз өчен хикмәтле көннәр башланды. Иң әүвәл аны вәзир Исхак чакырып алды. Башта шуңа гаҗәпләнде. Нигә вәзиргә хан кәтибе? Һәм вәзир күрше чирмеш авылыннан даны якын тирәгә таралган камны алып килергә кушкач, бөтенләй аптырашта калды. Нигә ул барырга тиеш, нигә, әйтик, Баян баһадир яисә башка берәү түгел? Алай да ул кеше кешесе иде, барырга булды. Кам аны ашамас, ашаса да иттән-сөяктән генә тора, һич югы могҗизалар кыла ала торган сихерчене күрер. Нәкъ шул кам еланнарны бетерә ала, диде аңа вәзир.

— Бетерә икән, бик яхшы,— диде кәтиб Хафиз бер дә исе китмичә.— Кайчан китим?

— Хәзер үк, бүген үк.

— Яхшы, вәзир.

Менә ул кам йорты каршында. Ниһаять, эзли торгач, Хафиз аның өен эзләп тапты, бар икән әле изге кешеләр — күрсәттеләр, хәтта бер малай бусагасына кадәр озатты. Үзе белән килгән ике азатны капка янында калдырып, кәтиб Хафиз чыпта кадаклаган тәбәнәк ишекне ачып, өйгә керде. Өй эче ярымкараңгы, күз һичнәрсә абайламый. Ниһаять, Хафизның күзе өйрәнә төште һәм ул түр якта утыручы озын чәчле, ул хәтле карт булмаган, ягымлы гына йөзле камны күрде. Кәтиб чирмеш телен әйбәт белә иде, бил бөгеп, сәлам юллады. Сәере шул булды, кам төрки телдә җавап бирде.

Камның түшендә балык тешләре, тире сырмасына төрле ялтыравык ташлар таккан, сул иңендә ике елан эленеп тора, уң иңендә мәче башлы ябалак утыра.

Хафиз камга бик озак итеп әүвәл чирмеш телендә, аннары төрки телдә йомышын аңлатты. Әйе, Чияле тау түбәгенә Сәлим хан зур Базаркала салырга ниятли икән, ә анда елан мыжлап тора, еланы бер хәл, еланнар патшасы яши, аны бары тик могжизалар кылучы кам куа ала, әгәр дә мәгәр ышбу эшне җиренә җиткереп башкарса, түләүдән тормаячаклар икән хан кешеләре.

Кам, кәтиб Хафиз йомышын аңлатып бетергәч, бик озак дәшми утырды. Аның иңендә утырган мәче башлы ябалак борсалана башлады, хуҗа аны мич башына җибәрде, үзе янә урынына килеп утырды.

— Түләвең ни бәядән булыр?

— Алтын белән, кам.

— Инде тыңла. Кара Бөркет кам иртәгә Чияле тауда булыр. Миңа бүген атланып килгән атыңны калдырырсың.

Хафиз нидер әйтергә авызын ачкан иде, сүзсез калды, кам муенындагы еланны кулына алды да идәнгә җибәрде, елан шуыша-шуыша кәтибкә таба килә башлады.

— Атым бәйләгән урында калыр,— диде ул һәм ишекне ачып тышкы якка чыкты. Кайтыр юлын ул үзе белән килгән азат атына атланып кайтты.

* * *

Икенче көнне иртән-иртүк барчасы да Чияле тауга, яңа кала салынасы төбәккә киттеләр. Алар килгәндә кам анда иде инде. Ул кәтиб Хафизның ап-ак атына атланган да Чияле тауның нәкъ түбәсендә тора иде. Янәшәсендә салам чүмәләсе, аннан тугызар адым ара калдырып, салам сибеп боҗра ясалган. Боҗра янына якынайган вәзиргә, ары килмәскә кушып, кам кулындагы таякны күтәрде.

— Туктагыз!

Вәзир Исхак чарасыз калып атын артка чиктерде. Шул мәлдә кам янында әзмәвердәй ике егет пәйда булды, аларның өстендә ап-ак күлмәкләр, икесе дә бер буйда, бер киемдә иделәр. Кам атыннан төште, ике егет атның арт һәм ал аякларын тоттылар да салам чүмәләсе янына ектылар, кам атның бугазына пычак кадады. Ат башын күтәрмәкче итте, әмма кам ирек бирмәде, тезе белән җиргә кысты. Аннары атны салам чүмәләсе астына күмделәр, шуннан соң гына кам вәзиргә якынлашты, ә кинәт пәйда булган ике егет, гүя җир астына төшеп киттеләр — юкка чыктылар.

— Син хан кәтибенең атын яткырып чалдың, салам чүмәләсе астына күмдең. Ни кылырга исәбең?— дип сорады камнан вәзир. Тегесе дәшмәде, Хафиз янына атлады.

— Минем бу адәм белән аңлашасым килми. Мин биредә бары тик сине беләм,— диде кам.

— Мин аны, беләсеңме, нишләтәм, Хафиз! — дип, вәзир якынаймакчы иде, камга җитәрәк вәзирнең аты пошкырынырга, тәпен-төпен артка чигенергә тотынды.

— Баян баһадир, алып китегез вәзирне. Мин кам белән үзем аңлашам!— диде Хафиз.

Баян вәзир янына юырттырып килде һәм аңа нидер әйтте, Исхак каерылып кам ягына карап алды да кул селтәп читкә атлады.

— Хан алдында үзегез җавап бирерсез!— дип кычкырды ул китеп барганда.

— Кам, кичер аны. Акылны кешегә бизмән белән өләшмиләр.

— Хан вәкиле, бүгенгедән санаганда тугызынчы көнне иртән иртүк бирегә килерсез! — диде һәм борылды да чия куаклары арасына кереп китте.

— Шуңа ышанасыңмы син, Хафиз?

— Башка чара юк, баһадир. Тугызынчы көнне без бередә булырга тиешбез. Мин шуны гына беләм.

— Кам түгел, күз буучы ул. Теге егетләр кайда югалды? Барлар иде, кинәт юкка чыктылар. Күз буучы булмыйча кем ул?

— Кайсы кам күз бумый, баһадир? Кайтыйк кирмәнгә. Тугыз көннән килербез. Сүзендә тормаса, иң әүвәл мин үзем аны...

— Остазым,— диде, ниһаять, алар янында торган Гали олан.— Кам кайда күздән югалды?

— Җир упты аны, олан, җир. Бәлкем елан патшасы янына киткәндер. Киңәшергә. Елан патшасы хакындагы хикәятне дә шул кам уйлап тапкан, диләр. Ул минем атымны корбан итте. Кемгә дип беләсең? Елан патшасына.

— Ул елан патшасы телен беләме?

— Белә. Тик уртак тел таба алырмы икән? Урын бик матур. Күрәсеңме, никадәр хозурлык! Идел елгасы җәелеп ята, Казан елгасына Болак елгасы килеп кушыла, ә анда Кабан күле. Бу исемнәрне миңа Бачман баһадир әйтте. Димәк, монда бик борынгыдан кардәш төркиләр яшәгән, олан.

Алар вәзирне, Булат оланны куып җиттеләр.

— Кәтиб, кам елан патшасы аждаһаны куып җибәрә алмаса, мин менә бу кылычым белән аның башын кисәчәкмен.

— Елан патшасын кем куар? Аждаһаны кам куса куа ала, безнең кулдан килә торган нәрсә түгел кебек миңа. Әллә соң вәзир бер-бер юлын беләме?

— Кемнән көләсең, кәтиб Хафиз?

— Көлмим, вәзир. Мин аңа атым корбан иттем, уч тутырып алтын бирдем. Мин түгел, син көләсең миннән. Ни дипме? Җиңел генә синең кармагыңа эләгүемнән.

— Мин моны хан боерыгын үтәү өчен эшләдем, кәтиб Хафиз.

— Әйе, без бирегә бер максат белән килдек, вәзир.

— Вәзир, мин монда кәтиб Хафизның бернинди дә гаебен күрмим. Киресенчә, ул кулыннан килгәннең барысын да эшләде кебек,— диде Баян баһадир.

— Мин еланнарны да, елан патшасы аждаһаны да Чияле таудан куу ягында түгел. Кала салу өчен Чияле таудан башка да урын бетмәгәндер,— диде моңа кадәр бер сүз дә әйтмәгән Булат олан.

— Һе-һе-һе, Булат олан да телгә килде, Булат оланның да теле ачылды.

— Елан патшасы аждаһаның ачуын китерсәң, безгә генә түгел, илгә дә яман хәлләр килер, ди.

— Кем шулай ди, Гали олан?! — дип сорады вәзир.

— Чәчәк-Ана шулай дип әйтеп әйтә, ди.

— Менә сиңа мә. Без хан оныкларына яңа кала салырга урын эзлибез, ә алар... Хәер, мин риза, көтик тугыз көн. Шуннан соң да Чияле тау тулы елан мыжгып торса, мин ул камның кулын кулга, аягын аякка чабып ташлаячакмын! Ишеттегезме?! Тугыз көннән! — диде вәзир һәм атына камчысы белән шундый китереп сукты ки, аргамагы үрә басты.

* * *

Чияле тау итәгенә барырга бер көн калгач, Мәкәрҗәдән Өргәнечкә юл тотучы Сәлим хан сәүдәгәре Биккол килеп төште. Хан сәүдәгәре улын җирләгән, шуңа кәефе юк, мәгәр бирегә кәтиб Хафизны күреп, күз яше белән елап алды. Биккол ханга сәүдәгәрлек кыла һәм ханның иң ышанычлы кешеләреннән берсе иде. Бикколны белмәгән баһадир юктыр, чик буйларында аңардан җыем да алмыйлар иде. Кирмәнгә олавы белән

килеп кергән Бикколны күрде дә кәтиб Хафиз аңа каршы китте. Ул бу кешене ярата, чөнки сәүдәгәр чит илләрдән янадан-яңа китаплар алып кайта, гыйбрәтле хәбәрләр җиткерә иде.

Хафиз кич белән хан сәүдәгәре туктаган өйгә китте. Үзе белән Гали оланны да алырга иткән иде, уеннан кире кайтты. Олан бирелеп китап укып утыра иде, бүлдерәсе килмәде.

Биккол сәүдәгәр кәтибне ишек төбендә килеп каршы алды, житәкләп диярлек түр якка алып керде, сәкегә җәйгән киезгә мендәр ташлаган иде, шунда утыртты.

Дога кылдылар, хәл-әхвәлләр сораштылар, ары килеп күзгә-күз карашып алдылар.

— Безне монда ходай үзе кавыштыргандыр, Биккол.

— Шулайдыр, шулайдыр, кәтиб. Йә сөйлә, ни эзләп килеп төштегез Казан кирмәненә?

Хафиз барысын да түкми-чәчми сөйләп биргәч, Биккол беркавым дәшми-тынмый утырды. Аннары торды да ишекле-түрле йөренергә кереште, чурасына кымыз һәм ризык китерергә кушты, шуннан соң гына:

— Сәлим ханның Казан елгасы тамагына олы Базаркала салуын хуплыйм, кәтиб Хафиз. Күптән кирәк иде. Мин әмир Хажига Казан кирмәнен сала башлагач та: «Урыны бу түгел кирмәннең, елга тамагына салырга кирәк»,— дигән идем, тыңламаган булды. Ә хәзер әнә үзе үк өтәләнеп йөри икән. Базаркала гына аз булыр, олы кирмәнле итәргә кирәк булачак аны. Урыны, урыны ни тора! Елан күп күбен. Бетәр ул, кешедән елан гына түгел, аю да кача. Тик менә нигә инде хан оныкларын китерергә? Азындыра, азындыра хан оныкларын. Мин алардан җир сукалатыр идем. Ерак җирләргә сәүдә итәргә җибәрер идем. Шомарсыннар, дөнья күрсеннәр. Бераз чамалыйм, кәтиб, бу оланнарның берсе тәхеткә билгеләнгәндер инде, ә? Чәчкә бәйрәмендә Гали оныгына вәгъдә итте дисеңме?! Бу бит коточкыч хәл, кәтиб Хафиз! Коточкыч! Менә күреп тор, тиздән бу ике олан кан коя башлар. Әйе, Хафизҗан, хикмәтле чорда яши Болгар. Биек Калада чиркәү салдылар, атна саен чаң сугалар. Хан сараен урыстан килгән баһадир саклый. Шәех Игәнәй ни уйлый икән? Бер кайткач, шул хакта ханга әйткән идем, беләсеңме ни дип җавап кайтарды? «Бер дин — бер акыл, ике дин — ике акыл»,— диде. Тукта, тагын бер хәбәр ишеттем бит әле. Имеш, Олуг Мөхәммәт илчесен үлтергәннәр икән! Хакмы шул?

— Хак, Биккол, үлтерделәр. Шайтан каласында.

— Гаҗәп. Нигә барган икән илче Шайтан каласына? Ни калган аңа анда?

— Гөнаһка батма, Биккол. Шайтан каласын кем саклаганны беләсең. Миңа калса, бүген Сәлим хан Болгарны икегә аермакчыдыр. Аңа ике оланның кайсы тәхеткә утырса да барыбер, ә миңа барыбер түгел, Биккол. Ханның Бөек Калада чиркәү салдыруын мин дә хупламыйм. Бер кешедә ике җан булмый, ә иман бары тик җан белән керә, җан белән чыга. Минем хыялым Гали оланны Болгар тәхетенә утыртудадыр. Шәех Игәнәй белән епископ Габбасны килештерергә теләмим. Алар икесе ике ярда басып сөйләшә, араларында күпер салып булмастай елга. Елга киң, ярларына бәрелә-сугыла ага, аларның берсе дә теге я бу якка чыгарга теләми, гәрчә елга башына табарак күтәрелсәләр, бер хикмәт күрерләр иде: тибеп чыккан җирдә елга ярсыз икән бит. Әйе, бер чыганактан чыга христиан һәм мөселман диннәре, бер чишмәдән. Хәзер әнә аркылы чыкмаслык киң елгага әверелгән — икесе ике күздән күрәләр дөньяны. Сәлим хан күп нәрсәне күрми, күрергә теләми, багучысы Таймас күп вакытта Ага Базарда кымыз чөмереп утыра. Сәлим хан тыныч: вәзир Исхак күп изгелекләр эшләде — күрше Владимир кенәзе белән солыхны янартты, угланы Илһамны кенәз нәселенә өйләндерде, аннан туган Булат оланның кулыннан кылыч төшми — ике туган арасын-

да канлы сугыш китсә, кемнең башы keләмгә очар дип беләсең, Биккол? Гали оланның. Кардәш бортаслар авыл-авыл кенәз Андрей Боголюб биләмәсенә күчә. Ни өчен дип беләсең? Тынычлык китеп бара Болгарда, хан энесе белән тынышмый, Тубыкбай да энесе Җик Мәргәнне куып җибәргән, тиздән Сәлим ханнан әмир Хаҗи углан аерылып чыгар — эшләр шуңа таба бара. Ә Сәлим хан кирмән өстенә кирмән салдыра. Илне кирмәннәргә бикләнеп кенә саклап калып булса икән ул. Илне кирмән түгел, илне яңа корал, көчле иман саклыйдыр...

— Илдән киттеңме, әллә ниләр була да куя. Куеп торыйк әле, Хафизҗан, сарай кайгыларын.

— Әйе шул, Биккол. Сәүдә эшләрең ничек бара? Коллар да алгалыйсың икән. Шәп түгел. Хан белеп алса...

— Хан белә, Хафизҗан, белә. Кол сатып алган юк диярлек хәзер. Йөртүе кыенлашты, качалар. Бу юлы аталы-уллы берәүне алдым, үзе теләде. Угланын кенәз сугышчы итеп алырга иткән, шуннан кача.

— Син гомерең буе изгелек кылырга теләдең. Мәгәр изгелекме бу? Белмиләр ул бичаралар, бер богаудан качып, икенчесенә эләгәчәкләр. Городецта бер богау йөрткән булса, Өргәнечтә аңа ике богау тагасыларын белмиләр шул ул бичаралар.

— Һәй, Хафизҗан, Хафизҗан, киләчәкне мин беләмме, синме? Барысы да алла кулында.

— Тик аллаһы тәгаләнең бизмәне юктыр, булса, берәүгә гелән кайгы-хәсрәт, икенчегә шатлык биреп тормас иде.

Ул арада табынга ашарга керттеләр. Сәүдәгәр Биккол ризыкның рәтен белә иде, әллә ниләр хәстәрләткән. Кәтиб Хафиз һәммә ризыкка да житеште, бик тәмләп ашады, әмма әче балына үрелмәде.

— Әче бал эч дип кыстамыйм, Хафизҗан, үз җаең үзең кара, иллә бер чокыр гына шайтан да күтәрәдер инде аны. Эчмәсәң, алып куярга кушам.

— Әйе шул, Биккол, алсыннар әле аны. Булмас, ахры. Иртәгә яңа кала салынасы Чияле таүга барабыз. Елан патшасы аждаһа белән очрашасы бар. Ошатмавы мөмкин, дим. Эчкән кешеләрне яратмый икән, диләр.

— Нинди аждаһа ул тагын? Сөйлә әле сер булмаса.

Хафиз иртәгә буласы хәлләрне төкми-чәчми сөйләп бирде. Сәүдәгәр Биккол тыңлап утырды-утырды да торып янә йөренергә тотынды.

— Менә хикмәт диген син аны, ә? Ни генә уйлап тапмый бу Сәлим хан.

— Сәлим хан түгел, вәзир Исхак, Биккол.

— Вәзир?! Аңа үзе утырган ботакны кисү нигә? Тамаша! Син угланның берсен чынлап та кала нигезенә күмәрләр, ягъни корбан итәрләр, дип уйлыйсыңмы?

— Шулай булмагае дип куркам. Сәлим ханга бер оланнан котылу кирәк дип уйлыйм.

— Кыргыйлык бит бу! Иманы кая ханның!? Мин моңа ышанмыйм, Хафизҗан.

— Хан җибәргән хат Баян баһадирда.

— Баян баһадирда? Менә нәрсә, Хафизҗан, безгә ул хатны кулга төшерергә кирәк. Мең алтын торса да.

— Баян баһадир моңа барыр дисеңме?..

— Баһадирны ни өчен Болгарга килде дип беләсең? Алтын китерде аны биргә, алтын, Хафизҗан. Хатны кулга төшерүне үз өстемә алам, Хафизҗан.

— Кабатла, кабатла, ни дидең, Биккол?

— Хатны кулга төшерүне үз өстемә алам, дидем. Син торып тор, мин Баян баһадирга барып киләм.

— Кара инде, Биккол. Бирсен ходай иде дә бит...

* * *

Күп тә үтми, серле хатны тотып кергән Бикколны күргәч, Хафиз үз күзләренә үзе ышанмады.

— Мин аны хәзер үк кире илтеп бирергә тиеш, Хафизҗан. Ач, укы, җилем белән ябыштыр. Мөһерне үзем сугармын. Биккол сәүдәгәр мөһере хан мөһереннән бер дә ким түгел.

Кәтиб Хафиз бу хәлгә аптырабрак калды. Хыялның чынга әверелү мәлләре шул микәнни инде? Иплән кенә мөһерне ватты, төргәкне сүтте. Һәм күзләре хат юлларына төшүгә, ике күзе дүрт булды.

— Хан монда бер оланны яңа кала нигезенә корбан итәргә боерган, Биккол.

— Корбан итәргә? Кайсысын?

— Җирәбә салырга кушкан. Кайсысына төшә.

— Йә хода, Хафизҗан. Хан, ахрысы, чынлап та акылдан язгандыр. Хәер, бик үк акылдан язган дип тә әйтеп булмый. Бер олан аңа чынлап та комачаулый. Кайсысына чыкса да, син аны коткарырга тиеш, Хафизҗан. Борынгы бабаларыбызның йоласын тоту кыргыйлык булыр.

— Ничек, ничек коткарып була ул оланны?..

— Уйларга кирәк, Хафизҗан. Уйларга кирәк. Хәзер хатны төр, мөһерем сугыйм да баһадирга илтеп бирим. Хатның миңа күпмегә төшкәнен соңыннан әйтермен.

Биккол хатны илтеп кайткач, бер чокыр әче бал эчеп куйды.

— Мин хәзер барысына да төшендем, Биккол. Ханга Гали комачаулый, ул шуңардан котылырга тели. Чәчкә бәйрәмендә аңа тәхет вәгъдә итте. Санаулы көн тиз җитә, Сәлим хан үз көчендә әле, ә тәхетне бирәсе килми. Моннан кайткач, Сәлим хан оланны яңа кала нигезенә корбан иткән вәзирен хөкем кылыр, бәлкем әле мине дә. Шаһитлар калмаска тиеш. Хәер, борын-борын заманнан ук Болгар ханнары акыллы кешеләрне яратмаганнар. Милади белән 921 елда Болгарга килгән Багдат халифе сәркәтибе язуынча: «Бу кеше бик күп белә башлады, тәңре янына китсен», — дип, хикмәт ияләрен агачка асып куя торган булганнар. Аларга күмелү дә тәтемәгән!

Икәүдән-икәү генә бер бүлмәдә, ризык-нигъмәт тулы табын янында Сәлим ханның якын кешеләре кылган эшләрнең ни белән бетәсен белмәүдән чарасыз калып, уйланып утырдылар. Ниһаять, кәтиб Хафиз телгә килде:

— Биккол, Болгарда серем ачыр кешем юктыр. Зарым тыңлаган бердәнберем син булдың. Киңәшең бир, Сәлим ханның кәтибе ни кылсын?

— Киңәшем шул булыр, кәтиб: хәзер үк камга бар.

— Камга?! Төн уртасындамы?

— Әйе, Хафизҗан, төн уртасында. Курыкма, синең белән мин дә барам. Кузгалыйк, без таң беленгәнче кайтып җитәргә тиешбез.

* * *

Бу төнне таң бик озак атты. Кичтән үк чыгып киткән остазын көтәкөтә Гали олан да йокыга китте. Хафиз таң аткач та кайтып җитә алмады, Галине вәзир Исхак кереп уятты. «Гали олан, Гали олан, тор инде. Кайда Хафиз, остазың дим кайда?»

Вәзир Исхак кичтән эчкән эчемлектән әле булса айнып җитмәгән, теле көрмәкләнмәсә дә, исерек иде. Ул менә ничә көн инде еланнарны бетерүне Хафизга тапшыруына үкенеп йөри, бу хакта кемгә булса да зарланасы килә, әмма Гали аны тыңларга теләмәде, башыннан ук ябынып ятты. Вәзир кул селтәп чыгып китте. Ул чирмеш камына ышанды да, ышанмады да. Бу эшне Хафизга йөкләве, тегенең бер көндә кыласы эшне тугыз көнгә тартуы, кам үзе, кием-салымы, кыяфәте бер дә иман китерерлек түгел иде. Ләкин вәзирнең башка чарасы юк иде. Ул көтте.

Бал, буза эчә-эчә көтте. Һәм, ниһаять, менә ул көткән көн дә килеп җитте. Чияле тауга барыр көнне ул бик иртә уянды. Кичтән эче бал салып, Бачман баһадир китергән каравыш кыз янында төн уздыргангамы, йокысы туймаган, кәефе юк, чапанын гына иңенә ташлап, Хафизны орышып чыкмакчы иткән иде — өйдә очрамады. Вәзир болдырга чыкты да каршыдагы мәчет манарасында чәр-чәр килгән чәүкәләргә игътибар итте. Нинди кош бу чәүкә дигәнең, мәчет, чиркәү манарасын ярата. Чыр-чыр да чәр-чәр, гелән сарай куштаннары инде, бер дә талашмый тормыйлар. Манарага мәзин менде, чәүкәләр чыр-чу килә-килә очып киттеләр. Мәзин ике колагына тотынды да сузып-сузып азан кычкырырга кереште.

Болдырга басып, манарада азан кычкырган мәзинне карап тору бер хәл иде, түзмәле, ә менә борып-борып эч авырта башлагач, җитмәсә, каравыш кыз килеп сарылгач...

— Ни булды, хәкимем?

— Күңел болгана, әллә кичәге симез ит ярамады инде. Әйттем аны кирәкми дип, тутырдың да тутырдың.

— Мин сиңа хәзер андыз суы бирәм, юып алгандай итәр, хәкимем.

— Куй,— диде вәзир.— Болай да көчкә басып торам. Бу мәзине дә туктамас булды. Чыгар әле ук-җәя, атып төшеримче үзен. Шул тамаша озак азан кычкыралармы...

— Бәлкем, хәкимем, ул да кичке якта әче бал эчкәндер?

— Һе-е, көлке түгел. Атам мин аны, мөртәтне?

— Хәкимем, кеше ишетүе бар.

— Кеше ни ул миңа. Мин үзем түрә монда! Хода ишетмәсен, диген. Кая чыгар әле шул андыз суыңны. Ярдәме тимәсме. Гел чыдамалы булмый башлады. Бөтереп-бөтереп китерә, хикмәт...

Каравыш кыз төнәтмә чыгарып бирүгә, вәзир бер савыт андыз суын тын алмыйча эчеп бетерде.

— Тагын чыгарыйммы? — диде кыз ягымлы итеп.

— Җитеп торыр.

Андыз төнәтмәсе тәмсез, агач тамыры исе килә иде. Эчкән вакытта вәзирнең күзе каравыш кызның зифа сынына төште. Шундук төнлә булган хәл күз алдына килде. Кичә кыз аңа болай ук зифа сынлы булып күренмәгән иде. Биредә исә, гүя, алиһә үзе. Бирсә бирер икән хода адәм баласына сылулыкны! Вәзирнең йортында өч хатын, берәүсен дә кимсетмәде, өчесенә өч өй салып бирде, иң мөһиме, яннарына ханнар кебек чиратлап түгел, теләге кайсына юнәлә, шуңа керде. Бер тапкыр ул карт хатыны янында ат караучысын күрде. Теге мут җан хатын янында шундаен сырпалана иде ки, вәзир көнләшеп куйгандай булды. Юк, көнләмәде, бераз гына ачуы чыкты, мәгәр озакка бармады ачу дигәне, шундук шатлыкка әверелде. Ул аларны күрмәмешкә салышты, аннан кинәт кенә яннарына килеп чыкмакчы иткән иде, бу уеннан кире кайтты. Мәгәр шушы көннән карт хатыны янына бөтенләй кермәс булды. Хәер, хатынның да бәгыре бик өзелмәде бугай. Ул ачыктан-ачык ук булмаса да, ат караучыны үзенә иялэштерде. Вәзирнең яратканы өченче хатыны иде. Исхак каравыш кызын кисәк кенә өченче хатыны белән чагыштырып карады. Яшь хатынына караганда да чибәр иде каравыш кызы. Күр әле бу хикмәтне, эч авыртуы да туктады бит. Вәзир кызның беләгеннән эләктереп алды, икенче кулы белән биленнән кочты.

— Хәкимем, кеше-кара күрүе бар ич...

— Күрсеннәр. Мин сине дүртенче катыным итеп алам. Үзеңә бер өй салырмын, барасыңмы? Әнә теге мәзиннән никах укытабыз да.

— Үртәмә әле, бар да шулай ди дә китә дә бара.

— Кем тагын бар да?!. Югал күз алдымнан!

Шунда ук кәтиб Хафизның болдырга менеп килүен күрде.

— Вәзир, кузгалырга вакыт җитеп килә, минемчә.

— Кузгалырга? — Кәтиб Хафиздан кайда йөрүен сорарга да онытып, вәзир киенергә үз ягына кереп китте.

* * *

Кам аларны Чияле тауда көтеп тора иде инде. Вәзир Исхак берәүгә дә күтәрелеп карамады, аның камны да, оланнарны да, баһадирны да, кәтиб Хафизны да, казый Саксинны да күрәсе килми, бу хикмәтле хәлне тизрәк үткәрергә ашыга, аңа, кайсы олан корбан ителсә дә, барыбер иде. Иллә бер нәрсәне ачык белә иде вәзир, хан фәрманы җиренә җиткерелеп үтәлергә тиеш. Күр әле бу хан кәтибен, әллә елмая инде? Елмай-елмай, тиздән үкереп еларга туры килмәгәе, әйтик, шәкертеңне җир астына күмгәч. Ә мин аны күмдерермен. Кайсы чыкса да! Тик бу кам еланнар патшасы аждаһаны качыра алырмы, бирерме аждаһа тауны? Бу тау — аждаһа утары лабаса! Хәзер инде кире кайту юк. Әйдә, куа бирсен еланнар патшасын. Безгә яңа кала салырга урын кирәк, менә шул Чияле тау төбәге.

Ул арада кам салам чүмәләсенә ут салды. Ә үзе чүмәлә тирәли шалтыравыкларын зеңләтә-чеңләтә, әллә ниткән ят тавышлар чыгара-чыгара әйләнә башлады. Камның муенында ике-өч елан — тереләр, кыймылдыйлар, әле муенына уралалар, әле бөтерелеп алалар. Кам чүмәлә тирәли тугыз тапкыр әйләнеп чыгарга тиеш. Һәм әнә шулай итте дә. Чүмәлә ялкынлап яна башлады. Шул чак чүмәлә төбеннән ябырылып елан көтүе чыкты, алар бөтерелә-бөтерелә ыслыйлар, чәбәләнәләр, бер-берсенә уралалар, ни кылырга белми бәргәләнәләр иде. Кам бертуктаусыз чыбыркы шартлата, яман тавышлар чыгарып кычкыра, кемгәдер яный, ул да түгел, ялыная лвара, елар дәрәҗәгә җитеп, аждаһаның күккә күтәрелүен үтенә иде. Кам муенындагы бер еланны дөрләп янган чүмәлә ялкыны уртасына ташлады, шундук утның икенче ягында ап-ак күлмәк кигән егет пәйда булды. Кам икенче еланны ташлады, икенче егет пәйда булды. Кам егетләргә икенче бож рага ут салырга боерды. Аның тавышы шундый көр, көчле иде ки, бер читтә дөрләп яна башлагач, кам икенче бож ра тирәли тугыз тапкыр әйләнеп чыкты. Бу юлы инде ул кемгәдер янады, кемнедер куды. Икенче бож ра салам өеме янын бетүгә, кам янә акырынырга-бакырынырга тотынды. Барысы да күреп тордылар, еланнар бер-берсенә уралган-бөтерелгән килеш зур салам чүмәләсенә күчеп беттеләр. Кам икенче бож раны ташлады да җир астыннан калыккан егетләргә уртадагы салам чүмәләсенә ут салырга кушты. Зур салам чүмәләсе кинәт янып китмәде, кам шалтыравыкларын зеңләтә-шалтырата чүмәлә тирәли әйләнүен дәвам итте. Менә чүмәлә өстендә кара төтен күренде, шунда шаман муенындагы өченче еланны салам чүмәләсенә ыргытты һәм шундаен каты итеп кычкырып җибәрде ки, моның артыннан чыбыркысын шундаен каты итеп шартлатты ки, тамаша кылучыларның беришесе борылып, бу тирәдән ераграк китү җаен карадылар. Әмма вәзир Исхак кузгалмады. Зур салам чүмәләсе астында кәтиб Хафизның ак аты ята иде. Бәхәссез, үләксә тирәсенә чебенчерки җыела, төрле хәшәрәт, ә төрле хәшәрәт янына еланнар. Еланнар беренче бож радан икенчегә күчтеләр, икенчедән төп чүмәләгә. Мәхшәр шунда башланырга тиеш. Чынлап та, чүмәлә өстендәге төтен торган саен куера барды. Чүмәлә дәү җанвардай селкенергә тотынды, ахырда очып китәргә теләгәндәй, төтенгә ияреп бер-берсенә ишелә-укмаша еланнар күккә күтәрелә башлады. Еланнар бер-берсенә урала-урала һаман биеккә, өскә юнәлде. Аларның кайберләре укмашкан җирдән ычкынып, кире ут эченә төште, ә кара төтенгә ияргәннәре һаман югарыга очты. Кисәк чүмәлә күзгә күренеп калтыранып куйды, ул да түгел, һавага кара төтен сузылды, ул өермә баганасыдай болытларга барып җитте. Кам тамагы ертылырдай хәлгә җитеп кычкырып җибәрде.

— Аждаһа өен ташлап китә, аждаһа өен ташлап китә!

Чынлап та, кара төтен эчендә ниндидер канатлы елан күренгәндәй булды, ул да түгел, аждаһа болытлар арасына кереп күздән югалды. Ниндидер мизгелдә бөтен әгъзалары ихтыярсыз тораташтай катып калган тамаша кылучылар иркенләп сулыш алды. Әйе, еланнар патшасы очып китте, моны барысы да күрделәр шикелле. Хәзер алар янган чирәмгә хәле китеп утырган камны күзәтә иде. Кам күмерләнгән чирәмгә

төртелгән дә тынып калган. Кисәк ул бүре улаган тавышлар чыгарып, еларга кереште, ә үзе куш йодрыгы белән җиргә төйде.

— Мин монда гаепле, мин! Мин аны кудым, мин! Ал җанымны, тәңрем, ал. Мин гаепле аждаһа алдында, мин!? Күмегез мине шушы төбәккә, казыгыз кабер! Ишетәсезме, казыгыз, күмегез!

— Кам акылдан шаштымы әллә? — дип сорады вәзир янәшәсендә торган кәтиб Хафиздан.— Нигә шашына?

Кәтиб Хафиз дәшмәде, атыннан төште дә шаман янына килде, сак кына иңбашына кагылды. Шунда кам тораташтай катып калды, гүя, ул үлгән иде. Кәтиб каты ташка кагылгандай кулын тартып алды. Кам җиргә капланган да тынып калган иде. «Ул исән,— дип үз-үзен тынычландырды Хафиз.— Ул исән, әнә егетләре дә аның исенә килүен көтеп тора. Күр әле, егетләре янында бер эт пәйда булды. Эт койрыгын селкә-селкә Хафизга карап тора иде.

«Йә алла, бу ни хәл инде тагын!» — дип уйлады кәтиб һәм камның нидер пышылдавын ишетеп, шым булды.

— Кичер мине, кичер мине, кичер мине,— дип, шаман бертуктаусыз тәкърарлап тора иде.

— Кам, тор инде, тор,— диде кәтиб.— Син изге кеше, кам, изге кеше, син аждаһаны кудың, син безгә ярдәм иттең.

Әмма шаман селкенмәде дә, ул һаман еланнар патшасының кичерүен теләп ята иде.

— Калдыр үзен,— диде вәзир Исхак.— Баян баһадир, бир ханның фәрманын кәтиб Хафизга. Юк, миңа бир! Кам үз эшен эшләде, рәхмәт аңа. Чияле таудан еланнар патшасы аждаһаны куып җибәрде.

Баян баһадир хан хатын вәзиргә китереп бирде, вәзир мөһергә күз төшереп кенә алды да хатны кәтиб Хафизга сузды.

— Вәзир, хат Сәлим ханныкымы? — дип сорады Хафиз.

— Ханныкы, кәтиб, ханныкы. Тизрәк ач та укы. Минем башым әйләнә башлады.

Кәтиб Хафиз әкрен генә төргәкнең җебен өзде, аннары кычкырып укырга кереште. Хат укылып чыккач, вәзир төргәкне үзенә алды һәм Баян баһадирга боерды:

— Баһадир, тиз арада кабер казыгыз! Әмер бир азатларыңа! Кабер күз ачып йомганчы әзер булсын. Без читкәрәк китеп торабыз. Сасы искә түзмәле түгел.

— Сәлим хан җирәбә салып, оланнарның берсен яңа кала нигезенә корбан итәргә боерган,— диде кәтиб Хафиз.— Мөмкин хәлме бу, казый Саксин?

— Хан боерыгы үтәлергә тиеш! — диде казый.

Вәзир хатны янә бер кычкырып укып чыкты.

— Оланнар, сез дә тыңлагыз, барчагыз да тыңлагыз! Менә ни яза хан: «Вәзир Исхак, мин сиңа илемне ышанып тапшырдым. Син һәрчак миңа тугры булдың. Хәзер янә бер боерыгымны үтә. Бабаларыбыз йоласын тотып, Чияле тауда Гали белән Булат оныкларыма җирәбә салдыр. Кайсысына җирәбә чыга, шуны яңа кала сарае салынасы төбәккә корбан иттер. Болгар ханы Сәлим. Миляди белән 1177, һиҗри белән 573 елдыр».

Азатлар ашык-пошык кабер казый башлады. Тирә-юньгә көл тузаны күтәрелде, янә көйгән сасы ит исе таралды.

Баян баһадир бу хәлгә ышанып җитмәде, вәзир шаярта дип уйлады, гәрчә вәзирнең һични кыла алмавын белсә дә, баһадир әле аңа, әле казый Саксинга, әле оланнарга карады. Оланнар бу хәлне чынлап та уен гына итеп кабул иттеләр бугай, хәтта көлемсерәбрәк торалар иде. Баян баһадир өчен гаять зур сынау башланды. Ни кылырга тиеш ул? Вәзир Исхакны туктата алмый, мәгәр аңа каршы тора ала. Юк, барысы да юри генә эшләнәдер. Болгар халкының кайберсе, йола куша дип, әле булса мәет янына өч көнлек ризык куя. Нигә кирәк ул ризык адәм баласына теге дөньяда, үлгән кеше ашый буламы?

— Чөегез көмеш тәңкә, кәтиб Хафиз! Кылыгыз хан боерганны!

Вәзир торган саен зәһәрләнә бара, аның һәр боерыгына ихласлык төсмере өстәлә иде.

— Кем кайсы ягын ала? — дип сорады кәтиб Хафиз оланнардан.

— Мин көн ягын яратам. Көн ягы миңа,— диде Гали олан.

— Миңа...— диде Булат олан һәм елар дәрәҗәгә җитеп йөзен чытты.

Вәзир каты бәгырьле кеше түгел иде, ул оланнарның берсен дә яңа кала нигезенә корбан итәргә теләмәде, ханга киңәшне дә ихлас күңелдән бирмәде, ләкин бу хәл чынга әверелгәч, кире кайтарып алып булмавына да инанган иде инде. Әгәр дә мәгәр бу оланны корбан итмичә Бөек Калага кайта икән, икенче көнне үк хан аның башын кистерәчәк, тикмәгә генә Саксин казыен иярте жибәрмәгәндер. Бәлкем әле шулай булуы хәерлерәк тә булыр. Бу ике олан арасындагы кан коюдан меңләгән гаепсез кеше һәлак булачак, ә монда бер олан, бер җан. Әйе, мин уйлаганча ук җүләр түгел икән шул Сәлим хан.

Вәзир боерыкларны бирә торды, аңа берәү дә каршы әйтмәде, әйе, кем генә вәзир кадәр вәзиргә каршы әйтергә кыяр икән! Ул арада кабер не өлгерттеләр. Әлегә кадәр җиргә капланып яткан кам торып утырды, акрын гына күтәрелде, вәзир янына килде. Көмеш тәңкәне чөеп җибәрделәр.

— Көн! — дип кычкырды тәңкә чөйгән азат.

— Гали олан! — дип кычкырды вәзир Исхак.— Илтегез Гали оланны кабер янына.

Ике азат Гали оланны иярдән йолкып алдылар, вәзир аты янына китереп бастырдылар.

— Гали олан,— диде вәзир.— Ир бул! Урының җәннәттә булыр, гөнаһсыз китәсең...

— Вәзир,— диде кам.— Мин сезне бу бәладән коткара алам. Оланны миңа бирегез. Мин аны үзем күмәм. Еланнар патшасы алдында язгым зурдыр, мин үземне аның алдында акларга телим. Аждаһа хәлемә керер дип уйлыйм.

Вәзир көлемсерәп куйды. Кам Чияле тау төбәгеннән еланнар патшасын куам диган булып, кәтиб Хафизның атын яндырды, дөресен әйткәндә, кам бу төбәкне алтынга сатты. Хәйләкәр, хәйләкәр ул. Ә хәзер олан белән... Хәер, күмә бирсен, язгы чынлап та үзенә булыр. Аннары бер азатны үлемнән коткарыр. Чөнки вәзир хәзер Гали оланны бер азатка, бәлкем әле икесенә үк оланны күмәргә кушар. Чөнки ни баһадир, ни казый, ни кәтиб, ни үзе моңа бармас. Исхак белә иде, оныгын яңа кала нигезенә күмгәнне ишеткәч, кем күмде дип сорар һәм халык алдында, бигрәк тә Гали оланның атасы белән анасы алдында акланырга теләп, кыргыйлык эшләгәнсез, дип, күмүчеләрнең башларын кистерер.

— Барың, кылың! — диде камга вәзир.

Кам оланны житәкләде дә Чияле тау башына таба алып китте. Тауга менеп басуы булды, аның янында бер эт, тәүге ике егет пәйда булдылар. Кам Гали оланның киемнәрен салдырды һәм эткә япты, ә Гали оланга озын ак күлмәк кигерде. Гали олан булган хәлгә ышанмый, шуңамы, сүз әйтергә дә кыймый тора, кам ни куша, шуны эшли иде. Кам кабер тирәли олан белән бергә әйләнеп чыкты, ә эт исә аларга ияр де. Аннары туктады да этнең колагына нидер пышылдады, эт шаманның битен ялады, нидер сизенеп, шыңшыды. Кам икенче бер ак күлмәк чыгарды, аны карачкы сыман итеп таягына элде. Элде дә кабер балчыгына кадады. Һәм янә кабер тирәли тугыз тапкыр әйләнеп чыкты һәм күз ачып йомганчы ак күлмәк кигән оланны кабергә ташлады, аның артыннан кабергә эт сикереп төште. Кам үзе һаман кабер тирәли йөгерде, үзе әзмәвердәй егетләренә тиз-тиз каберне күмәргә кушты. Егетләр каберне бик тиз өеп куйдылар һәм капылт юкка чыктылар. Кам кабер өстенә таягын кадады һәм кәтиб Хафиз янына килде, баш иде.

— Кәтиб Хафиз,— диде вәзир, букчасыннан бер янчык алтын чыгарып.— Бир шуңа минем исемнән янчыкны.— Аннары һәммәсенә дә мөрәҗәгать итте: — Инде Гали оланның яңа кала нигезенә корбан ителүен барыгыз да күрдегезме? Күрдегез! Әйдә, баһадир, юлга кузгалыйк!



## 6

Сәүдәгәр Бикколның булмаган иле юк иде, диярлек. Ак җилән кигән гарәпләрдә дә булды ул, Димәшкъ сәүдәгәрләре белән дә аралашты, кара чикмән өстеннән кызыл билбау буып йөргән әрмәннәр аша Багдадка да барды, киндер бау белән билләрен буган яһүдләр иленә дә сугылды, аңа хәтта маңгайларына кара миң төшергән һиндуслар һәм кысык күзле табгачлар илендә дә булырга туры килде. Биккол җиде-сигез телдә сөйләшә, күп халыклар белән аралаша, кеш тиресе белән бүрекләре каелган Владимир сәүдәгәрләре аның якын дуслары, кара сакаллы Кияүкала товар ишләре белән тыгыз элемтәдә тора, Новгород сәүдәгәрләре белән очрашкан саен бүрек алыша иде. Сәүдәгәр Биккол уенча, илне куәтле итүче чара — сәүдә. Гомерен сәүдә эшенә багышлаган кешегә ул бик күп вазифалар йөкли. Чын сәүдәгәр үз ишләренә һәрчак ярдәм кулы сузарга, алар телендә сатулаша белергә, кирәк икән, әҗәткә акча биреп торырга да тиеш. Шушы сыйфатлары булмаган сәүдәгәр бик тиз бөләчәк. Казан елгасы тамагына салынасы Базаркалага ул зур өметләр баглый, аның икенче Ага Базар буласына иманы камил иде. Сәүдәгәр Биккол хан казнасына һәрчак керем китерде, чит илләрдән мең төрле гыйбрәтле хәбәрләр алып кайтты, ә менә кәтиб Хафиз сораган маңгелләр хакында ишеткәне булмады. Аның барысы да көйләнгән, барысы да җайланган чакта гына үзе белән илдән илгә ияртеп йөргән угланы вафат булды. Аңа Биккол зур өметләр баглый иде. Фаҗигадән соң миңгерәүләнеп калды. Менә шунда аңа Хафиз хан оныгын тәкъдим итте. Угланлыкка ук түгел, мәгәр үз оланы кебек үк күрә икән, күрсен, иң мөһиме, яшертен генә Өргәнечкә алып китсен.

Хан сәүдәгәре башта моңа ышанмый торды, Хафизны шаярта дип уйлады, әмма соңыннан барысы да ачыклангач, шатлыктан үз-үзенә урын табалмый башлады.

Кеше үлә — халык үлми, диде ул фәлсәфәгә бирелеп. Бу — хакыйкать. Дөньядагы һәммә нәрсә үзгәрергә мөмкин: йола, дин вә иман, ә менә халыкны алыштырып булмый, халык — мәңгелек. Халыкның дине, теле алышынганда да гореф-гадәте, хезмәткә мөнәсәбәте, сәнгате кала, ягъни җырланган җыры, әйткән такмагы кала. Җир йөзендә бары тик ике нәрсә үлемсездер — истәлек һәм хәтер. Әгәр дә мәгәр кем дә булса сиңа: «Хәтерем калдырдың»,— дип әйтә икән, димәк, син ул кешене бик нык рәнҗеткәнсең, ата-бабаларының иң изге, иң кадерле булган истәлекләренә кагылгансың. Истәлек буыннан-буынга күчә килә, ул һәрчак үткәнне искә төшереп, искәртеп тора. Үткәне булмаган халыкның киләчәге дә булмавы мөмкин. Бары тик үткәнне хәтердә саклап кала алган халык кына киләчәккә зур өмет баглый ала.

Биккол тумышы белән Болгардан иде. Үсмер чакта ук атасы аны үзе белән йөртте. Бикколга җиде яшь тулганда әнисе вафат булды. Үсмер чакта ук атасы аны Өргәнечкә алып китте. Монда атасы икенче хатынга өйләнде. Үги ана янына сыймады Биккол, бабалары янына Бөек Калага кайтып китте. Балигъ булгач, аны бабасы бер сәүдәгәргә эшкә бирде. Бераз кул очына акча керә башлагач, иясе йомышы белән Өргәнечкә китте. Анда килсә, атасы вафат, үги анасы берүзе дөнья көтә, атасы җыйган мал таралып-сибелеп бара. Өргәнечкә барганда Биккол бер хикмәтле хәлгә тап булды. Саксин каласына җиткәч, кәрван елга буена туктады. Барысы да йокларга яттылар, шунда кәрванбашы Биккол янәшәсенә сарык түшкәсе китереп салды, ә аны үз янына алып китте.

Иртәнге якта уянып, кичтән яткан урынына килсә, ике күзе дүрт булды: түшкәгә терсәк буе хәнҗәр кадалган иде. Шул көннән алып Биккол Өргәнечкә җиткәнче төннәрен күз-керфеген йоммады. Ни өчен аны үтерергә теләделәр? Кем? Ул черегән бай сәүдәгәр түгел, кесәсендә нибарысы өч алтын, аны да берәүнең дә күргәне булмады лабаса. Өргәнечкә барып җиткәнче кәрванда булган кешеләрне күзәтте, әмма берәүдән дә шикләнә алмады. Өргәнечкә җитеп, үги әнисе өенә килеп кергәч кенә эшнең асылына төшенде. Ул анда кәрванда булган бер таныш йөзне күрде. Аңлады: үги анасы җибәргән булган ышбу адәмне. Шул ук көнне Биккол атасы тарафыннан үзенә васыять итеп калдырган әйберләрне алды да Болгарга кайтып китте. Бикколның канында сәүдәгәр шаукымы бар иде. Болгарга кайтуга, ул Ага Базарга юнәлде, бабасының ярдәме белән зур булмаган кибет сатып алды. Шул көннән аңа сәүдә чире кагылды.

Ике-өч елдан ул Ага Базарда күренекле сәүдәгәрләрнең берсенә әверелеп китте, моңа, әлбәттә, бабасының вафат булуы һәм аның барлык байлыгы Бикколга калуы да ярдәм иткәндер. Егерме биш яшендә Биккол Бану атлы кызга өйләнде. Бану аңа ел саен кыз бала тапты һәм кызлар яшьләрен дә тутыра алмый үлә тордылар. Ниһаять, Бану малай тапты һәм әллә инде саклабрак караганга, малай туп кебек булып ай үсәсен көн үсте, күп тә үтми атасының кул арасына да керә башлады.

Кәтиб Хафизның тәкъдименә куанычы бер дә тикмәгә генә түгел иде Биккол сәүдәгәрнең. Ул олыгаеп бара иде инде һәм байлыгын, җыйган малын калдыру өчен аңа углан кирәк иде. Ә угланы, бахыр, унжиде яшен дә тутырыр-тутырмас дөнья куйды.

— Кәтиб, хан оныгын миңа бирүең ихластан булса, мин сиңа ат башы кадәр алтын бүләк итәрмен.

— Син ул угланны камнан сатып алырсын, Биккол. Юлдашларын шаһит булсын...

— Димәк, кәтиб, мин Бөек Калага кермәскә тиеш булам. Кулыма төшү белән олан минеке булыр, шул көннән алып ул ата-анасын да, туган-тумачаларын да онытырга тиеш булыр. Кыскасы, Гали олан атасы Хаҗи өчен дә, хан өчен дә вафаттыр.

— Вафат түгел, Биккол, без аны яңа кала нигезенә корбан иттек. Без, вәзир Исхак, Саксин казый һәм мин. Исеңдә тотсаң иде, Биккол, кайчан да булса Гали олан Бөек Калага әйләнеп кайтыр да тәхеткә утырыр. Мин аны карарга казый Нисбахны Өргәнечкә җибәрәчәкмен. Ул угланны эзләп табар һәм шәех Пәһлеван Мәхмүткә тәрбиягә бирер.

— Тагын ни, Хафиз?

— Сәлим хан чик буйларына ышанычлы йөзбашларын җибәрде. Сине туктатулары бар, Биккол. Оланны син камнан кол итеп сатып алдың. Шул хакта онытмасаң иде. Хан Болгардан берәүне дә чыгармаска дип боерды.

— Бу хәл миңа кагылмый, кәтиб Хафиз. Мин хан сәүдәгәре.

— Кам олан белән сине Чияле тау итәгендә көтеп торыр. Аңа алтының кызганма, әйткәнемчә, янында шаһитлар булсын.

— Барысы да хак булса, бу хәл минем үземә дә бик тә кызык булып китте әле, кәтиб. Кушканнарыңның барысын да эшләрмен, эшләрмен...

## 7

Сәүдәгәр Биккол Казан кирмәненнән иртәнге якта чыгып китте, Чияле тау итәгеннән узган юлга якынлаша башласа да, кәтиб Хафизның кичәге сүзләренә ышанып җитмәде. Юк, ул аңа ышана иде, мәгәр барыбер күңелендә берчак кына шик бар иде. Биккол күпне күргән кеше, аны алдадылар да, ялганлап та киткәләделәр, мәгәр әлегә кадәр бер-

кайчан да мондый хәлгә тап булганы юк иде. Хак булса, кәтиб уен уйнамаса, тиздән хан оныгы аның кулында булачак. Ышанырдай хәлме!

Юл өстендә җан иясе күренми, ә Чияле тау инде менә кул сузарлык кына арада. Әйе, сайлый белгәннәр яңа калага урынны хан куштаннары. Алга баксаң — киң Идел, уңга баксаң, уйдык-уйдык болыннар, тугайлар, сулга баксаң — урман, ул офык читенә барып тоташа сыман. Юлда берәү дә юк. Бернинди кам да, хан оныгы да көтми аны. Биккол ике юлдашын дәшеп алды, атыннан төште һәм җәяүләп Чияле тауга менә башлады. Анда, Чияле тауның нәкъ түбәсендә диярлек, чынлап та кабер бар сыман иде. Юлдашлары теләр-теләмәс кенә аңа ияределәр. Әллә соң чынлап та хан оныгы Галине яңа кала нигезенә корбан иттеләрме? Йә хода, кай тарафка тәгәри бу Болгар? Биккол кабер янына җитте һәм кичә генә бирелә булган фаҗигале хәлне күз алдына китерергә тырышып карады. Кем алдады аны? Вәзир Исхакмы, кәтиб Хафизмы? Үземе үзен алдарга теләде? Чөнки угланы үлгәннән соң җанына аз гына булса да җиңеллек килмәсме дип уйлавы иде...

Күзләрен ачты һәм исе китеп, чак кына авып китмәде. Аның каршында диярлек, чия куаклары янында, кам белән хан оныгы Гали басып торалар иде.

Биккол сәүдәгәр үз-үзенә ышанмый янә күзләрен йомды, янә ачты. Булган сурәт хак иде: аның алдында кам белән хан оныгы Гали басып торалар.

— Кам, колыңны сатасыңмы? — дип сорады Биккол кәтиб өйрәткән сүзләрне буташтырып.

Кам оланны Бикколга таба этебрәк җибәрде. Гали олан үксеп китүдән чак кына тыелып Бикколга таба атлады, килде дә сәүдәгәрнең күкрәгенә капланды. Бикколның аскы ирене килешсез калтырана башлады, ул оланны кочагына алды да күз яше белән елап җибәрде.

— Вафат булган угланыма охшаган ышбу бала, кам, шаккатма,— диде Биккол һәм аңа бер янчык алтын ташлады, тәге янчыкны тотып алды да түшенә тыгып куйды һәм кисәктән юкка чыкты.— Елама, Гали олан, елама. Әйе, үзем дә елыйм шул. Сине күргәнгә. Онытмагансыңдыр ич Биккол аганны? Юкмы? Шулай диген. Хәзер син минем белән сәфәр чыгасың, еракка-еракка.

8

Картая барган саен хан колы — осталарның остасы Алпар өчен көннәр дә озая бара кебек тоела башлады. Яшьрәк чакта кояш чыгарчыкмас эшкә керешер, кич кояш баеганчы баш күтәрми эшләр иде. Оста Алпар биле катып китә башлагач, таш өстенә утырды, сарай салучы меңләгән ташчыларга күз төшерде. Кай тарафлардан гына юктыр монда ташчылар. Кырмыска кебек мәш киләләр. Ташчылар сарай тирәләрен җыештыра, сарай күтәрелде, бизәү эшләре дә инде төгәлләнеп килә. Бизәк төшерүчеләр көн-төн эшли, ташчылар мунча салырга күчтеләр. Бизәк төшерүчеләр арасында аның улы да бар, бердәнбер дәвамы, Дәүраны. Оста Алпар оланын ярата, ярата дию генә аз, ул ансыз яши алмас кебек, шулай ук хатыны Туйбикәсез дә яши алмас кебек. Хак анысы, Туйбикәгә булган мәхәббәте башка, ә улына булган хисе башка иде. Тел белән әйтеп кенә бетерә алса икән ышбу ике кешегә булган мәхәббәте хакында!

Алпар этисен дә, әнисен дә белми иде. Аны биш яшьлек чагында гарәп дәрвише оста әрмәнгә сатып китте. Болгарда гомер кичергән дәрвишләр үзләренә кол итеп малайлар сатып алалар иде. Мәгәр теләкләре изге булса да, ачлы-туклы йөргән дәрвишләр, хәлләре мөшкелләнә башлагач, еш кына юк кына бәһагә малайларны теләсә кемгә бирен китәләр

иде. Әрмән остасы Бабаҗан Алпарны җиде яшеннән осталыкка өйрәтә башлады. Каты бәгырьле булмаса да, эшне җиренә җиткереп башкармаганда кечкенә Алпарның колагын борырга да күп сорамый иде оста. Картаеп тәмам йөрер хәле калмагач, мәетен ханнар зиратына күмдерү исәбенә, Бабаҗан оста Алпарны Сәлим ханга кол итеп бирде.

Әнә шулай ундүрт яшендә Алпар Сәлим хан колы булып китте. Шунысы да хак, хан аны беркайчан да рәнҗетмәде, кул күтәреп сукмады һәм башкалардан да суктырмады, шуңа күрә оста Алпар ханга ихлас күңелдән хезмәт итте. Кысыр хатыны Туйбикәне кияүгә бирүе дә шуннан — останы хөрмәт итүеннән иде булса кирәк. Ханның бу бүләгенә (Алпар Туйбикәне иң-иң зур бүләк итеп кабул итте) оста җанын уч төбенә салып илтеп бирердәй булды.

Көннәрдән бер көнне вәзир Алпарга, хан сараеннан ким булмасын дип, үзенә йорт салырга кушты. Ул вакытта ирек хакында бөтенләй уйламый иде әле Алпар, гел: «Хан мине хөрмәт итә, сабыр итим»,— дип ирек хакында сөйләшүне кичектерә килде. Ә менә вәзир: «Өйне бер дигән итеп сала алсаң, мин сиңа ирек бирәм»,— диде. Моңа бик үк ышанып җитмәсә дә, оста Алпар беренче тапкыр зәңгәр һавага күтәрелеп караган иде. Биектә-биектә, күз күреме ераклыкта горур тилгән әйләнә иде.

Оста Алпар нәкъ вәзир теләгән өйне салып бирде, ә инде бизәү мәсьәләсенә килгәндә, өйгә кергән кеше тиз генә чыгып китә алмый йөрер иде. Вәзир өе турында хәбәр сарай куштаннарына килеп җиткәч, өйне карарга Сәлим хан үзе килде. Өйне хан ошатты, останы мактады, әмма вәзир, «кол остага ирек бирик», дип әйткәч: «Кол кемнеке, вәзир, синекеме, минекеме?!» — дип ачуланды.

Оста Алпар шунда хан алдында тезләнеп: «Галиҗанәбем, шөһрәтлем...» — дип башлаган иде, хан аңа сүзен әйтеп бетерергә бирмәде. Колны җан сакчыларына торгызырга боерды. Шунда бер хикмәтле хәл булып алды. Хан алдына вәзир тезләнде: «Ханым, колга ирекне мин вәгъдә иткән идем, бирик остага ирек!» — диде. Хан вәзирне таягы белән төртеп аударды да: «Бик кәмитләнсәң, вәзир, үзеңне кол итәрмен»,— дип китеп барды.

Алпар булган хәлдән соң тәмам өметен өзде. Шул ук вакытта бик үк баш алып кайгырмады да. Хан аңа Туйбикәне биргәч, өй салырга рөхсәт итте. Үзе теләгәнчә өй салып кергәч, оста Алпар тынычлана калды. Ул бәхетле иде. Сәер хәл, ничек инде кол үзен бәхетле санасын, дип әйтүчеләр табылыр, әмма оста Алпар бәхетле иде. Чөнки ул күк гөмбәзендәге йолдыз уч төбенә төшеп кунасына ышанырга әзер булса да, Сәлим хан: «Туйбикәне сиңа бирәм»,— дигәч, ышанмый торган иде. Туйбикә аның сөюен ничек кабул иткәндер, Алпар өчен дөнья һәрчак караңгы иде, әмма Туйбикә килгәч, оста җирдән түгел гүя һавадан йөри башлады. Әле булса хәтерендә, хан аңа Туйбикәне илтергә иш ат җигеп җибәрде. Өйгә килеп керүгә, бизәкләргә карап торды Туйбикә, аннары ни әйтергә белми аптыраган Алпардан сорап куйды: «Колларың алтын икән, ир-канат, үзең ясадыңмы?» — диде. Һәм зур гәүдәле, киң күкрәкле, бераз гына ир-ат исе килеп торган Алпарның күкрәгенә килеп капланды да пышылдап кына: «Мин сине яратырмын, Алпар, менә күрерсең, яратырмын»,— диде. Хан хатыны Туйбикә шул көннән аны чын ире итте.

Аннары бергәләп дөнья көтә башладылар. Аксөякләр гаиләсендә туып үскән Туйбикәгә үзе дә төшенеп җитмәгән мәхәббәт килде, ул ир-канатның эштән кайтканын көтеп ала алмый башлады, кайчак хәтта каршы алырга баргалады.

Бергә булганда, яратып сөешкәндә Туйбикә ир-канатының куенына сыенып иде дә: «Менә күрерсең, мин сиңа бер малай табып бирәм»,— дип тәкърарлар иде.

Әллә инде фәрештәләрнең амин дигәненә туры килде, әллә ханнан килгән хатынның теләге бик зур иде, еллар үтүгә, Туйбикә чынлап та балага узды. Менә шунда инде ул, гүяки, күккә ашты. Менә бит син

аны, ир-канатың бик яратса, ниләр була икән. Рәхмәт сиңа, Алпарым, мең-мең рәхмәт!

Бала тапкач, җитмәсә угыл да булгач, Туйбикә тагын да түгәрәкләнеп, матураеп китте. Урамнардан Туйбикә үткәндә ирләр туктап калыр, гүзәллегенә сокланудан тел шартлатырлар иде. Бирсә бирер икән адәм баласына гүзәллекне! — дип калырлар иде. Туйбикә Алпарыннан башка берәүне дә күрмәде. Ир генә түгел иде инде ул аның өчен, пәйгамбәр үзе иде.

Аттан — ат, коштан — кош туар, диләр. Охшаса охшар икән Дәүран да атасына. Җиде яшендә үк аның кул астыннан шундаен бизәкләр чыга башлады ки, шаккатмалы иде. Әүвәл башта ата кеше углының эшен күрмәмешкә сабышты, иллә тора-бара баласы ясаган бизәкләрне күреп, чарасыз туктап калды — соклангыч иде бизәк, өлкән бизәк төшерүчеләрнекеннән дә камилрәк иде. Шуннан Алпар улы ясаган бизәкле бер ташны хатыны Туйбикәгә алып кайтып күрсәтте. Сәере шул булды, моңа Туйбикәнең артык исе китмәде, ә ир-канатын шаккатырып: «Алпарым, улыбыз оста гына түгел, хан янында хан буласы кеше»,— диде. Оста Алпар өзелеп яраткан хатыны Туйбикәдән бу сүзне ишетте дә ачкан авызын ябалмый катып калды.

— Ни сөйлисең син, Туйбикә,— диде ул, ниһаять, исенә килеп.— Тузга язмаганны! Ханнар аллаһы тәгалә тарафыннан куела. Тәүбә диген, барысы да алла кулында.

— Әлегә чаклы куелган ханнарда минем катнашым юк, ә менә Сәлим ханнан соң улыңның хан булып куюы бар. Моңа иманым камилдер, Алпарым,— диде хатын.

— Йә, хода, Туйбикә. Авызыңнан җил алсын. Оста безнең олан, зур оста. Күр әнә нинди бизәк төшергән, күргән саен күрәсе килә.

Туйбикә шунда гына ак ташка төшерелгән бизәккә чын-чынлап игътибар итте. Сурәттә кояш чыгып килә, аста Иделкәй, Иделдә аккош, ялгыз аккош янына икенче берәүсе төшәргә җыена. Сибелеп киткән кояш нурлары бигрәк тә матур, чынлап та күз алмаслык сокланггыч иде. Иделдәге аккош һавадагы ишенә башын кырын салып караган, ә тегесе дустанә тавыш белән: «Мин монда, мин монда!» дип кычкыра сыман иде.

Туйбикә канәгать калды углы эшеннән, әмма аның максаты бөтенләй башка иде — углын хан итү. Һәм ул хан булыр да. Хәзер әнә Дәүранга унҗиде яшь тулып килә, тиздән, бик тиздән ул хан кызына гашыйк булыр, бәлкем булгандыр да инде һәм хан кызы да аның гыйшкына битараф калмас — менә шунда күрерсең, Алпаркаем, углыңның кем булуын, дип уйлады.

Әле балага узгач та, нидер сизенеп, Туйбикә кендек әбисен чакырып алды: «Зөбәрҗәт тә авырга уздымы әллә?» — дип сорады. «Ие-ие, Туйбикәм!» диде тегесе. Ә инде тугыз ае җитеп тулгакка калгач, хәле мөшкел булуына карамастан: «Зөбәрҗәтнең кеме бар?» — дип кызыксынды. «Ханбикәнең кызы бар», диде кендек әбисе. «Минеке ул булыр»,— диде Туйбикә тулгакка чыдый алмый иренен чәйни-чәйни.

Һәм шулай булды да.

Малай тапкач, Туйбикәнең шатлыгы эченә генә сыймады, тышка да бәреп чыкты. Хатын-кызга үзе теләгән кешедән, үзе теләгән бала табудан да зур бәхет бармы икән. Әйе, колдан булмагае шайтаннан булсын, тик яраткан җаныңнан булсын, тик ул теләгән олан булсын. Ул табуын Туйбикә хода ярдәменнән күрде һәм бу теләге кабул булгач, янә бер теләгенә юл юрады — углы хан кызы белән кавышырга тиеш. Әйе, аларга кавышырга язган, язмаган булса, бу хәтле туры килмәс иде, бер төндә, бер таңда диярлек таптылар, бер көндә исем бирделәр.

Кемгә дә сер түгел, сер итеп сакламады да Туйбикә, Сәлим ханга яратып килгән иде ул. Иллә язмыш аңа аяк чалды — балага узмады, әнә шул кендек әбисенә биргән акчасын санасаң, сарай салырлык бул-

гандыр. Әмма нишләмәк кирәк, кемнәргә генә күренмәсен, нинди өшкерүләр генә кичермәсен — узмады балага Сәлим хан белән яшәгәндә Туйбикә. Ә кол Алпарга күчеп килгәч, ходайның хикмәте, узды да куйды, тора-тора булса да узды.

Бала тапкач башланды Туйбикә өчен хикмәтле көннәр. Ул белә иде, хикмәтле хәлләрне эшли алса, кендек әбисе эшли ала. Хан сараена, ханбикә Зөбәрҗәт янына бердәнбер кеше — кендек әбисе генә рөхсәтсезнисез керә ала. Көннәрдән бер көнне Туйбикә кендек әбигә әйтте: «Бер таңда туган бу ике баланы балигъ булгач та кавыштыр. Бу эш килсә, синең кулыңнан килә,— дип, карчык кулына бер янчык алтын тоттырды. Кендек әби бу бәһагә Туйбикә өчен авызы белән кош тотарга да разый иде.— Алдыңмы, әби, янчыкны, килештекме?» — дип сорады Туйбикә.

«Килештек, ханбикә»,— диде кендек әби, гәрчә Туйбикә күптән ханбикә булмаса да.

Шушы хәлдән соң кендек әбисе Туйбикә янына килүне ешлатты. Бирелә аңа килгән саен акмаса да тама: аннары хәйләкәр карчык Зөбәрҗәт ханбикәдән дә өлешсез калмый иде. Туйбикәгә килгән саен карчык хан кызы Назлыгөлнең йә бернечә бөртек чәчен, йә күлмәген, я ялтыравык сәдәфен алып килде, ә Туйбикә аларны кадерләп төенгә төйнәде һәм үзе белгәнчә дога укып, йә угланы Дәүранның мендәр астына салды, йә үз куенында йөртте. Бу хакта ул беркайчан да берәүгә дә әйтмәде. Ул кылган эшләр бары тик аның сере, аның хыялы, аның юанычы, аның теләге иде. Хан кызы Назлыгөлгә җиде яшь тулганда аның кимендә чирек әйбере Туйбикәгә күчкән иде инде. Хак анысы, хәйләкәр кендек әби гел Назлыгөлнең генә әйберләрен дә китермәгәндер, мәгәр кыланышы белән йөкләнгән вазифасын ихластан башкара иде. Углына җиде яшь тулгач, Туйбикә ире Алпарга аты-даны Болгарга таралган чирмеш камын китерергә кушты. Хатыны өчен аны гына түгел, һавадагы йолдызны алып бирергә әзер торган Алпар хан сарае караучысыннан арба-ат сорап, юлга чыгып китте һәм ике көн дигәндә янына камны утыртып кайтып төште. Хан кирмәненә камнарны кертмиләр иде, Алпар аңа ташчы киемен кигерергә мәҗбүр булды. Кам өйгә килеп керүгә, артыгын сөйләп ташламагае дип, Алпарына ишегалдына чыгып торырга кушты Туйбикә. Ир-канаты артыннан ишек ябылгач кына Туйбикә камга булган хәлне тәфсилләп сөйләп бирде. Сихерчеме, күрәзәме кам — Туйбикә белми иде, әмма ишеткәне бар иде, үлгәнне терелтә алмаса да, мәчене чыпчык, чыпчыкны карчыга итә ала, имеш. Кыскасы, бала чактан ук төрле могҗизалар күреп үскән Туйбикә камга чын күңеленнән ышана, ә инде углы Дәүран хан кызы Назлыгөлгә өйләнәсе кеше, ул гынамы, хан буласы кеше дигәч, чак кына күрер күзгә яман котсыз кунакны кочаклап үпмәде.

Күпне күргән камның Туйбикә кыланышына бер дә исе китмәде, мондый хәлләргә беренче генә тап булуы түгел иде, күрәсең, хәтта Туйбикә бирәсе хак мәсьәләсен дә кузгатмады, шундук эшкә керешге. Иң әүвәл ул кургашын сорап алды, кургашны табага салып, утка куеп эретте дә ике савытка аз гына су салырга кушты һәм эрегән кургашны шул ике савытка койды. Аннары баланы башыннан алып юрган белән бөркәндерде, кургашын катканчы буда тотты. Эрегән кургаш икесе ике сурәткә кереп катып калгач, баланың өстеннән юрганны алды. Кам каткан кургашыннарга бик озак нидер сөйләде, кулына алып, авыш-тәвеш китерде. Шуннан соң бераз ир-атка охшаганын Дәүранның муенына такты, икенчесен нинди генә юллар белән булса да хан кызы Назлыгөлгә житкерергә кушты. Аты-җае табылмаса: бер төн булса да чүпрәккә төреп, хан кызы мендәре астында кундырырга боерды, чүпрәге угланныкы булсын, диде. Туйбикә кам сөйләгәннәрне дикъкать белән тыңлап һәм ул әйткәннәр белән килешеп, баш кагып утырды. Һәммәсе дә кылынгач, Туйбикә камның уч төбенә дүрт алтын салды һәм ишеккә озата барды. Алай да түзмәде, кунак ишекне чыгып барганда:

— Инде балалар кавышырлармы? — диде.

— Мин аларның җаннарын бергә куштым, калганы тәңре кулында,— диде кам.

Аны капкадан озатып җибәргүгә, Туйбикә кендек әбине чакыртып алды һәм әлеге кургашын кисәген углының күлмәк җиңенә төреп бирде. Кендек әби нинди юллар белән генә булса да аны хан кызы Назлыгөл баш астына куярга тиеш иде.

Алпар хатыны Туйбикәдә бик сирәк була торган куаныч күреп, аптырый калды.

— Шәех Игәнәй фәрештәләр җибәрдеме әллә үзеңә, нигә болай чыгып килгән кояштай елмаясың?

— Фәрештәләр килмәде, карткаем-җаныкаем, өйгә син кайтып керден,— диде Туйбикә. Шулай диде дә елмая-көлә ир-канатының куенына кереп сеңде.

— Аллаһы боерган итсә, атасы, барысы да без дигәнчә барса, менә әйтте диярсең... Әй, Дәүран углым, балакай, бар әле урамга чыгып тор. Ишләрең анда гузналы уйныйлар.

Туйбикәгә өйләнгәнче дә, өйләнгәч тә хатын-кызның эч серләрен беркайчан да белеп бетермәгән һәм бик үк белергә дә теләмәгән (аңа болай да бик әйбәт иде Туйбикә белән), аларның гүзәллегенә сокланудан ары китмәгән, яшереп кенә ничәмә-ничә тапкыр сөеклесенең сурәтен ясарга керешкән, әмма хан шымчыларыннан куркып, ясаган рәсемнәрен төнлә белән Иделгә ташлый барган Алпар, шушы көннән соң тагын да канатланып яши башлады. Углын иң оста бизәк төшерүчегә малайлыкка бирде. «Ите сиңа, сөяге миңа, өйрәт, тыңламаса, чыбыгың кулында»,— диде.

Беренче көннән үк Дәүран углының чүкеч, кискеч тоту чамасын күреп, икенче тапкыр китергәч, карт оста ата кешегә әйтте: «Бу баланы өйрәтәсе юк, кулы алтындыр»,— диде.

*Дәвамы киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ

*А. С. Пушкинның тууына 190 ел*

## А. С. Пушкин

Мәгъдән базларында — Себердә
Түземлекне горур саклагыз сез,
Юкка чыкмас кыен хезмәтегез,
Бөек уйлар сүнмәс сөргендә.

Өмет сезгә куәт, рух бирер,
Бәхетсезлек белән ул бертуган,
Алып чыгар сезне караңгыдан,
Зарыгып көткән гаҗәп көн килер:

Зиндан ишекләре аркылы
Сөю, дуслык барып керер сезгә,
Кергән кебек ерак өнегезгә
Азат тавышым — җырым ялкыны.

Өзелеп төшәр авыр богаулар,
Бар зинданнар хәрабәгә калыр,
Ирек сезне тагын каршы алыр,
Кылыч бирер дуслар-туганнар.

*Нури Арсланов тәрҗемәсе*

Мин яраттым сезне! Мәхәббәтем
Исән әле... Бәлки мәңге сүнмәс.
Тик ул сезне бүтән сискәндермәс,
Борчу салмас, сагышларга төрмәс.

Мең үкенеп, мең көнләшеп сөйдем,
Ялваруга күмдем исмегезне.
Бирсен Ходай: минем кебек шулай
Тагын кемдер сөя алсын сезне.

### Бәхилләшү

Уйларымда иркәләдем сине,
Соңгы тапкыр төрдем сине назга.
Кайтты миңа якты кыяфәтең,
Сагыну кайтты, кайтты мәхәббәтең,—
Кунак булып кайтты — тик бик азга.

Үзгәрә көн, без дә үзгәрәбез.
Якын дустым! Хәзер инде менә
Җуйдың мине. Үзең җуеласың:

Томан гына булып тоеласың
Сине җыр дип йөргән шагыйреңә.

Бу хушлашу сүзе йөрәгемнен—
Карышмыйча сыйдыр үз җаныңа,—
Тол хатындай... йә дус дустын җуеп,
Сүзсез генә башны башка куеп,
Озаткандай аны зинданына.

*Нияз Акмалов тәрҗемәләре*

# Анна Ахматова

●

Юатырга теләп дәште миңа,
Югарыдан аваз иңде дә:
«Гөнаһлы һәм өнсез илең калдыр —
Рәсәеңне калдыр мәңгегә.
Кулларыңнан канны юармын мин,
Йөрәгеңнән — оят тапларын.

Җиңелү һәм рәнҗү әрнешләрен
Яңа исем белән капLармын».
Мин битараф, салкын кулым белән
Колагымны каплап бәсләдем:
Мескен тавыш, мескен сагыш белән
Мәсхәрәләнмәсен мәсләгем...

●

Юк, китмәдем алар — авыр чакта
Илне ташлап качканнар белән!—
Андыйлардан ялган наз-дан алмам,
Җырларымны биреп — мин беләм...

Тик кызганып карыйм мөһаҗиргә:
Авыру тоткын яки имгәк ул.
Әй, юлыгыз кыен, мөсафирлар,
Әрем тәмле — сезнең икмәк ул.

Ә без монда янгын-утлар кичеп,
Яшьлекләрнең соңын үткәрдек.
Тайчанмыйча каршы алдык — җанга
Төшкән һәр таякны күтәреп...

Һәм беләбез: һәр сәгате чорның
Акланыр ул бер көн, җөпләнер...
Тик булмастыр илдә бездәй буын:
Яше кипкән... горур... тәкәббер!

## Дога

— Бир миңа чир,
Бир миңа, бир
Елатып егар елларны...
Ал миннән, ал,
Баламны ал,
Дустымны ал, син җырларны.—

Һаман дога кылам шулай
Җеназаң торган урында,
Рәсәй өстендәге болыт
Өртелсен дип таң нурына.—
Дан нурына...

●

Бер-беребезне каргаганда,
Һәм дәрт уттан бузарганда,
Ике йөрәк өчен — хәтта
Җирдә — урын булмаганда,
Яндырганда ярсу хәтер,
Бөек җәза йөдәткәндә,
Йөрәгең төпсез төннәрдә:

«Киткән дустым минем кая?»—
Дип сорарга өйрәткәндә,
Янган чакта ладан, төтәп,
Яңгырап, хор янаганда,—
Котылгысыз, кырыс күзләр
Бага һаман... җанга бага.

*Ләис Зөлкарнәй тәрҗемәләре.*

# Карой Чех

## Алтын-көмеш

Түбәдәге буй-буй шифер
зәңгәр күккә кадакланган кар көртләре кебек;
салкын сентябрь иртәсендә
үгез селәгәенең җепләре көмешләнә,
әмма
аста әле җете балкый
карга миләшенең
куе тәлгәше.

Трибуна кебек кәпрәйгән үрдә
бер бала басып тора —
үзе библиянең җиде елыдай ябай —
үлү-үчүне инкяр итеп,
хакыйкать балкышының
көнбагышның алтын таҗы сыман
мәңгелек булуы хакында
хәбәр бирә.

## Кышкы тылсым

Ак мәрмәрдәй җемелди кар бакчасы...
Күз карашы таелып китә дә йомры-йомры көртләрдән
көмешләнгән чия кәүсәсе буйлап
үрмәли өскә.
Кәүсәсенең —
хәтерендәме?—
июнь аенда муеныңнан ничек сыйпады кулы!
Хәзер туңган бармак очларыннан
йокыга талган бөреләргә
тамчылап саркый җылы.
Төне буе котырынган
ап-ак тылсым
йолдызлыкларга әверелдергән
ботакларны,
чәч кыстыргычларыңны, күзләреңне...
Һәм барысы бергә
күк гөмбәзендә балкыйлар
карашларын миннән ала алмаган
бозчыклардай.

## Тоз кебек ак

Болганчык су кебек дөнья
миндә тона;
күңелем тугайларында тузганаклар
кристаллашкан тоз юшкыны сыман.

Маңгаемдагы җыерчыклар —
икегә сынган балдак;
хатынымның йөзе тирәли
иртә килгән җәйнең күбәләкләре әйләнә:
аерым челтәрләргә таркалган
туй фатасы...

Утызның аргы ягында
факт арына
бизәкләрдән.

Тоз кебек ап-ак минутлар җемелдәшә
көннәр төпкелендә,
юшкын булып куера
хәтер.

Тоздай чиста, сукрайтырлык ап-ак
кәгазьгә төшкән ике юл сүзгә
сыеп бетә бөтен гомер.

*Ренат Харис тәрҗемәләре.*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Барлас Камалов

# УЗГАН ГОМЕР БИГРӘК ҖӘЛ

ПОВЕСТЬ

## I



Кичә котым очып уяндым. Таң алды иде. Абзарында ләтчә изалаган ат шикелле, шабыр тиргә батканмын. Йөрәкнең кагуына чик-чама юк. Күңел болгана...

Шушы халәттә күземне ачып җибәрү нидәнме? Куркыныч төш күрдем.

...Җиде төн уртасы икән. Күк гөмбәзендә ник бер йолдыз җемелдәсен!

Кемдер, җилкә тамырыма төя-төя, мине кара ябалдашлы куаклар арасыннан — бормалы сукмактан каядыр алып бара. Мин карыша да, әрепләшә дә алмыйм. Бара торгач, текә яр буена килеп життек.

— Хәзер мин өчкә кадәр саныйм да эшең бетте! Йә үзең аска сикерәсең, йә мин мәтәлдерәм! — Бу сүзләрне гөбедән чыккандай калын тавышлы адәм әйтте. Аның буй-сынын да, йөзен-чыраен да күрер хәл юк. Ул минем артыма баскан. Гыж-гыж сулый, тешләрен шыкырдата.

Ә аста — упкын! Аның төбе бу караңгыда күренми, җан өшеткеч суык бәреп торган тирәнлек икәнлеге генә абайлана.

— Бер!..

Минем күз алдыма төн карасыннан да кararак пәрдә элена, тез буыннарым калтырый, гәүдәм сыгылып төшәргә тора. Ялвара алмыйм, телем аңкавыма ябышкан.

— Ике!..

Шул чак тармаклы-тармаклы булып яшен яшьни, бөтен тирә-юньне күзләрне камаштырырлык булып яктыра. Упкын ярындагы кыя-ташларны күреп алам. Дөнья җимерердәй итеп күк күкри. Мине мәтәлдерергә әзерләнгән бәндә дә тынып тора. Ул да шүрли, күрәсең.

Ышанырлык та түгел, кинәт янәшәмдә генә көчле кырыс тавыш ишетелә:

— Ах, кабахәт! Упкынга ташламакчымы? Мә, алайса! — Пистолет шартлый. — Рамазан! Артка ау!

Мин чалкан егылам. Шул мизгелдә берәү тартып торгыза да әйтә:

— Уңга киттек! Кояш чыгышына!

---

Барлас КАМАЛОВ *(1930) — прозаик, публицист. «Урамнар киңәя», «Канат ярганда», «Ярсыяр ярдәмәсе» һ. б. китаплар авторы. ТАССРның атказанган культура хезмәткәре.*

Мин ни хәлләр итәргә дә белмим. Әҗәлдән йолып калган мәрхәмәтле затка тел әйләндереп рәхмәт әйтер хәлем дә юк...

Шундый төштән соң кабат йоклап китү мөмкин түгел иде инде. Бер бүлмәле фатирымның көнтуар тарафка караган тәрәзәсе буена килеп бастым. Бүлмә җиләслегеннән җанга-тәнгә аз булса да ярау алдым.

Күк гөмбәзе читенә аксыл тасма сузылган. Акрын-акрын гына аңа сыек кызгылтлык өстәлә. Мин, гомеремдә беренче мәртәбә таң каршылаган төсле, хәйран-гашыйк булып басып торам. Менә әлеге тасмага алсу төс керде. Әйтерсең лә һәр мизгелдә аңа берәр тамчы нур тама да, балкышлырак итә.

Күп тә үтмәде, чын-чынлап яктыра башлады. Күгелҗем-кара томан эреп юкка чыкты. Баягы тасма урынында кояшның беренче нур-сеңгеләре күренде...

Шул сәгатьтә мин, ни сәбәпледер, күргән төшем белән таң атуны узган гомерем һәм бүгенгем белән чагыштырдым. Аннары, тирән уйга батып, инде ничәнче тапкырдыр, үз-үземне каһәрләдем. Хәвефле юл башын эзләп, үткәннәремә кайттым. Ул кара сукмакның очын тапкандай булдым...

Ә бүген җаныма тамган нурлардан әйләнә-тирәм якты! Мин Аны күрдем, Назирәне! Элекке хатынымны, улым Рамил белән кызым Гөлзаданың әнисен.

Үзебезнең күпер төзү конторасына кереп чыккач, йомыш белән Куйбышев мәйданына төшкән идем. Эшләремне түгәрәкләп, троллейбус тукталышына килдем. Мин дә килеп җиттем, троллейбус та китеп барды. Икенчесен көтеп алдым. Салонга узсам... ул!

Бер шәһәрдә яшәп тә өч ел очрашканыбыз юк иде. Әллә нишләп киттем. Тәнем эсселе-суыклы булып алды. Йөрәк күкрәк читлегеннән каядыр аска шуышты шикелле.

Ул да бөтенләй ваемсыз калмагандыр. Ни генә димә, утыз елга якын бергә гомер иткән кешеләр бит без. Башлап мин сәлам бирдем.

— Исәнме, Назирә!

— Исәнме, Рамазан! — Ул яшьлегендәгечә килешле елмайды. Тик бу елмаю, «ай күрде, кояш алды» дигәндәй, шундук сүнде.

— Эшкәме? — дидем мин, аның поликлиникага барганын белә торып. Бүген көндезге икедән кабул итә, димәк. Танкодром районына күчеп киткәннән соң да эш урынын алыштырмады.

— Әйе, эшкә барышым.

Аннары дүрт-биш тукталышны сүзсез уздык. Миңа «Химиклар сарае»на төшәргә кирәк иде, ул «Восстание» тукталышына кадәр барачак.

— Хуш, Назирә!

— Хуш! — Тагын саран гына елмаю. Монысы бәгырьгә пәке белән сызып җибәргәндәй итте.

Көтмәгәндә, уйламаганда туры килеп, унбиш минутлык юлны аның белән бергә узу минем рухымны айкап ыргытты, тик барыбер кояшлы тәэсир калдырды. Шул тәэсир хәтер җепләрен аның белән беренче танышу көннәренә илтеп ялгады.

Ул көннәр күңел дәфтәремә салават күперенең һәммә төсләре белән язылган. Шул бизәккә дистә еллар буена күпме дегет сыланды, мәгәр олыгайгач та минем өчен ул төсләр балкыйлар, кире кайтмас сөенеч билгеләре булып яшиләр. Сабый чак тылсымы безне гомеребез азагына тикле озата барган шикелле, беренче мәхәббәт очкыннары да кабергәчә сүнмидер дип уйлыйм. Еллар көле томалап сүндерә алмый аларны.

2

...Фашистларга каршы сугышның өченче елы. Авылның боектанбоек көннәре. Миннән алты яшькә өлкәннәрнең фронтка китәсе көзе.

Егетләр (аларга унсигез тулыр-тулмас) комиссия узып кайттылар, военкоматтан чакыру кәгазе көтәләр. Ут эченә китәчәк яшьләрнең ата-аналары (күбесенең әниләре генә, этиләр сугышта), туган-тумачалары хәзинәдә барын җыештырып, озату мәҗлесләре уздыралар. Бүген — берәүләрдә, иртәгә икенче егетләрдә.

Сугыш чыкканчы авылда егермеләп гармунчы булгандыр. Сайратыпмы-сайраталар иде тальянын да, «саратский» дигән кыңгыраулысын да. Хәзер ике йөзгә якын хуҗалыклы Яртуган авылында гармун шыгырдатучы бер мин калдым. Бишенчедә укучы малай.

Мәҗлесләргә йөртәләр үземне. Гозерләп-ялварып чакыралар. Бармаска итсәм, үпкәлиләр, чакыра килгән кызмача абыйлар хәтта тотып тукмау белән яныйлар. Әби дә:

— Бар инде, бәбкәм, бар, яуга китәсе кешеләрнең гозерен екма. Дөньяның эшен белер хәл юк, үкенечкә калмасын,— ди. Шулай ди дә, пышык-пышык елый башлый.— Әткән дә, балакаем, канлы туфрак астында ятып калды. Өрлектәй ир иде Каюм улкаем... Ул Ржев дигәннәре кайдадыр инде? Каберен дә таба алмассың...

Әтинең һәлак булу хәбәре килгәч, бик бетерешкән әби, әнине дә урманда агач басып үтергәч, тәмам аңгыраеп калды. Бер үк сүзне әллә ничә кат сөйли. «Бигрәк тә гомерсез булдылар улым да, киленем дә...» Бу — аның һәр тумыш көндә әйтә торган сүзләре. Ә күңеле гел яхшылыкта, кешеләргә изгелек кылмакта.

Шулай да Югары оч Мөхсин абыйларда мәҗлестә булып кайткач, мине өйдә утырту ягын каера башлады. Моның сәбәбе — аның котын алган хәл иде: ул көнне мине сыйлап җибәрделәр. Ава-түнә кайтып кергәнмен дә бусага аркылы ауганмын. Гармунны Мөхсин абыйлардан әби алып кайтты. Әй тиргәнде, әй елады, әй рәнҗеде әби ул төндә! Җәлләдем үзен.

— Бирмим моннан ары гармуныңны! Әткән төсе ул, бердәнбер сагынмалыгы,— диде. Аннары йомшый төшеп, үгетли башлады: — Әй бала, бала! Шушы яшьтән хәмер белән агуланалармы соң, әстәгыфирулла! Ярамый, балакаем, ярамый! Уттан курыккандай куркырга кирәк хәмердән...

Мин тәүбәмне дә әйтә алмый йоклап киткәнмен. Мөхсин абыйлардагы мәҗлестән йорт башының моңаеп җырлаганы хәтердә калган:

Ал яулык, зәңгәр шәл,
Узган гомер бигрәк җәл...

...Мин укырга алты яшем тулгач кергән идем. Хәзер бу гадәти хәлгә әйләнеп килә, ә утызынчы еллар уртасында мәктәпкә сигездән генә алалар иде. Унынчы классны уналты тулып узуга тәмамладым. Институтка керү ниятем бик бөтен булса да, хәерчелек чабудан шул тикле нык тоткан иде, адым да атлатмады.

Үзебезнең Яртуганда мәктәп җидееллык кына иде. Өч ел район үзәгенә йөреп укыдым. Һәр көнне уникe чакрымны барам, уникене кире кайтам. Фатирга кереп торасы гына иде дә соң, хакын нәрсә белән түлисең?! Бар байлыгы дүрт-биш тавык белән бер әтәч булган әбидән (колхоз карчыклары ул елларда пенсия алмыйлар иде) ни өметләнәсең? Әле дә мең рәхмәт үзенә, туфрагы җиңел булсын, «Укы, балам!» — дип кенә торды.

Җәйләрен колхозда эшләдем, үгез җигеп, ындырга көлтә керттем. Станциягә ашлык, бәрәңге, яшелчә заданиеләре ташыдым. Үгезнең йөк тартуына соклану, тискәрелегенә гомерлек рәнҗү шул еллардан калган.

Колхозда эшләгән хезмәт көненең тиярe ташка үлчим иде ул елларда. Кешеләрнең чыдамлыгына, зар елап мәлҗерәмәгәнлекләренә дә мин шул вакытта нык иман китердем. Сугыш дәверендә, аннан соңгы кыт-

лык чорында чыдаган буынның кадерен бик белергә кирәк!

Өлгергәнлек аттестаты алгач, армиягә киткәнче дип, эшкә урнашмакчы булдым. Җидееллыкка укытырга җибәрмәкчеләр иде, шүрләдем, бала-чага санга сукмас дип уйладым.

Икеле-микеле йөргән көннәремнең берсендә район үзәгендә яшәүче карт артистка мине урамда туктатып сөйләште. Район агитбригадасы эшендә еш катнашканга, бик әйбәт белә иде ул мине.

— Карале, Лотфиев, кем, Рамазан энем, ни бит әле... Сине авылыңнан чакыртып сөйләшим дип йөри идем. Менә бит ул, бирәм дигән колына чыгарып куя юлына...— Артистка апа гомергә шулай булды, төп сүзен әйтер алдыннан су буе кереш сузар иде.— Ни бит әле... Сине институтка китми, диделәр...

— Әйе,— дидем,— китеп булмый, апа. Чама юк.

— Карале, Рамазан энем, колхоз-совхоз театрына яшь артистлар кирәк. «Галиябану»ны куеп яталар. Массовкага кешеләре җитми. Кермисеңме шунда эшкә? Акчасы юк инде аның, сәнгатькә мөкиббән киткән кешеләр генә эшли анда. Ну, син бит сәхнә фанатигы!..

— «Һәм башкалар» булып уйнаргамы, апа?

— Соң, башта шулайрак була инде ул, кинәттән генә Хәлил итмәсләр. Ике атнадан гастрольгә чыгып китәселәр алар.

— Белмим шул,— дидем аптырап.— Безнең авылның исәр Туади Нургалие агитбригада килгәч тә: «Кәҗә — мал түгел, артистлык — эш түгел»,— дип әйтә иде.

— Чү-чү, кем, Лотфиев энем, син утызынчы еллар кулагы җырын җырлыйсың түгелме? Анысын ташла, башыңда чүп-чар булып тормасын! Белмим дип тә маташма. Син бит тумыштан актер. Җырлыйм дисәң, тавышың бар. Биим дисәң, өермә куптарасың. Тагын да кем, Рамазан энем, гармунда уйныйсың, баянда беләсең. Районда сине болай да артистка чутлыйлар лабаса!..

Мин иңнәремне җыердым. Әйле-шәйле торуымны чамалаган артистка апа мине район клубына, театр директоры Исхак Дасаев янына җитәкләп китте.

Шул килүдән мин репетициядә калдым. Су буе күренешендә Хәмзә булып уйнарга, Исмәгыйль Хәлилне аткач, йөгереп керүче ике кешенең берсе булырга тиешмен. Җиде җөмлә сүз әйтәсе, башкаларга кушылып җырлыйсы, биисе. Кирәк икән, гармун уйнармын. Гармунчылары бик чамалы күренә.

Репетиция кичке уннарда гына бетте. Авылга кайтырга соңгардым дип торганда, Бәдрине уйнаучы Гали абый Донской мине үзе янына кунарга чакырды. Ул бер марҗада бүлмә алып тора икән, бергә йоклар быз, диде.

Кайттык, бүлмәгә кердек. Мин, ярлы гаиләдән булсам да, бер мәлгә аптырый калдым. Яшь яшәгән, байтак еллар театрларда эшләгән абый шушы шартларда яши микәнни соң?

Гап-гади тимер карават. Солдат караваты. Бер мендәр, бер одеал. Бердәнбер тәрәзә буена куелган кечкенә өстәл. Анда чәнечке белән кашыклар. Тәлинкә, стаканнар.

Чатта этажерка. Аның аскы бүлемендә грим каплары һәм иследай шешәсе, пудра, сакал-мыек ябыштыра торган җилем. Урта бүлемдә ике дистәләп китап. Иң өстә ике фотосурәт.

— Утыр,— диде Гали абый.— Юлга кузгалыр алдыннан ял ит.

Нинди юлга кузгаласын аңламадым.

Гали абый өс-башын алыштырды, пижама киде. Аннары этажерка өстенә сөяп куелган фоторәсемнәргә күрсәтеп, сорады:

— Болар кемнәр, беләсеңме?

Дөресен әйттем, белмим, дидем.

— Их син, артист! — диде агаем, сүзләрен теш арасыннан кысып

чыгара-чыгара. Минем дә кәеф кырылды.

Кинәт абый йомшап китте. Мине бала иркәләгән сыман юата башлады:

— Йә, борыныңны салма! Булды, бетте! Мин шундыйрак инде. Өйрәнерсең, күнегерсең әле минем холыкка да. Дөнья бу! Ә хәзер... хәзер син кибеткә бар да,— дежур кибет рәдем и төнге уникегә хәтле эшли,— зәмзәм суы алып кайт. Икене. Аңлашылдымы?

Нишлим, бер тиен дә акчам юклыгын әйттем.

— Акча миннән, бару синнән,— диде Гали абый.— Мәле! — Ул чабата кадәр кызыл утызлыклар тоттырды. Кибетнең кайдалыгын белә идем, бик тиз алып кайттым. Агай мин кайтуга икмәк тураган, суган чистарткан, йомырка белән колбаса кыздырган.

— Бар, кулларыңны юып кер дә, өстәл янына рәхим ит. Мин бүген синең артистлык гомерең башлану уңаеннан банкет ясыйм.

Мин юынгыч яныннан әйләнеп кергәндә, өстәлдә ике стакан мөлдер-мөлдер килеп утыра иде инде.

— Тот, Рамай! Синең киләчәктә буласы уңышларың өчен!

Бер минут эчендә Рамазан Лотфиев Рамайга әйләнде.

— Рамай! Шәп бит, ә?! Артистның исеме дә, фамилиясе дә кыска булырга тиеш. Менә минем дә мулла кушкан исемем — Галиулла. Чуртыма кирәкме аның «улла»сы? Фамилиям дә Дәүләтханов иде. Мин Донской иттем. Галигә Донской ятышмый, әйеме? Миңа аның ятышмавы кирәк, беләсеңме? Ятышмаганы хәерле! Зато яңгырый! Йә, киттек!

Эчкәнем юк, эчә алмыйм, дидем. Гали абыйның болай да зур күзләре шараеп, ат күзенә әйләнде.

— Их, син, булдыксыз!

Сүксен әйдә, чыдармын. Яңакка ялтыратсын, түзәрмен. Тик кыстамасын, эчермәсен генә. Стаканнан килгән ис үк күңелгә тиеп тора.

— Рамай! — диде Гали абый шул минутта ук этинекеннән дә ягымлырак тавыш белән. Ни арада бер аллыга, бер гөллегә әйләнеп өлгерәдер ул? — Рамай! Синең Семен Розенфельдның «Шаляпин» дигән китабын укыганың бармы?

— Юк,— дидем.— Кем соң ул Розенфельд?

— Их, син! — Донской абый тагын кызып китте.— Нәрсә генә укыганың бар соң синең?

— Болай укымыйм да түгел инде...

Гали абый тагын мөлаемланды.

— Семен Розенфельд, Рамай, Петербургтагы опера театрының оркестрында беренче скрипкачы булган кеше. Вот шул яза: миңа, ди, Федор Иванович әйтә ди: «Пей, брат, от водки талант крепчает». Чамалыймсың, крепчает, ныгый! Ә син мулла кызы булып утырасың. Тот! Яртысын гына...

Мин урынымнан сикереп тордым да чыгып качмакчы булдым. Тот капчыгыңны! Гали абый арысландай кузгалды да, якамнан эләктереп алды, урындыкка дыңк иттереп утыртты. Аты-юлы белән сүгәме, әллә кыйнап ташлыймы дисәм, ялына-ялвара башлады:

— Рамай! Яшь дустым минем! Бүгенгесе көннән ахирәтем, яшь коллегам! Мин бит үзем генә эчә алмыйм. Ялгызыма гына бик авыр була. Бүген хозяйка да өйдә юк. Сине чакыруым да шуның өчен иде бит. Рәнҗетмә актер абыеңны. Тыңла сүземне, миңа бит инде утыз алты яшь... Тотчы яртысын гына...

Авызыма көчләп койгандай итте тәки. Пошкырындым, төчкерендем, үңәчемә ут капкандай булды. Күпмедер секунд тыным буылып торды, аннары гына аһ итеп сулыш алдым.

— Суган кап, суган! — диде агай.— Суган — ашыгыч ярдәм ул мондый чакта.

Бераздан миңа да кызык сымак булып китте. Гали абый хәзер тыныч, сабыр иде. Җай гына сөйләшә башлады.

— Син әнә теге кешеләрне белмим, дидең. Белеп кал. Сул яктагысы — Константин Сергеевич Станиславский. Рус театрында яңа дөнья ачкан кеше, үз мәктәбен булдырган гали зат. МХАТның терәге булган даһи... Ә уң кулдагысы — Габдулла Кариев, татар театрының атасы, белдеңме? Аның да чын исеме Миңлебай Хәйруллин булган. Мәдрәсәдәге остазы Зариф мулла Камалов, Такталы авылы кешесе, әйткән аңа: бүгеннән синең исемең Габдулла, фамилияң Кариев булыр, йөрмә шундый сәләтле башың белән мажик фамилиясенә чумып, дигән. О-ох, Кариев! Ансыз татар театрын күз алдына китерү кыен, Рамай. Мин аллага ышанмыйм, намаз укымыйм, ураза тотмыйм, чукынырга тәре дә кирәкми, мин менә шушы ике даһига табынам. Син дә, вакыты житкәч, табына башларсың. Ә даһи кем ул? Ул — миллионнар күрмәгәнне күреп алучы, миллионнар тоймаганны тоеп эш итә белүче. Бу ике гали зат та сәхнә нечкәлекләрен шулай тоеп эш иткәннәр...

Әллә ниләр белә иде Донской абый. Бик күп сөйләде. Әйбәт хикәяче икән. Котырыгы басылганчы гына житмеш жидегә әверелеп бетә. Тамак чылаткач, майлаган кебек утыра, каян килгән тәүфыйк иясе диярсең. Ул өстәл яныннан кузгалып этажеркасы янына килде, аннан калын бер китап алып, минем алдыма куйды.

— Театрда эшли башлагач, иң беренче укыганың шушы китап булырга тиеш синең,— диде.— Түтенең тиз генә туры йөреп китмәс, аңламаганнарыңны үземнән сорарсың. Кулдан килгәнен төшендерермен. Гастрольләрдә без синең белән фатирга бергә төшәрбез дип беләм. Ярыймы?

Ни дип тә үзеп әйтә алмадым. Китапны кулыма тоттым. «Моя жизнь в искусстве». Станиславский китабы икән. Шәптер инде бу! Тик минем ишеләрнең теше үтәрлек микән?

Шешәдәгеләрнең берсеннән үз стаканына салып бетерде дә, Донской абый:

— Бетте! Ак чалмалының икенчесенә кагылмыйбыз. Анысы — кара көнгә, төшендеңме? — диде.— Ә салганнарын изге юлга озатып куябыз да, аңгәмәбезне дәвам итәбез. Аракыны аны, Рамай дустым, ашказанына утлы су тутырып куяр өчен генә эчмиләр. Аракыны аны башказанына да йөгерсен өчен, кәефне күтәрсен, зиһенне чарласын, тел ачылсын, кешеләр сөйләшеп кинәнсен өчен эчәләр. Монда, Рамай, күңеленә алтын чылбыр үрелә, алтын чылбыр... Яле, тотып жибәр!

— Бик житте, Гали абый...

Сүземне әйтеп бетерергә дә җай бирмәде.

— Разговорчики! — дип кычкырып куйды. Мәктәптә безнең военрук кына сафта сөйләшсәң, шулай жикеренеп ала иде.— Эчмәгән ир-егетне кем дә кешегә чутламый бит аны, Рамай. Эчә алмаганнарны, койрык тагып, көтүгә генә куасы. Ә кем эчми? Каны качкан саранннар. Раз. Кемнең сәмәне юк. Два. Кемгә салып бирмиләр. Три. И кем өметсез чирле. Була дүрт. Калган категория ирләр эчә. Кәнишне, кемдер курыкмыйча эчә, кемдер юрган астына качып чөмерә. Алар бездән ким күбенмиләр, ләкин — маскировка! Эчмәгән кеше булган булып, пост билиләр, югарыдагыларга ярыйлар. Ә миңа нәрсә? Күктән югары асмаслар, жирдән түбән күммәсләр... Хәзер хатыннар да стаканга мәхәббәт тота башлады, төшенәмсең? Аннары ирләрне хыянәттә гаепләгән булалар. Чынында бит үзләре аздыралар... Тот әйдә!

Бу юлы артыгын карышып тормадым. Беләм, барыбер эчерәчәк. Аннан соң шактый күңелле дә булып китте шикелле. Жырлыйсым килә башлады, ышанасызмы?

Минем уйларымны укыгандай, Гали абый да әйтә куйды:

— Артистка апаң, карт ханымны әйтәм, сөйләде, Лотфиев бик шәп жырлый, диде. Күрсәт әле һөнәреңне!

Мин, өйдә кемнәр бар соң, ярап бетәрме бу эш дигәндәй, уңлысуллы карангаладым. Донской абый сагаюымны аңлады.

— Әйттем ич, бүген хозяйка кунакта. Аның бөтен биләмәсенә без хуҗа. Җырла!

— Нинди көйгә җырлыйм соң?

— Әйтик, «Галиябану»га.

Җырлап торып җибәрдем, бугазымның кытыклануы басылды, рәхәт булып китте.

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә...

Артист дисәң, артист: Гали абый урындыгыннан җәлт күтәрелеп, минем борын төбендә үк кул чаба башлады. Үзе акыра: «Браво! Афәрин!» — ди. Урынына китеп утыргач, бик мәгънәле итәргә тырышып, нәтиҗә ясап куйды:

— Сиңа Хәлилне уйнарга кирәк, Рамай, Хәлилне! Безнең Галиәкбәр Әхмәтинең тавышы тоже шәп, әмма гәүдәсе бик юан бит. Сыра мичкәсе. Тамашачы аның Хәлил булуына ышанмаячак. Ышанмый, и вәссәлам! Теләсә нинди артистны Хәлил дип танырга социалистик йөкләмә алганмы әллә ул?! Шалишь! Әйтер тамашачы, Әхмәтиегез «Башмагым»да Себер баен уйнасын, дияр. Менә күрерсең...

Тагын сөйләшеп киттек. Донской абый өстән-өстән генә булса да үз башыннан кичкәннәрне бәян итте. Буйдак түгел икән ул. Өйләнгән булган. Кызы туган. Хатыны, театр дөньясыннан ерак кеше, тегүче. Галиулласының гастрольдә йөрүләреннән туеп, аерыласы иткән. Итчегәме, итекчегәме кияүгә чыккан. Горур нәрсәкәй булган, алимент та алмаган. «Артистның ябыштырган сакалын каезлыйсыңмы аның? Артист акчасына калсаң...» — дип әйткән, имеш.

Шуннан бирле Гали абый, үзе әйткәндәй, иманы какшамас буйдак. Хатын-кыз аның өчен әллә бар, әллә юк. «Сөйгәнем дә, сөяркәм дә — театр минем»,— ди.

Сөйли торгач, Гали абый ялыкты бугай. Йоклыйк, диде. Мин яту белән мәлҗерәп киткәнмен. Шулай да йоклау дигәнең озакка бармаган булырга тиеш, бер заман күңелем болганып уянып киттем. Үләм, косасым килә! Җитмәсә, ят йорт, йокы аралаш аякланып, чыгар ишекне таба алмыйм. Тешләремне кысып торам, кеше өен пычратудан куркам. Көч-хәл таптым ишекне. Болдырга чыгып җитүем булды...

Сәгатькә якын газапланганмындыр. Кергәч, караватка түгел, идәнгә сузылып яттым. Тере мәет кебек. Ичмаса тизрәк таң да атмый, август ае дип тормас идем, Зөягә кадәр өстерәлеп барып, салкын суга чумар идем, дим. Вакыт бит ул син көткәндә, терәтеп куйган диярсең, үтми җәзалый...

Шулай да таң атмый калмады. Яктырды. Кара тәлинкәле репродуктордан Кремль сәгатенең чыңнары ишетелде. Гали абый да күзен ачты, яткан җирдән генә киерелде, авызын зур ачып иснәде. Аннары миңа эндәште.

Мин хәлемнең мөшкеллеген аңлаттым, җеп өзәрлек тә куәтем юк, дидем. Башым әйләнә, өйнең түшәме дулкынга эләккән көймәне хәтерләтеп чайкала иде.

— Тәпи бас! — Донской абый шундый әмер бирде.— Хәзер дәваланабыз. Чөйне чөй белән бәреп чыгарганны беләсеңме син? Кара көнгә дип мин сиңа кичтән тикмәгә әйттемме, ә? Донской абыең — бу мәсьәләдә карт бүре. Хәзер сихәтләнәбез. Беренче репетиция үнбердә генә әле. Үнбергә чаклы, Рамай дустым, патша малае кебек булабыз, патша малае! Бу сырхауның дәвасы бер — шул үк антигрустин... Грусть — кайгы, сагыш, хәсрәт, анти — шуңа каршы. Хәсрәт-сагышка каршы сыеклык! Кеше алдында антигрустин дип кенә сөйләшергә өйрән, аракы димә, ямьсез, кешеләрдә нәфрәт уята... Ак аракыны закрепитель

дип тә атарга ярый, кызылын — проявитель дип. Монысы фотография осталарыча була. Шулай ук Эзоп теле. Эзопны беләсеңме син?

— Беләм лә! — Тел әйләндереп сөйләшер җаем юк, җитмәсә сорау биреп тинтерәтә.

— Кем?

— Уф, аллам! Борынгы грек мәсәлчесе. Киная белән язу ягыннан атаклы... Уәх... уәх!..

— Әлеге мәсьәләдә төтенең туры йөри,— дип мактады Гали абый. Үзе майкадан, трусиктан гына килеш өстәл янына килеп, стаканнарга аракы бүлә башлады. Хәл эчендә булсам да, аның нечкә ботларына, сәлперәйгән беләкләренә күзем төште. Спорт белән шөгыльләнмәүдәнме, әллә аракы шулай ябыктыргдныы, дип уйладым. Нибары утыз алты яшен тутырган бит әле ул...

— Суган шиңгән шиңүен дә, ярар инде! — дип сөйләнде абый.— Кил бире! Тот!

Өстәл ягына әйләнеп каравым булды, тотынды укшытырга, эчем актарылып чыгамы дип торам. Донской абый киңәшләр бирде:

— Болай итәбез, аз-азлап эчәсең. Кире чыгуы бар. Зыян юк, бер чыга, ике чыга, өченчесе кереп урнаша аның...

Сүзе хак. Беренче йотымны шунда ук кире бәрде. Сыйлаучы-дәвалаучы абый өстенә чак кына бөркеми калдым. Аның исе дә китми.

— Дәвам итәбез,— ди.— Күзеңне йом, борыныңны кысып тот та, авыз ит.

Янадан шул ук хәл.

— Тамчысы булса да кала аның,— ди остазым.— Хәзер күбрәк эләктер. Менә шулай!

Ниһаять, дүртенче омтылыш барып чыкты! Ярты стакан кереп урнашты. Алай да хәл яхшырмады, баш әйләнә иде әле.

— Ун минут! — дип ышандырды Гали абый.— Шуннан зәмзәм суының гайрәте канга күчеп өлгерә. Шул чагында син — патша улы!

Әйтсәң-әйтмәсәң дә, беравыктан хәл рәтләнгән кебек булды. Күңел болгануы бетте, баш әйләнмәс булды. Этажеркадагы көзге китегеннән барып караган идем, мин — мин инде. Интеккән Рамай димәссең, гап-гадәти Рамазан Лотфиев.

Вакыт унберенчегә атлый башлагач, хезмәткә җыендык. Гали абый булдыра алганча пөхтә итеп киенде һәм... мине гаҗәпләндергәне — кызлар шикелле бизәнде. Рас әгәре! Сәхнәдә грим ягуны аңлыйм мин. Ә менә көпә-көндез, кеше арасына урамга чыкканда, ир кеше... Битен дә сизелер-сизелмәс кенә кызартты, иреннәренә лә иннек тидереп алды, пудрасын да якмый калмады. Олыгаеп бушангаи бите яктырып киткәндәй булды. Соңыннан ислемай сөртенде. Миңа да бирде.

— Сөртен! Ислемай җинел-җитез канатлы. Аракы исеннән алда барып җитә. Беренче тәэсир белән сугып алдыңмы, кешенең борыны бүтән исне әллә ни абайламый... Тик хушбүй-ислемайның ирләрнеке булганын сайлап сөртенә белергә кирәк. Югыйсә ис тоемлау осталарыннан: «Исәнме, абыйстай-абзый!» — дигәнне ишетүең дә бар...

Гастрольләргә чыгып киткәнче мин һәр төнне авылга кайтып йөрдем. Донской абый бүлмәсенә бүтән бармадым. Тик бу — кыска вакытлы бәйсезлек кенә иде.

Гастрольләрдә без фатирга бергә төшүчән булып киттек. Теләсәмтеләмәсәм дә, аның арбасына утырырга туры килде.

Гали абый мине улы сымак яратты. Әмма ихтирамын өстәлдәш булып күрсәтә төшә иде.

Көннәрнең берендә, Бузай дигән авылда, Галиәкбәр абый Әхмәти авырып китте. Спектакльне өзәргә ярамый иде. Бер тамаша фәлән йөз сум тора. Аннары халыкның да кәефе китәчәк. Тагын шул кадәре дә бар: ярый ла баш рольне уйнаучы артист иртәгесен савыкса? Уйный алса, җырлый алса?.. Баладән котылу юлын Донской абый күрсәтте.

— Дасай,— диде ул директорыбыз да, режиссерыбыз да булган Исхак абыйга (ул Исмәгыйльне уйный),— киендерик Рамазанны Хәлил итеп. Сүзләрне яттан белә, җырлый. Әхмәтидән ким түгел. Гармунны да арттан уйнап торасы булмый, үзе сыпырта...

Килеште җитәкче. Мәҗбүр иде. Мин Хәлилне уйнадым. Ничек шурләгәнемне үзем генә беләм. Юанычым шул — ерып чыктым.

Һәй шатланды Гали абый! Авыл кибетчесен тәнлә уятып, үзе әйтмешли, антигрустин төяп кайтты. Төшкән фатирыбызның хуҗасы безгә кулай агай иде, чөкердәшеп таң аттырдык...

Ике ел театрда эшләп, өс-башны аз-маз карагандай иткәч, сай кесәнең төбенә бер генә кат булса да акча җыйгач, мин институтка киттем. Әгәр керү имтиханнарының берсен генә «өч»легә бирсәм дә, стипендия булмаячак һәм мин укый алмаячак идем. Шуны яхшы белеп, икенче вариантка әзер булып килдем Казанга.

Бәхеткә, кабул итү имтиханнарын «өч»лесез тапшырдым һәм төзелеш инженерлары институтының гражданлык төзелеше бүлегенә кердем, студент булып киттем.

Укуны сагынган идем, сөлек булып ябыштым. Беренче курсны тоташ «отлично»га тәмамладым. Урта мәктәптә физика укыткан абыйның әйткәне бер генә көнгә дә хәтеремдә сүнеп тормады. Ул: «Белемне студент чакта көрәп алырга тырыш. Баесаң, белемгә шунда баеп калырсың»,— дигән иде.

Ул елларда әле безнең белән фронтовиклар да укый иде. Мәгълүм инде, ул халык стипендия тиеннәренә генә карап яши алмады. Дөнья күргән кешеләр, ихтыяҗлары бүтән. Берәр хатын-кызны култыклап театрга гына барсалар да, күпме чыгым кирәген ачык беләләр иде. Кытлыктан котылу юлын фронтовик Дима Бобров тиз тапты. Ерак Усиягә, пристаньга, баржа бушатырга йөри башладык. Ардыра, алҗыта, тузанга батасың, цементка катасың, аның каравы көненә үк учлап акча аласың. Аласың да, аруларны юып төшермәк булып әвәрәләнәсең. Нинди генә кысмыр булсаң да, илдән аерым ишәк булып каласың килми. Алай кылансаң, синең күзеңне дә ачырмыйлар, бүтән вакытта бригадага да алмыйлар. Артык баш ватмый гына уртак казанга үз өлешеңне салырга тиеш буласың... Донской абый сабаклары мине шактый юмарт булырга өйрәтә башлаган иде инде. Әмма теләсә кемнең күзенә туры карап әйтәм: боларның берсе дә ул елларда укуыма да, җәмәгать эшләремә дә зыян китермәде.

Кулга диплом алган елны эшкә керешер алдыннан ял вакытым. Август башында бер генә көнгә дип Атлыбайга барып кайтмакчы булдым. Анда минем әтинең дусты, минем Адаш абый яши. Механизатор.

Адаш абый, урак өсте булуга карамастан, минем күңелне күрергә вакыт тапты. Хатыны Халидә апа да бик кунакчыл булды.

Адаш абый эштән кайтып, чишенеп ыргытты, билдән ялангач калып, пошкырына-пошкырына юынды. Аның чиста күлмәк изүен төймәли-төймәли түр якка үтүе булды, хуҗабикә өстәлгә мул итеп сый тезде.

— Инде, Халидә, тегесен дә алып кер,— диде йорт башы.— Тансык кунак хакына тотып куюның гаебе юктыр.

Гәпләшә башлап, сүзебез куерганда, ишек буенда ак халатлы бер хатын-кыз күренде. Ул кыю атлап кереп бара иде, мине күреп булса кирәк, туктап калды. Аннары:

— Һай, гафу итегез, кунак бар икән,— диде дә ялт борылып чыгып та китте.

— Кер, кер, Назирә, кер! Кайтып җиттеңмени? — дип, Халидә апа урыныннан кузгалды.

— Керегез, тартынмагыз! — Мин, кунак булсаң, тыйнак бул дигәнне онытып, кычкырып калдым. Соңыннан үземә дә кыен булып китте. Мәгәр мин бу сүзләремне әйтүдән тыелырлык хәлдә түгел идем. Аның бусага буена килгән мизгеле минем рухи халәтемә яшен уты булып керде. Мо-

нарчы йокымсырап яткан соклану, гаҗәпләну, таң калу хисләрем кинәт уяндылар да, үзләрен тышаулап-богаулап торган чылбырларын өзеп, тышка атылырга, сүзләргә әверелергә теләп, ярсына башладылар. Алсу-ак йөзле, зур соры күзле, тал чыбыгыдай нечкә билле бу кыз бала шул тикле чибәр һәм мөлаем иде, андый сөйкемлеләр, ышаныгыз миңа, тормышта сирәк очрый. Минем хыялымда, теләгемдә берничә елдан бирле сурәте ясала килгән зат шушы түгелме? Минем аны кайчандыр, кайдадыр күргәнем дә бармы әллә югыйсә?

— Акчарлак! — дидем мин.— Идел акчарлагы!

Адаш абый миңа карап көлемсерәде дә:

— Һәй, безнең ир-ат халкы! — диде.— Матур хатын-кыз дигәндә, утка кергәнен дә белми.

Шул арада Халидә апа да әйләнеп керде.

— Безнең медсестрабыз шул инде, Рамазан,— дип сөйләп китте.— Районнан кайтып килеше. Чит кеше булганда, табынга узамы соң?! Узмый! Тәрбияле. Аз сүзле. Авырулар янында ай да кояш инде менә.

Адаш абый кыстап, мине тагын бер көнгә калдырды. Иртәгә китәсе дигән кичне мине озату сые хәстәрләтте. Шунда Назирәне дә чакырдылар. Аның белән шул кичтә якыннан таныштык. Танышлыгыбыз дуслыкка юл ачты, дуслык — мәхәббәткә...

## 3

Кызым Гөлзаданың унынчыны бетергән елы иде шикелле. Җәй башы. Мин район үзәгендәге машина төзү заводына командировкага барган идем. Анда ике-өч көн булдым да, Казанга кайтышым иде. Тимер юл вокзалында Волгоград-Казан поездын көтәм.

Иртән яңгыр явып узганга, куаклар ямьләнеп киткәннәр, аларның яшеллеге күзләргә рәхәтлек бирә. Һичнәрсәгә алыштыргысыз саф һава.

Яңгыр вакытында яуса, сөенеп туя алмыйм инде мин. Бик тансык, һәр тамчысы алтын чак. Корылык төшенчәсе ачлык төшенчәсенә ялганып, яшьтән үк котны алган. Канны-җанны гомерлеккә өшетеп калдырган. Шуңардан күңел гел сагаеп яши.

«Ипекәй!» димәгән сулышыбыз юк, ә «төшереп» алсак, аны да хакламый башлыйбыз түгелме? Типкәләп йөртү генә хакламау түгел бит. Тирәнрәк күз салыйк әле. Ярты литр хәмер акчасына күпме ипи бирерләр иде? Илле кирпеч! Капчык белән генә күтәреп кайтып булмас, кеч-кенә арба кирәгер иде. Җилгә очкан акчаларны икмәккә әйләндереп карау да җитми безгә!..

Ил туклыгы, игеннәр язмышы, акча тота белү-белмәү турындагы уйларымны бүлдереп, кемдер иңемә шап итеп сугып алды. Әйләнеп карасам — Зариф Солтанов, мәктәптәш, райондаш. Хәзер авиация инженеры инде. Шәп баянчы. Урта мәктәптә чагында парлап аз уйнамадык үзе белән. Миннән бер генә класс өлкән укыды ул.

Ай да вай килеп күрештек. Поездга дип килгән кешеләрнең бер ишесе: «Нишләп шул тикле җан аталар болар?» — дип, гаҗәпсенә калдылар төсле.

— Рамазан Каюмович! Туган туфракта очрашасылар бар икән!

Поезд килергә егерме минуттан артык вакыт бар иде әле.

— Әйдә, бакчага кереп утырабыз,— диде Зариф.— Аяк өстендә хаклык юк,— диләр.

Кердек. Эскәмияләргә гәзит җәеп утырдык.

— Кәефең кай тирәләрдә? — дип сорады мәктәптәш.

— Әйбәт. Командировкада ничек булсын, ди? Мин бит, агай-эне, ак мыек, сәфәрдә сер сынатмаска тырышам. Андый чакта бер алдыңны, бер артыңны кара, диләр.

— Дөрес сүзгә җавап юк, бәрәңгедә сөяк юк, Рамазан Каюмович.

Без синең командировкаң уңышлы тәмамлануны тантаналы төстә, әмма ләкин президиум сайламыйча гына билгеләп үтәрбез. Сыйлау миннән, сыйлану синнән. Закускага каклаган каз боты. Минемчә, шедеврально!

Зариф зур сары портфеленең кечкенә бүлеменнән җыелма стакан чыгарды. Капкачында көзгесенә хәтле бар. Эч тә, кара чәһрәңне, ягъни йөзең-кыяфәтеңне. Кара да, уйлап бак, кемгә охшагансың... Юк бит, шуңа карау җитми кала! Вакыт тар, ара юк.

— Тот әле ипләп кенә!

Зариф җыелма стаканны миңа тоттырды да, портфеленең киң карынлы бүлеменә үрелде. Анда «чалмалы» игезәкләр бер-берсенә елышкан. Берсенең башына җиттек. Каклаган каз боты, чыннан да, искиткеч тәмле иде...

Сүз бозау имезә, дигәннәр. Свияжск тирәсенә кайтып җиткәнебезне тоймый да калганбыз диярлек. Икенче кат башларыбызны күтәрсәк, Свияжск станциясенә килеп терәлгәнбез, семафор ябык, безнең составны кертми торалар...

— Ерак калмады, тиздән Казан,— диде юлдашым.— Әйдә, шуның өчен!

Ул пръннек кадәр генә булып җыелган стаканның «колагы»н яңадан торгызды. Яңадан бер шешәнең «чалма»сын салдырдык. Каклаган казның боты ике булган икән, анысы да кулга керде. Тагын яшәреп киттек, юмартландык, дуслык хисләре ургый башлады. Безгә кырын караучыларны сүктек, тел-теш тидерүчеләрне өченче сорт кешеләр дип бәяләдек. Йөрмәсеннәр буталып, эчә белмәсәләр!..

Казан вокзалында аның портфелен, минем кечкенә чемоданны күлдәвек уртасына куеп (яңгыр монда да шәп яуган!), кечкенә генә киңәшмә уздырдык.

Сүзне мин башлаганым истә.

— Тәнзиләң өйдә булырмы?

— «Крутушка»да ял иткән кеше ничек өйдә булсын, ди? Әле бер атнасы бар.

— Алайса, рөхсәт ит, мин сездә генә төн кичим. Бу хәлдә кайтып керсәм, Назирә тагын чырайсызлана, тагын сүз, тагын нервы талку... Бөтен шарты килгән өч бүлмәле квартираң була торып, шунда кайтырга аягың тартмасын инде, ә?

— Ниткән сүз?! Кайтабыз, безгә кайтабыз! Минем фатир да өч бүлмәле ич. Кайтабыз, чалмалы пәриләрне сыгып бетерәбез. Гастроном — кул сузымында. Идея! Бик шәп фикер әйттең!

Шул чаклы хуплап та, мактап та торгач, киттек Зариф Сафиевичларга. Такси да «яшел күз»ен кысып чакыра, безнең эшләр һәр тарафтан ал да гөл! Җәннәт инде менә...

Зариф якташның кызлары бик тыныч, бик тәртипле әр, этиләренә дә, килгән кешегә дә ялгышып кына да кыңгыр сүз әйтмәделәр. Аш-су әзерләп, өстәл көйләделәр дә каядыр чыгып үк киттеләр.

Өч бүлмәдә ике ахири калдык. Вакыт кичке сигезенчегә авышканда, без бертигез идек инде. «Ак чалмалы»лар безгә каршы көрәштә чыдый алмадылар, бушап аудылар. Яман күздән читтәрәк торсыннар дип, Зариф аларны каядыр караңгы почмакка яшерде. Аннары гына:

— Ә төнне ничек кичәрбез? — дигән сорау куйды.— Уянып киткәндә шымытыр булачакны уйлап карамадыңмы син?

Мин шымаеп калдым. Аннары кесәләремне капшадым, әйләндереп салдым хәтта. Тик аннан юанырлык чама чыкмады. Зариф та капшанды. Сөенерлек хәзинә таба алмады. Алай да булмагач, кием шкафының астын-өскә китерде, адашып, кысылып калган иске бер өчлек килеп чыкты. Һәммәсен бергә туплап санагач, бер «чалмалы» килердәй байлык җыелды.

— Магазин ябылганчы...— диде дә хуҗам ашыгып чыгып чапты. Чапты дигәч тә, ары лап-лап, бире лап-лап инде...

Мин аны дүрт күз белән көттем. Озакламады, җимерелеп кайтып керде. «Булмады! Кибетне ябып өлгерделәр»,— ди. Эчемдә ниндидер җепсел шартлап өзелде. Өметнең өзелүе шулай була икән. Өметсез яшәп кара, төн кичеп кара!..

Үзем генә иштерлек итеп сүгенеп тә куйдым бугай. Минем мескенләнүгә чыдамады, Зариф шаркылдарга кереште.

— Әй, беркатлы да соң син, якташ! Институт бетереп, инженер булырга башың җиткән, Зарифның буш кул белән кайтмасын чамаларга башың юк,— диде.— Булды, брат! Кибетне бикләп куйсалар, башка урыны бар ич аның...

Шул шатлыктан берәр йотым гына күтәреп куйдык. Артыгы бармый да иде инде. Аракы да үтмәс хәлгә килдек, ризык та кабып булмый, йокы да алмый, эч поша, сару кайный. Ни җирдә түгелмен, ни күктә. Башны ташка орырдай булып утырам. Тыным кысыла. Иң яманы — уралып-уралып күңел болгана башлады.

Зариф җәймә караватт куйган иде, шуны сытып изәрдәй булып, йөзтүбән капландым. Җыелма караватт чинап куйды. Миңа хәзер мал да, дан да кирәкми иде. Ни хатын, ни балалар исемә керми. Алар исән, алар сау-сәламәт, ә менә минем тәпи сузуым бар. Калганнар яши ул, үлгәннәр җәл. Мондый үлем белән ычкына калсаң, кем сине рәтле сүз белән искә алсын!.. Хатының тел чарлап йөрер әле: «Әйбәтләп тә әйтеп карадым, әрләшеп тә бактым, юк инде, юк, тартып ала алмадым хәмер күленнән!» — дияр. Кызганыч кешемени мин? Ю-юк әле, агай-эне, иптәш хатын...

Мигә әнә шундый котырынкы уйлар килеп сылана. Кыргыч белән дә кырып төшерә алмассың. Күк аязып киткән төсле булганда, әйтәм үз-үземә: «Назирә хаклы бит югыйсә! Гомер заяга үтеп бара түгелме?» — дим. Күңел күген яшенле болытлар баскач, үз-үземне кире кагам: «Чүпрәк булма, Лотфиев! Хатының күзенә карап тора башласаң, бәдрәфкә дә рөхсәт сорап кына йөртәчәк ул сине. Ирләр була белик, шайтан алгыры!..»

Чөй өстенә тукмак: тыйгысыз булып очкылык тота башлады. Чыкылдау озакка китсә, бик яман, диләр. Аптырагач, дүрт аякланып җыелма караваттан төштем дә йөренгәндәй иттем.

Йөрәк чыгымчылый, торып-торып типмәскә итә. Нишләсен, протест белдерә!

Менә шунда аңладым мин «Котым ботыма җитте!» дигән сүзләрнең чын мәгънәсен. Аякларым суына башлады шикелле. Йөрәк каядыр аска төшеп китте. Лап итеп идәнгә утырдым. Өнсез калдым. Җавап бирер чамам юк иде. Очкылык өреп очыргандай юкка чыкты, бетте. Мишәрләрчә әйткәндә, дыдык булып калам дип торам. Тотлыгып сөйләшүче. Дустың шул хәлгә куйсын әле! Усал-унтагай булса икән.

Туасы көн тумый калмый. Кем өчен нинди булып туа — хикмәт шунда. Минем өчен җәйге иртә хәттин ашкан хәвефле булды. Миндә махмырның шул дәрәҗәсе икән, Зариф куркынып:

— Зәңгәрләнгәнсең бит, күзләреңә үлек төсе кергән. Ике-өч сәгатьтән артыкка тартмассың... Минем өйдә тәпи сузарга язган микәнни сиңа? — дип ачыргаланды.

Ярты сәгать дигәндә, Зариф үзенең таныш врачын йокысыннан каерып алып килде.

— Һә-ә-ә, таныш иптәш,— диде табип, үтергеч караш ташлап алгач. Уколларны шундый итеп кадады, үлмәгәнгә генә исән калдым. Киткәндә, янакка чалтыраткан сыман итеп кисәтте:

— Булды, иптәш! Мин сезгә ике тапкыр ярдәм кулы суздым. Өченче очрашмасак иде. Тагын шундый хәлдә күрсәм, республика газетасына язып хур итәчәкмен.

Уколлардан соң мин изрәп йокыга киткәнмен. Уянсам, сәгать тугыз тулып узган. Өйдә берүзем. Ишек бикле.

Зариф кая олакты икән? Ул башын «ремонтлаган» булырга тиеш, кичтән кайткан «чалмалы»ны тәмам төбенәчә корыткан.

Сәгать ун тулды, унберенче яртыдан узды, унбер булып килә иде, йозак уентысына ачкыч тыккан тавыш ишетелде.

Хуҗам кайтты!

Авызы көлә, күзләре көлә, борын астындагы бармак бите кадәр генә мыегына хәтле көлә. Айның үндүртенче кичәсемени!

— Хәерле иртә, йокы капчыгы! — диде ул, шамакайланып.— Күпме селкетеп, күпме йолкып карадым, уянмадың. Карарны ялгызыма гына кабул итәргә туры килде. Кулың-битең юганмы, әйдә, кухняга гына чыгып тәһарәт яңартыйк та...

— Кай арада баедың әле?

— Менә шул хакта тәмсезләнмәсәк иде димен, Рамазан Каюмович. Шул мәсьәләдә...

— Аңламадым.

— Хәзер аңларсың. Сәгатеңне дә, алтын балдагыңны да салып куйгансың. Җаның тыгызлангандыр. Минем паспорт кесәдә, балдагыңны «Яхонт»ка сатып кайттым.

— Ә?!

— Шулай. Алдашмыйм, дөресен сөйлим. Алтмыш тәңкәгә бирдем. Менә егерме сумы исән, ал. Калганы — портфельдә моңаеп утыручылар эчендә. Ә бер атнадан миңа премиальный бирәселәр, сиңа яңа балдак алабыз. Күпмегә төшсә дә... Ышан, джентельмен сүзе. Логика (бармы?

Мин телсез дә, аңсыз да калдым. Назирә белән икәү сатып алган балдак иде бит ул. Аның кадере кибеттә түләнгән бәясе белән үлчәнми.

Без өйләнешкән елларда гади кешеләрдә махсус туй күлмәкләре тектерү, алтын балдаклар алмашу да, ЗАГСта шампанский аттыручылар да, дүртәр-бишәр җиңел машинага төялеп йөрүләр дә юк иде. Балдакларыбызны без бүтән нужаларыбызны көйли төшкәч кенә алдык.

Назирә бармагыма кидергәндә, мин аның кулыннан алтын балдак кына алмадым, хатын-кыз изгелегенең дә бер дулкыныи үземә кабул иткән идем. Аңа каршы баскан хәлдә, кибет стенасындагы зур көзгедән хатынымның җылы карашын тоттым. Мин, гомумән, Назирәнең матурланганын күзәтергә ярата идем. Аның төз гәүдәсен, матур аякларын, беләкләрен күреп, сихәтләнми калмадым. Кибет көзгесеннән дә ул күзләремә түгел, гүя җаныма текәлгән иде.

Инде менә шул балдактан колак кактым. Үтә принципиаль мәсьәлә. Моны Назирәгә ничек дип аңлатырга? Ботинка яки пальто югалу гына түгел ич бу. Зариф якташны сата алмыйм. Ул тиклесе минем кәсепкә керми. Кеше сатып ипиле булучылардан җирәнәм. Үз өстемә алырга мәҗбүрмен. Тик ничек очын-очка ялгап ышандырырга?

Башым катты. Әйләнә-тирәмне шундый бушлык урап алды, аны мичкәләгән аракы белән дә тутырыр хәл юк. Мин үземнең күләгәм генә булып калдым. Күптән тупаслана башлаган җаным сөяләнеп катты.

Изге бүләк, мөкатдәс истәлекне аракыга корбан итүне ни дип атарга, аңа ни дип исем табарга?!

«Балдак маҗарасы» Назирәнең сабыр канатларын сындырды. Аның түзем касәсе болай да мөлдерәмә тулы иде, алтын балдакның «тылсымлы» югалуы касәнең тулып ташуына өстәмә сәбәпче булды. Назирә безнең күпер төзү оешмасына хат язган (әйтәм җирле минем белән артыгын тәмсезләнеп тормады), анда минем үткәндәге һәм соңгы аралардагы тәртибемне тасвирлаган, ярдәм сораган. Мине отряд башлыгы янына чакырдылар. Хатынны гаепләр хәл юк иде чынында, тик барыбер ачу кабармый калмады.

Башлык — җайлы, кешеләр белән мөгамәләдә нәзакәтле иптәш. Мине ачык йөз белән каршылады, кул биреп күреште, урын тәкъдим итте. Бер дә урау юллар эзләп тормыйча, сүзгә керешге.

Мин акланырга җыенмадым. Акланыр урыным юк та иде. Аракы

эчәргә йөргәге житкән ир үзендә дөресен сөйләрлек көч табарга тиеш. Боргаланып-сыргаланып утырырга мин ресторан кокеткасы түгел.

— Булгалады шул килешеп бетмәгән эшләрем,— дидем.

— Булдырмаска иде. Сез бит бала-чага түгел. Инженер. Гаилә башлыгы. Балалар атасы. Хәлегездән күп нәрсә килә. Алынсагыз, менә дигән эшлисез. Эшчеләр ярата үзегезне. Кешедән сорыйсым юк, үз күзәтүләрем житәрлек. Сезнең уңай сыйфатларыгызны бирәү дә инкарь итәргә теләми. Нигә дип аракыга сыенасыз? Нигә?

— Дөрес, мине рәнжеткән кеше юк...

— Турысын әйтим, эленке-салынкы йөрисез. Сәбәбен аңлыйсыздыр дип беләм. Моны гафу итеп булмый...

— Гел генә идеаль хәлдә яшәү бит...

— Без сезне капка астыннан тапмадык, сез институттан менә дигән характеристика белән килдегез. Давайте яңадан күрсәтә башлагыз ниләр майтара алганыгызны! Капка астына тәгәрәргә юл куймабыз, иптәш Лотфиев. Ләкин аңлагыз, зинһар, сезне саклап йөрергә персональ сак беркетә алмыйбыз. Упкыннан котылуда төп көч сезнең үзегездә.

Дөрес әйтте. Шуңа күрә мин аңа күтәрелеп карарга да кыймый утырдым. Янып-пешеп чыктым.

— Алексей Максимович Горькийның Капридан язган бер хатында ярым исерек, ярым сукыр бер саилче турында әйтелә...— Начальник ашыкмый гына сөйли иде.— Ул, белер-белмәс көенә, үзенә сәдака итеп ялгыш бирелгән алтынны читкә ыргыта. Тимер-мазар кисәге дип уйласа кирәк. Гомерендә алтын күргәне, кулына тотып караганы булмаган. Сез бит үзегезнең кем икәнегезне яхшы беләсез, нигә үз-үзегезне, сукыр хәерче алтын ыргыткан шикелле, тормыш сазлыгына, тарлавыкка ыргытмак буласыз? Уяныгыз, житте! Ил-көн алдындагы җаваплылыгыгызны, бурычыгызны истән чыгармагыз. Балаларыгыз, хатыныгыз сезгә ата итеп, ир дип карап торалар. Азак килеп, совет интеллигенты дигән исемне пычратмагыз, ниһаять!..

— Тырышырмын.

— Тырышырга гына түгел, ир булырга, яңадан сафка басарга кирәк. Минем киңәшем: шушы атнада ук чираттагы ялыгызны алыгыз да стационарда дәваланыгыз. Ике сөйләшмибез. Хушыгыз!

Аңлашылса кирәк, өйгә кайтканда сөмсерем коелган иде. Чишенеп, өс-баш алыштырып, бүлмәмә кереп утырган гына идем, Гөлзада шакып керде.

— Ни бар иде, кызым?

— Менә военкоматтан китерделәр, мин кул куеп алып калдым.— Кызым чакыру кәгазе сузды. Иртәгә сәгать тугызда мин хәрби комиссариатта булырга тиешмен икән. Комиссарның үзенә чакырулы.

— Рәхмәт, кызым.

Ул чыгып китте. Мин исә бер «операция»нең серен ачыклый калдым. Повестка — шулай ук хатын тырышуының нәтиҗәсе. Алар хәрби комиссарның сеңелесе белән бер поликлиникада эшлиләр. Назирә гаилә хәлләрен аңа зарланган, тегесе шуны полковникка житкергән. Комиссар, кеше зарына бик тиз колак салучан, ярдәмчел, кыю кеше, минем белән хәрбиләр телендә сөйләшмәкче. Мине институт комсомолында эшләгән еллардан ук белә. Студент елларда шәһәр һәм республика күләмендә уздырыла торган киңәшмәләрдә әледән-әле очрашып тора идек. Утлы табага бастырырга чакыруы.

Иртәгесен мин полковник бүлмәсенә килеп кердем.

— Сәлам! — диде ул, мин килеп кергәч үк.— Утырып җибәр. Хәлләреңне сорамыйм, беләм. Полтава янында шведлар янган кебек янасың икән. Дүшәмбедән үзеңә ял бирәчәкләр. Белештем. Сишәмбедән дәваланырга керәсең. Без дә сөйләштек. Волков урамына. Бу — үтә тәжел эш. Шунысын да әйтим, дәвалану курсын үтеп чыккач, хәрби өйрәнүләргә озатам мин сине. Өч ай солдат шулпасы эчеп, артык майларыңнан

арынып, акыл жыеп кайтырсың. Анда сиңа рюмка да, зәңгәр каймалы тәлинкәләрдә закускалар да булмас, капитан! Бер тарихчы, тормышның үз тапкырлау таблицасы бар, дип санаган. Ишеткәнең бармы?

— Юк, бугай...

— Аерым бер кешегә күчергәндә, кылган кынгыр эшләре кырыкка тапкырланып, кешенең йөз карасына әверелә, дип аңларга кирәк моны. Киресенчә дә, әлбәттә. Яхшылыкны яхшылыкка тапкырласаң, йөз аклыгы... Аңлаштыкмы? Уңышлар телим. Хуш!

Кырысланды полковник. Әлек җәелеп сөйләшә иде. Бүген исә хуш килдең, хуш китә күр булып чыкты. Тәҗел эш дигәне — бик тиз эшләнергә тиеш, кичектергесез эш була инде. Соңгармыйк, диләр. Мин ашыкмаганга ашыгалар... Тик, ничек кенә булмасын, полковник үзенең миһербанлы йөрәген кабырчык астына яшереп маташа...

4

Мин Волков урамындагы шифаханәдә. Монысын мактыйлар. Арча кырындагысы яманрак, диләр. Кереп, дәваланып караган җирләрем түгел — анысын да, монысын да белмим. Бер нәрсә ачык: судсыз-нисез ябып куйган урын бу. Тик бер ягыннан зарланасы түгел, өйдән китергән ашамлыкларны, газета-журналларны берсүзсез үзеңә тапшыралар.

Палатада без өчәү. Миңа кадәр энергетик, физкультурачы һәм мин. Эшсез-шөгыльсез без монда. Эч поша башлады, гаиләне сагынам кебек. Өйдә һәр көнне янәшә булганда, бер-береңнең кадерен белеп җиткермисең бугай. Миңа әле күпме генә аерым торам, ялгызлык сиздерә. Бергә чакта ни дип эндәшәбез соң без, ни дип бер-беребезнең күңел түгәрәклеге турында кирәгенчә уйламыйбыз?..

Палатаның тыкрык ягындагы тәрәзәсенә бер хатын-кыз килде.

— Исәнмесез! Аркадий кайда икән?— ди. Әһе, энергетикның кемедер бу. Мин: «Хәзер чакырам!»— дип чыгып киттем. Аркадий кызыл почмакта телевизор карап утыра иде. «Әйдә, синең яныңа килделәр!»— дип баш кактым. Аңлады. Сикереп торды да палатага миннән алда элдертте.

Мин кайтып кергәндә, пластилин белән генә ябыштырылган тәрәзә күзе алынган, килгән ханым белән Аркадий арасында кыска дипломатик сөйләшү бара иде. Саубуллаштылар. Ханым китеп барды. Тәрәзә күзе янә ябыштырылды. Обходка кергән врачларың да сизәрлек түгел!

Аркадий, мин кереп җиткәләгәнче, целлофан капчык белән күчтәнәчләр алып өлгергән икән. Капчыкны ике куллап күтәрде дә: «Яшәсен минем хатын! Ул булганда, без яшибез!»— дип көйләп-шыңшып алды.

Аркадийның хатыны аракы китергән икән, егет шуңа канатланган. Дөресрәге, су кушылган спирт. Ашамлыкларны миңа дигән, котлетлар.

— «Тасма»да эшли ул минем Таня. Лаборантка. Аларда спирт бетеп тормый. Молодец, Танюша!— дип хатынын өзми дә куймый мактый бу.

Өлкән кеше санаптыр, энергетик миңа беренче булып эчәргә тәкъдим итте.

— Юк, Аркадий, эчмим, рәхмәт! Мин монда эчәргә дип кермәдем.

— Һи-и-и, Рамазан Каюмович! Сез аларның даруларын эчмәгез, даруларын. Бер файдасы да юк, тәҗрибәләр әйтә моны. Впрочем, тагын ике көннән сезне законлы төстә эчерәчәкләр. Даруга ничек күнеккәнне, нинди реакция барганын тикшерү өчен. Провокация дип атала ул.

«Аркадий хак сөйлиме?»— дигән сорау белән спорт мастерына карадым. Әнвәр раслап баш какты. Шуннан соң теле белән дә әйтте: «Әйе, Рамазан абый, дәвалау курсы дәвамында берничә тапкыр эчереп, сынап карыйлар».

— Әйттем бит, Рамазан Каюмович. Сез мине дә, Әнвәрне дә рәнҗетмәгез. Бер генә тотып куегыз, бүтәнчә кыстамам. Ошап китсә инде, баш өсте...

Тамак шул тикле кымырҗып китте, тәһарәтне бозмый булдыра алмадым. Егетләр маташкалаган арада хәмер гайрәте канга күчәргә дә өлгердеме, кәеф барометры аязуны күрсәтә башлады.

Егетләр дә эшне тиз тоттылар. Монда өндәүле мәҗлес түгел. Ялтйолт булырга кирәк.

— Менә, егетләр,— дидем палатадашларыма,— без хәзер кылган гамәл, беләсегез килсә, чиктән ашкан нахаллык дип атала. Аны сугыштан соң болай аңлаталар иде. «Чамадан тыш нахаллык ул — дәһшәтле сугыш елларында ерак тылда ятып, солдаткалар белән кәеф-сафа кору һәм, сугыш беткәч, үзеңне фронт батырлыклары өчен бүләкләнүчеләр исемлегеннән эзләү». Дәваланырга кергән җирдә пир ясап яту ни дип атала?

— Әй, сез юкка вөҗдан газабы кичерәсез, Рамазан Каюмович! Шик-шөбһәләрегез тәмам таралсын өчен тагын түнтәреп куегыз әле...— Ул миңа тагын су кушылган нәрсәне сузды.— Менә шулай! Берәүләр дәүләттән йөзәр меңләп урлыйлар, газапланмыйлар. Кеше үтерүчеләр бар, уйлап та карамыйлар. Ә без дуслар сыйлаган хәмерне эчкән өчен ут йотарга тиешме?

Әнвәр, эчеп алгач, бөтенләй сүзсезгә әйләнә икән. Телен йоткан кешедәй тик утыра. Чамасыз уйланамы әллә? Ак дип тә, кара дип тә сүзгә кушылмый.

Мин Аркадийга үзем уйлаганнарны әйтмәк булам.

— Син, энем, казна каракларын да, кеше үтерүчеләрне дә мисал итмә,— дидем.— Алар — аномалия. Сүз нормаль кешеләрнең вөҗданы турында бара. Шуңа әйтәм: вөҗдан йокламаска тиеш. Ул йокыга талса, без әллә нинди кыргыйлыкларга барып җитәрбез.

Аркадий караватына барып утырды да, сүлпән генә сөйләнеп алды.

— Вөҗданлы кешегә яшәве җиңел түгел шул, Рамазан Каюмович. Акыллы юл куйдым дип тора бирә, нахал мин җиңдем дип тантана итә. Җиңә дә! Миңа утыз яшь инде, байтакны күрдем, намуслылар намусын учлап кала, басымчакларның эше худта. Кайчак шул идиотларга ачу килеп, артыгын эчеп ташлыйм.

— Идиотларга каршы аек килеш көрәшеп була, Аркадий. Исерекнең хак сүзен дә чутка сукмыйлар.

— Шуннан нәтиҗә?— Аркадий минем белән килешмәскә итте.— Тотып ярыргамы аларны? Изеп ташларгамы?

— Алай эшләсәң, хөкем итәрләр!

— Нишләргә соң?

— Аек килеш көрәшергә иде дә бит, аек килеш!..

Аркадий чәчәләнеп кул селтәде.

Кичен Назирә ашамлыклар, газеталар китерде. Язуында ул: «Бернке сүз язып чыгар. Мин ашыгам, поликлиникада профсоюз җыелышы. Иртәгә Гөлзада килеп китәр. Әйбәтләп дәвалан»,— дигән иде.

Мин алдан ук хат язып куйган идем, шуның азагына: «Барысы өчен дә рәхмәт. Гөлзадага әйтче, «Огонек»ның соңгы санын алып килсен әле, яме»,— дип өстәдем дә хатны аңа тапшыруларын үтендем. Аннары... аннары Зариф дуска хат яздым. Безнең палатада тәрәзәнең аскы күзе «тылсымлы» икәнен, ара табып, берәр нәрсә китереп китүен сорадым. Мондагы иптәшләргә әҗәтле булып каласым килмәгәнне аңлаттым.

Якшәмбедә безне шифаханәнең бакчасына чыгардылар. Саф һава суларга, гәүдәләрне язарга. Килгән кешеләр белән дә шунда күрешергә рөхсәт бирәләр икән. Минекеләр килмәсләрдер, бакчага киткәннәрдер дип фараз кылдым. Кичтән китергән газеталарны караштыргалап утыра идем, «Әнә ул Лотфиев!»,— дигән сүзгә башымны күтәреп карадым.

Күзләремә күренәме дип торам: мәктәп-интернатта эшләүче Динә Мәсәгутова икән. Мин аның белән моннан ике ел элек бакчага бару юлында сөйләшеп-танышып киткән идем.

Больница киемнәреннән килеш ничек каршы барыйм да, ничек күрешим инде? Бүкән шикелле утырып та булмый. Тордым. Динәгә таба атладым. Шул чак, каһәр генә суксын, тапталып беткән йомшак туфлиларның берсе аяктан төшеп калды бит. Туктап аны тәпигә элэктерергә туры килде. Кызарып, пешеп чыктым. Борыным өстендә тир бөрчекләре пәйда булды.

— Исәнмесез, нинди язмышлар китерде сезне бирегә?— дидем. Сөйләргә сүз таба алмыйм, телем тотлыга.— Зинһар, гафу итегез, мин кеше кабул итәр кыяфәттә түгелмен...

— Борчылмагыз, Рамазан Каюмович, бер дә борчылмагыз. Больница күрмәгән кеше түгел мин...— Ул шундый итеп елмайды, тиз тынычландым.

Чибәр ләгънәт! Бакчадагы ир-ат игътибар итми калмады. Шушы чибәр ханым алдында бакча карачкысы булып утыр инде, билләһи!

— Әйдәгез, аргы баштагы эскәмиягә утырыйк,— дидем мин. Күргәзмәгә баскан гүзәл белән хәерче-сәләмә принц кебек бакча уртасында басып торып булмас бит.

Барып утырдык.

— Минем килүемә гаҗәпләнмәгез дә, Рамазан Каюмович, ачуланмагыз да, үтенеп сорыйм. Кичә сезне дәвалаучы врачны очраттым. Ул заманасында минем ирем белән якын дус иде. Сөйләшеп киттек тә, ничектер сезнең фамилиягезне әйтте. Берүк моның өчен аңа бәйләнә күрмәгез... Менә килеп китәргә булдым. Сезнең мондалыгыгызны бераүгә дә сөйләмәм, ант итәм. Сез генә ачуланмагыз, яме?

Сүзебез юк иде. Әкәмәт бер хәл. Шуңадыр, Динә озакламады, китәргә талпынды. Тагын бер-ике минут алданрак кузгалса, әүлия буласы икән дә бит!

Динә минем яннан кузгалырга торганда, бер шәфкать туташына ияреп Назирә килеп керде. Шик юк, ул Динәнең минем белән саубуллашып китүен искәрде.

Әйе, нәкъ мин уйлаганча булып чыкты. Хатыным белән сөйләшүнең рәте-коты китте. Назирә Динәнең кемлеген сорады. Мин аның мәктәп-интернатта эшләгәнен әйттем. Дөресен. Ашамаган ризык авызга ябышмый, юк гаебемне бар итеп, алдашып утырмам ич инде.

Назирә кара янып чыкты. Аның бөтен матурлыгы югалды кебек. Күчтәнәчләрен дә «Мә, тыгын!» дигәндәй генә биреп, юньләп саубуллашмый да китеп барды.

Әбәдкә чакырдылар. Аппетитым беткән иде, ашарга бармадым. Күчтәнәчләрнең Динә китергәннәренә дә, Назирә алып килгәннәренә дә кагылмадым. Егетләрне сыйладым. Аркадий Динә алып килгән бик шәп колбасаны ак кәгазьгә төреп, бер читкә алып куйды.

— Моның чираты бераздан,— диде.

Иртәгә шифаханәдән чыгарасылар дигән көнне, өйләдән соң, «тылсымлы» тәрәзәгә Зариф килде. Кәефе шәп күренә иде, курку-өркүне оныткан. Авызын ерып, тышкы яктан:

— Сим-сим, ач ишекне!— дип тора.

Күреп алуым булды, йодрык селкедем. Тәрәзә күзен алгач, берике сүз алыштык.

— Килдеңме?

— Килдем. Мә!

— Рәхмәт! Иртәгә чыгам...

Егетләрне сыйладым, иңемнән таш төште.

Унсигез көн дигәндә чыктым шифаханәдән. Анда ятуым турында документ тутырганда, дәвалаучы врач «диагноз» дигән графага бик куркыныч сүз язды.

Больница киемнәрен салып ташлагач, гәүдәм җиңеләеп калгандай булды. Спорт мәйданына йөгереп чыгу теләге туды. Үз киемнәремне киеп алгач, регистратор бүлмәсе каршындагы зур көзге алдына килеп, галстук та бәйләгәч, үз-үземә күз кыстым: бу йорттан азатбыз, туганкай!

Өйдә бәйрәм өстәле әзерләп көткәннәр иде. Аш янында күбрәк мин сөйләдем. Ә өч көннән хәрби өйрәнүләргә киттем. Андагы тәртип билгеле инде...

Елга якын гомер ярыйсы гына үтте, җан тынычлыгы белән узды ул көннәр. Ә аннары... аннары тагын тәмуг газаплары ябырылды.

Җәйге көннәрнең берсендә соңгы рейстагы теплоход белән Суксуга — бакчага барганда, транспорттан төшкәч, Назирә күзем маңгаема менәрлек яңалык әйтте.

— Син, зинһар, җенләнми генә тыңла һәм чын ирләрчә объектив фикер йөртергә тырыш,— дип кисәтте ул. Мондый «увертюра» мине шул мизгелдә үк ярсыта башлады.

— Хуш, сөйләп бак.

— Ничек тапкан, кемнән белешкәндер, белмим, кызыксынмадым, сорамадым, бүген поликлиникага Атлыбайда минем арттан йөргән Фәйзи килеп чыкты. Теге заманда миңа өйләнергә дип йөреп тә, укытучы-англичанкага ияреп киткән ветврач...

Ниткән визит ул? Минем сине күрәсем дә, сөйләшәсем дә килми. Мин — ир хатыны, балалар анасы, улым, кызым буй җиттеләр, дидем. «Күреп кенә чыгыйм, дигән идем»,— ди. Бүтән монда эзегез булмасын, дидем дә кереп киттем. Сиңа сөйләвем шуның өчен, мине кабинеттан чакырып чыгарган сестра чамасыз гайбәтче, берне биш итәргә оста. Фәйзинең килүен кайчан да булса бер сиңа ирештерәселәрен беләм. Билгеле булып торсын, дим.

— Сез очраша торыгыз, син миңа хәбәр итә бар, мин регистрациягә ала торыйммы?

— Җенләнмәскә булган идең бит әле.

— Бәлки мине «тәти» малай итәрсез дә, ике арагызда хат йөртергә ялларсыз?

Назирә елый башлады.

— Сүзләреңә хисап бирәсеңме син?..

Мин, артык тилелек эшләп ташламагаем дип, үземне боргычлап тордым. Бакча өенә барып кергәч тә, чәй дә эчми, ялгызым гына диванга барым яттым. Кадаклары очлы ягы белән тырпаешкан матрацка салдылармыни!

Фәйзи хәбәре болай да аязучан болытлы күгебезгә өере белән соры болытлар куып китерде. Мин Назирәне Фәйзи кочагында итеп күрдем, оятсыз ваклыкларга кадәр күз алдыма килгәндәй булды. Аннары эчемнән: «Юк ла, юк!»,— дип кабатладым. Ниндидер ят тавыш исә колагыма кересен тукый иде. Кайдадыр укыганым бармы соң, әллә берәр танышым ачы тәҗрибәсен сөйләгәндә әйткән идеме: хатынының хыянәте турында ир иң соңгы кеше булып ишетә, имеш...

Вакытлар узгач, мин янә Динәне очраттым. Оптика кибетендә күзлеккә чират тора идем. Ул бер читкәрәк китеп нидер язды да миңа кош теледәй генә кәгазь бирде. Үзе киткәч укыдым мин аны.

«Рамазан Каюмович!

Әгәр вакыт таба алсагыз, үзегез өчен кечерәю дип санамасагыз, безгә килеп чыгыгыз әле. Ялгызым гына булам. Мин сәгать өчтән дә калмый өйгә кайтып җитәм. Ничәдә килсәгез дә көтәм. Сезнең белән генә киңәшер сүзем бар. Тартыну белмәүдә, әдәп бозуда гаепләргә ашыкмагыз, зинһар.

Адресым...»

Ми күзәнәкләренә бәреп кергән беренче уй шундый булды: «Ниткән әрсезлек, ниткән батыраю бу?»

Мәсәгутовага ялгыш та сүз кушканым, мондый язу бирерлек якынайганым юк. Гаиләле кеше икәнемне беләдер дип уйлыйм. Балаларым барлыгы да аңа мәгълүм булырга тиеш. Шулар ачык икән, ни дип әле ул мине үз фатирына аулакка чакыра? «Ялгызым гына булам»...

Киңәшер мәсьәлә баш калкыткан икән, аны чиратта сөйләшеп булмый идемени? Инде ни хәл итәргә?

Тотарга да бармаска! Бетте-китте. Ник килмәдең, дип дәгъва кылыр урын юк. Әйтик, минем алдан ук планлаштырылган кичектергесез эшем бар, ди. Чү, аның алдында акланып тору нигә кирәк әле? Кем каршында? Ни өчен?

Бәлки... бәлки аның, чыннан да, киңәшер җитди мәсьәләсе бардыр? Бәлки мин, нәкъ менә мин аңа ярдәм кулы суза ала торган эштер ул. Бу очракта кешенең моңын-зарын тыңлау гаеп-кыекмы?

Киңәшик дигәне — юкә чөй дә булсын, ди. Шундый дама чакырып торганда, сөттән ак, судан пакь булып кылану ирләрчәме? Бармый калсаң, күңеленә киртләп куячак, ужым бозавы икән бу Лотфиев дигән бәндә, диячәк. Ходай ялгыш ир иткән ул мескенне, дип әйтәчәк. Әйтсә? Рамазан шуннан ни югалта? Алай да... Назирә ничә еллардан соң Фәйзи белән очрашкан ич әле! Миңа кайтып һәммәсен шоп-шома сөйләгәч тә... Аларның ни гәпләшкәннәрен, ни кыланганнарын каян беләм мин? Көннәрнең берендә, җене кубып әйтсә, «Әйе, син айнымас белән әрәм үткән гомеремнең ачуын алдым!» — дисә? Тугры Туктар булып йөрүеңә гарьләнеп, асылынырсың тегеләй...

Барырга!

5

Икенче подъезд.

Өченче кат.

Ишек төбенә җиткәч, чабудан тарткандай, шып туктадым. Басаргамы кыңгырау төймәсенә, юкмы? Борылып китәргә дә соң түгел әле. Берәү дә күрмәде, берәү дә һични сизмәде. Такси тотарга да өйгә сыпыртырга!

Шул чакта ишек биге этәрелде. Бусагада Динә күренде. Кулында бәрәңге, суган кабыклары салган савыт. Күз нурыңны алырлык итеп зәңгәрдән киенгән (күзләре төсенә иш итеп тектергән җинел-затлы күлмәк!), аш-су тирәсендә әвәрәләнгәч, ак алъяпкыч бәйләп җибәргән. Анысы да үзенә бик килешеп, йогышып тора.

— Ой! — Динә, иманеп киткән төсле, бер адым чигеп куйды. — Ой, гафу итегез, Рамазан Каюмович... Керегез, кер, рәхим итегез, мин хәзер...

Динә мине эчкәре уздырып, үзе савытны бушатып, бик тиз әйләнеп керде. Ашыгып кулларын юды да минем яныма килеп җитте. Бик мөлаем итеп:

— Түргә узыгыз. Менә йомшак туфлиләр. Узыгыз, газеталар карый торасызмы, телевизорны кабызасызмы? — диде. Аннары ул мул итеп өстәл әзерләде.

Шул өстәл янында, зәңгәр күзләренең зәңгәрлегенә сокланып, ихластан өзгәләнеп кыстауга каршы тора алмыйча, үз дигән кешемнең ихтимал хыянәте утында көйри-көйри, мин коньяк эчтем. Башта аз гына, аннары күп итеп. Кыюланып китеп, Динәнең ире хакында да сораштым.

— Сынаучы-очучы иде ул, — диде ханым. — Капитан дәрәҗәсенә җиткән иде. Һәлак булды. Сынаучылар язмышы... Кызым белән калдым. Луиза техникумда укый. Икенче курсны бетерде дә студентлар белән Әстерханга китте. Помидор плантацияләрендә эшләячәкләр икән. Хаты юк әле.

Динә киңәшер сүзен һаман әйтми иде әле. Хәер, минем киңәш

бирер чамам да кимеп бара иде инде. Ятып торырга рөхсәт сорадым. «Авырсынмасагыз...»— дидем.

— Бернинди авырсыну да, кыенсыну да юк, Рамазан Каюмович. Бер генә минут, теге бүлмәгә урын салып бирәм, ял итегез. Кәефегез яхшыргач, кайтырсыз...

Ике сәгатькә якын йоклаганмын. Уянып китүгә, кайдалыгымны чамаламый аптырап тордым.

— Торасызмы инде, Рамазан Каюмович?

Динә тавышы ич! Булды, илаһи уптым барысы искә төште. Мин — Динә ханым Мәсәгутоваларда. Биш йолдызлы... Йокы басуы... Ялгышып та төш күрми генә йоклау...

«Торасызмы...» Китәргә кирәк дигәнне аңлатуыдыр. Ә шулай да...

Иплап кенә Динәнең кулларын тоттым. Йомшак, нәфис иде аның куллары. Дорфаланып тартып алыр дигән идем, алай тупасланмады. Аны үземәрәк елыштырдым. Ул иелде дә иреннәре белән яңагымны көйдереп алгандай итте...

Иртән Динә биш тулыр-тулмас борын торды. Чәй куйды, ашарга әзерләде. Мин томан эчендә ятмакчы идем, тик ул бик эшлекле тәкъдим әйтте.

— Ваннага су җибәрәм, юынып чыгыгыз, Рамазан Каюмович. Һәрхәлдә, начар булмас,— диде. Мин бик теләп ризалаштым. Ул янымнан китеп өлгергәнче үк махмырны куарга рөхсәт сорадым. Зарланмаска тырыштым. Сәрхүш зары белән берәүне дә бәхетле итәрмен димә. Шыншымавың хәерле.

— Рәхим итегез. Кичтән куйганым өсталдә...

Миңа, ничек кенә булмасын, тәүлеккә якын югалып торуымны «фәнни нигез»гә куярга кирәк иде...

Урамга чыгуга, такси туры килде. Зарифка юл тоттым.

Йокысыннан торган, юынып-кырынып йөри иде. Тәнзиләсе эшкә китеп өлгергән, рәхмәт төшкере!

— Һо-о-о! Русь реформаторы! Иртә таңнан кем куып китерде безнең тарафларга? Кояш көнбатыштан чыкмаса ярый инде,— дип каршылады ул мине.

— Миңа айныткычта булды дигән кәгазь кирәк, аңлыйсыңмы?

— Аңлаудан баш тартам, әфәндем. Кешеләр шул кәгазьне язмасыннар, эш урынына җибәрмәсеннәр дип, койрыгы пешкән мәче сыман кыланалар, ә син — доброволец...

— Минем эш урынына берәү дә җибәрмәячәк, чөнки анда булмадым. Бүгеннән ялда.

— Ашыктырма. Барысы да тәртиптә булыр. Син бер тавык та бер савыт дигәнен кайгырт башта.

— Савыты булыр сана, булыр!

Икәүләп, мине бәладән йолу шаһәдәтнамәсе юлларга кузгалдык.

Өйдә исә ул кәгазь җәнҗал утына керәчин сибү белән бер булды.

— Курсташым белән күрештем дип алкынганың гына җитмәгән, инде акчаны да суга салып кайткансың. Һөнәрләрең көнләп түгел, сәгатьләп арта! Балалардан оялыр идең, күрше-куләннән,— дип дуллады Назирә. Тагын әллә нинди фәлән-фәсмәтәннәр...

Бүлмәмә кереп утырдым. Шул арада сизми дә калганмын, кесәдән квартира ачкычын алган да, мине биклэп чыгып та китте. Шушы яшемә житеп, гомеремдә беренче мәртәбә өй тоткыны булып калдым. Бар икән күрәселәр!

Мәгълүм шартлар мәгълүм карарга китерә, дип белми әйтмиләрдер. Эврика! Әлеге цивилизация дөньясында яшибез ләбаса! Телефон бар ич! Дус-ишләргә хәбәр салып карыйк. Тик кемгә? Мәҗит ярдәмгә килмәс, үтә аек баш. Салих. Салих... Юк, соңгы елларда, аракы белән арасын өзгәч, эреләнде, коймага ябышып йөргәннәрен онытты... Садыйк Гарипович? Мәгъсүмәсеннән ычкына алмаячак. Мәхмүт, Мөшти,

Гаффи?.. Булышырга теләкләре булуы мөмкин, акчалары юктыр. Үзем кебегрәкләр. Бүген миндә бар барын, тик телефон аша җибәреп булмый ич. Хәйрүш-Хәйләлигә сүз кушсак? Ул инде, максат итеп куйса, акчасын да җиде кат җир астыннан таба, тегесенә дә аптырап калмый. Өметсез шайтан, диләр, җыеп карыйк әле аның телефонын.

— Тыңлыйм.— Телефон трубкасында җанга якын тавыш ишетелде. Мондый тавышлы кешене мәҗлес түренә утыртып, җырлатып кына тотарсың.

— Хәерле иртә, иптәшкәй! Сез Галиҗәнабны Рамай борчырга җыена иде.

— Кайсы Рамай? Лотфиевмы?

— Маташтырма, гозеремне тыңла.

Хәлне аңлаттым. Күнде. Дус-дошман турында уйга бирелдем, чөнки күңел йомшап китте. Авыз эченнән генә җыр сузам:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемен Даян итәм.
Алмагачларың булса да,
Талларга таян икән...

Хәйрүш-Хәйләли — таяныр талларымның берсе.

Ярты сәгатьтән балконга чыксам, Хәйрүш-Хәйләли безнең йорт каршында үрә каткан. Башын арткарак атып, дүртенче катка карый.

Кире кереп, караңгы бүлмәчектән кибеткә-базарга йөри торган сумканы эзләп алдым, кер элә торган җепләрне суырып чыгардым. Шул җепкә сумканы бәйләдем дә балконнан төшереп җибәрдем.

— Шунда сал! — дип ымлыйм Хәйрүш-Хәйләлигә. Кычкырып сөйләшеп булмый. Күршеләр үлмәгән бит. Әлеге тамашаны берүк искәрмәсеннәр иде инде. Югыйсә Назирә кайтуга рапорт биреләчәк. Аннары зилзиләнең нинди кубасы мәгълүм.

Шешәне кулга төшергән генә идем, ишеккә кемдер килде. Кыңгырау чыңлатты. Кат-кат. Эндәшмәдем. Мине бикләп киттеләр, кертә алмыйм, дисеңмени?! Ничек инде ул олыгаеп беткән ир кешене бикләп китсеннәр, ди? Бар, аңлатып кара син шуны ишек катына килгән Төгән Төгәневкә! «Һи-и,— дияр, бер пычак теллесе булса,— сакаллы сабыйкаем, хатының-нан да шул хәтле шүрләргә калдыңмыни инде? Шартлатып бикләп киткәндә дә ләм-мим сүз әйтә алмыйсыңмыни? Бар, баш тарт ирлегеңнән! Сал чалбарыңны, ки хатыннар ыштаны, бәйлә башыңа яулык!»

Кыңгырау тагын чыңлады. Бу юлы таләпчәнрәк. Мин шым торам. Өстәл янына каккан казык. Кыймылдасам, өйдә кеше барлыгын сизәр шикелле.

Инде өченче чиратка төймәгә басты билгесез кеше. Озын-озын итеп чыңлатты. Мин телсез кала бирдем. Янәшә фатирдан күршеләр чыкты. Пенсионер карт, Заһидулла абзый.

— Өйдә юктыр алар, Назирә киткәнне шәйләп калдым. Рамазан командировка-мазарда түгел микән, кичә дә күренмәде,— диде.— Вакытыгыз сыйдырса, кичләтеп кагылыгыз. Назирә кичен өйдә була инде. Үзегез каян килдегез?

— Мин авылдан килгән идем. Кичләтеп сугылып чыгармын әле. Төнлә кайтып китәсе була...

Кем икән бу? Кайсы авылдан? Тавышы таныш та сыман. Искә төшерә алмыйм... Әһә! Балкон ишеген ачып, күренми генә карыйм әле, ул кеше хәзер аска төшеп җитәргә тиеш ич.

Килдем, ишекне ачтым. Теге кешенең чыгып киткәнен көтеп торам. Менә ул... Адаш абый! Ахмаклык өчен бирелә торган җәза аркасында, туганымнан да якын кешене бусага төбемнән борып җибәрдем. Ул бит, үзләренә баргач, өрмәгән җиргә дә утыртмый. Иллә дә барып чыктым мин! Кичкә килергә булып китте. Назирә генә вакытында кайтса ярар иде инде. Тагын җыелыш-фәләне булмаса... Ә бит әле ул кайтканчы айныйсы да бар, чәнчелгере!

Назирә соңламады, кайтты. Сүзсез-нисез генә кухняда кайнаша башлады. Ун-унбиш минут уздымы-юкмы, Адаш абый килеп керде. Ишекне Назирә ачты.

— Рамазан а-бы-ый! — Шул тикле дә якын күреп, өзелеп әйтте, агайны кочаклап кына алмады.— Әйдә, әйдә, уз, чишен.— Аннары, минем белән берниндн дә тәмсезләнү булмагандай, миңа эндәште: — Рамазан! Иптәш Лотфиев! — Хатыным шаяра башлады.— Чык әле, чык оянңнан, беләсеңме кем килде?

Алтын-көмешеңә, җәүһәр-гәүһәрләреңә алыштыргысыз бер гадәте бар Назирәнең: кеше алдында сер сынатмый, авызы тулы кан булса да төкерәсе юк.

Мин дә Адаш абыйны үз каршыладым, ихластан күрештем, түргә чакырдым.

— Узарбыз, узарбыз,— диде ул, гадәтенчә, сабыр-салмак кына. Аның тоныграк тавышы җанга якын иде.— Син, Назирә сеңелем, менә бу сумканы бушат әле. Халидә апаң күчтәнәчкә дип безерик кенә бал җибәргән иде.

— Бик рәхмәт инде, Рамазан абый. Бик рәхмәт Халидә апага! Шул хәтле бал безерик була димени!

— Мин көндез дә бер килеп киттем инде, өйдә кеше юк иде...— Адаш абыйның шулай дию булды, Назирә, мин юньле-юньсез сүз ычкындырып өлгермәсен диптер инде, аңлатырга ашыкты:

— Рамазанның эш белән чыккан чагы булгандыр...

Уф, җилкәдән тауны алып ташлады Назирә! Ык-мык итеп торасы калмады.

Кичке ашны ашадык. Атлыбай хәлләрен сораша-сораша чәйләдек. Назирә өстәл җыештырып, савыт-сабалар юып маташканда, Адаш абый мине үз бүлмәмә керергә өндәде. Бармак белән генә.

Утырыштык.

— Мин хәзер китәм. Сәгать тугызда колхоз машинасы чыгасы. Павлюхинга. Сүзем бар...

— Тыңлыйм, Адаш абый.

— Бик ямьсез хәбәрләр ишетәбез синең хакта, энем.— Адаш абыйның болай да картлык баса башлаган йөзенә кара күләгә ятты.— Чама югалтасың, диләр.

— Артыгын кыланып алулар булды, Адаш абый.

Ул чыршы тактадай каты кулы белән язу өстәленә кагылып куйды.

— Бетер, энем. Ходай өчен акылыңа кил. Әтиләребезнең дуслыгы хакына. Гүрләрендә әйләнеп ятмасыннар иде инде. Гаиләң хакына. Назирә дип ни өзгәләндең яшьлегеңдә. Инде кадерен бел. Яшь-җилкенчәк чагың түгел бит инде. Шөкер, яшең бара. Ябыккан Назирә, бетеренгән...

— Үзем дә аңлыйм, Адаш абый. Бөтенләй туктарга кирәк.

Адаш абый әрнүле иде.

— Булган заманалар,— диде ашыкмый гына.— Илгә ваба килгән. Тиф ябырылган. Бизгәк тинтерәткән. Тагын әллә нәрсәкәйләр... Ну бит аларны берәү дә сатып алмаган. Син бит, энем, илгә афәт булып төшкән чирдән акча түләп өлеш аласың. Мин сөйли дә, үгетли дә белмим, эшләп кенә өйрәнгән кеше мин, бетер яман гадәтеңне, хода хакына. Булма рисвай! Шуны әйтергә дип атап килдем...

Адаш абый — «таяныр таллар»дан.

Аны троллейбус тукталышына кадәр Назирә белән икәүләп озаттык. Шуннан сөйләшеп тә киттек.

Ә йокларга яткач, башыма чыгымчы бер фикер килеп ябышты. Нәрсә дип әле чит кешеләр минем шәхси тормышыма тыгылалар шул кадәр? Мин — мин инде, кай җирем авыртуда кемнең ул кадәр эше бар? Нәрсә дип әле читтән-чаттан да кызганган булалар? Кызганычка калганмы әллә мин?

Моңа каршы фикер дә уянмады түгел. Кеше булган кешеләрнең

һәркемдә эше бар. Алар минем туры юлдан гәүдәмне төз тотып баруымны телиләр...

## 6

Кеше булган кешеләрнең һәркемдә эше барлыгын мин Адаш абый килеп киткәннән соң бер атна чамасы үткәч, бик җилле аңладым.

Гаиләдә чираттагы җәнҗалдан соң нык сәрхүшләшеп кайткач, ишек шакып карыйм, ачмыйлар. Дөбердәтергә керешкәнче ачкычым белән маташып карадым — файдасыз! Эчтән ачкыч тыгылганмы, нәрсәме, ачылмый — вәссәлам! Эчкән кешегә песинең койрык күтәреп йөрүе дә ошап бетми, диләр. Хак инде.

Дөбердәтә торгач, ишек ачылды. Аннан бөтен йортыбызның, алай гына да түгел, шәһәрнең мөхтәрәм кешесе — Бөек Ватан сугышы ветераны Шәйхи абзый Гыйльфанов килеп чыкты.

— Нәрсә, энем, ни дип шаулыйсың? — дип сорады. Шул чакта, кислород камерасына кертеп чыгардылармыни, кинәт айнып киттем. Хатамны бик төшендем, тик соң иде инде. Шәйхи абзыйның карчыгы урын өстендә ята лабаса! Ә мин, дүртенче катка дип, бишенчегә күтәрелгәнмен икән бит!..

Гафу сорап, ялгышуымны аңлатып торган арада күрше квартиралардан ике ханым чыгып, шаулый башладылар. Кыскасы, эш милиция бүлегенә барып житте. Бу инде минем юньсезлегемнең шул көнгә пешеп житкән иң ачы җимеше иде.

Акланыр урыным да, боргаланыр җаем да юк иде. Нинди җәзага тартсалар да, берәүгә дә әнә очы кадәр дә үпкәли алмый идем. Әмма карт полковник Шәйхи абзый милиция хезмәткәрләренә үзе нидер аңлатты, дәгъвасы юклыгын ачык әйтте.

Аның күршеләре бу хәлгә бик тузындылар.

— Синең ише сөяксезләр азындыра бу адәм актыкларын! — дип чәрелдәде ханымнарның берсе.— Утлы табага бастырырга кирәк мондый җәнҗалчыларны! Таш капчыкка тыгарга, бер кисәк икмәк белән бер стакан су биреп яшәтергә. Нибуч, шул чагында акылга килерләр иде...

Шәйхи абзый алар белән дә бик тыныч, бик сабыр сөйләште. Абруе бик олы шул аның. Күршеләре минем өстән янә шикаять кылып йөрмәделәр.

Назирә өчен әлеге очрак соңгы сигналларның берсе булды.

Мин дә упкын читенә якынлашуымны әлегәчә булмаган ачыклык белән тойдым, ләкин...

## 7

Ләкин күңел тормозына баса алмадым. Дөресрәге, нәфсем тормозына.

Май урталары иде. Шимбә. Иртүк сәгать алты булыр-булмаста колхоз базарына юл тоттым. Кибетләр ачылганны көтсәм, тәпи сузасымны сизеп торам. Итәк астыннан эш йөртүче агай-энедән берәр нәрсә юнәтеп булмасмы дигән өмет белән искәнеп бактым. Берсе эссенция тәкъдим итте, бәясе дә сырт сынарлык түгел. Кыймадым. Икенчесе самогоны барлыгын төшендергән иде, хәлем хөрти булса да, дәүләт стандарты белән ясалганы табылырына өметләнеп, китеп бардым. Йөренгәләп тора идем, күзем әстерхан чикләвеге үлчәтеп торучы берәүгә төште. Дикъкатьне тартуы шуннан: бик тә бик таныш йөз, тик үтер, кем икәнен, кайда һәм кайчан күргәнемне әйтә алмамдыр төсле.

Читтән генә чекерәеп күзәтәм. Урта буйлы бу картның баш түбәсе самавыр җиздәй ялтырый, ә чигәләрендә һәм түбәсе артында яна яуган

кар сыман чәчләре дулашып тора. Борыны карчыганыкыдай. Зур күзләре ялт-йолт килә, керфекләрен еш-еш йома. Үзе сәлперәйгән булса да (җилкәләр бутилкәләнеп калган), тавышы шактый көр.

Якынрак килдем. Сатучы:

— Пахуды белән, артыгы белән, туганкай,— дип сөйләнә-сөйләнә картның сумкасына чикләвек бушата. Карт, күрәсең, белеп тора: борыч сатучы белән чикләвек сәүдәгәреннән алырсың артыгын! Әмма ачуланмады, елмайды гына һәм:

— Их, син! — дип куйды.— Хәйләкәрлегең кадәр юмарт та була алсаң иде...

«Их, син!..» Хәтерләдем! Таныдым! Кырык елдан соң да таныдым! Картның акча түләп, чикләвекче белән эшен бетерүен көттем дә, ул китәргә борылгач, каршысына төштем.

— Исәнмесез, Гали абый! Мине танымыйсыздыр да инде, гаҗәбе юк. Рамай мин, Донской абый, Рамазан Лотфиев!.. Шәкертегез... Заманында бергә эшләгән идек...

Гали абыйның хәле киноттән начарланып киткәндәй булды. Кулындагы сумкасы җиргә төште, аннан чикләвекләр тәгәрәшеп чыкты. Карт, ярга алып ыргыткан балык шикелле, өзек-төтек сулап, иркенләп тын ала алмый торды. Мин шүрләп куйдым, шулай да югалып калмадым, аны култыклап алдым, тынычландырдым. Аннары сумкасын күтәреп алдым, чәчелгән чикләвекләрен җыйдым.

— Ба-а-а! — диде исен җыеп Донской абый.— Ба-а-а! Рамай! Сине дә күреп үләргә насыйп икән...— Ул миңа кул сузды, күрешик дию иде.— Син Казандамыни соң, Рамай?..

Бер-ике авыз сүз генә үзем турында аңлаттым да, аның бик аз гына көтеп торуын үтенеп, самогонлы эзләргә китеп бардым.

Гали абзыйны көттерүем озаккарак китте дип борчылган идем, ул алай ялыкмаган булып чыкты. Әллә кем белән кызып-кызып бәхәсләшеп тора иде, мин килеп җиткәнне искәрми дә калды.

— Әйдәгез, Гали абый, безгә кайтабыз. Һәммәсен шунда сөйләшербез.

— Ерак торасыңмы соң син, Рамай? Мин инде троллейбус белән кольцога төшәрмен дә, аннан экспресска утырып китәрмен дигән идем. Мин бит Дәрвишләр бистәсендә, Дербышкида дигәнем... Андагы картлар йортын беләсеңме?

Шушы сүздән әллә нишләп киттем, тик абзыйга һични сиздермәскә тырыштым.

— Минем квартира Ямашев проспектында, якын гына,— дигән булып, сүзне икенчегә борырга ашыктым.— Җәяүләп кенә кайтабыз. Өйдә ялгызым гына, аулак. Хатын белән кызым бакчага киттеләр, Идел аръягына...

— Алаймы? Алаймы? Ярар, алай булса, синең резиденцияне дә күреп чыгыйк...— Гали абый минем җайга атларга өлгереп үк җитә алмый иде шикелле. Мин адымнарымны акрынайттым. Ул, тынына капкан төсле, гыж-гыж килә иде. Сабыррак атлавымнан аңлап алды.

— Ашыгып булмый шул инде хәзер, Рамазан,— дип куйды. Аның бу сүзләре күңелнең әллә кай җиренә энә булып кадалды.— Ашыгып булмый. Тотрык бетте... Яшь тә бара... Җитмеш алтыны түбәләмә итеп киләм бит... Аннары, үзең беләсең, шаярылды бит бу тормышта.

— Хәзер, Гали абый, хәзер... Шәплэп иртәнге чәйне эчәрбез, хәл алырбыз,— дип сөйләндем.

Гали абый фатирыбызны ошатты. Җиһазларны җентекләп күздән кичерде. Китапханәмне карады. Аннары бер читкә барып утырды да моңаеп-боегып калды. Начармы-яхшымы, үз оясында яшәгән кеше тормышын күреп йөрәге бозылды булса кирәк. Мин өстәл хәстәрләгәнче ләм-мим эндәшмәде. Җыерчыклар ермачлаган бүшәнүле йөзендә көзге болытлар йөзде дә йөзде шикелле.

Абзыйны өстәл янына чакырдым. Ул, йокыдан уянып киткән төслерәк хәлдә, табынга теләр-теләмәс кенә килде. Аш-суга да, рюмкаларга да игътибар итмәстән, күңелендәгесен сөйли башлады.

— Матур яшисең, Рамазан энем... Иң кадерлесе — гаиләң бар, балаларың... Үз квартираң, үз тәртипләрең, үз иркең... Мин менә ялгыз ата каз булып кичтем гомеремне. Районда театр ябылгач, нефть якларына киттем. Анда да театр эшли иде, урнашмадым. Чегән тормышы гарык иткән иде инде. Үзешчәннәр белән эшләдем. Бик талантлы яшьләр кылә бит хәзер үзешчән сәнгатькә... Эшлә дә эшлә генә! Ну-у! Саулык бетте. Бетте! Икенче ел инде менә Дәрвишләр бистәсендә... Тормыш кругом кармәзин. Тәмуг. Рухи тәмуг. Күрмәгәнгә күрсәтмәсен!...

Мин Донской абыйның йөрәгендәге сагышлы өермәне аңларга тырыштым.

— Тотып куйыйк әле, Гали абый. Әйдәгез, аш булсын! Үземнең дә хәл шәптән түгел,— дидем.— Исәнлеккә, Гали абый! Ничә елдан соң очрашуыбыз хакына!

Торып бастым. Рюмкамны авызыма китерергә иткән идем, Гали абый күзләрен шарландырып (мин зур ачылган ул күзләрдә ниндидер гайре табигый очкыннар күрдем һәм акылына зыян килгәнме әллә моның, дип уйлап алдым), чыраен сытып, миңа үрелде. Уң кулыма чытырдап ябышты, рюмкамнан хәмер чайпалып түгелде.

— Эчмә, Рамай! Эчмә, Рамазан! Бер үк эчә күрмә, энем! Улым бул, бәгырем бул, эчмә!..— Аның тавышына кыргый бер ялвару аһәңе үтеп кергән иде. Әйе, әйе, кыргый ялвару. Иңрәүле аваз. Гадәти генә үтенү, гадәти генә гозерләү түгел иде бу.— Эчмә, ташла. Хәмер корбаны ялварып сорый моны синнән, хәмер корбаны. Мин...— Гали абый үкереп елап җибәрде. Аны юатыр да, туктатыр да хәл юк иде. Мин аптырап калдым, баш төзәтү дигәнем онытылды, ирексездән айнып киттем.

Елап туктагач, ул өстәлгә салган беләкләренә башын куйды. Аннары уң кулы белән йөрәген тотты.

— Миннән гыйбрәт ала күр, энем. Эчмә, Рамазан, эчмә... Саулыгыңны сакла, бәхетеңне саклый күр... Миннән васыять шул, бары шул гына...

Ул тагын хәлсезләнде.

— Ашыгыч ярдәм машинасы чакыртыйммы, Гали абый?

— Үтәр әле... Күпмедер гомерем калган булса, узар, Рамазан энем. Бераз тынычланыйм да, мине кольцога кадәр озатырсың, яме? Дөньянықын белеп булмый...

— Такси белән илтеп куярмын, Гали абый, борчылмагыз...

Аны картлар йортына имин тапшырып кайткач, үземне бизгәк тота башлады шикелле. Тыела алмыйм, калтыранам. Калтыранган кулларым белән мишәр абзыйдан алган шешәне унитазга илтеп бушаттым да, тәрәзәләрне ачып, бүлмәләрне җилләтмәк булдым.

— Житте! Нокта!

Тик ноктаны куярга шактый соңарган булып чыктым. Никах мәсьәләсен карау өчен судка чакырдылар. Суд карарыннан соң ике атна дигәндә, Донской абзый мактаган квартира бүленде...

## 8

Егерме бишенче май. Якшәмбе. Минем туган көнем. Язмышым бырғысы бүген таңда илле алтыны уйнады.

Иртән беренче рейс теплоход белән Идел аръягындагы бакчамнан кайттым. Бәлки искә төшереп, килеп чыгучылар булыр, чәй хәстәрләп торырга кирәк, дидем. Бакчага куна барган идем. Анда һава гаҗәеп саф, ымсыз тынлык. Өстәвенә чишмә суы эчеп туйгысыз. Бакчада булып кайткач, шәһәрдә краннан килгән суны эчәсе дә килми.

Төнлә һәм яктырыр-яктырмас ук иртән шәп кенә яңгыр яуды анда. Табигатьтә яшеллек патшалыгы. Сандугач сайрап кинәнә, аңа кәккүк кушыла.

Табигатьнең гүзәллеген үсмер чагымдагыча кабат тоя башлавыма өч ел булды. Тормыш матурлыгы, яшәү мәгънәсе турында, бәхетнең ни икәнлеге хакында тирәннән уйлана башлавыма да өч җәй, өч кыш үтте. Шуңа кадәрге чирек гасырдан артыграк гомер ничектер әйле-шәйле булып, күп нәрсәгә кул селтәп, байтак хәл-әхвәлгә ваемсыз гына карап уздың. Моның мәгънәсезлек икәне дә билгеле иде югыйсә миңа. Бүтәнчә итәргә кодрәтем җитмәде. Сөрем аралаш аккан елларда байтак нәрсә ватык көзгедәгечә күренә икән...

Юл киемнәрен салып, өс-башымны алыштыргач, кулдан килгәнчә мул итеп табын көйләп куйдым. Минем хәстәрлегем түгәрәкләнгәнне генә көткәндәй, ишек кыңгыравы чыңлады. Кемдер килде!

Ашыгып ишек ачтым. Элемтә бүлегеннән бер ханым. Телеграмма сузды.

Кемнән бу телеграмма? Эчтәлеге белән танышудан да элек иң соңгы сүзне карадым: «Гульзада». Кызым Гөлзададан. Чаллыдан.

«Кадерле әти, туган көнең белән котлыйм, сәламәтлек, уңышлар телим. Бәхетле бул! Кайта алмавыбыз өчен кичер, Фәрһад командировкада. Сине чын күңелдән ихтирам итүче кызың Гөлзада».

— Рәхмәт, кызым, рәхмәт! Туган көнемне хәтереңнән чыгармавың өчен рәхмәт! — Иреннәрем шулай дип пышылдады. Ә кияү юлдан кайтып керми инде ул. Автомобильләр сынаучы инженер.

Бик акыллы, бик сабыр булып үсте Гөлзада. Әнисе юлыннан китте, медицинаны сайлады. Хәзер педиатр. Уларына яшь тулыр-тулмас кына әле. Яшь гаиләләр йортыннан фатир бирделәр үзләренә.

«Сине чын күңелдән ихтирам итүче кызың Гөлзада...» Мин бу телеграммага бик шатландым. Моннан берничә ел элек балаларның явыз мәчедән өркеп очкан чыпчыклар сыман читләшүләре мине пычаксыз суя иде. Инде, әниләреннән аерым булсам да, кызым белән улымның янәдән миңа тартылулары минем өчен бәяләп бетергесез шатлык иде. Шулай да, бер дә боргаланмыйча таныганда, мин телеграмманы әниләреннән түгелме икән дип ымсынган идем. Назирәдән түгелме дип. Гәрчә мондый өметкә бернинди нигез булмаса да. Назирә төнлә төшкә кергән иде. Сүз җаеннан әйткәндә, Назирә төшләремә гел елмаеп, бик сабыр, акыллы сөйләшеп керә. Югыйсә тормышта төрле чаклар булды бит инде...

Сәгать уникенчегә китте дигәндә, тагын ишек кыңгыравы төймәсенә бастылар.

Зариф килгән! Зариф!

— Хуш киләсең, Зариф Сафиевич! — дип каршыладым. — Рәхим ит, сабакташ!

Соңгы елларда бик сирәк килә башлады ул.

— Ник ялгызың гына? Тәнзилә өйдә юкмы әллә? — дидем.

Озын буйлы, киң җилкәле, каратут йөзле авиация инженеры Зариф Солтанов — телгә беткән кеше. Хатын-кызның һушын алырлык итеп елмая да тасма телләнә башлый. Биредә тел чарлауны кирәк тапмады, фикерен гади генә итеп әйтте.

— Былтыр да килә алмаган идем, барып чыгыйм әле, мин әйтәм. Хәзер безнең кеше түгел түгелен дә син...— Зариф бик кәефсезләнгән кыяфәт белән сөйләнеп алды. Чынында ул инде кәефләнергә өлгергән, шаярырлык дәрт җыйган иде.

— Сезнең кеше булмый, ЦРУданмы әллә?

Зариф сискәнеп киткәндәй хәрәкәт ясады.

— Син нәрсә? Ходаем сакласын! Мин әшәке мәгънәдә әйтмим, Рамазан. Кайбер сыйфатларың буенча безнең полкның личный составы исемлегеннән сызылганлыгыңны гына әйтүем. Русь реформаторы син, Рамазан Каюмович. Реформаларың күпмегә барыр?..

— Иә, сайрама, утыр чәй янына, гәпләшик бер. Күрешмәгәнгә дә байтактан.

Зариф яшь егетләр житезлеге белән урыныннан торды да зур-зур атлап, ванна бүлмәсенә кул юарга кереп китте.

— Чәй дә ярый торган нәрсә. Грузиядә чәй үстерүче совхозга экскурсиягә баргач, аның житмеш жиде төрле сихәте турында сөйләгәннәр иде. Тик мин уйлыймын, ул сихәтләр Россиядәге татар карчыклары өчен генә бугай. Миңа лично... Карасана, онытып торам, минем сиңа кечкенә генә бүләгем бар иде бит.— Зариф Сафиевич куен кесәсенә тыгылды һәм аннан бик матур капка салынган авторучка тартып чыгарды.

— Үзе яза! Алтын каләмнән алтын сүзләр коя. Күп итеп премия алганда гына тот кулыңа. Гади зарплата алганда әрәм итмә, яме.

— Рәхмәт, якташ, олыладың.

— Ну, Каюмович, башка-баш диюем түгел, шулай да алтын путалы рюмкаңны куймый котыла алмыйсың.

— Бик теләгең бар икән, рәхим ит.— Буфетны ачып куйдым да сорадым: — Ниндиен телисең?

Зариф әллә ни әдәп сакламады.

— Фью-ю-ют! Мондый хәзинәгә ия булыр өчен күпме эчми торырга кирәк?

— Өч ел,— дидем мин.— Зыялы кешегә саныйсың үзеңне. Авырткан сөялгә гел генә басып тору интеллигентлык төшенчәсенә сыеп бетми түгелме соң? Әйт, кайсы белән сыйланасың?

Тавышымда суык чагылып китте булса кирәк, Зариф ык-мык итә калды. Аннары, буфетны ябып куймасын, бөтенләй бирмәве дә мөмкин бит моның дигән төсле, өзеп әйтте:

— Ачуланмасаң, «Петровская водка»ны татыр идем.

Мәскәүдән алып кайткан аракыны өстәлгә куйдым. Алтын путалы рюмка китердем. Алдындагы тәлинкә янына чәнечке-пычак куйдым.

— Сыңар рюмка белән сыңар канат булып утырырга мәжбүр инде мин, ә, Каюмович? — дигән булды Зариф. Ләкин үтә күреп торам: бу аның рәвешкә килсен өчен, сүз җилеме итеп кенә сөйләве.

— Минә нәрсә, Зариф туган... Бүтән хәсрәтләрең булмаса, минем өчен хафаланма. Кеше ашына катык катырга ният итмә. Элеккеләр үткәнбеткән, гүргә киткән!

Бер-ике рюмканы бушаткач, Зариф Сафиевич үзендә атаклы ораторлар белән ярышырлык дәрман тоя башлады.

— Хөрмәтле Рамазан Каюмович,— диде ул, торып баскач.— Кулымны пинжәгемнең сул канатына куеп әйтәм, «Үткән-беткән, гүргә киткән!» дигәнеңне мәрмәргә чокып язарга кирәк. Укысыннар! Мин дә килеп укырмын. Бәлки, акылга керермен шуннан соң...

Акылга керүнең, ихтыяр көче булмаса, нинди корбаннар соравын белмәсәм икән. Мәрмәргә чокып язган сүзләр генәме соң, күк гөмбәзенә яшен уты белән язсалар да файдасыз. Шуны Зарифка да әйттем. Нинди йогынтысы булыр дип түгел, эчемдә кату булып калмасын дип әйтүем иде.

— Сүзләр көчсез, Зариф, гел көчсез. Акылга килер өчен бердәнбер дару бар, бердәнбер...

Зариф иреннәрен бүлтәйтеп, күзләрен шакмакландырып, миңа карап тора башлады.

— Нинди? — Ул шундый тырышлык белән сорады ки, башы алга чайкалып китте.

— Ике сүздән тора: и х т ы я р к ө ч е! Шуннан башка дәваланып азапланулары да, сиңа укыган вәгазь, үгет-нәсихәт тә, шелтәләр, эштән куулар да — һәммәсе файдасыз... Ирмен дигән ир кешедә әнә шундый көч булырга тиеш икән. Мин моны артык соң аңладым. Кемнәрдер кичергәнне түгел, үзем газапланганны кычкырасым килә. Мин эндәшмәсәм, минем өчен кем әйтер?!

— Даһ,— диде Зариф, кабымлыгын чәйнәп йотты да авыз тирәсен

салфетка белән сөрткәләп куйды.— Даһ... Синең белән озаграк утырсаң, эчкән аракы алмый башлаячак, беләсеңме? Тамугтан чыккан шайтан вәсвәсәсе ыругдашлары өчен бик үтемле була, диләр иде аны...

Мин ирексездән көлеп куйдым.

— Төрттергәләп утырсаң да, үзең дә сизмәстән, ярыйсы әйттең бит әле: тамугтан чыккан! Нәкъ өстенә бастың, тамугның да ниндиеннән әле! Мин сиңа ихластан әйтәм: бар булдыгыңны җуеп бетергәнче син дә акылыңа кил!

Зариф, чытлык кызлар хәрәкәтенә охшатып, уң кулын селкеде.

— Хәзергә Зариф абзаң, әйе, әйе, абзаң, мин синнән бер яшькә өлкән, шәп котироваться итә әле, арзан бәяләнми.

— Хәзергә...

— Пенсиягә ерак калмады.

— Аннары! Үрдәк әйткәнчәме? Бөтен дөньяны су басса да ни кайгым бар, дигән ди бит ул. Сиңа да шулаймы?

— Ярый, ярый, балыкны йөзәргә өйрәтмиләр, каргага парашют кирәкми... Ә пенсиягә чыккач, муенымнан элмәк төшәчәк. Кемнәрдәндер бәйлелек бетәчәк. Сәлам аларга шуннары! Бүген, бүгеннәрдә мин ата казга да сәлам бирергә мәҗбүр. Парткомына, завкомына, конструкторлык бюросы җитәкчесенә. Законлы пенсиямне учлап ала башласаммы, мин аларның җиде бабаларын казып чыгарып, сварка утына бастырам әле. Бүген минем борынга чирткәләп торучыларны автоген уты белән көйдерәчәкмен. Аның бит яшертен эчүчеләре дә әллә кем булып йөри. Не пьющий, не курящий, попугай говорящий! Аракы кытлыгы башлангач, бер цех начальнигы, хәшәрәт, яшь егетне, эштән бушатып, үзенә аракы алырга чиратка җибәргән...

Аның әле сөйләгәннәре әрнеп-көюдән иде. Үзе дә исереклек эшәкелекләрен эшли тора ул, үзен дә эттән алып эткә салып сүгә, бүтәннәрнең кыек басканнарына да җаны әрни. Тик... ни мәгънә?

Зариф тагын кул селтәде. Бу юлы сул кулын.

Менә тыңлаусыз куе кара чәчләрен ике учы белән артка сыпырды, урындыгына тураебрак утырды һәм миңа текәрәеп карады.

— Ачуланмыйсыңмы, бер сүз әйтәм.

— Әйтеп кара.

Мин чынаягымны өстәл эчкәресенәрәк этеп куйдым да аңа борылдым.

— Шартым шул: ачуланмаска вәгъдә бир.

— Ачуланмам.

— Син, якташкаем, госел коенып, тәһарәт яңарттым да эш бетте, фәрештәгә әйләндем, ил күзендә абруйлыларның да абруйлысы булдым, дип фикер йөртәмсең? Ялгышма! Кара сакалың, кара шәүләң кебек, сине каберстанга кадәр озатып барачак. Ярты ел урын өстендә ятып вафат булсаң да, шул ай эчендә аракы сүзенең «а»сын әйтмәсәң дә, эчеп үлгән диячәкләр. Миңа да шул күчтәнәч хәстәрләнгән... Димәгәйләре! Мин үлгәч, җитмеш громкоговорительдан җитмеш Левитан кычкырып торса да, ни кайгым?! Тирә-юньдә бүтән берәр шаккатыргыч хәл булгач, онытачаклар мине. Кешеләргә аларга гайбәтнең свежие кирәк, түтәлдән өзеп кергәне. Искергән гайбәт аларга күгәргән балык булып тоела. И... синең игътибар иткәнең бармы? — Зариф уң кулының имән бармагы белән күккә төртте.— Гайбәтне кем ярата, кем майлап-майонезлап сөйли? Үзе зина кылучы, үзе карак, үзе әләкче һәм сатлык җан булган адәмчекләр... Беләсеңме, син белергә тиеш, сезнең контордагы бер дама хакында ниләр генә сөйләп бетермәделәр?

— Беләм! — дип кырт кистем.— Монда аның ни катнашы бар?

— Бар! — Зариф йодрыгы белән тезенә сугып куйды.— Ә бит ул гайбәтне таратучы кеше үзе ул даманы көчләргә ябышкан булган. Югарыга чакыргач, чырае кәфен төсенә кергән. Калтырап, дерелдәп: «Бетте баш!»— дип бара икән. Баксаң-торсаң, аны өскәрәк күтәрергә дип әңгәмәгә дәшкәннәр булып чыккан... Менә бит ул ничек тә әйләнгәли!..

Миңа боларны тыңлап тору җайсыз иде.

— Үзебез дә гайбәткә чумып барабыз түгелме, Зариф Сафиевич,— дидем.— Бүтән кайгыларыбыз да бетмәгән.

Зариф килешмәде.

— Мин гайбәтен сөйләмим, теге подлецның гадәтен әйтәм. Андый табигатьле кешеләрне белеп торырга кирәк. Алар беркайчан да: «Миннән сакланыгыз!» — дип, маңгайларында кызыл ут кабызып йөрмәячәкләр...

— Чәй яңартыйммы? — Зарифны яңадан өстәл кырына дәштем.

— Ясап куй, иренмәсәң. Ә мин синең рөхсәтең белән, иптәш юбиляр, ну, юбиляр түгел, моннан фәлән ел элек шушы числода дөньяга килгән кеше, кәеф яңартыйм әле.

— Ихтыярың.

Ул шешәгә үрелгән генә иде, имәнеп китәрлек итеп кыңгырауга бастылар. Зариф, утта пешкәндәй, кулын тартып алды, лап итеп урынына утырды. Җинаять өстендә тоттылар диярсең.

— Фу, шайтан! Нервылар! — диде аннары, хәтта миннән дә кыенсынып куйды.— Шул кадәр шылтыратмасалар соң...

Тагын элемтәче ханым килгән иде. Тагын телеграмма китергән. Кул куеп алдым. Янә рәхмәтләр укыдым. «Борчыйлар сезне»,— дидем. Ханым бик гади генә:

— Эшебез шул,— диде дә лифт кабинасы ягына атлады.

— Кемнән? — Зарифның бик беләсе килә иде, ахры.

— Хәзер укыйбыз.— Үзем тагын бер кат өмет аралаш ымсыну кичердем. Назирәдән түгелме? Юк, түгел. Улымнан. Төмән өлкәсеннән. Нефтьче улым юллаган. Аны мин артыграк сагынам. Урта мәктәпне тәмамлаганнан бирле янибызда торганы булмады. Әүвәле Мәскәүдә, Губкин исемендәге нефть институтында, аннары Әлмәттә, бишенче елы инде менә Төмән өлкәсендә. Ялга да ике елга бер генә кайтып китә. Болай тормышы бик күркәм. Ике бала үстерәләр. Хатыны укытучы.

— Я, укып җибәр инде, ни дип мәрткә киткән төсле торасың?

— Укыйм. «Хөрмәтле эти, туган көнең белән чын йөрәктән тәбриклим. Саулык, уңышлар, бәхет гомерлек юлдашларың булсын. Так держать! Минем эшләр әйбәт. Кочып: улың Рамил».

Рамилгә утыз тулып килә. Назирә дүртенче курста укыганда тапты аны. Савиновода бер татар абзыеның кече өендә яши идек. Булышырга әби — Назирәнең әнисе килде. Мин нәнине һәм әнисен алып кайтасы көнне эшкә бармадым, рөхсәт сорап калдым. Мостотряд начальнигы җайлы яһүд иде, рөхсәт итте. Кирәге чыкканда, калып эшләрмен, дидем.

«Улың бар!» — дигән хәбәрне фатир хуҗасы белән жиренә җиткергәнче «юдык» инде. Аннары әлеге дә баягы Зарифларга киткәнмен. Ничек кайтканмын, ниләр кыланганмын — һични белмим. Иртән әбинең сөмсере коелуыннан чамалап алдым: егетлек кылмаганмын.

Иртән баш җимерек глобус хәлендә иде. Чигәләргә ике чүкечле шайтан утырган. Чүкечләрнең нindиләре белән бәрәдер, бөтен гәүдәм калтырап китә. Телне әйләндереп сөйләшерлек түгел, игәүгә әйләнгән. Сакалмыек керпе сыртыдай.

Куллар калтыраса да, кырынмый ярамый иде. Өскә-башка адәм рәтләрәк киенгән булдым. Махмыр чагында киемең дә ни җитте генә булса, урының — шәһәр чүплегендә. Хәер, алтын тәңкәләр таккан йөгән генә карт алашаны бәйге аты итә алмый инде ул. Шулай да рәткә керми ярамый иде.

Бәләкәчне алмаш-тилмәш кулыбызда тирбәттек. Мине яхшы, мәрхәмәтле булу омтылышы биләп алды. Назирәгә томырылып караучан булып киттем шикелле. Бу минутларда үземне гаҗәеп кодрәтле дә, сабыйларча көчсез дә итеп сиздем. Башымны мендәргә төртеп, бала чактагыча елыйсы килә иде. Күңелдәгене укырга маһир Назирә минем яңакларымны сыйпады.

Хатыным акыллы һәм сабыр гына түгел, батыр да булып чыкты. Ра-

милгә ай ярым дигәндә, үзлегеннән әзерләнеп, һәммә имтиханнарын тапшыра алды. Өзлегә күрмәсен дип шиккә төштек.

Өзлегүен өзлекмәде, әмма бик ябыкты, суырылды. Малай «быргычы» булып чыкты. Төнлә дә «Подъем!» уйный, көндез дә янымнан ярты адым китәр хәл юк. Өч ай буе тинтерәтте, аннары тынды тагын. Әнисе дә азрак ял алды.

— Бала атасы булдың бит инде, уйланыр идең,— дип сыкранды.— Минә улың үсеп җитсен әле, барсын бәйнә-бәйнә сөйләп бирәчәкмен. Үзе бәяләр кемлегеңне. Шул чагында балаң күзенә ничек карарсың? Син бит томана имгәк түгел, сиңа киңәш-акыл биреп торырга да җайсызланам мин. Белмисең бит, чама белмисең!..

Мондый сүзләргә җенем кабарды. Кычкырынасым, җикеренәсем килде. «Үзеңә юк акылны сатма миңа!» — дип бакырырга җыенган минутларым булды, түздем. «Йөзең кара — телең кыска»,— диләр бит. Хак сүзгә нахак белән җаваплашу да ир-егетлеккә керми...

Зариф утырган җирендә кымшанып куйды. Аннары торып басты да:

— Рамазан Каюмович, мин китим, ә, иптәш Лотфиев? Басты бугай мине Петр аракысы. Иллә зыян юктыр дип беләм. Чит кешедә түгел лә мин. Гаепләмәссең дип ышанам...— диде.

— Ярый алайса, хәерле юл! Искә төшереп килүеңә рәхмәт. Кайткач, Тәнзиләгә сәлам әйтерсең. Онытып бетермә. Минем дуслар болай да сирәгәеп калды.

— Шалканның сирәге яхшы, эрерәк була...

— Һәрвакыт өчен дә дөрес түгел бу әйтем. Мин бит шешә дуслары сирәгәюдән хәсрәт күленә чумарга җыенып әйтмим. Аларның бөтенләй булмавы да бәхет кенә икәнен аңладым.

Зариф айнып киткәндәй булды. Башын күтәреп, муенын сузып сорады:

— То есть, ягъни?

— Ягъни шул: эчкечеләрне тансыклар заманым үтте, бөтенләйгә,— дидем.— Акыллы дусларны, хаклыкка өндәгән иптәшләрне югалтуга әрним. Бик әрним! Чын дуслар — акча түгел, ат урынына эшләп кенә табып булмый аларны. Аларсыз бик кыен. Кыен! Яфракларын көзге җил тузгыткан шәрә агачка охшап калдым дусларсыз...

— Мине кайсы категориягә кертәсең булып чыга инде? Үзең сүгәсең, үзең онытып бетермә, дисең. Алогизм. Логикага каршы килү...

— Бернинди дә логикасызлык юк, Зариф Сафиевич. Син минем өчен аерым бер категориядә. Әлегә упкын чигенә җитмәгәнсең. Тик аяк астың тайгакланып бара.

Ник телемнән ычкындырдым шул сүзләрне дигән көнемә төштем, билләһи! Ябышты шул җөмләмә, чыда гына!

— Син миңа хәзер әйткәннәреңне бала-чагага сөйлә, яме, Каюмович. Йомырка тавыкны өйрәтә, имеш, мин бит синнән бер яшькә өлкәнрәк. Янә дә мин синнән бик күпне артык күргән кеше. Мин дамба өймим, очкычлар иҗат итәм.

— Яхшы, килештем. Әрепләшмик. Әйбәт кенә кайт. Озатып кую кирәкмидер ич?

— Юк! Мөстәкыйль кайтыр хәлдә без. Автоном режимда...

## 9

Яшьлегемдә мин дөньяның фәкать яхшылыкларын гына җыярмын дип хыяллана һәм шуңа ышана идем. Тормышка үчегергә ярамаганын да белеп яшәдем. Рухи җәрәхәтләремне күрсәтеп, кешеләр кәефен бозмаска тырыштым. Зарланып чинавым белән берәүнең дә колагын тондырасым килмәде. Тик барыбер тормышым шома гына барып чыкмады.

Малай чакта күңелгә кереп калган җырның мәгънәсен хәзер тирәнрәк аңлыйм шикелле.

Сандугачның, мескенкәйнең,
Канаты каерылган.
Бер без генә түгел инде
Иленнән аерылган...

Моны фашистларга каршы сугышка китүче егетләр җырлаган иде. Алар илдән аерылуны туп-туры мәгънәсендә әйтеп җырлаганнар. Әмма ил-көннән аерылу — күз күрмәгән, колак ишетмәгән чит-ят җирләргә китәргә мәҗбүр булу, ят тарафларда каңгырып йөрү генә түгел икән ул. Туган туфрагында үзең корган ояда гомер итеп, сине күптән күргән-белгәннәр белән бергә эшләп тә илдән-көннән аерылулар була икән. Канатың каерылса, илгә берегеп китә алмыйсың икән. Канатларыңны үзең каерган булсаң, бигрәк тә...

Оян тузгыса, аны тиз генә сипләр хәл юк. Кайчагында сипләү мөмкин дә түгел икән.

Өйдәге татусызлык корыч холыклы адәмне дә тетрәндерә. Хезмәттәге чатаклыклар, синең өчен кемнеңдер мәсьәләне хәл итеп утыруы, җигелеп эшләп торган кешегә аз ышануы иҗат дәртен сүндерә. Әллә ни төстәге чирләргә — ваемсызлыкка, битарафлыкка, эчүчелеккә җирлек туа. Шулар өчен җылы, дымлы туфрак хасил була. Үз хезмәтеңне хөрмәт итми башлыйсың. Тотрыгы кимегән кешегә халыкара хәлнең үтә кискенлеге дә тәэсир итә бугай. Планета язмышы дип чәч агарта торган заманда яшәве җиңел түгел...

Ләкин бу рәвешле канатлар каерылуда кеше иң әүвәл үзе гаепле.

Упкынга тәгәри язу бик көендерә, шулай да кара җәһәннәм базы авызын ачып торганда янәшәңдә кул сузучылар барлыгы — олы шатлык. Тормыш шундыйлар иңендә бара.

Бер нәрсә бөтенләйгә югалды — гаилә бәхете. Ул кире кайтмаячак. Моны да ирләрчә кичерә белү зарур. Шыңшымыйча, селәгәй агызмыйча. Кулың белән эшләгәнне иңең белән күтәрә белү дә — ярыйсы сыйфат.

Аерылышуга килеп җитүнең мең дә беренче сәбәбе Динә Мәсәгутова белән мөнәсәбәтем булды. Юк, мин аның янына кабат бармадым, үземне тезгенләрлек көч таптым. Тик менә шул бармау Динәнең миңа карата хисләрен нәфрәт-агуга әйләндерде. Фатирында булганнарны түкми-чәчми Назирәгә ирештерү өчен ул үзе бик тырышты. Яманаттан, гайбәттән, гомумән, һичнидән тайчанмыйча, Назирәгә җиткерердәй кешеләргә үзе бәйнә-бәйнә сөйләп йөргән. Иң азактан, числосына кадәр әйтеп, Назирәгә телефоннан үзе шылтыратты. Хатын-кызның бер ишесе шундый оятсызлыктан да тартынмый икән. Дөрес, ул вакытта Назирә дә аңа: «Бу сөйләшү булмаса, кемлегегезне белми калырлар дип курыктыгызмы әллә? Юкка хафалангансыз. Сез бөтен шәһәргә атаклы ич»,— дигән.

Ничек кенә үтсәләр дә, узган еллар — тарих. Үткәннәрне каргау белән генә чикләнергә ярамый. Заманында Сенека әйткән ич, әхлаклы булуның төп шарты — әхлаклы булырга теләү, дигән. Кирәшергә кирәк дигән сүз. Алтын — утта, ир-егетлек бәладән арынганда сынала...

Революция, кискен борылыш һәм үзгәрешләр дәүләтләр тарихында гына түгел, кешеләр язмышында да була. Өч ел инде мин — кайнап торган тормышның уң сызыгында. Бөтен республика күзен текәгән төзелештә эшемне дәвам итәм. Идел аша автотранспорт өчен зур күпер салабыз. Соңгы көннәрдә унберенче терәк баганаңы утырттык. Ул елганың нәкъ уртасыннан күтәрелде.

Күпер Займище поселогы яныннан уң ярга сузыла.

Мин үзем дә килер көннәремә ныклы, ышанычлы күпер корам кебек.

*1986—1987 еллар.*
*Казан.*

# Роберт Миңнуллин

## Ялгыз калгач...

Өйдә Алмаз — ялгызы.
Куркыта әллә нигә,
Берәр нәрсә, берәр ни
Бар микән әллә өйдә?
Нәрсәдер дөп-дөп итә.
Күзгә күренми генә
Нәрсәдер үтеп китә,
Нәрсәдер әтеп китә,
Нәрсәдер төртеп китә.
Нәрсәдер дөп-дөп итә
Бүлмә түрендә генә,
Нәрсәдер дөп-дөп итә
Колак төбендә генә.

Баштарак ул бер яктан
Дөп-дөп-дөп иткән кебек,
Аннары ул өч яктан
Дөп-дөп-дөп иткән кебек,
Аннары ул бар яктан
Дөп-дөп-дөп иткән кебек,
Шуннан соң ул почмактан
Дөп-дөп-дөп иткән кебек...
Дөп-дөп итә! Әллә инде
Берәр карак керәме?
Юк ла, курыкканга гына
Дөп-дөп тибә йөрәге!

## Спортның яңа төре

Спорт өчен тугандыр ул,
Шул спорт — бөтен эше.
Спорт төрләренең Алмаз
Ярата бөтенесен.

Спортның телевизион
Төрләрен ул бигрәк тә
Нык ярата һәм мавыга
Көннәр буе — кирәктә!

Калдырмый ул хоккеен да,
Футбол, волейболын да,
Баскетболын, мотоболын,
Тагын... ягъни, барын да!

Аннан тотына тенниска,
Бөтен эшен ташлый да.
Ә нәфис гимнастиканы
«Ясый» ашый-ашый да.

Иртәнге гимнастиканы
Ясый ул ятып кына.

Тик озаграк ятып булмый —
Кыскарак вакыт кына.

Күренеп тора Алмазның
«Авыр» атлет икәне.
Шуңа күрә калдырмый ул
Авыр атлетиканы.

Җиңел атлетиканы да
Карап бара — калдырмый.
Анысының зыяны юк —
Җиңел булгач, ардырмый.

Көн буена — спорт, спорт...
Юк, барыбер арый ул.
Хәлсезләнә, хәлдән тая,
Ә шулай да карый ул.

Ә телевизор карарга
Сәбәп чыгып тора шул.
Әмма Алмаз түзә һаман —
Спорт чыныктыра шул!

---

Роберт МИҢНУЛЛИН *(1948) — шагыйрь, «Бәхетле булыгыз», «Сөенсеннәр әле каеннар», «Акбай цирк карый» һ. б. татар һәм рус телләрендә басылган уннан артык китап авторы. Ул — Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Архимед белән Спартак

Безнең авыл — данлы авыл!
Ышанасыңмы, туган?
Архимед та, Спартак та
Безнең авылда туган.

Беләм әти-әниләрен,
Беләм бабаларын да.
Туганнары авыл тулы —
Беләм мин аларын да.

Аларның ничек үскәнен
Бигрәк тә әти белә,
Чөнки алар икесе дә
Укыган әти белән.

Икесе дә безнең урта
Мәктәптә укыганнар.
Икесе дә бер партада
Янәшә утырганнар.

Архимед физикасыннан
«3»леләр алгалаган.
Ә Спартак ярышларда
Артта да калгалаган.

Ә шулай да мактый халык.
Чыннан да, мактарлык та —
Спартак Гапсаттаров та,
Архимед Акмалов та!

## Торам менә елмаеп!

Әтиемнең малае
Бераз шаянрак.

Әниемнең малае
Бераз наянрак.

Әбиемнең оныгы
Бераз кирерәк.

Ә бабамның оныгы
Бераз эрерәк.

Абыемның энесе
Начаррак укый.

Сеңелемнең абыйсы
Артыграк йоклый...

Шул бер малай бит инде
Алар барсы да —

Торам менә елмаеп
Сезнең каршыда!

## Җиләк чыпчыгы

Миләш чыпчыгы! Безнең
Җиләкне ник ашыйсың?
Түтәлдәге җиләкне
Нигә читкә ташыйсың?

Кичә дә син тигәнсең!
Бүген дә син килгәнсең!

Мондый начар гадәтне
Вакыт сиңа ташларга.
Миләш чыпчыгы тиеш
Миләш кенә ашарга!

Тыңламыйсың мине син,
Ахры, тыңлый белмисең.
Тот син минем киңәшне.
Аермыйсың әллә син
Җиләк белән миләшне?

Әгәр дә моннан соң да
Тыңламасаң сүземне,
Җиләк чыпчыгы диеп
Йөртәчәкмен үзеңне.

Шулай, миләш чыпчыгы,
Әй лә... җиләк чыпчыгы!

## Җайдаклар

Безнең якның малайлары
(Әйтү түгел мактанып)
Тәпи йөри башлау белән
Чаба атка атланып!

Атларда чаба малайлар —
Атлары да атлары!
Малайларның әле шулай
Чаба торган чаклары.

Атлана да чаба алар
Иярсез дә йөгәнсез.
Бу инде — безнең малайлар
Чын җайдаклар дигән сүз.

Чаба алар, оча алар,
Калмый хәтта эзләре.
Канатлы әллә атлары,
Әллә инде үзләре...

Кызыйлар кала кызыгып,
Энекәшләр — көнләшеп.
Әй оча, оча малайлар
Абыйларга тиңләшеп.

Кирәк булса, очар алар
Йолдызларга, айларга...
Кемдер атларга соклана,
Ә кемдер — малайларга!

## Авырып ятканда

Мәктәпкә дә баралмыйм,
Урыннан да торалмыйм.

Чынаяк та тоталмыйм,
Хәтта дару йоталмыйм.

Карлыккан тавышым да,
Чатный гына башым да.

Китап та укый алмыйм —
Хәлләремне бик аңлыйм...

Малайлар урамдадыр,
Туйганчы уйныйлардыр,

Аларны тыймыйлардыр,
Чыгармый тормыйлардыр...

Их, әни тыймасамы?
Урамда уйнасаммы?—
Мин дә терелер идем,
Аз гына уйнасам да
Терелеп керер идем.

Тик әни чыгарырга
Бөтенләй уйламый да...

Терелермен әле бер
Урамда уйнамый да!

## Балаларның көлүе

Яңгыратып көлсәк бергә
Дөньяның бар балалары,
Җир шатлыкка һәм бәхеткә
Күмелмичә калаламы?

Балаларның көлүләре
Тынычлыкның җыры сыман.
Ул көлүгә балачакның
Әллә күпме җыры сыйган!

Кирәк түгел тәрҗемәче —
Көлешәбез бер телдә без.
Бергә булсак, бердәм булсак,
Бирешмәбез беркемгә без!

Балаларның көлешкәнен
Ишетсен Җир, тыңласын Җир!
Балаларның көлүеннән
Берчакта да тынмасын Җир!

Көлү безне дуслаштыра,
Көлү безне берләштерә.
Бәхетле дә, көчле дә без,
Бергәләшеп көлгәч кенә!

Ә балалар көлә икән
Илебездә, Җиребездә,
Димәк, Җир дә исән әле,
Имин, димәк, илебез дә!

## ӘДӘБИ МИРАС

# МАКТАЛГАН ҺӘМ ТАПТАЛГАН ӘДИП

Гаяз Исхакый — иманы шулай кушканга, Октябрь революциясен кабул итә алмыйча, эмиграциягә киткән, иманы кушканча, шунда нидер эшләгән, нидер язган һәм шунда үлеп калган каләм ияләренең берсе. Әмма бу хәл аның революциягә кадәрге әдәби мирасын халыкка кайтаруга һәм әдәби-гыйльми әйләнешкә кертүгә комачауламаска тиеш. Чөнки, беренчедән, Г. Исхакый талантлы прозаик, драматург һәм публицист, шул заманда ук дөнья күргән сигез томлык әсәрләр җыелмасы авторы. Дөньяга карашы ягыннан ул революцион демократ, һәм аның иҗаты Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирханнар иҗаты белән бер үк үзәннән бара. Икенчедән, Г. Исхакый «Теләнче кыз» һәм «Мулла бабай» романнары, күпсанлы повестьлары һәм хикәяләре, сәхнәдә шаулап уйналган пьесалары белән иң караңгы татар авылларына кадәр барып җиткән, укылган, танылган. Өченчедән, революциягә кадәрге әдәби тәнкыйть үк инде Г. Исхакыйны яңа татар әдәбиятына нигез салучы итеп бәяләгән иде. 1910 елда Г. Ибраһимов, мәсәлән, болай дип язды: «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәтле вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора. Бу мөхтәрәм зат татар әдәбиятына башлап реализмны кертүче иде». Г. Тукайның «Кем ул бу милләтне күтәргән кеше?» дип башланып, «Караңгыда идек, аттырды «Таң» кем?» рәвешендә дәвам иткән һәм «Безнең өчен зәхмәт чиккән, соңыннан рәхмәтен уртак иткән кем?» дигән сүзләр белән тәмамлана торган «Кем ул?» исемле мәдхия язып чыгуы да очраклы хәл түгел иде.

Боларга тагын Г. Исхакыйның революциягә чаклы ук ил күләмендә танылганлыгын да өстик. Үзәк рус матбугатында аерым әсәрләре басыла, үзе турында мәкаләләр чыга. А. М. Горький да аның иҗатын күреп алган, күп еллар буе алар хат язышканнар. Г. Исхакыйның даны хәтта ил чиген дә атлап чыккан. М. Һартман исемле Берлин профессоры китабында (1910) яисә Лондонда чыга торган «Рашен ревью» журналында (1914), мәсәлән, Исхакый турында байтак мәгълүмат бар.

Егерменче елларның ахырына кадәр дип әйтерлек «ак эмигрант Гаяз»ның әсәрләре дөньяга чыгарылган һәм пьесалары сәхнәдә күрсәтелгән кебек, дәреслек һәм хрестоматияләрдә дә аңа җитәрлек урын бирелгән. Ә шуннан соң, Сталинның шәхес культы көчәю белән бәйле рәвештә, әсәрләре әдәби-фәнни әйләнештән чыгарыла һәм исемен хәтта телгә алу да тыела башлады.

Шөкер, ул заманнар узып китте, Г. Исхакыйның әдәби мирасын халыкка кайтару һәм гыйльми әйләнешкә кертү кичектермәс бурыч сыйфатында көн тәртибенә килеп басты. Чөнки бу мирастан башка татар халкының мәдәни үткәне җитәрлек тулы күренмәгән кебек, XX йөз башы татар әдәбияты тарихы да чын мәгънәсендә фән була алмый.

Г. Исхакый Казан губернасы Чистай өязенең Яуширмә авылында мулла гаиләсендә 1878 елда туа. Атасыннан укырга-язарга өйрәнгәч, башта Чистай, аннары Казан мәдрәсәсендә белем ала. Соңра Татар укытучылар мәктәбен Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов лар белән бергә тәмамлый. Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта һәм яшьли мәдәни-агарту, халыкның революцион аңын уяту хәрәкәтенә катнашып китә, шуның өчен бернича тапкыр төрмәгә ябыла һәм сөргенгә сөрелә. Әдәби иҗатын сүлпәнәйтмәгән хәлдә, ул тора-бара иҗтимагый көрәшкә кереп чума, Петербургта һәм Мәскәүдә газеталар чыгара, татар театрын, матбугатын, җәмәгать фикерен үстерүгә җитди өлеш кертә. Октябрьдән соң эмиграциягә китә, Төркиядә яши, шунда 1954 елда вафат була.

Укучыга тәкъдим ителә торган хикәя 1910 елның августында Финляндиядә язылып, 1912 елда «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр җыентыгында басылып чыккан. Русчага тәрҗемәсе 1914 елда А. Н. Веселовский хөрмәтенә чыгарылган «Восточный сборник» (Мәскәү, XIII чыгарылыш) дигән китапта дөнья күргән. Кардәш күршеләребез теленә тәрҗемәсенең «Башкорт телендә әдәбият хрестоматияһе» (1927) исемле китапка кертелгәнен искәртеп китү дә, шаять, артык булмас.

Хикәянең мәгънәсен һәм сәнгатьчә үзенчәлеген аңлатып маташу кирәкмәс дип беләм. Шулай да укучы әдипнең Урал табигатен, башкорт җирен, башкорт халкын үз итканенә һәм бу халыкның кешегә бәхетсезлек китерә торган кайбер гореф-гадәтләренә ачынганына игътибар итсә, зарар булмас иде.

## Гаяз Исхакый

# БАШКОРТ БӘХЕТЕ

хикәя

Инде әллә кайчан, онытылып та бетте, мин бер зур рус авылыннан Агыйделнең бормаланып киткән башындагы бер авылга барырга ат эзләргә тотындым. Кайсы авылга бару хәбәрем чыгу берлә базардагы башкортлар мине сырып алып: «Мин дә мин!» дип, гауглалаша да башладылар. Бердән минем аяк асты тазарды: элгәреге ат таба алмам, дип куркулар бетте. Мин сайланырга тотындым: кайсының атын яратмадым, кайсының арбасын. Ахырдан, бер башкорт: «Минем арбам тимерле», дигәч, юкәләр берлә бәйләгән, жепләр берлә ныгайткан башкорт арбасына утырып сәяхәт итү Урал тауларында никадәр мәшәкать буласын хисаплап, тимер арбалы башкортны ялладым.

Юлым озынга күрә, тамакны туйдырыр өчен бердәнбер мөселман хәрчәүнәсенә, дөресен әйткәндә, мөселман дворына кереп, ашарга сорадым. Ашханәнең хуҗасы, минем кеби, шул тирәдә булмый торган киемнән кергән егетне күргәч тә, әлбәттә, хәзер килеп житеп, нәрсәнең яхшылыгы хакында сөйләшә башлады:

— Ат ите дә бар, лапша да бар, өйрә дә бар, кирәк булса, пилмән дә бар — диде. Мин, Казандагы кеби, иң шәбе инде пилмән, дип, пилмән кушмакчы идем. Теге абзыйның «Ничә?» дигән сөаленә, үземнең карыным ачлыгын исәпкә алып:

— Йөз,— дидем. Абзый:

— Ничә кеше?— диде. Мин:

— Ялгыз гына,— дигәч, ул аптырабрак карарга тотынды. Мин аның күз каравында: «Кара, нинди генә булса да, йөз пилмән ашамакчы була», дип таңга калуны күреп:

— Әллә аз булырмы?— дидем. Абзый:

— Юк, булмас. Без итне кызганмыйбыз, безнең пилмәнләр һәйбәт була, Сәфәр старшина да бездә пилмән ашый. Күп булмасын дип әйтәм. Ясавын ясарбыз,— диде. Мин:

— Соң, кешеләр күпме кушалар?— дип сорагач:

— Төрлесе була: иллене дә әйтәләр, егерме бишне дә, унбишне дә,— диде. Мин пилмәннең зурлыгын кечкенәлеген белмәгәнгә:

— Алай булса син, абзый, уртача кешегә житәрлек иттереп үзен хәзерлә!— дидем. Абзый чыгып китте. Ярты сәгать үтмәде, ул мине, башын иеп кенә чакырып, ак якка алып чыкты. Мин керү берлә алдыма кызыл зур бер чүлмәк китереп куйды. Мин:

— Никадәр?— дигәч.

— Унбиш,— диде. Мин, ул унбише туйдыра торган пилмәнне күрер өчен, чүлмәккә тыгылдым. Кашыгымнан берничә мәртәбә төшеп киткәннең соңында бер пилмәнне өстерәп чыгарып тәрилкәгә куйдым. Шунда гына мин бая «йөз» дигәч абзыйның исе китүенең мәгънәсен аңладым. Пилмән Казандагы, Оренбургтагы мәгънәдә пилмән түгел иде. Ул — чынаяк асты кадәр итеп ясалган, мишәрләрнең кәкәше, яисә казаннарның кечкенә бәлеше иде. Моның йөзен түгел, унбишен генә ашап бетерергә минем шикелле дүрт-биш егет кирәк иде. Мин, тәрилкәдә жәйрәп яткан шул пилмәннең кай төшеннән башларга аптырап торганда, нинди корал берлә һөжүм кыйлырга хәйран булып торганда, теге абзый

тагы бер ашаяк[1] бәрәңге берлә бер башкорт дустагы шулпа да алып керде.

Шул ашларның күплегенә мин, шатланудан битәр, курка башладым. Уйлап-нитеп, кашыкка ярдәмгә пычак сорап алып, пилмәнне дүрт бишкә кисеп ашарга хәзерләндем. Пилмәннең эченнән ярты кадак чамасы тураган (тапамаган) иттән башка, ярты суган, ярты балкашык чамасы борыч та чыкты. Пилмәннең табактан аз гына нечкә камыр камзулын читкә этеп ашарга тотындым. Ашыйсы килгәнгә күрә, бисмилланы әйтергә онытсам да, шуның аркасында абзыйның пилмәнен үзем генә түгел, теге «Фәзаилеш-шөһүр»дәге[2] симез шайтан берлә бүлешсәм дә, өченче пилмәннән үтә алмадым.

Абзый минем аз ашауыма исе китеп, яратмадымы әллә дип, тагы әллә ниләр китермәкче булса да, мин үзем алган кечкенә карбыз берлә авызны юарга тотынгач, ул калган унике ярым пилмәнне, алты кешегә җитәрлек бәрәңгене, кечкенә генә бала коендырудан артып калырлык шулпаны алып чыгып китте.

Мин карбыз ашап бетерергә өлгерә алмадым, минем башкортым килеп җитте. Мин, үземнең барлы-юклы әйберләремне күтәреп, капка төбенә чыктым. Бер тәртәсе озын, берсе кыска иттереп, эшләясез камыт берлә җигелгән кабыксыз арба минем исемне китәрде. Мин арбаның дүрт көпчәгенең дүрт үлчәүдәлеген күреп, башкорт абзыйга карап:

— Ник алдадың, арбаң бик начар ич? Моннан төшеп калмас өчен җәпле кеше кирәк, тимерле дигән буласың! (Әлбәттә мин тимерле арба дигәч, үземнең якның бай мужикларының таза арбалары дип белгән идем). Карт ук кешесең, алдыйсың!— дидем. Башкорт абзый суык кан берлә генә:

— Алдамыйм! Тимерле шул, күрмисеңмени?— дип, элгәре вакытта кабык кадалып куйган, хәзер кеше киемен ерту хезмәтен үти торган кечкенә генә кабык кадагына төртеп күрсәтте. Мин ачуланасын да, көләсен дә белми арбага менеп утырдым.

Юлга чыккач, аты да шул арбасы кеби булды. Тигез юлда начар бара, тау менгәндә туктый-туктый эштән чыгара, тау төшкәндә бөтен әйберләрне коеп бетереп дулый торган булып чыкты. Шуның өчен теге зур пилмәнләр бик тиз селкенеп бетте. Ләкин озын сахраларда лертлерт сыер адымы берлә бару, борылып-борылып төшә торган тауларда тәгәрәп, мәтәкләнеп китүләр бик тиз мине туйдырды. Мин ни эшләргә аптырап килгәндә арттан бик яхшы атка утырган, таза арба җиккән бер башкорт егете килеп җитте. Ул минем башкорт берлә сөйләшергә тотынды. Бик тиз сүз миңа күчте. Минем кая баруым соралды. Минем теге башкорттан унике чакрымлы гына авылга баруым беленгәч, тимер арбалы башкортымның авылы мин бара торган авылдан җитмеш чакрым читтәлеге беленгәч, башкортлар арасында мине сату-алу хакында базар китте. Минем башкорт йөз утыз чакрымга бер сум егерме тиенгә килешкән булганга, шуны бүлү хакында байтак тавыш купты. Ахырдан, болар егерме тиендә килешә алмаганны күреп, мин үземнән егерме тиенне кушарга булып, яшь башкортка сатылдым.

Аның аты яхшы, арбасы нык, үзе ачык булганга, юл җиңел булыр кеби күренде. Дөресе дә шулай чыкты. Утырып китү берлә без сөйләшергә тотындык. Мин иң әүвәл теге тимер арбалы башкортның бер сум егерме тиенгә йөз утыз чакрымга баруының, аннан үз авылына тагы җитмеш чакрым борылып кайтырга разый булуының сәбәбен сорадым. Яшь башкорт:

— Кунак булырмын дигәндер. Әле эш өлгермәгән — печән җитмәгән,— диде. Мин шул бер чәй, бер аш ашар өчен җитмеш чакрым юлга чыккан башкортка, әлбәттә, исем китми калмады.

---

[1] Ашаяк — аш савыты, табак.
[2] «Фәзаилеш-шөһүр»— чәчмә белән язылган дини-әхлакый әсәр.

Сүз берлә юл тиз үтте. Без Урал тауының төбенә барып җиткәндә кояш батарга якынлашты. Таудан агып килә торган су янында без кунарга туктадык. Шарлап ага торган чишмәдән салкын суны алып, минем юл чәйнегемә салып, ут ягып чәй кайнаттык. Башкорт берлә, бер стаканнан гына булса да, бик кәефләнеп, чәйгә утырдык. Урал тауының өскә аварга теләп, һаваланып торуы, шарлап суларның агуы, Урал буйларының зур наратлар берлә бизәкләнеп, хуш исләр таратуы, әлбәттә, безнең чәйне тагы тәмләтте. Чәй бетү берлә кояш та баеды. Шуны гына көтеп торган кеби, түм-түгәрәк ай, көмеш такта кеби ялтырап, Уралның теге башыннан күтәрелә башлады. Ай үзе берлә яктылык кына түгел, тынычлык та тараткан кеби, бөтен Уралны тындырды.

Башкорт атын рәтләгәндә мин баш астыма бишмәтемне салып, шул ай яктысында Урал тауын, бабайлар, бабайларның бабайларының үз тауын карарга тотындым. Ай яктысында аның буе тагы озын кеби тоелды. Аның бормаланып, борылып киткән тармакларының очы ерактагы караңгылык берлә берләшеп китеп, тагы мәһабәтләнде, тагы зурайды. Аның өстендәге агачлар, нечкә генә бер кат караңгылык киеме киеп, тагы юанайды. Аларның яфраклары ай яктысында тагы яшел, тагы матур күренде.

Шылтырап ага торган сулар акты да акты. Аларның шул тавышларын матур итеп җибәрү өчен кеби, әллә кая тартар кычкырырга тотынды. Аңар каршы әллә нинди бик зур тавыш берлә:

— Һөп, һөп!— дип, күрше күлдә су үгезе кычкырып куйды. (Бу кычкыручы су үгезе булмаенча, кечкенә генә бер корт[1] булса да, тавышы зурга, безнең халык су үгезе дип сөйли).

Әллә кайда сыер мөңрәде. Безнең ат айгырланып, кешнәп җибәрде. Аңар каршы Урал кешнәп җавап биргәч, ул тагы гайрәтләнеп китте.

Башкорт та минем яныма килеп, аркасына ятып, күкне, шул матур Уралны карарга тотынды. Аңар да шул матур күк, мәһабәт тау, кызлар кеби пөхтә урман, шул суларның шылтыраулары, нечкә исләренең борынны кытыклаулары, ахрысы, тәэсирсез калмады. Ул озын гына иттереп сузып:

— Уф-ф-ф!— дип куйды. Мин аның шул «уф»ының мәгънәсе бардыр дип уйлап:

— Әйдә җырлап җибәр! Җырлый беләмсең?— дидем. Ул:

— Син җырла, синдә Казан көйләре күптер,— диде.

Сандугачлар минем асыл тавышымны ишетеп, тәменнән йөрәкләре ярылып үләрләр, дип куркып, Уралны сандугачсыз, шул матур Урал буен музыкасыз калдырмас өчен, әлбәттә, җырларга разый булмадым. Башкорт та җырламады.

Без акыртын гына сөйләшергә керештек. Мин тегеннән:

— Син өйләнгәнме? Сездә туй ничек була?— дип сорадым. Шул сөаль аның авырта торган җиренә барып бәрелгән кеби булды. Ул тагы бик зур сулап:

— Өйләнгән...— диде. Мин:

— Я әле, сөйлә әле! Сездә туй ничек була?— дип, бик сорашкач, ул сөйләргә хәзерләнде. Ул:

— Мин солдаттан кайттым...— дип хикәясен башлады. Аның хикәясе гыйбрәтсез булмаганга, мин хәзер дөньяның икенче кырыенда торганда, шуны хәтергә төшереп, язарга булдым.

— Әтием бай булганга, мин солдаттан кайтыр алдыннан яңа итек алдым, яңа шинель, яңа куртка тектердем. Туры аткан өчен алган знакны бик матурлап күкрәккә кададым. Юл буе бөтен халык миңа гына карап килде. Станцияләреннән үткәндә, сөт сатучы марҗалар миңа көлеп калдылар. Үземнең башкорт авыллары янындагы станцияләргә

[1] Корт сүзе монда «кош» мәгънәсендә кулланылган (Кош-корт!)

житкәч тә, мин бүрекне кыңгыр киеп, чыгып йөрдем. Башкортлар мине күргәч тә:

— Бу нинди түрә икән?! — дип әйтеп калдылар. Мин белмәгәнгә салынып, мыекны борып, һаман йөрдем.

Менә Оренбургка килеп життем. Аннан пар ат яллап, кыңгырау так-тырып, тарантасның артына гына баяр төсле ятып, кайтып киттем. Юл буйларындагы башкорт авылларында:

— Бу нинди түрә икән?! — дип карап калдылар.

Менә мин авылга кайтып кердем. Бөтен авыл мине күрергә килде. Һәммәсе минем шинельнең һәйбәтлегенә, знакның ялтырап торуына, төймәләрнең түрәләрнеке кеби кояшка каршы ялт-йолт итүенә исләре китте.

Әти мин юкта үлгән икән. Әни сыер суеп мине кунак итте. Бөтен ил-су минем хөрмәтемә бәйрәм ясады. Без өйдән өйгә кымыз эчеп, сарык ите ашап йөрдек. Аннан соң мин күрше авылларга да барып, кунак булып килдем. Анда да үземнең киемнең шәплеге берлә исләрен китәрдем.

Менә атна үтте, ике атна үтте, мин йорт эшләрен караштыргалый башладым. Әти үләнчүк абый аерылып чыккан булганга, әнием баш булганга, эшне бик чуалчык таптым. Әнинең печәннәре рәтләп өелмә-гән, ашлыклары рәтләп урылмаган, сугылмаган булган. Мин акрын гына эшкә кереп киттем. Эшкә барганда шул шинельләр, курткалар берлә ба-рырга оят булганга, мин берәм-берәм ул киемнәрне ташладым. Эл-гәре аларны ташлап иске башкорт киеме кию оят кеби тоелса да, бара-тора бөтенләй гадәтләндем. Ул гына да булмады, үземнең шул шинель-ләремне күргән саен, шуларны киюдә үземнең рәхәт табуыма исем ки-тә башлады.

Әнием карт булганга, шул зур йортны күзләп килергә кеше кирәк булганга, мине өйләндерергә уйладылар. Мин үзем дә чит күрмәдем. Элгәре күрше авылдан, мишәрдән алырга теләдем. Мишәрләрнең кызлары зур, тулы, матур була. Ләкин әниләр, карендәш-кабилә:

— Сасы мишәрдән алырга ярыймы соң! — дип, бик каршы килгәч, алар юлына төштем. Үзебездән сигез чакрымлы бер бай гына башкорт-ның кызын килештек. Туй булды.

Безнең башкорт гадәте буенча, кызның атасы-анасы берлә күре-шүдән элек кыз берлә күрешергә ярамый. Ата-ана берлә күрешер өчен кызның анасына төлке эчле камзул, атасына постау җилән бирергә кирәк, һәм дә кызның калымын тутырырга кирәк. Шуның өчен егет бер-лә кыз арасында аталарыннан яшереп күрешү китә. Шул эшләрдә җиң-гиләрнең ярдәменнән башка булмаганга, җиңгиләргә дә әллә ни кадәр бүләк бирелә.

Менә минем дә туй үтте. Мин, кызны күрергә дип, атка атланып киттем. Җиңгине күреп, аңар зур йон яулык бирдем.

Кояш батыр алдыннан, башкорт гадәте буенча, авылның бөтен кызлары берлә минем бикәчем дә урманга китте. Мин шул ун-унбиш кыз арасыннан үземнең бикәчемне танып алырга тиеш. Әгәр үз бикәчең дип башканы тотсаң бик зур оят була; егетнең булдыксызлыгы беленә. Кай вакытта камчы берлә сабак та укытыла.

Күрмәгән, белмәгән кызлар арасыннан ничек танып алырга кирәк? Монда да, әлбәттә, җиңгиләр ярдәменнән башка булмый.

Кулдагы кәнфит, прәннекне күтәреп, бикәчемнең башына ябар-га дигән куендагы ефәк яулыкны саклап, мин кызлар артыннан киттем. Җиңги биш-алты тишекле тәңкә бәһасенә минем бикәчемнең күлмәге сары икәнен әйтте. Кызлар бөтен тарафыннан вак кына нарат урманы берлә чорналган бер аланның читенә туктадылар. Мине күргәч, барысы да яулыкларын каплаштылар. Үзләре «кых-кых» көлешә башладылар. Мин шул кызларның иң артында утырган сары күлмәкле кызга ефәк шәлне яптым. Кулым берлә аны тотыйм дип сузылырга өлгермәдем,

ул торып чабарга тотынды. Мин аның артыннан киттем. Ул озак чаба алмады, мин аны куып җитеп, камчы берлә суктым. Бикәчем туктады. Ул куллары берлә күзен, йөзен томалады. Мин аның кулларын йөзеннән аерып алып, үптем. Шуннан, кочаклап алып барып, аны бер нарат төбенә утырттым.

Баеп килә торган кояшның моң гына яктысында мин бикәчемне карарга тотындым. Аның кара сачлары, кара күзләре, түгәрәк йөзләре миңа матур да күренде, ләкин аның йөзендәге, күзендәге балалыгы минем исемне китәрде. Аның ун-унөч яшендәлеген белгән булсам да, мин аны һәр вакыт зур, җитеп беткән кыз дип уйларга өйрәнгән идем. Аның йөзе генә түгел, бөтен әгъзаларыннан да балалыктан башка нәрсә тапмадым. Күкрәк дигән нәрсә үсә дә башламаган иде; кул, аяк тулырга да тотынмаган иде. Мин әллә кайчаннан бирле уйлап йөргән шул көнгә ирешкәч, аны кочарга, сөяргә, үбәргә тотындым. Ләкин ул шуларның берсенә каршы да миңа җавап бирмәде. Алай гына да түгел, ул һаман миннән йөзен яшерүен бетермәде. Мин үземнең иптәш егетләремнән әүвәлге күрешүнең ничек булганын ишеткәләгәнгә, бик күбесе үзләренең бикәченең карангы төшеп, төн булып җиткәч аерыласы килмәенчә еглаганын да белгәнгә, минем бикәчемнең шулай суык кылануына азрак гаҗәпкә калдым. Ләкин аннан әллә нинди мәгънәләр чыгарып торырга өлгерә алмадым, безгә аерылырга вакыт җитте. Мин тагы кысып кочаклап үптем. Ул бу юлы да миңа каршы җавап бирмәде. Мин айгырыма атланып, камчы берлә сугып, күз ачып йомганчы өйгә кайтып җиттем.

Иртәгесен тагы вакыт җитү берлә киттем. Бу юлы аның берлә сөйләшергә, серләшергә булып киттем. Җиңги мине каршы алып, бикәчемнең яткан келәтенә кертте. Ул тагы минем сөюләремә каршы бер төрле дә җавап бирми башлады. Мин бераз шөбһәләндем. Мин аның берлә сөйләшергә тотындым. Сүзеннән дә бер дә артык мәгънә таба алмадым. Ул бөтен куллары, аяклары берлә бөгәрләнеп ятканга, миңа иркенләп кочарга, үбәргә дә ирек булмады. Мин шуңар бераз ачуланып:

— Син ник болай кыланасың?!— дидем. Ул миңа карамаенча:

— Син марҗалар берлә әллә нинди оят эшләргә салдаттан өйрәнеп кайткан!— диде дә тагы бер сүз дәшмәде. Минем күңелем шөбһәләнеп китте. Шулай итеп, берәр атна мәгънәсез вакыт үтте. Мин аннан бер көләч йөз, сөю әсәре күрмәдем.

Бер иптәшемә серне сөйләдем. Ул миңа:

— Аның типерченүенә, тырмашуына карамаенча, аңы үз хатының яса!— дип киңәш бирде. Шул киңәш буенча мөгамәлә кылсам да, минем бикәч элгәрегедән бозылмады. Ул элгәре бер дә минем берлә сөйләшмәде. Ахырдан, мин алган юлымдан барасымны күргәч кенә, ул:

— Зинһар, шул салдаттан өйрәнеп кайткан оят эшеңне кылма!— дип, ялынырга, ялварырга, егларга тотынды.

Бикәчле кияү булуның бөтен кәефе китте. Мин рәхәтләнеп бер төн уздыра алмадым. Кай вакыт ачуым килеп, аның еглавына-фәләненә карамасам да, аның күз яше минем шул матур көннәремне зәһәрләде. Мин бик өметсезләнеп әнигә дә сөйләдем. Ул әллә кемнәрдән өшкертеп китертсә дә, файда чыкмады.

Көн үтте, атна үтте, ай үтте, мин һәр көнне кич булу берлә айгырыма атланып китеп, барып куныл, таң ату берлә кайтып китеп йөрсәм дә, күңелем канәгатьләнмәде. Мин яңадан өйләнергә-фәләнгә, моны аерырга дип уйлый башладым. Әни: «Сабыр ит, сабыр ит!»— дисә дә, күңелемнән өйләнергә карар бирдем.

Бер төнне бикәчем бик ачуны китергәч:

— Син ни эшлисең? Шулай ярыймыни? Мин хатын кирәккә өйләнгән!— дип, тегеннән үземнең разый түгеллегемне белдердем. Шуңар гына аның исе китмәгәнне белгәч:

— Алай булса, мин икенчегә өйләнәм!— дидем.

Шул сүз аны бөтенләй үзгәртте. Ул егларга, еглап-еглап ялынырга

тотынды. Аның берлә генә дә калмады, мине үбәргә, кочарга тотынды. Мин аптырап калдым. Аның теле ачылып:

— Мин сине бик сөям! Шул салдаттан өйрәнеп кайткан эшең булмаса иде, тагы сөяр идем!— диде. Мин, кызгануданмы, тагы яңадан өйләнү уен куйдым. Ирле-хатынлы булып рәхәтләнеп тора алмасам да, бара-тора әллә рәтләнер дип, калымны да түтырдым, атасы-анасы берлә дә күрештем. Ләкин бикәчем һаман үзгәрмәде. Мин аны өйгә төшердем. Эни үзен яратты. Сыер, бияне саварга әллә кайчан өйрәнгән, кымызны да ясарга өйрәнгән; аш, икмәк пешерә дә белә, ләкин шул үзе һаман балалыгыннан чыкмый!

Мин бөтен яшьлегемне харап итмим дип, Бөрҗән хәзрәткә өшкертергә алып бардым. Бик һәйбәт бер ат бирдем. Ләкин бикәчем үзгәрмәде. Шуннан соң, салдат вакытында бергә хезмәт иткән бер фельдшер — таныш урысым бар иде, Троицкиның теге ягында тора. Ат җигеп шунда барып, дүрт йөз чакрымнан аны эзләп табып, серне сөйләдем. Ул аптиктан алырга әллә нәрсә язып бирде. Өч йөз чакрым булса да, Оренбурга барып, шул даруны алып кайттым. Аннан да файда булмады.

Менә хәзер инде өйләнгәнемә дүрт ел булды, бикәчем һаман шул минем ирлегемне салдаттан өйрәнеп кайткан, кирәкмәгән бер эш дип ышанудан күчә алмады. Инде ни эшләргә белмәенчә торам: өйләнсәм аны кызганам, өйләнмәсәм тагы вай!— диде дә туктады. Үзе тагы озын гына итеп сулап куйды.

Түгәрәк ай болыт астына кереп китте. Сөйләүченең йөзе кеби, күк йөзе дә караңгыланды. Тау тагы зуррак кеби күренде, агачлар тагы юанрак кеби сизелде. Караңгылык, йомшак куллары берлә, бөтен Урал буен каплап алды. Башкортның авыр сулавы берлә тартар тавышыннан башка бер нәрсә дә шул моңлы тынычлыкны бозмады.

Менә тагы башкорт әйләнеп ятып, авыр суларга тотынды. Ат та, иптәшенең кайгысын сизгән кеби, моң иттереп кешнәп куйды; урман аннан да моң иттереп җавап бирде. Ай болыт астыннан чыгып, бөтен тауларны, агачларны, сузылып яткан иптәш башкортымны ап-ак нуры берлә коендырды. Безнең күзләр берләште. Ул миннән киңәш көткән, мәслихәт көткән кеби, күзен тутырып карады. Мин, ни әйтергә белми аптырап калып, борылып яттым.

Иртәгесен без башкортның өенә барып җиттек. Башкорт мине бик сыйлады. Мин кымыз, ит ашауны онытмасам да, теге хикәянең каһарманы — киленне дә күземнән качырмадым. Кечкенә генә, 14—15 яшьләр чамасында, кара чәчле, кара күзле, зур калош кигән бер бала самавыр керткәч тә, мин «шулмы?» дигән кеби иттереп, сөальле күзем берлә башкортка карадым. Башкорт мине аңлады. Ул, башын чайкап:

— Ийе!— дип җавап бирде.

Шул баланың нечкә кулларын, җитлекмәгән тәннәрен, әллә нинди карт бала төсе чыккан йөзен күргәч тә, шул тормышның трагедиясенең сәбәпләрен тәмам аңладым.

Мин киттем, башкорт һаман әле шул бала хатын берлә калды. Шул бала аның солдаттан өйрәнеп кайткан гөнаһларын аңлый башладымы, юкмы? Әллә үзе шул баланы хатын дип тотудан туеп бетеп, үзе кеби таза, нык хатын алдымы? Белмим.

Кереш сүз авторы һәм текстны әзерләүче
профессор **Ибраһим НУРУЛЛИН**

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ИСЕМЛЕГЕ

Соңгы вакытта әдәби җәмәгатьчелек аның турында кызу бәхәсләр алып барган шәхес — революциягә кадәр күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган Гаяз Исхакый. Республика рухи мирас комиссиясе генә дә бу мәсьәләгә үзенең өч-дүрт утырышын багышлады. Бөек Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты һәм театр сәнгате, вакытлы матбугаты һәм самодержавиегә каршы көрәш сәхифәләре бу исемнән, аның әдәби һәм иҗтимагый мирасыннан башка тулы була алмый, дигән беренче карашка ук бик гади фикернең әле һаман да үз урынына утырып җиткәне юк. Чыннан да, гади бит инде, бик ачык. Кеше өч дистә югары художестволы зур күләмле әсәрләр язган, патша хөкүмәтенә каршы тиңдәшсез көрәш алып барган, моның өчен төрмәләрдә утырган, газеталар чыгарган h. б., ягъни татар халкының иҗтимагый-политик көрәшенә дә, художестволы фикер үсешенә дә тиешле өлеш керткән, милли әдәбиятның һәм сәхнә сәнгатенең уңышларында аның шиксез катнашы бар — димәк, ул өйрәнелергә һәм тиешенчә бәяләнергә тиеш. Әлбәттә, боларны тану Г. Исхакыйның гаять катлаулы шәхес булуын оныту исәбенә эшләнмәячәк. Аның иҗаты һәм көрәше Бөек Октябрьгә кадәр дә туры сызык буенча, шома гына бармаган һәм үсмәгән — моны истә нык тотабыз. Шуны ук замандашлары да күргәннәр һәм искәрткәннәр. Мәсәлән, бу яктан Г. Ибраһимовның 1915 елгы 26 февраль санында «Тормыш» газетасында басылган «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе характерлы. Мәкалә авторы конкрет бер әсәр турында гына сүз алып бармый, ә Г. Исхакыйның иҗатына анализ ясап, аның мәсләге анык булмавын әйтә, әсәрләрендәге идея буталчыкларының аерым чыганакларын шунда күрә. Г. Исхакый иҗаты мондый карашларны да истә тотып өйрәнелергә тиеш. Ә инде әдипнең Октябрь революциясе көннәрендәге эш-гамәле, аннан соңгы тормышы, эмиграциядәге иҗаты тагын да катлаулырак. Шул ук шәхес бит инде Бөек Октябрь сынавын уңышлы уза алмаган, баррикаданың теге ягына чыгып, калган гомерен Совет строена каршы көрәшеп уздырган. Фаҗигале язмыш! Татар милләтен азат итеп, бөек итеп күрергә теләгән, үзенчә бу идеалына гомере буе тугры калган кеше язмышы. Шул идеалы намына Бөек Октябрьдән соңгы елларын чит-ят җирләрдә уздырган, үзенчә көрәшкән, Советка каршы көрәшәм дип еш кына үз халкына каршы позициядә торып хәрәкәт иткән, үзенчә көчле шәхес. Кайбер мәгълүматларга караганда, ниндидер контрреволюцион оешмалар оештырырга тырышып, чит илләр разведкалары белән бәйләнештә торган перспективасыз көрәшче.

Кыскасы, Гаяз Исхакыйның катлаулы тормыш юлын һәм иҗатын безгә ныклап өйрәнергә, тикшерергә кирәк. Хәзер инде бер нәрсә ачык: моңарчы без татар әдәбияты тарихын бу иҗаттан башка күзалларга тырышып күп нәрсә югалтканбыз. Татар театры тарихында да, журналистика тарихында да, иҗтимагый хәрәкәт процессы тарихында да... күп оттырганбыз. Аерым күренешләрне аңлатуда бозуларга барганбыз, алданганбыз һәм алдаганбыз. Мәсәлән, бер генә мисал. Татар театрының беренче пәрдәсе ачылган пьеса итеп тәрҗемә әсәр — «Кызганыч бала» күрсәтелә иде. Ә бит ул Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» пьесасын сәхнәләштерү белән ачылган.

Революциядән соң Советларга каршы көрәшкән кеше — безнең идеологик дошманыбыз, шуңа күрә аңа безнең гражданлык тарихында да, әдәбият-сәнгать тарихында да урын булмаска тиеш, дигән авазлар һәм раслаулар әле дә яңгыравын дәвам итә. Мондыйларга мин түбәндәгечә җавап бирәм.

Андый талант иияләре бер Г. Исхакый гына түгел. Аларга мөнәсәбәттә без В. И. Ленин үрнәгенә мөрәҗәгать итәргә, аның өйрәтүләрен методологик нигез итеп алырга тиешбез. Мәгълүм факт: 1921 елда Парижда акгвардияче язучы Аркадий Аверченконың Россиядәге социалистик революциягә чиксез дошманлык рухы белән сугарылган «Революция аркасына унике пычак» («Дюжина ножей в спину революции») исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. В. И. Ленин бу китапка рецензия язып, аны «Правда» газетасында (1921 ел, 22 ноябрь) бастыра. «Автор үзенең хикәяләрен үзе белмәгән темага багышлаганда, сәнгатьчә килеп чыкмый»,— ди Владимир Ильич һәм мисал итеп үзенең, Троцкийның шәхси тормышлары турындагы хикәяләрне китерә. Рецензентны болары кызыксындырмый, аларны ул игътибарга да алмау ягында. «Аркадий Аверченко үзе яхшы белгән, үз башыннан кичергән, кат-кат уйлаган, хис иткән» темаларны сурәтләгәндә исә, дип дәвам итә В. И. Ленин, тормыш, аерым алганда «байлар Россиясе вәкиленең тәэсирләре һәм настроениеләре искиткеч талант белән сурәтләнгән», мондый әсәрләрдә «ул белә... башыннан һәм хисеннән кичергән, ...монда ул ялгышачак түгел». «Талантны дәртләндерергә кирәк»,— дип нә-

тиҗә ясый ул һәм революция дошманының капиталистик катлауның паразитлык тормышын чагылдырган хикәяләрен яңадан бастырып чыгарырга тәкъдим итә (К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Казан, 1976, 87-88 бб.).

Менә бу — мәсьәләгә даһиларча караш, кабатлап әйтәм, бу — безнең өчен бүген дә кулланма булырлык методологик күрсәтмә. Г. Исхакый иҗатына да без бөек юлбашчы үрнәгендә якын килергә бурычлыбыз. Язучының Бөек Октябрьгә кадәрге әдәби мирасын кичекмәстән укучыга кайтару белән бергә, без аның эмиграциядә язганнары арасыннан да безнең өчен файдалы булганнарын, революциягә кадәрге халык тормышын дөрес чагылдырганнарын сайлап ала һәм укучыга бирә белергә тиешбез.

Г. Исхакыйның революциягә кадәрге иҗатын өйрәнү эше акрын-акрын башланды. Ләкин язучының әсәрләре аз сакланып калган булуы, ә эмиграциядә вакытта нилә язганлыгы бөтенләй дә билгесез иканлеге эштә нык комачаулый.

Минем кулымда Төркиядә, Истанбулда басылып чыккан бер брошюра бар. Ул «Милли көрәшче һәм милли әдип Гаяз Исхакый» дип атала, 1955 елда, язучы үлгәннең икенче елында, аның истәлегенә багышлап чыгарылган. Кырык җиде битлек брошюра язучының төрле елларда төшкән фоторәсемнәре белән бизәлгән. «Әүвәлге тәэсир», «Бер көрәшченең тормышы», «Гаяз Исхакый Иделле — газетачы» дигән һ. б. бүлекләрдән, аерым истәлекләрдән тора. Безнең өчен аерата кыйммәтлесе — монда Г. Исхакый әсәрләренең исемлеге бирелгән. Дөрес, без аны язучы иҗатының барлык якларын да иңләп алган һәм тулы чагылдыра дип раслый алмыйбыз. Мәсәлән, Г. Исхакыйның бай публицистикасы, әдәбиятка һәм сәнгатькә караган мәкаләләре, рецензияләре бөтенләй дә китерелмәгән. Монда һәр әсәргә бирелгән аннотацияне дә объектив дип кабул итмибез. Аларда тенденциозлык, рус дәүләтенә, революциягә каршы булу «кычкырып» тора. Ләкин әдипнең прозасы һәм драматургиягә кергән әсәрләре, зур күләмле гыйльми хезмәтләре һәм истәлекләре бирелгән булу, аларның язылу һәм басылу (яки сәхнәгә куелу) даталары күрсәтелгән булу бу исемлекне әдәбият галимнәре өчен кызыклы һәм кирәкле итә. Шуларны истә тотып, аны төрекчәдән тулы хәлендә тәрҗемәләп укучыларга тәкъдим итәбез.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы,
профессор.

• • •

«Түбәндә Гаяз Исхакыйның кайбер әсәрләренең кыскача эчтәлеген бирәбез:

1. **«Тәгаллемдә сәгадәт»** *(укуда бәхет — А. Ә.).* 1896-1898. Мәдрәсәләрнең тынчу һавасы урынын мәдәният яктысы алуы, ялкаулык һәм буйсынганлык урынына җанлылык, иман һәм өмет барлыкка килү турында куанычлы хәбәр...

2. **«Кәләпүшче кыз».** 1898-1900. Бу әсәрендә ислам диненең кайбер куе фанатизм элементларының хатын-кызларда хөрмәт, намус, горурлык хисләрен өзгәләгәнен һәм соңгы елларда моңа кушылган урам куркынычының кызларның әхлакый хәлен тагын да ныграк какшатуын; бу бәлаләрдән «бары тик югары милли тойгылар барлыкка килеп кенә котылып булыр!» дигән фикерне яклап әйтә.

3. **«Бай улы»** — роман. 1899-1903. Бу әсәре белән Гаяз бәк *(Гаяз Исхакый — А. Ә.)* «залим гаиләгә хөрмәт һәм мәхәббәт җирлегенә таянган гаилә тормышын каршы куеп, берсендә кайгы-хәсрәт, икенчесендә исә шатлык хакимлек итә!» дигән фикерне бирә.

4. **«Өч хатын белән тормыш».** Драма. 1901-1902. Өч хатынга өйләнгән бер җаһилнең *(надан, томана — А. Ә.)* җәһәннәмдәй тормышыннан ачы һәм көлкеле күренешләр.

5. **«Ике гашыйк».** Комедия. 1901-1903. Артык көчәнүдән бозылуның җәзасы.

6. **«Теләнче кыз».** Роман. 1902-1903. Әйе: 400 еллык тиранлык астында изелүгә хөкем ителгән бер милләтнең кызы теләнчелектән тормышның иң югары баскычына күтәрелә һәм, Гаяз бәкнең ышануынча, моның юлы да — «намус һәм милли тойгыдыр!»...

7. **«Очрашу».** 1902-1903. Милләтчелек ноктасыннан торып гади бер кеше тормышының нечкәлекләре белән һәм җитди итеп тасвир ителүе.

8. **«Ике йөз елдан соң инкыйразмы?»..** *(инкыйраз — һәлакәт — А. Ә.)* «Кайсы гына милләт тә милли әсирлекнең даими изелүе астында яшәтелгәндә инсан рухында барлыкка килгән хәрабәләр Казан төрекләренә *(Казан татарлары — А. Ә.)* шулай ук янаган куркынычны чагылдыра!» дип, автор укучыларын кат-кат аңларга чакыра (язылуы — 1902, нәшир ителүе — 1904).

9. **«Хикәяләр».** 1905-1907. Бәхетсез бер милләтнең хәятындагы хәлләр сурәтләүчесен көтә иде. Менә Гаяз Исхакыйныкы булдылар!

10. **«Мөгаллим».** Драма. 1906-1907. Шулай итеп, ышаныч, рухи вөҗданлылык... Беркатлы ышаныч исә кешене һәлакәткә сөйрәр!

11. **«Зиндан»**. Хикәя. 1906-1908. Рус зинданнарындагы бик күп томкыннар җәмгыять ноктасыннан зарарлы кешеләр түгелләр. Чөнки милли тоткынлыкта ыңгырашканнар гүзәл максат итеп көрәшне сайлаганнар һәм бу максат урынына зинданда черүләре мөмкин...
12. **«Алдым-бирдем!..»** Драма. 1907-1908. Комсыз, намуссыз, хатынын кол итү белән мәшгуль бер җаһилнең тормышы.
13. **«Тартышу»**. Драма. 1908-1914. Милли яшәеш хәзинәсе булган яшьлекне фидакарьлекләр белән туендырган тормыш.
14. **«Кыйсмәт»** *(«бәхет» — А. Ә.)*. Комедия. 1909-1910. Явызларның кыланышлары.
15. **«Җәмгыять»**. Комедия. 1909-1910. Рус режимының мускулы белән мәйданга кителгән тормыш шартлары көчләүләренә каршылык күрсәтү максаты белән төзелгән «Җәмгыяте хәйрияләр» һәм алар тирәсендәге көрәш.
16. **«Тормышмы бу?»** Хикәя. 1909-1910. Тормышның вак-төяк бәргәләүләре аркасында тынычлыгын җуйган кешеләрнең һәр төрле авырлыкларны горур каршылавы.
17. **«Мулла бабай»**. Роман. 1910-1912. Гасырларча рус деспотизмы астында яшәгән Казан төрекләренең дини һәм милли яшәешләрен югалтмау өчен, рус режимының интригаларына эләккән дин һәм дини әһелләр белән шаяруларга каршы көрәшкән авыл муллаларының хәяты.
18. **«Гаилә бәхете»**. Хикәя. 1910-1912. Уңышсызлыкка очраган дүрт гаиләнең бәхетләрен сабырлыктан эзләүләре.
19. **«Сәнгатьче бабай»**. Хикәя. 1911-1913. Инде менә атадан балага күчә килгән бер профессия иясе сәнгатьче тибының рухи кыйммәтләкләренең тасвиры; андыйларның милли чыдамлык мәйданында фидакарьлекләре.
20. **«Шәкерт абзый»**. Хикәя. 1911-1913. Шәкертлек пәрдәсе артында яшеренгән кайбер начар гадәтләр.
21. **«Зөләйха»**. Трагедия. 1911-1917. Хөкүмәт түрәлегеннән коры калган рус руханиларының Казан төрекләренә каршы кулланган мәрхәмәтсез һәм коточкыч дини изүләренең корбаннары.
22. **«Бер тоткынның саташуы»**. Роман. 1912-1914. Мин-минлек тойгыларын җиңгән, идеаллар хөрмәтенә җаннарын фида кылган адәмнәр.
23. **«Солдат»**. Хикәя. 1908-1917. Милләтен коллыкта җәфалаган бер чит халыктан алган алтын медаль бәрабәренә кардәшләренә хыянәт иткән җаһилнең хикәясе.
24. **«Кияү»**. 1912-1913. Бәхетсез халыкның иҗтимагый кыйпылчыклары.
25. **«Мөгаллимә»**. Драма. 1913-1915. Һичбер киртәне танымаган, милләтен һәр тарафтан югары күтәрергә тырышкан идеалист бер укытучының маҗарасы.
26. **«Остабикә»**. Хикәя. 1914-1915. Милли изелүгә карамастан, һичбер газапка бирешмәгән, кирәк булганда ир-ат кардәшләре белән дошманына каршы иңгә-иң торып сугышырга әзер торган намус иясе бер хатынның маҗаралары.
27. **«Ул әле өйләнмәгән иде!»** Хикәя. 1915-1916. Рус мәктәпләрендә укыганга һәм рус әдәбияты чаралары белән тәрбияләнгәнгә үз милләтенә булган мыскыллы мөнәсәбәтләр.
28. **«Ул әле икеләнә иде!»** 1915-1916. Рус әдәбиятының тәэсире астында калып, үз милләте кызларына хурлап караган бер җаһилнең хәяты.
29. **«Юлсызлар»**. Драма. 1917. Милли ихтыяр көчләресез һәм мәгънәви кыйммәтләрсез яшәгәндә янаган хәвеф-хәтәрләр.
30. **«Дулкын эчендә»**. Драма. 1920-1937. Рус империясе егылуы һәм Төньяк төрекләренең милли-азатлык сугышы тарихыннан кайбер күренешләр.
31. **«Ике ут арасында»**. Драма. 1921-1937. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Төньяк төрекләре арасында булган хәлләрнең чагылышлары.
32. **«Өйгә таба»**. Роман. 1920-1937. Рус гаскәрләрендә хезмәт иткән Идел-Урал офицеры һәм солдатының рухи халәте һәм милли хисләренең ярсуы.
33. **«Көз»**. Хикәя. 1923-1938. Идел-Урал төрекләре арасындагы рус пропагандасы тәэсире белән мәйданга килгән кайбер иҗтимагый һәм әхлакый гариплекләр.
34. **«Локман Хәким»**. Хикәя. 1923-1938. Кызыл агуның Идел-Уралдагы тәэсирләре.
35. **«Олы бәйрәм»**. Хикәя. 1923-1938. Тырышкан шәхесләрнең уңышы — бәйрәм бәхетедер; милли уңышның нигезе — шәхесләр бәхетедер.
36. **«Җанбаевич»** (руслашкан бер наданның фамилиясе). Комедия. 1923-1938. Бер түрәнең тормышыннан көлке күренешләр.
37. **«Утыз еллыгым»**. Хатирәләр. 1927. Гаяз Исхакый, тыйнаклык белән, тормышыннан кайбер вакыйгаларны аңлата.
38. **«Идел-Урал»**. Тарихи мәгълүматлар. 1927. Французча, рус, фин һәм япончa чыкты.
39. **«Олуг Мөхәммәт»**. Тарихи роман. 1947. Халкы 1 миллион булган Казан ханлыгының 10 миллион халыклы рус империясе белән җаннарын аямыйча сугышы.
40. **«Хатирә дәфтәрләре»**. Әлегә нәшир ителмәгән.

налары төзи торган завод-гигант салынуын хәбәр иткән истәлекле таш куелган иде?!

Хәбәрләр үзенекен итте, күңелем тәмам урынныннан купты, әлеге төзелеш турында китап язу теләге белән яна башладым. Иҗатым белән даими кызыксынган Габдрахман ага Әпсәләмов: Мәхмүт, производство командирлары — инженер-техниклар турында берәр әсәр яз әле, син булдыра алырсың төсле, югыйсә, ул тема безнең әдәбиятыбыз өчен һаман да «күтәрелмәгән чирәм» булып кала бирә, дигән иде. Автогигант төзеләчәк урын да — халкыбыз тарихының чишмә башы, борынгы Болгар, чал Чулман буенда. Мәсьәләнең ул ягы да булачак әсәрдә нинди роль уйнарга тиеш иде.

Әсәр язарга алынганчы мең төрле шик-шөбһә, мең төрле сорау да туды: героик чор, героик характерлар таләп итү белән бергәттән, яңа әсәр яңача фикер йөртү, яңа форма да таләп итәчәк. Җиңеп чыгып булырмы? Вакыйгаларга фәлсәфи гомумиләштерүләр ясап, китапны монументаль әсәр дәрәҗәсенә күтәрә алырмынмы?

Алда әйткәннәремә тагын бер игътибарга лаеклы нәрсә өстәлде. 1955-1957 елларда Мәскәү Югары әдәби курсларында укыганда миңа остаз итеп Константин Фединны билгеләделәр. (Татар икәнлегемне белгәч, ул мине үзенә алган). Остазымның бер мәкаләсендә, нәкъ минем романым турында әйтелгәнгә охшаган сүзләр бар иде. «XX гасырның икенче яртысында яшәгән художникның китапларын атом производство новаторлары да укырлар, шунлыктан без элекке әдәби алымнар белән генә чикләнә алмыйбыз», диелгән иде анда. Бу сүзләргә дә колак салмый мөмкин түгел иде. Шулай да — тәвәккәлләдем.

Уйларга бирелеп, күз явын алырлык ак диварлар белән бизәлгән якты яңа калага килеп җиткәнемне сизмичә дә калганмын. Иң әүвәл Ленин орденлы «Камгэсэнергострой» берләшмәсе органы «Кама таңнары» газетасына, иске танышларым янына кереп чыгасы иттем. Анда да мине яңалыклар көтә иде. Автозавод районында берсеннән-берсе матур йортлар күтәрелә. Аларны СССР Архитекторлар Союзы члены, СССР Министрлар Советы премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган төзүчесе Марат Шакирович Бибишев җитәкләгән йортлар төзү комбинаты сала. Менә 54/08 нче йорт янына аның төзүчеләре җыелды. Ул көнне бер миллионынчы квадрат метр торак мәйданын сафка кертү билгеләп үтелде. Митингтан соң юбилей йортына мәрмәр такта беркетелде.

Шул ук көннәрдә Чаллы шәһәрендә концерт залы ачылды. Анда беренче концертны татар артистлары куйды. Концертны Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе шагыйрә Гөлшат Зәйнашева ачып җибәрде...

Чаллы урамнарында тоташ ташкын булып машиналар чаба. Ыгы-зыгы, кара сөрем, тынга кабарлык газлы, тынчу һава. Бихисап торбалардан күккә кара төтен бөркелә. Шәһәр санитария-эпидемиология станцияләре җитәкчеләре әйтүенә караганда, соңгы елларда һавада зарарлы матдәләр рөхсәт ителгәннән шактый артып киткән.

Заводны сала башлаган елларда мәсьәләнең ул ягы турында бөтенләй борчылмаганбыз. Чөнки, вәкаләтле белгечләрнең аңлатуына караганда, КамАЗның берсеннән-берсе зуррак заводларын һәм шәһәрне төзегәндә һәр нәрсә җентекләп тикшерелгән, бөтен яктан да исәпләнгән, хәтта җилнең кайсы яктан күбрәк исүе дә исәпкә алынган иде. Барлык предприятиеләр санитария-саклау зонасы белән әйләндерелә, дигәннәр иде безгә. Әле дә булса хәтеремдә: җиде заводтан торган берләшмәнең пычранган суларын чистарту корылмалары, башка беркайда да булмаганча, камил иттереп ясалачак дип, язып та чыктылар.

Без, диваналар, шул сүзгә ышандык. Чынлыкта исә әлеге вәгъдәләрнең күбесе, сабын куыгы кебек, шартлады яки буш вәгъдә булып һавада асылынып калды. Шәһәрдә әйләнә-тирәнең һәм һаваның чисталыгын саклау мәсьәләсе, вакыт үткән саен, җитдиләнә бара. Без моны шәһәр санитария-эпидемиология станциясе белгечләренең мәгълүматларыннан да ачык күрәбез. Алар төтен һәм газ чыгаручы предприятиеләрне җентекләп тикшергәннәр, күп төрле технологик режимнарның бозылуын ачыклаганнар. Һаваны агулаучы предприятиеләрнең бары тик илле процент чамасында гына чистарту корылмалары, газ һәм тузан тоткыч җайланмалар нормаль эшли икән. Металл кою заводында, мәсәлән, 350 гә якын һава чистарткыч бар. Алар металл эреткәндә хасил булучан төрле газларны, корымны үзләренә йотып, тышка бер төрле дә начар исле, кеше организмы өчен зарарлы газ чыгармаска көйләнгән. Агрегат заводында исә хәлләр мөшкел хәлдә, термогальваника, цинклау, декоратив хромлаштыру автоматлары күкерт кислотасы пары бүлеп чыгаралар. Кеше организмы өчен ифрат та зарарлы әлеге газлар еш кына атмосферага эләгә...

КамАЗ төзелеп яткан еллар иде. Минем бу төбәктән кайтып кергән юк, айлар буе шунда ятам. Бик күп кешеләр белән танышып хәтта дуслашып киттем. Көннәрнең берендә бер төркем яшь инженерлар белән балыкка төшәргә, зурдан кубып, куна китәргә булдык. Балыкның яхшы каба торган урынын да беләләр икән. Моторлы көймәләргә төялешеп шунда юл тоттык.

Балыктан бигрәк мине андагы табигать хәйранга калдырды. Ташлы, текә яр. Яр

өстендә рәт-рәт «гаскәр кеби» тез, җиз кәүсәле наратлар...

Шундук эш бүлештек. Ике-өч егет, палаткалар корырга, өч-дүрт егет көймә белән кереп кармаклар салырга булдылар. Мин учакка коры-сары җыярга тиеш идем. Су буенда утын ише нәрсә күренмәгәч тауның өстенә күтәрелдем. Күтәрелдем дә тирә-юньгә күз салып кабат хәйран калдым. Утын турында онытып адәм аяк басмаган кыргый урманның эченәрәк уздым. Коелган ылыс, вак-төяк куаклыклар, оя-оя утырган абагалар арасыннан алга киттем. Күлне котырып үскән җикән камышлар урап алган. Күл өстен күрү нияте белән бер якка авып төшкән карт наратның юан кәүсәсе буйлап өскә үрмәли башладым. Инде беренче ботакка күтәрелдем дигәндә күл өстендә шау-шу купты: берьюлы бер көтү үрдәк һәм пар кыр казы очып китте... Андый гүзәллекне минем үз гомеремдә һичкайчан күргәнем юк иде. Су өстенең урман күләгәсе төшкән өлеше яшькелт бәрхет. Икенче өлеш, күк йөзенең зәңгәрлеген чагылдырып, күзләрне камаштырып ялтырап ята. Күз явын алырдай ап-ак төнбоек чәчәкләре чәчелгән. Өстәвенә күл балыклы да иде: су өстен тынгысызлап, бөҗралар ясап алар уйнамый кем уйнасын ди?!

Күлнең аръягында ботак шартлап сынган тавыш ишетелде: куе наратлык арасыннан ике поши килеп чыкты. Алдан килгәне, мәһабәт мөгезлесе кеше барын сизенде, ахрысы, ана пошины туктатып, аны гәүдәсе белән каплады...

Шул кыргый күл еллар буе төшләремә кереп газаплады. Һәм, ниһаять, соңгы баруымның берсендә, элеккеге танышларым белән очрашкач, кайчандыр балык тотып яткан җиргә алып баруларын үтендем.

— Анда хәзер балык та юк, яр буйларының да рәте-чираты калмады, — дип, баш тартып матташсалар да әйләнеп кайтырга күнделәр. Бармасак, хәерлерәк буласы икән. Яр буйлары чокыр-чакырлар белән ермачланып беткән. Сазлык сыман сулык кына бар. Төнбоекларның, камышларның эзе дә юк. Хәтта наратлар да киселеп беткән. Аларны ташыр өчен, басма-күперчек салганнар. Кая карама, чүп-чар өемнәре, учак эзләре...

Болайга китсә, бик тиздән бу тирәләр, ягъни борынгы Чулман төбәгенең тиңдәшсез матурлыгы тәмам бетәчәк. Оныкларыбызга бу тирәләрне мәшһүр рәссам Шишкин әсәрләреннән карарга гына калыр микәнни?!.

* * *

Заманалар үзгәрде...

Моннан берничә ел элек халык депутатларының Түбән Кама шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары иптәш Г. Щеглова экологиягә кагылышлы сорауларга тулы җавап бирә торган иде. Папкасын ачар иде дә, алдан ук ятлап куелгандай, саннар тезә башлар иде. Кайчак, иптәш Г. Щеглованың сүзен бүлеп, игътибарны промышленность предприятиеләре эшчәнлегендәге җитешсезлекләргә юнәлдерү ягын күрсәң. Баксаң, монда да эшләр «ал да гөл» икән!..

Заманалар үзгәрде... Бүгенге көндә табигатьне саклау, һаваны чиста тоту, шәһәрдә нормаль яшәү өчен тиешле шартлар тудыру мәсьәләсе белән КПССның шәһәр комитеты да, халык депутатларының Түбән Кама шәһәр Советы башкарма комитеты да даими шөгыльләнә. Чөнки соңгы елларда тирә-юнь мохитнең ямьсезы турында борчылып, шәһәр халкына суларга һава җитмәве турында нәфрәтләнеп язылган хат-шикаятьләрнең исәбе-хисабе юк. Бу хатлар хәрәкәттә.

Заманалар үзгәрә...

Хикмәте шунда, табигатьне саклау мәсьәләләренә багышланган сессияләр электәгечә ябык ишек артында тикшерелми, аңа теләге булган һәр кеше катнаша, үз фикерен, тәкъдимен әйтә ала. Көн тәртибенә табигатьне саклау мәсьәләсе куелса, игъланнар район һәм шәһәр газеталарында алдан ук бастырыла. Залда, депутатлардан тыш, хезмәт коллективлары вәкилләрен дә, үзләрен «яшелләр» дип атаган укучыларны да, пенсионерларны да күрергә мөмкин. Сессияләр ифрат та киеренке шартларда, җанлы бәхәсләр атмосферасында уза. Бу турыда матбугатта язып та чыккаладылар. Иптәш А. Зариповның хатына игътибар итик. Мәкаләнең исеме үк язманың җисемен әйтеп тора: «Тизрәк күтәрелик!»

«Татарстан табигате аз күрдеме инде төрле зыяннарны? — дип яза ул. — Түбән Кама ГЭСын төзеп күпме җирне су астында калдырдылар. Иң бай, иң гүзәл болын-әрәмәлекләрен югалткан Актаныш, Минзәлә, Мөслим, Тукай, Сарман районы халкы күпме тормыш итү чыганагыннан мәхрүм калды?!»

«Татарстан яшьләре» газетасы күптән түгел: «Табигатьне ярату гына җитәме?» дигән темага сөйләшү уздырды. Әңгәмәдә катнашучылар бертавыштан, табигатьне, тирә-як мохитне саклау, тулысынча, кешенең үзенә бәйле дигән фикергә килделәр. Бу сөйләшү нәтиҗәсе басылып чыккач, редакциягә хатлар агыла башлады. Укучылар: «Табигатьтән

41. **«Төньяк төрекләренең әдәбият тарихы».** Әлегә басылмаган.
42. **«Татар кызы».** Роман. 1943-1945. Бар булган милли казанышларын сакларга тырышып та, гыйльми нигезләре булмаган кайбер китаплар астында кабиләчелек тарлыгына кереп киткән ике кыз кардәшнең хәяты.
43. **«Хәят юлында».** Драма. 1940. Милли революция һәм милли күтәрелеш дәверенең иҗтимагый күренешләре.
44. **«Тәүбә иткән хатын».** Хикәя. 1948. Әхлак юлыннан чыгу куркынычын атлап үткән бер кызның маҗаралары.
45. **«Алпавытлар».** Гогольдән тәрҗемә. 1948.
46. **«Казан тарихы».** 1945-1952. Басылмаган».

*«Милли көрәшче һәм милли әдип Гаяз Исхакый» исемле китаптан (Истанбул, Османбәй матбагасы, 1955, 16-21 битләр).*

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

**Журналыбыз киләсе елда сезне Гаяз Исхакый иҗаты белән таныштыруны дәвам итәчәк — аның «Сөннәтче бабай» һәм «Зиндан» повестьларын бастырып чыгарачак.**

---

# *Бер сорауга бер җавап*

**— Журналыбыз хакында сез нинди фикердә?**

— Әтием Габдрахман (Троицкида туган) әдәбиятыбыз-сәнгатебез үсешенә сөенеп, аны кайгыртып яшәүчеләрнең берсе иде. Өебездә татар китаплары күп, төрекчә, әзербайҗанча һәм, әлбәттә, үз телебездәге вакытлы матбугатны даими алдырып тора иде ул. Шуңа күрә мин, «Төрек йорты», «Мулла Насретдин»нан әүвәл, татар журналларын укып үстем. Әтием «Ак юл», «Сөембикә», «Шура», «Аң»нарга кызыксыну уятты. Журналлар һәммәсе җыйналып, текмәгә тупланып барганлыктан, аларның элегрәк чыккан саннарын да күздән кичерергә мөмкин иде. Мин аларны бик бирелеп, сурәтләре белән зәвыкләнеп таныша идем. «Кечкенә иптәшләр» журналы да балачагым дөньясын баетып килде.

«Казан утлары» белән «Безнең юл» дип аталган дәвереннән үк танышмын. Залим И. Сталин заманында әлифбабыз алыштырылып, туган телебезгә, мәдәниятебезгә ифрат зур зыян салынды. Шул елларда бер ара мин дә татар матбугатыннан аерылып тордым. Әмма тырыш, сәләтле халкым тагын тернәкләнде, матди хәятен, рухи халәтен алга җибәрү, тәрәккъкый иттерү өчен бихисап көч салды. Мин моны «Азат хатын», «Казан утлары» аша белеп, шулардан азыкланып, рухланып яшим.

Журналның борынгы мәдәни мирасыбызны кайтару хәрәкәтен, аңа мәхәббәт уятырга омтылуын хуплыйм. Сынлы сәнгате катлаулы язмыш кичергән милләтнең әдәби журналы тышлыгында архитектура намунәләрен, халык сәнгатенең кыйммәтле үрнәкләрен сурәтләп баруына да шатланам...

Бу башлангычларны киләчәктә дә дәвам итү яхшы. Борынгы һәйкәлләрнең рәсемнәре, фотосурәтләр журнал битләрен бизәп тора, мәгърифәтле ата-бабаларыбызга, шанлы казанышларыбызга ихтирам уята. Бу җәһәттән мин үзем дә редакциягә булышырга һәрвакыт әзер.

Журнал елдан-ел кызыклырак чыга. Бу, әлбәттә, халкыбызның иҗади дәрманы, дәрте яңадан җанлануын, редакция хезмәткәрләренең җаваплылык тоеп эшләвен күрсәтә. Киләчәктә «Казан утлары» тиражы йөз меңнән ашуын, мәдәниятебезнең колачы, мавыктыру көче, тәэсире тагын да ишәюен телим.

**Чыңгыз ӘХМӘРЕВ,**
Үзбәкстанның халык художнигы, СССР Дәүләт һәм Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

*Ташкент шәһәре.*

# Хәсән Туфан

*Хәсән Туфанның әдәби мирасын барлаганда, шигъриятенең никадәр рухи инануга нигезләнгән булуына ышанасың. Басылмаган, яки аерым өзекләре генә матбугатта күренгән әсәрләре аның һәрвакыт килешүсез, киеренке, ярсу көрәш шартларында яшәгәнлеген күрсәтәләр. Хәзер инде вакытында чыга алмаган әнә шундый әсәрләр әдәбиятыбызга кайта,— укучыларга тәкъдим итела башладылар. Шул юнәлештәге бер сәхифә сыйфатында бу санда без Хәсән Туфанның басылмаган кайбер шигырьләрен тәкъдим итәбез. Аларның бүгенге (хәтта киләчәк) көнгә атап язылгандай актуальлеге, бүген дә әле сискәндерә ала торган көйдергеч кайнарлыгы, бер яктан, халык күңелендә мондый тискәре тенденцияләргә каршы протестның күптәннән булуы, димәк, илебездәге үзгәртеп кору эшенең ни дәрәҗәдә җитлеккән булуы турында сөйләсә, икенче яктан, мондый тискәре күренешләргә каршы киң җәмәгатьчелекнең һәм һәр кешенең шәхси активлыгы ни дәрәҗәдә зарур икәнлеге хакында да искәртә.*

*Хәсән Туфанның, төрле елларда язылып, басылмый калган бу шигырьләре тормышыбызны үзгәртеп кору өчен барган көрәштә — бүген дә — үткен корал хезмәтен үти алалар, безнеңчә.*

**Мәсгуть Гайнетдинов.**

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

❁

...Җитәкләп китерделәр дә,
«Сөйләшеп» утырдылар:
«Исәнлек-саулык» сорашып,
Анкета тутырдылар.

Ул — «Идел-Урал» турында
Нәрсәдер сөйли — сорый.
Ә минем күңел еракта —
Ирекtә очып йөри:

...«Ничек, дим, якын танышлар
Булмасын болар минем?—
«Идел» — ул туган җирем ич!
Ә «Урал» — торган җирем!

Кем дә кем, әйтик, әгәр дә
Бөтенләй өмми түгел,
Ул «Урал эксизлары»м бит
Аз гына белми түгел.

Уралның, иптәш, ялкынлы
Халыгын сөйде йөрәк.
Бозларын түгел, Иделнең
Кызларын сөйде, димәк...»—

«Килешле итеп кенә» ул
Өстәлгә ямый-ямый:
«Без сиңа иптәш түгел!— ди,
Абайлап сөйләш, абый».

«Җилкенеп» «җайлы гына» бу,
«Килешле генә» дулап.
«Без түгел, сиңа — иптәш, ди,—
Тамбов бүресе, дурак!..»

«Әйе, дим, иптәш түгел без,
Бусы, дим, пожалуй, рас.
Ә дустым урны турында...
Ул ягың — ялгыш бераз:

Дускаем китте бит аннан,
Ул анда кайтмас тагын,
Мәңгегә безнең йөрәктә
Калдырып урманнарын»...—

Үз эшен бик тә уңышлы
Үтәгән кеше сыман,
Кулларын уып куя бу,
Мин исә — уйга чумам...

«Ә-ә-ә,— ди бу:
— Тамбов... урманнар...
Китүе сезгә анык...—
Инде баш тартып карагыз,—
Сүзләрең безгә — таньк»...

«Хет үтер, кабул итәлмим
Мин сезнең сүзне бөтен,—
Тын Тамбов урманнарыннан
Аеру аны читен:

Ул үзе барган тарафка
Ияреп барды алар,—
Мәңгегә безнең халыкның
Күңлендә калды алар.

Такташы белән кулга кул,
Казанга килде алар.
Такташ юк, мәңге халыкның
Күңелендә инде алар.

Мәңгегә китте, Җыр калды,—
Тылсымлы безнең нәсел:

Дәверләр үтә, гасырлар,
Ә усак — һаман яшел!

Дәверләр, чорлар үтәләр,
Ә усак — шаулый һаман,—
Ил белән бергә баралар
Киләчәк көнгә табан...—

Хәтерли минем йөрәгем
Дустымның туган ягын,
Тамбовтан безнең йөрәккә
Күчерелгән урманнарын»...

«Ә ник, ди, кәпәч киясең?»—
«Минем, дим, картуз шулай,—
Туганнан бирле түгел дә,
Тукайдан бирле бугай...»—

«Җитәкләп» китерделәр дә
«Сөйләшеп» утырдылар,—
«Төрле хәл сорашып», шулай
Анкета тутырдылар...

*11—13 январь, 1949.*

❁

Үлем белән байтак тапкыр инде
Күзгә-күз без туры килештек,—
Ул ыржаеп карап торды миңа,
Читлектәге сыртлан шикелле.

Әллә дөнья шунда, әллә судья
Аерып тора әле гел генә,—
Бер килер бит, ләкин, ул имансыз,
Букет тотып килмәс, билгеле...

Мин якыннан күргәнем бар аны:
Тимер тырнаклары кыналы...
Тәне — кум-күк. Сөяк кулларында —
Кан таплары аның... Кем каны?—

Бәлки безнең дуслар каныдыр ул —
Хәбәре юк кордашларныкы?—
Юри аны безгә китергәндер,
Алар киткән эзләр аркылы...

Һәлакәте серле мәрхүмнәрнең
Дөньядагы соңгы көннәрен,

Ташсыз каберләре кайдалыгын —
Барсын, барсын ачык белгәнен,

Нәрсәседер аның әйтеп тора,—
Нәрсәседер, кара йөземе?
Бернинди дә битлек асларына
Яшереп булмый торган күземе,—
Нәрсәседер аның әйтеп тора...

Ул, ыржаеп, күз төбәгән миңа:
«Вәт, бусы да каба...» дигән күк,
Бәбәкләрен миңа терәгән ул.
Ә мин исә: «Пока!..»— дигән күк,

Бүрегемне артка күтәрәм дә,
Китәм «иртәгә»ләр эченә,—
Ул, ыржаеп, борынын төртеп кала,
Әле... үземә түгел, эземә...

*1949*

❁

Ильич синең төп сыйфатны андук
Күргән: язган, илгә тапшырган,—
«Бу, Генсекретарь була алмас,— дигән,—
Үзен өскә куя барсыннан»...

Исеме белән атап дорфалыгын
Холкында бар илгә ятларны,
Киләчәген уйлап бу дөньяның,
Язган Ленин васыять хатларн

Кем дә булса түгел, Ленин язган!
Авыру хәлдә! Әрнеп ил өчен!
Онытырмы чынлап зур көрәшкә
Җан бирергә әзер — Ильичын?!

Кайда идең аны укыганда?
Кая китте ул хат шуннан соң?!—
Дәрәҗә өчен генә, шул чорда ук
Ленин юлыннан син шылгансың.

«Шаһит булып карап торма, Идеал,
Дидең, җәһәннәмгә кит — олак,—
Минем «эш»не синнән башка гына
Башкарырга җирдә яхшырак.

Беркем калмас Илдә миннән бүтән,
Кыйблаларны барлар кешеләр.
Көрәш байрагының тирәсенә
Туплансын тик минем ишеләр...

Бу заманда Ленин — ул мин, дидең...
Таш аттың син халык йөзенә,
Илнең эшен, партиянең данын
Үзләштерә барып үзеңә.

Үз формаңа кертмәк булдың безне,—
Кешелегебезне кимсеттең.
Инициативаны эзәрлекләп,
Миллионнарны йөзсез кол иттең.

Без ышандык: чындыр дип уйладык
Антыңдагы изге вәгъдәләр.
Ышандык без: Ленин эшенә, дидек,
Тик лаеклы кеше шул мәгәр.

«Интернационал» җыры кебек,
Чыннан көчле иде ул антың:
Аны безнең теләкләрдән алдың,
Ул хисләрне үзең югалттың...

Нахак яла, җәза астында да
Шушы антка тугры калдык без,—
Дарга тупас сөйрәп барганда да
Синең антны искә алдык без.

Уйлый идек: намус, ил каршында
Аз гына да бездә юк гаеп,
Коммунизм юлы җиңсен өчен
Шулай итү тиеш, мөгаен?..

Динле чакта, хәтта аллага да
Шул кадәр үк ышандык микән?!
Бугазларга элмәк салганда да
Шул иманны сакладык исән.

Ишләрем исменнән әйтә алам:
Безнең чиксез моңлы чак иде,—
Тик шунда да күңеле ишләремнең,
Бүгенгечә, изге, пакь иде.

Һәм синең дә... мыек һәм кашларың
Матәм төсе белән пар иде...
Шәхес, халык, тарих күңелендә
Сиңа әче рәнҗү бар иде...

Халыкларның хисен дорфалаттың,
Безне шикләнергә өйрәттең.
«Дан» бирдеме сиңа мәсхәрәләү,—
Әрнүләре керсез йөрәкнең?

Чечен, ингуш, татар, карачайлар
«Антихристлар алар», янәсе!—
Ә миллионлап сабый, әниләрнең
Сиңа дошман иде нәрсәсе?—
Тагын... сөннәтеме?...

Хайваннарга дигән вагоннарда
Сөрдең халыкларны, илләрне.
Карап тордың, кызыгып,
тынып калган —
Үч алынган моңлы көйләрне.

Пәрдәләргә эшең, өрәк иттең
Татар, монгол исемен галәмгә.—
Илнең көчен түктең, күндерергә
Син чыгарган «яңа» әмәлгә.

Син чыгарган милли сәясәтнең
Хак түгелен күреп, чыдадык:
Явызлыгың — «көч»кә,—
Идеал өчен
Ярсу омтылышка юрадык.

Конституция законына...
Итегеңне сөрттең... Аннары
Сабыйларның яшен ташу итеп,
Акты әтиләре каннары...

Берияләр илне имгәткәндә,
Син куянча читкә шылмадың,—
Ленинчылар дарда тирбәлгәнен
Ярык аша карап тормадың...—

Үзеңне син «даһи», «корыч зат» дип
Такмаклаттың телдә, һәйкәлдә.—
Дан сөюдә Нерон, Чан Кай-Шидан
Калышмадың, дөресен әйткәндә.

Ярый, үлдең, юкса, яши бирсәң,
Безнең хәлләр яман иде бик:
Телдә инде сине мактый торган
Сүз запасы беткән иде бит...

Син тик гүя, Ильич кисәтүен
Раслар өчен гомер иткәнсең,—
Һәйкәлләрдә, хәтта җылы чакта,
Тетелә торган «сталь» икәнсең.

Салам кыстыручы сафташларың
Үзең белән... китеп бардылар...

Күпме югалтулар! Җаннар түгел,
Сине хәтта ташлар каргыйлар...

*16.6.1956. 6.11.1961. 11.12.1963.*

## Илле еллыкның беренче көнендә

*Сез бу хатны минем укыганда,*
*Авыр еллар үткән булырлар...*

Һ. Такташ.

Корылышларның биек түбәсеннән
Күз төбәп син ерак чорларга,
Эндәшкәндә ерак кырлар аша
Киләчәккә, үлмәс җырларда:

«Мин дә күрим бөек бәйрәм елын!—
Тизрәк атла, исән булгыры,—
Очрашыйк әле!»— дигән идең...
Бүген сине эзли сыман менә
Октябрьнең илле еллыгы.

Синең белән башлыйм елны, Һади;
«Исмең һаман истә торсын, дип —
Нәкъ йөз меңгә җиткән тираж белән
Йөз мең өйгә керсен дустым», дип.

Һәр яңа ел саен шулай инде...
Бер урын буш минем табында,—
Утыргычың, Һади, өй түрендә,
Ә син үзең — минем җанымда...

«Зур талантлар тумас... Халык бетә...
Соңгы могиканнар болар», диде
Безне кайбер политсабыйлар,—
Юк, саннардан түгел, көрәшләрдән —
Давыллардан туа Һадилар.

Бер халык та әзерләнми җирдә
Мәхрүм хәлдә мәрхүм булырга,—
Бүгенгесе көндә вак халык юк,
Көрәшләрдә кайный бу дөнья.

Аны-моны уйлап тормый-нитми:
«Бар да инде тигез»,— дисең дә...
Бар «вак»ларның илләр төрмәсендә
Кимсетелгән көне исеңдә...

Синең белән башлыйм елымны мин,
«Исмең һаман истә булсын», дип,—
Нәкъ йөз меңгә җиткән адресатка
Сәлам булып барсын дустым», дип,

Тормышыңның соңгы елларыннан
«Киләчәккә хатлар» язганда,
Алгы чорлар — ерак кырлар аша
Эндәшкәндәй итеп заманга:

«Очрашырбыз әле...— дигән идең,—
Хәзергә, хуш, исән булгыры...»
Бүген менә сине тәбрик итә
Октябрьнең илле еллыгы.

Һәр яңа ел саен шулай инде:
Бер урын буш табын түрендә,—
Урының, Һади, шулай буш булса да,
Үзең мәңге халык күңелендә.

Син былтыр да миндә булган идең,
Адресым да әле истәдер,—
Онытсаң да әгәр адресымны,
Барыбер кил... төндә... төшкә кер...

*1.1.67.*

ПУБЛИЦИСТИКА

## Мәхмүт Хәсәнов

# АЭС САЛДЫ ХАФАГА

Ифрат тынгысыз чорда яшибез. Бүгенге кеше өстендә берьюлы өч Дамокл кылычы асылынып тора: атом-төш сугышы, табигатькә салынган зыян һәм әхлакый яктан череп-таркалу. Академик Д. С. Лихачев әйтүенчә, биология кануннарына игътибар итмичә, кеше үз-үзенә үлем әзерли. Икенче төрле әйтсәк, Шекспирның Гамлеты сыман: «Яшәргәме? Бетәргәме?..» дигән дилемма алдында калдык. Халык, социалистик плюрализмнан файдаланып, урамнарга чыкты. Телебезгә «митинг», «забастовка», «эш ташлау», «халык чуалышларын көч белән бастыру» кебек сүзләр килеп керде. Безнең республикада да узды митинглар. Казанда, университет янында булган митинглар турында ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Нәтиҗәсе дә билгеле: Казан янында салынырга планлаштырылган биохимзавод төзелмәячәк.

Әлмәт шәһәрендә булып үткән күпмеңле митинг турында «Социалистик Татарстан» газетасы язып чыккан иде. Бирелгән сораулар, куелган таләпләр җитди: «Һава начар булганлыктан, тын алуы авыр. Пычрак. Балаларыбыз чирдән арынмый. Нәрсә карыйсыз?..»

Хәзер, экология мәсьәләләре экономика һәм социаль проблемаларга караганда да җитдирәк төс алды.

Түбән Кама шәһәрендәге хәл аеруча җитди. Иң яманы шунда: атмосферага нинди күләмдә, нинди химик матдәләр ташлануын, һаваның ни дәрәҗәдә пычрануын кешеләрдән яшерәләр. Түзәр чамасы калмаган халык, гаярь группалар төзеп, шәһәрнең иң зур җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп карый. Әмма бу нәтиҗә бирми. Алай гына да түгел, андый кешеләрне, экстремистлар, дип, гаепләү очраклары да булгалый.

Узган көздә, Түбән Кама шәһәрендә, «Язгы аҗаган» романым буенча республикабызда беренче тапкыр буларак, китап премьерасы үткәрелде.

Мин ул көнне кунакханәгә төн уртасында гына кайттым. Шулай соң булуга да карамастан, бүлмәмә бер төркем иптәшләр килеп керде. Арада төрле һөнәр кешеләре бар иде. Теләкләре бер: аларга язучының ярдәм сүзе кирәк.

— Үтенечебезне аяк астына салмассыз, — диделәр алар. — Үзегез күреп торасыз, безне газ белән генә тончыктырып үтерә алмагач, борын төбебезгә терәп, АЭС төзи башладылар. Атом радиациясе белән кырырга уйлый торганнардыр...

Чәчләр үрә торырлык саннарны телгә алдылар: «Нефтехим» берләшмәсе бүлеп чыгарган зыянлы газлар (тәүлекнең кайбер вакытларында) ярагannан илле-алтмыш мәртәбә артыграк икән. Тирә-юньдәге агачлар корый, шәһәрдәге авыручылар саны күзгә күренеп арта, балалар иза чигә...

Шуңа охшашлы моң-зарны миңа Азнакайда, Чаллыда, хәтта төзелеп ята торган Кама Аланында да ишетергә туры килгәләде. Һәркайда диярлек бер үк сорау, бер үк үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр: язып, күтәреп чыксагыз иде!... һәм мин, җәйнең иң матур, иң озын көннәренә туры китереп, сәфәргә чыгып киттем.

Сәяхәтемне, әлбәттә, Азнакайдан башларга булдым. Бу төбәк миңа аеруча якын, туган җирем кебек. Азнакай якларын елына берәр тапкыр әйләнеп килмәсәм, үземне изге вазифасын үтәмәгән кеше сыман хис итә башлыйм.

Иң беренче күреп-сөйләшкән кешем, КПССның Азнакай шәһәр комитеты беренче секретаре Октябрь Салихович Мөхетдинов булды. Уттай урак өстендә, иртәнге алтыларда ук кабинетында иде инде ул. Иң әүвәл көннәрнең торышы, эш барышы, иген уңышы турында гәп саттык. Мине иң гаҗәпләндергәне беренче секретарьның район хуҗалыкларында җыеп алынасы уңышны конкрет саннар белән атавы булды. Алар һич кенә дә куанычлы түгелләр иде.

— Әмма, һәркайда да алай начар булмаячак, — диде Октябрь Салихович минем уемны аңлагандай. — «Авангард»та, мәсәлән, көзге бодай белән арыштан утыз центнердан да артыграк уңыш җыеп алынып дип торабыз...

Сүз иярә сүз китеп, әңгәмәбез үзләрен данга күмгән нефтьчеләргә күчте. Баксаң, зур тантаналы көннәргә туры килгәнмен лабаса! Дөньяда тиңдәше булмаган Ромашкино нефть ятмасын ачуга 40 ел тулуны билгеләп үтәргә җыеналар икән. Ул уникаль ятма турында илебездә генә түгел дөнья матбугатында да күп яздылар. Нәкъ менә шул хәзинә Татарстанны «Кара алтын» республикасына әверелдерде, «Икенче Баку» итте, сыек ягулык чыгару буенча илебездә беренче урынга чыгарды...

Бераздан Октябрь Салихович: «Синең тикмәгә генә йөрмәгәнлегеңне беләбез», дигән булып, минем нинди йомыш белән килеп чыгуым турында кызыксынды, ярдәм кирәкмиме, дип сорады. Җавабымны ишеткәч җитдиләнеп калды.

— Әй-йе!.. — дип көрсенде секретарь. — Күрәләтә торып харап иттек табигатьне. Ул югалтуларны нинди генә бизмәннәргә салып үлчәргә мөмкиндер? Барысына да җавапсызлык, хуҗасызлык гаепле. Җавапсызлык булган җирдә гаепле кеше дә гаепсез, ягъни, җавап бирүче юк...

Октябрь Салихович бер генә мизгелгә туктап торды да, нидер исенә төшергәндәй, дәвам итте.

— Шул ук нефтьне алыйк, ди. Бер скважина үзе урта кул предприятие кадәр җир били. Башта, басу киңлекләренә кертеп, буровой куялар. Анда инде җир-ана белән санашып торды юк, җирнең асты-өскә килә... Юллар кирәкме? Кирәк. Электр энергиясе кирәкме? Кирәк. Басу киңлекләренә меңнәрчә баганалар утыртылды. Су кирәкме — тагын траншея казыла, тагын кызыл балчык өелә. Басуларның карар җире калмый. Механизаторларыбыз зар җылый: бар, иркенләп эшләп кара син баганалар белән чуарланып беткән, тигезле-тигезсез басуда. Һәр багана төбенең, чокыр-чакырның чүп үләне чыганагына әверелүе турында әйтеп тә тормыйм. Белгәнегезчә, скважина бораулау — эшнең башы гына, промыселчылар килгәч, башлана хикмәтләр: җирне чын мәгънәсендә көчләү, мәсхәрә итү... Яңадан тау-тау кызыл балчык өемнәре калка. Уннарча километрга нефть үткәргечләре күмелә. Бер заман әлеге торбалар, көчле басымга чыдый алмыйча, шартлый башлый, нефть өскә бәреп чыга. Алар елга-күлләребезгә агып төшә. Ул арада скважиналарны ремонтларга керешәләр. Басу янә мең төрле техника, тимер тавыдай зур, авыр агрегатлар белән тула. Төзәтүләр тәмамлангач, тагын да җан әрнеткеч күренеш: якты кояшны кап-кара төтен каплый. Нефтьчеләребез басу өстенә агызылган нефтьне яндыра, җирне тәмам эштән чыгарган кара таплардан «котылалар». Әлеге сөремле кара болытлар, басу-болынлыкларыбызга утырды. Сыерларыбызның сөте күзгә күренеп кими? Сөтне кабул итмәү очраклары да ешайды, чөнки сыерлар ашаган үләннәрдә нитрат, организм өчен гаять тә зарарлы азот матдәләренең бик күпкә артып киткәнлеге билгеле булды...

Таныш-белешләрем, дус-ишләрем белән дә очрашу чарасын күрдем. Андыйлар бихисап Азнакай якларында. Нефтьче ветеран Салих ага Гарипов белән дә очраштым. Кайчандыр мин аның фидакарь хезмәте турында берничә тапкыр язган идем. Бу юлы берничә кеше бергә туры килдек. Истәлекләргә бирелдек. Ромашкино нефть чыганагы да телгә алынды. Ул турыда гәп кузгалгач, Салих ага аеруча кызып китте:

— Әйе, бар иде заманалар. — дип сөйләргә тотынды ул. — Нефтьнең бер дә исәбе-хисабы юктыр сыман кылана идек. Йөз елга җитәрлек запасыбыз бар дигән сүзгә берсүзсез ышандык. Ышанмаслык та түгел иде шул. Җир асты басымыннан, скважина авызына куелган «елка» — арматуралар яман гөрелдәп, калтырап-дереләдәп торырлар иде. Скважинаны бер генә минутка да күздән яздырды юк. Вахталарга бүленеп тәүлекләр буе дежур тора идек. Нефтьне борчак сыярлык кына тишекле «штуцер» аша алабыз. Скважинаның басымын киметмәс өчен шулай итәбез, сыек ягулык чыгаруның технологиясе шуны таләп итә. Шул бәләкәй генә диаметрлы тишек аша да тәүлегенә 120-140 тонна чыгара идек, ходайның рәхмәте.

Салих аганың йөзенә күләгә кунгансыман булды, тавышына үкенү, уфтану галәмәте чыкты.

— Әмма бу сакчыллык кылулар, технологик режимны саклаулар озакка бармады, кемнәргәдер тагын да күбрәк нефть кирәк булды. «Давай да, давай!..» принцибына күчтек. Административ-командалык ысулының чәчәк аткан чоры. Планны да арттырдылар. Штуцерларны алып ташладык. Нефть ташкын кебек ага. Акчаны да күрәп алабыз. Ай саен премия. Орден-медальләрне өләшеп кенә торалар. Дөнья базарында нефтьнең иң кыйммәт чагы. Чит илгә нефтьне алтынга сатабыз. Димәк, илебез тиз арада череп баеячак. «Коммунизмга чыгабыз» дигән сүз дә телгә керде. Җитмәсә, һәр «яулап алган тарихи җиңүебез», мәҗлесләр ясап, билгеләп үтелә. Дивана әйтмешли, көн дә бәйрәм, көн дә туй. Күзләр тонган килеш вахтага чыгулар да гадәткә әверелде. Технологик режим, техника куркынычсызлыгы дигән нәрсәләрне тәмам оныттык. Күп тә үтмәде,

аварияләр, фаҗигале хәлләр башланды. Яңа елны каршылаган төннәрнең берсендә, нефть кудыру станциясе шартлап, берьюлы алты иптәшебез һәлак булды...

Салих аганың күз карашларына кадәр үзгәрде.

— Һаман да әле бернәрсәгә төшенә алмыйм: шул кадәрле нефтьне вәхшиләрчә әрәм-шәрәм итү кемгә кирәк булды икән? «Йөз елга җитәрлек запас» дип күрәзәлек кылулар нигезсез булып чыкты. Ун ел чамасы вакыт үттеме икән, нефть катламнарының егәре күзгә күренеп кимеде, фонтаннар «шиңде», сыек ягулык чыгаруны механик ысулга күчерергә мәҗбүр булдык...

ИНФОРМАЦИЯ. **1960 елда илебез 17,8 миллион тонна нефть саткан булса, 1985 елда бу сан 117 миллионга җитте. Шул ук вакытта илебез иң эре импортчыга әверелде. 1960 елда чит илдән 200 мең тонна икмәк сатып алган булсак, 25 елдан соң бу сан 44 миллион 200 мең тоннага җиткерелде. Шул ук вакыт эчендә электротехника җиһазлары сатып алу 22 тапкырга, металлургия җиһазлары — 19 тапкырга, ә авыл хуҗалыгы машиналары сатып алу — 154 тапкырга артты.**

— Сез, Салих ага, һаман да әле республикабызның горурлыгы булган нефтьнең тискәре якларын сөйлисез. Аның бит уңай яклары да бихисап. Шул ук юлларны гына алыгыз! Өйләргә газ керде, кайнар су килде, — дидем.

— Мин дә гелән яманлык булып кына кайтты димим ич. Тормыш дәрәҗәбезнең күтәрелүе өчен бик кыйммәт түләргә туры килүе турында гына әйтәм. Табигать-анабызны талавыбызга эч поша. Моның бер чиге булырга тиештер бит?! Урман-суларыбызның рәте калмады. Чишмәләр корыды. Су буйларында каз каңгылдавы, үрдәк бакылдавы ишетелмәс булды. Елга-күлләребездә тереклек заты калмады. Хәтта бака качты. Инде килеп, син әйткән газ турында бер-ике сүз. Алтын чыккан җирендә кадерле, ди. Шушы көнгә кадәр авылларыбызга газ кертү нибары 7 процентка үтәлгән.

Салих ага тыңларлык, күңелен бушатырлык кеше очратуына куангандай, сөйләде дә сөйләде:

— Миллион сум табыш алырбыз дип, миллиард сум зыян китерүләребезнең нәтиҗәсен бүген үк күрәбез, табигатьтә генә түгел, кешеләрдә дә рухи коргаксу башланды бугай инде...

Мин, ветеран нефтьчене ямьсез уйларыннан арындыру нияте белән, сүзне революцион үзгәрешләргә, хәбәрдарлыкка күчердем. Салих ага шундук эләп тә алды.

— Тормышыбызны савыктыру, үзгәртеп кору бик кирәк иде. Тик, кызганычка каршы, үзгәртеп кору һаман да әле без көткән юлын таба алмый. Еш кына сүз эштән аерыла. Карарларның үтәлешенә контроль кирәк! Чирне кирәгеннән артык тирәнгә җибәрдек. Бюрократларны, бушбугаз түрәләрне, сорыкорт чиновникларны симертү белән артыграк мавыгып, тормыш терәге, тормыш төткасы — хезмәт кешесе турында онытыбрак җибәрдек. Шул сорыкортлар кеше намусының гына түгел, фидакарь хезмәтнең дә кыйммәтен төшерделәр...

...Районны аркылыга да, буйга да айкап чыктым. Гүзәл Ык буенча да төштем. Хәсән Туфан, Сибгат Хаким агалар белән атналар буе палаткада яшәп яткан чакларны искә төшереп, әкияткә тиң тирә-юнь белән хозурланып ике-өч көн ял итәргә иде ниятем.

Су буена төшмәсәм, хәерлерәк буласы икән. Ыкка карадым да күзләремә ышанмыйча тордым. Ишелеп аккан мул, чишмәнекедәй саф сулы Ыкның танырлыгы калмаган: кечерәйгән, саеккан, моңсуланган. Ярларыннан бик түбән төшеп ага башлаган. Талыйлар икән елганы: нефтьчеләр аның суын җир астына кудыра, колхоз-совхозлар көне-төне басу киңлекләренә сиптерә...

Йөрәк әрнүенә чыдый алмыйча көч-хәл белән таңны аттырдым. Элегрәк, кояшның беренче нурларында, салават күперенең бөтен төсләрен чагылдырган су өстендә, балыклар уйнар иде. Бу юлы күрмәдем. Бөтен елганы иңләп мазут элпәсе ага...

Шактый күңелсез уйлар белән саубуллаштым мин Азнакай яклары белән. Безгә алмашка киләсе буыннар да бар бит әле. Оныкларыбыз, варисларыбыз алдында, Салих ага әйтмешли, ничек итеп җавап тотарбыз?..

* * *

Мин тагы юлда. Бу юлы Чаллыга ашкынам. Анда зур тантана: КамАЗ бәйрәме, баш конвейердан миллионынчы машина төшәчәк. Маңгаена 1000000 саны сугылган «КамАЗ» Африка илләренең берсенә озатылачак. Хәзер берләшмә, яңача хуҗалык итү шартларында, чит илләр белән турыдан-туры элемтә урнаштырды.

Миллион автомашина! Уйлый китсәң, хәйран калырлык бит: искән җил кебек уза икән гомер дигән нәрсә! Әле кайчан гына ап-ачык басу уртасына монда авыр йөк маши-

башка яшәү юклыгын хәтеребездән чыгарып җибәргәнбез», — дип, ачынып яздылар.

Менә Х. Мөхәммәтҗанов мәкаләсе. Ул аны «Каравыл кычкырыр вакыт» дип атаган. «Мин элек тә табигатьне саклау, аны пычратуларга юл куймау хакында гел уйлана идем. Безгә бит әллә кайчан каравыл кычкырырга вакыт җиткән! Ә халкыбыз һаман да баш иеп, авызын йомып торуын дәвам итә. Татарстан республика-заводка, агуланган республикага әверелеп бара!»...

Бу сүзләрне укыгач, Латвия язучысы белән булган бер әңгәмә искә төште. Хәзерге безнең КамАЗ Латвия портларының берсе янында салынырга тиеш булган икән. Әмма республиканың партия оешмасы һәм хөкүмәте: без болай да аз санлы халык, андый зур төзелешне күтәрә алмаячакбыз, башка яклардан килеп тулган халык исә милли пессимизм, депрессия, сәяси апатия тудырачак, дип әлеге төзелештән баш тарта.

Без исә Татарстанны «завод»ка әверелдерүебезне дәвам итәбез. Яңадан-яңа заводлар, нефть химиясе предприятиеләре салынуы турында әледән-әле ишетеп торабыз. Алабуга янында җиңел автомобильләр заводын төзү эшенә керештеләр. Менделеевск шәһәре янында тагын бер биохимзавод салынуы турында ишетмәгән кеше калмагандыр инде.

Сүзне яңадан укучы хатларына бирик. Түбән Камада яшәүче язучы, Татарстанның атказанган культура хезмәткәре Рахмай Хисмәтуллин, «Дәшмәү — үзе җинаять!» дигән мәкаләсендә, үзенә генә хас ордылы-бәрделе алым белән түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Борчулы уйларның очы-кырые юк. Изге җир ботарлана, табигатебезгә афәт әзерләнә... Минемчә, кечкенә генә Татарстанда, ике яклап, атом станциясе төзү бернинди мораль кысаларга да сыеша алмый...»

Атмосфераның нефть химиясе промышленносте, авыр индустрия предприятиеләре тарафыннан агулануы, басуларыбызның мең төрле агулар һәм минераль ашламалар белән эшкәртелүе кеше сәламәтлеге өчен ни дәрәҗәдә зарарлы булуы турында күпме язалар?! Без исә әлеге мәсьәләгә һаман да тиешле игътибарны юнәлтә алганыбыз юк.

Бүген дөнья галимнәрен, белгечләрен бер сорау борчый: табигатебез химия промышленносте басымын күтәрә алырмы? Хәзерге вакытта тирә-юнь мохиттә, табигатебез тарафыннан кабул ителмичә торган күптөрле химик кушылмалар хасил булган.

Бу турыда бөтен дөнья матбугаты, радио-телевидениеләр чаң суга. Бездә дә хәзер бу турыда ачыктан-ачык яза башладылар. Мәсәлән, Ростов өлкәсендәге сулыклар пестицид белән агуланган. Әмма хакыйкатьне халыктан яшергәннәр. Соңыннан бу хакта үзәк матбугатта: «Экологик авантюристлар», — дип язып, җинаятьчеләрне фаш иттеләр.

Белгәнебезчә, XIX нчы Бөтенсоюз партия конференциясендә СССР Табигатьне саклау Дәүләт комитеты председателе иптәш Ф. Т. Моргунов чыгыш ясады. Аның: «Химик иптәшләр! Халыкны агулаудан кайчан туктыйсыз сез?!» — дигән сүзләре озакка сузылган көчле алкышларга күмелде.

Әйе, Җир дигән өебез — куркыныч астында. Көнбатыш Европа илләрендә: «Бүген табигатьне харап итсәк, иртәгә үзебез бетәчәкбез», — дигән плакатларның нигезсез түгеллеген торган саен ачыграк күрәбез. Без әле һаман да, экология авантюристларының: «Барысы да — халыкныкы, барысы да — халык өчен», дигән купшы сүзләренә ышыкланып, җинаять арты җинаять эшләүләренә күз йома киләбез.

Шул ук партконференциядә табигатебезне һәлакәткә илтә торган коточкыч саннар телгә алынды. Мәсәлән, безнең промышленность предприятиеләре илебез атмосферасына ел саен миллионнарча тонна зарарлы матдә чыгара икән: күкерт ангидриды, азот окисе, углеводород, нитрон, метафос, теодан, перопал, циболт һ. б. лар кебек зарарлы матдәләр алар.

Болар өстенә тагын авыл хуҗалыгында табигатькә аеруча зыян китерә торган агу-химикатлар кулланылуны да өстәсәк, хәлебезнең никадәр мөшкел икәнлеген аңлау кыен булмастыр.

Химикатлар туфракның биологик активлыгын киметә, кирәкле микроорганизмнарны юк итә, бал кортларын, сайрар кошларны, файдалы бөҗәкләрне, суалчаннарны кыра, туфракның җилгә, суга каршы тору сәләтен киметә, кителмәгән урыннарда эрозияләр ясый. Шулар безгә җитди кисәтү түгелмени?!. Бүгенге көндә Американың меңнәрчә фермерлары, пестицидлар кулланудан баш тартып, «чиста» ашлык җитештерәләр һәм иген уңышларын өчләтә бәягә сата башлаганнар.

«Кызыл китап»та җир йөзендә бөтенләйгә бетеп баручы 62 төрле имезүче, 63 төрле кош-корт, 437 төрле үсемлек һәм 29 төрле су асты җан иясе теркәлгән. Димәк, фәнни-техник революция колачын киңәйтә барган саен, табигатьне саклау, аның байлыкларыннан акыллы файдалану зур социаль проблемага әйләнә.

Дөнья галимнәре, табигатькә карата мәрхәмәтсез булабыз икән, аннан рәхим-шәфкать көтәргә хакыбыз юклыкны мең тапкырлар кисәттеләр.

Американың бер галиме пестицидны, зыян китерү ягыннан, атом радиациясе белән бер дәрәҗәгә куя. Пестицидлар белән агуланган пычрак су кулланудан ел саен дөньяда

15 миллион бала үлә икән. Балалар арасында киң таралган авыруларның 80 проценты химикатлы су кулланудан килә, ди.

Бу мәсьәлә безнең илдә ничегрәк тора соң? СССР Статистика дәүләт комитетының бер документында түбәндәге саннар китерелгән: бездә ел саен 15 яшькә кадәрле 200.000 бала үлә, шул кадәрле үк бала вакытыннан элек туа, авырлы чагында һәм бала тапканда үлгән хатыннар саны, башка социалистик илләр белән чагыштырганда, 2,4 тапкырга күбрәк. Уйландыра торган саннар болар.

Билгеле булганча, Түбән Кама шәһәре — илебездә иң эре нефть химиясе промышленносте үзәге. Ачынып язылган хатларның Түбән Кама шәһәреннән күпләп килүе дә бик табигый.

«Без Түбән Кама шәһәрендә яшибез, — дип яза С. Газизова үзенең «Балалар турында уйлыйк!» дигән мәкаләсендә. — Безнең шәһәр өстендә нинди болытлар куерганын, ничә процент чиста һава сулавыбызны без, гади халык, белмибез, чөнки күп белергә ярамый. Ә бит шәһәрдә күп санлы врачлар армиясе дә яши. Алар халыктан аерым һава суламыйлар, шул ук суны эчәләр. Мине аларның фикерләре дә бик кызыксындыра. Ни өчен, белә торып, алар чаң сукмады моңарчы?..

Үзәк телевидениенең «Сәламәтлек» программасы бер тапшыруын пестицидларның кеше организмына ничек тәэсир итүенә багышлаган иде. Җанны тетрәндерерлек күренешнең шаһиты булырга туры килде. Молдавиянең йөзем плантациясендә эшләүче бер хатын гарип бала тапкан. Баланы зур иттереп күрсәттеләр: нарасыйның куллары кып-кыска, бармак араларына элпә үскән, үрдәк тәпиенә охшаган. Йөзе дә бака башы кебек. Анның күз карашында шул тикле әрнү, ачыну, нәфрәт, берүк вакытта бөтен дөньясына ләгънәт ярылып ята.

Врач сорау артыннан сорау бирә.

— Агулы химикатны үзегез сиптердегезмени?

Ананың җавабында җан өшеткеч битарафлык:

— Трактор сиптерде. Без арттан тәлгәшләрне бәйләп бардык.

— Маска кимәгән идегезмени?

— Анда, кызуда, маскасыз да тын алырлык түгел иде.

Мәгълүм ки, сәламәтлеген югалткан анадан сау-таза бала тумый. Нәселнең генә түгел, милләтнең, илнең киләчәге сау-сәламәт хатын-кызларга бәйле.

Галим, язучы Николай Амосов «Литературная газета»да басылган «Реальлек, идеаллар һәм модельләр» дигән мәкаләсендә химияне атом-төш коралыннан да яманрак, дип атый. Чөнки ул «яшерен дошман», сулаган һавабыз, тукланган ризыгыбыз, эчкән суыбыз белән организмга кереп, кешене әкренләп, сиздермичә үтерә.

Шул уңай белән галимнәр бер эксперимент ясыйлар. Алар кайнар сулы савытка бака салалар. Бака, күз иярмәслек тизлек белән, әлеге савыттан атылып чыккан... Икенче тапкырында баканы салкын суга салалар да акрынлап җылыталар. Бу экспериментның хикмәте шунда: бака, суның әкренләп җылынуына, кайнарлануына иялəшә... һәм һәлак була.

Алда әйтелгән бәлаләрдән чыгу юлы бармы соң? Бар, әлбәттә. Моның өчен тирә-як мохитне, табигатьне саклауны һәркем өчен әхлакый бурычка әверелдерергә кирәк. Бу изге эшкә карата беркем дә битараф калмаска, табигатьне саклау кичекмәстән бөтенхалык ихтыяҗына әверелергә тиеш. Бары тик шулай иткәндә генә без җир-анабыздан рәхим-шәфкать көтә алачакбыз.

Без табигатькә ел саен 25 — 30 миллиард сумлык зыян китерәбез икән. Әмма тирә-як мохитне торгызуга, савыктыруга, агымдагы бишьеллыкта нибары 15 миллиард сум гына тотканбыз. Америкада исә табигатьне саклауга, торгызуга һәр елны 80 миллиард доллар тотыла.

Галимнәребез әйтүенә караганда, тирә-як мохиткә зыян китерүнең иң зурысы табигый «байлыкларыбызның беркемнеке дә булмавында» икән. Әгәр промышленность предприятиеләре, җир, су, урман, минераль ресурслардан файдаланган өчен, түләргә тиеш булсалар, халык байлыгын шул тикле кадерсезләмәсләр иде. Ул министрлыклардан алынган керем табигатьне саклауга, аны яңартуга тотылыр иде, диләр галимнәр.

Икенчедән, милли доходыбызның бер генә процентын файдаланган тәкъдирдә дә, тирә-як мохит күзгә күренеп тернәкләнер, савыгыр иде, диләр алар. Ә инде милли доходның өч яки биш процентын тотканда, табигатьне саклауда аеруча җитди уңышларга ирешергә мөмкин икән. Хәзергә әле соң түгел. Бераздан исә, суның кайнарлануын сизмичә, һәлак булган бака хәлендә калуыбыз бар...

* * *

Кама Аланына килеп төшкән кешене искитмәле манзара каршылый. Алда таң кебек якты, җыр кебек моңлы булып борынгы Кама-Чулман ага. Икенче якта нечкә зәвык белән

салынган яңа шәһәр үсә. Кама Аланы. Арырак илебезнең иң зур атом электр станциясе төзелә.

Монда килгән саен мине таный алмаслык үзгәрешләр хәйран калдыра. Яңалык сулышын, заман колачын тоясың.

Соңгы тапкырында без монда АЭС төзелешенә шефлык итүче «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, язучыларның Чаллы бүлеге җаваплы секретаре Г. Кашапов, шагыйрә Э. Шәрифуллина, журналист Х. Бәдретдинов һәм Чувашиядән килгән бер төркем язучылар белән бергә булдык.

Ул очрашу — онытылмаслык хатирә. Анда, тантаналы шартларда, миңа, Эльмира Шәрифуллина һәм Хәмзә Бәдретдиновка Татарстан атом электр станциясе төзүчеләре премиясе лауреаты дигән мактау грамотасы һәм акчалата премия бирелде.

Бу юлы баруымда да миңа бик әһәмиятле яңалык тапшырдылар: шул көнне, көндезге аштан соң, «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең Татарстан атом электр станциясен төзү идарәсе начальнигы Михаил Исаакович Вайнер белән очрашу булачак, аңа Мәскәүдән килгән журналистлар да катнашачак икән.

Бу хәбәр күңелемне күтәреп җибәрде. Тулай торак буфетында аннан-моннан капкалап алдым да, урамга чыгып киттем. Кай якка гына күз салма, берсеннән-берсе матур ташпулатлар. Тау сыртларына елышып утырган үзенчәлекле архитектура белән салынган йортлар киртләчләнеп, үзәнлеккә таба төшә... Монда бер генә игезәк йортны да күрмәссең. Ак, кызгылт, сары, зәңгәр төсләргә буялган диварлар, өстән караганда, шау чәчәкле аланны хәтерләтә. Бу йортларны Ленин орденлы «Камгэсэнергострой»-ның Рәис Сәләхов җитәкчелегендәге 12 нче төзү-монтаж идарәсе коллективы сала...

...Юк, ТатАЭС төзелеше начальнигы иптәш М. И. Вайнер белән очрашу җанда канәгатьләнү хисе тудырмады. Ул бик рәсми төстә башлады. Муенына берьюлы өч-дүрт фотоаппарат таккан берәү, беренче сүз алып, Михаил Исааковичны зур бүләккә лаек булуы белән тәбрикләде. Иптәш Вайнерга шул көннәрдә генә 50 яшь тулган һәм аңа КПСС Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау Грамотасы бирелгән иде.

Михаил Исаакович, кереш сүз ясап, төзелеш начальнигының АЭСта тоткан урыны, аның төп вазифалары турында сөйләде. Моң-зары да җитәрлек булып чыкты начальник кешенең . Иң теңкәгә тигәне, әлеге дә баягы, кадрлар җитмәү икән:

— Бигрәк тә инженер-техник работникларга кытлык зур, — диде. — Мастер вазифасын да еш кына очракларда звено җитәкчеләре башкара. Төзелеш материаллары, кирәкле техника белән тәэмин итү мәсьәләсе дә тиешле югарылыкка куелмаган. Торак чиратын тизләтәсе, мәктәпләр, балалар бакчалары төзүнең темпын бермә-бер арттырасы бар. Тимер юл сузу эше дә төгәлләнмәгән...

Әкренләп төп мәсьәләгә күчтек. Сүз ТатАЭС турында бара. Әмма сораулар бер дә мин теләгәннәр түгел, бик гомумиләр, бары тик сүз югында сүз булсын дип бирелгәнгә охшаганнар.

— ТатАЭСның беренче энергоблогы кайчанрак эшли башлаячак?

Михаил Исаакович Вайнер, өзеп, төгәл җавап бирергә ашыкмады. Беренче реактор 1990 елда ук электр энергиясе бирә башларга тиеш булган. Әмма Чернобыльдәге вакыйгалардан соң проектка күп төрле үзгәрешләр кертелгән, сроклар кичектерелгән.

— Һәрхәлдә, 1991 елның беренче яртысында беренче энергоблок файдалануга тапшырылыр, дип торабыз. Чернобыль фаҗигасе барыбызның да күзен ачты. Шунлыктан һәрбер эшне зур җаваплылык тоеп, энә күзеннән үткәреп башкарабыз. Безнең АЭС — моңарчы мин белгән барлык станцияләр арасында иң ышанычлысы. Мин бу турында бернинди икеләнүсез әйтә алам, — диде ул.

Әлеге сүзләрдән соң төзелеш начальнигы очрашуны түгәрәкләү ягын карады.

— АЭСның техник үзенчәлекләре, нечкәлекләре турында мәгълүматлар аласыгыз килсә, төзелешнең баш инженеры Анатолий Прохоренкога мөрәҗәгать итәрсез. Станцияне ул биш бармагы кебек белә...

Юк, күңелем булмады минем әлеге очрашудан. Начальникның Чернобыль тикле Чернобыль турында, ничектер, бик җиңел гәп сатуы бөтенләй аптырашта калдырды. Ә бит Чернобыль турындагы вакыйгалар бөтен дөньяны аякка бастырды, авария турындагы беренче хәбәрләр тамырларда кан катарлык иде. Европа илләрендә паника купты.

Аптырашта калдырганы шул: бүгенге көнгә кадәр әле без Чернобыль турында чын хакыйкатьне белеп бетерә алганыбыз юк. «МАГАТЭ бюллетене»ндә шактый тулы мәгълүматлар дөнья күрде, дип язып чыктылар чыгуын. Әмма ул бюллетень белән кайда танышасың? Чернобыль янгынын сүндерүдә катнашкан, соңыннан Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Леонид Телятников язмаларыннан күренгәнчә, без Чернобыльдәге кебек аварияга бөтенләй әзер булмаганбыз. «Радиоактив нурлардан саклый торган киемнәр дә юк иде. Дозиметрик үлчәүләрнең камил булмавы турында әйтеп дә торасы юк», дип язып чыкты янгын сүндерүче каһарман.

Академик Валерий Алексеевич Легасов Чернобыль авариясен иң хәтәр, иң зур вулканнар ату, Помпейның һәлак булуы белән чагыштыра, кешелек тарихына мәңгегә кереп калачак фаҗига дип атый. Авариянең сәбәпләрен дә яшерми: уннарча һәм уннарча еллар буена дәвам иткән җавапсызлыкның, хуҗалык итә белмәвебезнең аянычлы нәтиҗәсе бу, ди. Академик В. А. Легасовның әлеге язмалары бары тик ул, үз-үзенә кул салып, һәлак булгач кына, дөнья күрде. («Правда» газетасының 1988 ел, 20 май саны).

Төзелеш начальнигы Вайнерның исә атом электр станциясенең хәтәр якларын телгә алмавы мине һич канәгатьләндермәде. Кама Аланындагы АЭС төзелеше турында бөтен газета-журналлар, радио-телевидение шау-гөр килә. Төзелешне дәвам итү-итмәү турында бәхәснең туктаганы юк. Әнә, журналистка Ф. Хуҗахмәтова «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан мәкаләсен, бер дә икеләнеп тормаган: «Атом станциясе кирәкме?» дип атаган һәм мәсьәләне кабыргасы белән куйган. «Барыбер куркыныч, барыбер зарарлы инде, тамырларыбызны корытыр төсле», дип, шик белдерә автор.

Хәйретдиновлар гаиләсенең басылган хаты да шомлы сүзләр белән тулы: «...Туган ягыбыз яңа куркынычка дучар булды: Кама буенда АЭС төзеп яталар... Чернобыль фаҗигасе барыбызга да мәгълүм булгач, моның куркыныч икәнлеген аңладык. Ә бит хәзер эшләп килгән АЭСларны башка максатка хезмәт итәрлек итеп үзгәртеп коралар, төзелеп килгәннәрен туктаталар, сүтәләр. Татарстан АЭСы — татар милләтенең үзәгенә салынган бомба булмасмы? Намуслы, кыю кешеләр сүзләрен әйтеп калсын иде».

Бәлки югарыда телгә алынган авторлар юкка борчыла, юкка хафалана торганнардыр? Алай димәс идем. Менә, Кама Аланы янында төзелеп ята торган АЭС турында, кыска гына бер

ИНФОРМАЦИЯ:...**Татарстан атом станциясенең бер реакторы (ә алар алтау) тәүлек саен 5 миллион (!) куб. метр су сарыф итәчәк. Бу — Казан шәһәре бер тәүлек куллана торган судан 7 тапкыр күбрәк. АЭС янындагы сулыкның температурасы 5-6 градуска күтәреләчәк.**

**АЭСларның абсолют ышанычлылыгы гарантияләнмәгән. Дөньяда ике ел ярым саен бер реакторда зур авария булу куркынычы бар. («Литературная газета», 19 август, 1987).»**

...Инде нишләп карарга? Бу юлы да сәфәрем уңмас микәнни? Әмма коры килеп буш кайтасы килми иде. Үч иткән кебек, язучыларның, журналистларның якын дусты (дөресрәге — әдәбият дусты), ТатАЭСны төзү идарәсенең партком секретаре Рифкат Кәшифович Кәтиев тә өйдә юк чак.

Узган килүемдә ул миңа бөтен төзелеш мәйданын күрсәтеп йөргән иде. АЭС өчен, дөньяның төрле почмагыннан кайтарылган җиһазлар, мең төрле машиналар, контейнерлар белән шыплап тутырылган причалда да, махсус бетон хәзерләү участогында да булган идек.

Татарстан атом электр станциясен төзүдә утыздан артык оешма катнаша. Коллективлар арасында «Иң яхшы бригада» исемен яулап алу өчен ярыш бара. Әлеге ярышта «Волгоэнергомонтаж» трестының Түбән Камадагы монтажлау идарәсеннән Фәнәви Нәбиев бригадасы беренче урынга чыккан. Аңа ТатАЭСның ярыш арбитры булган «Социалистик Татарстан» газетасының күчмә вымпелы тапшырылган.

Фәнәви белән дә таныштык. Биографиясе дә, хезмәт юлы да кызыклы, гыйбрәтле. Бригадир Нәбиев әлеге идарәдә 1971 елдан бирле эшли икән инде. Зәй гидроэлектростанциясен, Чаллыдагы һәм Түбән Камадагы җылылык электр үзәкләрен салышкан. Татарстан атом электр станциясе төзелешенә дә беренче десант составында килә.

Коллективта — могҗизалар тудырырга ашкынып торган яшьләр. Баш очларына гына: «Комсомолецлар һәм яшьләр! Төзелештә корчагиннарча эшлик!» дигән плакат эленгән. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән, сиксәнләп милләт вәкилен бер гаилә иткән АЭС төзелешендә комсомол-яшьләр чын мәгънәсендә фидакарьлек күрсәтәләр. Идарә участогының өлкән прорабы иптәш И. Балаев та коллективны мактап торды:

— Соңгы вакытларда бездә эш фронты киңәя, темплар кызулана бара, — диде. — Әмма, тиз эшләсәк тә, бездә кабалану, кайбер урыннардагы кебек теләсә ничек план артыннан куу юк. Безнең өчен алар — чит нәрсәләр. Бу һәркемгә дә ачык аңлашыладыр. Без башкарган эшнең таләпләре үзгә: сыйфат, сыйфат һәм тагын бер тапкыр сыйфат! Нәбиев бригадасында бер генә тапкыр да техник таләпләрдән тайпылу очрагына юл куелмады. Бездә контроль нык, төзүчеләр үзләре дә икеләтә-өчләтә җаваплылык тоеп эшлиләр. Башкарылган эшне тикшергәндә рентген һәм тагын башка төрле төгәл прибор-аппаратлар кулланыла... Ни хикмәттер, кирәк кадәрле материал тупланса да, ул чакта мин очерк яза алмадым. Күңелем тартмады, кулым күтәрелмәде. ТатАЭС турында тискәре фикерләр: «Бездә дә Чернобыль вакыйгасы кабатланмасмы?» дигән шөбһә мине тәмам үзенә буйсындырып өлгергән иде.

Инде бу юлы да буш кул белән кайтып китеп булмый бит! Һәм мин кабат, төзелеш мәйданына бару өчен, автобуска утырдым. Шәһәр артта калды. Электр станциясен төзү идарәсе — шәһәр һәм төзелеп яткан ТатАЭС белән ике арада. Ниһаять, тукталыш.

Әле иртәнге җиделәр тирәсе генә булуга карамастан, идарә каршындагы бакча буена, төрле маркалы җиңел автомобильләр килеп бөялгән.

Икенче катка күтәрелдем. Кабул итү бүлмәсе ачык. Кердем. Сул якта төзелеш начальнигы Вайнер кабинеты. Каршы ишектә: «ТатАЭС төзелешенең баш инженеры Анатолий Дмитриевич Прохоренко» дигән язу эленгән. Секретарь-машинистка: «Гафу итегез, Сезгә кем кирәк?» — дип сорады.

— Анатолий Дмитриевичны күрергә иде!

— Йомышыгыз нидән гыйбарәт?

— Мин Казаннан. Сезгә шефлык итүче «Казан утлары» журналыннан...

Күрәм, сылу кыз бер дә: рәхим итегез! дип, алдымда ишекне ачарга җыенмый. Ахыр чиктә мин дә, соңгы «мөмкинлек»тән файдаланырга булдым.

— Әгәр дә ул, кем, дип сораса, әйтегез: ТатАЭС төзелеше премиясе лауреаты, язучы Хәсәнов диегез!

— Хәзер аңарда — планерка. Сигезләрсез бушамаячак.

— Мин көтәрмен...

Вакыт бик акрын уза сыман. Кабинет ягына колак салам. Сөйләшүләре шау-шусыз, гаугасыз бара. Кабинет ишеге ачылып китте. Шау-гөр килеп, төркем-төркем булып, кешеләр чыга башлады. Берсеннән-берсе чибәр, зур төзелешләрдә чыныгу үткән инженер-техниклар, производство командирлары. Күпчелеге яшьләр, карап сокланып туймаслыклар!

Күп тә үтмәде, ачык йөзле секретарь кыз, ачык ишек ягына ишарә ясап:

— Рәхим итегез! — диде.

Айлар буе күңелдә йөргән сорауларым да онытылып киткән сыман булды. Каушап югалып калуымны сиздермәскә тырышып эчкә уздым.

Анатолий Дмитриевич, мине күрү белән, күптәнге танышын каршылагандай дустанә елмаеп, урыныннан күтәрелде, кул биреп күреште. Җыйнак гәүдәле, җиңел сөякле, ифрат та ачык йөзле кеше икән.

Миңа урын күрсәтте дә, «тыңлыйм сезне», дигәндәй, каршыма күчте. Сүзне гафу үтенүдән башладым. Гадәттә йомышларыбызны төзелешнең партком секретаре, язучыларның якын дусты, Рифкат Кәтиев аша йөртүебезне, әмма аның өйдә булмавы аркасында, монда килүемне әйттем.

— Әйе, иптәш Кәтиев командировкада, — дип элеп алды баш инженер. — Башкортстан АЭСы төзелешендә.

Вакытның бик тә чамалы булуын исәпкә алып, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым: ТатАЭС турында, аның ифрат куркыныч афәт белән янавы, кешеләрне хафага салуы турында әйттем. Минекенә охшаш сүзләрне беренче тапкыр гына ишетмәве әллә каян сизелеп тора. Ул болай башлап китте:

— Минемчә, мәсьәләгә реаль караш җитенкерәми, эмоциягә күбрәк биреләбез, — диде. — Сүз дә юк, әйләнә-тирә мохитне саклау, бүгенге көндә биологик проблема гына булып калмыйча экономик, социаль, политик проблемага әверелде. — Инженерның йөзендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю чагылып киткәндәй булды.— Бер генә минутка, илебезне дип әйтмим, бары тик бер шәһәрне генә электр энергиясез калдырып карагыз.— Ул кабат җитдиләнде. — Илебез энергия дефициты кичерә. Бу хәл халыкның тормыш дәрәҗәсе күтәрелгән саен үзен күбрәк сиздерә. Каян алырга тиеш соң без кирәк кадәр электр энергиясен? Энергетиканы табигатьтән аерып булмый. Дөрес, тирә-як мохиткә зыян китерми торган (җил, кояш, диңгез-океан дулкыннарының хәрәкәте) энергия чыганаклары да бар. Әмма алар гына безнең проблемаларны хәл итә алмый. Энергиянең башка төр чыганакларына күз салыйк. Безнең ил дөньяда иң күп ташкүмер яндыручылардан санала. ТЭЦларның экологиягә ни дәрәҗәдә зыян салуы турында әйтеп тормыйм, бу һәркемгә билгеле. Ташкүмер төтене-сөременнән кислоталы яңгырлар ява. Кара диңгездә, Балтик буйларында су керә алмыйча кайталар.

Баш инженер бераз сулу алып торды да дәвам итте:

— ГЭСлар турында әйтим: гидроэнергетиклар үзләрен, иң чиста промышленность тармагы, дип мактарга яраталар. Чынбарлыкта табигатькә алар китергән зыян санап бетергесез. Гидроэнергетика суны «үтерә», суның үзен-үзе чистарту сәләтен киметә, елгадагы планктонны бетерә, шуның нәтиҗәсе буларак балык һәлак була, миллионлаган гектар уңдырышлы җирләр су астында кала.

Анатолий Дмитриевич авыр сулап куйды:

— Кешеләр аңласын иде: ТЭЦ һәм ГЭСлар белән чагыштырганда, АЭСлар иң чиста, иң җыйнак, иң отышлы станцияләрдән санала.

Әңгәмәбезгә кискен борылыш ясап, СССР Атом энергетикасы буенча Дәүләт комитеты председателе А. М. Петросьянцның: «АЭС зонасы халык күп яши торган урыннардан, ким дигәндә, 50 километр ераклыкта булырга тиеш», — дигән сүзләрен искә төшердем.

— Ә безнең булачак ТатАЭС янына Чистай, Түбән Кама, Мамадыш, Чаллы, Әлмәт, Алабуга, Зәй шәһәрләре урнашкан. Борынгы Кама-Чулманыбыз...

Баш инженер елмайды һәм минем сүзне бүлде.

— Шуңа күрә дә без, шик тудырмаслык, куркынычсызлыгы гарантияләнгән реакторлар булдыру өчен тырышабыз...

Академик Вернадскийның тууына 125 ел тулу уңае белән үткәрелгән Бөтенсоюз семинарында атом энергетикасы үсеше планнарын кабат карау кирәклегенә басым ясалган иде. Нормаль эшләгән вакытта да АЭС тулы бер регионның климатын үзгәртерлек җылылык бүлеп чыгаруы, радиация фоны югары күтәрелүе һәм атмосферада инерт газларның котылгысыз артуы турында әйтелгән иде ул мәкаләдә.

— Чыңгыз Айтматов инициативасы белән үткәрелгән «Ыссык күл» форумында катнашкан япон язучысы Нома АЭСларны шартларга тиешле потенциаль атом бомбасы дип атаган иде, — дидем. — Анда атом радиациясе астында калган кешеләрнең балаларына, балаларының балаларына гаилә булу тыела икән, чөнки нәсел черек.

Баш инженер миңа кушылып дәвам итте:

— Ә бер акыллы башның күрәзәлегенә караганда, АЭСлар булган регионда яшәүчеләр үзләрен үлемгә дучар ителгән санарга тиешләр икән. Әле бит табигатьнең «холыксызлануы»да бар. Англиянең бер АЭСында бик әһәмиятле кабельне яшен суга. Әле дә ярый, сакта янгын сүндерүче роботлар торган. Алар янгынны, күз ачып йомганчы, сүндереп, афәтне булдырмыйча калалар.

— Ә ник?.. — дидем мин, бик белдекле кыяфәт белән. — БМОның табигый бәла-казадан зыян күрүчеләргә ярдәм итү идарәсе мәгълүматларына караганда, соңгы биш елда гына да дөньяда 444 тапкыр табигатьнең «холыксызлануы», ягъни җир тетрәүләр, гарасатлар, су басулар, вулкан ату кебек бәла-казалар булган.

Анатолий Дмитриевич шактый ук мәзәк кеше булып чыкты. Бу юлы инде ул чын күңелдән кеткелдәп көлде.

— Һәрбер бәхетсезлектән курка калсаң, фән-техника прогрессына бөтенләй кул селтәргә туры киләчәк. Безне күп куркыттылар инде, ул-бу килеп чыкмагае дип, аяк-кулларыбызга тышау салдылар. Нәтиҗәсе күз алдында, шактый артта сөйрәләбез. Мисалга шул ук генетика белән кибернетиканы китерү дә җитәдер? — Прохоренко чак кына көлемсерәгән бер халәттә дәвам итте. — Төрле шикчел күрәзәчеләр карашынча, безнең планетада күптән инде биологик катастрофа булырга тиеш иде. Күсе-тычканнар һәм кеше өчен ифрат та куркыныч бактерияләр генә калырга тиеш иде. Юк, күңел әлеге фаҗигаләрне, мәхшәр көннәрен кабул итә алмый...

Тагын пауза. Бу юлы Анатолий Дмитриевич үзе сорау бирде.

— Сезгә Медоузның «Үсеш чиге» дигән китабын укырга туры килмәдеме? Бик кызык әсәр. Авторның әлеге китабында: 2000—2010 елларда җир йөзеннән кеше заты юк булачак, дигән сүзләр бар. Ул: «Биосфера бетә, тормыш бетә, туктагыз! Акылыгызга килегез!..» дип, кисәтә. Аңар карап фән-техника революциясе туктамады, һаман алга бара, дөньяда атом электр станцияләре төзү дә дәвам итә...

ИНФОРМАЦИЯ. **Узган ел бөтен дөньяда 22 атом электр станциясе сафка керде. Бер үк вакытта Болгариядә, Һиндстан, Кытай һәм Японияда тагын 9 АЭС төзелә башлады. МАГАТЭның докладында шул хакта хәбәр ителә: 1987 елның азагында бөтен дөньяда 417 атом электр станциясе эшли иде, электр энергиясе җитештерүдә аларның тоткан урыны 16 проценттан күбрәк тәшкил итте. Ел дәвамында АЭСларның гомуми куәте 8 процентка диярлек артты. Докладта әйтелгәнчә, Чернобыль авариясеннән алынган сабак «атом-төш иминлеге мәсьәләләрендә хәбәрдарлыкны шактый киңәйтте». МАГАТЭда член булып торучы дәүләтләрнең күпчелеге атом энергетикасына тугрылыгын раслады.**

— Узган юлыбызга реаль карарга, хаталарга объектив бәя бирергә һәм алардан гыйбрәтле сабак алырга кирәк. — Баш инженерның тавышы, торган саен, ныгый. — Бүгенге көндә илебездә 40 атом реакторы эшләп тора. Аларның куәте 23 миллион киловаттка тиң. Якын елларда тагын уннап АЭС сафка басачак...

— Димәк, яңа афәтләр ихтималы да арта? — дидем.

— Җавапсызлык хөкем сөрсә, күңелсез хәлләрнең теләсә кайсы тармакта килеп чыгуы бик мөмкин. Мисалга транспортны гына алыйк. Ни булды безнең тимер юлларыбызга? Самолетларга? Атлаган саен — һәлакәт. Сәбәбе бер: әле һаман да экономика һәм экология, җәмгыять һәм табигать арасында камил мөнәсәбәт урнаштыра алганыбыз юк. Соңгы елларда без бөтенләй җаваплылык сизми башладык, битарафлыкка бирелдек. Чернобыль фаҗигасе дә эксплуатацияләү персоналының техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен тупас рәвештә бозуы аркасында килеп чыккан. Хәзер инде бу беркем өчен дә сер түгел. Әгәр дә бездә хәзергедәй хәбәрдарлык, ачыктан-ачык дискуссияләр алып барырга яраган булса, һич икеләнүсез әйтә алам, 1986 елгы бу афәтне кичермәгән булыр идек. Без хәзер шундый фаҗигаләрнең кабатланмавы өчен тырышабыз. Станциянең проекты өр-яңадан карап чыгылды, җитди үзгәрешләр кертелде. Куркынычсызлыкка юнәлдерелгән бик күп чаралар өстәлде.

— Анатолий Дмитриевич, әгәр дә мөмкин булса, шул чараларның берәрсе турында тәфсиллебрәк сөйләгезче!

— Аңлашылырмы икән? Бик тә үзенчәлекле, тоташтан техник терминнарга бәйле тармак бит. Мәсәлән, чылбырлы реакцияне киметү ысулы үзгәртелде. Һәрбер реакторның эшләвен күзәтү өчен махсус диагностик җайланмалар кую күздә тотыла. Җылылыкны аеру системасының проекты да өр-яңадан каралды...

Аңлап бетермәдем, әлбәттә. Шулай да сер бирде юк, сорау артыннан сорау яудырам:

— Анатолий Дмитриевич, бары тик безнең ТатАЭСка гына хас яңалык бармы?

— Андыйлары да бар. Безнең АЭСта, илебездә беренче тапкыр буларак, радиацияне томалау чарасы күрелә. Без аны үзебезчә «Блок-88» дип атыйбыз.

— Ниндирәк вазифа үтиячәк ул, «блок»?

— Әйткәнемчә, көтелмәгән ситуация була-нитә калса, әлеге «Блок-88», автоматик рәвештә, реакторны томалап куячак.

Инженер сөйли, ә мин әлеге «Блок-88»не күз алдыма китерергә чамалыйм. Ул бинаһая зур гөмбәзле калкан сыман булып күз алдыма килә. Бәла-каза була-нитә калса, әлеге калкан өстән төшә дә, реакторны, тирә-юньгә радиация нурлары чыгармаслык итеп, томалый да куя...

— Ә реактор янында эшчеләр, ягъни операторлар булса?

— Атом реакторлары янында кешеләр булмый.

— «Блок-88»ләр кыйммәткә төшәчәкләрме?

— Кеше гомереннән дә кыйммәт түгел.

— Шулай да?

Минем төпченүем Анатолий Дмитриевичка мәзәк булып тоелды.

— Йөзәр миллионга төшәчәк дисәм, канәгатьләнәсезме?

Аның сүзне шулай уен-көлкегә борып җибәрүеннән файдаланып тагын сорау бирдем.

— Гафу итегез, Анатолий Дмитриевич, сез әйткән «Блок-88»не һич кенә дә күз алдыма китерә алмыйм. Кеше сәламәтлеге өчен иң яман радиацияне дә томалый алгач, димәк ул Чернобыльнең дүртенче реакторын «томалаган» саркофаг ролен үтәячәк?..

— Гадиләштереп әйтсәк, шулай дияргә дә мөмкин.

Әңгәмәне әкренләп түгәрәкләр вакыт та җитте. Мин сүзне кабат хезмәт иясләреннән килгән хафалы хат-хәбәрләргә күчердем. Арада ТатАЭС төзүне туктату турындагы язмалар да барлыгын искә төшерүне кирәк таптым.

Бу хәбәрне дә тыныч каршылады Анатолий Дмитриевич:

— Узган атнада Түбән Камага, партиянең шәһәр комитетына чакырганнар иде. Нәкъ шул турыда зур киңәшмә булды. Кабатлап әйтәм: бездә тормышка реалистик караш җитенкерәми. Кама Аланындагы АЭСны туктату — фән-техника прогрессыннан баш тарту булыр иде. Атом энергетикасына алмашка башка төр энергия чыганагы тапмыйча торып, кешелек атом-төш реакторларын отставкага чыгара алмаячак...

— Ләкин АЭСлар төзүне туктатулар турында әледән-әле ишетеп торабыз.

— Әмма бөтен дөнья күләмендә төзелешләр дә дәвам итә.

— Анатолий Дмитриевич, зинһар дип сорыйм, гафу итә күрегез. Тагын бер сорау бирергә мөмкинме? Соңгысы итеп...

— Рәхим итегез!

— Тик, кулыгызны күкрәгегезгә куеп, дөресен әйтегез...

— Тырышырмын.

— Әйтегез әле, әлеге АЭСка урын сайлауны, Чернобыль фаҗигасеннән соң кушсалар, сез бу регионда тукталыр идегезме?

Анатолий Дмитриевичның елмаюы бу юлы шактый сүрән иде.

— Техник яктан караганда, АЭСның урыны искитмәле, идеаль. Янында ук зур сулык. Сулык та, нәкъ проект таләп иткәнчә, Камадан табигый ярымутрау белән аерылган. Ландшафт та менә дигән, нәкъ АЭС таләп иткәнчә!

Кечкенә генә паузадан соң сүзен түгәрәкләп, әйтте:

— Хәзер без бу турыда уйларга, баш ватарга соң дип беләбез. Чыгымнар миллионнар белән генә исәпләнми... Хәзер сүзне АЭСны тизрәк сафка бастыру, аның куркынычсызлык ягын ныгыту турында алып бару отышлырак... Перспектива белән яшәргә кирәк. Мин бернәрсәгә ышанам: безнең киләчәгебез дә, Җир йөзендә исән-имин калуыбыз да, тулысынча фән-техника прогрессы кулында. Тиздән, бик тиздән без, грандиоз ачышларның шаһиты булачакбыз. ТЭЦлар, ГЭСлар, АЭСлар безнең өчен музей экспонатлары гына булып калачак... Дөнья галимнәре кешелекне экологик катастрофадан, энергетика кытлыгыннан мәңгегә котылдырачак. Хәзер атом-төш реакторы булдыру буенча тәҗрибәләр ясала. Бу эш белән СССР, АКШ, Япония һәм Көнбатыш Европа галимнәре шөгыльләнә. Төш изотопы синтезы белән водород яралгысын кушудан иксез-чиксез энергия аерылып чыгуы балаларга да сер түгел. Төп чыганагы су һәм кояш булган электр станцияләре алмашка киләчәк.

— Булырмы икән?

— Хәзер сүз аларның булу-булмавы турында түгел, АКШның атом-төш энергия

комиссиясе директоры Рой В. Гульдча әйтсәк, аларны кайчан файдалануга тапшыру турында гына барырга мөмкин...

Яшерен-батырын түгел, әлеге сөйләшү оптимистик рухта тәгәлләнсә дә, шом тулы җаным бөтенләй үк тынычланып җитә алмады.

Юк, җаным тынычлык белми. Тирә-юнемә күз салам да, тагын хәйранга калам. Чыннан да, нәрсә булды безгә? Нигә әле без кендегебез белән береккән җир-анабызга, бердәнберебезгә карата шул кадәрле битараф? Кемнән йоккан һәм каян килгән безгә шул тиклем ваемсызлык? Һәрхәлдә бу ваемсызлыкны, гамьсезлекне, бары тик торгынлык елларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас. Моның сәбәпләрен, тамырларын каяндыр тирәннәнрәк эзләргә кирәктер. Бәлки, балаларыбызны «череп бай булуыбыз» рухында тәрбияләп үстерүебез чиредер? Безнең ил чамасыз бай, аның хәзинәләре бетмәс-төнкәнмәс дигән «оетка» салуыбыз гаепледер? Яшь буынны илнең чын, кайгыртучан хуҗасы булырга, җир-ананың кадерен белергә өйрәтмәдек. Табигатьне, әйләнә-тирә мохитне саклау турында күп сөйләдәк һәм сөйлибез, яздык һәм язабыз, әмма эшләребез киресен күрсәтә. Сүз эштән аерылды. Кеше һәм табигать — бербөтен. Бу мөнәсәбәтне бала һәм ана мөнәсәбәте белән чагыштырырга мөмкин. Шул хакыйкатькә күз йомдык.

«Җир бер генә ул!» Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Халыкара хезмәттәшлекнең девизы шундый. Җир бер генә. Ул социализмныкы яки капитализмныкы була алмый. Җир — бөтенхалык байлыгы. Юрий Гагарин сүзләре белән әйтсәк, «Гүзәл зәңгәр планетабыз»ның үзе исә исәпсез-хисапсыз сугышлар белән яраланып, куәтле техника ярдәмендә акылга сыймаслык экспериментлардан теткәләнеп-ермачланып беткән, карар җире калмаган. Планетабызны, кан тамырлары сыман тукландырып, яшәү сүле белән тәэмин итеп торучы елга-сулыкларыбыз химик матдәләр белән агулана. Урманнарыбыз күзгә күренеп кими, агачлар агулы корым-сөремгә чыдаша алмыйча, төптә килеш корый, күкрәк тутырып суларлык һава кими бара.

«Бүген табигать бетерелсә, иртәгә — без» диярлек сәбәпләр арта тора. Моның өчен дөнья океанының пычрануын, климатның үзгәрүен, «озон ертыгы» барлыкка килүен искә төшерү дә бик җиткән. Бу төшенчә берничә ел гына элек телгә керде. Баксаң, «Җирдәге тормыш чыганагы, рәхимле-шәфкатьле» Кояшыбыз бик мәрхәмәтсез дә була ала икән ич. Галимнәрнең әйтүенчә, кояшның бик куәтле, тереклек өчен куркыныч ультрамиләүшә нурланышы атмосфераның озон катламында тоткарланып кала икән. Җентекләп өйрәнү, ачыклау-тикшеренүләрдән соң галимнәр бик тә хәвефле, бик тә күңелсез ачышка юлыгалар. Антарктида өстендә «озон ертыгы» барлыгы мәгълүм булган. Фараз итүләренә караганда, торган саен зурайганнан-зурая барган әлеге «ертыклар» кеше «эшчәнлеге» белән барлыкка килгән икән ләбаса. Бөтен тереклекне космик радиация һәлакәтеннән саклый торган атмосфера катламының «ертылуы» планетабызга исәпсез-хисапсыз бәлаказалар китерәчәк, дип фараз кылалар галимнәр.

Кешелеккә тыныч кына яшәргә язмагандыр, күрәсең. Халык телендә XX гасыр афәте дип кергән СПИД эпидемиясе үзе генә ни тора?! ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, ул инде 120 дән артык илгә таралырга өлгергән. Әлеге яман чир белән көрәшүче япон докторы Кен Того, күптән түгел генә болай дип язып чыкты: «Японниядә СПИД Хиросимага караганда яманрак булачак». АКШ хирургы К. Э. Куп: «Әгәр дә тиз арада СПИДка каршы вакцина табылмаса, 2000 нче елга дөньяда йөз миллионнан артык кеше һәлак булачак», — дип белдерде. Инде бездә дә СПИДтан үлүчеләр бар... Барысы да табигать белән санашмау бәласе.

...Язмамда кара буяулар артык куера башлады сыман. Ярамый. Ничек кенә булмасын, кеше якты өмет белән, алга карап яшәргә тиеш. Шагыйрь әйтмешли, дөнья матур, дөнья киң. Безгә төшенкелеккә бирелеп, башны түбән июн килешәме соң?! Илебездә революцион үзгәрешләр бара. Революцион дигән сүзгә аеруча басым ясап әйтәсе килә. Димәк, тормышыбызны тамырдан уңай якка үзгәртергә тиешбез. Бүтән артка таба чигенде юк!

Ышанычны җуймыйча, киләчәгебезгә якты, олуг өметләр белән атлыйк!

Мансур Вәлиев

# ТУКАЙ ЯШЕН УЗГАНДА...

Төп сүзебез яшьләр турында... Яшь прозаиклар, яшь шагыйрьләр иҗаты хакында. Һәм биредә алар тормышын, алар иҗатын үлчәү берәмлеге итеп Тукай гомере, Тукай иҗаты алыну да укучыны гаҗәпләндермәскә тиеш. Чөнки, барыбыз да бик яхшы белгәнчә: Тукай яше ул — егерме җиде яшь. Гади бер татар малае үзенең егерме җидесенә килеп җиткәндә инде «халык шагыйре» дип аталырдай биеклеккә күтәрелә! Яшьлекнең, һәм димәк шагыйрьлекнең дә, иң югары мәртәбәсенә ирешә. Егерме җиде яшендә ул үз халкының иң җитди, иң мөһим хисләрен чагылдыручы бер үтә сизгер һәм намуслы йөрәккә әверелә.

«Тукай мондый биеклеккә ничек күтәрелгән соң?» — дигән сорауга да җавапны ерактан эзлисе түгел. Галимнәребезнең һәм башка каләм ияләренең бөек шагыйрьгә багышланган күп санлы язмаларында без ул сорауга җавапны моңа кадәр дә күргән идек инде. Шагыйрьнең үз язмышы, шәхси язмышы аның туган халкы язмышына бик тә охшаш! Һәр икесендә — бихисап кыерсытылу, матди һәм рухи яктан гаять тә кысынкы тормышта яшәү. Һәр икесендә төрле яклап изелү.

Менә шушы хәл Тукайны башка бик күп талантлы каләм ияләреннән аерып куя. Аны кабатланмас үзенчәлеккә ия шәхес итә. Шагыйрьне халыкның тәмам үз улы итеп, исемен һәм иҗатын халыкның бәгъ рь түренә үк кертеп урнаштыра!

Кабатлап әйтик: болар барысы да бары тик егерме җиде яшькә кадәр генә дәвам иткән гомер юлындаирешелгән иҗади һәм рухи-әхлакый биеклекләр!

Әйе, Тукайда шулай.

Ә менә бүгенге көнгә килсәк? Безнең яшь иҗатчыларыбыз ни хәлдә яшиләр? Башта яшь прозаиклар иҗатын күздән кичерик.

## Яшь прозаиклар

Моңа кадәр матбугатта әлләни күренмәгән Вахит Имамов (хәер, безнең яшь прозаикларыбыз үз әсәрләре белән нинди генә басма органда еш күренә алсыннар соң?! Яшь язучыларыбызның үз журналлары — язган әсәрләре белән укучы алдында, халык каршында беренче имтихан тота, көч сыный торган мәйданнары моңа кадәр булмады бит) үткән 1988 елда Татарстан китап нәшриятында «Ир канаты» исемле беренче җыентыгын һәм шул ук үткән елда «Казан утлары» журналының 8 санында «Күке» исемле повестен бастырды. Күргәнебезчә, бу — безнең яшь язучыларыбызга бик сирәк эләгә торган бәхет. Шунлыктан аның иҗаты укучыбызның да махсус игътибарына лаек.

В. Имамовның беренче китабына кергән әсәрләре вакыт ягыннан алданрак язылганнар, биредә без дә аларга — китаптагы әсәрләргә — баштарак тукталыйк.

«Менә бүген дә, энесе Вәкил белән киленнең әреп-талашлары чамадан тыш ешаеп китүен чамалап, араларын бераз көйлим дип барган иде Сания. Ничек мәсхәрә иттеләр?! Сания үзенең алардан бәрелә-сугыла чыгып китүен генә хәтерли. Аннары юл буе, чит кешеләр алдында күз яшенә ирек бирмәс өчен, үзен көч белән тыеп кайтты. Өенә кайткач, туйганчы бер елап, күңелен бушатырга иде исәбе. Шуңа күрә, подъездга кергәч, квартирасы ишегенә кадәр ике-өч баскычны бер итеп чапты. Ишекне бәреп диярлек ачып керде дә, плащ-яулыкларын уңга-сулга ташлап, өстәл почмагына ауды. Ишек ябылмаган, күтәреп кайткан сумкалар юл өстендә авып калган иде. Саниянең аларда гаме юк, ник барганына үкенү бәгырен пычаксыз телгәли. Чыннан да, ни хаҗәтенә генә барасы итте шул Вәкилләргә? Анда аны сагынып көткән кеше бармы, күңе-

лен бәһали беләләрме? Олы башын кечә итеп, атлаган саен шул энесе янына барган була, барган саен күңелен яраларга җай табалар. Әллә соң табигать-ана аның башка туганнарына бәгырь бирмәгәнме, кеше хәтерен саклау дигән исәп-чамадан мәхрүм калдырганмы, ярабби?!»

Бу өзек язучының «Олапа» хикәясеннән алынды. Проза әсәрләре өчен күләм ягыннан бик аз булган менә шушы өлештә дә В. Имамов каләменең байтак кына сыйфатлары чагылып ала. Ул үз героинясы Саниянең кимсетелгән күңел халәтен нечкә тоя, психологик яктан төгәл аңлый. Үз урынындагы, күңел халәтенә туры килә торган сүзләр кулланып хикәяли. Һәр сүз, һәр җөмлә укучы күз алдында реаль кешене, чын тормыш күренешен китереп бастыруга булыша.

Хәзер инде яшь язучы игътибар иткән күренешнең эчтәлегенә, мәгънәсенә күз салыйк. Ул тормыш өчен зур мәсьәлә, мөһим нәрсә күтәрәме?

Әйе, В. Имамов бүгенге чынбарлыктагы көчле кешеләрнең бер тибын тотып алган. Аның хикәясендәге Сания кебекләр — алар үзләрен онытып, башкаларга ярдәмгә ашкынучылар. Алар изгелек кылуны, яхшылык эшләүне тормыш максаты иткән кешеләр!

Иҗатта табылган әнә шундый бәрәкәтле туфрак, җирлек хакында сөйләүче бүтән әсәрләр дә бар бу китапта. Андыйлардан «Тол хатыннар» исемлесе аеруча истә кала.

«Кифаяның, бар дөньясын онытып, мич артында сызгырышкан чикерткәләр тавышына колак сала-сала камыр изеп азапланган чагы иде. Шуңа урам якта җилкапка ачылуын сизмичәрәк калды...»

Биредә дә ипле агышлы һәм бер үк вакытта тыгыз мускуллы җөмләләр белән алып кереп китә безне автор хикәя эченә. Ә бераздан әлеге Кифаяның түгел, ә капка ачып кергән икенче берәүнең өйалдында үз-үзе белән сөйләшүе бирелә:

«— Дөньясына тел-теш тидерерлек түгел моның. Япа-ялгыз дими, хәтәр тырмаклашып ята бу. Бакчы өйалды сәкесенә. Тегө кайтканда гына иске иде, кай арада яңартып өлгергән. Ялгыз башына бу тыштагы сәке нигә инде? Әллә, әкәмәт, йортына өйдәш кертте микән?»

Күрәсезме — әсәрдә әле үзе пәйда булмаган килеш яңа персонаж безгә никадәр мәгълүмат биреп өлгерде! Беренче җөмләдән үк ике хатын арасындагы мөнәсәбәт тә ачылып китте (чөнки «моның» дип бер-берсен якын белгән кешеләр генә сөйләшә), Кифаяның тынгысызлыгы, тырышлыгы да күренде (яңа сәкеләр). Шулай ук керүченең бирегә еш кына кайтуы да беленде. Шәһәрдә яшәүче кеше психологиясе дә нечкә генә чагылып алды) «ялгыз кешегә бу тыштагы сәке нигә инде?»).

Тора-бара өйгә килеп кергән Фатыйманың Ижаудагы кызында яшәве һәм ничек яшәве ачыклана, аның авылга сагынып-җирсеп кайтуы билгеле була. Аннары хикәядә бу хатыннарның хәзер инде дөнья куйган ирләре күренеп китә...

Ләкин яшь авторның хикәясе шулай тыныч кына акса, аны әлләни мактарлык урын булмас иде. Алга таба ике тол хатын һич уйламаганда дигәндәй (буш яткан ихатаны нишләтү хакында сүз чыккач) әләгешеп китәләр. Һәм менә ул бәхәснең иң югары ноктасы:

«...Әле ярый уртада өстәл тора иде. Шуның ике ягында ике туган бөерләренә таянып бер-беренә зәһәр чәчтеләр:

— Аһ, әле син шулаймы? Минем әүлия Ихсаныма тел тидерәсеңме, иманың беткере?!».

Җылы гына башланып киткән хикәя бик тиз арада бүтән төс ала. Яшь авторның биредә дә вакыйгалар дилбегәсен әйбәт тотуын күрәбез. Аның күңеле күренешләрне тирәннән тоя, күзе төгәл күрә. Укучы автор каләменнән канәгать бара. Төрле характердагы вакыйга-күренешләрне шулай төгәллек белән, динамик халәттә сурәтли алу — бу инде яшь иҗатчының шактый ук киң диапозонда язачак каләм иясе булачагына ышандыра.

Хикәя ахырында тагын бер мөһим момент бар.

«Җилкапка аша чыгып барышлый, Фатыйма, артына борылып, ихатага иркенләп бер төкермәкче иде дә, ниятен болдыр ишегеннән карап торучы Кифаяның соңгы сүзе бүлде:

— Төкермә дим, имансыз, безнең ихатага. Икенче елга тагын кайтасың бар...»

Менә нинди чынлык! Көләрсең дә җыларсың да! Нәкъ тормыштагыча! Әйе, әле Фатыйма туган җирен сагынып тагын кайтачак. Әйбәт кенә сөйләшеп, гөрләшеп утырганда бу ике тол хатын тагын шулай, уйламаган җирдән генә ачуланышып китәчәк... һәм бу ызгыш икенче елга тагын онытылачак. Туган җирнең тартуы бу вак ызгышны күңелдән юачак, бетерәчәк.

Яшь язучы бүгенге тормышны, кешеләрне шактый әйбәт белә. Күренешләрнең зур әхлакый сабак, мәгънә бирердәйләренә генә игътибар итә. Аның «Җәза» хикәясендә дә җанны тетрәндererлек вакыйга һәм гыйбрәтле язмышлар тасвирлана. Бу

хикәядә чатнап торган характерлар бар, аларның көчле бәрелешләре бар. «Адашкан кош» белән «Соңгы йорт» та җитди хис-кичерешләргә корылган. Югарыда без күреп үткән һәм әле яңа гына исемнәрен атаган барлык хикәяләрдә дә заманның актуаль мәсьәләләре яши. Аларның укучы өчен төп кыйммәте дә әнә шунда — тирән, җитди эчтәлек булуда.

Ә яшь язучы иҗатының нинди «йомшак» яклары бар? Үз үсешенең хәзерге баскычында ул нәрсәләргә игътибар итәргә тиеш?

В. Имамов хикәяләрендә шактый еш очрый торган бер җитешсезлек — ул әлегә диалоглар остасы түгел. Аның геройлары шактый бер төсле сөйләшәләр. Яисә инде алар алынган бер тыныч кына көй белән бик озак, тормышта була алмаганча, артык күп сөйләп ташлыйлар.

«Ир канаты» повестындагы бер геройның ни рәвешле сөйләшүен карап үтик:« — Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына. Уйламаганда-көтмәгәндә килеп чыгуың шәп булды бит әле, малкай. Алайса үзебезнең бригадир Әхнәфтән ничә көннәр инде ялварып сорыйм, әрхәрәй генә бер трактор аламасы бирми. Аларның анда адым атлаган саен кампания. Башта язгы чәчүне бетерик диде, аны көттем...» Менә шул рәвешчә атка карап бик озак сөйләнә әлеге кеше.

Ә бит оста каләм ияләре үз геройларын озаграк сөйләтергә кирәк булган очракта моның бик әйбәт җаен табалар. Алар сүз арасында геройның үз-үзен ничек тотышын күрсәтеп алалар, аның ни рәвешле сөйләвен тасвир кылалар. Шулай итеп әсәрдә әлеге персонажның озак сөйләве дә сизелми, артык сыман тоелмый. Андый очракларда сүзләр белән хәрәкәт бергә үрелеп бара.

Бу китаптагы повесть хакында сүз чыккач, инде ул сүзне әйтеп тә бетерик. «Ир канаты» — яшь прозаикның уңышы түгел. Матур гына хикәяләр белән укучыны сөендергән В. Имамов әлеге повестенда түбәнрәк төшә. Дөресрәге, аңа зур гына күләмле бу әсәрне һәр яктан камил итеп эшләп бетерергә иҗади көч һәм тәҗрибә җитмәгән. Повесть шактый таркау, озын чыккан. Анда персонажлар бик күп, аларның берсе дә диярлек истә калмый. Шулай ук вакыйгалар җебен дә мавыктыргыч итеп үрә алмый әле яшь автор.

Беренче китап белән танышканнан соң күңелдә туган тагын бер тойгы — яшь язучы әсәрләренә яңалык җитми. Әйе, без югарыда мисалга китергән байтак кына хикәяләрдә тормыш өчен мөһим нәрсәләр сөйләнүгә, тирән генә эчтәлек алып килүенә карамастан — әле аларда В. Имамовны башкалардан аерып, өр-яңа биеклеккә күтәрә алырдай, аны өр-яңа һәм үзенчәлекле язучы итеп танытырдай зур һәм принципиаль яңалык сизелми. Әсәрләрдә карт кешеләрнең күплеге дә әнә шуның бер дәлиле. Ныклап тикшерә башласаң, аларның бик күбесенең безнең классик әдипләребез тарафыннан инде сурәтләнгән типларга аваздашлыгы, ул персонажларны шактый ук кабатлаулары ачыкланып иде.

Нәкъ әнә шундый яңалык таләбеннән чыгып караганда В. Имамовның узган ел «Казан утлары»нда басылган икенче повесте яшь язучы иҗатында югарыга таба җитди бер баскыч булып тора. Тик шунысы бар — бу әсәргә «Күке» дип исем кую укучы күңелендә төп геройга карата башта ук тискәре мөнәсәбәт уята. Ә мондый хәл әдәбият-сәнгать дөньясы өчен әйбәт нәрсә түгел. Ул «образлы фикерләү» дигән уникаль сәнгати көчнең энергиясен киметә, эчтәлек даирәсен тарайта, хис-кичерешләр мөхитен кечерәйтә. Гап-гади генә итеп әйткәндә, әсәрнең кызыгын киметә.

Ярый, бу кадәресен яшь автор ялгышы һәм повестьны редакцияләүче хезмәткәрнең уйлап җиткермәве генә дип кабул итик тә, әсәр турындагы төп сүзгә күчик.

Үзәктә Якуб Массарович Мортазин фигурасы. Повесть башында ул — 15 еллык эш тәҗрибәсе булган мәктәп директоры. Көньякта ял иткәндә аны Рәйсә Захаровна исемле тол һәм чибәр коллегасы үз кармагына эләктерә. Биредә без геройларның характерларын ачучы бер ачкыч булган һәм әсәрдә яшь язучы тарафыннан оста кулланылган әдәби детальгә игътибар итик. Якубның әтисенең исеме Мияссәр, ә Рәйсәнеке — Зәкәрия. Ә биредә алар, күрәсезме, ничек итеп кыланалар: Мияссәр улы түгел, ә Массарович; Зәкәрия кызы түгел, ә Захаровна!

Әнә шундый кыланчык холык нигезендә башланып китә дә инде курчак театры! Бу театрда Якуб Массарович — курчак, ә Рәйсә Захаровна аны йөртүче, хәрәкәткә китерүче оста артист.

Якуб дигән ул курчак үз хатынын һәм ике малаен ташлап Рәйсәгә йортка керә, аның торган шәһәренә үк күченеп килә. (Бу шулай ук ир-атның чүпрәклеген белдерүче факт — әдәби әсәрдә бик төгәл уйнаучы деталь!) Үзе РОНОда эшләүче Рәйсә бу курчакны мәктәп директоры итеп тә куйдырта. Тора-бара алар мәктәптәге менә дигән бер укытучының да язмышын харап итәләр. Ә Якуб Массаровичка шул ук вакытта «атказанган» исеме яулап алына. Соңгы битләрдә исә бу оятсыз һәм дәһшәтле пар Венгриягә сәяхәткә җыена. Повестьның иң ахыргы җөмләсе менә мондый:

«Нәкъ бер айдан Рәйсә ханым белән Мортазин ЗАГС бүлегенә барып язылышты. Монысы чит илгә китәр алдыннан кирәк булган котылгысыз формаль таләп иде».

Әсәрне йомгаклаучы җөмләдәге түбәндәге сүзләргә игътибар итик: «Рәйсә ханым белән Мортазин» — никадәр официальлек, салкынлык бу сүз тезмәсендә! «ЗАГС бүлегенә»— шулай ук официаль орган, формальлек бюросы. «Чит илгә китү» — бусы да күңелгә ераклашу, китү тойгысы сала — шундый ук җанны суыта торган тойгы. «Котылгысыз формаль таләп» — ә монысы инде әлеге ике геройның тулаем алганда да тормыш маягы бит! Формаль таләпләр — аларның яшәү мәгънәсен тәшкил итә, ләбаса! Менә шушы соңгы бер җөмлә ике геройның бөтен яшәвенә диярлек нәтиҗә ясап куя, аларның кем икәнлекләрен укучы күз алдында тагын бер кат балкытып ала. Менә шул бер җөмләгә ике геройның барча язмышы, холык-характеры сыйган! Нәселдәнлек билгеләре геннарга тупланып, алар аша күчкән сыман — бу җөмлә дә ике кеше холкын үзенә бик мул туплаган!

Кыскасы, «Күке» повесте белән В. Имамов заман темасына яңа сүз әйтте, укучы алдына яшәвебезнең яңа якларын ачып салды, уйланырга мәҗбүр итте. Безнең алда тасвирланган әлеге ике персонажның укытучылар, педагоглар булуы күңелдәге уйларны тагын да кискенләштерде.

Республикабызның газета-журналлары битләрендә соңгы елларда икенче яшь прозаик Зиннур Хөснияр хикәяләре еш кына күренә башлады. Мисал өчен «Казан утлары» журналының 1988 елгы 10 санында «Көзнең соңгы көннәре» исемле яңа әсәре басылды. Хикәя кайсы ягы белән кызыклы соң?

Иң элек бу әсәрдә укучы мавыгып кабул итәрдәй сюжет бар. Авыр елларда Әбелкәрим исемле кешенең ике капчык ашлык урлавына, ә моның өчен бөтенләй гаепсез берәүнең — бригадир Мотыйгулланың төрмәгә җибәрелүенә корылган ул сюжет. Әмма яшь язучы әсәрдә әлеге җинаять эшләнгән үткән чорны түгел, ә бүгенге көнне — шул ике геройның хәзерге тормышын игътибар үзәгенә куя. Үз гомерләренең ахырын ни хәлдә, ничек кичерүләрен тирәннән күзәтә.

Гөнаһсызга озак еллар төрмәдә утырып, бөтен язмышы җимерелгән Мотыйгулла гомер соңында, авырып үз авылына кайта. Аның хәлен күргән Әбелкәрим эчтән газаплана, үкенеп, аңа барысын да сөйләргә тели. Ләкин үзенең моңа кыюлыгы җитми, ул һаман суза да суза. Һәм, ниһаять, Мотыйгулла үлеп китә... Бу үлем Әлбелкәримгә җан тынычлыгы алып килә. Ул бит үзенең булачак хөкемдарыннан котылды!

Хикәянең башында да һәм беткән чагында да килеп кереп, әлеге вакыйгалар фонында яңгыраган борынгы әсәр — Йосыф кыйссасы — эчтәлекне нык киңәйтеп, тирәнәйтеп җибәрә. Эш шунда: көзге кичтә Әбелкәримнәргә җыелып, ул әсәрне күз яшьләрен агыза-агыза тыңлап утырган карчыкларның һәркайсының узган гомерләрендә эшләнгән байтак кына гөнаһлары бар. Ләкин моның турында — нәкъ менә Әбелкәрим кебек — һәркем эчтән генә тына, үзе генә белә...

Автор хикәясен болай бетерә:

«Менә бүген аларга күрше-күлән җыелышып керер. Гаҗбикамал карчык үзенең изге китабын укыр... Бу изге китап каршында үзләрен бик кечкенә һәм түбән итеп тоялар алар. Һәммәсе дә шул яшел тышлы китапка өмет күзләре белән багарлар...»

Хикәяне әнә шул рәвешле тәгәлләү укучы күңелен тагын да олырак уйларга алып килә. Кеше гомере һәм намус үлчәве... Дөнья кырыслыгы һәм вөҗдан сафлыгы... Фани дөнья кануннары һәм рухи омтылыш арасындагы аерма, ераклык...

З. Хөсниярның «Татарстан яшьләре»ндә (29 май саны, 1988 ел) һәм «Социалистик Татарстан»да (11 апрель саны, 1987 ел) басылган тагын ике хикәясенә кыскача тукталып узыйк. Аларның икесендә дә шактый четерекле язмышлар сурәтләнә.

Яшьләр газетасындагы «Тупыл мамык очыра» хикәясенең төп герое — ялгыз яшәүче шәһәр кызы Зарифә. Ул моңа кадәр күбрәк кәеф-сафа корып яшәгән, таныш егетләре дә шактый күп... Ә көннәрдән бер көнне язмышы Зарифәне сукыр егет белән очраштыра. Бераздан боларның сукмагы тагын кисешә, алар бакчада күрешәләр, арада җылы гына сүзләр булып ала... Соңрак Зарифә егетне бүлмәсенә музыка тыңларга да чакыра. Егет аңа күрмәгән күзләре белән сокланып утыра, ихластан ярата...

Һәм менә шушындый кешелекле, ихлас ярату ялгыш юлдан атлаучы кызның күңел күзен ачып җибәрә. Икенче көнне инде Зарифә элеккеге арзанлы кавалерларын ишектән дә үткәрми, куып җибәрә.

Яшь язучы бүгенге көндә гаять тә үткенәйгән социаль һәм әхлакый проблеманың бер чишелеш вариантын тәкъдим итә төсле. Ягъни хатын-кызның бүгенге хәле — аңа җәмгыятьнең мөнәсәбәте нинди булуга бәйле! — ди ул. Без аңа хатын-кыз итеп карасак — ул да хатын-кыз булачак! — ди автор.

Әйе, биредә З. Хөснияр белән килешмичә мөмкин түгел. Чыннан да, без көн саен хатын-кызга «син — азат, син — бәйсез» дип тукып торабыз икән, ул әлбәттә бәйсез, иреклe булачак. Гаиләдән дә, баладан да, әхлактан да азат булачак! Бүген мондый

мисалларны адым саен күреп торабыз! Җәмгыятебез хатын-кыз азатлыгының җимешен татый-татый инде соңгы чиккә килеп җитте...

Бу авторның икенче хикәясе әлеге идеяне тагын да калкурак итеп күтәрә. «Тәүбә» дип исемләнгән кыска гына күләмле ул әсәрдә Әсхәт дустының хатынына карап менә нинди уйлар кичерә: «...Тавышы мөлаем, йомшак, ягымлы. Ул хәзер аның классташы түгел, Мәрьям — әни, Мәрьям — хатын, Мәрьям — күгәрчен (ире аңа шулай ди.)»

Шулай итеп назлылык, иплелек, йомшаклык сыйфатлары бу әсәрдә югары күтәрелә. Бүген кызларыбызга, яшь киленнәребезгә һәм, гомумән, хатын-кызга бик тә, бик тә җитешмәгән сыйфатлар игътибар үзәгенә куела. Тормышны төзәтүнең, ныгытуның ышанычлы нигезе, җирлеге күрсәтелә. Мондый әхлак сабагы бирә алырдай әсәр иҗат итә алу — яшь язучы өчен шактый мәртәбәле эш инде ул.

Зиннур Хөсниярның каләме алда сүз барган Вахит Имамовныкына караганда шомарак. Җөмләләренә дә, геройлары сөйләшүенә дә тел-теш тидереп булмый. Ләкин аның каравы биредә, бу авторда, әле тормыш материалы В. Имамовка караганда азрак. В. Имамов каләме вакыйга һәм күренешләрне киң иңләп бара, кыюрак, активрак хәрәкәт итә. Анда яшәеш төсмерләре дә күпкә мулрак чагыла. З. Хөснияргә бу юнәлештә тырышлыкны арттыру кирәк.

Әдәбият мәйданында болардан алданрак күренгән Н. Гыйматдинова белән Ф. Бәйрәмова соңгы елларда яңа әсәрләр язып, үз иҗат юнәлешләрен тагын да ныгыта төштеләр. Беренче авторның «Казан утлары» журналының 7 санындагы (1988 ел) «Ханым-солтаным» повесте әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бик җылы каршыланды. Әсәр үткен проблемасы, тормышчанлыгы, кыюлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Автор яшәү катлаулылыгын реаль күрсәтә, бизәми. Күп нәрсәне укучының үзенә уйларга калдыра, аның фикерен, уен эшкә җитә.

Ф. Бәйрәмова соңгы елларда шулай ук берничә яңа повесть язды. Әмма укучы әле бу авторның 1987 елның 9 сан «Казан утлары»нда басылган «Күл балыгы»ннан бүтән яңа әсәрен белми. Шунлыктан «Күл балыгы» хакында берничә сүз әйтеп китик. Биредә безнең чор кешесе ниһаять килеп ирешкән, дөресрәге күпләр әле ирешергә тиешле халәт чагыла. Ул — дөньяны, тирә-юнь чынбарлыкны тулы бербөтен килеш кабул итә алу. Кеше белән табигатьнең аерылгысыз бербөтен булуын аңлый, төшенә алу. Әсәрнең ике герое — балык һәм кеше — әнә шул аерылганлыкны, үзара каршылыкны күрсәтү өчен алынган символ сыман образлар. Биредә миф кыяфәтендәге чынлык яши. Повесть музыкаль феерия кебек, бик сәнгатьчә иҗат ителгән.

...Шулай итеп, биредә берничә яшь прозаикның иҗатын кыскача күздән кичердек. Күргәнебезчә, аларга байтак кына мактау сүзләре дә әйттек, кайбер җитешсезлекләрен дә атадык. Болары, әлбәттә, кирәк иде. Әмма без еш кына очракларда зуррак таләпләрне, сизгеррәк үлчәүләрне истән чыгармыйбыз микән соң? Биредә бит сүз инде Тукай яшен узып баручы яки инде аны узган иҗатчылар турында! Димәк, аларга таләп тә шундый булырга тиеш! Укучы алардан Тукайныкы төсле зур иҗат, ялкынлы иҗат көтәргә хаклы.

Тукай белән безнең «яшь» дип саналучы язучыларыбыз арасындагы зур аерманы күрү кыен түгелдер. Иң элек шул күзгә ташлана: яшьләрнең проза әсәрләрендә тормышыбызның кискен конфликтлары юк. Торгынлык елларына хас рухи халәт, тыныч кына агучы «Лирика» анда чын-чыннан чәчкә ата! Ә бит үзебезнең тирә-юньне, таныш-белешләребезне генә барлап чыксак та — никадәр трагедия, күпме кан һәм күз яше күрәбез! Болар барысы да әдәбият материалымы? Бәлки барысы да түгелдер, ләкин тормышта кан һәм күз яше түгеп яшәгән үз замандашларыбызның күңел таләпләре — әдәбият өчен маяк сыман булырга тиеш!

Чорыбыз китереп чыгарган иң-иң кискен, иң-иң четерекле сораулар да яшьләр иҗатында тулы чагыла дип булмый. Дөресрәге, алар бөтенләй диярлек чагылмый. Яшьләрнең геройларына, әсәрләренә масштаблылык, уй-фикерләрнең тирәнлеге, җитдилеге җитми. Чорның бәгырен ачучы Ч. Айтматов иҗатын гына искә төшерик. Андагы кыюлык, тирәнлек нишләп бездә юк? Дөньябыз, чынбарлыгыбыз шул ук бит!

Яңа типлар тудыру буенча да яшь проза актив эшли дию кыен. Классик әдәбиятыбыздан килгән карт һәм карчыкларны бераз гына үзгәргән кыяфәттә әсәрдән әсәргә йөртү еш күзәтелә. Яшьләрнең үз замандашлары хикәя-повестьларга бик сирәк килеп керә. Чор тудырган яңа геройлар галереясы бик ярлы. Үзенчәлекле көчле характерлар тудырырга омтылыш сизелми. Әдәби тәнкыйтебез дә хәзер яңа характерлар тудыру мәсьәләсенә игътибарны киметте.

## Яшь шагыйрьләр

Узган елда өч яшь шагыйребезнең Ркаил Зәйдуллинның, Ләис Зөлкарнәевнең һәм Газинур Моратовның икенче китаплары басылып чыкты. Өчесенең дә беренче

җыентыклары хакында минем тарафтан матбугатта сүз әйтелгән иде («Казан утлары»ның 1985 елгы 1 санындагы «Егермедәгеләр» исемле мәкаләне һәм «Татарстан яшьләре»нең 1985 ел 24 декабрь санындагы «Елларга калсын!» исемле мәкаләләрне карарга мөмкин). Шуңа күрә икенче китаплар да үзеннән үзе игътибарны сорап тора.

Язмабызга исем итеп куелган «Тукай яшен узганда...» дигән сүз бу яшь шагыйрьләргә бигрәк тә туры килә — чөнки хәзерге вакытта аларга, чыннан да, егерме җидешәр яшь чамасы! Алар нәкъ менә Тукай яшен узып баралар!

Әйдәгез карыйк: Тукай яшендәге яшь шагыйрьләр укучыны нинди иҗади үрләр белән сөендерәләр икән?

Иң башта Р. Зәйдуллинның «Күрәзә» дип аталган китабын ачабыз. Уйларыбызны хуплаган төсле аның беренче битенә үк Тукайга багышланган шигырь урнаштырылган. Шигырьнең башында яшь иҗатчы Тукайны әле гомумирәк төстә генә күзаллый: «Ят итмидер, килә. Ләйсән булып тәрәзәмә минем сибелә. Таң йолдызы булып кайчагында күзен сала бүлмәм түбәнә». Соңрак автор «Бәгырь бит ул безнең. Әрнүләре йокламаска ахры уятты» дип, Тукай темасының эченәрәк үтә. Ары таба китеп «Ул ризамы бездән?» дигән конкрет сорау да куя. «Безгә бөек йокысызлык теләсен» дип тә белдерә. Һәм шигырьне «Кем өчендер малай. Миңа абый! Шуңадырмы мин ныграк сыгынам» дигән юл белән бетереп тә куя.

Тукай гомере һәм Тукай трагедиясе янында болай гына дип язу, чыннан да, малайларчарак килеп чыккан шул... Әмма әле тулаем нәтиҗә ясап куярга ук ашыкмыйк. Китапның эчендәрәк Тукай турында тагын бер шигырь бар. Тукай үлгәч:

*Өлешенә тигән көмеше дип*
*Кешнәп куйды шулчак тук мәйдан.*
*Һәр шигыре, һәрбер сүзе өчен*
*Түләү таләп итте Тукайдан.*

Менә биредә инде укучы Тукайча кыюлык, саллылык, кайнар хис һәм революцион фикер белән очраша!

*Сузылдылар керле куллар белән*
*Аның соңгы сулышын бүлдереп.*
*Төкерде ул,*
*Тук Рәсәйнең шома маңгаена*
*Ябышып калды канлы төкерек.*

Яшь шагыйрьнең күңел түреннән кайнап чыккан чын шигъри сүзләрне тиз танып алабыз. Тукай рухы исәнлекне тоеп сөенәбез! Ә мондый егетлек күренешләре китапта тагын күпме соң?

«Тик кайда соң шәрыкъ? Мәгърип кайда? Кая карап җанны юатырга? Бу шаушулы таш калада, бик тиз кыйбланы да мөмкин югалтырга» дип бүгенге яшь кешенең рухи халәтен төгәл билгеләүләр бар. «Әгәр күтәрелмәс икән, Каерып ат ул келәне» дигән юллар аша кеше рухын богаулаган нәрсәләрне кискен кире кагу бар. «Сүзләрдә дә шул төс, шул бер төрле. Нинди халәт соң бу, җир йоткыры» — дигән гаҗизлек халәте дә еш очрый. Һәм менә үз буыны язмышын бик тә калку чагылдырган «Без очарга әзерләнгән идек...» дип башлана торган шигырь:

*Ә куәтләр ташып тора иде...*
*Давылларны җиңмәс идекмени*
*Күктә булсак?*

Әйе, Р. Зәйдуллинга яшь кешенең күңел халәтен төрле яклап тасвирларга омтылу хас.

Ә икенче яшь шагыйребез Г. Моратовның «Мин дөньяны тыңлыйм» исемле китабы менә мондый юлларны эченә алган шигырь белән ачыла: «Каләмемне мандым мин каныма — Бу җыр Ватаныма!»

Туган ил, туган җир һәм яшь шагыйрьне тудырып үстергән халык темасы, шәхеснең алар алдында җаваплылыгы — бу уйлар Г. Моратов шигырьләрендә кайта-кайта такърарлана, укучының күңеленә тәмам сеңдерергә тырышыла.

*Авылымда соңгы түмәр*
*Утын беткәч, мөгаен.*
*Салкын мичкә үзе кереп*
*Дөрләгәндер бу каен.*

«1942 елның кышында киселгән каен» дип аталган шигырьдәге әнә шул каен образы батырлар йөрәгендәге изге хисләрне чагылдыру өчен бик тә отышлы, тәэсирле. Зифа буйлы матур каенның ут эченә керүе — яшь йөрәкләр фидакарьлегенең бәһасен укучыга тирәннән аңлата.

Чорыбызның кайбер сыйфатлары да яшь шагыйрь әсәрләрендә уңышлы гына ачыла: «Бозлык дәверенә кайтмасмы җан», Ярларыннан чыкса тимер ташкын?», «Нәни улым Чыңгыз, әнә, Агач атка атлана», «Утка хуҗасызлык хуҗа», «Күңелдәге умырзая Шагыйрьләр кебек туңган», «Илләр имин, тату торса, Без кайгы булмас идек»...

Р. Зәйдуллин һәм Л. Зөлкарнәев белән чагыштырганда Г. Моратов китабында бүгенге яшь гражданинның йөрәк авазы көчлерәк ишетелә. Аның «Ялвару» дигән шигыре ничек башланып китүгә генә күз салыйк.

*Һәр көн,*
*һәр таң,*
*һәр төн,*
*һәр иртәдә*
*Кыйтгалардан шомлы аваз ишетелә —*
*SOS авазы!*
*Җаннарыбыз һәләк була —*
*Коткарыгыз!*
*Нигезебез һәлак була —*
*Коткарыгыз!*
*Халыкларыбыз юк итела —*
*Коткарыгыз!*
*Тарихыбыз мәсхәрәләнә —*
*Коткарыгыз!*
*Киләчәгебез кыл өстендә —*
*Коткарыгыз!*
*Коткарыгыз!*
*Коткарыгыз!*
*...Кайчандыр,*
*Иделдә су коенганда,*
*бата башлаган кызчык та*
*нәкъ шулай ялварган иде:*
*— Коткарыгыз!*

Әрнегән ихлас җан авазы укучының йөрәгенә шундук барып тия! Халыкларны кечкенә кыз белән чагыштыру шигырь идеясен бик тә нечкә итә, үтемле итә, тәэсирле итә. «Иделдә» сүзе исә вакыйгаларның мәгънәсен безнең җирлеккә якынайта. Димәк шигырьнең көче тагын да артып китә дигән сүз!

Өченче яшь шагыйребез Ләис Зөлкарнәев тә «Кар өстендә алмалар» исемле китабында үзенең менә мондый карашын игълан итә:

*Кичер, шигырь, мин юләрне — ялгышканмын.*
*Синдә икән дәверләрне кичәр көчем.*
*Тормыш заман комнарына терәлгәндә,*
*Давыл даула*
*Кубарылып китәр өчен.*

Ә үзенең тирә-юнендәге чынбарлыкны бер мизгелдә автор болай күрә:

*Күкрәгендә кош йөрәге йөрткән кешем,*
*Читлек булып кыса сине бертөслелек.*
*Кая бакма: кысалы уй, кысалы хис —*
*Язмыш куйган як-ягыңа көзге элеп.*

*Беркая да китеп булмый, тынычлан дип*
*Тыпырчынган хисләреңнән сыйпый ялган.*
*Синнән өркә көзгедәге чагылышың —*
*Канатларың кысаларга сыймый калган.*

*Чиксезлеккә табынучы борынгылар*
*Түбәсе юк манаралар күккә чөйгән.*
*Түбәләрдән югарыда биеклек бар —*
*Асылыңа бер күтәрел күгәрчендәй.*

Әйе, җәмгыятебезне алга таба кызурак үстерү өчен актив көрәш, давыл даулау, биеклеккә чакыру әйбәт. Бу — барыбызның да күңеленә хуш килә. Әмма яшь шагыйрьләрнең бүтән шигырьләре мондый чакыруны тагын да ныгыталармы соң? Әлеге чакыру башка әсәрләрдәге тирән хисләр, яңа ачышлар булып дәвам итәме? Ягъни югарыга дәшү, өндәү сүзе нинди поэтик адымнар, нинди конкрет эш белән ныгытыла?

Өч яшь шагыйрьнең китабын укыганда да хиснең аныклыгы, ачыклыгы җитмәү

һәм шуңа бәйле рәвештә поэтик көче дә азрак булу үзен бик еш сиздерә. Нindидер гомумилек — тоюы, аңлавы авыр булган абстрактлык күп очрый.

Тагын да ачыклабрак әйтсәк — аларда бер конкрет язмышка ия булган конкрет кеше йөрәге сирәк очрый. Булса да, ул һәрвакыт диярлек — яшь шагыйрьнең үз йөрәге генә, үз язмышы гына. Әйе, башка йөрәкләргә күпләгән җепләр белән тоташса, андый йөрәк тә укучы өчен кызыклы булырга мөмкин. Ләкин әле дөньядан күп сабак, күп гыйбрәт алмаган бер яшь йөрәкнең «мин» кысасына гына омтылуы бик үк шәп түгел. Бу тарлыкка, вагаюга илтә. Ә бит бик якында гына үтә авыр проблемаларга уралган, чәбәләнгән язмышлы никадәр яшьләр — яшь шагыйрьләрнең үз яшьтәшләре бар! Кызганыч, безнең яшь каләм ияләре үзләренең андый яшьтәшләренә җитәрлек әһәмият бирмиләр. Әгәр игътибар ителсә, безнең яшь поэзия үзендәге драматизмны көчәйтер, конкретлыкны арттырыр, экспрессиврак булыр һәм әлбәттә укучыларын да күпкә арттырыр иде!

Р. Зәйдуллин китабының беренче бүлеген нигездә «мин» дип сөйләүче шигырьләр тәшкил итә. Бүтәннәрендә дә андый «мин» бик күп. Ә инде китап ахырындагы «Минем кайбер әйберләр белән хушлашуым» дигән гаять тә зур күләмле бер әсәр «мин»нең кем икәнен тәмам фаш итә. Анда поэзия, хис һәм кичереш үтә сүлпән! Анда гап-гади проза җөмләләре... Ә «Ни таптым мин җирдә шигырь язарлык? Шигырь язарлык ни югалттым соң?» дигән юллар әлеге тып-тыныч агучы юлларның сәбәбен дә аңлатып торалар... Әйе, гадел йөрәк дөресен сөйли. Тормышта күңелләре тетрәнерлек зур табышлары һәм югалтулары булмаганга күрә — зур шигъри дөнья тудыра торган актив җан, ярәлы җан белән яшәмәгәнгә күрә — яшь каләмнәребездән халык өчен кадерле шигъри сүзләр, шигъри юллар аз чыга.

Г. Моратов китабын ачыйк та, рәттән шигырь исемнәрен карап барыйк әле. Менә алар нindиләр: «Бу җыр», «И вакыт», «Ул көн», «Һәйкәлләр», «Ике яра», «Алма риваять», «Имитация», «Кәсеп» һ. б. Исемнәрдәге бер үзенчәлеккә игътибар иттегезме икән? Бөтенесендә дә җансыз әйберләр үзәккә куелган. Җансыз әйбер хакында сүз баргач, инде аңлашыла — алар өчен тагын яшь шагыйрьнең үзенә тырышырга туры киләчәк. Ул алар өчен, алар хакында сөйләргә тиеш булачак... Менә каян килеп туа күңелсез бертөрлелек, еш очрый торган көпшәклек! Ә моның киресе булса — яшь шагыйрь үз тирә-юнендәге җан ияләрен һәм бигрәк тә кешеләрне ныграк күзәтсә, ничек булыр иде икән? Алай була калган тәкъдирдә аның шигъриятенә шифалы агымдай өр-яңа «мин»нәр килеп керер иде, эчтәлек кызыклырак булыр, мәгънә тирәнәер иде. Чынбарлык хакында да күпъяклырак тәэсир, фикер тудырылыр иде! Ягъни яшь иҗатчының дөньяны күрү, тою нокталары күбәер иде...

Л. Зөлкарнәев китабы да бу яктан мактана алмый. Хәтта әле киресенчә дә бугай — томанлы «мин» исеменнән сөйләүче, гомуми төстә генә сүз алып баручы шигырьләр анда күбрәк тә бугай әле. Җыентыкта берсе 11, икенчесе 6 бит күләм алып торган «Дуңгәләк» һәм «Төнге әйтеш» шигырьләре мәгънәви бушлык белән бигрәк тә аерылып тора. Тукайга багышлап бик тә катлаулы исем белән аталган («1891 ел. Казан. Пасха. Пәйгамбәрнең иңүе») шигырь дә «...уенчык карарга килде! Кайтарыгыз, кайтарыгыз аны өенә!» юллары белән генә тәмамланып куя. Әлбәттә, монда нindидер ым сизелеп ала. Ләкин Тукай кебек зур трагедияне һәм олы мәртәбәне бергә туплаган язмышлы кеше хакында мондый гына ым бик тә аз бит! Шундамы соң яшь шагыйрьнең яшьлек кыюлыгы, яшьлек кайнарлыгы?!

Ә китапның ахырына «Кояш оясы» исемендәге, күләм ягыннан җыентыкның 18 битен (!) биләп торган мозаика урнаштырылган. Ул үзенең оешмаганлыгы, көпшәклеге белән Р. Зәйдуллин китабы соңындагы «Минем кайбер әйберләр белән хушлашуым»ны бик хәтерләтә. Һәр икесендә йөрәктән ташыган хис-кичереш юк. Һәр икесендә укучы өчен кызыклы яисә мөһим булган мәгънә юк. «Бирεдә яшь шагыйрьләр үзләренең моңа кадәр язган шигырьләренең бөтен каралама вариантларын тезгәннәрме соң әллә?» дигән шик тә туып куя. Чөнки китаптагы шулкадәр дә битараф, хиссез-уйсыз строфаларны бүтәнчә аңлатуы кыен. Шигырь белән бернинди уртаклыгы булмаган менә шушындый тезмәләр төшерә бит инде бүген безнең шигъриятнең абруен! Шундый җавапсыз караш безнең көчле шигъриятебезгә бүген бик тә зыян китерә бит!

Һәр өч яшь шагыйрь китабын укыганда шундый бер закончалык күзәтәсең: аларда тыштан караганда, ягъни сүздә шигырьне мактау, аңа мәхәббәт белдерү бар, хәтта бик күп. Ләкин шул ук вакытта, өч яшь шагыйрь дә үз иҗат практикалары белән шигъри сүзгә җавапсызлык үрнәген бик еш күрсәтәләр. Шигъри сүзнең кадерсезлеге адым саен диярлек очрый. Алда без ике яшь шагыйрьнең ике озын язмасын күргән идек. Г. Моратов китабындагы «Түбә» исемле 8 битлек шигырь моңа тагын бер мисал. Ул тезүче философ Марат Бибишевка багышланган. Барыбыз да белә: бу кеше — безнең үтә кызыклы замандашыбыз! Бик тә көчле шәхес ул! Әмма дөресен әйтик: яшь шагыйрьнең бу шәхескә «теше үтмәгән». Бу «чикләвек»не вата алмаган ул... Ә бит

мондый шәхесләр тормышында нинди генә көчле давыллар булмый! Алар бит һәрдаим давыл эчендә яшәүче натуралар! Үзләре давыл шикелле шәхесләр бит алар! Кызганыч — биредә яшь шигърият андый көчле шәхес өчен тагын бер канат була алмаган...

Яшь шагыйрьләрне укыганда тагын бер күңелсез үзенчәлек күзәтелә. Аларның әсәрләрендә бөтенләй диярлек авыл һәм табигать күренешләре юк. Бигрәк тә көендергәне: мәхәббәт юк! Болар бит — инде гомер-гомергә яшәүнең, тереклекнең нигезе булган нәрсәләр! Табигать һәм мәхәббәт — бөтен әдәбиятның, шигъриятнең анасы икәнлекне инде әйткән дә юк! Нәрсә бу?! Нинди мәхрүмлек бу!

Ә бәлки бөтен хикмәт тә шундадыр? Без югарыда күреп киткән бөтен җитешсезлекләрнең сере әнә шундадыр?! Иҗат өчен дөрес туфрак, дөрес җирлек булмаудадыр?! Шуңа күрә безнең алда зәгыйфь үсентеләр торадыр? Яшьләрнең шигырь телендә бик еш очрый торган ясалма һәм ят сүзләр, әйтүе үк үтә кыен булган атама-терминнар әлеге гариплек тойгысын тагын да көчәйтәләр... Нинди дер бозылган камиллек, җимерелгән гармония күз алдына килә. Китапларда ипсез, көйсез, моңсыз сүзләр ташкыны агыла...

Тукай яшен узып баручы безнең яшь шагыйрьләребез ни өчен мондый хәлдә? Ни өчен Тукай белән алар иҗаты арасында җир белән күк аермасы? Сан ягыннан караганда да, сыйфат ягыннан алганда да нишләп хәзерге яшьләр оялырлык дәрәҗәдә мескеннәр?

Ни өчен бүгенге егерме җиде яшьлекләрнең язганнарында халкыбызның иң-иң мөкатдәс уйлары, кичерешләре чагылмый? Нишләп ул әсәрләр кыюлык, намус, егетлек үрнәге түгел? Ни өчен безнең яшьләребезнең язганнары әдәбиятыбыз өчен бер баскыч югары мену санала алмый?

Без санап киткән менә бу «нишләп?», менә бу «ни өчен?»нәр аларга шәхсән бәйләнү түгел! Юк, биредә эш бәйләнүдән генә узган инде. Монда шундый мескенлек тудыручы сәбәпләрне ачарга кирәк!

Чөнки, барыбыз да бик яхшы белгәнчә: кешеләрне, шәхесләрне билгеле бер иҗтимагый шартлар формалаштыра. Шартлар нинди булса — анда үскән шәхесләр дә шундый була. Димәк, кешеләрне үзгәртү өчен иң элек аларны формалаштыра торган шартларны үзгәртергә кирәк! Кешелекле шартлар булдырырга кирәк!

Димәк — шартлар... Алар хакында, әйдәгез, алдагы бүлектә сөйләшик.

## Нишләп болай?

Ниһаять, без үзебезне иң-иң борчыган сорауга да килеп кагылдык. Нишләп бүген безнең яшь язучыларыбыз халкыбыз сөенерлек дәрәҗәдә күп түгел? Нишләп алар язган әсәрләрнең сыйфат дәрәҗәсе бик түбән? Халык шагыйре исемен алырдай титаник эш эшләп өлгергән Тукай яшендәге безнең хәзерге иҗатчыларыбыз ни өчен үтә дә яшь һәм «яшел» күренәләр?

Юк, моңа кадәр булган бик күп очраклардагы шикелле, бу мәсьәләдә дә без аклану юлыннан китмик. Җитәр — Тукай кебек талантларның үтә сирәк тууын әйтеп, без инде моңарчы күп хәйләләдек. Шулай итеп һәрчак иң авыр сорауның асылыннан кача килдек. Һәм, гомумән, торгынлык елларында бездә аклану, үзебезгә бәйле булмаган объектив кыенлыкларны эзләп табарга тырышу күп иде. Авыл хуҗалыгындагы арт-талыгыбызны без илнең климатик шартларыннан һәм ел саен бүтәнчә килә торган һава торышыннан (?) күрдек, шуңа сылтадык. Промышленностьта да чимал азаюга бәйле байтак сәбәпләр таптык... Ә культура өлкәсендә инде әйткән дә юк!

Шуңа күрә, милли культурабызның иң авырткан урыны булган сорауга — «Яшьләребез арасында Тукай кебек көчле шагыйрьләр нишләп аз?» дигән сорауга — биредә дөрес җавапны эзлисе һәм табасы килә. Чын сәбәпләрне эзләп табасы килә.

Журналыбызда басылган соңгы мәкаләбездә («Казан утлары», 1988 ел, 10 сан) без шигъриятнең «сәламәтлегенә» зыян иткән факторлар хакында сүз алып барып, ул сәбәпләрнең кайберләренә кагылган идек. Шуңа күрә биредә аларын кыскача атап кына китик.

Халыкның нигездә табигатьтән ераклашуы һәм шәһәрләшүе нәтиҗәсендә тормышның, яшәүнең үзендә гармония җимерелү, иплелек һәм тотрыклылык бетү — биредә иң башлангыч, иң беренчел сәбәп булып тора. Әнә шул җимерелгән гармония шартларында формалашып үскән шәхесләр инде үзләре яшәүдә һәм иҗатта бүтәннәрне ул гармониягә алып бара алмыйлар. Укучыга үз әсәрләрендә ул гармонияне тәкъдим итә алмыйлар. Ягъни биредә иҗатчының эчке «компасы» бозылган булып чыга, ул дөрес эшләми. Кечкенәдән гармоник тәрбия алган шәхеснең эчендә исә бәләкәйдән үк дөрес, сизгер «компас» формалаша. Әнә шул компас бөтен гомер юлы

буенча аңа яшәү өчен дә, иҗат өчен дә дөрес юнәлеш күрсәтеп бара. Аны күп төрле көрәшләрдән исән-сау, хәтта җиңүче итеп алып чыга. Төп юлдан тайпылдырмый. Бусы иң мөһим, иң хәлиткеч фактор булды.

Фән һәм техника революциясе нәтиҗәсендә тормышыбызда көчәйгән стандартлык, бертөслелек исә сәбәпләрнең икенчесен тәшкил итә. Чыннан да: миллионлаган кеше яши торган шәһәрләрдәге адәми затларның көн күрү рәвешләре бик тә бер төрле бит! Ул стандартлык, бертөрлелек яшәүдә дә, уйлауда да һәм хис итүдә дә нык сизелә. Шәһәр тормышы — заводтагы конвейер шикелле — штампланган затларны коеп кына тора! Иң мөһиме: әлеге бертөрлелек тәрбия өлкәсендә, мәктәптә көчле чагыла. Биредә шаблон таләпләр хөкем сөрә, алар бала институт бетергәнче аны үз кысасыннан ычкындырмыйлар. Ә аннары инде үзенчәлекле иҗатчылар эзләргә, әлбәттә, соң була!

Тормышта иҗатчы шәхесләр кимүгә китерә торган әлеге ике зур сәбәп — бөтен кешелек дөньясы өчен уртак бәла. Әдәбият өчен үткән гасырның «алтын чор» дип саналуы юкка гына түгел! Ә үз чорыбызда исә гармоник әдәби әсәрдән бигрәк, теге яки бу ягы бүлтәйгән язмалар белән күбрәк очрашабыз. Шуңа күрә дә Толстойларны, Чеховларны, Буниннарны еш сагынабыз! Хәзергебездә гармония җитмәгәнгә!

Югарыда без сүз алып барган ике сәбәпкә тагын бер зур фактор өстәлә. В. И. Ленин вафатыннан соң дәвам иткән чорда — ә ул чор, белүебезчә, 1985 елга кадәр сузылып, алтмыш елны тәшкил итә! — милли культуралар нык кысылдылар. Бу мәсьәләдә гигант ялгышлык хакимлек итте. Кечкенә һәм рус булмаган бүтән зур халыклар якын киләчәктә бетәчәк дип каралды, шундый караш, мөнәсәбәт таратылды, урнаштырылды. Моның тулы бер халык өчен нинди авыр трагедия икәнен аңлап бетерүе дә кыен. Әле без бер авылның перспективасыз дип санала башлавы аркасында никадәр бәлага таруын беләбез. Анда бернинди яңа йорт төзелми, ул авылда яшәгән кешенең алга таба төзергә, яшәргә күңеле үсми, рухи һәм физик таркалу башлана, байтак халык икенче урынга күчеп үк китә... «Перспективасыз» дип саналган халыкларда да шуңа охшаш һәм аннан да яманрак хәлләр күзәтелмәде мени?! Әлеге ялгыш караш тудырган бер генә күңелсез күренешне алыйк: әдәбиятыбызда башка телгә тәрҗемә аша гына уңышка ирешергә теләгән бер төркем язучы, шагыйрьләр пәйда булды. Нәкъ менә теге — «перспективасыз» авылны ташлап китүчеләр кебек иде алар.

Киң таралган бу ялгыш караш хөкем сөргәндә милли культура ничек итеп иркенләп үсә алсын инде?! Урыннардагы власть органнары югарыдан нинди җил исүен бик яхшы сизәләр бит алар! Югарыдан чыккан җилне алар үз кабинетларында давыл итеп үзгәртәләр бит! Үз халыкларына каршы эш булса, андый җитәкчеләр бигрәк тә ныграк тырыша. Чөнки бит әнә шул моментта политик «уяулык күрсәтеп калырга» мөмкин. Ә бу исә креслоны ныгыту өчен бик тә кирәк нәрсә!

Яңа Тукайлар тумауга тагын бер зур сәбәп — милли мәктәпнең бетәргә йөз тотуы. Халыкларны мәктәп аша корыта башлау иде бу! Һәм андый караш үзенең җимешләрен бирә дә инде — милли нигилизм хәзер бездә котырып чәчәк ата. Шуның бер нәтиҗәсе буларак Казаныбызда яшь җинаятьчеләр күбәйде.

Яшь иҗат көчләребезнең саны азлыкка һәм алар язганның сыйфаты да тиешле югарылыкта булмауга тагын бер мөһим сәбәп — милли матбугатның бик тар булуы, аның сыйфатының да тормыш таләп иткәнчә югары түгеллеге. Егерменче елларны алып карасак, без илебезнең төрле төбәкләрендә татар телендә басылып яткан бик күп газета-журналлар күрербез. Шулай ук татарча китап нәшриятлары да байтак була ул чорда.

Ә Сталин хакимлеге һәм торгынлык еллары безнең милли матбугатны нишләтте? Җиде миллионлы татар халкының хәзер бары тик 1 китап нәшрияты һәм 1 әдәби журналы бар! Шуңа күрә безнең язучыга әсәр бастыру өчен еллар буе чират торырга кирәк. Андый темп белән язганда нинди үсеш, хәрәкәт була алсын, ди?!

Хәзерге матбугатыбызның эчтәлеге, сыйфат дәрәҗәсе дә яшьләребезне заман таләп иткәнчә үстерердәй түгел. Эш нәрсәдә, ни җитми соң?

Кайнарлык җитми, ялкын җитми! Актив позиция юк! Бәхәсләр, полемика бик аз, сүлпән. Ә бу исә тормыштагы хәрәкәтне чагылдырмау дигән сүз, аңа теге яисә бу якка тәэсир итмәү дигән сүз. Яшь каләм өчен каршылыклар аша ныгый-ныгый үсә алмау дигән сүз. Матбугат көрәшләрендә чыныгу гына иҗатчыны ныгыта, аны төрле яклап чарлый, купкырлы итә. Әнә бит Тукай ничек көрәшкән!

Ә бездә әлегә боларның берсе дә юк! Шулай икән — яшь һәм яңа Тукайлар каян, ничек пәйда булсын соң? Бер нәрсә дә юктан бар булмый бит! Бөтен нәрсә билгеле бер шарт булганда гына туа, үсә.

Алдарак карап үтелгән яшь иҗатчыларыбызның шундый мактана алмастай хәле дә тиешле шартлар булмау нәтиҗәсе. Димәк, безгә сүлпән иҗатчылар үстерүче андый шартларны үзгәртергә кирәк!

# ДУСЛЫКНЫҢ БӨЕК КӨЧЕ

Октябрь революциясе, кайчандыр артка калган халыкларны феодализм дәвереннән туп-туры социализмга чыгару өчен, экономик изүне генә бетереп калмады, рух, культура тормышына да кискен үзгәрешләр кертте. Партия һәм Советларның тиңсез үзгәртеп кору эшчәнлеге Урта Азия мисалында аеруча күзгә ташлана. Мондагы революцион яңарыш процессын көчәйтүгә тарихи үсештә алгарак киткән күп кенә халык вәкилләре, җөмләдән, татарлар да киң җәлеп ителде.

Татар халкы уллары һәм кызлары, Татарстан вәкилләре Совет иленең төрле төбәкләрендә яши. Алар хезмәттә булсын, сугыш кырында булсын, бүтән милләт кешеләре белән иңгә-иң торып, матур казанышларга ирешәләр. Кая гына барсалар да, җирле халык белән уртак тел табып, тату тормыш корып җибәрделәр һәм аларның ихтирамын яулап алдылар. Менә шундый затларыбыз турында Татарстан китап нәшрияты 1960, 1962 елларда рус телендә «Без — Совет Татарстанынннан» дигән ике китап бастырып чыгарган иде. Укучылар кызыксынып каршы алган ул җыентыкларга Татарстанның абруен күтәрерлек бик күп каһарманнар хакында төрле милләт язучылары, журналистларыннан җитмешләп автор бик матур очерклар, мәкаләләр тәкъдим иткән иде. Әмма хуплауга лаек эш шуннан соң өзелеп калды. Тәүфикъ Әйдинең «Кайда да кадерле», «Тылсымлы көч» китаплары әнә шул күркәм башлангычка җан өрә.

«Кайда да кадерле» (Казан, 1984) җыентыгында композитор Латыйф Хәмиди (Алма-ата), аталы-уллы күз врачлары, фән докторлары Габдулла, Радомес Ходаяровлар (Уфа), җырчы игезәкләр, СССР халык артисты Рищат белән Казахстанның халык артисты Мөслим Абдуллиннар (Алма-ата), Мәскәү рәссамы Әхмәт Кытаев, СССР халык артисткасы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Мәрзия Даутова (Баку), йолдызларны өйрәнүче галим, фән докторы Шафика Шәрәф (Ленинград) һәм башкалар — илебезнең төрле тарафларында яшәүчеләр гәүдәләндерелгән. РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Наҗар Нәҗми, «Кызыл Таң» газетасында (Уфа) бу китапка бәя биреп: «Тәүфикъ Әйди һәр һөнәр кешесе хакында профессиональ осталык белән яза, төрле алымнар табып, һәр мәкаләнең дип әйтерлек үз сюжетын кора, ә кайберләре зур булмаган новеллаларны хәтерләтә», дип язып чыкты. Гадел һәм лаеклы бәя бу!

«Тылсымлы көч» (Казан, 1987) җыентыгы исә бөтен иҗади сәләтен һәм көчен Урта Азия, хосусан, Үзбәкстан фәнен, әдәбият-сәнгатен, мәгарифен үстерүгә биргән кешеләрне яктырта.

Үзбәкстанның атказанган культура эшлеклесе Габдулла Уразаев, фән докторы, профессор дәрәҗәләренә ия юрист Фатыйх Әбүбәкиров, архитектор Мидхәт Булатов, рәссам Чыңгыз Әхмәрев, Дәүләт премиясе лауреатлары биюче Галия Измайлова, язучы Әсгать Мохтар — кем генә юк алар арасында. Урта Азиягә дә алар төрле еллар-да төрле язмыш белән килеп төпләнә. Г. Уразаев белән Ф. Әбүбәкировны, мәсәлән, монда партия, комсомол үзәк Комитетлары эшкә юнәлтә, алар Төркестанда Совет властен урнаштыруда актив катнашалар. Гражданнар сугышы каһарманы, Оренбург хәрби-революцион советы әгъзасы Әхмәт Донской да монда 1918 елда җибәрелә. Гимназиядә укыган, шәрык телләрен яхшы белгән егет Төркестанда нәшрият эшләрен юлга салыша, университет ректоры итеп билгеләнә.

Якташларыбыз Төркестанда мәгариф, сәламәтлек саклау, культура өлкәләрендә аеруча зур хезмәт күрсәтә. Мисалга, беренче җәдит мәктәпләренә XIX йөз ахырында монда Ш. Мохтар, З. Габделвәһап шикелле алдынгы татар мөгаллимнәре нигез сала. 1910 елда инде алар шундый белем учаклары санын Куканда уналты, Ташкентта егермегә җиткерә. Таҗик совет әдәбиятының булачак классигы, академик С. Гайни шуларның тәҗрибәсен үзләштерер өчен, 1907 елда Бохарада якташларыбыз ачкан бер дөньяви мәктәпкә эшкә керә һәм андагы мөгаллимнәрнең, татарча дәреслекләрнең сыйфатына югары бәя бирә.

Им-том, өшкерү-төкерү хакимлек иткән Бохарада Европача беренче аптеканы якташыбыз Т. Диникәев ача. Каттакурган үзбәк драма театры композитор Салих Сәйдәшев оештырган татар труппасыннан үсеп чыга.

«Ихтыяр», «Рәхмәтуллин дулкыннары», китапны йомгаклаучы «Гомерлек мәхәббәт» очерклары аеруча җылы язылган. «Ихтыяр» әсәрендә бертуган өч кыз — биология, география, этнография өлкәсендә бирелеп эшләүче талантлы Кармышевалар язмышы күз алдыннан уздырыла.

Ташкент педтехникумын тәмамлаган Хәлил Рәхмәтуллинның гыйлем дөньясына килеп керүе дә бик кызыклы тасвирланган. Искиткеч сәләтле, гаҗәеп эшчән егетнең дөнья күләмендә атаклы физикка әйләнүе, космик парашют проектлаудан алып катлаулы теоретик хезмәтләр иҗат итүгә кадәр ирешүе, СССР Дәүләт премияләренә, Социалистик Хезмәт Герое, академик һәм башка дәрәҗәле исемнәргә лаек булуы белән танышу күңел дөньябызны баетмый калмый.

Каракалпак язма әдәбиятына нигез салган мәгърифәтче Сәйфелгабит Мәҗитев, Арал буенда Совет властен урнаштыручы кызыл гаскәридән дәүләт эшлеклесенә кадәр үскән Шәриф Әхмәдиев, каракалпак театр сәнгате учагын кабызучы Гали Омагулов, Касыйм Ямашов кебек шәхесләргә багышланган соңгы бүлек Урта Азиядәге якташларыбыз эшчәнлегенең яңа сәхифәләрен ача, халыклар арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлегебезгә дан җырлый.

Т. Әйдинең «Тылсымлы көч» китабы ел саен чыгарылып торган очерк җыентыкларының гадәтие генә түгел. Автор халыкка хезмәт итү уе белән янган, шушы юлда йөрәк дәртен, көчен кызганмыйча, якты эз калдырган олы шәхесләрне, фидакарь җаннарны эзләп тапкан. Гомер буе белемнәрен тулыландыра килеп, җәмгыятьне үзгәртеп коруга җаны-тәне белән алынып, шул максатка ирешер өчен, авырлыктан, мохтаҗлыктан, җирле кара йөзләрнең, сыйнфый дошманнарның ярсулы һөҗүменнән курыкмыйча, көрәш утына ташланучыларны зур мәхәббәт белән гәүдәләндергән басма бу. Китаптан егерменче-утызынчы еллар...ың кискен көрәшләре сулышы бөркелә, соңгырак дәвердәге зур казанышлар нуры сибелә. Сыйныфташларына ярдәмгә килгән, Урта Азия хезмәт ияләренең ышанычлы терәгенә, киңәшчесе һәм дустына әйләнгән якты идеаллы, юмарт рухлы, нык ихтыярлы татар егетләре һәм кызлары Төркестанда феодализм коллыгын, дини караңгылыкны җимереп килгән сыйныфтагы ...зәбәр китерешә. Җирле халыкка ирек, тигезлек, социаль һәм милли хокуклар яулап алышкан арада алар үзләре дә рухи үсә, күңелләрен Төркестан галимнәре, әдәбият-сәнгать даһилары иҗат иткән җәүһәрләр белән баета. Әл-Фараби, Әбүгалисина, Олугбәк, Нәваи исемнәре аларга Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Шиһаб Мәрҗани шикелле үк үз булып китә.

Авторның Идел буе һәм Төркестан, татар һәм Урта Азия халыклары хезмәттәшлеге, аларның культура бәйләнешләре, дуслыгы хакында фикерләре, уйланулары тирән дәлилләнгән, шуңа күрә бу җыентык күңелдә матур тәэсирләр уята. Ул элек артта калган халыкларның кыска вакыт эчендә нинди зур уңышларга ирешүен, бу яңарыш процессының этәргеч идеяләрен һәм көчләрен ышандырырлык итеп чагылдыра, илебездәге иҗтимагый хәрәкәтнең дөрес юлдан баруын һәм зур казанышларга китерүен исбатлый.

Очерк геройларының барысы да диярлек татар халкы вәкилләре. Алар туган телләрен, туган җырларын сөючеләр, туган җирләрен яратучылар, аны сагынып яшәүчеләр. Бу бик табигый, чөнки гармоник үскән шәхесләр бары шундый гына була ала. Менә шул башлангыч нигезгә аларның бүтән күркәм сыйфатлары органик рәвештә тоташып киткән: якташларыбыз рус теле, культурасын, Көнбатыш Европа казанышларын да яхшы үзләштергәннәр. Шуның өстенә, алар Шәрекъ дөньясын да үз кабул итәләр, Урта Азия халыклары телен, әдәбиятын-сәнгатен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, тарихларын өйрәнеп кенә калмыйлар, шушы тармакларны җиң сызганып үстерергә дә керешәләр. Аларга милли чикләнгәнлек, милли эгоизм бөтенләй ят. Шуңа күрәме, үзбәк, казах, кыргыз, төрекмән, каракалпакларның күпчелеге якташларыбызны үзләреннән аерып карамый, хәтта аларның татар икәнлеген белми дә. Ләкин нәкъ менә шушы егетләребез һәм кызларыбызның булуы Урта Азиядә татар милләтенә мәхәббәтне арттыруын без бик яхшы беләбез. Чын дустанә, мөнәсәбәт, чын интернационализм хисе безне әнә шулай якынайта һәм берекterә. Тәүфикъ Әйдинең «Тылсымлы көч» китабы тормышыбыздагы, тарихыбыздагы бик әһәмиятле сәхифәләрне оста җанландырып кына калмый, дуслыгыбызның кадерен белергә, киләчәктә дә шушы бәрәкәтле, җимешле юлдан атларга илһамландыра.

**Равил ВАХИТОВ**,
техник фәннәр докторы, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе.

*Уфа шәһәре.*

# АК ТАПЛАРНЫ КИМЕТӘ

Сөекле шагыйребез Тукайга багышланган кичәдә чыгыш ясарга туры килде. Соңыннан: «Тукайдан башка телгә алырлык тагын кемнәребез бар соң?» — дип сорау бирделәр. Җавапсыз калмадым, билгеле. Ләкин хәзер торып-торып үкенәм: их, Тәүфикъ Әйдинең «Тылсымлы көч», «Кайда да кадерле» китапларын элегрәк укыган булсамчы!

В. И. Ленинның «философик дәфтәрләр»еннән Идел-Урал төркиләренең Урта Азиядә мәгърифәт, мәдәният таратуы хакында укыганым бар. Бу турыда В. В. Бартольд фикерләре белән дә бераз таныш идем. Әмма телевизордан үзбәк балеринасы Галия Измайлова турында фильм карасам да, бу атаклы биючене татарга мөнәсәбәте барлыгын башыма китермәдем. Шулай ук үзбәк галиме Рәхмәтуллин, үзбәк язучысы Мохтар, үзбәк архитекторы Булатов, үзбәк рәссамы Әхмәревләрнең дә шәхесен, язмышын белмәгәч, күңелдә халкыбызга килеп тоташмавы сер түгел.

Ниндидер уй, мәгълүмат чикләнгәнлеге хөкем сөрә. «Татар мәдәнияте» дисәң, халкыбызның бары тик чиреген генә үз эченә алган Татарстанны һәм андагы культура әһелләрен генә күз алдына китерәбез. Онытабыз: культурага ясалма чикләр кертә була алмый. Шул шартлы чикләргә ябышып яту аркасында да халкыбызның Татарстаннан тышта яшәүчеләре милли мәдәният казанышларыбыздан тиешенчә файдалана алмый. Чикләр һәм республикаларның төрле-төрле статуслары туганлык бәйләнешларын, хәтта мәдәниятнең үсеш колачын да зәгыйфьләндерә.

«Статус» дигәне бигрәк тә рәхимсез: ул халыкның борынгы мирасын да, мәдәни потенциалын, милләтнең санын да искә алмый. «Автономия» статусы Татарстанга фәннәр академиясе, нәфис фильмнар киностудиясе ачарга, хәтта әдәбият-сәнгать газетасы чыгаруга да, радио-телевидение тапшырулары күләмен арттыруга да мөмкинлек бирми.

Элекке заманда Казанның олы фән үзәге булуын искә төшермичә булмый. Монда 1927 елда ук «Булат батыр» исемле нәфис фильм төшерелгән. Ләкин татар милли кино сәнгате үсеше шунда тукталып калган. Базасы корылмагач, кино эшлекләре дә күренми... Уйлап куясың: Рәхмәтуллин шикелле исеме бөтен дөньяга шаулаган галимнәребез, Әхмәрев, Булатов, Измайлова кебек сәнгатькәрләребез Татарстан җирлегендә шундый зур казанышларга ирешә алырлар иде микән?

Т. Әйди китабын укыганда, әнә шундый уйлар да күңелгә килә. Әлбәттә, автор боларны язмый. Аның китабы Үзбәкстанда яшәүче күренекле якташларыбыз белән таныштыруны гына максат итә. Таныштык. Рәхмәтләр яусын! Аңа мондый эзләнүләрен дәвам итеп, безне яңадан-яңа атаклы кешеләр белән очраштыруны гына теләргә кала.

Әйдинең бу китабын уңышлы дип санарга кирәк. Шундый мавыгып укырлык очерклар язуны сәләтле, белемле кеше генә булдыра ала, минемчә.

Әйди стиленең бер күркәм ягы игътибарга лаек: барысын да әйтеп бетерми, укучының үзенә дә уйларга мөмкинлек бирә. Уйлы укучыга шундый урыннарны аңлау үзе бер рәхәтлек, ләззәт татыта. «Ихтыяр» очеркында, мәсәлән, күренекле этнограф, биолог, географ кызларның әтисе турында: «1934 елда... Хәлил Кармышев ирекккә чыгарыла,— диелә.— Бу юлы ул, балаларының алга таба белем алуын җиңеләйтергә теләп, зуррак фән үзәгендә төпләнергә карар бирә. Җәй уртасында инде ул гаиләсе белән Ташкентка күчеп килә. Монда алар Иске шәһәрдәге җир идәнле ике бүлмәгә урнашалар. Әти кеше якындагы бер кышлакта канал төзелешенә эшкә керә һәм якшәмбе саен балалары янына кайтып йөри».

Нигә соң шундый укымышлы кеше канал казырга йөри? Нилектән аңа Ташкент кебек зур шәһәрдә эш табылмаган? Ә-ә-ә, дисең, ул мондый калада яшәүдән мәхрүм ителгән булгандыр шул!

Китап җиңел укыла. Әмма аны уку белән, бер сорау да туа: халкыбызның шундый күренекле вәкилләрен, аларның хезмәт җимешләрен нигә бик аз беләбез соң?

«Тылсымлы көч»тә китерелгән мәгълүматларны, фикерләрне күңел төбенә салып кую һәрберебезгә хаҗәт. Без күренекле замандашларыбызны гына түгел, культура тарихыбызда тирән эз сызган кадерле затларыбызны, аларның мирасын да игътибардан читтә калдырабыз. Мәсәлән, Ризаэтдин Фәхретдиневнең хезмәтләренә игътибар җитмәгән хәлдә, аның ачышларын яңадан «ачкан» галимнәр бар, имеш. Аның күренекле мөселман хатын-кызлары турындагы язмалары соңгы дәвердә басылмаганлыктан, шундый ук әһәмиятле хезмәтне төрек теленнән русчага тәрҗемә итеп укучыларга тапшырырга мәҗбүрбез.

Безнең әле Газиз Гобәйдуллин тарихи мирасын халкыбызга кайтарып бирәсе бар. Фазыл Туйкинның югалган кульязмаларын табасы, Мирсәет Солтангалиев «җинаяте» нәрсәдән гыйбарәт булганын беләсе, Гаяз Исхакый әсәрләрен яңа буын укучылар кулына тапшырасы бар. Безнең әле культурабыз тарихындагы «ак таплар»ны бетерәсе һәм карага буялганнарын юып, үз төсенә кайтарасы бар. Бар!

Бу җәһәттән, Т. Әйдинең очерклар җыентыгы зур бушлыкны өлешчә тутыруы белән кадерле. Әйди китаплары байтак атаклы замандашларыбызны культурабыз тарихына кертә. Онытылганнар, югалганнар күп булды, ичмаса болары саклансын, дип уйлыйсың.

**Айрат ИБРАҺИМОВ,**
отставкадагы офицер.
*Ульяновск шәһәре.*

# «БЕЗ ДӘ ХАКНЫҢ БӘНДӘСЕ»

Т. Әйди «Кайда да кадерле», «Тылсымлы көч» китапларында читтә яшәүче милләттәшләребез турында яза, аларның әдәбиятта, сәнгатьтә, фәндә, иҗтимагый хәрәкәттә һәм фикер мәйданында тоткан урыннарын ачыклый. Китаплар күләм ягыннан зур булмасалар да, эчтәлек ягыннан ифрат бай. Андагы шәхесләр белән танышканда: «Айһай, бездә дә бар икән талант иясләре!» дип горурланып куясың. Кем генә очрамый алар арасында: язучы, композитор, артист, архитектор, художник, юрист, биолог, физик, тарихчы галимнәр, партия, комсомол, совет эшлеклеләре — шөһрәтле затлар һәм гадәти хезмәт ияләре. Шуларның тормышын, катлаулы хезмәт, иҗат юлларын укучыларга аңлаешлы итеп сурәтләр өчен авторның да белемле булуы һәр тармак үзенчәлеген яхшы күзаллавы кирәк бит. Төрлетөрле, еш кына бер-берсеннән ерак һөнәр ияләрен укучыны мавыктырырлык итеп гәүдәләндерү профессиональ осталык та таләп итә. Т. Әйдидә белем дә, осталык та барлыгы күренә: китаплар җиңел укыла.

Т. Әйди, табигый ки, үзе белгән, исемнәрен атаган бик күп эшлеклеләребез хакында иркенләп, җәелеп яза алмаган. Язучы, журналист каләме сурәтләүгә лаек кешеләребезнең күплегеннән бу. «Тылсымлы көч»тә телгә алынган күренекле шәхесләрне кәгазьгә терки барган идем, ике йөздән арткач, туктадым. Халкыбызның йөзек кашлары! Шулар барысы да Татарстаннан читтә хезмәт итә, Урта Азия халыклары сәнгате, фәнен алга җибәрүгә өлеш кертә.

Әлбәттә, яхшы эш бу. Без, интернационалистлар, кардәш халыкларга ярдәм кулын юмарт сузганбыз. Маңгай тиребез, акыл көчәнешебез белән хәзер Урта Азия җәмәгатьчелеге горурлана торган байтак казанышларны дөньяга китерешкәнбез.

«Тылсымлы көч» китабында мәдәни багланышлар, мәгариф өлкәсендәге хезмәттәшлек тә дәлилле һәм матур сурәтләнгән. Милләттәшләребезнең Төркестанга дөньяви белем, әдәбият-сәнгать казанышларын алып баруын белү бик күңелле. Урта Азия халыклары егерменче-утызынчы елларда Казанга зур гыйлем-мәдәният учагына дип сәфәр чыга. Ә менә хәзер инде алар нигездә үз казанышларын күрсәтергә килә. Без аларның нәфис фильмнарына, утызлап театрлары чыгышына, илгә, дөньяга танылган язучылары, композиторлары, рәссамнары иҗатына кул чабабыз.

Менә шул ук вакытта башка якны да онытып җибәрү килешмәс: халык бай ул, дисәк тә, талантлар чишмәсе иксез-чиксез түгел бит. Зур потенциаль көчләрнең татар җирлегеннән читкә китүе халкыбызның рухи үсешен сүлпәнләндерүен, фәкыйрьләндерүен дә танырга кирәк. Унынчы-егерменче елларда татар культурасы дөньясын шаулаткан Оренбург, Троицк, Сембер (Ульяновск), Әстерхан, Томск, Самара кебек мәркәзләр хәзер тәмам тоныкланды, сүнде. Халкыбызның данын еракларга яңгыратырлык, ниһаять, безне яңа югарырак баскычка күтәрерлек ялкынлы йөрәкләребез, талант ияләребез тарихи ватанын ташлап киту аркасында гына булды бу, минемчә. Инде тарату, сибү дәвере узды, «ташларны кире җыю» заманы башлансын иде. Югыйсә, татар культурасын хәзер халкыбызның Татарстанда яшәүче чиреге генә үстерә, калганы, яхшы дигәндә дә, кулланучы гына! Ә безгә, җиде миллионлы милләткә, әнә шул сангә лаеклы казанышлар да кирәк, ул казанышларны исә күмәк көч түгеп, бу юнәлештә һәр татар кешесен актив иҗатка, актив хезмәткә тартып кына ирешергә мөмкин.

Кайчакта күңелгә шундый чагыштыру да килә: милли культурабыз, фәнебез, калада яшәүче интеллигент улларына соңгы пенсиясен җибәреп, үзе тәрәүле өйдә яшәргә калган мескен картны хәтерләтә башлый түгелме? Бу хәл безне һич тә пошындырмый калмый. Тукай әйтмешли, «без дә хакның бәндәсе» ләбаса!

Т. Әйди китаплары башка халыкларга мәхәббәтебезне арттыра, культура хәзинәбезнең яңа катламнарына игътибарны юнәлтә, аның каһарманнары тормышыбызда җанлы үрнәк бирә. Шул ук вакытта «Кайда да кадерле», «Тылсымлы көч» китаплары ваемсыз гына яшәгән укучыларга борчылу очкыны сала, йокымсырап гомер итүдән туктарга, хәрәкәткә килергә чакыра.

**Мөхәммәт МИНАЧЕВ,**
кранчы, Мәскәүнең «Туган тел» җәмгыяте идарәсе рәисе.

# ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ БАРМЫ?

Бертөрле уртакул әсәрләр әдәбиятны басып китте дип борчылып йөргән заманда кинәт күк капусы ачылдымыни?! Укучы кулына күптән язылып та дөнья күрә алмый яткан, яки басылып чыгуына ук үлемгә дучар ителгән әсәрләр килеп керде. Бүгенге заман укучыларына гына түгел, яшьрәк буын язучыларның да колагына ят исемнәр: «Эт йөрәге», «Чевингур», «Котлован»... Моңа кадәр тәнкыйтьчеләребез иҗат торгынлыгын тудырган сәбәпләрне әдәби осталык җитмәүдән, тормышны белмәүдән, эрудиция түбәнлегеннән, тагын әлләниләрдән эзләделәр. Тик бер нәрсәне ачык итеп әйтә алмадылар: чын дөреслекне бирергә мөмкинлек булмау язучының кулын тота иде. Тормыш хәлләрен бик яхшы белеп тә, хакыйкатьне бөтен ачылыгы белән сурәтләп бирәсе урынга — ярыкларны сылап, буяп йөрүче штукатур-маляр хәлендә утыруыбыз чын сәнгать әсәре тудыруга комачаулык итте бит. Редакцияләргә кыю гына әсәрләр килеп кергән очракта да редактор тарафыннан йолкынып, өтелеп, кайчагында автор үзе дә танымаслык хәлгә китерелеп укучы кулына барып керә иде. Билгеле, моның өчен язучыны да, тәнкыйтьчене дә, хәтта редакторларны да гаепләве кыен. Заманы шундый булды.

Инде илдә хәбәрдарлык башлангач тыныч кына җәйрап яткан әдәбият күле өстенә дә таш төшкәндәй булды һәм безнең татар әдәбиятында да үткен генә ситуацияләргә корылган әсәрләр күренә башлады. Нәбирә Гыйматдинованың «Ханым-солтаным» дип исемләнгән яңа повестен әнә шушы күл өстендә барлыкка килгән бәрәкәтле дулкыннарның бер тамчысы дип карарга мөмкин.

«Ханым-солтаным» күп планлы әсәр түгел, катлаулы вакыйгаларны да эченә алмый. Гадәти татар авылында (анда гынамы соң) очрап торган күренешләр. Мөршидә исемле ялгыз хатынның гыйбрәтле язмышы. Матур әдәбиятны кеше җанын өйрәнүче фән дип уйласак, бу әсәрне шактый кызыклы тикшерену объекты итеп карарга мөмкин. Мөршидә образы аша автор тәҗрибәле психологлар гына аңлата алырдай каршылыклы характер, үтә чуалчык, вакыты белән логикага сыймастай язмыш иясен күз алдына китереп бастыра. Бер карасаң, автор Мөршидәне буй җитмәслек биеклеккә күтәреп мактый, икенче бер карaганда чыгып булмаслык сазлыкка төшереп җәзалый. Менә ул яшь, моңлы, эшчән, йомшак күңелле ялгыз хатын, ул райком бюросы һәм колхоз идарәсе әгъзасы. Гаделлекнең, сафлыкның эталоны булырдай Зөлфия аны табыныр дәрәҗәгә җитеп ярата, ялгышлары өчен җаны көеп яши. Шул ук вакытта бу хатынны дан артыннан куучы, кирәген йолкып ала торган ертлач, телчән, уйнашчы итеп тә күрәбез. Рәсемен ясап стенага эләрлек тә, борынгы авыл гадәте буенча, капкасын дегеткә буярлык та аның. Бер кеше җанында никадәр каршылык. Ә бит автор ышандыра, геройларның эчке дөньясын хакыйкатькә аз гына да хыянәт итмичә анализлап бара (ә хакыйкать ул тоташ бер чылбыр кебек, ялгау өчен башка сыйфаттан булган әйберне куллан — шунда ук чылбырның ныклыгы югалачак. Андый юл белән барып, моңа кадәр күпме иҗат газаплары кичерде язучы халкы).

Авторның язу алымы урыны һәм вакытына карап үзгәрә тора. Әйтик, ул Зөлфиянең Мөршидәгә карата тискәре мөнәсәбәтен тасвирлаганда максималист яшьләргә генә хас кискенлек һәм ярсуны бирә алса, шул ук Мөршидә белән Таһирның очрашкан чакларын үтә сак, җылы, мәхәббәтләрен соңлап тапкан кешеләрчә моңсу итеп сурәтли. Инде килеп, Мөршидәне сазаган, кыюсыз бер егеткә димләгән бүлекне көлә-көлә укырлык йомшак юмор белән яза. Бер настроениедән икенчесенә шулай җиңел күчә алу әсәрнең җанлылыгын, сыгылмалылыгын арттыруга сәбәп булган. Повесть җиңел укыла. «Авыл борынча йөрсә таш чүлмәк тә кыршылып, ватылып бетәр иде», «Яратуның ялы юк икән» кебек чагыштырулар, аерым тәгъбирләр бер укуда истә кала. Авторның әдәби тел өстендә җитди эшләвен, әсәрдән әсәргә камилләшә баруын күрсәтә.

«Ханым-солтаным» мәхәббәт турындагы әсәр. Гәрчә бу исемгә бераз ирония салынган булса да, чынлыкта ул барлык ваклыклардан, гайбәт һәм пычраклыклардан өстен, олы, саф мәхәббәт турында. Моңар кадәр басылып килгән, җиңел укылып та тиз онытыла барган, социаль җирлеккә автор кодрәте белән генә тотынып торган кайбер төче

мәхәббәт романнарыннан аермалы буларак конкрет шартларга бәйле, реаль җирлеге нык, тормышчан әсәр. Мөршидә дә, Таһир да нинди профессия кешеләре икәнен дә чамалап булмый торган абстракт образлар түгел. Аларның хисләре билгеле бер шартларда ачыла, яшь һәм реаль сәбәп аркасында һәлакәткә очрый.

Шушы мисалда автор кешенең шәхси һәм иҗтимагый тормышы аерылгысыз икәнен раслый. Аның берсе генә чатнап китсә дә, тиз үк икенчесенә тәэсир итүен күрсәтә. Мөршидә әнә мәхәббәттә бер генә тапкыр талымсызлык күрсәтә. Түбән нәфесле башка берәүләрнең кул салуына шул җитә кала. Аягыңны бер пычраткач юлны карап атламыйсың шул инде. Гайбәтчеләр авызын томалыйм дип ул дан-дәрәҗәгә омтыла башлый, ләкин хезмәттәшләренең нәфрәтенә юлыга. Гадел хезмәт белән дә хөрмәт казанырлык ихтыяры да, көче дә булган хатын дөньясына, кешеләргә, язмышына уч итеп, нахак юлдан китә. Яшь сердәше Зөлфия белән сөйләшеп утырганда шул турыда ул менә нәрсә ди:

— ...Алам тек алам орденны! Юлыма аркылы төшкәннәрне таптап, изеп алам! Усал дисеннәр, сүксеннәр, тиргәсеннәр, минем эшем юк.

— Ал, ал, Мөршидә апа. Тик Зиннәт абый белән генә уйнамагыз сез.

— Ансыз ярамый, балакаем. Прсидәтелсез булмый. Берара булышучы, артыңнан этәрүче кирәк ул. Хәләл көчең белән генә әллә ни майтара алмыйсың.

Бүләкләрне учлап өләшкән, кода-кодагыйлык, ашнәлек хөкем сөргән ул заманда теләгенә ирешәсен белеп әйтә моны Мөршидә. Алачак ул орденны, ләкин шатлыгын гына күрмәячәк. Аны котлаучы да, хөрмәтләүче дә, сәнга сугучы да булмас авылда.

Кемнәргәдер ярыйм дип (беренче чиратта, редакторга, әлбәттә) элеккечә, бер генә буынын ташлап кара инде син бу хакыйкатьнең, ясалмалыкка китүеңне сизми дә калырсың һәм повестең телеграмм баганасыдай туры, шома, җансыз бер язмага әйләнер. Бәхеткә каршы Нәбирә кыенлыктан качмаган, әйтәсе сүзен укучысына туры итеп әйтә алган. Таләпчәнлек! Менә нәрсә җитми безгә. Үз-үзебезгә карата аяусыз зур таләпчәнлек җитми. Өйдә дә, эштә дә бер төсле үк таләпчәнлек. Сафлыкның, гаделлекнең, кешелеклелекнең сагында торган таләпчәнлек. Шушы сыйфат булмаганга Мөршидә әнә үз куллары белән олы бәхетен җимерә. Язмыштан узмыш юк диләр. Ә Нәбирә менә кешенең язмышы үз кулында икәнен ышандырып әйтә. Повесть гыйбрәтле бер күренеш белән тәмамлана: Мөршидә: «Аһылдап куйды да, ялгышын төзәтергә ашыккан кебек, кабаланып янә баскычка таба борылды. Үзе, кемдер тартып төшерүдән курыккандай, сөрлегә-сөрлегә өскә үрмәләде. Аңар ничек кенә булса да менәргә, менәргә кирәк иде. Ул үрмәләп менә башлады. Кул сузарлык арада бәхете... Югалтасы килми-и! Килми-и-и!»

Ләкин гөнаһларың аягыңа уралганда бәхет бусагасын атлап керүе ай-һай авыр ла.

Повестьта Мөршидә белән Зөлфиядән кала пәйгамбәрдәй изге күңелле Саимә карчык, деспот ир белән яшәп изелгән, ләкин олы җанлы, сабыр хатын булып калган Сәкинә образлары күптәнге танышларың кебек истә кала. Әмма ир-атлар турында алай ук дип әйтеп булмый. Алар турындагы хәбәрне без күбрәк башкалар авызыннан ишетәбез. Таһир да гашыйк җан буларак кына ачыла. Зөлфияләр бакчасында түтәл ясап бодай үстереп йөрүенә (бодайны кәлшәләп үстерү кадәресе дәреслеккә ни кадәр якындыр, анысын белгечләр әйтер) никтер ышанасы килми. Ул бит колхоз агрономы, тәҗрибә өчен колхоз җиреннән бәләкәй генә бер участок таба алмас идемени? Әгәр инде аның бу эшен председатель Зиннәт өнәп бетермәсә, әсәрдә тагын бер бәләкәй конфликт төйнәргә мөмкин булыр һәм Зиннәт тә, Таһир да каршылыклар аша күбрәк ачылыр иде. Хәер, бу кадәресе автор ихтыярына калсын ди, повесть бит башлыча ханым-солтаным өчен язылган, ул үзәк фигура, әсәр шулай уйланган. Ә менә икенче бер кеше — исемсез генә килеп кергән һәм Мөршидә куенында бер кич кунып чыкканнан чоң искә-санга алынмаган вәкил образына күбрәк игътибар итәргә кирәк булгандыр. Чөнки ул геройларның язмышында искиткеч әшәке роль уйнасы кеше. Әсәрнең финалында гына онытылып беткән вәкилнең яңадан килеп керүе бераз сәерсендерә. Шәп кенә барганда сөрлегеп киткәндәй буласың. Нәзек кенә булса да бәйләп торучы бер җепнең булмавы аркасында Мөршидәнең машинага утырып китүен аңлавы кыен. Бик буталчык, тайгак юллардан килеп тапкан иде бит ул үзенең мәхәббәтен. Бернигә дә алыштыргысыз, кадерле, кирәксә, җаныңны да бирерлек хис булырга тиеш иде ул. Шундый чакта, менә-менә бергә булабыз дип торган көндә вәкил белән китүенә ни сәбәп соң? Таһир мәхәббәтеннән дә көчле хисе бармы аның бу кешегә? Әллә орден алу хәбәре башын әйләндергәнме? Тагын бер пычрак гайбәт тарату белән куркыттымы аны вәкил? Әгәр шулай булса, боларның берсе дә Мөршидәгә тәэсир итәргә тиеш түгел иде кебек. Кызганычка каршы, болар турында бер сүз дә юк финалда.

Йомшак язылган уртакул әсәрдә бу төгәлсезлекләр бәлки сизелмәс тә иде, болганчык суда ни барын да белеп булмый. Ә бу әсәрдә һәр нәрсәнең үз урынында торуы бик сорала, ашыгыбрак төгәлләнүе канәгатьсезлек тудыра. Яхшы әсәрнең финалы да көчле булып тәмамлансын иде. Бу вакыйга әсәрнең иң югары ноктасы бит, соңгы аккорды.

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре докторы.

# АМЕРИКА ГАЛИМЕ ТАТАРЛАР ТУРЫНДА

Турыдан-туры татар халкының этник һәм гражданлык тарихына багышланган соңгы хезмәт моннан 60 еллар элек басылып чыккан иде. Ул — тарихчы галим һәм язучы Г. Газизнең Мәскәүдә, СССР халыклары үзәк нәшриятында 1925 елда дөнья күргән «Татар тарихы» исемле монографиясе. Дөрес, 1967 елда Мәскәүдә «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» дигән монографик җыентык һәм 1984 елда Р. Фәхретдиновның «Очерки по истории Волжской Булгарии» дигән хезмәтләре нәшер ителде, алар да халкыбызның тарихына карыйлар. Ләкин бу хезмәтләрнең беренчесе халкыбызның гореф-гадәте, көнкүреше, моң-җырлары, һөнәрләре мәсьәләсенә — этнографиягә карый, ә икенчесе, ерак бабаларыбыз болгарлар турындагы хезмәт, асылда Идел буе болгар дәүләте буенча билгеле булган хезмәтләрнең историографиясен хәтерләтә. Соңгы елларда халкыбызның теле, әдәбияты, сәнгате, иҗтимагый фикер тарихы, басма сүзе буенча, шулай ук тарихыбызның аерым чорларын тикшерүгә багышланган хезмәтләр дә дөнья күрде. Әйтик, С. Алишев татарларның Пугачев хәрәкәтендә катнашуын тирәнтен өйрәнеп язды. Әмма бу хезмәтләр әле татар халкының тулы тарихын ачып бирүдән ерак тора, алар зур тарихның аерым өлешләре генә булып кала.

Шәхес культы, торгынлык заманнарында рус булмаган халыкларның, бигрәк тә татар халкының тарихын өйрәнү читкә этелеп килде. Шул ук вакытта әдәбиятта атлаган саен безгә монгол басып алучылары дигән мөһер сугылды, шушы караш пропагандаланды. Халкыбызның этник, гражданлык тарихын өйрәнү милләтчелек дип каралды. Бу заманнарда халыкның гражданлык тарихын өйрәнү эше географик зона тарихын тикшерүгә кайтып калды. Менә шуңа күрә бездә татар халкының тарихы урынына Татарстан АССР тарихы гына тикшерелде. Өстә сәясәт үзгәрү, яңа «юлбашчы» утыру уңае белән тарих өзлексез «төзәтелеп», үзгәртелеп килде. Соңгы елларга хәтле гуманитар фәннәрдә политизация, идеологизация төп метод булуын искә алсак, моңа хәтле дөнья күргән «Татарстан АССР тарихы»ннан татар халкының объектив тарихын эзләү ялгыш булыр иде. Бу тарих китапларында Татарстан АССР территориясенең экономикасы, авыл хуҗалыгы, анда булган вакыйгалар яктыртылган, шул исәптән бу территориядә яшәгән татар халкының тарихы да өлешчә чагылыш тапкан, әлбәттә. Әмма, билгеле булганча, татар халкының дүрттән өч өлешеннән артыгы бу территориядән читтә яши. Димәк, аларның тарихы «Татарстан АССР тарихы»ннан читтә калып килә. («Татарстан АССР тарихы»ның ни дәрәҗәдә фәннилеге, объективлыгы турында биредә сүз алып барылмый. Без аның вульгар социологизмнан азат булмавын гына искә алып үтәбез). Йөзәр меңләп, компакт төркемнәр булып Башкортстан, Чувашстан, Мари автономияле республикаларында, Чиләбе, Ульяновск, Куйбышев, Оренбург, Әстерхан һәм башка өлкәләрдә яшәүче татарларның тарихы «Татарстан АССР тарихы»нда чагылыш тапмый, бу төбәкләр тарихы буенча чыккан хезмәтләрдә дә анда яшәүче татарлар тарихы турында сүз юк.

Югарыда мин, татар халкының тарихын бербөтен итеп өйрәнү тыелып килде, дидем. Моны үземнең тәҗрибәмнән дә күрсәтә алам. Татар китабы тарихы белән шөгыльләнә башлагач, Казаннан, Татарстаннан тыш татар китабын басу тарихын минем фәнни эш планымнан төшереп калдырдылар. Шуңа күрә Татарстан АССРдан тыш милли китабыбыз тарихын эштән соң, ял хисабына алып бардым. Мин эшли торган Тел, әдәбият һәм тарих институтында Мәскәү, Әстерхан, Оренбург һәм Татарстаннан тыш башка төбәкләрдә оешкан татар театры тарихын өйрәнүне дә институт планына кертмәделәр. Ерак барасы түгел, Казанда чыккан «Батырлар китабы»на Татарстан АССРдан

читтә яшәп Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеме алган татар халкының батыр уллары кертелмәве дә шуның мисалы.

Октябрь революциясеннән соң татар халкы тарихын өйрәнүгә мөмкинчелекләр туа башлый. Халкыбыз тарихын төрле пычратулардан азат итү, аның фәнни тарихын булдыру йөзеннән махсус эшләр гамәлгә кертелә, «Татароведение» дигән фән барлыкка килә. Хәтта революциягә хәтле дә халкыбызның тарихы буенча, авырлыклар белән булса да, хезмәтләр чыга башлаган. Моның өчен Ш. Мәрҗани, Һ. Атласи, Г. Әхмәров, Г. Баттал, Р. Фәхретдинев, Г. Баруди һәм башкаларның татар халкы тарихы буенча китапларын искә төшерү дә җитә. Аларның хезмәтләре егерменче еллар азагында тыелган, яндырылган. Шушы еллардан башлап, татар халкының тарихы буенча эшләү берьяклы гына алып барыла. Сталин аңлап эш иткән, үз тарихын оныткан халыкның киләчәге булмавын яхшы белгән.

Татар халкының үткәне турында уйдырма, ялгыш карашлар, аларны монгол токымнары итеп карауның нигезендә төп сәбәп булып безнең гражданлык һәм этник тарихыбызның җитәрлек тикшерелмәве һәм пропагандаланмавы ята. Бөтен Европа халкы татар исеме астында монголларны таный, шул ук хәлне без АКШта да күрдек. Төркиядә дә татар дип монголны атыйлар, биредәге татарлар үзләрен «төрки», «Казан төркие», «шимали төрки» дип йөртәләр.

Европа, Америка халыклары арасында безнең кем булуыбызны аңлату юлында ифрат кирәкле эш башкарылды. Мин бу урында 1986 елда АКШта, Лос-Анжелеста инглиз телендә басылып чыккан «Идел буе татарлары тарихы» дигән монографияне күз алдында тотам. Аның авторы — Азад-Гайшә Рорлих, Төньяк Калифорния университеты профессоры. Зур күләмле бу хезмәт өч кисәктән, һәр кисәге берничә бүлектән тора. Беренче бүлеге «Идел буе татарларының килеп чыгышы» дип атала һәм ул Г. Газизнең «Татармы, төрекме?» (төркиме — Э. К) дигән хезмәте исеме астында ачыла. Хезмәтнең һәр бүлеге исеменнән соң эпиграфлар китерелә, без аларны алда күрсәтә барырбыз. Автор бу бүлектә татар этнонимының тарихына туктала һәм бу исем астында хәзер билгеле булган халыкның килеп чыгышы турында булган карашларга анализ ясый. Профессор Азад-Гайшә бу этноним турында С. Соловьев, Г. Перетяткович, Н. Карамзин, И. Березин, В. Григорьев, Н. Чернов, Н. Калинин, Н. Фирсов, М. Худяков, А. Смирнов, С. Толстой, Н. Воробьев, Т. Трофимова, Н. Дмитриев, М. Тихомирнов, В. Бартольд хезмәтләренә таянып эш йөртә. Авторга безнең халыкның исеме һәм килеп чыгышы турында борынгы төрки, көнчыгыш галимнәренең карашлары да таныш. Ул шулай ук бу мәсьәлә буенча Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Баттал, З. Вәлиди, А. Халиков, Ф. Вәлиев, Л. Җәләй, М. Зәкиев, М. Госманов, Һ. Гимади, Я. Абдуллин карашларын да яхшы белә. Шундый киң чыганаклар нигезендә автор хәзерге заман татарларының монгол түгеллеген, ә төрки халык булуын күрсәтә. Хәзерге татар исеме астында билгеле булган халыкның Идел буе болгарларыннан килеп чыгуын, аларның формалашуында кардәш кыпчакларның катнашуын күрсәтә. Автор, тиздән татарлар турында яңа хезмәтләр язылыр, аларда болгар-кыпчак теориясе расланыр, дигән ышаныч белдерә.

Азад-Гайшә үзенең хезмәтен «Идел буе татарлары тарихы» дип атаса да, бу исемнең Урал, Себер татарларын да үз эченә алуын ассызыклап күрсәтә, безнең кайбер тарихчыларыбыз, шагыйрьләребез кебек, аңа Кырым татарларын кертми.

Монографиянең икенче бүлеге «Болгар дәүләте» дип атала һәм Асия Минһаҗеваның «Болгарда уйланулар» шигыреннән алынган өзек белән башлана:

*Катлам-катлам тарих ята,*
*Гасырларга бүленеп...*
*Халыклар аһ-зары кайта*
*Күз яшенә эленеп...*

Биредә Болгар дәүләтенең кайчан барлыкка килүе, Азов-Дон буйларыннан болгар кабиләләренең Идел буена күчеп килү сәбәпләре, Идел-Кама буендагы Болгар дәүләтенең чикләре, шәһәрләре, тормышы, культурасы, галимнәре турында мәгълүматлар китерелә. 922 елда Болгарга Багдад илчелегенең килүе, рәсми рәвештә ислам динен кабул итү, илчелекнең секретаре Ибне Фазлан язмалары, Болгар дәүләтенең Рус дәүләте һәм башка халыклар белән сәүдә, экономик, культура мөнәсәбәтләре, Болгар дәүләтенең даны ерак җирләргә билгеле булуы турында сүз алып барыла.

Өченче бүлек «Монгол басып алучылары» дип атала һәм аңа болгар-татар кабер ташларында очрый торган «Без киттек. Башкалар килер» дигән юллар эпиграф итеп куелган. Бу бүлектә монголларның 1228, 1232 елларда ясаган һөҗүмнәре, болгарларның басып алучыларга каршы героик көрәше, Болгар дәүләтенең Алтын Урда кул астындагы хәле тасвирлана. 1256-1502 елларда Алтын Урда тәхетендә утырган ханнарның хронологик таблицасы да китерелә.

Дүртенче бүлек «Казан ханлыгы» дип атала һәм М. Каюмовның «Казанымда шундый чатлар бар» дигән шигыреннән:

*Киләчәгем нурлы булсын өчен*
*Үткәннәрдән һәрчак ут алам.*

— дигән юллар китерелә. Бүлекнең исеменнән күренгәнчә, анда Казан ханлыгының 1437 елдан алып 1552 елга кадәрге тарихы яктыртыла. Анда Болгар дәүләте җимерелгәннән соң Казан ханлыгының ничек барлыкка килүе, аның элекке башкаласы, Мәскәү белән Казан арасындагы хәрби, экономик, культура, сәяси мөнәсәбәтләр, Казан илендә мәктәп-мәдрәсә, кулъязма китап, әдипләр, илнең экономик хәле, ханлыкның Урта Азия, Себер, Кавказ, Төркия белән элемтәләре тикшерелә. Бу бүлектә Касыйм ханлыгының тарихына да урын бирелгән. Казан ханнарының хронологиясен эченә алган таблица да китерелгән. Монографиянең беренче өлеше шушы бүлек белән тәмамлана.

Китапның икенче өлеше «Идел буе татарлары һәм Рус дәүләте» дип атала һәм 5-9 бүлекләрне үз эченә ала. Бишенче бүлек «Казан ханлыгын аннекцияләү, Россиянең татарларга карата тоткан политикасы» дип исемләнгән. Бүлеккә эпиграф итеп Ш. Маннурның «Сабыр төбе» шигыреннән түбәндәге юллар алынган:

*Патша җиңгән,* — *Чал маңгае җиргә тигән,*
*Халык башын игән,* — *Ирексезлек камап алган бөтен яктан.*

Бу бүлектә Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынганнан соң анда яшәгән халыкларның башыннан кичкән газаплары, халыкны көчләп чукындыру, җирен-байлыгын талау, күпләрнең иленнән куылуы, татарларга карата алып барган милли-колониаль изү политикасы тасвирлана. Шушы чорда татар халкының төрле җирләргә таралуы, Степан Разин, Емельян Пугачев хәрәкәтендә актив катнашуының сәбәпләре, Екатерина II нең татарларга карата ясаган кайбер ташламалары: мәчет салырга, мөфтилек ачарга рөхсәт бирүенең сәбәпләре күрсәтелә. Лука Канашевич, Ильминский кебек христиан миссионерларының татарларны чукындыру, мәктәп-мәдрәсәләрне эзәрлекләү, бу чордагы халык мәгарифе мәсьәләләренә дә урын бирелә.

Алтынчы бүлек «Дин исеме астындагы реформизм» дип исемләнгән. Ул С. Ялчыголовның: «Һәр урында төрле милләт кузгалыша»,— дигән сүзләре белән башлана. Бирелә без Г. Курсавый, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинев, М. Бигиев, Габдрәшит Ибраһимов, З. Камалый, Г. Килдешев кебек татар зыялыларының эшчәнлеге белән танышабыз. Аларның халык мәгърифәтенә керткән өлеше, халык арасындагы уянуның, торгынлыктан чыгуның беренче адымнары сурәтләнә. Шул уңайдан вәисевчеләр һәм аларның эшчәнлеге, Урал, Себер татарлары арасында мәктәп-мәдрәсә эшләре, Иж-Буби мәдрәсәсен тар-мар итүнең сәбәпләре, Бөтенроссия мөселманнарының беренче съезды кебек темалар яктыртыла.

«Дөньяви-дини симбиоз» дип аталган җиденче бүлек Ф. Кәримнең

*Үзең турында уйлама,*
*Илең турында уйла,*

— дигән шигъри юллары белән ачыла. (Бу юллар ялгыш Т. Миңнуллинныкы дип күрсәтелгән.)

Эчтәлегеннән күренгәнчә, бу бүлектә сүз татар мәгърифәтчелеге турында бара. Анда мәгърифәтчелекнең күренекле вәкилләре Ибраһим Хәлфин, Гали Мәхмүдов, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов эшчәнлегенә киң урын бирелә. Татар басма сүзенең барлыкка килүе, Казан, Оренбург, Уфа, Петербург, Әстерхан һәм башка урыннарда татар китапчылыгының тарихы, татар вакытлы матбугаты ачу өчен көрәш, җәмгыяте хәйрияләрнең мәдәниятебездә тоткан урыны һәм башка мәсьәләләр дә тикшерелә. Татарлар арасында киң тарала башлаган мәгърифәтчелеккә, дөньявилыкка каршы Ишми ишан кебек реакцион ислам әһелләренең патша жандармериясе белән бер союзда торып көрәшүе дә яктыртыла.

Сигезенче бүлек — «Белемлелек». Аңа эпиграф итеп И. Гаспринскийның рус телендә язылган «Русское мусульманство» дигән мәкаләсеннән түбәндәге юллар китерелә: «Когда мы в своем мектебе приобретаем первоначальные плоды вашей науки и знаний, когда мы из татарских книг узнаем нашу Россию и ее порядки, будьте уверены, у нас появится желание и средства наполнить ваши гимназии и университеты, чтобы трудиться рядом с вами на поприще жизни и науки». Бу бүлектә татар уку йортларының программалары, мәдрәсәләр тарихы, татар мәктәпләренә карата царизм алып барган эзәрлекләү политикасы, татар яшьләре өчен рус уку йортларының бикле булуы, шуңа күрә аларның Каһирә, Бәйрүт, Истанбул, Женева, Сорбонна, Япония, Кытай, хәтта Америка уку йортларына белем алу өчен китә башлаулары күрсәтелә.

Татар халык мәгарифе өлкәсендә эшләп килгән күренекле зыялылар турында да мәгълүматлар китерелгән бу бүлектә.

Тугызынчы бүлекне мин «Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте» дип тәрҗемә иттем. Ул А. Минһаҗева шигыреннән алынган түбәндәге юллар белән башлана:

*Шундый вакыт килер! — диеп*
*Өметләнеп көткәннәр.*
*Вакыт җиткәч, әллә кемнәр,*
*Әллә кемнәр киткәннәр.*

Профессор Азад-Гайшә татарларда җәдитчелек хәрәкәтен XIX гасырның ахырыннан башлый. (Хезмәттә сүз нигездә, мәгърифәтчелек турында бара, шуңа күрә без бүлек исемен «җәдитчелек» дип тәрҗемә итмәдек). Автор, бу хәрәкәт 1917 елгы революциягә хәтле дәвам иткән, дип саный. Шул уңайдан ул «пантюркизм» мәсьәләсенә дә тукталып үтә. Бүлектә 1905 елның 17 октябрь манифестыннан соң иҗтимагый хәрәкәтнең киң җәелеп китүе тасвирлана. Сәяси-иҗтимагый хәрәкәттә Садри һәм Һади Максудилар, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров кебек социал-революционерлар (алар арасына автор Г. Камалны да кертә), Г. Терегулов кебек меньшевикларның роленә тукталa.

Шушы ук бүлектә беренче татар большевигы Х. Ямашев, татар социал-демократлары турында да сөйләнә. Большевикларның үз карашларын пропагандалауда «Азат», «Азат халык», «Казан мөхбире» кебек газеталарны файдалануларына, шулай ук беренче татар большевистик газетасы «Урал»ның роленә тукталa. Бу бүлектә Беренче һәм Икенче Бөтенроссия мөселман съездлары турында да, I-IV Дәүләт Думасының мөселман фракциясе эшчәнлеге турында да күп мәгълүматлар алырга мөмкин. Автор татарларда төрле юнәлештәге сәяси хәрәкәтне «җәдитчелек» исеме астында, бер тоташтан диярлек карый. Татар большевикларының эшчәнлеге дә шушы бүлектә карала. Әлбәттә, аларның эшчәнлеген, тоткан максатларын «җәдитчелек»кә кайтарып калдыру белән килешү мөмкин түгел.

Татарларда җәдитчелек хәрәкәте профессор Я. Абдуллин тарафыннан махсус өйрәнелде, аңа тиешле бәя бирелде, җәдитчелек белән мәгърифәтчелекнең нинди агымнар булуы шактый тулы күрсәтелде. Профессор Азад-Гайшәнең җәдитчелек, мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның вәкилләренең тоткан урыннары турындагы бәяләре белән Я. Абдуллин концепциясе арасында аермалыклар бар. Безнең максатыбыз бу ике галимнең — Америка профессоры Азад-Гайшә Рорлих белән совет галиме Я. Г. Абдуллин карашларын чагыштырып тикшерү түгел, ә күрсәтелгән тарих китабы белән таныштырып үтү генә.

Монографиянең өченче өлеше «Идел буе татарлары һәм Советлар Союзы» дип атала һәм ул үз чиратында өч бүлектән тора. Унынчы бүлек «Революция: культура автономиясеннән ТАССРга хәтле» дип исемләнгән. Эпиграф итеп Х. Әюповның «Бәйрәмнәр» шигыреннән түбәндәге юллар китерелгән:

*Бәйрәме бар халык — бай халык:*
*Гасырларның бәйрәм елларында*
*Җире кала,*
*Байраклары кала чайкалып.*

Бу бүлек 1917 ел Февраль революциясеннән алып Татарстан АССР оештырылуга хәтле чорны эченә ала. Бу дәвердә эшләп килгән Милли шура, Хәрби шура, Казан мөселман комитеты, Мөселман социалистлар комитеты, РКП(б)ның Көнчыгыш халыклары коммунистлар оешмасы, Милләтләр эше халык комиссариаты, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе эшчәнлеге, Татар-башкорт республикасы, Татарстан республикасы төзү өлкәсендәге көрәш мәсьәләләре каралган. Октябрь революциясеннән соң татарлар яши торган башка шәһәрләрдә, регионнарда төрле мөселман комитетлары, милли мәктәпләр, милли матбугат эшләре, культура учаклары оештырылуы, аларның төп эшчәнлеге, Октябрьнең татарларга үз культураларын үстерү өчен ачкан мөмкинлекләре тасвирлана.

Татарстан республикасын оештыру буенча М. Вахитов, К. Якубов, Г. Ибраһимов, Һ. Маликов, М. Галиев, М. Конов кебек революционер һәм җәмәгать эшлеклеләренең исемнәре белән очрашабыз. Шулай ук татар хезмәт ияләренең Октябрь революциясе казанышларын саклауда кулларына корал тотып төрле фронтларда сугышулары да күрсәтелгән. Бүлек ТАССР территориясенең географик картасы һәм статистик мәгълүматлар белән дә тулыландырылган.

Унберенче бүлек «Милли коммунизм һәм Татарстан АССР Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан» дип атала. Бу урында иң әүвәл Зөлфәтнең «Сак бул» шигыреннән алынган өзек белән танышабыз:

*Канатлы ат чаба җир буйлатып —*
*Азат җан ул — Хыял һәм Өмет!*

Бу бүлектә яктыртылган темалар: республикада татар телен гамәлгә ашыру буенча эшләр, татар теле терминологиясен тудыру буенча эшчәнлек, яңалифкә күчү, аны кириллицага алыштыру, культура революциясе, Үзәк һәм Татарстан, Татарстан коммунистларының партия оешмасы, Халык комиссарлары Советы, Үзәк Башкарма комитеты, РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Татар-башкорт бюросы, Сәетгалиев, Солтангалиев, «солтангалиевчелек» һәм аңа каршы көрәш, «Татар культурасы нинди юл белән барачак?» дигән мәсьәлә тирәсендәге бәхәсләр, татар әдәбияты һәм культурасының торышы һәм башкалар.

Егерменче еллар уртасында башланган террор нәтиҗәсендә татар халкы һәм аның культурасы күп югалтуларга дучар булды. Милли мәсьәләнең драматик авыр тарихы шушы чорга барып тоташа. Азад-Гайшә үзенең бу хезмәтендә менә шушы моментларны да әйтеп үтә. Шунысы игътибарга лаек, ул бу елларда татар халкы ирешкән культура уңышларын да таный, шул исәптән 1941 елда Мәскәүдә үткәрергә әзерләнгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы турында да яза.

Уникенче бүлек «Культура сыгылмалыгы һәм Икенче бөтендөнья сугышыннан соң милли үзаңлылык» дип атала. Биредә эпиграф итеп ике автор сүзләре китерелгән:

К. Мостафин: «Ватан да бер, Тукай да бер, әни дә бер».

Ә. Еники: «Сезне онытырга хакыбыз юк, аңлыйсызмы?» («Әйтелмәгән васыять»тән).

Бу соңгы бүлектә татар халкының саны, аның күпме өлеше чит регионнарда яшәве, татар мәктәпләренең хәле, анда укучыларның елдан-ел кимүе, матбугат-нәшрият эшләренең торышы, туган телдә китап басуның кимүе — кыскасы, хәзер без янып йөри торган мәсьәләләр турында сүз бара. К. Фасеевның һәм А. Калагановның «Коммунист Татарии» журналында басылган мәкаләләренә таянып, Татарстанда ислам диненең торышы, аңа каршы пропаганда, атеизм буенча укылган лекцияләр саны, Ишмөхәммәтовның Тукай атеизмына карата язган китабы турында әйтелә.

Бу бүлектә сугыштан соң татар әдәбиятының үсеше турында да шактый мәгълүматлар китерелгән. Ватан сугышыннан соңгы татар әдәбияты өлкәсендә уңышлы эшләп килүче Г. Бәширов, Н. Фәттах, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Ф. Шәфигуллин, М. Әгъләмов, Ш. Галиев, Зөлфәт, Р. Гәрәйләрнең исемнәре искә алына. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертүче галимнәрдән М. Гайнуллин, М. Мәһдиев, Х. Миннегулов һ. б.ның хезмәтләре күрсәтелә. Татар культурасын өйрәнү буенча Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының эшчәнлегенә уңай бәя бирелә, бу өлкәдә эшләүче А. Халиков, Р. Мөхәммәдова, М. Госманов, Ю. Мөхәммәтшин, Я. Абдуллин, С. Алишев, Ә. Кәримуллин, Ф. Вәлиев, Д. Вәлиева, Х. Хәсәнов исемнәре һәм хезмәтләре искә алына.

Азад-Гайшә татар халкының авыр елларында да үзенең милли культурасын, сәнгатен саклап кала алуын һәм киләчәктә дә яшәячәгенә ышаныч белдерә. Китапның исеме дә шуңа ишарә ясый, анда «Идел буе татарлары тарихы» дигән сүзләрдән соң китерелгән «Профиль ин нашионал ресайлиенс» дигән юлларны мин «Милли сыгылмалыкның профиле» дип тәрҗемә итәм.

Монография «Иомгаклау» сүзе белән тәмамлана. Кушымта итеп I-IV Дәүләт Думасының татар һәм башкорт депутатлары исемлеге (биографик белешмәләр белән), «Искәрмәләр», хезмәттә очраган «Исемнәрнең һәм төрле шәһәр, вакытлы матбугат, аерым оешмаларның алфавит күрсәткече» китерелгән. Китап ахырындагы библиография дә гаять бай, анда СССРда һәм Европа, Азия илләрендә бу темага каралган, кайберләре безгә дә билгеле булмаган диярлек хезмәтләр исемлеге китерелгән. Китап тарихыбызның төрле якларына бәйләнешле карталар, таблицалар белән баетылган.

Хезмәт авторның гаять эрудицияле галим булуы турында сөйли. Бу китап бай чыганакларга таянып язылган. Хезмәтнең төп максаты — татар халкының гражданлык, этник тарихын тасвирлау. Шуңа күрә, автор мәсьәләне Татарстан АССР кишлекләре белән генә чикләми.

Бездә СССР тарихын өйрәнүче чит ил галимнәрен советолог дип атыйлар. Бу исем астында аларга карата ышанмаучылык, аларның эшләрен шик астына алу кебек төсмер ята, кайвакытта бу исем яман мәгънәдә дә кулланыла. Соңгы елларда советологлардан кайсының кем икәнен аера башладылар. Элек заманнарда советолог дип аталган кайбер чит ил галимнәренең хезмәтләрен хәзер рус теленә тәрҗемә итеп басу эшенә дә керештеләр. Профессор Азад-Гайшә Рорлихның «Идел буе татарлары тарихы» битләрендә безнең илебезгә карата нинди дә булса яла ягуларны очратып булмый. Автор халкыбыз тарихының бик ачы хәлләрен язганда да объектив булырга тырыша. Халкыбызның теле, культурасы, мәктәбе, рухи мирасының язмышы турында матбугатыбыз битләрендә безнең күзебезне ача башлаган байтак мәгълүматлар игълан ителде. Аларда безнең хәлебез турында Азад-Гайшә хезмәтендә искә алынмаган бик күп нәрсәләр әйтелә. Аларның кайберләре галимәнең ошбу хезмәтендә дә чагылган икән, моннан чыгып без аны тенденциозлыкта гаепли алмыйбыз. Мин бу хезмәтне татар телендә бастырып

чыгаруны да яклар идем. Бай информацияле, халыкның этник һәм гражданлык тарихына караган бу хезмәт безнең өчен, укучыларыбыз өчен, һичшиксез, файдалы булыр.

Китап татар халкына хөрмәт белән сугыралган. Без авторның кем булуы белән дә кызыксындык. Ул Румыниядә татар гаиләсендә туган, Бухарест университетының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган. Аннан АКШның Висконсин-Мэдисон университетында стажировка үткән, бирелә Россия тарихы буенча диссертация яклаган. Хәзерге көндә, әйтеп үткәнчә, Лос-Анжелес шәһәрендәге Көньяк Калифорния университетында Россия тарихы буенча профессор булып эшли. Бик күп телләрне белә, шул исәптән Европадагы төп телләрне, рус, төрек, татар, гарәп, фарсы, борынгы төрки телләрне... Рун, гарәп графикасында укый һәм яза.

Аның беренче басма хезмәтләре Россия тарихына карый. Хәзерге вакытта, Россия тарихы белән беррәттән, Советлар Союзында исламның тоткан урыны һәм хәле турында лекцияләр алып бара. Соңгы елларда профессор татар халкының тарихы белән дә якыннан кызыксына. Югарыда телгә алынган китап әнә шул өлкәдәге эшчәнлекнең бер җимеше. Аның татар халкы тарихына, культурасына караган башка хезмәтләре-мәкаләләре дә бар.

Хәзерге вакытта профессор Азад-Гайшә Рорлих Россиядә революциягә хәтле яшәгән, эшләгән мәшһүр мөселман хатын-кызлары турында монография яза. Бу хезмәтне уңышлы башкарып чыгу өчен Азад-Гайшә ханым Казанга килергә җыена, архив һәм китапханәләрдә эзләнүләр алып бару, Казан белән танышу турында хыяллана.

---

## *Котлыйбыз!*

# Кыям Миңлебаевка — 60 яшь



Кыям Сәләхетдин улы Миңлебаев 1929 елның 25 июнендә Татарстан АССРның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туган. 1953 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган. Сарман урта мәктәбендә укыткан, 1955 елның көзеннән Татарстан китап нәшриятында эшли башлаган.

К. Миңлебаев — иҗади сәләтен тәрҗемә жанрына багышлаган профессиональ тәрҗемәче. Аның беренче тәрҗемә эше (П. Цвирканың «Сандугач» исемле җыентыгы) 1954 елда басылып чыга. Шуннан соң узган 35 ел эчендә К. Миңлебаев тәрҗемәсендә рус классикасы, чит ил әдәбияты һәм совет авторларының егермеләп китабы дөнья күрә: Л. Н. Толстой — «Балачак», «Үсмерчак», «Егетчак» (1955-57), «Яртыколак» (төркмән халык әкиятләре, 1958), В. Шишков — «Хәсрәт дәрьясы» (1963), А. Толстой — «Михнәтле заман» (1976, 1977, 1979), Э. Войнич — «Кигәвен» (1981), А. Толстой — «Аэлита» (1983) һ. б.

К. Миңлебаев тәрҗемә теориясенә һәм практикасына кагылышлы мәкаләләр, рецензияләр, сынлы сәнгатькә багышланган язмалар авторы. Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1980 елда РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

К. Миңлебаев — 1969 елдан СССР Язучылар союзы члены.

*Каләмдәшебезне 60 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз! Яңадан-яңа иҗат уңышлары һәм сәламәтлек телибез!*

**Җәүдәт Миңнуллин,**
тарих фәннәре кандидаты

# УТЫЗЫНЧЫ ЕЛЛАРДА...

Хәбәрдарлык һәм тормышны демократияләштерү соңгы еллардагы яшәешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып әверелде. Алар партиябез башлаган үзгәртеп коруның иң зур казанышларыннан саналырга хаклы. Үзгәртеп кору тарих фәне өлкәсендә дә зур үзгәрешләргә китерде, тарихыбызның билгесезлеге белән үзәккә үткән «ак таплар»ыннан арыну башланды. Эш шома гына бармый, әлбәттә. Күп кенә мөһим мәсьәләләр коллектив көч куюны таләп итә, шуның өстенә теге яки бу тарихи проблеманы тикшерү, аның нәтиҗәләре белән укучыларны таныштыру — шактый вакыт сорый торган катлаулы эш.

Укучыга тәкъдим ителгән бу язма да тарихыбызның моңа кадәр чагыштырмача аз яктыртылган бер өлкәсенә — утызынчы елларда кулъязма мирасыбызны өйрәнү һәм саклап калуга бәйле сәхифәләргә, шул өлкәдә эшләп фаҗигале рәвештә гомерләре өзелгән галимнәргә багышлана.

Көнчыгыш язмаларын, шул исәптән татар кулъязмаларын җыю һәм өйрәнүнең ике йөз елга якын тарихы бар. Нигезе күренекле галимнәр Ибраһим Хәлфин (1778-1829), Христиан Мартин Френ (1782-1851), Карл Фукс (1776-1846) һәм башкалар тарафыннан салынган татар археографиясенең барлык дәверләре дә бертигез өйрәнелмәгән әле. Бу җәһәттән караганда, СССР Фәннәр академиясе тарафыннан 1934 елда Татарстанга җибәрелгән археографик экспедициянең оешу тарихы һәм эшчәнлеге дә мәгълүм дәрәҗәдә әһәмияткә ия. Тарихи әдәбиятта бу экспедициянең оештырылуы турында төрле фикерләр яшәп килә. Мәсәлән, тарихчы Е. А. Серова аны, СССР Фәннәр академиясе инициативасы белән оештырылган, дип саный[1]. Күренекле татар археографы Сәет Вахидинең автобиографиясендә исә экспедициянең оештырылуы аның инициативасына кайтарып калдырыла[2]. Ләкин, милли тарихыбыз нигезен тәшкил иткән меңнәрчә кулъязмаларны, документаль чыганакларны җыеп фәнни оешмаларга бүләк иткән бу затның фидакарь эшчәнлеген тәкъдир иткән хәлдә дә, без әлеге раслау белән килешеп бетә алмыйбыз. Чөнки СССР Фәннәр академиясенең 1934 елда Татарстанга оештырылган әлеге экспедициясе 20-30 елларда илебездә һәм шул исәптән Татарстанда барган күп кенә фаҗигале хәлләргә, төрле политик процессларга бәйле. Экспедициянең оешуын һәм эшчәнлеген бары тик шул вакыйгалар җирлегендә генә тулырак аңларга мөмкин.

Егерменче-утызынчы еллар башы көнчыгыш, шул исәптән татар кулъязмалары яшәешендә иң авыр вакытларның берсе була. Бу хәлнең тууы түбәндәгеләргә бәйле иде. Беренчедән, ул елларда татар әлифбасын латин графикасына күчерү нәтиҗәсендә, гарәп язулы татар кулъязмалары һәм басма китаплары үзләренең моңа кадәр мең ел буе үтәп килгән вазифасын югалта. Дәүләт оешмаларында, уку-укыту, фән, сәнгать, әдәбият — гомумән, җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә диярлек гарәп язулы басмалар кирәксезгә әверелә, үги хәлгә куела.

Икенчедән, егерменче-утызынчы елларда чын мәгънәсендә фәнни-атеистик булырга тиешле эш ил күләмендә формаль рәвештә алып барылган «ура-атеизм» политикасы, искелек калдыгы дип игълан ителгән гарәп язулы китапларга каршы көрәш белән алыштырылды. Нәкъ шушы елларда — меңәрләгән мәчет манаралары киселгәндә, мәдрәсәләр ябылганда — халкыбызның йөзләрчә еллар дәвамында тупланып килгән кулъязма байлыгы йөге-йөге белән яндырылды, җиргә күмелде, туздырылды.

Өченчедән, «солтангалиевчелек» дигән политик уйдырма хәрәкәтне тар-мар итү вакытында да кулъязма мирасыбызга зур зыян ясалды. Тора-бара эш шуңа барып җитә ки, гарәп хәрефләре белән язылган китап саклаучыларны солтангалиевчелектә гаепли башлыйлар. Әйтерсең лә В. И. Ленин әсәрләре, партия-совет документлары әле кайчан гына шушы хәрефләр белән басылмаган?! Әнә шул солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынган татар галимнәренең шәхси китапханәсендәге кулъязмалар да (ә алар, әлбәттә, иң кыйммәтле дигән әсәрләрне саклаганнар) эзсез югала.

Дүртенчедән, кулъязма мирасыбызга иң зур удар Сталинның шәхес культы елларын-

---

[1] Серова Е. А. Историко-археографический институт Академии наук СССР (1931-1936 гг.)— К-та: История и историки. Историографический ежегодник. 1976, М., 1979, 70 б.

[2] СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге, Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 111 ф., 1 тасв., 19 эш, 5 б. (Алга таба: Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы).

дагы репрессияләре, бигрәк тә авыл хуҗалыгын коллективлаштыру һәм «кулакны сыйныф буларак бетерү» кампаниясе чорында ясала. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, кулъязма мирасыбызның шактый зур өлеше нәкъ менә шул елларда юк ителә.

Егерменче еллар азагында һәм утызынчы еллар башында уздырылган макулатура җыю кампаниясе дә архив документларының күпләп юкка чыгарылуына өлешчә булышлык иткән. 1928 елның 20 декабрендә илдәге бөтен оешмаларга һәм предприятиеләргә кәгазь макулатурасын, шул исәптән «фәнни һәм практик әһәмияте булмаган» архив документларын да Бумсиндикатка тапшырырга әмер бирелә[3]. Бу карар үзәктә дә, урыннарда да үтә зур тырышлык белән тормышка ашырыла. Шул чордагы архив хезмәткәре А. Максимов бу кампаниянең Татарстан Үзәк Дәүләт архивында уңышлы алып барылуын, кәгазь промышленностена планда каралган 95 тонна урынына 103 тонна 247 килограмм архив документлары тапшырылуын хәбәр итә[4]. Тонналаган архив материалларын макулатурага бу рәвешле тапшырганда бик кыйммәтле документаль чыганакларның да юкка чыгарылуы көн кебек ачык. Ул вакытта архив материалларына фәнни экспертиза ясарлык махсус хезмәткәрләренең бармак белән санарлык булуын да истән чыгармыйк. Шул ук А. Максимов язуынча, 1930 ел ахырында Свияжск районы җыеп тапшырган 7,5 тоннага якын архив документлары арасында «мәңге саклanyрга тиешле»ләре дә булган.

Кулъязмаларга, архив документларына карата булган мондый наданлык тарихчыларны һәм, гомумән, фән эшлекләләрен борчымый калмаган, әлбәттә. Шуңа күрә тарихчы-марксистларның 1928 ел ахырында һәм 1929 ел башында булып узган Беренче Бөтенсоюз конференциясе тарихи кыйммәткә ия булган архив материалларын саклап калу турында махсус резолюция кабул итә. «Архивны юк итү җиңел. Яңадан торгызу мөмкин түгел»,— дип язылган конференция резолюциясендә[5].

Кыскасы, тарихи чыганакларның мөһим өлешен тәшкил итүче кулъязма ядкарьләр, табигый хәвеф-хәтәрләр тәэсиренә караганда, егерме-утызынчы елларда күбрәк ясалма, субъектив сәбәпләр аркасында юкка чыгарылган. Һәм менә шул югарыда бәян ителгән сәбәпләр Татарстанга кулъязма истәлекләрне җыю буенча махсус археографик экспедиция оештырылуга нигез булган.

Көнчыгыш телләрендә язылган кулъязмаларның күпләп юк ителүе хакындагы хәбәрләр утызынчы еллар башында төрле яклардан (Урта Азия, Идел буе, Урал) СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтына, академик А. Н. Самойлович җитәкләгән Урта Азия кабинетына килә башлый. Көнчыгышны өйрәнү институты хезмәткәре, күренекле галим Е. Э. Бертельс мәгълүматларына караганда (ул 1930 елда Урта Азиядә командировкада булып кайта), кайбер бик тә кыйммәтле, уникаль кулъязмаларның чит илләргә озатылуы билгеле була. Ул вакытта СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары башлыгы, ягъни мөфти булып хезмәт итүче күренекле татар галиме, язучы, журналист, мәгърифәтче Риза Фәхретдинев 1932 елның 7 августында СССР Фәннәр академиясе Президиумына хат белән мөрәҗәгать итә[6]. Ул, Фәннәр академиясенең игътибарын уникаль кулъязмалар сакланган шәхси китапханәләрнең юкка чыгарылу фактларына юнәлтеп, исән калган кулъязмаларның аеруча кыйммәтлеләрен булса да саклап калырга өнди. Кыйммәтле кулъязмалар саклаучы шәхси китапханәләр җөмләсеннән Р. Фәхретдинев Татарстанның Түнтәр авылындагы Гали ишан, Бөре өязендәге Учбуле авылындагы Тупиевлар, Саратов губернасы Кузнецк өязе Пенделка авылындагы Дебердиевлар, Сембер губернасы Карсун өязе Гурьевка (Биябашы) авылындагы Хәсән Акчуриннар китапханәләрен саный. «Түбән өязе Малчын авылындагы Сәйдуковлар китапханәсендә Багдадта Габбасилар дәверендә язылган кулъязмалар булуы турында мәгълүматлар бар»,— дип яза Р. Фәхретдинев. Шунысын да әйтергә кирәк, Октябрь революциясенә кадәр үк армый-талмый халкыбыз тарихын өйрәнүче, ун ел буе үз редакторлыгында чыгып килгән «Шура» журналы аша укучыларны татар кулъязмаларын, документаль чыганакларны җыярга, сакларга чакыручы Р. Фәхретдиневнең бу мөрәҗәгать хатын галимнең совет чорында кулъязма мирасыбызны саклауга юнәлдерелгән иң соңгы өндәве диярга дә ярый.

Соңгы вакытларда мәгълүм булганча, 1925 елның февраль азакларында Риза Фәхретдинев Казанга килә һәм Татарстан хөкүмәте вәкилләре белән рәсми очрашулар үткәрә. Әлеге сөйләшүләрдә һәм шулай ук Г. Ибраһимов фатирында булган очрашуда да Р. Фәхретдинев дини оешмаларның эшчәнлеге, аларның дәүләт органнары белән мөнәсәбәте, дин әһелләренә карата законлылыкны саклау һәм башка мөһим мәсьәләләр белән бергә борынгы кулъязмаларның кайбер очракларда конфискацияләнеп юкка чыгарылуы, шәхси китапханәләрнең туздырылуы турында да ачынып сөйли. Һәм хөкүмәт вәкилләре-

---

[3] Максаков В. В. История и организация архивного дела в СССР 1917-1945. М., 1969, 215 б.

[4] Максимов А. Работа Татцентрархива в 1931 г.— «Архивное дело», Вып. III-IV. М., 1932, 89 б.

[5] Труды Первой Всесоюзной конференции историков-марксистов. т. 2. М., 1930, 613 б.

[6] Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 152 ф., 1 а тасв., 308 эш, 4-5 б.

нең, галимнәрнең игътибарын янә бер кат кулъязма мирасны саклауга юнәлтә[7]. Бер елдан соң, шушы очрашуларда катнашкан һәм ул елларда Гыйльми Үзәкне җитәкләгән Г. Ибраһимовның кулы куелган документ — «Төрек-татар һәм Көнчыгыш кулъязмаларын җыю турында» өндәмә-мөрәҗәгатьнең басылып чыгуы очраклы хәл түгел, әлбәттә. («Кызыл Татарстан», 1926, 15 июнь). Шул ук 1925 елда, Уфада, Диния нәзарәтының таш биналарын бушатырга дигән боерык булгач, Р. Фәхретдинев шәһәр комитетына мөрәҗәгать итеп, киләчәк буыннар өчен әһәмиятле фәнни чыганак булган 68250 берәмлек архив материалларын саклап калуга ирешә. Ә. Хәйруллин язганча, галимнең «шушы олы хезмәте генә дә фәнни һәм граждалык батырлыгы булып тора». («Казан утлары», 1984, 1 сан, 162 б.).

Р. Фәхретдинев белән электән үк таныш һәм дустанә мөнәсәбәттә торган академик А. Н. Самойлович, галимнән хат алгач, Көнчыгышны өйрәнү институты директоры академик С. Р. Ольденбургка мөрәҗәгать итеп, 1933 елда Идел буена һәм Урта Азиягә борынгы кулъязмалар җыю буенча ике экспедиция оештырырга тәкъдим итә[8]. Үз чиратында академик Ольденбург, 1933 елның 21 маенда СССР Фәннәр академиясе президиумына мөрәҗәгать итеп, Идел буена һәм Урта Азиягә оештырылачак экспедицияләрне акча белән тәэмин итүне сорый[9].

Шул ук вакытта, ягъни 1933 елның маенда, СССР Фәннәр академиясе секретаре академик В. П. Волгин да ВКП(б) Үзәк Комитетының культура һәм пропаганда бүлегенә хат җибәрә[10]. Көнчыгыш телләрендә язылган борынгы кулъязмаларның юк ителүен, шәхси китапханәләрнең туздырылуын билгеләп үтеп, В. П. Волгин СССР Фәннәр академиясенең коммунистик фракциясе исеменнән барлык милли республикалар һәм өлкәләрнең партия, совет органнарына хат җибәреп кулъязмалар җыю, аларны саклау өчен кешеләр һәм средстволар бүлеп бирүне, фән өчен аеруча кыйммәтле кулъязмаларны сатып алуны, шулай ук Академия тарафыннан шушы максат белән Урта Азиягә, Идел һәм Урал якларына җибәрелгән белгечләргә ярдәм итүне сорый. В. П. Волгинның мөрәҗәгате дә Көнчыгышны өйрәнүче галим Е. Э. Бертельс мәгълүматлары һәм Р. Фәхретдинев хатына таянып язылган. Әмма күрсәтелгән төбәкләргә 1933 елда экспедицияләр җибәрелми кала.

1934 ел башында Казаннан күренекле археограф-тарихчы Сәет Вахиди озак еллар буе Татарстанда җыйган кулъязмаларны Көнчыгышны өйрәнү институтына бүләк итәргә теләвен хәбәр итә. Кулъязмаларны кабул итү һәм Ленинградка җибәрү өчен Казанга академик А. Н. Самойловичның шәкерте, татар халык шагыйре Г. Тукайның туганнан туган энесе Вәли Габдрахман улы Зәбиров килә. С. Вахиди җыйган кулъязмаларны кабул итү һәм Ленинградка җибәрү белән бергә, 1934 елның маенда В. Зәбиров Казандагы фәнни оешмаларның архивлары, кулъязма фондларының торышы һәм XIX-XX гасыр башы татар галимнәренең, әдипләренең шәхси китапханәләре язмышы белән дә ныклап кызыксына. Кулъязма, архив фондларының торышын өйрәнү нәтиҗәсендә, ул Көнчыгышны өйрәнү институты директоры урынбасары П. И. Воробьевка, Тарих комиссиясе председателе академик В. П. Волгин, Ленинградтагы Тарих-археография институты директоры С. Г. Томсинский һәм ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты культура һәм пропаганда бүлеге мөдире И. Рәхмәтуллинга доклад язмасы җибәрә[11]. Әлеге документта С. Вахидинең археографик эшчәнлеге турында яза һәм аның тарафыннан Көнчыгышны өйрәнү институтына тапшырылган кулъязмаларга кыскача күзәтү ясый. Бу документта шулай ук борынгы татар китапханәләре турында да шактый мәгълүматлар тупланган, аларның соңгы дәвердәге язмышлары тасвирланган. Мәсәлән, хәзерге вакытта Татарстанның Кукмара районына кергән Түнтәр авылындагы китапханәгә моннан өч гасыр элек нигез салынган, дип яза В. Зәбиров. Инде әйткәнебезчә, коллективлаштыру һәм «кулакларны сыйныф буларак бетерү» дәверендә шәхси китапханәләр бигрәк тә аяныч хәлдә кала. Алардагы хәзинәнең күп өлеше район һәм авыл советы башкарма комитетлары тарафыннан макулатурага тапшырылган. Шул ук вакытта Зәбиров кулъязмаларның сан ягыннан аз булса да, сыйфат ягыннан караганда кыйммәтле өлеше төрле юллар белән сакланып калынганлыгын да хәбәр итә.

Әлбәттә, борын-борыннан язулы, китаплы халык булган татарларда төрле-төрле гарасатлардан соң да кулъязма китаплар сакланып калган. Казан дәүләт университеты белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтларының алтмышынчы еллардан бирле даими эшләп килгән археографик экспедицияләр эшчәнлеге әнә шуны күрсәтә.

В. Зәбиров язмасыннан күренгәнчә, Казандагы кайбер фәнни оешмалар хосусый китапханәләрне оешкан төстә «үзләренә алу» белән дә шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, рес-

---

[7] Султанбеков Б. Попытка диалога — «Вечерняя Казань», 1989, 10 февраль.

[8] Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 152 ф., 1 а тасв., 319 эш, 59 б.

[9] Шунда ук, 308 эш, 1 б.

[10] Шунда ук, 152 ф., 1 а тасв., 308 эш, 3-3 а б., 429 эш, 1-3 бб.

[11] Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивы, 152 ф., 1 а тасв., 72-29 бб.

публиканың Үзәк фәнни китапханәсенә Түнтәр авылындагы укымышлы Нәҗип Түнтәри китапханәсенең бер өлеше, Кышкардан Исмәгыйль Утәгәнев китапханәсе, күренекле татар тарихчысы Хәсәнгата Габәши китапханәсе һәм Казанда Казаковлар китапханәсе алынган. ОГПУ органнары тарафыннан да кайбер шәхси китапханәләр хуҗалары белән бергә «кулга алынганнар». В. Зәбиров мәгълүматларына караганда, 1934 елларда Татарстанның ОГПУ органнарында күренекле татар галимнәре Габденнасыйр Курсави һәм Һади Атласи китапханәләре сакланган. Солтангалиевчелектә гаепләнеп репрессияләнгән галимнәрнең (Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Юнысов һ. б.) шәхси китапханәләрендә дә кулъязмалар күп булган. Шул ук документта В. Зәбиров ул вакытта Казандагы фәнни оешмаларның кулъязмалар фондына кыскача бәя бирә һәм борынгы мирасны өйрәнүче үзәк булмавын, эшнең плансыз алып барылуын, кулъязмаларның төрле оешмаларга сибелүен һәм шулай ук аеруча кыйммәтле кайбер кулъязма истәлекләрне урлау очракларын да күрсәтеп уза. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, В. Зәбиров 1934 елның җәендә Татарстанга көнчыгыш кулъязмаларын җыю буенча археографик экспедиция оештырырга тәкъдим итә. Моннан тыш галим ВКП(б) Үзәк Комитеты каршына ОГПУ органнары тарафыннан алынган барлык көнчыгыш кулъязмаларын Фәннәр академиясенә тапшыру, РСФСР һәм Татарстан хөкүмәтеннән Казандагы кулъязма чыганакларны саклау һәм фәнни эшкәртү мәсьәләләрен тәртипкә салуны таләп итү мәсьәләсен дә куя. Шулай ук Көнчыгышны өйрәнү институтында саклanучы татар кулъязмаларын тикшерү эшен кичектермичә тормышка ашырырга кирәклеген да билгеләп үтә.

В. Зәбиров тарафыннан язылган әлеге доклад язмасын алган академик В. П. Волгин тиешле тәкъдимнәр белән яңадан РСФСР һәм Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советларына мөрәҗәгать итә. Бары тик шушы күмәк тырышлык нәтиҗәсендә генә мәсьәлә уңай хәл ителә һәм Татарстанга СССР Фәннәр академиясенең археографик экспедициясе җибәрелә. Составында В. Зәбиров һәм С. Вахиди булган бу экспедиция Казанда, Арча, Биектау, Балтач районнарында ике ай чамасы эшли, 1203 кулъязма, бер мең данә чамасы документаль чыганаклар, 1859 басма китап җыела һәм Көнчыгышны өйрәнү институтына, Ленинградка җибәрелә. Экспедициянең эше урып-җыю вакытына туры килгәнгә күрә төрле кыенлыклар килеп чыга, кулъязмаларны җибәрү өчен транспорт һәм эрҗәләр җитми. Экспедиция эшенә халыкның мөнәсәбәте дә төрлечә була. Берәүләр галимнәргә теләп булышсалар, икенчеләре — дингә каршы көрәш кампаниясе, солтангалиевчелек карачкысы белән куркытылганнары — шикләнеп карыйлар. «Халык бик сак. Күпләр счет яки расписка бирү түгел, фамилияләрен атарга да теләмиләр»,— дип яза В. Зәбиров Г. Папаянга адресланган хатында. Шул ук вакытта Зәбиров экспедиция эшенә «җирле органнар, бигрәк тә НКВД дустанә мөнәсәбәттә тора һәм булышлык итә»,— дип яза[12]. Экспедиция тарафыннан җыелган материаллар турында сөйли башласаң, сүз озакка китәр иде. Аларга кыскача күзәтү ясап, В. Зәбиров матбугатта чыгыш та ясаган[13]. һәм СССР Фәннәр академиясенең 1934 елгы декабрь сессиясендә экспедиция эше белән фәнни җәмәгатьчелекне дә таныштырган була.

Әлеге экспедициянең уңышлы нәтиҗәләре Фәннәр академиясенә киләчәктә археографик тикшеренү эшләрен планлы рәвештә алып барырга һәм кулъязмалар җыюны Татарстан белән генә чикләмичә башка төбәкләргә дә җәелдерергә нигез биргән. Әйтик, 1935 елда В. Зәбиров Әстерхан — Уральск — Оренбург — Троицк — Орск маршруты буйлап археографик сәфәргә чыга һәм берничә йөз борынгы кулъязманы эзсез югалудан саклап кала. 1936 елда да Зәбиров төрле төбәкләрдә татар кулъязмалары җыярга әзерләнә. Фәнни оешмалар белән килешүләр төзелә. Әмма бу елда аңа зур иҗат планнарын тормышка ашырырга насыйп булмый. Шәхес культының җан өшеткеч җилләре Көнчыгышны өйрәнү институты коридорларында да исә башлый. Бер-бер артлы академик А. Н. Самойлович, аннары В. Зәбиров гаепсезгә кулга алынып юк ителәләр. Казанда С. Вахиди да кулга алына.

Шуннан соң милли-мәдәни тарихыбызның нигезен тәшкил иткән кулъязма мирасны планлы рәвештә, экспедиция ысулы белән җыю һәм өйрәнү эше алтмышынчы еллар башына кадәр тукталып кала.

---

[12] Көнчыгышны өйрәнучелер архивы, 152 ф., 1 а тасв., 353 эш, 50-50 а битләр.

[13] Забиров В. А. Предварительное сообщение о работе Археографической экспедиции Академии наук.— К-та: Исторический сборник. М.-Л., 1934, № 4, 269-282 бб.

# ЯШЬ ДУСТЫМ ФАИЛ

Фаил Шәфигуллин безнең әдәбиятыбызга алтмыш бишенче елларда килде. Аның шигырьләрендә башкалардан бер кадәр аерылып торган шәһәр күренеше, завод цехлары, эшче кешеләр гәүдәләнде. Чөнки ул, үзе эшче буларак, үз мохитен дөрес итеп чагылдырырга, шуннан шигърият табарга, аны гади һәм колоритлы итеп, ачык төстәге буяулар белән сурәтләүгә зур әһәмият бирә иде. Бу юлда ул, кайберәүләрнең бик үк урынлы булмаган тәнкыйтьләренә карамастан, шактый уңышларга ирешә. Дөрес, болар әле беренче уңышлар, беренче адымнар иде.

Бу җәһәттән аның: «Завод җыры», «Кою цехында», «Тимер» дигән шигырьләре игътибарга лаек. Ә тагын «...Төнге күктән атылып төште яшен», «Мәңгелек ут», «Кызык хәл», «Бәхәс», «Ел фасыллары» кебек шигырьләре Фаилнең нечкә хисле, сизгер, йомшак күңелле, тирән фикерле, ә кайчакта фәлсәфи авазлы шагыйрь икәнлеген дә әйтеп торалар.

Аннан миңа Фаилнең «Бәхет йолдызы астында» исемле повестен рәхәтләнеп, бер утыруда укып чыгарга туры килде. Монда автор, туган халкы кебек, авылдан аерылып, вакытлыча, хуҗалык өчен акча юнәтергә дип ерак диңгез буйларына эшкә киткән бер егет хәлләрен сөйли. Мин бу повестьны укыгач Фаил өчен чын күңелдән шатландым. Шагыйрь кеше үзен әдәбиятның һәр жанрында да үз өендә кебек иркен һәм ышанычлы итеп тоярга тиеш. Менә бу повесть шуның бер дәлиле инде, дип нәтиҗә ясадым.

Шулар белән бергә, Фаилнең иҗаты сатира-юмор ягыннан да ачылып китте. «Чаян» журналында эшли башлау белән ул жанр анда тагы да активлашып, камилләшеп мәйданга чыкты. Аның бу төр иҗаты безнең олы язучыларыбыз тарафыннан төрле чыгышларда булсын, төрле рецензияләрдә булсын мактаулы бәя алды. Шагыйрь дә, хикәяче дә, сатирик та булып Фаил Шәфигуллин күз алдыбызда үсте, көннән-көн яңарды, олыгайды. Арабызда ун елга якын бергә хезмәт иткән, станоктан әдәбиятка килгән, чын иҗат юлына аяк баскан талантлы яшь дустыбыздан безгә кинәт, көтмәгәндә мәңгегә аерылырга туры килде. Аның һәлакәте мине бик борчыды... Минем өчен дә, әдәбиятыбыз өчен дә бик үкенечле югалту булды.

Мин әле һаман да Фаилне бик сагынып искә алам. Хәзер аның урынында «Чаян» журналы редакциясендә шулай ук талантлы яшь дусларымнан берсе Зөлфәт утырса да, редакциягә килгән саен Фаилне бик юксынам... Шулай шул, һәр эштә, һәркемне алыштырып була, ләкин иҗат эшендә беркемне дә алыштырып булмый. Андыйны, күпме эшләү һәм яшәвенә карамастан, шәхес буларак алыштырып булмый: аның үз урыны, үз иҗаты, үз аһәңе бар. Ә ул — гомерлек!

Фаилне мин беренче тапкыр Зеленодольск шәһәрендә күрдем. Шәһәрнең культура сараена, без, берничә язучы, әдәби кичәгә барган идек. Шунда, кичәдән соң, мине Фаил белән олы язучыбыз Идрис Туктар ага таныштырды. Уртадан беркадәр тәбәнәгрәк буе, Мефистофельнекенә тартым кылыч борыны һәм күзләре, бераз кыюсызлыгын сиздереп торган үзен тотышы белән ул һаман күз алдымда.

Идрис Туктар ага миңа:

— Менә, Арслан, теге мин әйткән бик талантлы эшче егет Фаил Шәфигуллин шушы була инде,— диде.

Шуннан беркадәр вакыт үткәч ул «Казан утлары» редакциясенә — минем янга килде. Шигърият бүлегенә шигырьләр китергән икән. Шулай итеп без аның белән якыннан танышып киттек.

Алтмыш дүртенче еллардан башлап «Казан утлары»ның шигърият бүлегендә эшләгәнгә күрә, яшьләрдән минем дусларым күбәйде. Шулар арасында Фаил дә беренчеләрдән иде. Редакциядә мин яшьләр белән сигез ел эшләдем. Шул вакыт эчендә без бик якын кешеләргә әйләнеп киттек. Мин яшьләрне яшьсенмәгән кебек, алар да мине картсынмадылар. Миңа инде ялга чыгар вакыт җитеп, редакциядән киткәч тә, безнең аралашу дәвам итте. Бик еш бергә җыелып, төрле хәлләр турында сөйләшә идек.

Мондый вакытларда әдәби мәсьәләләр турында сөйләшүләр дә сирәк булмады. Гәпләшүләр, җыелышлардагы шикелле рәсми төс алмаганга күрә, үтемлерәк, тәэсирлерәк, кызыклырак була иде.

Бервакыт мин шулай, эш көне азагына таба, «Чаян»га килеп, өстемне Фаилләр бүлмәсендә салдым да, «Ялкын» редакциясенә җыелган бер төркем яшьләр янына юнәлдем. Бер кадәр вакыт үткәннән соң, гәпнең иң кызган чагында, ишектән берәү килеп керде. Эшләпәсен күзләренә басып кигән, өстендә үзе кадәр ике кеше сыярлык кара куртка, аның чабулары тезеннән түбән, кулына таяк тоткан... Туктале, бу минем таяк түгелме соң?! Әйе, бу минем таягым, минем курткам, минем эшләпәм иде. Җыелганнар бер тавыштан хахылдап көлеп җибәрделәр: Фаил мин булып киенеп кергән икән. Башта керүченең карикатуралы шәкеленә күбрәк игътибар биргәнгә күрәдер, размеры белән Фаил өстендә бөтенләй ят төскә кергән киемнәремне үзем дә кинәт таный алмадым. Менә ул миңа охшатып, шау-шуны басарга тырышып, калын тавыш белән:

— Исәнмесез, җилкуарлар!— дип исәнләште дә, эшләпәсен салып, үзе шаркылдап көлеп җибәрде. Башыннан салгач, куртка тагы да зуррак булып күренде. Туйганчы рәхәтләнеп көлештек.

Бервакыт, ниндидер бәйрәмгә журнал өчен «Чаян»ча котлау кирәк булып чыкты. Бик тәгаен вәгъдә итмәсәм дә, үтенгәч бер көйле әйбер язып китердем. Редакциянең җаваплы секретаре Мәгъсум Хуҗин да шунда иде. Фаил кульязманы карады да:

— Нури абый, бу бит «Чаян»ча килеп чыкмаган, моны теләсәң кайсы газетага биреп була, көлкесе юк, җитди плакат!— диде.

Мин аның шулайрак икәнен үзем дә сизенгән идем, каршы бер сүз дә әйтмәдем. Күпмедер вакыттан соң тагын шул ук редакциядә шундый ук хәл булды. Бу юлы котлауны Фаил үзе язган иде. Укыды.

— Ничек, Нури абый?— диде.

Котлау «Чаян»ча чыкмаган иде. Мин:

— Бу нәкъ теге бәйрәмдә мин язган котлау шикеллерәк килеп чыккан икән,— дидем.

Мәгъсум Хуҗин сәер елмаеп Фаилгә карады. Фаил шаркылдап көлеп тә җибәрде, кульязмасын ерткалап, чүплек кәрзиненә дә ташлады. Әдәби мәсьәләләрдә безнең арада шулай бернинди тәкәллефсез, ачыктан-ачык мөнәсәбәт гел яшәп килде.

Бервакыт телевидениедән юбилеема мине телевизион язмага алабыз дип хәбәр иттеләр һәм үзем белән бергә ике яшь шагыйрьне дә алуымны үтенделәр. Уйлап та тормыйча Фаил белән Зөлфәтне сайладым. Сәгате килеп җиткәч, без өчәүләп, әлеге тавышлы һәм хәрәкәтле рәсемгә төшерә торган тылсымлы аппаратлы машинага утырып, Казанның төрле урыннарына бардык, агачлыкта, чишмә буйларында булдык. Шулай итеп бергәләп тасмага язылдык. Ул тасма хәзер фондта хатирә булып саклана. Ихтыяҗы чыккан саен, сирәк булса да, телевидениедән күрсәтелә. Минем өчен ул тылсымлы язма бәя биреп бетермәслек хатирә булып калды.

Әйе, ярата иде Фаил Нури абыйсын, мин аны яраткан кебек үк ярата иде. Фаилнең хикәясендә кечкенә куллы көчле бер абзый сурәте бар. Үзем түгел микән бу дип шикләнеп, мин аннан:

— Ул абзыең ниндирәк кеше иде?— дип сораштыргалый идем.

Мондый вакытларда Фаил җавап кайтармый, тик бик серле итеп, минем кулларыма карый да, Мефистофельчә елмая гына иде.

**Нури АРСЛАНОВ.**



## *Татар халык музыка уен кораллары*

# ГӨСЛӘ ҺӘМ ЯТАГАН

Гөслә күп төрле халыкларның яраткан уен коралы. Татарларда да гөслә элек-электән үк кулланышта булган. Гөслә җырчыларга, бәет, мөнәҗәт әйтүчеләргә кушылып уйнау, шулай ук инструменталь көйләр башкару өчен дә кулланылган.


XVI йөздә билгесез бер рус авторы егерме еллар чамасы татарлар арасында яшәү дәверендә Казан татарларының гореф-гадәтләрен, көнкүрешен өйрәнә: «Казанлылар... үзләренең гөсләләрендә уйнап... күңел ачалар, биниләр, тирә-юнь шаулап, гөрләп тора»,— дип язып калдыра.

Татар халкы гөсләдә бүгенге көндә дә яратып уйный. Бигрәк тә ул Казан арты авылларында сакланып калган. Татарстанның Арча районы Сәрдәбаш, Носы, Балтач районының Субаш, Дорга, Кукмара районының Янил, Чура авылларында бик матур итеп уйнаучы апалар һәм гөслә ясаучы осталар бар. (Мәсәлән, Арчада Р. Алмаев, Субашта А. Семенов, Әгерҗедә Г. Волков.)


Татарларда гөслә уйнауның буыннан буынга сакланып килгән традицияләре булган. Уйнау алымнары, тавышларының көйләнелеше, формасы буенча ул бүтән халык гөсләләреннән аерыла. Тарихи чыганакларга караганда татар гөсләләре берничә төрле булган. Унике кыллы кече гөслә, егерме дүрт кыллы зур гөслә һәм гөсләгә охшаш уен коралы ятаганның булуы турында мәгълүматлар бар.

Кече гөслә ярым ай рәвешендә эшләнелә. Ясау өчен озак еллар дәвамында күләгәле урында киптерелгән өрәңге, чыршыдан 2-3 мм калынлыкта такталар хәзерлиләр. Билгеле зурлыкта хәзерләнгән такталарны бер-берсенә агач җилеме яки эпоксид сумала ярдәмендә тоташтыралар. Гөсләнең дугаланып килгән ян-як стенасы 86-87 см озынлыкта, 9-10 см киңлектә тоташ өрәңге агачыннан эшләнә. Аны кирәкле формага китереп бөгәр алдыннан кайнар суга салып пешекләргә кирәк.


*Гөсләне җыйнау түбәндәге тәртиптә башкарыла.* Аскы тактага ян стенаны һәм алгы тактаны ябыштыралар. Авыр әйбер белән бастырып биш-алты сәгать киптерәләр. Өске тактаның эчке өлешенә ныграк агачтан ныгытма куела. Кылларны тарттыргач өске такта бөгелмәслек булсын. Аннан соң өске тактаны ябыштыралар. Тагын берике көн җил керми торган бүлмәдә киптергәннән соң агачның үз төсе калганчы чистарталар һәм төссез лак белән лаклыйлар. Өске тактаның уртасына резонатор өчен зур булмаган тишем тишелә. Гөсләнең сул ягына 15 мм биеклектә каты агачтан ясалган күтәртмә, икенче ягына боргычлар куела. Боргычлар урынына электр гитарасы яисә пианино боргычларын файдаланырга мөмкин.




Гөсләнең өске күренеше





Гөсләнең аскы күренеше





Гөсләнең алгы күренеше

Гөсләнең өске өлешенә төрле озынлыктагы һәм төрле калынлыктагы барысы унике металл кыл тарттырыла һәм билгеле бер музыкаль тавыш югарылыгына көйләнелә. Көйнең характерына карап кече гөсләне ике төрле ладка көйлиләр.



Мажор пентатоникасы




Минор пентатоникасы


Беренче кылдан алып тугызынчы кылга кадәр мандолинаның иң нәзек кылын, ә инде ун, унберенче һәм уникенче кылларга гитараның дүртенче кылын куярга мөмкин.

Гөсләдә, утырып, ике кул белән берьюлы уйныйлар. Гәүдәне төз, иркен тотарга, башны аска бик имәскә кирәк. Музыкаль тавышны бармаклар белән чиертеп чыгаралар. Уен алымнары күп төрле: уң кул бармаклары көй, ә сул кул бармаклары аккомпонемент уйный; берничә кылны берьюлы чиертеп уйнау (аккорд); аккордларны таркатып уйнау (арпеджио); кулланылмаган кылларны сул кулның бармаклары белән каты басмыйча гына тотып, сүндереп, ачык кылларны уң кулның бармагы яки медиатор белән аска һәм өскә шудыртып чиертеп чыгу (глиссандо) һәм башка шундый алымнар.

Егерме дүрт кыллы зур гөслә Таҗетдин Ялчыгол сызымында күренгәнчә әчпочмаклы булган. Кыллары диатоник, ягъни җиде тавышлы ладка көйләнелгән.

Соңрак чорга караган мондый төр гөсләләрнең бер варианты Татарстан АССР Дәүләт музеенда да саклана. Түбәндә шул гөсләнең рәсеме һәм кылларының көйләнелеше бирелә.





Диапазоны кече октаваның до диез тавышыннан алып, өченче октаваның фа диез тавышына кадәр. Көйнең характерына карап кылларның көйләнелешен үзгәртергә дә мөмкин.

Зур гөслә соңгы вакытта кулланудан бөтенләй төшеп калган. Аны хәзер шушы күрсәтмәләрне истә тотып яңадан эшләргә кирәк. Эшләү алымнары нәкъ кече гөслә ясагандагы кебек, тик күләме генә зуррак.

Бик борынгы заманнарда ук төрки халыклар арасында күп төрле кыллы музыка уен коралларының булуы мәгълүм. Алар төзелешләре буенча бик гади булганнар. Мәсәлән, ятаган тоташ агачтан тагаракка охшатып ясалынган һәм аңа кылны боргыч ярдәмендә тарттырып түгел, ә бәлки бәйләп кенә куя торган булганнар. Һәр кыл астына аерым-аерым куелган күтәртмәләр (мендәрчекләрне) шудыртып кылларны кирәкле тавыш югарылыгына көйләп булган. Бу төр уен кораллары шулай ук борынгы болгарларда да кулланылган һәм хәзерге көнгә кадәр сакланып килгән.

XVIII йөздә Идел-Урал, Себер якларын өйрәнүче сәяхәтче галимнәр И. Лепехин, П. Паллас, И. Георги, П. Рычков хезмәтләрендә бу төр җиде кыллы уен кораллары турында күп тапкырлар искә алына. Алар аның исемен төрлечә атыйлар: «ятаган», «елтага», «җатаган». Бу сүзләрнең нигезендә бер үк тамыр — җиде саны ята»: ягъни сүз җиде кыллы уен коралы турында бара.


XIX гасыр башларында Оренбург губернасында яшәүче татарларның көнкүрешен өйрәнүче А. Масловның хезмәтләрендә болай әйтелә: «татарларда гөслә еш очрый... ләкин гөсләгә кадәр аларда шуңа охшаш җиде кыллы уен коралы булган. Алар аны «етиган» дип йөртәләр». А. Маслов әлеге уен коралының якынча үлчәмнәрен дә язып калдыра. Озынлыгы 102 см, киңлеге 14 см, биеклеге 14 см. Кылларның көйләнелеше билгеле түгел. («Сибирский вестник» журналы, 1868.)

Мондый уен коралларының шулай ук Әстерхан һәм Идел-Кама төбәгендә яшәүче татарлар арасында да киң кулланылышта булуы хакында сәяхәтче И. Георги: «...алар үзләренең яткан арфага охшаш уен коралларында уйныйлар һәм аны «елтага» дип атыйлар», дип язып калдыра.

Ятаган төрки сүз. Ул ике өлештән тора: «җиде» һәм «аган». Ягъни «җиде» — кылларның саны, ә «аган» — аһәң, көй, моң дигән мәгънәне аңлата. Димәк, җиде кылның да үз моңы, үз аһәңе бар. Сәяхәтчеләр һәм фольклорчылар ятаганны чыршы агачыннан ясалган тагаракка охшаган һәм аңа төрле калынлыкта җиде кыл тарттырылган дип искә алалар.

1980 елда ятаган Арча педагогия училищесы укытучылары Ринат Алмаев һәм Ринат Гыйләҗевлар тарафыннан яңадан камилләштерелеп ясалды.

Озынлыгы 110-120 см, киңлеге тар башында 21-23 см, ә киң урыны 25-30 см. Биеклеге 8-9 см. Өске тактасының калынлыгы 3-4 мм. Кылларны боргычлар ярдәмендә тарттырып яки кыллар астындагы мендәрчекне шудыртып та көйләп була. Кыллар урынына бас балалайканың беренче һәм икенче кылларын файдаланырга мөмкин. Өске өлешенә 12 кыл тарттырылган. Кылларның көйләнелеше ре кече октавадан до диез беренче октавага кадәр. Түбәндә шул ятаганның сызымы бирелә.



Ятаганның көйләнелеше

Зур гөсләне һәм ятаганны тагын да камилләштереп ясауның зур мөмкинлекләре бар әле. Нәкъ шушындый ук тәртиптә аның берничә яңа төрен ясарга мөмкин. Әйтик, кузовның күләмен, формасын үзгәртеп карарга, кылларының саны, аларның көйләнелеше, тавышның көче, тембры өлкәсендә эзләнергә була. Кыскасы, милли музыка уен коралларыбызны чын күңелдән ихтирам итүче, яратучы энтузиаст осталар тырышлык күрсәтсәләр, бик күп уен коралларыбыз яңадан торгызылыр, тагын да камилләшер иде.

**Ринат ГЫЙЛӘҖЕВ,**
Татарстан АССР Культура министрлыгы
фәнни-методик үзәге директоры.

## *Журналыбызны кайда купме алдыралар*

ИЛЕБЕЗДӘ

| *Республикалар, өлкәләр* | *1988, № 4* | *1989, № 2* |
|---|---|---|
| РСФСР | 61 466 | 71 098 |
| Татарстан | 31 408 | 36 582 |
| Башкортстан | 16 628 | 18 249 |
| Үзбәкстан | 2 129 | 2 358 |
| Казахстан | 2 225 | 2 270 |
| Оренбург | 1 839 | 2 065 |
| Төмән | 1 350 | 1 685 |
| Свердловск | 1 341 | 1 583 |
| Пермь | 1 324 | 1 499 |
| Чиләбе | 856 | 1 001 |
| Куйбышев | 737 | 933 |
| Ульяновск | 801 | 925 |
| Мәскәү | 507 | 825 |
| Удмуртия | 675 | 810 |
| Горький | 312 | 436 |
| Кемерово | 383 | 425 |
| Киров | 336 | 392 |
| Чувашстан | 292 | 372 |
| Мари | 291 | 363 |
| Кыргызстан | 325 | 343 |
| Коми | 326 | 341 |
| Таҗикстан | 313 | 339 |
| Украина | 269 | 305 |
| Красноярск | 212 | 232 |
| Пенза | 131 | 210 |
| Төрекмәнстан | 167 | 209 |
| Омск | 176 | 193 |
| Әстерхан | 110 | 176 |
| Курган | 110 | 159 |
| Саратов | 118 | 134 |
| Якутия | 122 | 131 |
| Иркутск | 104 | 121 |
| Ленинград | 63 | 102 |
| Томск | 86 | 98 |
| Новосибирск | 69 | 73 |
| Мордовия | 48 | 72 |
| Сахалин | 58 | 68 |
| Магадан | 55 | 64 |
| Ростов | 43 | 51 |
| Хабаровск | 45 | 47 |
| Ставрополь | 36 | 46 |
| Мурманск | 43 | 45 |
| Чита | 36 | 43 |
| Камчатка | 36 | 40 |
| Приморье | 38 | 40 |
| Әзербайҗан | 33 | 37 |
| Бурятия | 32 | 36 |
| Волгоград | 26 | 35 |
| Архангельск | 18 | 30 |
| Бүтән якларда | 323 | 414 |
| СССРда | 67 005 | 77 007 |
| Чит илләрдә | 44 | 47 |
| Барысы | 67 049 | 77 054 |

ТАТАРСТАНДА

| *Районнар, шәһәрләр* | *1988, № 4* | *1989, № 2* | *мең татарга туры килә (1989)* |
|---|---|---|---|
| Арча | 1660 | 2015 | 34,4 |
| Азнакай | 1600 | 1706 | 34,5 |
| Әлмәт | 1416 | 1552 | 18,5 |
| Саба | 1315 | 1516 | 38,1 |
| Кукмара | 1102 | 1331 | 35,0 |
| Балтач | 1093 | 1318 | 56,3 |
| Актаныш | 1124 | 1207 | 36,0 |
| Сарман | 1090 | 1198 | 39,1 |
| Мамадыш | 939 | 1168 | 31,7 |
| Мөслим | 989 | 1147 | 54,4 |
| Апас | 856 | 1047 | 30,4 |
| Түбән Кама | 1028 | 991 | 10,0 |
| Октябрь | 794 | 928 | 37,7 |
| Буа | 750 | 868 | 27,0 |
| Әгерже | 626 | 728 | 30,0 |
| Лениногорск | 599 | 716 | 18,1 |
| Чистай | 588 | 716 | 24,2 |
| Тукай | 601 | 713 | 36,0 |
| Баулы | 602 | 693 | 18,0 |
| Зеленодольск | 508 | 670 | 13,0 |
| Балык Бистәсе | 501 | 651 | 25,8 |
| Биектау | 478 | 622 | 23,6 |
| Зәй | 548 | 622 | 20,7 |
| Минзәлә | 459 | 554 | 24,7 |
| Әлки | 489 | 540 | 35,3 |
| Питрәч | 512 | 517 | 35,2 |
| Бөгелмә | 368 | 410 | 12,3 |
| Чирмешән | 294 | 382 | 31,8 |
| Кама Тамагы | 315 | 380 | 38,8 |
| Яңа Чишмә | 250 | 347 | 51,0 |
| Аксубай | 266 | 331 | 22,8 |
| Чүпрәле | 275 | 326 | 16,5 |
| Лаеш | 240 | 281 | 23,4 |
| Куйбышев | 186 | 226 | 28,6 |
| Алабуга | 163 | 224 | 13,8 |
| Тәтеш | 158 | 216 | 23,7 |
| Алексеевск | 182 | 201 | 26,4 |
| Менделеев | 148 | 188 | 15,9 |
| Югары Ослан | 48 | 64 | 17,3 |
| Чаллы шәһәре | 2459 | 2411 | 16,9 |
| Казан шәһәре | 3797 | 4860 | 11,7 |
| Барысы | 31984 | 36582 | 22,1 |

### БАШКОРТСТАНДА

| Районнар, шәһәр | 1988, № 4 | 1989, № 2 |
|---|---|---|
| Туймазы | 1 299 | 1 374 |
| Краснокама | 1 096 | 1 154 |
| Дүртөйле | 917 | 925 |
| Илеш | 772 | 925 |
| Бүздәк | 705 | 788 |
| Чакмагыш | 524 | 605 |
| Миякә | 490 | 537 |
| Бакалы | 461 | 525 |
| Янавыл | 479 | 510 |
| Стәрлетамак | 444 | 506 |
| Авыргазы | 494 | 476 |
| Стәрлебаш | 391 | 472 |
| Әлшәй | 419 | 456 |
| Кушнаренко | 423 | 434 |
| Шаран | 365 | 391 |
| Борай | 373 | 382 |
| Баймак | 350 | 382 |
| Аскын | 304 | 370 |
| Ярмәкәй | 323 | 364 |
| Тәтешле | 321 | 360 |
| Бишбүләк | 317 | 347 |
| Благовар | 329 | 324 |
| Зыянчура | 261 | 287 |
| Каридел | 255 | 278 |
| Мәчетле | 224 | 269 |
| Чишмә | 236 | 266 |
| Күмертау | 218 | 264 |
| Балтач | 219 | 242 |
| Кырмыскалы | 255 | 241 |
| Кыйгы | 169 | 233 |
| Федоровка | 194 | 227 |
| Салават | 140 | 177 |
| Күгәрчен | 139 | 174 |
| Хәйбулла | 145 | 164 |
| Уфа районы | 119 | 151 |
| Дәүләкән | 136 | 146 |
| Ишембай | 131 | 145 |
| Гафури | 117 | 139 |
| Учалы | 117 | 142 |
| Бөрҗән | 129 | 133 |
| Белорет | 103 | 129 |
| Габҗәлил | 102 | 127 |
| Бәләбәй | 110 | 122 |
| Мәләвез | 100 | 119 |
| Калтасы | 93 | 97 |
| Дуван | 60 | 80 |
| Нуриман | 61 | 79 |
| Мишкә | 71 | 76 |
| Зилаер | 59 | 68 |
| Благовещенск | 60 | 60 |
| Иглин | 61 | 57 |
| Бөре | 31 | 41 |
| Белокатай | 20 | 30 |
| Архангел | 21 | 18 |
| Уфа шәһәре | 876 | 974 |
| Барысы | 16 628 | 18 249 |

## *Укучыларыбыз игътибарына*

Илебездә 1990 ел өчен газета һәм журналларга язылу дәвам итә. Укучыларыбызның үтенечен искә алып, татар телендә чыга торган вакытлы матбугат турында кыскача мәгълүмат бирәбез.

### КАЗАНДА:

Журналлар:

**Татарстан коммунисты»**
Индексы 73377
Бер елга язылу бәясе — 3 сум

**«Агитатор сүзе»**
Индексы 73946
Бер елга язылу бәясе — 1 сум 44 тиен

**«Чаян»**
Индексы 73488
Бер елга язылу бәясе — 6 сум

**«Казан утлары»**
Индексы 73210
Бер елга язылу бәясе — 10 сум 80 тиен

**«Идел»**
Индексы 73951
Бер елга язылу бәясе — 4 сум 80 тиен

**«Азат хатын»**
Индексы 73002
Бер елга язылу бәясе — 3 сум

**«Совет мәктәбе»**
Индексы 73363
Бер елга язылу бәясе — 3 сум

**«Ялкын»**
Индексы 73582
Бер елга язылу бәясе — 2 сум 40 тиен

Газеталар:

**«Социалистик Татарстан»**
Индексы 54123
Бер елга язылу бәясе — 7 сум 80 тиен

**«Татарстан яшьләре»**
Индексы 54121
Бер елга язылу бәясе — 3 сум 12 тиен

**«Яшь ленинчы»**
Индексы 54124
Бер елга язылу бәясе — 1 сум 8 тиен

### УФАДА:

**«Кызыл таң»** газетасы
Индексы 50602
Бер елга язылу бәясе — 7 сум 80 тиен

**«Агитатор блокноты»** журналы
Индексы 73864
Бер елга язылу бәясе — 1 сум 92 тиен

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

21 апрельдә Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы булды. Анда Татарстан язучыларының XI съездына әзерлек турындагы доклад белән Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Гәрәй Рәхим һәм «Казан утлары» журналында милләтара элемтәләрнең яктыртылышы турында журналның баш редакторы Ренат Харис чыгыш ясады. Фикер алышуларда Ә. Еники, Р. Ишморат, Б. Гыйззәт, А. Расих, М. Хәсәнов, Р. Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Хатипов, Д. Вәлиев, М. Вәлиев һ. б. катнашты. Йомгаклау сүзе белән Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин чыкты.

## ТУГАН ТЕЛ БӘЙРӘМЕ

23 апрельдә Татар иҗтимагый үзәге, ТАССР Халык мәгарифе министрлыгы һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты инициативасы белән Казанда «Туган тел» бәйрәме уздырылды. Сөекле шагыйребез Габдулла Тукай һәйкәле янында узган бәйрәмдә балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр һәм мәктәп укучылары Тукай шигырьләрен сөйләделәр, җырлап-биеп күңел ачтылар.

«Туган тел» бәйрәме К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында дәвам итте. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда Татар иҗтимагый үзәге үткәргән митинг бәйрәмнең үзенчәлекле дәвамы булды. Анда сүз милли традицияләрне яңарту, Татарстанга союздаш республика статусы сорау турында барды.

## ДУСЛЫК ОЧРАШУЛАРЫ

12—15 апрельдә Яр Чаллыда «Казан утлары» һәм «Агыйдел» журналларының дуслык очрашулары булды. Аларда «Агыйдел» журналының баш редакторы урынбасары Галим Хисамов, шагыйрьләр Ирек Кинъябулатов һәм Ринат Хәйри, «Казан утлары»ның баш редакторы Ренат Харис, язучылар Мөхәммәт Мәһдиев, Газиз Кашапов, Фирдәвес Бәшировалар катнашты. Дуслык очрашулары шәһәрнең 2 нче номерлы мәктәбендә, КамАЗ һәм «Татэлектромаш» заводларында, язучылар оешмасында үтте.

Язучыларны КПССның Яр Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре А. И. Логутов кабул итте.

## ИҖАДИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

12—13 апрельдә Татарстан кинематографистларының иҗади ел йомгакларына багышланган конференциясе булды. Анда катнашучылар беренче көнне Казан кинохроника студиясендә һәм Казан телевидениесендә эшләнгән документаль фильмнарны һәм киножурналларны карадылар, икенче көнне әлеге эшләр турында җитди сөйләшү булды. Фикер алышуда кино белгече Б. Клешенко (Мәскәү), Казан кинохроника студиясенең баш редакторы В. Пранов, Казан телевидениесенең программаларны тасмага төшерү редакциясе баш редакторы Л. Букштейн, киносценарист Э. Гущин, ТАССР Кинематографистлар союзы идарәсе беренче секретаре Х. Фәхретдинов һ. б. катнашты.

## БЕРЕНЧЕ

Татар халкының нибары 4 драматик театры бар иде: Г. Камал, К. Тинчурин исемендәге театрлар, Минзәлә һәм Әлмәт коллективлары. Ниһаять, узган ел бишенче театр пәйда булды. 1988 елның 17 декабре көнне «Салават күпере» исемле Беренче татар миниатюралар театры үзенең беренче тамашасын күрсәтте. Театрның баш режиссеры Батулла, директоры Ш. Галиуллин. Казан театр училищесын тәмамлаган яшь артистлар «Тузга язмаган» исемле спектакль белән беренче гастролен башлады. «Салават күпере» артистлары инде йөзгә якын спектакль күрсәтте.

Республикабыздагы күп санлы тамашачыларның ихтирамын яулаган «Зәй утлары» эстрада театры, шәһәр Советы башкарма комитеты карары белән, хуҗалык исәбендә эшли торган мөстәкыйль эстрада театр-студиясе итеп үзгәртелде. Егерме ел элек Зәй ГРЭСының профсоюз комитеты каршында оешкан бу коллектив белән беренче көненнән үк Ринат Гәрәев җитәкчелек итте. Халыкка культура хезмәте күрсәтүдәге тырышлыгы өчен ул Татарстанның атказанган культура хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек булды. Хәзер театр студиясе коллективы Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә, республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез белән очрашырга әзерләнә.

## ТАТАР ЯЗУЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

12 апрельдә Казанның М. Горький исемендәге музеенда татар язуы күргәзмәсе ачылды. Ул татар язма культурасының ерак гасырлардан алып бүгенге көнгә ка-

дәр килгән гаять бай тарихы турында сөйли. Экспозициядә рун, гарәп хәрефләре белән язылган археологик табылдыклар, хан ярлыклары, XIV-XVI гасырларга караган язма чыганаклар бар.

Мәгърифәтчелек тарихына аеруча игътибар бирелгән. Монда мәдрәсә шәкертләре кулланган математика, география, тарих дәреслекләре генә түгел, аларның дәфтәрләре дә урын алган.

Татар хатын-кызларының укымышлылыгын раслаучы экспонатлар (хатлар, фотосурәтләр, альбомнар, китаплар) күпләрдә аеруча кызыксыну уятты. Алар арасында иң кыйммәтлесе — үткән гасырның иң укымышлы хатын-кызларыннан берсе Сара Шакуловага Сорбонна университеты биргән диплом.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘКЛӘРЕ ХӘБӘРЛӘРЕ

**Мәскәү.** Башкалабыз Мәскәүдә соңгы айларда байтак кына милли культура җәмгыятьләре һәм үзәкләре төзелгән иде. Инде менә шуларга татар мәдәниятенең Мәскәү берләшмәсе дә өстәлде.

Бу берләшмәнең максаты — кунакларга Татарстан турында күбрәк мәгълүмат бирү, культурабыз мирасын киң тарату, һәр төрле кичәләр, очрашулар уздыру. Моңа кадәр үк бу өлкәдә шактый эш башкарылган булуын искәртеп китәргә кирәк. Яңа берләшмәнең исеме — «Туган тел».

**Таллинн.** Узган елның 28 октябрендә Эстония башкаласы Таллинн шәһәрендә Татар мәдәнияте җәмгыяте оешты. Тарихтан билгеле булганча, татарлар Эстония территориясендә берничә гасыр буе яшиләр һәм Эстония буржуаз республикасы дәверендә Таллинн һәм Нарва шәһәрләрендә үзләренең ике җәмгыятьләрен төзиләр. Әмма Бөек Ватан сугышы еллларында бу җәмгыятьләр таратыла, биналары җимерелә. Эстониянең культура фонды химаясендә яңадан ачылган җәмгыять татар культурасын пропагандалауны, якшәмбе мәктәбендә татар телен тирәнтен үзләштерүне максат итеп куя. Шулай ук ислам дине турында лекцияләр сериясе уздыру һәм яңа мәхәллә ачу планлаштырыла.

**Ташкент.** Партия өлкә комитеты һәм халык депутатларының өлкә Советы башкарма комитеты каршында төзелгән милләтара мөнәсәбәтләр комиссиясе членнары Ташкентта яшәүче татарлар белән очраштылар. Очрашуны партиянең өлкә комитеты секретаре, милләтара мөнәсәбәтләр комиссиясе председателе Э. И. Фазлыев алып барды. Анда Ташкент шәһәрендә татар милли культура үзәге булдыру мәсьәләсе тикшерелде. Очрашуда мәктәпләрдә татар телендә укыту өчен махсус класслар ачу, культура мирасына сак караш турындагы мәсьәләләр дә каралды.

Тәкъдимнәрне һәрьяклап тикшергәннән соң, милли культура үзәген оештыру турында карар кабул ителде.

**Оренбург.** Оренбург шәһәренең «Төзүче» культура сараенда татар һәм башкорт культурасы үзәге ачылды.

Биредә музыка-драма театры, вокаль-инструменталь ансамбль берләшмәләре, татар һәм башкорт телләрен, гарәп язуын өйрәнү буенча түгәрәкләр эшләячәк. Шулай ук милли кичәләр, производство алдынгылары белән очрашулар, конкурс-викториналар уздырылачак.

**Свердловск.** 3-8 февральдә Свердловскида һәм өлкәнең берничә шәһәрендә (Түбән Тагил, Каменск-Уральский, Первоуральск, Ревда) Татар әдәбияты көннәре уздырылды. Свердловскидагы «Урал» дип исемләнгән татар-башкорт иҗтимагый культура җәмгыяте һәм өлкә китап сөючеләр җәмгыяте тарафыннан оештырылган бу бәйрәмдә Казаннан шагыйрьләр М. Хөсәен, Э. Шәрифуллина һәм прозаик Т. Әйди катнашты. Очрашулар вакытында алар халыкны әдәби яңалыклар белән таныштырдылар, үзгәртеп коруның милли культурабызны үстерүгә уңай йогынты ясавы, Татарстанның иҗтимагый тормышы турында сөйләделәр.

**Киев.** Киевта эшләүче «Болгар» татар клубы һәм шундагы университет чакыруы белән Казан дәүләт университетының «Каз канаты» ансамбле күптән түгел Украина ССР башкаласында кунакта булып кайтты. Биредә студентларның бию ансамблен җылы каршыладылар, концерт заллары һәрвакыт тулы булды. Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки шәһәрдә егерме мең татар яши.

«Болгар» клубы эшли торган Халыклар дуслыгы китапханәсе студентларга аеруча ошады. Татарча байтак китаплар саклана торган бу китапханәгә хәзерге вакытта татар телендә чыга торган газета-журналларның һәрберсе диярлек килә.

**Куйбышев.** Куйбышев өлкәсе үзәгендә — Куйбышев шәһәрендә «Туган тел» дигән татар культура үзәге төзелде. Ул үз карамагында татар китапханәсе булдыруны да максат итеп куйды, хәзер аңа китаплар туплана. Бу эштә Татарстан Язучылар союзы идарәсе беренче ярдәмне күрсәтте. Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, Җәүдәт Дәрзаманов, Марат Әмирханов кебек шагыйрьләр һәм язучылар үзләренең шәхси китапханәләреннән дә китаплар бүләк иттеләр. «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе дә культура үзәге китапханәсенә шактый гына китап тапшырды.

## Т. МИҢНУЛЛИН — СССР ХАЛЫК ДЕПУТАТЫ

643 нче Кукмара милли-территориаль сайлау округы буенча СССР халык депутаты итеп Казан шәһәрендә яшәүче, Татарстан АССР Язучылар союзы идарәсе председателе, КПСС члены Миңнуллин Туфан Абдуллович сайланды.

# Сәйдәш моңнары

**Мәхмүт Хөсәен** сүзләре

**Әнвәр Бакиров** музыкасы.

Назлый Идел дулкыннарын
Кояш нурлары.
Кояш нурларыдай җылы
Сәйдәш моңнары.

Сандугач сайрап уята
Урман-кырларны.
Сандугачтай сокландыра
Сәйдәш моңнары.

Сәйдәш җырларына гашыйк
Илнең уллары.
Күңелләрдә мәңге яши
Сәйдәш моңнары.

**Бу җырның гонорарын Салих Сәйдәшевкә һәйкәл салу фондына күчерәбез.**

**Авторлар.**

Хөрмәтле укучылар, музыка сөюче дуслар!

Мәгълүм булганча, 1990 елда күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшевнең тууына 90 ел тулачак. Аның истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән, республикабыз башкаласында һәйкәл ачу күздә тотыла. Һәйкәлне булдыруга Сез дә хәлегездән килгәнчә өлеш кертә аласыз. Акчалата ярдәмне түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

**г. Казань, Татарская контора Жилсоцбанка, расчетный счет № 702203 республиканского отделения фонда культуры. На памятник С. Сайдашеву.**

**(Салих Сәйдәшевнең мирас комиссиясе)**

**ИГЪТИБАР!**

Үткән елның тугызынчы саныннан башлап журналыбызда гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку һәм язу дәресләре бирелеп килде. Бишенче санда сез аларның тугызынчысы белән таныштыгыз.

Борынгы имлабызны өйрәнергә теләүчеләрнең күпсанлы теләкләрен искә алып, без быелның тугызынчы саныннан яңадан гарәп әлифбасы нигезендә уку һәм язу күнекмәләре бирә башлаячакбыз.

Туган телебезнең тарихына караган махсус әдәбият белән танышу сезгә бу өлкәдәге белемегезне тирәнәйтергә ярдәм итәр. Түбәндә ул хезмәтләрнең кыскача исемлеге тәкъдим ителә.



**Курбатов Х.** Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан, 1960.
**Госманов М. Г.** Иске татар язуы нигезләре. I кисәк. Казан, 1983.
**Зәкиев М.** Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан, 1977.
**Ногман М.** Иске татар язуы үрнәкләре. Казан, 1971.
**Хангилдин В. Н.** Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан, 1976.
**Хәмзин К. З., Мәхмүдов М. И., Сәйфуллин Г. Ш.** Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан, 1965.
**Хаков В. Х.** Татар әдәби теле тарихы буенча очерклар. Казан, 1965.


## *— Тышлыктагы сурәтләр*

**Беренче биттә:** «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары» журналларының төрле елларда чыккан саннары.

**Дүртенче биттә:** Борынгы Казан күренешләре. Җәмигъ мәчет. XIX йөз инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.




Искәрмә: ялгыз да, дуэт һәм хор белән дә җырларга мөмкин.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)**